# КАЗАН УТЛАРЫ

11.1990



## «Социалистик Татарстан» газетасы

Республикабыз язучыларының әле яңа гына язылган шигырь һәм хикәяләрен, повесть-романнарыннан өзекләрен, йөрәк түреннән чыккан публицистик мәкаләләрен укыйсыгыз, әдәбият-сәнгатебезгә, мәдәниятыбызга, тарихыбызга, телебезгә, гореф-гадәтләребезгә кагылышлы кызыклы һәм гыйбрәтле язмалар белән танышасыгыз, атна саен «Әллүки» кушымтасын кулыгызга аласыгыз килсә, «Социалистик Татарстан» газетасына язылыгыз.

Газетаны, әлбәттә, «Союзпечать» киоскларыннан да сатып алырга була. Ләкин бу очракта һәр көнне шактый вакытыгыз исраф булачак, өстәвенә әле газеталарның сатылып бетүе һәм сезнең көндәлек матбугатсыз калуыгыз ихтимал. Ә инде сатуга чыгарылган газеталарның бәяләре шактыйга кыйммәткә торуын да исегезгә төшерсәк, «Социалистик Татарстан»ны өегезгә алдыруның күпкә файдалырак булуын төшенерсез.

Газетага Яңа елдан языларга соңга калдым инде, дип һич тә борчылмагыз, аны февраль, март аеннан да алдыра башларга була.

**Газетаның индексы —54123.**
**Еллык язылу бәясе —14 сум 04 тиен.**

## «Татарстан яшьләре» киңәш итә

Бу юллар язылганда Казанның Үзәк колхоз базарында 7 сум 80 тиенгә («Татарстан яшьләре» газетасына еллык язылу бәясе) ярты кило чамасы сыер ите яисә тавык түшкәсенең өчтән бер өлешен, бер кадак бал, ике-өч лимон яисә бер килодан чак кына артык тозлы кыяр алып була иде.

Әлеге саннар тирәсендә фәлсәфә куертып тормастан, укучыларга киңәш бирәбез: әгәр гаиләгезне җан азыгы белән дә тәэмин итәргә ниятләсәгез һәм аның өегезгә ел дәвамында үз аягы белән килеп торуын теләсәгез, «Татарстан яшьләре»нә язылыгыз.

Яшьләргә хас кыюлык һәм тәвәккәллек, хисләр кайнарлыгы һәм әчкерсезлек, күпләр сагынып көтеп алучы «Сердәш», «Сезнең хатлар» сәхифәләре, тормыш-көнкүреш хәлләрен яктырткан кызыклы һәм гыйбрәтле мәкаләләр, Казан һәм Мәскәүнең атналык телевидение программасы, милли сәясәт, экономика һәм милли бәйләнешләр темасына язмалар, «кайнар ноктлардан» репортажлар, яңа җырлар — болар барысы да — «Татарстан яшьләре».

**Газетаның индексы —54121.**

*(Ахыры тышлыкның өченче битендә)*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАИ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1990

11

(817)

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Г. МОРАТ.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . 3
**М. МАЛИКОВА.** Фидая. *Роман* . . . . . . 7
**Р. ХАРИС.** Көмеш нур. *Шигырьләр* . . . . 84
**Г. САДӘ.** Төнге кошлар. *Шигырьләр* . . . . 88
**Г. ҮЗИЛЕ.** Гыйфрит. *Роман-дилогия* . . . 91
**К. БУЛАТОВА.** Күктүбә дәфтәреннән яңа шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 138
**Н. МАДЬЯРОВ.** Дулкын таулары эчендә. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 142

ПУБЛИЦИСТИКА

**А. ХӘЛИМ.** Иле барның теле бар . . . . . 144
**Җ. РӘХИМОВ.** Акланмаган өмет . . . . . 160

КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

Сүрәтү Иасин . . . . . . . . . . . . 166

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

**Р. МОСТАФИН.** Телебез ярлы түгел! . . . . 179

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

**Э. СӘГЫЙДОВА.** Галим, педагог, журналист . 185
**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.** Гафур Коләхмәтевның яңа табылган хаты . . . . . . . . . . . . 187

Котлыйбыз . . . . . . . . . . . . . 159
Безнең календарь . . . . . . . . . . 178
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

ТАТАРСТАН
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Поэзия и проза»: новые стихи Г. МУРАТОВА, Р. ХАРИСА, Г. САДЭ, К. БУЛАТОВОЙ, Н. МАДЬЯРОВА; окончание романа М. МАЛИКОВОЙ «Фидая», начало романа Г. КАШАПОВА «Чудовище».
«Публицистика»: известный татарский поэт А. ХАЛИМ размышляет о судьбе татар, проживающих в Башкирии; статья З. РАХИМОВА «Неоправданная надежда».
Суры из Корана.
«Острая проблема»: отклик-рецензия Р. МОСТАФИНА на книгу «Русско-татарский словарь».
«К истории культуры»: статья Э. САГИДОВОЙ о педагоге, журналисте К. Сагидове.
Х. ГУБАЙДУЛЛИН «Неизвестное письмо Г. Кулахметова».
Хроника культурной жизни.
На наших обложках: исторический памятник Оренбурга «Караван-сарай»; известный писатель, лауреат государственной премии Г. Тукая И. Салахов.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 10.10.1990 ел. Басарга кул куелды 20.11.1990 ел. Офсет ысулы белән басылы. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83044. Заказ Д-420. Бәясе 90 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

## Газинур Морат

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Азан

Азан вакыты.
Үз моңы,
Үз зары бар азанның.
Тәңресе белән серләшер,
Берләшер чагы җанның.

Азан вакыты.
Күкләрдән
Коела төннең көле.
Халкым минем дога кылып
Каршылаган һәр көнне.

Ни кылса да, халкым эшне
Бисмилладан башлаган.
Шуңа исән чыккандыр ул
Әҗәл дигән басмадан.

Азан вакыты.
Намазга
Дәшә Таң, дәшә Иман.
...Бабамны азан уяткан,
Мине уята Гимн.

Азан вакыты.
Заманга
Иман иңдерер чаклар!
Ак намазлык өсләренә
Башың идерер чаклар!

Ә бит булган шундый заман —
Сүндереп Ай, Кояшны,
Ак намазлык өсләрендә
Уйнаганнар уйнашлы.

Тәмугка олактырганнар
Абыстаен, мулласын...

---

Газинур МОРАТ *(1959) — шагыйрь, «Җир хәтере», «Мин дөньяны тыңлыйм», «Тылсымлы тел» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Кемдер, димәк, Унҗидедә
Әйтергә бисмилласын

Оныткан булган.
Шуңадыр
Гөнаһлар — ашкан баштан.
Диктатураның холкы бер:
Көчләгән, кискән, аскан...

Диктатураның холкы бер,
Бер үк — кай заманда да...
Казанда — азан вакыты,
Дәшә мәзин намазга.

Азан вакыты.
Үз моңы,
Үз зары бар азанның.
Дөньялык белән бергә-бер
Аңлашыр чагы җанның.

## Черек күл

Черек күлгә кармак салдым,
Еллар аша үрелеп.
Айкалды күл, чайкалды күл,—
Сере китте түгелеп.

Айкалды күл, чайкалды күл,
Чайпалды күңелләрем.
Татарның күпме затлысы
Чүплеккә түгелгәнен

Уйладым да уем качты.
Текәлдем калкавычка...
Котылсын заман — сәяси
Капкыннан, алдавычтан.

Кешенең кадере булсын,
Кабере булсын җирдә.
Саклансын заман — капмасын
Кабаттан сыйнфый җимгә.

«Шагыйрьләрнең каберләрен
Эзлим»,— дип язган дустым,
Киләчәккә зират аша
Синме карарга куштың?!

Күпме табут кайтты илгә,—
Күпмесе — безгә кордаш...
Кай зиратта ята, димсең,
Якташың Фәтхи Борнаш?

Кай зиратта ята, димсең,
Хөр уйлы гали җаннар —
Мирсәет Солтангалиев,
Тинчурин, Галимҗаннар?..

Шигырьгә күчәдер — җанга
Сыймаган борчу, кайгың...
Ярый әле яд итәргә
Кабере бар Тукайның.

Кадере бар... Шөкер әйтеп
Коенабыз данында.
Кабере бар...
Яшәсә дә
Халыклар зинданында.

Ә бит кемнәрдер синең дә
Шәхесеңә тукына.
...Черек күлдә дога кылдым
Шәһитләр рухына.

## Кичәге көн батырлары

Кыюлык хупланган чакта
Һәркем чыгар алышка...
Кичәге көн батырлары
Бүген дә бил алыша.

Кичәге көн батырлары
Батыр икән һаман да.
Алышалар...
Кичәге көн,
Әйтерсең, булмаган да.

Алышалар... Алышларның
Алымы инде үзгә.
Ятлап нотык сөйли-сөйли
Май яза алар сүздән.

Бик тә дөрес сөйли алар,
Хаталанмый ялгыш та.
Кичәге көн батырлары
Кыюлыкта алыша.

Казна караклары илнең
Күз нурын урлаганда,
Куркаклыкта бил алышу,
Әйтерсең, булмаган да.

Кичәге көн батырлары
Һаман хаклык сагында.
Гаделлектә алышалар
Тәүбә итәр чагында.

Кичәге көн батырлары
Бүген дә үз көчендә.
Һай, зур батырлыклар кирәк
Тәүбә итәр өчен дә.

Кичәге көн батырлары —
Батыр бу заманда да.
Алышалар...
Кичәге көн,
Әйтерсең, булмаган да...

## Сәяси сорау

Һәрбер ялган — дөрес булып
Күренә генә.
Ялганга ышанмый халык —
Күнегә генә.

Ник алайса ялган
Илнең
Түренә менә?..

## Балбаллар иле

Бу илдә табынып кына
Яшиләр: һәрбер чатта
Балбаллар. Кайсы — иләмән,
Кайсы атланган атка.—

Кулында — кылыч. Билендә —
Алтатары. Кичәге.
Ничә җанны кыйды икән
Бу алтатар, ничәне?

Кемнәр каны саркый икән
Кылычы кынысыннан?..
Әмер генә булсын — җайдак
Кабат яу чабар сыман.

Кабат яу чабар сыман ул —
Индерелсен тик әмер...
Илдә таш балбал ишәйсә,
Башларга бетә кадер.

Илдә балбаллар ишәйсә,
Кадер бетә аллага...
Ә бу илдә көн итәләр
Табынып таш балбалга.

## Тузга язылмаган сүзләр

Тузга язмаганны сөйләмә, дип
Өйрәткәннәр иде әдәпкә —
Тузга язылмаган сүзләр эзлим,
Җаным бүген шундый халәттә.

Тузга язылмаган сүзләр эзлим
Туган телем — туңган телемнән.
Тузга язылганны сөйли-сөйли
Телсез кала яздык ил белән.

Тузга язылмаган сүзләр эзлим
(Кем эзлидер шәраб, колбаса...)
Тузга язылганны укый-укый
Томанага калдык лабаса.

Тузга язылмаган сүзләр эзлим.
Тел сәүдәсе гөрли базарда.
Тузга язылганны яза-яза
Өйрәндек ич донос язарга.

Тузга язылганны тукый-тукый
Өйрәттеләр ләса түземгә...
Тузга язылмаган һәрбер сүзне
Эзләп табу кирәк үзеңнән.

Түрә әнә түргә элеп куйды:
«Син үзеңнән башла ислахны»...
Тузга язмаганны сөйләр өчен
Кайтты илгә Гаяз Исхакый.

Тузга язмаганны сөйләмә, дип
Өйрәттеләр юкса әдәпкә,—
Тузга язылмаган сүзләр эзлим —
Дөньям бүген шундый халәттә.

# Чәчмә әсәрләр

## Мәдинә Маликова

# ФИДАЯ

РОМАН

23



Ишегалдын уң яктан ышыклап тезелеп баскан тупыллар бөтен буйларына ыңгырашып чайкалалар һәм көзге кыраулардан көйгән яфракларын өзгәләп искән ачы җилдән зарланалар. Ләкин Фидаяга, күпме генә зарланса да, беркем дә ярдәм итмәячәк. Хәтта райбашкарма рәисе Искәндәров тә, Нурханова аңа Мирхуҗиннан зарланмакчы булып караган иде инде.

Искәндәров, күзлеген маңгаеннан төшереп, рәтләштереп куйды да, үзалдына, өстәлдәге кәгазьләргә карап:

— Мирхуҗин кебекләр районда күбрәк булса, без республикада күптән беренче булыр идек инде,— диде.— Уңган, өлгер, теләгәнен таба, әйткәнен эшли.

— Хикмәт шунда, ни тели бит ул...— Фидая киная белән башлаган иде, Искәндәров башын күтәрми генә, әмма тавышын көчәйтә төшеп әйтте:

— Без эш-төзелеш мәйданындагы теләкләр турында гына сөйли алабыз,— диде.— Калганына тыкшынырга хакыбыз юк. Моңарчы үз хатыны да, кеше хатыны да елап килгәне юк бит әле!

Фидая, урынсыз кинаясе өчен оялып, кызарып чыкты, бөтен тәне эсселәнде. Чыннан да, Мирхуҗинны әхлаксызлыкта гаепләргә ни хокукы бар аның?

Искәндәров күтәрелеп карамады, ләкин аның кичерешләрен сизеп алды. Тавышын йомшартып, алдындагы кәгазьләрне тәртипкә салган арада:

— Без шул барыбыз да кешедән гаеп эзләргә остарып киттек. Эшләгәннең кадерен белү җитми,— диде.— Син аның кырык яшен ничек билгеләп үтәргә икәнлеген ныклап уйладыңмы соң әле?

Фидая югалып калды: Мирхуҗинга кырык яшь тула микәнни? Кайчан икән аның туган көне? Нишләп берәү дә әйтми?

— Сигезенче мартта туган ул,— диде Искәндәров.— Моның ишеләрне син үзең алдан белеп, минем исемә төшереп йөрергә тиеш. Зурлап билгеләп үтәргә кирәк Мирхуҗинның юбилеен. Ныклап уйларга кирәк. Нинди бүләк бирергә? Орденга тәкъдим итәргәме, әллә исем бирергәме? Аның «Почет билгесе», медальләре бар инде. Син

---

Ахыры. Башы 10 нчы санда.

менә, бик турыдан бәрмичә генә, үзенең кылын тартып кара, күңеле ни тели икән? Аннары бик матур итеп характеристика язарсың. Югары оешмалар кире кайтарырлык булмасын. Моны да белеп эшләргә кирәк, югыйсә, без кайчакта, кешенең күңелен күрәм дип, кәефен кырып ташлыйбыз.

Урынына утыртты председатель үзенең урынбасарын һәм шул ук вакытта аңа хәрәкәт итү юнәлешен дә бик матур итеп ачып бирде. Икенче очрашканда Мирхуҗин белән ачылып, елмаеп сөйләшергә тулы нигез бар иде инде. Табис үзе мактаулы исемне хуп күрә икән, чөнки бишьеллык тәмамлангач, лаеклы кешеләрне орден-медальләр белән бүләкләргә аерым бер мөмкинлек булачак әле. Нурханова аңа характеристиканы үз кулы белән язачагын да сиздереп куйды. Мөнәсәбәтләр җайланды: Мирхуҗин ел башыннан Кармаш төзелешенә ташчылар бригадасы җибәрде.

Хәзер инде ул бригаданы өзлексез эшләтү — кирпеч, измә белән туктаусыз тәэмин итү, ашау-эчү, яшәү шартларын кайгыртып тору кирәк иде. Ләкин ике көн дә үтмәде, ташчылар бригадиры Нурханованың үзенә — Фидая шулай кушкан иде, берәр көйсезлек чыкса, турыдан-туры үземә шылтыратыгыз, дигән иде — телефоннан, измәне кирәгенчә ясап өлгертмиләр, ашарга рәтләп әзерләмиләр, дип, канәгатьсез тавыш белән зарланды.

Монысын инде урында баш врач карарга тиеш иде. Фидая аның белән телефоннан түгел, үзен күреп сөйләшергә булды.

Урамның каршы ягында мунча салынып беткән, бер мичен чыгарып та куйганнар, икенчесенә керешкәннәр икән инде. Бу эшкә Газимов бөтен районда дан тоткан телсез Зөфәрне чакырган. Ул ашыгып эшләми, ләкин җиренә җиткереп сала, мунча шәп булачак иде. Фидая, аның янына кереп, кулларын буташтырып сөйләшеп алды: Зөфәр, олыгаеп килгән таза гәүдәле, тыныч, киң чырайлы ир кеше, больница ягына кулын изәп, начар, начар, дип, тамак төбенең бер читеннән генә чыккан нечкә аваз белән әйтеп куйды һәм, чыннан да начар икәнен аңлатып, башын чайкады.

Ташчыларның эше начар гына түгел, бөтенләй туктаган булып чыкты. Алар эссе итеп ягылган бер бүлмәдә, такта өстәлдә домино сугып утыралар иде.

Сөйләшү шактый ук күңелсез килеп чыкты: ташчылар, бер-берсен бүлә-бүлә, бу хәлгә бүтән түзеп тормаячакларын, әгәр кирпеч белән измә китерелмәсә, иртәгә үк китеп барачакларын әйттеләр. Алар — читтән ялланган кешеләр, эш хакын көн үткәнгә түгел, башкарган эшкә карап алалар. Монда өстәл төеп нишләп утырсыннар!

Ни карый Билал? Нигә чарасын күрми, ник ичмасам өзеклек буласын алданрак хәбәр итми?

Фидая, больница ишеген каерып ачып, шакылдап барып керде, итәгенә сарган карны ишек төбендә дөп-дөп басып какты. Әмма бу тавышка игътибар итүче, аңа каршы чыгучы булмады.

Фидая өлкән медсестра бүлмәсенә юнәлде.

— Әкренрәк!— дип, кашларын җыерып каршы алды аны ак башлыгын маңгаена ук төшергән Гөлфия.

— Билал кая? — диде Фидая, аның белән кыска гына исәнләшкәч.

— Юк Билал!

— Ничек юк, кая китте?

— Бетеп килә Билал!— диде Гөлфия, ачулы пышылдау аша. Үзе, Фидаяга карамый гына, пыяла шкафындагы кәкре-бөкре тимерләрне — хирургия инструментларын рәтләштергәндәй итте.

— Рәтләп кенә аңлат әле, бу ни дигән сүз?

— Бу — синең теләгең кабул булды дигән сүз! Ни теләгән идең соң син Билалга, ә? Әллә оныттың дамы?

Ул, каты-каты басып, ишек янындагы почмакта торган озын ак шкаф янына килде, аны ачып, халат белән башлык алды да Фидаяга тондырды:

— Мә, ки!

Фидая, берни аңламыйча, өстен алыштырды: халат белән башлыкны киде, итекләрен салып, аякларын артсыз зур күн башмакларга тыкты. Ә Гөлфия, әле һаман кашын-күзен җимереп, сипкелләрен чекрәйтеп, читтәнрәк карап тора, ул инде иягенә марля битлек асып куйган, икенче битлекне, Фидая өчен булса кирәк, кулына тоткан иде. Фидая, аны алып, авыз-борынын каплап бәйләде. Ул әле һаман үзен ник болай киендергәннәрен аңлап җиткерми иде.

— Әйдә!

Гөлфия аны операция бүлмәсенә таба алып китте.

Өске өлешендәге пыяла турына эчтән ак пәрдә капланган ишекне ачуга, Фидаяның тезләре йомшап китте; ул, егылмас өчен, ишек яңагына тотынды: анда, озын ятакта, кайчандыр Мәгъсүм яткан төштә, нәкъ шундый ук тимер терәкләр, көпшәләр арасында, ак җәймә өстендә берәү ята иде. Фидаяның бугазына нәрсәдер килеп бөялде: узганнар кире әйләнеп кайткандай тоелды.

Фидая күзләрен йомды. Бу... мөмкин түгел... Мөмкин түгел...

— Син нәрсә, Гөлфия, кешенең котын алып йөрисең? Әйттем бит мин сиңа, берегез дә кермәгез дип!

Бусы йомшак тавыш, Билал тавышы иде. Фидая күзләрен ачты, ятактан башын борып, аңа Билал үзе карап ята иде. Менә ул тимер терәктәге банкадан сузылган көпшә очындагы энәне беләгеннән алды да терсәген бөгеп тотты. Гөлфиягә:

— Тампон бир әле,— диде. Торып утырды.

Фидая аңына килә башлаган иде инде. Ул, йөзеннән битлеген тартып алды да, сулышына буылып:

— Бу ни дигән сүз?— дип сорады.

— Профилактик чара гына бу,— диде Билал, аягына басып.

Гөлфия алар арасына кереп туктады. Фидаяның күзләренә тишәрдәй итеп карады — аның күзләре яшел һәм аяусыз икән.

— Син чакырып китергән хәл бу,— диде.— Кара, кинән, сөен! Теге чакта ниләр генә кыланмадың, ниләр генә әйтеп бетермәдең, ә бит Билал үзе җанын бирердәй булган иде! Ни дип белдегез сез врачны? Һәр үлгән артыннан үзе җан биргәндәй була бит врач! Ул чакта синең кайгыларыңны өчәүләп күтәргән идек, бу юлы куанычы сиңа гына булсын инде, рәхәтлән!

Нәкъ шушы бүлмәдә, нәкъ шушы урында, сүзләре дә шул ук бугай, тик әйтүчесе генә алышынган!

— Гөлфия, тукта, ни сөйлисең син? Хомана карчык түгел бит, адәм көлдермә,— диде Билал, гадәтенчә йомшак итеп.

— Көлүдән узды бит инде, нишләтәсең син үзеңне?— диде аңа Гөлфия еламсырап.— Бетерәләр бит инде, бөтенләй юкка чыгаралар! Больницада берүзең, ишшу җитмәсә, шундый зур төзелешкә җиктеләр, бу чирең дә аза бара, аза бара! Чирен яшергән үлгән, ди, яшермим дә, нитмим дә моннан ары!

Ул, битен ике кулы белән каплап, бүлмәдән йөгереп чыгып китте.

Ә Билал сер бирмәскә тырыша, кыяфәте алай бер дә чирле кешегә охшамаган иде. Фидая да бераз тынычлана төште, алай да, халатын салып пальтосын-итекләрен кигәндә, аның куллары калтырый иде әле. Ул тизрәк тышка, болытлап торса да якты, салкын, сулышларны иркенәйтә торган дөньяга, иркенлеккә чыгарга ашыга иде. Билал да халаты өстеннән пальтосын киде, бүреген эләктерде, Фидая белән чыкты.

Ул арада измәне китергәннәр, ташчылар да, озак көттергән өчен ачулары килгәнлекне күрсәтеп, әкрен генә, атлар-атламас дигәндәй, бина ишегеннән килеп чыктылар, котельныйның аргы башында күтәрә башлаган стеналары янына киттеләр.

— Биредә ни була соң?— дип сорады Фидая.

— Морг,— диде кыска гына итеп Билал.

— Ә тегесе?

— Анысы да морг.

— Нигә сезгә ике морг?

— Берсен склад итәрбез, бәлки.

Фидая шәрәләнеп торган кызыл кирпеч стеналарга ямансулап карады: кемнәрдер шушында кереп ятачак... Бүген җирдә йөри, эшли, күңел ача, уйлый, куана, сөя, ачулана — мең мәшәкать кичерә, мең төрле хисләр белән яна торган кешеләрнең кайберләре озакламый җансыз, хиссез булып, берни тоймый-белми торган җисем булып шушында кереп ятачак, кемнәрдер ул тарафка үзәге өзелеп карап торачак. Кайчандыр теге ярым җимерек куышка Фидая үзе карап торган шикелле.

Аның Билалга рәнҗеп әйткән сүзләре исенә төште: «Миңа килгәннәр сезнең үз башыгызга төшсен, мин күргәннәрне сез дә күрегез!..» Әллә, чыннан да, каргыш төшә микән? Фидая Газимовка борылып карады: аның йөзе картайган, суырылган, күгәргән кебек тоелды. Бәлки, моңарчы Фидая бу үзгәрешләрне күрми-сизми генә йөргәндер: теге чактан бирле аңа Газимовның чыраена текәлеп карау да, аның белән ачылып сөйләшү дә бик авыр, ул үзен мәҗбүр итеп, хисләрен яшереп кенә аралаша бу кеше белән, шуңа күрә андагы үзгәрешләрне дә күрми килгәндер.

— Сезгә ни булды?— дип сорады Фидая.

Билалның сүзе бүленде: ул үзен гаепле саный, кичә дә, бүген иртүк тә, Мирхуҗинга шылтыратып, хәлне аңлатканын, Мирхуҗинның иртүк машина җибәрергә вәгъдә иткәнен, ләкин ни сәбәптәндер сүзендә тормаганын сөйләп маташа иде; аклануын ярты сүздә бүлеп, Фидаяга карады, ниһаять, аның ни хакта сораганын, төшенеп:

— Хәл китеп тора кайчакта,— диде.

— Күптәнме?

— Сез врач түгел бит,— диде Билал, моңсу гына елмаеп.— Анысын үзебез карарбыз инде, Фидая Госмановна, үзем табип кеше...

— Табип авырса, башка табипка барырга тиеш. Сез бардыгызмы соң?

Билалның бу хакта сөйләшәсе килми иде. Фидая тагын тәрәзәсез стенага — булачак моргка карады. Беренче булып анда Билал үзе кереп ятса?

— Мин сезне Казанга җибәрәм,— диде Фидая.

Билал көлде:

— Юкны сөйләмәгез, Фидая Госмановна. Минем иртәгә иртәнгә билгеләнгән операциям бар.

— Операция көтә ул...

— Бездә андый гадәт юк, Фидая Госмановна. Әгәр ул операцияне көтеп ятучы сез үзегез йә берәр якыныгыз булса? Ә мин нәкъ шул сәгатендә китеп барсам?..

Фидая аңа күзләрен тутырып карады, аның: «Син тагын мине каргар идең бит...» — дигәнен көтте, әмма Билал шунда туктады, дәвам итмәде. Көлемсерәде дә ташчыларга таба атлады.

Ул үзе Казанга китмәячәк. Һәрхәлдә, тиз генә бармаячак. Кайчаннан бирле шушылай кан тамырына дарулар салып хәлләнә икән ул? Авыруы кайчан башланган икән? Гөлфиядән сорарга кирәк иде, ә Гөлфия Фидая белән тыныч сөйләшмәячәк.

Юлда кайтканда Фидая мондый карарга килде: Казаннан врач-

ларны монда чакырып китерергә кирәк. Килеп төшсәләр, Билал үзен каратмыйча кала алмаячак. Әгәр куркыныч чире юк икән, бик әйбәт. Әмма... Гөлфия күпне белә һәм һич тә юкка гына борчылмас...

Шулай булып чыкты да.

Казаннан килгән врачлар Газимовта шактый ук нык азган кан чире таптылар һәм үзләре белән алып киттеләр.

Икенче көнне Нурханова Казан белән сөйләште: андагы врач, авыруга шактый вакыт дәвамында кан салып торырга кирәклеген әйтеп:

— Донорлар табуда ярдәм итсәгез, яхшы булыр иде,— диде.

Кан бирердәй кешеләрне каян, ничек эзләргә?

Иң ачы хәсрәтләр алып килгән салкын, җилле май көннәре кире әйләнеп кайткандай булды. Чарасыз калырга да ярамый, нидер эшләргә кирәк иде. Фидая телефон трубкасын күтәрде һәм... «Үзәк»не алды.

Нигә «Үзәк»не? Теге чакта, больница ишеге төбендә, Мәгъсүмгә кан бирергә дип тезелеп баскан егетләр искә төшкәндер, бәлки?

Ул трубкадан тизрәк таныш тавыш ишетелгәнен көтте. Ләкин аннан шактый озак вакыт озын-озын чинау гына ишетелеп торды. Фидая гүяки ике араны тоташтырган озын чыбыклар аша чылтырап утырган кызыл телефон аппаратын күрә, алай гына түгел, зур, елтыравык өстәлләрне, алар тирәли тезелгән урындыкларны, бер ягын тоташ китап шкафлары биләгән зур бүлмәне күрә иде. Бүлмә буш, аның хуҗасы урам як капкадан кереп кенә килә. Ул кызыл аппаратның әледән-әле сузып-сузып зыңгылдаганын ишетми, ләкин күңеле сизә, шуңа күрә ике ягына биек итеп кар көртләре өелгән сукмактан эре-эре атлый. Әнә, инде өенең почмагыннан борыла. Почмак турыннан тутыккан торба сузылып төшкән, аның аскы очы җирдән ике метр чамасы биеклектә. Бервакыт аның турыннан узганда Давыт үзе бәрелмәскә башын иде һәм, артыннанрак килгән Фидаяга борылып: «Башыгызны бәрә күрмәгез!»— дип көлде. Фидая аңа шулай ук елмаеп җавап биргән иде: «Үсәм әле мин, үсәм!» Почмакның ишегалды ягына зур гына плакат эленгән, анда авыл өендәге мич һәм аның авызыннан ургылып чыккан янгын телләре тасвирланган, астына эре-эре хәрефләр белән: «Төзексез мичкә яксаң, менә шулай була ул!»— дип язылган.

Әгәр Фидаяның йөрәгеннән үрләгән ялкын күзгә күренә торган булса, шул рәсемдәгедән ким булмас иде.

— Тыңлыйм, Гаяров!

Фидая күз алдына китергәннәр әллә чыннан да дөрес булды инде — Давытның сулышына кабып сөйләгәне сизелде. Ә шулай да аның җавабы сискәндереп җибәрде. Сулыш киселде: Фидая, тавышы үзгәрәчәген тоеп, тиз генә сүз әйтә алмады.

— Алло! «Үзәк» тыңлый!

Фидая житди дә, шул ук вакытта үзенең хезмәт вазифасын үтәгәндәй җиңел дә сөйләшергә тырышты. Кан тапшыручылар эзләп район үзәгеннән нәкъ менә Баллыболынга мөрәҗәгать итүләре бераз сәер тоелуы ихтимал иде, әмма Гаяров моны табигый дип тапты, гаҗәпләнмәде, хәзер үк егетләргә хәбәр итәчәген әйтте.

— Үзем контрольдә тотармын,— диде.— Машинасын бирермен, кешеләрне җибәрермен. Казанга озату ягын сез кайгыртырсыз,— диде.

Сөйләшү эшлекле тонда барды, әмма Фидая, үзенең ихтыярсыздан аннан яшерен бер мәгънә эзләгәнен тоеп, трубканы куйгач та үзалдына кызарынды: «Нигә соң мин аңа шалтыраттым әле?»— дип үкенә үк башлады.

Гөнаһлы уйлар иде бу һәм Фидая алардан тизрәк арынырга тырышты. Ул фәкать эш турында гына уйларга, шуны гына кай-

гыртырга тиеш. Ә Газимов Казанда чакта эш икеләтә авыр булачак. Фидая Мирхуҗин янына үзе барып кайтырга булды.

Һичек тә аны больница төзелешен эшнең үзәгенә куярга мәҗбүр итәргә кирәк иде. Сүз арасында Фидая:

— Әле минә үзегезне бик зурларга ниятләдек, юбилеегыз матур итеп уздырылачак, характеристиканы бик әйбәт итеп яздык, моннан соң мин тиешле оешмалардан нәтиҗәсен белешеп торырмын,— диде.

Таҗис, күзләрен кыса төшеп, өздереп, мәгънәле итеп карады:

— Их, Фидая Госмановна, сез мине исем өчен, бүләк өчен тырыша дип белдегезме әллә?— диде.— Әгәр алай уйлыйсыз икән, бик нык ялгышасыз. Мин дәрәҗә дип тырмаша торганнардан түгел. Кешеләрнең чын күңелдән, ихластан әйткән рәхмәте — иң зур бүләк. Әгәр минә сез эшләгәннең кадерен белсәгез, без бер-беребезне аңлашып яшәсәк, шуннан ары ни кирәк тагын?

Ул, урындыгыннан калкына төшеп, үзенә яны беләнрәк утырган Фидаяның өстәлдә яткан кулларына зур, симез, көчле, юан бармаклы кулын куйды. Фидаяның беренче омтылышы — ниндидер чиркандыргыч хәшәрәт төсле, аркасына эре, кара, сирәк төк үскән, бармаклары нык каптыра торган, учы җылы-дымлы бу кул астыннан үзенең бармакларын тартып алу иде. Ләкин ул вакытында тыелды. Колагында әле бая гына телефон аша шифа биреп яңгырап узган тавыш яңаргандай булса да, аны куарга тырышты, көчәнеп елмайды. Бу кешенең кәефен кырырга, гайрәтен чигерергә ярамый: югыйсә, ул Кармашта бөтен эшне туктатачак. Беразга гына түзәргә. Изге максат вөҗданга болай гына каршы килүне аклар...

— Эш тукталып тормасын иде,— диде Фидая үтенүле тавыш белән.— Фәкать шул чакта гына без уртак тел табачакбыз.

— Әгәр уртак тел табабыз икән, эше барачак инде аның!— Мирхуҗин күз ерыклары аша майлы елмаеп җавап бирде.

## 24

Язгы җил, Һаиләнең ятимлеген, яклаучысы юклыгын белгән кебек, аның ихатасы аша аерата өздереп, кистереп исә иде шикелле. Дөрес, өй артыннан бик үк иркенләп, дуылдап уза алмый ул, анда мәрхүм хуҗа утырткан биш-алты төп алмагачның нык кәүсәләре, тармаклы ябалдашлары каршы тора. Агачлар, өйне дә үз ышыгына алырга тырышкандай, шәрә ботакларын шифер түбә өстенә үк җәеп салганнар. Ә менә ишегалды ягы бөтенләй ачык, андагы тавык кетәкләкләре, баз өстендәге куыш, хәтта мунча да елдан-ел җиргә иңә, искерә бара, җил алар өстеннән уйнаклап кына уза. Ул абзар-кура, койма тирәләрендәге карны берничә көн эчендә ялап алды, урам як коймасының эчке ягында корыган тигәнәк, кычыткан куралары кар астыннан тырпаеп килеп чыкты, алар ятимлек шыксызлыгын тагын да көчәйтә иде.

Иртән эшкә киткәндә дә, көндез чәй эчәргә кайтканда да Давыт аларга карап-карап уза, йолкып ташларга һаман кулы җитми иде. Көннәрнең берендә ул, өенә кайткан арада, урман хуҗалыгыннан, машина түбәсенә бәйләп, нарат һәм каен үсентеләре алып килде. Нератлар тәбәнәк, әмма яшел, куе бөдрә, ә каеннар нечкә, күгелҗем кәүсәле һәм озынча, нык бөреле иде. Иртән идарәдән кайткач, Давыт койма кырындагы тигәнәк һәм кычыткан кураларын йолкып ташлады. Көрәк алып, ике-өч селтәнүдә әйбәт кенә чокырлар казыды һәм урам капкасыннан сул якка — өч наратны, уң якка өч каенны утыртып куйды. Каеннарның кәүсәләрен озын таякларга нығытып бәйләде — җил-давыл сындырмаслык итте, ә наратларның төпләрен нык-нык басып таптады.

— Артыграк басасың түгелме? Тамырларын өзеп бетермә тагын!— диде Һаилә.

Ир кешенең ихатаны тутырып, иркенәеп йөрүе хуҗалыкка ямь керткән, йортның дәрәҗәсен күтәргән иде һәм Һаилә бу бәхетне түкми-чәчми татырга, шушы гайрәтле ирнең эшенә кысылып, өйрәтеп, үзенең монда хуҗа икәнлеген күрсәтеп, хокукларын файдаланып калырга тели иде. Ирнең аяк астында буталып, комачаулап һәм үзенә юк акылны аңа өйрәтеп йөрмәгән хатын-кыз үзен чын хатын-кыз дип хис итәмени?

Ә Давыт үз эшен дәшми генә эшли, агач тирәләренә Һаилә китереп биргән тулы чиләктән су коя. Ул да, көздән бирле гаиләсеннән аерым яшәгәнгә, хатын-кызның үз тирәсендә чуалуына зарыккан. Һаиләнең ат дагалаганда бака ботын кыстыргандай чәпчеп йөрүе бераз эчне пошырса да, үзенә бер рәхәтлек бирә иде. «Бу каеннар яфрак яруга, Фазилә белән Алмазны да алып килермен инде»,— дип уйлый ул. Хәзер үк тә алып килгән булыр иде дә, йортны җиткереп өлгермәделәр. Өлгергән дә булырлар иде, колхозның балта осталары көзен янган хуҗалыкларга — Фаязларга һәм Гыйззетдиннәргә өй җиткерделәр, аннары Кармаш больницасына мунча салдылар. Анысын Давыт Фазиләгә әйтмәде, әйтсә, хатын дулаячак иде: сиңа ни кадерлерәк — балаң-хатының белән бергә яшәүме, йә булмаса әллә ниткән авылдагы чирле-гарипнең мунча керүеме, дип бәгырьгә үтәчәк иде. Мунчаны кыш уртасында салып бетерделәр, аннары өйгә тотынырга соңарып куйдылар. Давыт мең мәшәкать арасында нигез салдырырга онытакан иде, кышын каткан җирне актартып эшләтергә намусы кушмады.

Инде менә идарә янындагы буш ихатага нигез салынды, әзер бураны күтәреп куясы гына калды. Каен бөреләре ачылып, шаулап яфрак яргач, түбә астына керергә мөмкин булыр. Давыт та ике авыл арасында уралудан котылыр, фатирчы булып түгел, үз өендә хуҗа булып яши башлар. Чит авылда Фазиләдәй киңәшчең булу, бер ачылып сөйләшү генә дә ни җиңеллек бирәчәк бит күңелгә!

Давыт суның агач төпләренә сеңеп беткәнен көтте дә, көрәге белән черемә салгалады, аннары Һаиләгә яны белән торган хәлдә:

— Чыршының табигате кырыс аның,— дип куйды.— Урынның ныгын, туфракның тыгызын ярата. Тамырлары җиргә нык берексә, тизрәк тернәкләнә.

Ә үзенең башында бөтенләй икенче уйлар иде Давытның.

Әле бүген иртәнге якта, нәрәттән соң, фермага менгән иде. Хатыннарның онны гына түгел, силосны, саламны да үзләре ташып йөргәнен күреп, кәефе кырылды. Терлек караучы Фаяз Ишмуллин фермага килмәгән икән...

Агачларны утыртып бетергәч, Давыт, аякларын киң басып, иелә төшеп, Һаилә тоткан комганнан аккан суга кушучын сузды, өтеп алырлык салкын су белән битен, муеннарын ышкыды, сискәнеп, рәхәтләнеп, «ах» дип куйды.

Аннары, чәй эчеп алгач, Фаязга үзе барып килергә булды.

Зәңгәр койма артындагы, такта белән тышланган, аклап-зәңгәрләп буялган биек йорт аңа сигез тәрәзәсе белән берьюлы көлеп карагандай итте. Көздән булган янгынның исе дә калмаган, киресенчә, бөтенесе яңадан, ныктан, затлыдан булдырылган иде. Хәзер инде Фаяз өендәге ишекләр саны утызга җиткәндер, шәт!

Капка уртасына калку, эре ак ромашкалар ясап кагылган. Давыт, өстән сузылып, ишегалдына карады — кеше-кара күренми, ә менә ачык тәрәзәдән шаулашкан, кычкырып сөйләшкән, көлешкән тавышлар ишетелә. Уңда койма буйлап тезелеп баскан нык тупылларның каерысын астан бер метр чамасы биеклектә тунап алганнар — агачның җәрәхәте ап-ак булып, дымланып тора, гүяки ак кан белән

юылган. Теге чакта янгын вакытында Фаязларның уң як күршесе Гарәфинең өен шушы тупыллар саклап калды, дип сөйләгәннәр иде. Хәзер менә Фаяз ул агачларны корытырга ниятләгән, яз килүгә яфрак ярмасыннар дип, каерыларын сыдырган.

Тупылларның янына терәтеп юан-юан нарат бүрәнәләр өелгән; алар, таралышмасын өчен аркылыга нык тимерчыбык белән бәйләпурап куелган, ә түрдә,— тоташтан тезелгән, өр-яңа бүрәнәләрдән салынган абзар-кура янында, араларына шакмаклар кыстырып, такта өелгән иде.

Ишегалдына караган өч тәрәзә ачык, эчке яктан челтәрле ак пәрдәләр җилфердәп тора. Гармун тавышы, сөйләшкән авазлар тынып калды. Өйдәгеләр, капкадан кем кергәнен күргәннәрдер, билгеле. Давыт тәрәзәне шакыды. Өйалдында салмак, авыр аяк тавышлары ишетелде; зур, авыр ишек әкрен генә ачылды: баганалары буынлап, кәрнизләре сырлап-бизәп ясалган, сары нарат чаеренә туенган болдырга мәһабәт кыяфәт белән хуҗа Фаяз чыгып басты. Шакмаклы күлмәгенең ачык изүенә кулын тыгып, кызарган, сирәк төк баскан түшен кашып куйды. Күренеп тора, кычытканга түгел, чакырмый килгән кунакка ихтирамсызлыгын күрсәтү йөзеннән. Ул шешенке күз кабаклары астыннан кимсетеп карады Башкаларга үзе өстән карарга күнеккән озын буйлы Давытның күңеленә бу бигрәк тә авыр тәэсир итте.

— Ә, иптәш персидәтел, әйдә, әйдә, рәхим ит, бик вакытлы килдең, мактап йөрисең икән.

— Син нишләп бу вакытта өеңдә утырасың?

— Күршегә кереп утырыйммыни?— дип көлемсерәде Фаяз.

— Сәгать ничәдә эштә булырга тиеш әле син?

— Башта хәл-әхвәл сорашырга кирәк, иптәш персидәтел,— дип аны өйрәтергә кереште Фаяз.— Давай-давай дип кенә эш кешесенең бугазына баса торган заманалар узып бара бит инде. Скотник дигәч тә, без дә адәм баласы. Кешечә булырга кирәк. Аш өстенә килгәнсең икән, табын янына уз. Аштан олы түгелсеңдер.

Давыт аның кызарынган киң чыраена, бөгәрләнгән киң балаклы чалбарына, бил каешы турыннан сәдәфе ычкынып, эчтән бүселеп чыккан керле майкасына карагач, үзенең зур хата ясаганын аңлады. Эт оясында көчле, ди, монда килеп йөрисе түгел иде. Фаязның үзен идарәгә генә чакырып китерәсе иде.

— Син сораганга җавап бир. Кайда булырга тиеш син бу сәгатьтә?

— Ә мин нәкъ тиешле урында бүген, беләсең килсә. Шушы хәтле авырлыклардан соң, тернәкләнеп, хәл алып кына килябез ләбаса. Туганнар кайтып төште менә. Алар белән бер утырып сөйләшергә хакым бармы минем, юкмы? Айга-елга бер тапкыр скотникка да ял тиештер.

— Әле генә күпме ял иттең!

— Анысы аның янган өчен бирелде. Стихийный бедствие. И, гомумән, мин ул эштән китәргә ниятләп йөрим әле. Туйдырды. Гарык!

Фаяз, җыерчыклы муенын суза төшеп, калын уч кырые белән аркылыга сызып күрсәтте.

— Китәсе кеше башта идарәгә гариза китерә.

— Ә, кәгазь кирәкмени? Эш шуңа гына терәлеп торса, хәзер язып бирәбез аны!— Ул ачык ишектән өй эченә таба башын сузды.— Хатын! Кәгазь-каләм чыгар әле, гариза сорап килгәннәр монда!

Аның артында бер-ике ир кеше күренде, алар, башларын сузып, Давытка текәлеп карадылар: «Кем ул? Табынга чакырырга кирәк! Әйдә-әйдә, ник узмыйсың, безне хөрмәт итмисеңме әллә?» — дип шаулаша башладылар.

— Китмәкче, димәк! Әә йортың, ихатаң? — диде Давыт, үзенең ваклана башлаганын, дәрәҗәсен төшергәнен тоеп.

— Йортка ни булсын? Авылга килгән бер персидәтел, ут чыгарып, безне көл-күмер итә, дигән кагыйдә юктыр бит! Читтә эшләгән бөтенесенең йортлары тора әнә, берсенә дә килеп ябышмыйлар!

Фаязның артында тылы бик көчле. Давытка хәзер хур булып, җиңелеп, чигенеп кире чыгып китүдән башка чара калмаган иде. Һәм аның бу капкадан шушы рәвешле чыгып китүе, гомумән, бу колхозда чигенүнең башы булачак иде. Ул, ярдәм эзләгәндәй, ярсу карашы белән ишегалдын күздән кичерде.

— Законнарны бик яхшы беләсең, димәк? — диде, тешен кысып.

— Беләбез, наданнар юк хәзерге заманда!

— Алайса, барысы да закон нигезендә булсын. Хәзер, шушы минутта, миңа шушы агач материалларына булган документларыңны чыгарып күрсәт әле!

Фаязның кызарган йөзе тәмам чөгендер кебек булды, ул, болдырның алдына ук килеп, юан бармаклары белән баганага тотынды. Давыт өстенә таба килеп:

— Ә синең ни эшең бар анда? — диде. — Болар миңа янганнан соң өй торгызырга бирелгән материаллар!

— Шулаймыни? Өч йортлык материал бирелдемени сиңа?

— Анда синең эшең булмасын. Кара син аны, прокурормыни? Тентергә ордерың бармы әллә?

— Ә менә бар! Халык контролеры буларак, бар минем хокук!

Давыт кесәсеннән кызыл кенәгә тартып чыгарды. Бу аның урман хуҗалыгында эшләгән чорыннан калган кенәгәсе иде.

— Әгәр дә үлчәгәннән соң нахакка бәйләнгән булсаң!.. — диде янаулы тавыш белән Фаяз. — Мин сине суд юлыннан кайтармам яла якканың өчен!

— Һичава! — Давыт, аның пошаманга төшкәнен сизеп, батырая башлады. — Үлчәү безнең күздә. — Ул, борылып, капкадан кергән Мөҗипкә дәште: — Бар әле, Әхсән белән Гаделша абзыйны табып кил тиз генә.

Фаяз сагаеп калды, шул ук вакытта тиз генә бирешергә дә исәбе юк иде әле:

— Урман арасы түгел бу сиңа! Син анда лесхозда кешеләрне тотып суд эскәмиясенә утыртырга күнегеп беткәнсеңдер дә бит, монда барып чыкмас!

Давытның беркемне дә утыртканы булмады, бусы кураләтә ялган иде. Әмма монысына ул җавап биреп тормады, кесәсеннән җыелма метр чыгарды. Аның кулында озыная барган тимер тасма Фаязга еландай тәэсир итте. Артындагы кешеләр алгарак чыгып янәшә бастылар, арттарак хатыннар күренде, бала-чага башын сузды. Алар каршында Фаязның хур буласы килми иде. Берничә тавыш Давытны тагын үгетли, табын янына чакыра башлады. Әмма Давыт тыңлап тормады, капкага борылды, машинаның әйләнеп килгәнен урамда көтеп алды.

Әкрен тавышлы, йомшаграк табигатьле Әхсәнне бик санга сукмас та иде Фаяз, җыерчыклы йөзен ямьшәйтеп картузы белән куләгәләгән, шунлыктан бик борчулы күренгән Гаделшаның кыяфәте аны тәмам пошаманга салды.

Картның элек тә әче пошыбрак йөргән, күрәсең, ул ике сүздән мәсьәләнең асылын аңлады, болдырдан җиргә төшеп, кунаклары белән бергә басып торган Фаязның каршысына ук барып:

— Әйтелде бит инде сиңа, артыгын кыланасың түгелме, — диде. — Өең торгызылган, абзар-кураң булдырылган, ник шул хәтле нәфесләнергә? Аның бер очы да чыгып куя бит менә шушылай... Син генә түгел авылда, әнә ветераннар бар, карт-коры...

— Бөтен мирне мин кайгыртмам,— дип, ярым пышылдап аның йөзенә төкереген чәчте Фаяз.

Гаделша, Давыт кулыннан метрны алды да, бүрәнәләргә сузып салды, кызарган күзләре начар күргәнгә булса кирәк, урталай бөгелеп, андагы саннарны карарга керепте.

— Карт иблис, тәмуг кисәве,— дип сүгенде Фаяз.— Син генә җитмәгән идең! Син әнә колхозны ничек талаганнарын кара! Районнан килеп, моннан күпмешәр ит ташыганнарын! Нигә анысын бер дә күрмисез?

Фаяз кызган саен, Гаделшаның арык чырае тынычлана гына бара иде шикелле; ул, иелгән килеш башын аңа таба борды да, бик тыныч һәм хәтта кайгыртучан тавыш белән:

— И, Фаяз туган, бу хәтле мәтриялга ничек кәгазь җиткермәк кирәк!— диде.— Үзебез бүлеп бирдек бит мәтриялны янган кешеләргә! Мулдан бүлдек, әмма чаманы да югалтмадык. Артыкка киткән бит инде болары!

Ул арада Мөҗип тагын бер әйләнеп килде, ишегалдына бер-бер артлы күрше-күлән тула башлады. Давыт читкәрәк китте — хәзер инде аңа уртада булуның һич кирәге юк иде. Капкадан эре-эре атлап, бөдрә чәче өстеннән кепкасын артка шудырган Гыйззетдин килеп керде.

— Нихәл, күрше!— диде ул, дәртле тавыш белән кычкырып.— Нәрсә син берүзең сабан туе ясап ятасың!

Бүрәнәләр янындагы Гаделшаны сыңар кулы белән билеңнән эләктереп, бөгелгән килеш өскә күтәрде, кешеләр көлеште.

— Син нәрсә, Гаделша абзый, тәртип бозып йөрисең? Бу хәтле халыкны ник җыйдың? Үзәк ревкомиссия члены, үзең көпә-көндез кешеләрне эштән аерасың!

Аңа кемнәрдер нәрсәдер аңлатырга тырышсалар да, ул берсен дә тыңламый иде:

— Фаяз туган, анда дояркалар минем хатынны тотып ашый хәзер! Тәртип урнаштыра алмыйсыз, безне икеләтә эшләтәсез, диләр. Давай, киттек хәзер үк, хатыннарны чыгырыннан чыгаргансың, үзең киртәгә керт, әйдә!

Ул, айга-вайга карамый, Фаязны капкага сөйрәде.

— Әйдәгез, әйдә,— диде җыелган халыкка.— Хуҗа үзе киткәндә, монда базар ясап ятмассыз! Гаделша абзый! Ишетмисеңме әллә? Фермада тәртип беткән! Әйдәле!

Анысын икенче кулы белән эләктереп, аягын җиргә дә тидерми диярлек капкага әйдәде Гыйззетдин.

— Ул карт тәрегә ферма ник чукынып китми шунда!— дип сукранды Фаяз.— Аңа ник бөтенесе өелеп янмый, кешенең тырнак астыннан кер эзләргә генә булсын!

Ул әле карышкан булып кыланды, кунакларына: «Утыра торыгыз, хәзер кайтам»,— дип башын борып кычкырды, әмма Гыйззетдиннең куерып килгән тамашаны бер селтәнүдә таратып ташлавына күңеле бик хуш иде.

Гыйззетдин Фаязны арткы утыргычка, Гаделшаны алгысына утыртты да машинасын кузгатты.

— Илтеп ташла шул агач-могачны тиешле җиренә,— диде.— Нәрсәмә кирәк аның артыгы! Агач бетмәс, башың исән булсын!

Фаяз тешен шыгырдатты:

— Нәрсәнең күпме кирәген үзем беләм мин.

Төн уртасында Наилә сискәнеп уянып китте. Капка шыгырдаганы ишетелде, кемдер каты-каты басып, ишегалды аша үтте.

Наилә дөп-дөп типкән йөрәген тынычландырырга тырышты: авылның хуҗасына тәүлекнең һәр сәгатендә кешенең йомышы төшү ихтимал лабаса!

Өйдә ир заты булганга, алгы бүлмәдә йокласа да, Һаилә, күлмәк киеп ятарга күнеккән иде. Ул, чаршау читен күтәрә төшеп, Давытның ашыгып өйалдына чыкканын карап калды. Менә тышкы ишекнең ачылганы ишетелде, анда нәрсәдер дөбердәде, шакылдап төште, кемдер ахылдады, гырылдады.

— Аллаһемә, ни булды? Кем анда?

Һаилә, торып, өйалды ишеген ачып җибәрде.

Идәндә чиләк, себерке, ләгәннәр аунап ята, уртада ак майкалы, яланбаш Давыт кемнеңдер өстенә атланып утырган. Ул кызарган чыраен Һаиләгә таба борды:

— Бау бир, Һаилә апа, тизрәк! Бау!

Һаилә исә аның астында ияген идәнгә терәп яткан кешегә карап шаккаткан иде. Теге боргалана, Давытны тәгәрәтеп төшермәкче, үзе гырлау аша сүгенә иде.

— Аллаһемә, кем бу? Фаязмы соң? Давыт энем! Ташла! Җибәр. Зәйниләрнеке белән бәйләнә күрмә! Башыңны ашарлар!

— Бау бир дим мин сиңа! — диде Давыт каты итеп.

Һаилә алгы өйдән кер бавы табып чыкканчы шактый вакыт үтте, тегеләр тагын әүмәкләшеп алдылар бугай, шакылдау, дөбердәү көчәеп алды. Кирәк чакта бавы да тиз генә табылмый бит әле аның! Әһә, менә, шикәр капчыгы артына төшкән икән...

Давыт тегенең сыртыннан төшми генә кулларын артка каерып бәйләде дә җилтерәтеп аягына бастырып куйды.

Бар икән үзендә гайрәт тә! Дуылдатып алып та чыгып китте. Һаилә аны, утларны сүндерми, озак көтеп утырды. Ике сәгатьтән соң гына кайтып керде председатель. Һаиләнең соравына кыска гына җавап бирде:

— Милициягә җибәрдем, — диде.

— Кем белән? — дип төпченде Һаилә.

— Вәлишин алып төшеп китте.

Давыт, сүзне озынга сузасы килмәгәнне белдереп, почмактагы кулъюгыч янына килде, иелеп, башына су коя башлады.

Ләкин Вәлишин Фаязны районга илтеп җиткерә алмаган икән: юлда буксовать итеп азап чиккәннәр, Фаяз, төшеп, машинаны этеп йөргән, тәмам айныган, кызуы басылган. Аннары төн уртасында районда кемне борчып йөрисең?

Иртәнге эш хәерле була, көн тугач карарбыз дип, аллага тапшырып, кире әйләнеп кайткан Вәлишин.

Чыннан да, моны ишеткәч, Гаяров чәчрәп чыкмады. Парторгка карап, озак кына уйланып утырды. «Буксовать итү, гомумән, хас шул бу Вәлишингә, — дип уйлады ул. — Артыннан ничек кенә этсәң дә, бер урында туктый да кала. Үзенә кирәк төштә туктый. Һиса белән ничек эшләде микән соң ул?»

— Таштимерова барда ничек эшләде соң ул? — дип сорады Давыт, ниһаять.

— Кемне әйтәсең? — Вәлишинның үз уйлары да әллә кайда йөри икән.

— Фаязны әйтәм.

Вәлишин, аска карап, серле елмаеп куйды:

— Һы, аларга ызгышырга бер сәбәп тә юк иде. Киресенчә... Әйбәт булды аларның мөнәсәбәте. Фаяз ничек теләсә, шулай...

— Әллә... Фаяз күпне тели идеме?

— Теләмичә генә булмагандыр инде. Һисаның больницаларга ут капкандай чабуына да шул Фаяз сәбәпче бит...

Вәлишин: «Әлегә хәтле шуны аңламадыңмыни, аңгыра!» — дигәндәй көлемсерәп, председательнең күзләренә туры карады.

Район җитәкчеләре чөгендер эшкәртүне бик куәлый башлаганнар иде. Нурханова шуны тикшерергә килде. Гаяров аңа үзе белән бергә басуларны әйләнеп кайтырга тәкъдим итте. Иртәнге якта, эссе артык көчәйгәнче йөреп кайту хәерле булачак иде, билгеле.

Ике «Газик»ка утырып, аллы-артлы кузгалып киттеләр. Эмма авыл урамыннан чыгып, үргә күтәрелә башлагач, Нурханованың машинасы туктап калды. Балкыш төшеп, капотны ачты. Гаяров алгарак киткән иде, кире борылып килде.

— Район җитәкчеләре арасында бердәнбер хатын-кызга яңа машина бирсәләр дә гөнаһ булмас иде,— диде.

— Сорар әйберләр аннан башка да күп әле,— диде Нурханова.

Машина тиз генә рәтләнә торган түгел икән. Гаяров теш арасыннан гына әйтте:

— Кысан димәсәгез, минем машинага утырасыз инде,— диде.

Парлашып басуларда йөрү яхшы түгел, ләкин... әгәр Нурханова баш тартса, үзенең уйлары чиста түгеллеген күрсәтәчәк, ә ул биредә фәкать җитәкче, фәкать эш турында гына кайгыртучы һәм аның үз-үзен тотышы да башка ир җитәкчеләрдән аерылып торырга тиеш түгел. Мондый очракта башка җитәкче нишләр иде? Әлбәттә, сүз куертып тормыйча, Гаяров машинасына утырыр иде.

Юл биегәеп үскән кукуруз басуын ярып уза иде.

— Монда кукуруз белән бер дә мантый алмаганнар икән моңарчы,— дип куйды Гаяров, артына борылып карамыйча гына.— Быел тырыштык әле, шуның белән бераз алдырып булмасмы, дибез.

Чыннан да, яшел яфраклы, биек үсентеләр юлның ике ягында тоташ коридор хасил иткәннәр. Бу коридордан чыгуга, алда сирәк йортлары белән бик киңәеп утырган бер авыл күренде. Аның киң урамына тоташ чирәм үскән, ая-ая казлар чупләнеп йөри, капка төпләрендә, агачлар күләгәсендә хатын-кыз, ир-атлар күренә, балачага болгана. Каладан калага китеп гомер итүче бик күпләрнең төшләренә керә торган, сагындыра, моңландыра. «Их туган ягым, балачагым!» дип уфтандыра торган бер күренеш иде бу. Йортлар арасында буш калган, тигәнәк, әрем баскан ихаталар, тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта каккан йортлар да булмаса, чын оҗмах диярсең!

— Беге чакта, сез мине председатель итеп куеп киткәч, иң күңелне төшергәне шушы авыл булды,— диде Гаяров.— Хәзер дә мин монда иртәнге якта килеп китәм, кичкә хәтле онытылыр бераз, дим.

Нурханова аның күңеле ник төшкәнен бик яхшы аңлый: үлеп бара торган авыл бу. Капка төпләрендә гамьсез утырган ирләр-хатыннар — шәһәрдән ял итәргә кайткан кунаклар гына. Көзгә таба алар да юкка чыгар, агачлар ышыгындагы йортларда гомеренең ахырын үткәрүче пенсионер карчыклар гына калыр. Хәтта әнә чирәмдә чүпләнеп йөргән каз бәпкәләре дә, көзен түшкәләргә әйләнеп, шул ук кала ягына озатылыр.

Арырак ике комбайн тора, яннарында өлкән яшьтәге ике абзый кайнаша. Гаяров, алар янында туктап, запас частьлар табу хакында сөйләшеп алды. Машинага утыргач, тирән итеп көрсенде дә:

— Болары — соңгылар,— диде.— Шушындый берничә кеше ярты колхозны җилкәсендә тота. Ләкин картаялар. Алмаш юк. Әнә, авылны һәлак итүчеләрнең соңгысы каршыбызга килә.

Урам буйлап таза, шома балтырлы, куе, сары чәчле бер кыз узып бара иде. Ул колонка янында туктады да, тимеренә басып су җибәрде һәм аягын тыгыз агымга сузды.

Гаяров, машинадан төшеп, аңа таба юнәлде. Кыз китә башлаган иде, председатель аны туктатты. Кыз быел район үзәгендәге

мәктәпнең унынчы классын тәмамлый. Киләчәккә планнары нинди? Шул хакта сүз китте.

— Идарәгә кил әле,— диде аңа Гаяров.— Сөйләшик. Без сине хисапчы итеп куя алабыз. Аннары укырга җибәрербез. Колхоз стипендиаты булырсың.

Кыз башын күтәрми, алтынсу чәчләре йөзен күләгәләгән. Председательгә өзеп кенә җавап бирергә ашыкмый, ә бәлки, үзе дә нишләсен ачык кына белмидер.

Менә ул, башын янтайта төшеп, председательгә сынагандай караш ташлады, нечкә тавышын күтәрә төшеп:

— Ә сез бит әнә клуб хакында бер сүз дә әйтмисез!— дип куйды.

Клуб хакында нәрсә әйтергә? Әнә ул, ерак та түгел, таш стеналары нык тора. Ләкин тирәсенә котырып үлән үскән, ишегендә йозак. Анда кичләрен җырлап-биеп күңел ачарга яшьләр юк. Дөресрәге, кызлар юк. Армиядән кайткан егетләр урамда бераз тулганып йөриләр, эшләп тә карыйлар, әмма үзләренә пар тапмыйлар, пар булмагач, авылда ямь тапмыйлар, китеп баралар.

— Клуб ди әнә,— диде Гаяров кыз китеп баргач.— Ә менә мин быел мәктәпне ябарга тиеш булам. Нибары өч укучы калды. Алар өчен генә тулы бер мәктәп тотып булмый. Кемнәрдер шушы хәлгә җиткергән, ә юкка чыгаручысы мин булам. Фәлән кеше председатель чакта ябылды безнең мәктәп, дип сөйләрләр инде...

Авылдан чыгып киткәндә Фидая каерыла-каерыла артка карады.

— Менә нишләттегез сез дөньяны,— диде Гаяров.

— Кемнәр ул без?

— Сез, хатын-кызлар. Тыныч вакытта авылларны корытуга хатын-кыз сәбәпче түгелмени? Кызлар, хатыннар туган якны ташламаса, киткән егетләр дә әйләнеп кайта. Ә кызлар — китсә, кире кайтмыйлар. Менә кызларны ничек алып калырга? Ата-бабаң гомер иткән авылның, җирнең язмышы синең кулда, дип ничек төшендерергә?

— Кызлар гаепле түгел моңа,— диде Нурханова.

— Алайса, мин гаепледер инде!

— Ничәмә еллар буе халыкка баш күтәреп тирә-ягына күз салырга мөмкинлек булмады. Аны җиргә мәҗбүриләп бәйләп куйганнар иде. Баш калкытып, күзләре ачылу белән, кешеләр бу мәҗбүрияттән котылу ягын карый башладылар. Бу бик табигый.

— Табигый? Авылларның нигезе буш калу, җирнең хуҗасыз калуы табигыймы?

— Бу кызлар — алар әле җир хуҗалары түгел бит,— диде Нурханова тыныч кына.

— Ә кем хуҗа соң бу басуларга?— Гаяров алда җәйрәп яткан иркенлеккә күз карашы белән ишарә ясады.— Кем? Әллә мин генә хуҗамы?

Нурханова председательнең үзе хакында сүзне озайтмады, аны котырткандай әкрен тавыш белән әйтте:

— Мин үзем дә кайчандыр шәһәргә, укырга киттем, колхоз җитәкчеләре эш көче җитмәүдән интегә бит, дигән уй башыма да килмәде,— дип куйды.— Элек кешеләрне авылда мәҗбүри яшәткәннәр, хәзер юмалап яшәтмәкче булалар... Системасы шул ук бит аның. Монда, күрәсең, бөтенләй башка яктан килергә кирәктер. Кешеләр үзләре: «Бу минем җирем, беркая китмим»,— дип ябышып ятарлык булсын.

— Ул чакта безнең кебекләр кирәк тә булмас шул.

— Анысы инде икенче мәсьәлә,— диде Нурханова. Аннары өстәп куйды: — Сезнең эше һәм безнең эшләр, халыкны көтүләп йөрүчеләр булмаса, эшләр ансыз гына әйбәт барса, ни әйтер идең аны!

Бу сүзләр Гаяровның мин-минлегенә кагылды.

— Үзегезне үзегез беләсездер, ә мин үземне файдасыз кеше дия алмыйм әле.— диде.— Әнә, карагыз, эшнең көйле барган төшләре дә җитәрлек!

Машина агачлык аша чыккан иде, каршыда чөгендер басуы күренде.

Киң кыр, менә күрегез мине, дигәндәй, сөзәк үр булып күтәрелгән, аның буйлап офыккача яшел тасмалар сузылган — чөгендер тишелгән иде. Урыны-урыны белән ул тасмалар арасына гүяки яшел келәм җәйгәннәр — бусы солычa, көне-сәгате белән күтәрелеп килә, из арада чөгендер рәтләрен аралап алмасаң үсентеләрне тәмам каплап китәчәк.

Басу киңлегенә, бер-берсеннән биш-алты адым чамасы ара калдырып, хатын-кызлар сибелгән, китмән белән селтәнәләр. Алар артыннан яшел тасмалар тигезләнеп, җетелтенеп, җир каралып бара. Машинадан төшкәч, көннең кояшлы, җилсез, ямьле икәнлеге аеруча сизелде, биектән тургай моңы ишетелде. Фидая үр күкрәгенә башкалардан алдарак менеп барган ике хатын-кызны еректан күреп алды: ак яулыклысы — Мөнирә, ләчәкле кыскача бәйләгәне, чуар итәклесе — Каләмгөл. Һәр эштә ярышалар, бу ярыш чөгендер кырларында да аермачык күренә. Аларны куып җитәм, дип башка узышучы да булмый. Хәер, әнә читтәрәк, кызыл кофта кигән тагын берәү шулай ук башкаларны узып киткән бит! Фидая кулын маңгаена куеп, текәлеп карады, ул хатынны танымады.

— Колхозчыларга — дүртәр гектар, хезмәткәрләргә берәрне бүлеп бирдек,— диде аңа Гаяров.— Өлкән класс укучыларына яртышар гектар өләштек.

— Чөгендә, әнә барысыннан да алда, кем ул?— дип сорады Нурханова.— Кызыл кофталы.

— Улмы? Минем хатын.— Моны Гаяров ничектер тупас итеп әйтте.

— Аны да эшкә җиктегезмени?

— Ул өйдә ятса, башкаларны ничек эшләтмәк кирәк. Хәзер мин аларны авыз да ачтырмыйм, әнә минем хатын, дим, аңа да үз гектары бирелде.

— Өегез әзер түгел иде бит әле.

— Гаилә апаларда торып торабыз әлегә,— диде Гаяров. Һәм якынрак эшли торган хатын-кызлар белән сөйләшергә китте. Шулчак теге кызыл кофталы хатын, сынын турайтып, бу якка таба борылып карады. Еректан аның йөзе, күз карашы күренми, әмма аның бөтен торышыннан, башын югары чөеп куюыннан Фидаяга ниндидер гаепләү, кисәтү сизелде. Ул үр күкрәгендә, зәңгәр күк фонында мәгърур сын кебек басып тора, бөтен гәүдәсе кояш нурына күмелгән иде.

Шул ераклыктан ул үзенең олы хокукын аклый һәм ул Фидаяны гүяки: «Син монда нишләп йөрисең? Кара аны, минем өлешкә кермә!» — дип кисәтә иде.

Кире машина янына әйләнеп килгән Гаяров та ничектер кыенсынган кебек күренде, куырылыбрак киткәндәй тоелды. Әмма Фидаяның да сер бирәсе килмәде. Ул:

— Безнең Искәндәров Казанга, чөгендерне бер кат эшкәртеп чыктык, дип рапорт бирдертте бүген,— диде. Гаяров айнып киткәндәй булды:

— Анысы үз эшегез,— диде.— Мин сезгә алдый рапорт бирмәдем. Без эшкә бүген генә керештек.

— Соңаргансыз,— диде Нурханова коры гына.

— Поезд түгел, расписаниесе төзеп куелмаган. Әнә, азык чөгендере бөтенләй тишелмәде әле. Авылдагы бөтен карчык-корчык белән

үзем сөйләшеп, шул басуны эшкәртергә килешеп куйган идек. Аларны ризалату гына да ни тора. Әй буенча үзем йөреп чыктым. Әчегендер тишелмәде. Яңадан чәчкән идек, ни булыр тагын...

Кузгалып киттеләр. Бераздан сөрелгән басу кырында туктадылар.

— Шушындамы?

— Шушында.

Гаяров машинадан төште дә, эре-эре атлап, буразналар арасына кереп китте. Менә ул, иелеп, сак кына, туфракны бер яккарак этте. Кара ярма арасында ак кисәкчек күреп, учына алды да күзләренә якын ук китерде.

Таш кыйпылчыгына охшаган сырлы, каты орлыкның бер кырыеннан йомшак, ак тамырчык төртеп чыккан иде. Димәк, тишеләчәк, моннан ике көн явып үткән яңгырның шифасы тигән. Димәк, яңадан чәчү дә, әй борынча карчыкларның күңелен күреп йөрү дә бушка китмәячәк... Тамырчык бик кечкенә, текәлеп караганда гына күренә иде. Давыт, аны имгәтүдән курыккандай сулышын тыйды: аның уч төбендә яшәешнең могҗизасы, сере тернәкләнеп ята иде. Бөртек эчендә күзгә күренмәс, туктаусыз тыелгысыз хәрәкәт бара, җепсел сузыла, туфракка омтыла. Аз арада ул, тармакланып, җиргә нык берегер, ике учка сыймаслык чөгендер булып үсәр. Гаҗәп, уйлап карасаң, баш җитмәслек могҗиза!

Күтәрелеп биек күк йөзенә, ерактагы агачлыкларга карады. Нинди иркенлек, рәхәтлек, гүзәллек! Нигә адәм балалары бу игелекле басуларны ятим итә, нигә алардан китә?

Аның күзе машина янында басып торган Нурхановага төште. Ул да, учына нидер алып, текәлеп карап тора иде. Ул да, иелеп, кулы белән җирне сыйпады. Назлап сыйпады. Ятим баланың башыннан сыйпап узган кебек... Әйе, ятим баланың... Безнең кырлар, басуларыбыз шул ук ятимнәр түгелмени? Буразналар арасыннан машинасына таба атлаганда башына килгән бу фикердән тетрәнеп китте Гаяров. Бу җирләр ятим булмасын өчен, аларга күңеле белән гомерлеккә береккән, куллары белән аларны һәрдаим сыйпап торучы кешеләр булырга тиеш. Алар шушы җир куенындагы бөртекләр белән өзелмәс бәйләнешне тоеп яшәргә тиеш.

Ләкин бу бәйләныш өзелгән. Гаяров үзе дә бу җир белән күпмегә бәйле булачагын белми. Быел монда, ә киләсе елны әллә кайда... Җитәкчеләр кая куяр... Ә бу җирләр буйлап үзен хуҗа тоеп әле кайчан гына Каштимерова йөргән, хәзер менә ул йөри, аннан соң башка берәү атлар...

Юк, бу туфракка күңел белән берегергә ярамый! Аерылганда авыр булачак!

Давыт, машина янына килеп, Нурхановаының йөзенә текәлеп басып торганын үзе дә сизми калды. «Минем җирем!» — дип кем әйтә ала бу иркен кырлар хакында? Кем аның хуҗалары?

Бу уйларны Давытта Нурханова кузгаткан иде. Күгелҗем күлмәк кигән, нечкә билле, алтынсу чәчле хатын.

Юк, алай гына түгел, күп уйланган, күпне кичергән, акыллы кеше басып тора иде Давыт каршында.

26

Хуҗалык җитәкчеләрен туктаусыз өйрәтеп, тегене болай эшлә, моны тегеләй ит дип күрсәтеп торырга кирәк, дип исәпләнә. Шушы максаттан чыгып, районнарда бик еш кына семинарлар үткәрелә.

Терлекләрне җәйләүләргә чыгару уңае белән «Җиңүче» колхозында шундый семинар үткәрүне планлаштыргач, бөтен көч анда үрнәк бер җәйләү оештыруга салынды. Мирхуҗин атналар буе

шунда булды: автоэчергечләр көйләделәр, терлекчеләр өчен йорт салдылар, юлларына асфальт җәйделәр. Һәм, барыгыз да шулай эшләгез, дип аңлату өчен, бер иртәне барча колхоз председательләрен һәм совхоз директорларын шунда чакырып китерделәр. Искәндәров үзе һәммәсен күрсәтеп, аңлатып йөрде, хәтта сөт бидоннары тезелгән эскәмия янына барып: «Бидоннарны әйбәтләп юа торган итегез, югыйсә заводка илтеп җиткергәнче сөтегез ачып чыга!» — дип тә өйрәтте. Күпләр үз хуҗалыкларында мондый җәйләүне тиз арада ясау мөмкинлеге булмавын белсәләр дә — тактасы да, асфальты да, эшләргә кешесе дә юк — дәшми-тынмый аның артыннан ияреп йөрделәр. Каршы әйтсәң, үз башыңа тукмак кына аласың! Җәйләү янына автолавкалар китергәннәр, кайсысыннан яшел кыяр, кызыл помидор, кайсысыннан шешәле су саталар, кайсыларының ачып куелган ишекләренә күлмәк-кофталар эленгән, аллы-гөлле киенгән хатын-кыз алар тирәсендә чиратка тезелгән иде.

— Нигә кыяр алмыйсың?— диде Мирхуҗин, Давыт янына килеп.

— Чират торасы килми.

— Кая, үзем чиратсыз алып бирәм. Кайткач хатыныңа әйтерсең минем күчтәнәч икәнне.

Давыт мәгънәле көлемсерәде:

— Үзем исән чакта хатынга сине мактыйммы соң!

— Озакка барыр микән инде бу?— Мирхуҗин ак күлмәк җиңен кайтарып куйды. Давыт ирексездән аның хикмәтле электрон сәгатенә текәлде. Тавис канәгать елмайды:

— Малны таный беләсең, ә?

— Тану нәрсә ул, кайберәүләр таба белә!

— Китереп бирәләр малай, эзләп йөрисе дә юк. Туган көн бүләге!— Аннары, аяк очларына басып, Давытның колагына үрелә төшеп өстәде:— Кызлар бүләге!

— Бездә шундый бүләк бирә торган кызлар да бармыни?

— Табылып торалар алар күзен ачып йөргәннәргә, ярның асылын үзенә карата белгәннәргә!— Шулай такмаклады да Мирхуҗин, кысык күзләрен тагын да кыса төшеп, каш сикертеп, читкәрәк карап куйды. Давыт сискәнеп китте: ул Нурхановага ымлады...

Ә Нурханованың гамендә дә юк, ул «Җиңүче»нең парторгы — бөтерчектәй түгәрәк Әслимә Фәләхова белән сөйләшеп тора. Зәңгәр күлмәк өстеннән билен өзәрдәй итеп ак каеш буган, башында аклы-зәңгәрле яулык, сул беләгенә ак бинт ураган. Ник бәйләде икән?

Шул минуттан башлап, кая гына барсалар да, Давыт Нурхановаңы күздән ычкындыра алмады. Юлда тезелеп торган «Волга», «Жигули», «Газик» машиналарына утырганда да, аннан төшкәндә дә һаман беренче булып зәңгәр күлмәк, нечкә беләккә уралган ак бинт күзгә ташлана. Әнә, Искәндәров тубыктан үскән бодай басуына кергән дә, бер кулына билчән, икенчесенә бодай үсентесе күтәреп:

— Гербицидларны самолеттан сиптергәнне көтеп тормагыз, самолетлар җитәрлек түгел, тагылма коралларны эшкә җигегез!— дип аңлата.— Күрәсезме, билчән тамыры нинди дә, бодай тамыры нинди? Чүп үләне хәзер бодай тамырын буа!

Ә Давыт бер читтәрәк торган Нурхановаңы күзәтә: Туфлиләре бигрәк ак, пычрата инде»,— дип уйлый.

Ниһаять, күргәзмә әсбапларны күрсәтү тәмамланды, инде хәзер парта артына утыртып сабак бирер вакыт җитте. Юл буйлап тезелеп барган машиналар колоннасы, рәт-рәт булып үскән наратлык янына барып, чирәмлеккә кереп туктады. Давыт мәктәптә укыган чакта

ук утыртылган наратлар инде чын урман булып үсеп житкәннәр. Уртадагы аланлыкка ак такталардан эскәмияләр тезелгән, алар каршына өстәл әмәлләп куйганнар.

Эскәмияләргә колхоз-совхоз житәкчеләре утырды, каршыдагы өстәл артына район житәкчеләре урнашты. Нурханова киңәшмән ачып жибәрде.

Иң читене менә шушысы. Хәзер рапо директоры Мөнипов доклад сөйләргә керешә, анда исеме чыккан кешеләрне аягүрә бастырып, вәгазь укый башлаячаклар. Мөниповның авызыннан минем фамилия ычкынмасмы, дип кан калтырап утырасың. Үз хужалыгында меңләгән гектар жирләргә, йөзләрчә кешеләргә баш дип саналган мөхтәрәм ир-ат монда — мәктәп балалары кебек, аның да начар укучылары хәлендә. Давыт мондыйга күнегеп жигә алмады әле. Шунлыктан ул тиргәлүчеләрне дә кызгана, үзе өчен дә гарьләнә. Хәер, әр-хур һәммә кешегә дә эләкми.

Мөнипов әледән-әле яңа фамилияләрне атап китә. Давыт бу хакта уйламас өчен, фикерен башкага юнәлтергә тырышты. Нурханова нечкә беләкләрен өстәлгә салган да тынып калган. Нинди уйлар икән аның башында? Мирхужинга теге затлы сәгатьне ни дип бүләк итте икән? Шулкадәр якын күрә микәнни? Юктыр, якын итү билгесе булмас. Артык горур, ирләр артыннан йөри торганга охшамаган.

Аллага шөкер, Мөнипов бу юлга аның фамилиясен әйтмәде. Тирләгән маңгаен кулъяулык белән ышкый-ышкый, такта өстәл артына барып утырды.

Искәндәров торып басты.

— Сөт буенча ярты еллык планны үтәү бик авыр булачак,— дип сөйләп китте ул.— Үлән күп, ашатыгыз сыерларны! Җәй башы коры килсә, сөт мул була, моны һәркем белә. Чиста парларга үлән чәчәргә кирәк, силос салынсын, яфрак азык жыелсын...

— Гаяров!— диде кинәт сүзенең уртасында Искәндәров.— Нишләттегез сез анда «Жиңүче»нең борчак басуын?

Давыт, сискәнеп, кызарынып торып басты. Бу аланлыкта, бу кояш астында, аннан да бигрәк өстәл артында утырган зәңгәр күлмәкле хатын күз алдында сузаеп басып торганчы, йомранга әверелеп, үлән арасындагы өңгә кереп посуың яхшырак булыр иде... Гомерендә беренче тапкыр ул үзенең шушы хәтле озын буйлы булганына үкенде.

Ни әйтсен ул? «Үзәк»нең бодай басуына самолеттан гербицид сиптергәндә, ызанның икенче ягындагы борчакка да коеп киткәннәр. Әллә бригадир флаглар белән сигнал бирүчеләр куйдырмаган басу кырларына, әллә очучы ялгышкан. «Жиңүче»нең орлыклык борчагы бераз шиңгән шул. Шуны район хужаларына әләкләгәннәр, күрше хәтерен саклауны да уйлап тормаганнар... Истә тотарга кирәк, аларның да бер йомышы төшәр әле...

Давыт дәшмәде. Аклана башласаң, башка тукмак күбрәк төшә. Искәндәров аны үзенең өстенлеген раслар өчен бастыргандыр... Зуррак урында Искәндәровны шушылай бастырып хурлый торганнардыр...

— Күрше хакы — алла хакы,— диде Искәндәров.— Зыян иткәнсез икән, түләрсез.

— Безнең басуның шулкадәр жиреннән урып алырлар әнә,— диде Давыт. «Жиңүче»нең председателе Ясәвиев «хе» дип куйды.

— Безнең орлыклык басу иде бит ул! Безнең кырдан урып алганның нииндилеге билгеле инде!

Нурханова, башын күтәреп, күзләрен зур ачып, Гаяровка текәлде. Аның йөзендә: «Менә, сез дә әллә кем түгелсез!»— дигән сым ынрак бер кинаяле көлемсерәү чагылып узгандай булды. Бетәрме бу газап, юкмы?

.иһаять. Искәндәров:
— Утыр!— диде.
Шуннан соң күп тә сөйләмәде, җыелышны йомгаклады. Ирләр, оеган аякларына салмак кына күтәрелеп, шулай ук оеп киткәндәй уй-фикерләрен кузгата башладылар. Аллага шөкер, бетте. Хәзер иң күңеллесе генә калды. Яшь наратлар арасындагы янәшә аланда Ясәвиев озын-озын өстәлләргә табын хәстәрләткән иде. Машиналар, бер-бер артлы кузгалып, шул тарафка юнәлде. Гаяров та, бераз зиһенен җыйганнан соң, шоферы Мөҗипкә алар артыннан барырга кушты.
Кәеф кырылган иде. Ул өстәлдә өем-өем торган калын калач телемнәреннән берсен алып, сындырып капты. .урханова күренми иде. Мирхуҗин да юкка чыккан. Кызык, бергә киттеләр микән, аерым-аерыммы?

## 27

.еминар .урханова күңелендә дә авыр тәэсир калдырган иде. Аланд. әзерләнгән табынга бармады ул. Искәндәровның, башка җитәкчеләрнең машиналары киткәнне көтеп алды да. Балкышка кузгалырга кушты. Машина урман читендәге чирәм юлдан рәхәт тирбәлеп бара иде. Уңда — яшь наратлык, сулда — ачык-шәмәхә басу. Гаҗәеп матур.
Моторда нәрсәдер аксагандай шакылдый башлады. Балкыш, кашын җыерып, машинаны туктатты.
— .инең эшең тиз генә бетәргә охшамый әле.— диде .урханова.
— Ярты сәгатьсез булмас шул.
Фидая, кеше эшләгәнне карап торуны яхшысынмыйча, нар.тлыкка кереп китте. Юл читендә агачлар куерып үскән, астагы корыган ботаклар тырпаеп тора, күлмәктән, чәчтән тарткалый.
Ләкин менә алда чирәмлек күренде, аның артынд. янә наратлык иде, тик монысы — сөзәк үр күкрәгенә рәт-рәт утыртылганы — куерып өлгермәгән әле. Монда агачлар төптән юанаеп, ботакларын киң җәеп, күкрәп үсеп киләләр, очлары Фидаяның баш өстеннән чак кына биегрәк булып тырпаеп тора.
.әт эчендә аларның бер-берсенә сузылган ботаклары тоташа язган инде, ә менә рәт араларына кояш нуры туры төшә, рәхәтләнеп җил йөри, куерып үләт үскән. Фидая наратның озын, сусыл, тыгыз ылысларын сыйпады. Ылыс арасында, яшәешнең серле төене булып, авыр, каты күгелҗем күркәләр яралган.
Көлсу туфрак кочагыннан нинди көчләр күтәрә алды икән мондый яшәү тантанасын, мондый муллык, гайрәтне? Ашлау да, карау да таләп итми, хәтта корылыкка да бирешми торган нинди кодрәт бу? Җирдән-туфрактан күтәрелеп, кәүсәләр, ылыслар буйлап туктаусыз агып торган шушы көчнең авазын ишетергә теләгәндәй, тынып калды Фидая һәм бераздан ул аны ишетә дә башлады кебек. Әйтерсең, чыннан да җир куенында нindидер өн ярала, ул нарат ылыслары аша кояшка таба саркып чыга иде.
Фидая, үзалдына елмаеп, яшь наратларның җырлы шавын тыңлап, шактый басып торды, аннары бөтен тәнендә бер талчыгу тоеп, рәтләр арасыннан аланлыкка таба китте, анда үлән аерата куерып үскән бер уйсулыкка килеп чыкты. .аратлыкта инде беркем калмаган, алда, киң басулар аша б.рмаланып узган аулак юл да буш иде.
«Ә нәрсә, чыннан да, бөтен дөнья үземнеке, нишләсәм дә килешә!» — дигән шаян уй узды Фидаяның башыннан. Ул уйсулыкта аерата тыгызланып үлән үскән урынны күреп алды. «Менә, минем өчен махсус җәеп куйганнар бит!» Ул чалкан сузылып ятты, нечкә үлән сабаклары аның тирәсендә бераз гына тирбәлеп тордылар да, күздән хәтта ерак түгел көй өйрәнеп утырган наратлардан да яшереп, тура-

ешып бастылар. Өстән тургай җыры һәм кояш нуры гына Фидаяга тоткарлыксыз килеп ирешә иде.

Башта бер уй, бер гамь калмаган, тәнне, рухны сирәк була торган бер рәхәтлек, яшәү бәхете, үзеңне шушы җирнең, күкнең бер өлеше итеп тою, шушы нәратлар, үләннәр белән бердәмлегеңне хис итү бәхете биләп алган иде. Әйтерсең, ул да тормышын башлый гына, җирдән күтәрелеп кенә килә, әйтерсең ул да әле үз җырын өйрәнә генә башлаган! Гомер алда, бәхетле көннәр алда, бөтен тавыш белән җырланачак җырлар алда шикелле!

Ул бөтен тәне белән җирдә, туфрак эчендә барган өзлексез, игелекле хәрәкәтне, андагы тамырларның үсешен, алар буйлап аккан суларны тоя кебек...

Дөнья камил, яшәү — бәхет, башка берни дә кирәкми.

Ул шулай күпме ял иткәндер, берзаман нечкә үлән сабакларын җай гына тибрәлдергән йомшак җил тавышына ниндидер ят, тупас авазлар килеп кушылгандай булды. Фидая тынып калды. Дөп-дөп... Дөп-дөп... Адымнар. Кемдер килә. Ә бәлки күрмәс, читләтеп узып китәр? Ләкин юк, алар көчәя бара, якыная... Күренми калып булмас, ахрысы. Фидая соңгы минутка кадәр тынып ятты, аяк тавышлары тәмам якынайгач кына кинәт күтәрелде, аягына басарга омтылды, тезләнде...

Алар икесе дә бу очрашуга әзер түгел иделәр, шунлыктан күңел төбендәге тойгыларның күз карашларында чагылганын сизми калдылар. Ә бу тойгы — башта гаҗәпләнү, ә аннары куаныч, шатлык иде.

Давыт аңа шул сөенеч белән кинәнеп, балкып караган хәлдә торырга ярдәм итәр өчен кулын сузды. Фидая сул кулын сузган иде, әмма Давыт, аның беләгендәге ак марляга күзе төшеп, авырттырмыйм тагын, дип уйлады, иелеп, аның җиргә таянган уң кулыннан тотып алды... тотып алды, үзенә таба тартты. Фидая үзе аягына басып өлгерә алмады, кинәт тартылудан тәмам аның ихтыярында калды һәм ир-егетнең кочагына килеп кергәнен, аның коры, эссе, каты, таләпчән һәм көчле иреннәре иреннәренә килеп кысылганын абайламый да калды.

Давыт аның бөтен ихтыярын алып, үзенә кысты. Аның битеннән, күзләреннән ярсып үпте. Аны шушылай кочаклап үбәргә күптәннән хыялланганга да түгел, аны өзелеп сөйгәнгә дә түгел, бүгенге җыелыш вакытында кимсетелгән, рәнҗетелгән, түбәнәйтелгән җаны өчен үч алуы иде бу аның, ирләрчә дәрәҗәсен күтәрүе, ахыр чиктә, бу хатынның фикере белән исәпләшмәве — барысы бергә иде. «Менә син өстәл артында кәпрәеп утырган идең... Мине аяк өсте бастырып, маңка малайдан җавап алгандай иткәндә... ...ин эре, дәрәҗәле идең... Ә менә мин барыбер егет, барыбер көчле, кодрәтле...» Бу кинәнүгә шул ук вакытта бөтенләй капма-каршы тойгы, үзенең буталган уй-хисләрен бер эзгә салырга тырышу, моның өчен үзен аңлаган бер җан иясенә сыенырга теләү дә һәм бер караганда котып балкышына, икенче караганда чәнечкеле гөлгә охшаган бу хатынга тартылу да бар иде. Бу тартылуның тыелгысыз икәнен, бу омтылышның акылдан көчлерәк икәнен ул шунда тойды.

...из аңына килде Фидая, калкулык битендә, еракларда күренгән ачык урында болай торуның никадәр акылсызлык икәнен аңлады. Ике учын Давытның күкрәгенә куеп, бар көченә читкә этәрде. Давыт аны әкрен генә аягына бастырды. Фидая, кыенсынып, аңа аркасы белән борылды, нәратлык аша машинасына таба юнәлде.

Бераз дәшми бардылар. ...иһаять, Давыт:

— Балкыш машина рәтләп азаплана иде анда, минем Мөҗип аңа булыша калды,— диде. ...и тыелырга тырышса да, аның тавышы калтыраганы сизелде.

Фидая дәшмәде. Ул Давытның арттан килеп кочып алуыннан

курка хәтта аркасы җыерылып килгән иде. Ләкин Давыт бер адымлап ара саклап килә, әллә Фидаяның халәтен аңлый, әллә үзенең тупас кыланасы килми. Бераздан ул сорап куйды:

— Беләгеңне ник бәйләдең?

— Укол ясаган иде медсестра. Басуга барасын белгәч, тузан кермәсен дип, урап куйды.

— Ә нәрсәдән ул укол?

— Болай гына. Витамин.

— Витамин хәзер болай да җитәрлек. Нәрсәгә тәнгә яра ясарга?— дип куйды Давыт, ризасызлык белән. Аның теге сәгать турында. Мирхуҗин беләгендәге сәгать турында сорыйсы килә иде. Әмма ул тыелды. Бу минутта ависның исемен телгә аласы килмәде.

Фидая кулларын, битләрен коры ботакларга сыдырттырып, адымын торган саен кызулата барды — юк, бу кеше белән үзен алай якын хис итүгә каршы иде ул, риза түгел иде!

Алда яктылык күренә башлагач, ул туктап калды.

— Барыгыз, алдан чыгыгыз,— диде.

Аның шоферлар янына куе ешлыктан парлашып чыгасы килмәгәнен аңлады Давыт, әйләнеп, орынмыйча узды да, әре-әре атлап китеп барды. Фидая, башындагы яулыгын салып, тирләгән битен сөртте, итәгеннән коры яфрак, үлән сабакларын алып ташлады, өстен рәтләштерде.

Мөҗип Балкышның машинасын буксир белән тартып кайтырга тәкъдим итте. Ләкин Фидая риза булмады. Аланлыктагы очрашуга хәтле ул аны-моны уйламас, Гаяров машинасы белән бергә кайтуны гаепкә санамас, кеше ничек карар, ни әйтер, дип исәпләп тормас иде. Ләкин соңгы берничә минут бөтенесен кинәт үзгәртте: ул инде кеше карашыннан, кеше күзеннән курка башлаган иде.

— Зарар юк, минем Балкыш әфсен укып булса да кайтарып җиткерә,— диде ул, шаярган булып.

## 28

Семинарда халыкка корылык торганда ниләр-ниләр эшләргә кирәген аңлатып җибәргәннәр иде. Табигать район җитәкчеләрен мыскыллагандай итте: нәкъ шул төнне коеп яңгыр ява башлады.

Иренең тәрәзәдән күзен алмаганын күреп, Фазилә:

— Бер коя башлагач, туктамас инде,— дип куйды.

Һәрвакыттагыча, аның сүзе хакка чыкты. Сабан туйлары җиткәч тә көннәр яңгырлы торды. Авыл халкының көтеп алган, елына бер килә торган бәйрәме бөтенләй булмый калу ихтимал иде, моңа Давытның бик нык эче пошты. Никадәр әзерләнделәр, күпме бүләк хәстәрләделәр, авыл кырындагы чирәмлектә мәйданын да ясап куйдылар. Давыт председатель булгач беренче сабан туе булмый калыр микәнни? Туктале, авылда ул гына түгел ләбаса! Башкалар ни уйлый икән? Давыт Каләмгөлләргә китте.

Ачык зәңгәргә буялган, уртасына ак тан кояш сурәте ясалган капкага юнәлде. Шәп җиткерделәр йортны яңгыннан соң Гыйззетдингә!

— Керергә ярыймы?

Бөдрә чәчен кызыл тасма белән бәйләгән Зарема болдыр такталарын юып маташа иде; тураеп, председательгә зур, серле күзләрен тутырып, җитди итеп карады.

— Әниең өйдәме?

Зарема дәшми генә ишегалды түрендәге лапаска кулы белән ишарәләде. Ә аның капкасыннан Гыйззетдин башын сузып карап тора иде. Ул кунакка каршы чыкты, аннан Каләмгөл дә күренде.

— Ни эшләр майтарасыз?

— Менә, машина юабыз.— диде Гыйззетдин.— Пычрак бит.
— Машинаны юарсыз. Ә бәйрәмне ничек үткәрмәкче буласыз?
Үзе шундук Гыйззетдиннең: «Ява бит!» — дигән сыманрак сүз әйтәсен көтте. Ләкин ялгышты. Каләмгөл, соры болыт каплаган күк йөзенә карады да, гади генә итеп:
— Бәйрәмне ясыйбыз аны,— диде.— Яңгыр хәзер туктый.
— Каян беләсең?
Каләмгөл председательнең күзләренә шаярткандай көлеп карады:
— Кәрт ачтым,— диде.—Хәзер халык җыела башласын, алар килеп җиткәнче туктый бу яңгыр.
Давытның аптыраганы йөзенә чыкты, ахрысы, ирле-хатынлы хуҗалар икәүләшеп көлеп җибәрделәр. Аларның шушылай рәхәт итеп, үчекләп тә, бер-берсен аңлашып та көлешеп торуы бүгенге болытлы көнгә бер дә ярашмый, шул ук вакытта офыкның бер чите ачыла, яктыра башлаган кебек тә тәэсир калдыра иде.
Алардан урамга чыккач, Давыт урам буендагы агачлар арасыннан үрелеп, әллә соң аяза башлаганмы дип, көнбатыш тарафына бик текәлеп карап та куйды, ләкин анда болытлар, киресенчә, куерып килгәндәй күренде.
Идарәгә кайткач, Әхсәнне табып, киңәшергә дип тора иде, ул арада урамнан җыр ишетелде:
«Сабан туе хезмәт туе, шатлык һәм бәхет туе...»
Давыт Зареманың тавышын танып алды: концертларда ишеткәләгәне бар иде инде. Сузылып урам якка карады: анда Гыйззетдиннең зәңгәр «Нива»сы килеп туктаган, ачык тәрәзәсеннән мегафон тәлинкәсе сузылып чыккан. Җырның куплеты тәмамланугa, мегафонны Каләмгөл алды:
— Авылдашлар, туганнар, дуслар! Барыгызны да сабан туена чакырабыз. Ярты сәгатьтән бәйрәмне башлап җибәрәбез. Ашыгыгыз! Килегез! Көтәбез!
Машина әкрен генә кузгалып китте, аннары бераздан туктады, тагын җыр ишетелде. Давыт урамга чыкканда, капка төпләрендә кешеләр күренә башлаган, күктәге болыт пәрдәсенең дә чите ертылып киткән иде инде.
Чыннан да, бер ярты сәгатьтән, уртасына казык, баганалар каккан, ике яклап эскәмияләр куелган һәм бер төшенә өсте ябулы трибуна ясалган яшел мәйданда, Давытны туры китереп, Гыйззетдин әйтеп алды:
— Олы башыңны кече итеп килдең, рәхмәт. Без дә синең сүзне аяк астына салмадык әнә,— дип, болыт арасыннан чыгып килгән кояшка күз кысып, хәйләкәр елмаеп куйды.
— Мин олы башымны олы итеп бардым сезгә, олы кешеләр янына,— диде Давыт.
Киң мәйдан кызыл тасма белән уратып алынган, уртадагы биек колгага зур тәкә бәйләнгән; авыш колга башында, ятьмә эчендә әтәч тыпырчына, өсте ышыкланган өстәл-трибуна тирәсендә җиңнәренә кызыл бәйләнгән кешеләр кайнаша. Мәйданда абзыйлар колгаларны, чүлмәк ватарга куелган таякларны тагын бер тапкыр тикшереп йөриләр, янәшә болында чабыш атларын һәм юртакларны аяк яздыралар — гомумән, күңел күтәренкелеге, рәхәт бер иркенлек һәм бәйрәмнең матур үтәсенә ышаныч та, моңа бер әшлекле әзерлек тә хөкем сөрә иде.
Бәйгеләрдә чапкан атларның янып үлгәннәре дә була, моны һәммәсе белә, әмма нәкъ менә бәйгене әзерләгәндә моны һәрвакыттагыча онытып җибәргәннәр иде.
Яңгыр туктады, җирне-күкне балкытып кояш чыкты, кызыл тасманың тышкы ягына, җәймәләр, плащлар җәеп, халык утырыш-

ты. Трибунага каршы якка Каләмгөл машинасын китереп куйган, инде комиссиядән бүләкләр алып килгән, иңенә баянын аскан: «Туганнар! Дуслар! Әйдәгез, кем тели, кем ничек булдыра, җырлап алыйк әле!»

Кечкенә малайлар башлаган көрәшне егетләр дәвам итте, бурәнәдә агайлар капчык белән сугышты, үсмерләр авыш колга буйлап әтәчкә таба киттеләр — анысын бик тиз алдылар, әтәч икәү генә булып чыкты, әмма малайлар колга буйлап менүне дәвам иттеләр: бүләге булмаса булмас, икенче сабан туена әзерләнә торырлар!

Кыскасы, сабан туе үзенең борынгыдан килгән күңелле бер тәртибе белән бара иде. Каләмгөл, иңеннән баянын салып, кызына сузды:

— Яле, кызым, мин дә бер җилкенеп килим әле, кеше күңелен генә күрергә димәгән, үз күңелемне дә күрим, үземне дә күрсәтим!

Ул, башын туры тотып, чәчкәле итәге белән әллә каян балкып, сыгылмалы нәфис адымнар белән мәйдан аша трибунага таба китте.

Нәкъ вакытында өлгерде: трибуна янында чәчкәле чиләкләр һәм бизәкле көянтәләр өләшәләр — су ташучы хатын-кызлар узышын үткәрергә әзерләнәләр иде. Каләмгөлнең килгәнен күрепме, әллә күрмичә калгангамы, көянтәләрнең берсен ак кофта, кара юбка кигән, толымнарын аркасына салган Мөнирә алган.

Нурхановның шоферы Балкыш, Зиләйлә күренмәсме дип караштырып, мәйдан тирәли йөри иде. Җыр ярышлары барган машинадан ерак та түгел, таныш кеше күренде: бу Зиләйләнең әтисе Гыйззетдин иде. Ул ике яшьлек улын кулына күтәреп басып тора, мәйданнан читкә борылып, басу юлыннан еракка, чабышка китеп барган җайдакларны күзәтә.

Балкыш якынрак килде.

— Кара, улым, кара, бераз үскәч, әнә син дә, шул малайлар кебек, чабышларга барырсың,— диде Гыйззетдин, малайның аркасыннан кояшта янган кулы белән сыйпап.

— Кара, Гыйззетдин, кара, син тегендәге чабышны күрми кала күрмә! — диде шунда табын ясап утырган төркемдәге ирләрнең берсе. Ул кырын яткан җиреннән күтәрелде, тезләнеп, мәйданның аргы башына ишарәләде. Анда чуп-чуар хатыннар төркеме көянтә-чиләк күтәреп чаба, чайпалып чәчрәгән су кояшта чагыла, итәкләр җилферди иде. Арада зифалыгы, адымнарының ипле матурлыгы белән Каләмгөл күзгә ташлана, тик ул берничә хатыннан калышкан, алда киткәннәр арасында Мөнирәнең сары толымнары җилферди. Шунда Каләмгөл көянтәне ике кулы белән баш очына күтәрде, чиләкләр чайкалды, ләкин сулары түгелмәде. Үрдәк кебек чүг[illegible] әүмән-тәүмән атлап барган хатыннарның чиләге яртылаш кына к[illegible]ган, ә аның — мөлдерәмә тулы. Көянтәсен күтәреп, ул суда йөзг[illegible] аккош кебек шундый тигез атлап китте ки, Балкыш аннан күзләр[illegible]н ала алмады, башкалар да ах иттеләр. Менә ул хатыннарны берәм-берәм узып китте, менә трибуна каршына беренче булып барып җитте, аннан сузылган шәлъяулыкны алгач, шулай ук җиңел хәрәкәт белән көянтәсен баш өстеннән төшерде.

— Көчле-е! — дип, кызыл муенын суза төшеп кычкырды тезләнгән ир. Бу Фаяз иде.— Көндәшен уздырамы соң чукынмыш, янып үлсә үлә, үзенекен итә! Шулай бит, ә, Гыйззетдин!

Фаяз хихылдап куйды, аның көлүендә ниндидер аст[illegible]ртын бер мәгънә ишетелде.

Балкыш борылып карады: Гыйззетдин улын җиргә төшергән, йөзе караңгыланган, иреннәре кысылган.

Мәйдан уртасында ак сөлгеләр таза егетләрнең кызарган билләренә урала, бер кырыйда күзен бәйләгән абзыйлар, апалар һәм үсмерләр таяк болгап чүлмәк ватарга азаплана. Ул арада еракан ат-

лар чабып килгәне күренде, утырганнар да кузгалып, халык шул тарафка авышты. Гыйззетдин дә улын кулына күтәрде. Ат өстендәге малайлар, башларын иеп камчыларын болгый, ерактан ук ярсу, ашкыну сизелеп тора.

Гыйззетдин күзләрен сөртте, гаепле кешедәй, Балкышка карап:

— Бар иде безнең дә шулай бәйгеләрдә чапкан чаклар! — диде. — Узды яшь гомерләр, аккан су кебек.

— Хәзер дә соң түгелдер әле!

— Атларның биле чыдамый шул инде хәзер безгә...

Чыннан да, чабышка катнашканнар — чандыр үсмерләр иде. Менә алар, пошкырып башларын чайкаган атларын җитәкләп, мәйдан әйләнә башладылар, һәр атның муенына күп итеп сөлге-ситсылар сарылган, кайберсенең очлары җирдән сөйрәлеп бара. Гыйззетдин яшь аралаш аларга йотылып карап тора иде. Шулчак радиодан:

— Утыздан узган хатын-кызларны йөгерешкә чакырабыз! — дигән тавыш ишетелде.

Трибуна турыннан мәйдан әйләнеп йөгереп килгән хатын-кызлар төркеме күренде. Башкаларны шактый ерак калдырып, җиңел, киң итәген сәхнәдә биегәндәй матур җилпеп, эре адымнар белән, башын артка ташлап, терсәкләрен нык хәрәкәтләндереп йөгереп килгән Каләмгөлгә Гыйззетдин кулын сузды:

— Кирәкмәс иде, әнисе, кирәкмәс иде...— диде.

Ләкин Каләмгөл аны ишетмәде, елмаюы гына чагылып узды. Тирә-яктан:

— Әйдә, әйдә, әлдер, җиткермә!

— Мөнирә, кызула, курыкма, алдан чапкан тиз талчыга! — дип кычкырышып калдылар, бу кычкырышуда үчекләү, кызык итү ярылып ята иде.

Трибуна өстәле артыннан Гаделша, сузылып, беренче килгәнгә дип, чәчәкле-чуклы япон шәле болгап тора. Шәлне ул алдан килгән Каләмгөлнең бите турыннан өскә таба җилпеде, хәер, Каләмгөл моны күрмәде дә бугай, ул туктамады, үрелмәде, килгән кызулык белән түгәрәкне икенче тапкыр әйләнергә китте. Аның артыннан бишалты хатын-кыз куып килә, алар арасында ак кофталы, кара юбкалы Мөнирә дә бар. Ә калганнары мәйдан читендәге юл буйлап берән-сәрән таралашкан иделәр инде.

Бу юлы хатыны озын, киң итәге астыннан тыгыз балтырларын күрсәтеп яныннан узганда, Гыйззетдин аңа үрелмәде, эндәшмәде, улын күкрәгенә ныграк кысып, читкә борылды. Хәер, Каләмгөл үзе дә аңа таба керфек какмады, аның йөзе кызарып чыккан, карашында үҗәтлек һәм ашкыну ярылып ята.

Ул икенче тапкырында да бөтен төркемнән шактый алда килде. Гаделша абзый тоткан шәлгә таба кулын сузып, сикереп куйгандай итте, әмма карт шәлне янә аның йөзе турыннан өскә таба селкеде дә кулын алга таба селтәде:

— Өчне әйләнергә кирәк! Тагын берне! Йөгер, әйдә! Йөгер!

Аңа кушылып өстәл артындагылар да үрелешеп кул изәделәр:

— Чап әйдә, чап, туктама!

Әмма Каләмгөл инде туктап калган, адымнарының көен югалтып, сулышына капкан иде. Ул, гаҗәпләнеп, үзеннән ни таләп иткәннәрен аңлый алмый торган арада, арттан килгән төркем аны узып та китте. Шунда гына Каләмгөл үзенең хатасын аңлады, тегеләр артыннан ияреп китте. Ләкин ул инде бар көчен биреп бетергән, хәзер аның адымнары элеккечә җиңел түгел, башы да артка ныграк каерылган иде. Ул инде ирен күрү түгел, мәйдандагы кешеләрнең йөзен бөтенләй аермый, алар аның күз алдыннан тоташ бер агым булып сызылып кына уза, йөрәк дөпелдәве аша ни кычкырганнарын да ишетерлек түгел.

— Ну, бу бүләк өчен генә чапмый инде,— диде җирдәге одеялга, алдындагы сыра шешәләре, ипи сыныклары, каклаган каз, тавык калҗалары янына кырын яткан Фаяз. Бу рәвешле яткач, аның корсагы аеруча бүлтәеп чыккан иде.— Шәл өчен генә түгел бу чабу, ә, Гыйзди?

Әмма Гыйззетдин дә аны ишетерлек хәлдә түгел иде. Ул, йөрәге сызлагандай, төркемне ерып, читкә, кешеләр артына чыкты; күрәсең, арыган чабыш аты кебек әледән-әле сөрлегә башлаган хатынына карап торырлык тәкате калмаган иде. Хатыннар ахылдашты, кемнәрдер көлде; Фаяз, кырын яткан килеш:

— Ничава, бирешмәс, биергә оста бит ул,— дигән булды.

Ләкин ул биреште. Янәшә йөгергән биш хатын-кыз, алар арасында Мөнирә дә аны уздырмадылар: аңа бәлки туктарга, түгәрәктән чыгарга кирәк булгандыр. Ләкин түгәрәктән чыгучылар Каләмгөл түгел шул алар! Ул алтынчымы-җиденчеме булып килде, иелеп сузылган Гаделшаның кулыннан кечкенә ак яулыкны битараф хәрәкәт белән алды да шундук читкә атлады. Халык арасына кермәкче булды, ләкин барын җитә алмады, чирәмгә авып төште. Аны шундук хатын-кызлар уратып алдылар.

Гыйззетдин улын җиргә бастырмакчы булды, малай, елап, аның кулына ябышты. Әтисе, сабырсызланып, мәйданны әйләндергән кызыл тасма аша әчкә атлады. Балкыш елаган малайны күтәреп алды.

Гыйззетдин мәйдан аша йөгереп китте. Тирә-яктан аңа бөтен халык текәлеп карап тора, шаярып кычкырган, көлгән, җырлаган тавышлар яңгырый — ә ул берүзе йөгерә иде. Бүрәнәгә атланып капчык белән бәрешкән агайлар турыннан, озын колгага үрмәләгән малай турыннан, кәкре мөгезен бәйдән ычкындырырга тырышып тартылган тәкә турыннан, туфракка тапланган сөлгеләрне билләренә урап, иелеп көч сынашкан егетләр турыннан, күзен яулык белән бәйләп, таяк күтәреп чүлмәк ватарга килгән апайлар турыннан...

Ул килеп җиткәндә Мөнирә, кечкенә чемоданын актарып, шприцын алган, энә очыннан даруны сиптергән иде инде. Ул монда да шәфкать туташы икәнен онытмаган, бөтен кирәк-яракны алып килгән! Менә ул Каләмгөлнең беләгенә үрелде, мамык белән аны ышкый башлады.

Шунда Каләмгөл, кинәт аңына килгәндәй, кулын аның бармакларыннан тартып алды да Гыйззетдингә сузды. Гыйззетдин аны сак һәм нык хәрәкәт белән тартып аягына бастырды. Ярый әле аларны хатыннар урап алган, ярый әле, тегеләй ит тә болай ит, дип кыткылдап торалар, югыйсә, бөтен мәйдан алдында өчәү генә басып калсалар, ни галәмәт кәмит булыр иде!

Кинәт кемдер Балкышның колак төбендә диярлек кычкырып көлеп җибәрде. Борылып караса, янында Зиләйлә басып тора. Ул, күзләрен кысып, тип-тигез, тып-тыгыз тешләрен күрсәтеп, башын артка ташлап, кинәнеп көлә иде. Балкыш кулындагы бала куркып китте, нәни, йомшак куллары белән егетнең муенын кысып кочаклады, башын аның артына яшерде.

— Нәрсә көләсең, ни кызык бар? — дип сорады Балкыш.

— Тамаша бит, көлке!

— Авызың ертылмасын,— диде Балкыш.

— Үз авызым бит, синеке түгел! Сиңа да бүләк бирделәрме әллә? — диде кыз, балага ишарә итеп.— Нинди ярышта җиңгән өчен?

Балкыш аның кызарынган, чибәр йөзенә текәлеп карады: моңарчы һәр очрашканда бик матур, җанга газиз күренгән бу йөзне бүген әчке үчләнү, усал тантана бозган иде.

— Кызык бүген сабан туйлары! Ха-ха-ха!

Давыт аңа кистереп җавап бирергә дип авыз ачкан иде, янын-

дагы кешеләргә карады да телен аркылы тешләде.

— Шулай инде ул, яши белмәгән кеше бөтен халык алдында көлкегә кала,— диде кырын яткан Фаяз, бик акыллы кыяфәт белән.

— Ә кайберәүләргә көлми торса да ярый! — диде Зиләйлә, кинәт көлүеннән туктап, аңа усал итеп карады.— Үзләренең адәм көлкесенә калган чакларын исләрендә тотсыннар!

— Ах, син, эттән туган нәрсә! — Фаяз калкына төште.— Мин сине кыйбатлы кыз дип тормам, телеңне кисеп кенә алырмын!

— Син кисә торган телләр безнең авызда түгел шул!

Зиләйлә, үзенә кизәнгән Фаязны читләтеп үтте дә, көлә-көлә халык арасына кереп китте. Микрофоннан:

— Шофер Зарипов! Шофер Зарипов! Трибуна янына килегез! — дигән тавыш ишетелде. Балкышны чакыралар иде. Ул, кулында тыпырчынган баланы Фаяз янына куйды да, ашыгып китеп барды. Балкышны Нурханова чакырткан, Каләмгөлне больницага илтергә кирәк икән. Гыйззетдин аны күтәреп диярлек арткы утыргычка утыртты, үзе дә машинага кермәкче иде, хатыны кулы белән читкә этәрде:

— Баланы соң кем карый?

— Авылдашларыгыз янында калдырдым — диде Балкыш.

— Үзең кара... үзең...— Каләмгөл Гыйззетдинне тышка этәрде.— Әнә, Зарема утырсын минем янга.

Зарема әнисе янына менеп утырды. Балкыш кузгалып киткәндә Зиләйлә, Зарема ташлап киткән машина әрҗәсенә менеп басып, бөтен көченә кычкырып җырлый иде:

Җилләр исә, җилләр исә,
Җилгә бөгелә гөлләр;
Безгә түгел, дошманга да
Килә ул кара көннәр!..

Басу юлы аларны олы юлга алып чыкканда, сабан туе бөтен чуарлыгы, шау-шуы һәм тынгысыз дулкынлануы белән артта калган иде инде. Аннан тонык һәм аңлаешсыз булып микрофон аша сөйләнгән сүзләр генә килеп ирешә иде. Асфальтка күтәрелә башлагач, Каләмгөл тар, көчле, кайнар учын Балкышның иңбашына салды:

— Авылга таба борыл.

— Больницага барабыз түгелме соң? — диде Балкыш, аптырап.

— Син кая барасыңдыр, белмим, ә без өйгә кайтабыз.

— Нурханова әйтте бит...

— Нурханованың үз юлы, безнең — үзебезнеке. Илтәсең килмәсә, турысын әйт, без монда төшеп калабыз.

— Ничек инде мин сезне юлда ташлап калдырыйм?

— Алайса, әйткән җиргә илтеп куй.

Балкыш машинасын сулга, авылга таба борды.

## 29

Әйтерсең, бүгенге көннең кояшы, яшеллеге, җиләс җиле, чуарлыгы, хәрәкәте фәкать бер ноктаны яктырту, ачыклау өчен генә кирәк, бәйрәмнең бөтен яме, мәгънәсе фәкать анда гына тупланган.

Бу нокта — Гаяров иде.

Мәйданга башкалардан алданрак килгән Нурханованың йөрәге сызлау дәрәҗәсендә борчылган, моның сәбәбе яңгыр яуганга борчылудан, дип уйлаган иде ул. Әмма елмаеп кояш чыкты, сабан туен башлап җибәрделәр, ә йөрәкнең сызлануы үтмәде, кимемәде. Нәрсәдер җитми иде Фидаяга, нәрсәдер кәтә һәм юксынудан бәгыре телгәләнә иде аның.

Менә, ниһаять, трибунадан ерак түгел таныш «Газик» килеп туктады. Нигәдер соңарып килделәр. Ә бәлки... ә бәлки хатыны озак җыена алмагандыр. Әнә ул хатын — бөреп, мул итеп тегелгән карасу-кызыл күлмәк кигән, итәге тубыгыннан ук булганга, буйга бигрәк зифа, озын булып тоела. Шома кара чәчен баш артына пөхтә дә, тыенкы-горур да итеп өеп куйган, матрос костюмы кигән биш яшьлек улын җитәкләп, туп-туры алдына карап бара. Малай икенче кулы белән әтисенең бармагыннан тотып алды. Алар шулай, өчесе янәшә барып, ашыкмый гына трибуна каршыннан узып киттеләр. Фидая йөзенең алланып чыкканын тойды, ул үзен кимсетелгәндәй хис итте. Гаяров аңа сәлам бирмәде, бәйрәм белән котламады. Хатыны исә трибуна тарафына башын да бормады, буш аланнан баргандай, үз юлы белән атлый бирде. Уртасыннан сабый белән ныгытылган өч кешедән торган бу чылбыр, өзелмәстәй нык, дип исбатлый иде кебек ул. Тигез, имин, ышанычлы тормыш менә шушындый була, дип, һәр адымы белән горур рәвештә раслый иде шикелле.

Бөтен мәйдангамы, әллә берәр кешегә, Фидаяга гынамы? Фидая бу өчәүне күңел түрендә аермачык саклады. «Минем беркайчан да алай узасым юк инде, беркайчан да, беркайчан да, беркайчан да...» — дип сулкылдады аның күңеле.

Алар, мәйданны уң яктан әйләнеп, Каләмгөлнең җыр машинасы янына ук диярлек барып бастылар, берара халык төркеме артында күздән дә югалдылар, әмма Фидая Давытның кайда икәнен тоеп торды һәм аның да үзен күзәткәнен сизде сыман.

Сәгать ике тулганда, бөтен ярышлар уздырылган, бүләкләр өләшенеп беткән иде инде? Менә мәйдан халкы, уңга авышып, юртаклар ярышын карады.

Менә, ниһаять, төп батыр да билгеләнде, ак майкасы тапланып беткән, таза беләкләре кызарып чыккан киң җилкәле, озын буйлы егетне үсмерләр, малайлар, дус егетләре уратып алды, баганадан тәкәне чишеп, аның муенына салдылар — батыр сыгыла төште.

Халык таралыша башлады. Гаяровлар, ашыкмый гына, баягыча ук тотынышып, янә мәйдан аша уздылар. Бу юлы Давыт борылып та карамады, нәкъ Фидая турысына җиткәч, хатыны горур муенын бора төште, иренә нәрсәдер әйтеп куйды.

Комиссия члennары мәйдандагы әйбер-караны җыеша башлаганнар, инде хәзер Нурхановага китсә дә ярый иде. Ләкин нишләптер Балкыш Каләмгөлне больницага илткән җиреннән һаман килеп җитми иде әле.

Майданны аркылыга иңләп, киң рәт булып тезелеп, урта яшьләрдәге хатыннар — сыер савучылар җырлап узды.

Баллыболынның мулла урынына йөри торган карты — кечкенә гәүдәле, мөлаем чырайлы, түгәрәк ак сакаллы Фәтхрахман абзый аларга каршы юлыкты, ул кемнеңдер машинасы янына ашыга иде. Фидая, тураеп, бу күренешне күзәтеп торды, ничектер сәер иде: рәт булып тезелгән унлап хатын мөхтәрәм абзыйга каршы җырлап киләләр. Нәрсәседер бик үк матур түгел иде моның. Әллә инде Фидая күңелендә сакланып калган, әбисе өйрәткән әдәп кагыйдәсе искә төште: өлкәннәр каршында кычкырып сөйләшергә ярамый, авыз күтәреп җырлау килешми. Әмма заманалар белән бергә абзый да үзгәргән иде бугай, ул, ләхәүләсен укып, читкә тайпылмады, хатыннарга юл биреп, бераз гына борма ясап узды, аның йөзендә елмаю иде...

Фидая янына, Иркәне җитәкләп, Шәрифә килде. Аның яулыгы бер якка авышкан, арыган, талчыккан йөзендә куаныч балкый иде. Шулай булмый ни, көннең көн буе Иркә белән бергә булды бит ул, көннең көн буе аның күңелен күрде! Ләкин шул ук вакытта йөзенә ялвару галәмәте дә чыккан, ул менә хәзер кызчыкны әнисе алып китәсен белә, аерылу минуты җиткәнгә йөрәге әрни башлаган иде.

инде.

Трибуна артында тәрәзәсез генә бер куыш ясалып, анда тамак ялгарга сумса-пәрәмәч ише әйберләр, шешәле сулар куелган иде. Фидая аларга су эчерде. Шәрифәнең кыенсынып, ничектер ялварып елмайган йөзенә карады. Аның Иркә белән аерыласы килмәгәне күренеп тора иде. Ә машина һаман килми...

Фидая Иркә белән әбисен культура йорты машинасына утыртып кайтарып җибәрде — Шәрифә, бөтен арыганнарын онытып, яшәреп китте.

Алар китеп баргач кына килде Балкыш. Хәзер инде Фидаяның беркая да ашыгасы юк иде. Һәм ул, асфальт юлга күтәрелә башлагач, Балкышка борылды да:

— Баллыболын каенлыгын бер әйләнеп кайтыйк әле,— диде.

Шофер егет аңа гаҗәпләнеп карады: бүген аңа икенче тапкыр, уңга барасы урынга, сулга борылырга кушканнарын әйтте. Фидая көлеп куйды, ләкин артыгын сорашмады, ул үз уйларына чумган иде.

Элекке елларда алар сабан туеннан соң дуслары белән бергәләшеп Баллыболыннан өч чакрым тирәләрендәге каенлыкка бара торганнар иде. Бу көнгә уртакка сарык алып суялар, учак ягып, шашлык кыздыралар. Чирәмлектә табын әзерләнә, анда һәркем хәзинәдә барын алып килгән була. Шунда ук үлән арасыннан оялчан-тыенкы гына, белгән кешеләр өчен генә саркып чыккан кизләве дә бар. Үр артына ышыкланган бу урында алар үз ярышларын оештыралар, йөгерешәләр, таяк тартышалар, көч сынашалар, җырлыйлар, бииләр иде. Мәңге шулай булыр кебек иде, әмма бергә чаклар бер генә икән шул. Бүген ул урын да ятимдер, тындыр. Фидая үзе генә килер дә, үләнкерфекләрен яшьле күздәй чылатып, күккә карап яткан кизләүдән үрелеп су кабар, бәхетле көннәрен, сөйгәненең баян моңнарын исенә төшереп, ямансулап алыр.

Юлдан борылып, чирәмлектә чак кына беленеп торган машина тәгәрмәчләре эзеннән калкулык артына юнәлгәч, ул бөтен тәнендә, рухында зур эшне башкарып чыкканнан соң, кеше күзләреннән арынгач була торган чишелү, таралу, юксыну тоя башлаган иде инде.

Әмма үрнең икенче ягына чыгуга, ул нәкъ элекке урында җәелгән табын һәм аның тирәсендә кайнашкан хатын-кызларны күреп алды. Учак та ягылган, анда берничә ир кеше болгана: шашлык кыздыралар. Укытучылар элекке гадәтне ташламаганнар, җыелышып килгәннәр. Бер читтәрәк эреле-ваклы бала-чага куышып-уйнашып йөри.

Машина килеп туктап, Фидая чыгуга, табын янындагы хатын-кызлар кулларын сузып, хуплап, ачык йөз белән аңа таба атладылар, кочаклап аркасыннан каккаладылар. Ләкин ачык чырайларда, күз карашларында нинди дер бер сагаю, эчке мәгънә тоеп алды Фидая. Ни генә әйтсәң дә, ул хәзер монда иш түгел, артык иде. Беренчедән, ул ялгыз, ә ялгыз хатын парлылар янына сыймый. Икенчедән, ул хәзер урындагы кеше, шулай булгач, хәзерге ишләре — район җитәкчеләре белән булырга тиеш. Тик, күрәсең, анда да иш итмәгәннәрдер, югыйсә, оясыннан аерылган, адашкан каз кебек мәнсез рәвештә монда килеп чыкмаган булыр иде...

Хатыннар белән янә кочаклашып, Әхсән белән кул бирешеп күрешкәндә һәм янә бәйрәм белән котлаганда, Фидая күз кырые белән ике кешенең кыяфәтен күреп алды: аларның берсе табын янында тураеп басып калган Фазилә иде, кочагын җәеп Фидаяга каршы килергә аның сәбәбе дә юк — алар таныш түгелләр. Гәрчә икесе дә берберсенең кемлеген бик яхшы белсәләр дә. Икенчесе — учак янында билен бөгеп нәрсәдер рәтләштергән Давыт иде. «Нигә килми ул? — дип күңеле сыкранды Фидаяның.— Ни дисәң дә, мин җитәкче кеше, авылның хуҗасы буларак, ул бу табынның да хуҗасы, иң беренче ул каршы алырга тиеш бит мине!»

Ләкин хуҗа Фидаяны да, ул килгәннән соң купкан ыгы-зыгыны да күрмәмешкә салышты, әллә ут өстендәге ит калҗаларын караусыз калдыра алмадымы — килмәде. Фазилә исә, бөтен кыяфәте белән бу аланлыкның, каенлыкның, аның уртасындагы кизләүнең, аннан да бигрәк, учак янындагы ирнең хуҗасы икәнен исбатлагандай, калкулык күкрәгендә биегәеп, ныгып басып тора иде. «Кермә минем өлешемә!» — дип кисәтә иде ул гүя. «Әллә соң теге наратлыкта булганны Давыт аңа сөйләде микән?» — дигән уйдан «жу» итте Фидаяның йөрәге.

Кизләү янына барганда ул кинәт: «Эти-и!» — дип кычкырган бала тавышын ишетте. Матрос костюмлы малай бар көченә учакка таба, Давыт янына йөгерә иде. Ул кулларын алга сузган, башын артка ташлаган, көлә, башлыгы артында зәңгәр тасмалар җилферди, күкрәгенә тузганакларның ак башлары өрелеп сибелә. Фидаяның күз алдында бу минут әкеренәйде, сузылды кебек: «Эти-и!..»

Фидая куе, дымлы үлән сабакларын аралап, кизләүгә иелде, салкын суны кушучлап алды да йөзенә каплады.

## 30

Язгы чәчүгә кадәр Кармаш больницасының стеналарын торгызып куя алдылар. Үзенә мактаулы исем бирүне көткәндә һәм туган көненнән соң Мирхуҗин, чыннан да, ул төзелешкә игътибарны нык бирде, хәрәкәтсез калдырмады.

Ләкин чәчү чорында һәм аннан соң да Нурханова төзелеш оешмасының башка корылмаларны алга чыгарганын тойды. Кайчан барма — шул ук кирпеч өемнәре, плитәләр кузгалмаган килеш ята; ә Мирхуҗин, елмаеп, дәртләнеп җавап бирә иде:

— Менә «Җиңүче»нең җәйләвен генә кеше карарлык итик, райбашкарма үзе кыздыра бит... Менә «Таң»дагы культура йортын тапшырыйк, квартальный план яна бит... Менә... Эшлибез аны, Фидая Госмановна! Бер тотынсак, очламыйча туктамыйбыз!

Әмма аның кысылган күзләренең карашыннан сизелеп тора: ул инде Нурхановaны бәхилләттем, дип саный. Матур язылган характеристика өчен дә, исем сорап Казанга шалтыратып торганнары өчен дә, ахыр чиктә, туган көндә бирелгән затлы бүләк өчен дә. Тулысынча түләнгән һәм вәссәлам. Моңарчы бу хатын алыш-бирешне үзенчә алып барды, инде хәзер Мирхуҗин үзенең гайрәтен күрсәтергә, кулга-кул сугышканда үз бәһаләрен куярга тели иде.

Нурханова, аңа гына ышанып тормыйча, яздан Казанга барып, төзүче-инженерлар институтыннан армия хезмәтен үткән, тәҗрибәле студентлардан оешкан бер отряд белән сөйләшеп кайткан иде. Имтиханнарны алданрак биреп киләләр, көне-төне эшлиләр һәм хакын да иң зурдан алалар. Эштә тоткарлык булмасын өчен бетон плитәләр, гудрон, рубероид, такталар, балкалар — һәммәсе кайтартылып куелды, монысы да җиңел булмады. Иң хәтәре студентларга акчаны түләү ягын җайлау иде. Аның өчен колхозлардан төзү оешмасына акча күчертергә кирәк, төзүчеләр эш хакын шул оешма аша алачаклар. Мондый очракта колхозлардан акча алу — хәвефле адым, ревизия тикшереп очына чыга башласа, суд тикшерүчесе каршына барып җавап бирү ихтималы да күз алдында тора иде. Колхоз җитәкчеләре телдән кушуга гына риза булмадылар, башкармадан кәгазь таләп иттеләр. Инде бу кадәресенә барып җиткәч, Нурханова акылына килер, күрәләтә закон бозуга бармас, дип өметләнгәннәр иде, әмма Нурханова үз имзасын куеп, аларга башкарманың рәсми күрсәтмәсен язма рәвештә җибәрде.

Бер җыелыш алдыннан, райбашкарма коридорында Ясәвиев:

— Алдан ук кисәтеп куям, Фидая Госмановна, бу хәлләрне казып чыгара башласалар, мин сезне үземнең җилкәм артына яшереп калдыра алмаячакмын, соңыннан үпкәләштән булмасын, сезнең бу кәгазегезне күрсәтергә туры килер,— диде.

Фидая аның шактый иңгән, май баскан, алай да тар җилкәләренә карап көлемсерәде.

Ясәвиевне бу эшкә «Җинүче»нең парторгы Рәсимә Фәләхова сындырган иде, ахрысы. Һәркемгә мәгълүм, анда эш башында, асылда, шул үткен, уңган, акыллы хатын тора. Ясәвиев өчәр ай авырып ятканда да хуҗалыкта берниндн үзгәреш сизелми, әмма моны барысы да күрмәмешкә салышалар. «Җинүче»нең алдынгылыгын тәҗрибәле Ясәвиев казанышы дип исәплиләр. Фәләхова үзе дә алга чыгарга ашкынмый; ул, кеше аркасына ышыкланып, зур эшләр майтаруны үзенә бер кызыкка саный иде, күрәсең.

Студент егетләр киләсе чакны көнләп түгел, сәгатьләп көтте Фидая, торак, ашау-эчү якларын кайгыртты. Иртәнге якта автобус белән килеп төшәргә тиеш иде алар. Фидая, эшкә килүгә, Мирхуҗинга шылтыратты. Ул үзе каядыр чыккан икән, секретаре җавап бирде. Әйе, студентлар отряды Казаннан килеп төште. Аларны шундук автобус белән «Спартак»ка озаттылар да инде, диде. Ничек «Спартак»ка? Нурханова башта аңламый торды. Нишләп «Спартак»ка? Секретарь йомшак кына аңлатып бирде: анда азык кухнясын эшләп бетерәсе бар. Искәндәров бик каты кисәткән, ярты еллык тәмамланганчы сафка бастырырга, дигән. Шуңа Тавис Миргазимович бик ашыктырып җибәрде дә бу отрядны.

Фидаяның бугазына төен килеп тыгылды.

— Кабахәт! Менә нишләтә бит! Әйтү-нитү юк, үз дигәнен эшли, бар дип тә белми, санга сукмый! Ну, күрсәтәм хәзер үзенә дә!

Балкыш машинасын гараждан бик озак чыгарган кебек тоелды. Хәтта машина да Фидаяга каршы, бөтенесе аңа аяк чалырга көйләнгән кебек иде. Аның ачуы кабарганнан кабара бара; ул, хәзерге минутта каршына Мирхуҗин килеп чыкса, аның битен-күзен тырнап бетерергә әзер иде!

— Тизрәк бул инде, нәрсә мыштырдыйсың! — дип ашыктырды ул Балкышны гараж ишеге төбендә.

Ул килеп кергәндә Мирхуҗин уңайлы, иркен кәнәфиендә түрәләрчә кырын утырып телефоннан сөйләшә иде. Нурхановны күргәч, сул кулын күтәреп сәламләгәндәй итте, елмаеп баш какты, ә үзе сөйләшүендә булды.

Фидая ишектән түргә ашыгып үтте дә, өстәлне әйләнеп узып, ул сөйләшеп утырган телефонның рычагына басты. Мирхуҗинның күзләре түгәрәкләнде; ул, урыныннан калкына төшеп, гаҗәпләнүеннән телсез калып, Фидаяга текәлде.

Фидая, аның янына ук килеп, өстән аска таба карады:

— Кайда студентлар?

— Нинди студентлар?

Тависның муены җыерылган, күзләре шар ачылган иде. Кара син аны, күзләре шактый зур икән үзенең!

— Казаннан мин чакырып китергән студентлар кайда?

— Алармы? Алар «Спартак»та.

— Ә нигә «Спартак»та?

Мирхуҗин тураеп утырды, костюм якаларын төзәтеп куйды.

— Нәрсә, «Спартак» гаеп җирме әллә? Үземә мунча салырга кушмаган,— диде ул кинәт, тупас итеп.

— Син нәрсә, мине шыр тилегә саныйсыңмы әллә? «Спартак» өчен чакырдыммыни мин аларны? Нинди оятсыз син, ә?

Фидая аның каршына басып сөйли, сөйләгән саен кыза, ныграк кычкыра башлады:

— Беләм бит мин синең нигә шулай кыланганыңны! Ни теләгәнеңне дә беләм! Син мине үзеңнең сөяркәң итмәкче буласың, менә нәрсә телисең син!

Мирхуҗин аңа куркынып, гаҗәпләнеп карады, шул ук вакытта ул, Фидая кычкырынган саен, тынычлана да бара иде шикелле.

Ул инде кәнәфиенә ныклап, җайлап утырды, кулларын өстәлгә куйды. Фидая сулышына буылып тынып калгач, ишеккә таба ымлады:

— Сез ишекне ябарга онытгыгыз,— диде.— Бөтен кеше ишетеп тора бит!

— Ишетсеннәр, бөтенесе белсеннәр синең кемлегеңне! Синең кебекләр аркасында авыруларны тиешенчә дәвалый алмыйлар! Кемнәрдер шуның аркасында җан бирә, беләсең килсә! Ә син... син үзеңнең нәфесеңне генә уйлыйсың, миннән теләгәнеңне алмаганга бөтен район халкына үчләнәсең! Анадан тумадыңмы әллә син?

Мирхуҗин, аның йөзенә текәлеп, кычкырып бетергәнен бер хәрәкәтсез, ишарәсез көтеп торды. Ниһаять, Фидая бушап калгандай булды, әйтеләсе әйтелеп беткән, күкрәкне буган кызу пар кимегән, ләкин әле чыгып бетмәгән иде. Ул, өстәлнең Мирхуҗинга каршы ягына чыгып, урындыкка утырды да, озакка урнашканын аңлаткандай, аркасын терәде һәм:

— Хәзер үк студентларны кайтартасың да Кармашка җибәрәсең,— диде.— Шунсыз мин моннан чыкмыйм.

Мирхуҗин сул кулын күтәрде, пинжәк җиңен кайтарып, сәгатенә карады. «Хәзер чишеп ала да минем битемә тондыра»,— дигән уй килде Фидаяның башына. Ләкин ул, сәгать чылбырын капшап, кара төкле беләгендә кайлап кына куйды, анда җемелдәгән яшькелт саннарга карап:

— Әле барып кына җиткәннәрдер,— диде тыныч кына.

— Барып җитмәгән булсалар, ярты юлдан кайтарт.

Мирхуҗинның исе китмәде.

— Кайтарырга икән, кайтарырга,— диде.— Сез начальник, сезнең власть.— Аннары, үртәгәндәй итеп: — Син начальник, мин дурак...— дип өстәде. Әле генә үзен-үзе белештермичә базар хатынындай кычкырынган Фидаядан аермалы буларак, сабыр, мәгънәле итеп карап кына куйды: әйтемнең ахырын — «мин начальник — син дурак» дигәнен кеше үзе аңларга тиеш.

— Тик менә шунысы,— дип дәвам итте Тавис, бик төптән уйлагандай итеп: — Эш фронты җитәрме икән соң?

— Нәрсә башны катырасың? Бөтенесен китереп ташлаганны әллә кайчан беләсең бит инде!

— Ике отрядка, дим, эш җитәрме, бер-берсенең аяк арасында буталып кына йөрмәсләрме?

— Нинди ике отрядка?

— Соң, анда кичә үк бер бригада китте бит инде. Тоташ инженерлардан торган бригада, вуз укытучыларыннан. Ун кешелек. Алдан килеп карадылар, проектта җитешсезлек таптылар, аларын да төзәтеп, медицина техникасын монтажлау өчен бөтенесен күздә тотып эшләргә булдылар. Өстәмә түләү турында Гаяров белән килештек. Эшкә керешкәннәрдер инде. Әле менә Билалдан шуны сорашып тора идем, сез килеп, сүзне өздегез.

Фидая, аның күзләренә карап, тынсыз калды. Юк, Мирхуҗин аннан көлми, утырттыммы, дип тантана итми, ул тыныч, йөзе җитди, хатын-кызның болай ямьсез, нахакка кычкырынуларына аның артык исе дә китмәгән, аның мыскыллауларын, яла ягуын ул җитди дип кабул да итмәгән. Менә шушы җитдилеге, үзен берни булмагандай гадәти тотуы белән үз-үзен тота белмәгән бу хатынны утыртты да инде ул!

Фидаяны беркемнең дә, беркайчан да бу кадәр кимсеткәне юк иде әле. Ул, пинжәк кесәсеннән кулъяулыгын алып, кызгән битен сөртте. Еламаска... Күз яшьләрен күрсәтмәскә... Мирхуҗин, урыныннан кузгалып, тәрәзә буендагы өстәлдән стакан алды, графиннан су салып бирде. Фидаяның тамагыннан су да үтәрлек түгел иде, ул бер генә йотты. Мирхуҗин аны үзе эчеп бетерде, аннары, барып, ишекне ябып килде.

Фидая аның авыр, эре адымнарын күзәтеп утырды. Әйе, ирләр басканда идән сыгыла. Алар, әнә, бер-берсе белән сөйләшкәннәр дә килешкәннәр. Аны, хатын-кызны, уйламаганнар да, адәм чутына да кертмәгәннәр. Аның башы аша киңәшеп, бөтенесен хәл иткәннәр дә куйганнар. Бар да бер иш... Билалы да, Давыты да. ...ник берсе аңа, шундый-шундый үзгәреш булды, дип әйтсен! Ә нәрсәгә аны катыштырып торсыннар, аның ыз да эш бара бит!

...авис тәрәзә янына барып басты.

— Ә теге сүзләрегез өчен мин сезгә үпкәләмим,— диде.— Сез яшь кеше, кайнар канлы, ир татыган хатын. Башыгызга төрле уйлар килүе ихтимал. Минем дә эчемдә җаным бар, сәламәт, таза яшь ир чибәр, сөйкемле хатынга сокланып, хәтта кайчакта бала башыннан сыйпагандай гөнаһсыз назларга теләп карый икән, моны тыеп булмый бит инде.— Ул бераз тынып торды.— Бөтенесен теләп итә аласың, Фидая Госмановна, тик миннән әле генә үзең караган төсле кара дошман итеп каравыңны теләп итә алмыйсың,— диде.— Син яратмыйсың икән — анысы синең эш, миңа син ошыйсың икән — анысы минем эш.— Ул, көлемсерәп, башын чайкады һәм һаман әле тәрәзәгә, киң ишегалдындагы зур-зур машиналарга, тракторларга караган килеш: — Тик мине, шушы гөзелештә чатаклыклар китереп чыгарып, үземне яратырга мәҗбүр итәм, дип хаталанасыз. Анысы инде минем теләк түгел, сезнең фантазия генә.

Ул борылып карады. Фидая башын иярга мәҗбүр булды. Әле бу минутта чыннан да, пычрак уйлар аның башына гына килгәнлеге исбат ителгән иде. Ә Мирхуҗинның бернинди ямьсез нияте булмаган, ул, киресенчә, эш турында гына уйлаган.

Менә ул өстәлгә якынрак килде һәм:

— Мин сиңа үпкәләмим,— диде.— Мин сине аңлыйм. Синең авыр чагың. Ә больницага килгәндә, җаның тыныч булсын: ел башында аңа беренче сырхаулар кереп ятачак. Анысын мин сиңа вәгъдә итәм. Һәм аның өчен берни сорамыйм да. Ул минем бурычым!

## 31

Сабан туеннан соң берничә көн үтеп китте, ә Каләмгөл больницага барып врачларга күренмәгән икән әле. Моны больницага кергәч юл уңаенда гына сорап белгән Фидая артык борчылмады: ир хатынының башы әйләнеп киткән чаклары булгалый, егылалар да торып китәләр. Алай да Фидая, Баллыболынга бер баруында, аның хәлен белеп чыгарга булды.

Зарема — чөгендер басуында, алты яшьлек Зөфәр — урамда. Каләмгөл янында нәни Өлфәт кенә калган икән — ул идәндә уйнап утыра иде. Хуҗа хатын үзе диванга, эре чәчәкле ястыкка аркасын терәп утырган, итәгендәге ачык журналларны идәнгә төшереп, кунакны каршы алырга күтәрелде.

Бер күз салуга, Фидая хәлнең җитдилеген аңлап алды: Каләмгөлнең йөзе суырылган, күз төпләре каралып киткән, гадәттә йолдыз кебек янган күзләрендә чоңгыл караңгылыгы шәйләнә иде.

Торып басканда да элекке нәфис житезлек сизелмәде, башы әйләнеп киткәндәй күренде. Фидая аны туктатмакчы иде, Каләмгөл кулын селтәде:

— Кем дип беләсең мине? Шундый кунакка чәй дә куймаска!

Ул аш бүлмәсенә чыкты. Фидая аңа иярде. Каләмгөл ак күмәчне юка телемнәргә телеп, йомыркага манып, кызган табада кыздырып алды, электр самавырын тоташтырды.

— Ник син теге көнне туры больницага бармадың? — дип сорады Фидая.

— Ни калган анда миңа? Өйгә кайтасым килде.

Каләмгөл тирәсендә, гадәттәгечә, бөтен нәрсә хәрәкәткә килгән: үзе көлә, таба чыжылдый, самавыр пар бөрки, чынаяклар гүяки үзләреннән-үзләре чәчәкле ашъяулык өстенә килеп тезелә... ик менә киң итәге генә элекке дәрт белән җилпенми, күзләрдән моң китми.

— Хәзер, бер-ике чынаяк чәй эчәбез дә, бергәләп барып килербез, минем машинада,— диде Фидая.

— Больницагамы? Таптың чакырыр урын,— дип көлде Каләмгөл, үткен һәм матур тешләрен җемелдәтеп.

— Син — культура кешесе, аңлагу да оят,— диде Фидая.— Бу рычын яшергән бөлгән, чирен яшергән үлгән.

Бик җиңел генә әйтте ул моны, әмма Каләмгөл аңа бик текәлеп карады. Калагы белән чынаяктагы чәен болгатты. Ни уйлаганын аңлап булмый иде.

— Үлү дөньяда бар нәрсә,— диде аннары, чәенә караган килеш.— Иң гаҗәбе ул түгел. Иң гаҗәбе — менә синең минем янга кереп, кара-каршы чәй эчеп утыруыбыз.

— Инде син кунакка чәй куюны да гаҗәпкә саный башладыңмы әллә? — дип сорады Фидая.

— Кунагы нинди бит!

Каләмгөл маңгаена сибелгән чәч бөртекләрен бизәкле яулыгы астына сыпырып кертте. Фидая аны аңлаудан гаҗиз иде, дәшмәде.

— Хәтерлисеңме, беренче елларны ничек карый идең син миңа! Кая ул өйгә керү, клубта да тешеңне кысып кына чыдый идең. Әллә нинди чегәнгә ияреп чыгып китеп, бала иярттеп кайткан, кеше ирен таргып алган, баланы ятим иткән, бар белгәне уен да көлке... Шулай уйлый идең бит минем хакта, әйе бит? Гыйззәтдингә сөйдергеч эчергән, дигән гайбәтләргә дә ышангансыңдыр әле!

Фидая кып-кызыл булып кызарынып чыкты. Кызып-кызып Мәгъсүмгә Каләмгөлнең начарлыгын исбат иткән, бәхәсләшкән чаклары искә төште. Әйе, ул чакта икәүдән-икәү шушылай кара-каршы чәйләр эчәрсез әле, дисәләр, чәчрәп каршы төшкән булыр иде ул!

Каләмгөл аның кыенсынып калганын күрмәмешкә салышты, табынны рәтләштергән булып кыланды.

— Син генә түгел, авылдагы хатыннарның күбесе шулай,— диде.— Менә хәзер ничә көн өйдә ятам, кереп караган, хәлемне белгән апалар юк. Кызлары гына килә! Аналарыннан качып киләләр, ындыр артлап. Әллә ничәсен тотып-тотып тукмадылар инде. Клубка йөргәннәре өчен дә бик каты эләгә бит, барыбер киләләр! Шуларга яңа җырлар эзлим менә.— Ул олы як идәнендә чәчелеп яткан журналларга ишарәләде.

— Синсез тора алмый инде алар! — диде Фидая, сүзнең үзеннән күчкәненә сөенеп.

— Минсез түгел, җырсыз-биюсез, күңел ачусыз яши алмый кеше.— Аннары, бөтенләй бәйләнешсез рәвештә, хәйләкәр көлемсерәү белән әйтеп куйды: — Нишләп эчмисең? Сөйдергеч салган дип куркасыңмы әллә? Курыкма, сиңа сөйдергечнең кирәге дә калмаган, болай да гашыйк булгансың инде!

Фидая тетрәнеп китте. Бу ни дигән сүз? ...инди гыйшык? ...иткән урынсыз шаярту бу?

Каләмгөл җентекләп аның йөзендәге үзгәрешләрне күзәтә, бөтен уй-хисләрен үтәли күрә сыман иде.

Фидая үзен кулга алырга тырышты, елмайды, шаяртkандай кыланып, алга таба иелә төшеп, пышылдап диярлек:

— Кем әйтте? — дип сорады.

— Алдамый-ялгышмый торганы.

Каләмгөл урыныннан кузгалды да янә алгы бүлмәдән әйләнеп чыкты. Бу юлы аның учында уен кәртләре, ул аларны күз иярмәс җиңел хәрәкәт белән бутый иде.

— Менә кем әйтте,— диде ул, Фидаяга карап.

Фидая көлми булдыра алмады:

— Ә нишләп алар сиңа минем гайбәтне сөйли? Нигә башканыкын түгел?

— Мин сиңа күп тапкырлар кәрт ачтым. Элекке елларны килеп сораган булсаң, күрәчәкләреңне әллә кайчан әйтеп куйган булыр идем дә бит, син горур идең шул, эре. Бәхетле, тәртипле, минем ишеләр белән бутала торганнардан түгел.

— Ә нигә син миңа кәрт салдың?

— Язмышыңны беләсем килде. Авыл хатыннарының башкаларына әллә ни ис китми иде минем, аларга түзеп була, ә менә синең миңа кимсетеп, гаепләп каравың гарьләндерә иде. Ник мин сиңа үпкә-рәнҗүемне әйтмәдем. Белә идем синең башкаеңа ниләр киләсен.

Каләмгөл учында уйнашып, алышынып торган, бер ягы кара бизәкле, шома, гүяки тере кәртләргә ишарә ясады:

— Ышанмасаң, үзең кара.

Ул чынаякларны бер читкәрәк этәреп куйды, кәртләр, аның озын бармакларыннан канат җәйгән кебек очып чыгып, өстәл өстенә бер-бер артлы сибелә башладылар:

— Син — черви дамасы... Ни булган, ни булачак, ни белән тәгәлләнәчәк... Йөрәк өстендә нәрсә, йөрәк түрендә нәрсә... Менә, үзең кара, гел шулай төшә. Нәрсә булган... Менә ике король, карга короле һәм буби короле... Өйләнгән кеше, димәк. Аларның сиңа интереслары. Менә күрешү булган, буби короле белән. Аның сиңа мәхәббәте, синең аңа интересың. Ләкин арагызга карга короле төшә. Нәрсә булачак?... Буби короленең сиңа юлы... зур сөйләшү... күз яшьләре... Нәрсә белән тәмамлана? Бик зур удар булачак, карга короле тарафыннан... Синең озын юлың белән тәмамланачак.

Фидая чынбарлык табигыйлегеннән каядыр башка бер мохиткә, аңлаешсыз, зиһен җитми торган, шул ук вакытта күңелне ургыткан хисләр белән бәйле дөньяга күчеп киткәндәй булды. Йөрәген шом басты. Каләмгөлнең сөйләгәне юк нәрсә, дип ышандырырга тырышты ул үзен, әмма күз алдына Давыт килде, Тавис килде. Каләмгөл сөйләгәннәр нәкъ шулар хакында кебек тоелды.

— Нәрсә йөрәк түрендә — әһә, менә ул — синең мәхәббәтең... буби короленә, ләкин арагызга тагын карга короленең интереслары төшә. Нәрсә йөрәк өстендә — буби дамасының интереслары, аның сүзе ... да хак!

— ...й-яй, дошманың күбәйде соңгы вакытта, Фидая! Элегрәк ...ренми иде! Күңелем сизә: минем баштан кичкән хәлләр ...а килә!

...л озын, хәрәкәтчән бармагы белән кәртләргә төртте. Аннары ө... лдән читләште, алгы бүлмәнең ишеге турына барып басты — монда ул кысага куелган сурәт кебек тоела, яктылык күрше бүлмәнең тәрәзәләреннән, арткы яктан ныграк төшкәнгә күрә, йөзе хыялый, илһамлы төс алган иде. Мондый йөзләр, гадәттә, өндә түгел, төсле, хәрәкәтле, тиргә батыра торган һәм хәтергә озакка сеңеп кала торган төшләргә керә.

— Әйе, элегрәк дөрес уйлый идең, үзеңчә гадел идең. Үз бәхетеңне кеше бәхетен җимереп төзергә ярамый, кеше баласын ятим

итәргә ярамый. Шулай бит? Шулай. Ә син сөю хәлләрен белә идеңме соң? Ул каршыңа килгәндә, бөтен дөнья томанланып, аның йөзе, аның карашы, аның елмаюы гына күзгә күренә. Гел аны гына уйлап була, аннан башка дөньяда яшәүнең дә кирәге юк кебек. Аңа күл белән орыну түгел, бер карап, бер-ике авыз сүз сөйләшер өчен генә дә уларга, җан бирергә әзер чаклар була. Әй, син каян беләсең аны! Иреңне яратмый идең бит син.

Фидая урыныннан калкына төште.

— Дәшмә. Ирең сине ярата иде, ә син бары аның сөюен кабул итә идең. Әйе, рәхәтен күрә белдең. Шул гына. Син үзеңне күрсәтергә, шушы авылда гына булса да кемнәрдер беләндер идарә итәргә омтылдың. Лидер майтарган булып кыландың. Ә ул белә иде синең йөрәгеңнең салкын икәнен. Белә иде! Әмма түзде. Ул синең аны дус иткәнеңә, анда-монда тайпылып, башкаларга карамаганыңа канәгать булып яшәде. Чын сөюне син менә хәзер тоячаксың. Әйе, аның өчен тәнең, рухың уянган булырга тиеш иде синең. Кояшның беренче нурлары чагылышын тойган булырга тиеш идең. Аннары шул нурларны болыт каплап, син еллар буе ялгызлык базына ташланган булырга тиеш идең. Төннәреңдә тәнең кызышып, татлы һәм шомлы төшләр күреп, сикереп торырга һәм бу ялгызлыкта яшәгәнче үлгәнеңне артык санап, язмышка ялварырга тиеш идең. Менә хәзер сиңа ул көннәр, ул төннәр килде.

Менә хәзер, син бөтен өметләрем кисе ｔде дигәч, офыктан кояш калкып, баш очыңа күтәрелә башлады. Ул синең бәгыреңне яндырачак. Дөрес, син үз хисләреңне тыярга тырышасың, намус, оят турында уйлыйсың. Ләкин эссе нурлар синең бу уйларыңны чык тамчылары кебек киптереп алыр, син уйлау сәләтен җуярсың һәм бөтен тәнеңдә аны көтеп, аны күрер минутларны санап типкән йөрәгеңнең сулкылдавын гына тоярсың. Бер генә көн аны күрми торган чакларыңда да бу сулкылдау шулкадәр газаплы тоелыр, син төнәрен уянганда әҗәлне чакырыр дәрәҗәгә җитәрсең, чөнки ансыз яшәү үлемнән ачырак күренер.

Менә ул синең янга килер, синең алдыңда тезләнер. Йөрәгең кайнарлыгы уйларыңны көйдереп юкка чыгарыр, кулларың, иреннәрең аңа омтылыр — аңа бер генә орынырга, бер генә кагылырга, аның йөрәге типкәнен тоярга, һәм аннары берни дә кирәкми! Минем йөрәгем аныкы белән кушылсын, икесе бергә типсеннәр, ә тәнем шул минутта юкка чыксын, диярсең син.

Фидая, баскан җиреннән шаккатып, Каләмгөлгә текәлгән иде. Сәхнәләрдә ялкын теле булып бөтерелгән бу хатынны күп күрде ул, әмма мондый эссе, көл итә торган утны тойганы юк иде әле. Әллә берәр роль уйныймы? Әллә монда авырыйм дип ятуы сәбәп кенә, ул шундыйрак берәр спектакль куярга әзерләнеп, репетиция ясавымы һәм, Фидаяны әвәрә итеп, үзенең партнерына әйләндереп, кызык итүеме? Шул рәвешле элекке тәкәбберлеге өчен аннан үч алуымы?

Фидая күзләргә тырышып карады, бу минутның бер шаяру икәнлеген аңлаганын сиздермәкче булды.

— Алай гына булыр инде, театрларда гел шулай уйныйлар бит... — диде.

Әмма Каләмгөл аңа керфек тә сирпемәде: ул, тар бүлмәнең сәхнәларын кайнар рухы белән үтәкүренмәләргә әверелдереп, каяндыр бик ерактан, үзе генә белгән бер ноктадан киләчәкне күргәндәй сөйли иде:

— Әйе, ул килер, тезләнер. Син тыела алмассың, син бөтенесен онытырсың: кем нәрсә әйтерен, моңарчы үзең өчен, бөтен кеше өчен катгый дип санаган кагыйдәләрне, кеше балаларын гына түгел, хәтта үз балаңны онытырсың!

Бу сүзләр шулкадәр куркыныч яңгырады ки, Фидая өнсез калды.

— Әйе, төннәрен йоклый алмыйча, кысан бүлмә буйлап әрле-бирле йөргәндә, син үзеңне акларлык мең сәбәп табарсың. Синең мәхәббәтең беркемне дә бәхетсез итми дип уйларсың.

Синең мәхәббәтең аның баласын гадел итеп тәрбияләргә ярдәм генә итә, дигән яңа кагыйдә уйлап чыгарырсың. Чыннан да, бер-берсен яратмаган ата белән ана янында, аларның рухы корып, холкы бозылып гомер иткәнен күреп үсү аңа файдагамы? Аның киләчәктә үз тормышы, үз язмышы, үз мәхәббәте булачак, хәзерге вакытта аның хакына дип, ике кешенең язмышын җимерү дөрес булырмы? Чын мәхәббәтнең, соңлап килгән булса да, җиңүен күрү аңа яхшы сабак кына булмасмы?

Бу юлы ул, борылып, уттай янган күз карашын Фидаяның йөзенә төбәде. Фидая аңа җавап бирми кала алмады:

— Ләкин бу рәвешле фикер йөртү — ул бит кеше үтерүгә китерергә мөмкин,— диде ул.— Акылыңа кил, ни сөйлисең син!

— Син миңа әйтәсеңме? — диде кинәт гади генә итеп Каләмгөл. Әйтерсең лә, рольдән чыгып, чынбарлыкка кире кайтты, йөзе үзгәреп китте:

— Син аны үзеңә әйтерсең, яме! Менә ул каршыңа тезләнер, син инде ничә төннәр уйлап, аны якын китермәскә үз-үзеңә ант иткән булырсың, ләкин аның сузылган кулларын, өзелеп текәлгән карашын күргәч, барысын кинәт онытырсың, тәкатьсез калырсың. Шунда аңыңа килеп кара! Ә мин үземне тыя алдым. Мин аннан карашымны аерып алдым, аңа сузылган кулларымны үз күкрәгемә кыстым, аңа тартылган тәнемне артка таба авыштырдым. Син башканыкы, башка берәүнең мәхәббәтен урларга теләмим, дидем. Мин, бәлки, киткән дә булыр идем. Тагын чегәннәр арасына, авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә күчеп, һәр кичне яңа сәхнәгә чыгарга, йөрәгем ялкынын анда сирпергә... Яңа урыннар, күз алдында алышынып торган кешеләр күп нәрсәне оныттыра. Мин киткән дә булыр идем. Ләкин ул алдан китеп өлгерде.

Фидая «ул» дигәненең Мөнирә икәнлеген аңлады.

— Әйе, ул китте, аны миңа үзе калдырды. Белеп тор: монысы инде синең белән булмаячак... Син бөтенләй башкага — үзенә тигәнне нык тота торган кешегә юлыгырсың... Ләкин ник кайтты ул кире? Бер киткәч, нигә бөтенләйгә югалмады?

Фидая әле һаман да аның сихереннән арынырга тырыша иде, мөмкин кадәр тыныч тавыш белән, хәтта ваемсыз гына:

— Яраткан, шуңа кайткан,— диде.— Аның да эчендә җаны бар бит!

— Әһә, син дә шулаймы? Син хәзердән үк шундыймыни?

Фидая аңа гаҗәпләнеп карады: нинди?

— Димәк — ярату ул үзең хакында, үз хисләрең турында гына уйлау? Шулаймы? Алайса, син, бу авыл кешеләре, гомумән, әхлак турында лыгырдаучылар, нигә соң сөюне бөтенләй санга сукмыйсыз? Кеше мәхәббәт газабыннан үләр чиккә житкәндә дә бүтәннәр ни әйтер, ничек карар дип уйларга тиеш, шулаймы? Болай фикер йөрткәндә, бөтенләй башкача килеп чыга бит: әгәр ул Гыйззетдинне чынлап яраткан икән, димәк, аның бәхетле булуын теләгән. Ә аның бәхете — минем белән кавышу. Элекке хатыны белән очрашып тору аңа газаплар гына китерә. Шулай булгач, ул бер киткәч, бөтенләй юкка чыгарга, үзенең дөньяда яшәве хакында мондагылар онытсын, дип тырышырга тиеш иде! Укы син иң бөек әсәрләрне, иң даһи язучылар шул хакта сөйләмимени?

— Син бәхетле бул, димәк, ә ул бөтенләй яшәмәсен, үлсен? Шулай димәкче буласыңмы?

Фидаяның күз алдында кинәт кенә Фазилә чагылып узды: аның

чишмә буендагы чирәмлектә, үз хокукын раслагандай, биегәеп, кузгалмастай нык басып торуы, горур башын да бормыйча сабан туе трибунасы каршыннан узып киткәне... Кинәт тетрәнеп китте: ул хатын кинәт юкка чыкса, Фидая өчен яхшырак булмас иде микән?.. Юк, юк, алай түгел, дип, үзенең уйларын төзәтергә тырышты ул. Киресенчә, Фидаяның юкка чыгуы — бөтенләйгә-бөтенләйгә — ул хатын өчен яхшырак булмас идемени?

Фидая кызарынып чыкты, ә Каләмгөл, тынып, аның уйларын укыгандай карап тора иде. Шул минутта ул ниндидер фаҗигане уйнаучы артисткадан юатучы-күрәзәчегә әверелгәндәй булды:

— Юк, син андый булмассың, бәлки. Ләкин ул мине шундый чиккә җиткерде, минем аның үлемен теләгән чакларым булды. Әйе, булды. Чөнки аның бөтен яшәү рәвеше, бөтен кыланмышлары минем тормышымны агулау өчен генә булды. Ул башка берәүгә кияүгә чыга ала иде — сораучылар күп булды, яшь хатыннар хәзер дефицит, менә диган егеткә бара ала иде. Ләкин алай итсә, безнең җан тынычлана иде бит, ә ул үзе кешечә яшәмәсә яшәмәде, безнең тормышыбызны да агулады. Ул кызын атасына нәфрәттә тәрбияләде. Әйт: шушы буламы ярату?

— Ә син үзең нишләр идең соң? — дип сорады Фидая һәм шундук бу сөальнең мәгънәсез икәнлеген аңлады. Каләмгөл башкача эшләр иде: ул араны бер селтәнү белән өзәр, араны өзә алмаса... үз гомерен... юк, мөгаен, көндәше гомерен өзәр иде. Ә бәлки, сөйгәне гомерен?

Фидая, шаккатып, аңа текәлде: Каләмгөлнең чибәр һәм тетрәндергеч хисле йөзе аңа куркыныч булып тоелды. Аннан да куркынычрагы, бу тыелгысыз хис һәм көч иясенең аны — Фидаяны үзе белән тәңгәл китерүе иде!

Ә бит элегрәк бу өчәүнең тормышы ямьсез, көлке, гадәти тормыштан түбән булып күренә иде аңа. Ничек өстән-өстән караган ул кеше язмышларына, аларның күңелләрен актарган хисләр давылына! Һәм, иң гаҗәбе — бу хисләрнең менә хәзер дә, ничә еллар бергә яшәп, ике бала булдыргач та шушы рәвештә көл-күмергә әверелдерерлек булуына.

Фидаяның зиһене кинәт ачылып китте, әйтерсең лә көйрәп кенә яткан учак, җилпенеп, ялкынын биеккә ургыды һәм аның яктылыгында моңарчы күренмәгән нәрсәләр аермачык күренә башлады: бу хисләрнең саклануына, алай гына да түгел, көчәя баруына Мөнирә сәбәпче бит! Әгәр көннән көнендә ул очрап тормаса, Каләмгөлнең Гыйззетдингә булган хисләре дә әкренләп уңар, ул аңа күнегер, суына төшәр иде.

— Күптән булган хәлләр бит инде, күнегергә вакыт,— диде ул.— Гел болай янып-көеп яшәп булмый. Хисләр дә тереклек иясе кебек — ярала, үсә, чәчкә ата, аннары...

— Үләме? — диде Каләмгөл, шаркылдап көлеп җибәрде.— Кеше хисләре хакында сөйләү ничек җиңел, ә? Нинди акыллы сез барыгыз да! Мин генә шыр тиле! Үз башыгызга төшмәгәнгә генә шулай ул. Ә үзегез бернәрсәне дә онытмыйсыз. Мәхәббәтне түгел, нәфрәтне дә гомер буе саклыйсыз! Ничә ел үтте, дисең? Ә нигә авыл хатыннары онытмый, нигә алар үзгәрми? Борынгыдан калган киемнәрне, сөлгеләрне, калфакларны да, мин сорасам, клубта спектакль куярга бирмиләр! Аларның кайчандыр үсеп чыккан нәфрәт тигәнәге һаман шиңми нишләптер? Аларның язмышына бәйле дә түгел бит, югыйсә! Менә нинди ул халык, менә нинди вакчыл, үчле, эчле була белә ул! Сиңа да күрсәтерләр әле.

— Син нишләп миңа бәхетсезлек телисең? — дип сорады Фидая, гаҗәпләнеп һәм әрнеп.

Каләмгөл, ниһаять, кысадан чыккандай, ишек турыннан кузга-

лып, якынрак килде. Талчыккан тавыш белән, битараф кына:

— Миннән тормый бит,— дип куйды.— Мин кеше язмышын үзгәртә алмыйм, алдан әйтеп куя гына беләм.

Әйе, шулай, язмышны алдан әйтеп куя беләм, диде ул. Үзен-нән-үзе аңлашылгандай, бәрәңге пешерә беләм, дигәндәй, шик тудырмый, бәхәс кузгатмый торган нәрсәдәй итеп әйтте.

Аның белән саубуллашып урамга чыккач, машинага утыргач та Фидаяның колагында аның шушы сүзләре чыңлап торды: «Ни күрәчәгеңне генә әйтәм». Генә! Аны әйтеп буламыни? «Алга килми белеп булмый башның ни күрәчәген»: Фидая, башын чайкап, үз алдына көлемсерәп куйды. Кайбер хатыннарның аны сихерче дип йөрүе тәки юкка түгел икән. Сихерләве бардырмы, юктырмы, әмма менә шушы рәвешле, спектакль уйнагандай, башларын әвәрә иткәли торгандыр. Кара син аны! Каршыңа килеп тезләнер, ди бит!

Фидая үз каршында Давытның тезләнеп торганын күз алдына китерергә тырышып карады, булдыра алмады. Андый хәрәкәт өчен ул ир-егетнең аяклары артык озын, муены артык текә шул. Тезләнсә дә, мөгаен, Фидаядан озын күренер. Алай да, әгәр чыннан да андый хәл булса?..

Юк, юк, ул чакта да Фидая аны шундук куып чыгарачак. «Хәзер үк чыгып кит!» — диячәк аңа.

Ул теге аланда очрашканнан соң бер генә минутка да аны оныта тора алмаганын исенә төшерде. Иртән күзен ачарга да өлгерми, беренче уе аның хакында, кичен күзен аның белән сөйләшеп йома... Һич ярый торган нәрсә түгел. Онытырга, онытырга, уйламаска... Кеше үз башына, уйларына хуҗа булырга тиеш.

## 32

Каләмгөлнең хәле төнгә каршы начарланып китте. Гыйззетдин йоклый иде инде, иңбашын каккалаган йомшак хәрәкәттән уянып, айный алмый ятты бераз.

— Гыйззәтлем,— диде Каләмгөл.— Тор әле. Бар, машинаны кабыз. Иртәнгә кадәр түзәрменме, дигән идем, булмас, ахрысы. Кан күп китә.

Гыйззетдин сикереп торып киенгән арада бик әкрен, сак кына кузгалган хатынына куркынып карады. Җәймәдәге кан тапларын күреп коты очты. Бу хәлдә машинада барырга... Каләмгөлне кузгатмаска, врачны алып килергә кирәк иде! Күңелгә Мөнирә килде. Ләкин Каләмгөл аны якын китермәячәк.

Ул, тизрәк чыгып, машинаны кабызды.

Язмыштан узмыш юк, күрәсең: Кармашка илтеп, Гыйззетдин бик нык хаталанган булып чыкты. Дежур врач больницада юк иде, медсестра йоклаган, ишекне бик озак шакыгач, көттереп кенә ачтылар. Баш врач үзе Казанга, яңа больница өчен «Медтехника» кибетеннән аппаратлар алырга киткән икән. Үзенең дә больницага кереп күренеп чыгасы бар икән. Иртәгәсез кайтмас. Йосыпов киткәннән бирле Кармашка яңа гинеколог килгәне юк. «Башка кеше ярдәм итә алмас»,— диде үзе дә аптырап калган яшь кенә медсестра.

Гөлфиянең өенә барып, уятып алып кердeләр. Ул, Гыйззетдинне бүлмәдән куып чыгарып, Каләмгөлнең үзе белән генә сөйләште. Ахырдан, коридорга чыккач, Гыйззетдин аның йөзенә карады да йөрәге каядыр убылгандай булды.

— Монда алып килеп ялгыш эшләгәнсең,— диде Гөлфия аңа.— Туры район больницасына илтергә кирәк иде.

— Әле кичтән дә әйбәт кенә йөри иде бит, зарланмый иде! — диде Гыйззетдин.

— Зарлана башлагач кына соң була шул ул! Йөккә узган һәр хатын авыр эш эшләмәсен, врачларга күренеп, тикшерелеп торсын, дип юкка әйтәбезмени без сезгә! Ә ул сабан туйларында узыша! Чөгендергә дә чыккандыр әле.

Гыйззетдин телсез калды. Әйе шул, узышты, йөгерде. Чөгендердә дә, Мөнирә белән куалаша-куалаша, зыр-зыр эшләде. Ләкин андый хәлдән кеше чирләми бит, үлми бит! Әнә, безнең әниләр ничек эшләгән, йөкле чакта аларны кем караган да кем тикшергән! Безне тапканнар менә, тудык, үстек, алар да исән-сау.

— Бездә хатын-кыз мәңге шулай бит инде, буразнада бала тапканнар...

Гөлфия, чыгу юлына борылып:

— Таба алганы тапкан, таба алмаганы үлгән,— диде.— Бар, машинага алып чыгып утырт, мин хәзер киләм. Балаларга гына әйтәм, куркып калмасыннар.

Теге чакта Мәгъсүмне Кармаш больницасына илткәне исенә төште Гыйззетдиннең. Ялан-ялан бертөсле булмас, дип ышандырырга тырышты ул үзен. Авыру бар, терелү бар, коткарырлар врачлар Каләмгөлне.

Күңел бәхетсезлеккә ышанырга теләми иде. Күз алдына килеп баскандай булгач та, хәтта Казаннан санавиация белән чакырылган врачлар килеп карап, башларын чайкагач, каны агуланган, дигәч тә ышанасы килмәде Гыйззетдиннең.

Район больницасында Каләмгөлне аерым бүлмәгә салганнар иде. Гыйззетдин килеп кергәч, ул, башын борып, елмаеп карады. Эчкә баткан күзләре уттай яна, бит очлары кызарып чыккан, әмма ак җәймә өстендәге куллары ап-ак, тырнаклары күгәреп киткән иде.

Гыйззетдин карават янәшәсендәге тумбочкага күчтәнәчләр тезде, көр тавыш белән балалар хакында сөйләргә кереште. Әмма Каләмгөл, күзләрен йомган да, хәл алгандай тын ята, күчтәнәчләргә күз салмый һәм, мөгаен, иренең сөйләгәнен дә ишетми иде. Менә ул иреннәрен тибрәтте, күзләрен ачты, башын бора төшеп, коры кайнар бармаклары белән иренең кулын тотып алды. Кулын бөтен көченә кысарга тырышкандай тартышты, әмма хәрәкәте сизелерлек булмады — көчсез иде ул.

— Гыйззәтлем,— диде, бик мөһим сүз әйтергә теләгәнен сиздереп. Аңа якынаерга омтылыш ясады. Гыйззетдин ашыгып иелде, йөзен аңа якын ук китерде.

— Йә әйтми калынып да, мәңге сыкранып ятармын, телем ачык чакта әйтәсем килә,— диде Каләмгөл.

— Ни сөйлисең син! Әйтәселәрне мең әйтербез әле!

Каләмгөл, керфекләрен кагып, сүзен бүлдермәскә кушты.

— Аңа өйләнмә, яме! — диде, иренең күзләренә текәлеп карап. Аның күз бәбәкләре зурая башлагандай, анда төпсез караңгылык куергандай булды. Гыйззетдин ихтыярсыздан артка тайпылды, ләкин бу хәрәкәте белән хатынын куркытканын уйлап, кире иелде, калтыранган кулы белән Каләмгөлнең чәчен, яңакларын сыйпады.

— Нинди өйләнү? Саташасың, ахры. Борчылма, уянырсың, сихәтләнерсең...

Каләмгөлнең йөзе чарасызлыктан тартышып куйды:

— Юк, мин аңымда. Мин моны төне буе уйладым. Гел шуны гына. Син аңа өйләнмә. Теләсә кемне алып кайт, аны түгел. Мәңге бәхиллегем юк! — диде ул, терсәкләренә таяна төшеп.

Гыйззетдин аны кочагына алды, йомшак кына итеп күкрәгенә кысты.

— Син дигәнчә булыр. Ничек теләсәң, шулай эшләрмен,— диде.— Без яшәячәкбез әле. Мондагыларны көлеп искә алачакбыз, менә күрерсең!

Шулай сөйләнде Гыйззетдин, әмма ул үзен дә саташкандай хис итә иде.

Каләмгөл аны ишетми иде кебек, кире мендәренә ятып, күзләрен түшәмгә төбәде дә:

— Әгәр ике хатын белән яшәргә мөмкин булса, син безнең икебез белән берьюлы яшәгән булыр идең, шулай бит? — диде.

Гыйззетдин, ни әйтергә белми таң калып, аңа текәлде.

— Шула-ай! — дип суды Каләмгөл.— Тик мин иремне башка берәү белән бүлешә торганнардан түгел. Син зур йөрәкле, синең йөрәк икебезне дә сыйдырыр иде, югыйсә.

Ул бераз тынып торды. Гыйззетдин телсез калган иде. Ул үзенең йөрәк түрендәге аңларга куркып йөргән, ә Каләмгөл барысын да сизгән, белгән икән!

— Мин юкта да син үзеңне ирекле санарга тиеш түгел,— диде Каләмгөл.— Син аңа якын барма. Кулы белән үзеңә орындырма. Кагылмасын ул сиңа. Бармак очларын да тигезмәсен. Якын барма, орындырма...

Ул, башын боргалап, бер үк сүзне такъррарлый башлады:

— Тимәсен, орынмасын... Кулы белән кагылмасын...

Гыйззетдин, аны саташа дип уйлап, шәфкать туташын чакырып кертте...

## 33

Каләмгөлнең үлеме Фидаяга яшен суккандай тәэсир итте. Бу мәгънәсез һәлакәттә ул үзен гаепле санады. Бер генә түгел, берничә мәртәбә язмыш аңа Каләмгөлне коткарырга мөмкинлек биргән булган бит. Сабан туенда аның больницага бармыйча үз өенә кайтып киткәнен белгәч, янына врач җибәргән булса... Аннары, теге көнне Каләмгөлнең күрәзәлек кылуларына мөкиббән китмичә, аны ничек кенә булса да ризалатып, больницага алып барган булса... Аннары Кармаш больницасына хатын-кыз врач китертүне алдан ук кайгыртКан булса... Йосыповның киткәненә кайчан бит инде!

Фидая тагын медицина китаплары укыды, врачлар белән сөйләште. Каләмгөлнең әҗәле минутлап якынайган, диделәр. Әгәр берике сәгать кенә алданрак тиешле ярдәм күрсәтелгән булса...

Каләмгөлнең үлеме бөтен районны «аһ» иттерергә, аякка бастырырга, Кармаш больницасы төзелешен үзәккә куярга тиеш булып тоелды Фидаяга.

Ул Искәндәровка кереп моны әйткәч, председатель, урыныннан сикереп торып, шундук больница төзелеше белән генә шөгыльләнергә тиеш иде кебек.

Искәндәров алдында яткан кәгазьләрдән башын күтәреп карады, ә аларда савымның тагын тиешенчә артмавы, чөгендер эшкәртүнең әле һаман тәгәлләнмәве, сенажның җитәрлек салынмавы, кайдадыр АВМның ватылып ятуы турындагы хәбәрләр язылган иде һәм алар председательнең кәефен нык кырган, аның кайбер хуҗалык җитәкчеләрен кыздырырга теле кычыта иде булса кирәк. Ул урынбасарына да ризасызлык белән карады: Фидая, аңа сүз әйтергә ирек бирмичә, каршына ук килеп басып, фаҗигале тавыш белән Каләмгөлнең һәлакәтен әйтте. Искәндәров баштарак аңламый торды, күзлеген маңгаена шудырып, күзләрен уып куйды, аннары тыныч кына сәбәбен сорады.

— Сәбәбе: больница юк, врачлар юк, ашыгыч ярдәм күрсәтү юк — менә кайда сәбәп! — диде Фидая.

Искәндәров аңа гаҗәпләнеп, күзлеген бер киеп, бер күтәреп карады.

— Бу нинди сүз тагын! — диде, тавышын күтәреп.— Син нәрсә, Фидая Госмановна, күктән төштеңме әллә? Баллыбольнда менә дигән медпункт, тәҗрибәле врачка торырлык фельдшер! Ул гына җитмәсә, больницасы биш чакрым! Әгәр авыруга тиешле ярдәм күрсәтелми икән, кем гаепле аңа? Ә?

— Без гаепле, без! Мин гаепле! — дип кычкырды Фидая.

Искәндәров, кулын сузып, команда биргәндәй итеп, каршындагы йомшак урындыкка ишарәләде:

— Утыр!

Бу шундый итеп әйтелде, Нурханова үзе дә сизми утырды һәм кинәт йомшап китте.

— Рәтләп кенә аңлат: нәрсәдән үлгән, авариягә юлыкканмы әллә?

— Хатын-кыз врачы кирәк иде аңа... Күп кан югалтты, каны агуланган, сепсис...

— Бер-ике сәгать эчендәме? — дип төпченде Искәндәров.

— Авыру берничә көн элек башланган да бит...

— Ни караган соң үзе? Ире ни көткән? Үзен-үзе карамаган кешеләрне без генә саклап бетерә алмыйбыз.— Искәндәров алдындагы кәгазьләрне кыштырдатып куйды. Көрсенде.— Нишләтәсең, үлгән артыннан үлеп булмый, авыр туфрагы җиңел булсын.

Аннары, фикерен җыярга тырышкандай, бераз уйланып торды да:

— Монда менә синең «Үзәк» бик эчне пошыра башлады әле,— диде.— Савымны ун килодан арттыра алганнары юк. Ул егеткә, гомумән, бик нык күз-колак булырга кирәк. Эшнең рәтен белми, каршы әйтергә дисәң, аңа куш. Салам силослый башлады микән әле? Үзем барып тикшерим, дигән идем, һаман вакыт җитми. Син белдеңме, тотынганнармы ул эшкә?

Фидая аңа шаккатып текәлде, берни аңлый алмады. Нинди салам, нинди силос, кем кемгә каршы әйткән? Кеше үлгән монда. Каләмгөл юк, өч бала анасы!

Искәндәров аның хәлен аңлады.

— Беләсеңме нәрсә, Фидая Госмановна,— диде,— без зур районның җитәкчеләре, ә мондый зур районда үлем-китем дә булып торыр, туучысы да булыр. Дөнья бу! Ә без үз эшебезне белергә тиеш!

Әйе-әйе, ул үз эшен белергә тиеш. Ә беләме соң әле? Берничә көн Кармашка бара алмады — бөтенесен Мирхуҗинга ышанып тапшырды. Үз күзең түгел инде!

Бүген үк, хәзер үк шунда барырга кирәк иде. Тик «Газик»-ны Балкыш ремонтка куйган, бер-ике көнсез чыга алмам, дип кичә үк кисәтте.

Фидая Мирхуҗинга шылтыратты. Аның тавышы гаҗәп көр иде:

— Безне бөтенләй онытыгыз сез, Фидая Госмановна! Үги итә башладыгыз!

— Онытмадым,— диде Фидая,— тик мөмкинлегем юк, машина ватык.

— Барасы килгән кеше җаен таба ул,— диде Мирхуҗин гамьсез генә.— Мин менә көн саен сугылмый калмыйм. Әле дә шунда барырга җыенып тора идем. Әйдә, бергәләп әйләнеп кайтыйк! Малайшалай шикелле мактанасы килә минем дә бер! Начальство җылы сүз әйтсә, күңел үсеп китә бит ул!

— Мактанырлыгы булса, ярый ла...

— Бик зур эшләр майтардык инде үзебезчә! Тик менә нәчәлникләргә ярап бетеп булмый. Әле безнең Ясәвиев тә бер туры килгәндә зур абзыйга мактанган икән: «Савымны көнгә унөч килога җиткердек без!» — ди икән. Орден ук булмаса да, медаль вәгъдә итәр, дип өметләнгәндер инде, бичара. Ә теге абзый аңа: «Унөч кило —

чик түгел, бер потка җиткерергә кирәк!» — дигән. Син дә шуның сыман түбәгә сугып куймагаең тагын, белмәссең! Әллә алып бармаска инде?

Көлеп бетергәч, Мирхуҗин тавышын кинәт үзгәртте дә бик эшлекле итеп:

— Алайса, мин синең янга сугылып чыгам, ярты сәгатьтән килеп җитәрмен,— диде.

Фидая аның машинасын ишек төбенә чыгып көтеп алды һәм, рульдә Мирхуҗин үзе утырганны күреп, аптырап китте.

— Шофер калага туйга китте,— диде Тавис, машина ишеген ачып, төшмичә генә.— Халык тәртипсез бит хәзер, ни яз түгел, ни көз түгел, ни сабан туе түгел, дигәндәй, теләсә кайчан бәйрәм ясыйлар, теләсә кайчан туй!

— Шәһәрдә загс билгели бит туйларның тәртибен,— диде Фидая.

— Шул-шул менә, сезнең кебек совет органнары шундый тәртипсезлекне үзләре урнаштырган икән, без каршы килә алмыйбыз! Ничек җибәрми каласың кешене туганының туена!

Тик бер генә мизгел икеләнеп торды Фидая яшел «Волга» янында. Нишләптер күңеле тартмый иде аның Мирхуҗин белән икәүдән-икәү бер машинада юлга чыгарга. Ләкин шул ук вакытта менә хәзер, әһә, шоферың юкмыни, үзең генәмени, дип кире борылып кереп китсә, бу инде хатын-кызның вакланувы булмасмы? Тегеләр чактагы кебек, уйлары гел начарлыкта икәнлеген исбатлау булмасмы?

Фидая Тавис ачкан ишектән кермәде, арткы утыргычка, кеше күзенә бик үк ташланмый торган итеп, кырыйгарак сыенып утырды.

Юлда сөйләшмәделәр диярлек. Ара-тирә Тавис, көләч йөзен аңа таба борып, күтәренке тавыш белән нидер әйтеп куя, әмма Фидаяның җавап бирмәгәнен яисә, әйе шул, юк әле, дигән кебегрәк сүзләр белән генә чикләнгәнен күргәч, ул да тынып кала иде.

Атна чамасы яуган яңгырлардан соң, көн аязып, басулар киң сулыш алып, күпереп киткәндәй булган иде. Чөгендер кырлары да юл читеннән каядыр еракка сузылган яшел тасма-рәтләр булып күкрәп утыралар, бодайлар башак чыгара башлаган,— җәй уртасы җитеп килә. Түгәрәк күл турыннан узганда Фидая, пар үрдәкләр күренмәсме дип үрелеп караган иде, әмма су өсте буп-буш булып ялтырап кына чагылып узды.

— Ясәвиев зарланып ята әле анда,— диде Мирхуҗин.— Осталарга ит-майны миннән генә каерасыз, башка колхозлар да ярдәм итсен, ди. Анысы шулай да инде, һаман бер кешегә генә салынырга димәгән, Гаяров та бераз кайгыртсын.

Юл уңаеннан «Үзәк»кә кагылып чыгарга уйладылар.

Гаяров идарәдә юк иде. Парторг Әхсән аны рациядән чакырып караган иде, җавап бирмәде. «Машинасыннан чыгып йөридер,— диде Әхсән.— Бераз көтик инде». Әмма тиктормас Тависның көтеп торасы килми иде, ул председательне үз машинасы белән эзләп табуны кулайрак күрде.

Гаяров АВМ машинасы янында булып чыкты. Анда, ике-өч ир кеше тимер баскычтан өскә менеп, нәрсәнедер төзәтәләр иде. Давыт Мирхуҗин белән Нурхакованың машинадан төшкәнен күрде, әмма, ашыгып төшеп, кулын сузып каршыга киләсе урында, аркасы белән борылды һәм янындагы ир кешегә озаклап нәрсәдер аңлатырга кереште. Килгән кунаклар аңа шактый вакыт башларын каерып карап торырга мәҗбүр булдылар. Ниһаять, ул, кулын кара майга сыланган чүпрәк кисәге белән сөртә-сөртә, ашыкмый гына килде, салкын гына исәнләште һәм ризасыз тавыш белән:

— Бөтен нәрсәне үзең эшләргә туры килә,— диде. Аннары шоферына кычкырды:

— Мөҗип, бар әле, сварка аппаратын алып килсеннәр!

— Гыйззетдин кичә генә хатынын күмде бит, бүген эшкә чыкмаган, аннан башка бу эшнең рәтен-чиратын белүче юк.— диде ул.— Бөтенесе председательгә генә кирәк диярсең, үзең килеп төртеп җибәрмәсәң, тәки тик утыралар, исләре дә китми!

Фидаяның янә күңеле сызып куйды: менә бит бусы да, машина ватылган, дип күбрәк кайгыра. Каләмгөлне күмәләр, аңа һич исе киткәндәй түгел!

Хәер, алай да ятим калган балалар турында берничә авыз сүз сөйләшеп алдылар. Өйләнми булдыра алмас инде, диештеләр. «Беренче хатыны монда бит, шуны алыр да кайтыр».— диде Гаяров.

Мирхуҗинның гадәттәгечә кычкырып, шәрран ярып, ачык сөйләшүенә карамастан, сүз ялганмый һәм бу читләшүгә, салкынлыкка Фидая үзе сәбәпче икәнлеген тиз аңлады. Ләкин ни өчен? Аның ни гаебе бар?

Фидая шундук аңлап алды: ул Мирхуҗин белән икәүдән-икәү генә бер машинада килүе белән гаепле иде Давыт каршында!

Фидаяның зиһене чуалып китте, ул инде ирләрнең нәрсә турында сөйләшкәнен ишетмәс хәлгә килде. Алар ит, сөт, май турында, такта-борыслар хакында сөйләшәләр. Мирхуҗин шат тавыш белән нәрсәдер сорый, ә Гаяров канәгатьсез кыяфәттә бирмәскә тырыша:

— Үз хәлебез дә мөшкел, эш көче җитми, бер кешене бишкә ярырдай булабыз. — ди, Нурхановага карамыйча, әмма, ул ишетсен дип, аның өчен сөйләгәндәй канәгатьсез, ризасыз тавыш белән исбат итәргә тырыша. — Менә дигән мунча салып бирдек, андый үзебезнең колхозда да юк әле. Башкалар кайгыртсын, бер без генә димәгән!

Сварка аппаратын алып килеп, ирләр АВМ машинасының чылбырын рәтләгәч, аннары зур факел белән аның бер өй биеклегендәге һәм аннан да озын цилиндры эчендә ут кабызып, ул ник гүләп әйләнә башлагач кына, Гаяровның чырае яктырып китте. Арырак китеп, йомшак, җылы печән онын учына алгач, ул бераз йомшара төште кебек. Фидая да печән онын тотып карарга иелде, керфекләренә кунган яшь бөртекләрен күрсәтмәскә тырышты.

Соңгы көннәрдә гел шушындый минутларны уйлап, аның тавышын ишетер чакларны гына көтеп яшәде бит ул. Ничек очрашасыларын, нәрсәләр әйтеп, бер-берсенә ничек караячакларын әллә ничә төрле итеп күз алдына китерде. Көненә ничәшәр тапкыр куллары ихтыярсыз телефон трубкасына ябыша, хәтердә уттай уелган саннарны бармаклар җыя, ләкин телефоннан чыңлаган авазлар ишетүгә, ул ашыгып трубканы кире куя, ә кайчакта аның: «Алло, «Үзәк» тыңлый! Кем бу?» — дип кабатланганын тыңлый, ләззәттән һәм Давыт ул шылтыратканны белер дә гаепләр, көләр, мөгаен, сизә дә торгандыр дип куркудан бөтен тәне чымырдый иде.

Менә очраштылар, менә янәшә торалар, сөйләшәләр һәм... алар хәзер икесе ике авылдагы чактагыдан да ераграк! Болай булыр дип Фидаяның башына да килмәгән иде! Һәм монда ул үзе генә гаепле, хәзер инде аклану-котылу чарасы да юк. Әмма... бер гаебе дә юк бит аның! Нишләргә? Ничек моны Давытка аңлатырга?

Мирхуҗинга идарәдән ниндидер документлар алырга кирәк икән. Председатель машинасы алдан, аларның «Волга»сы арттан кайтып киләләр иде, кибет турыннан узганда сатучы хатын кул изәп туктатты. Гаяров машинадан төште.

Сатучы Әлфия — урта яшьләрдәге, ябыграк кына хатын — Фидаяга бер сүз белән генә сәлам бирде дә Гаяровка:

— Складка барырга дип ашыга идек, — диде. — Тегe әйберне хәзер карап чыксаң, әйбәт булыр иде.

Әлфия күптәнге таныш, ләкин аның да үткен күзләре белән телеп алгандай карап куюында гаепләү, өнәмәү сизелде.

Кибеткә өчесе дә керделәр. Әлфия каяндыр — төймә, йөзек, сәгать

ише әйберләр саклана торган киштәдән — кечкенә тартма алды. Анда кызыл кашлы алтын алкалар иде.

— Минә шушындыйдан матурын тапмадык, — диде ул. — Кигезеп карап алсаң, әйбәтрәк булыр иде дә бит. Ошамаса, карарсыз тагын, алыштырырбыз.

Мирхуҗин бик белдекле кыяфәт белән алкаларны җентекләп карады:

— Нинди хатын-кыздыр бит, — диде. — Кара чәчле, озын муенлы кешегә әйбәт бу.

Гаяров аның сүзләрен илтифатсыз калдырды, тартманың кабарынкы кара капкачын ябып, гүяки серен башкалардан яшерергә теләп, Әлфиягә:

— Ярар, рәхмәт, көнендә булуы әйбәт, — диде.

— Нәрсә, хатынның туган көнеме әллә? — дип сорады Мирхуҗин, Гаяровның салкынлыгын бөтенләй сизмәгәндәй.

— Шулай иде шул... Күптәннән алтын алка сорап йөри инде.

— Хатынның сүзен аяк астына салып булмый, малай. Аларга ярарга кирәк!

Ә Фидаяның күкрәк куышына боз тыгып куйдылармыни — аның бәгыре өши башлаган иде кебек. Димәк, теге тәкәббер хатынга бүген туган көнендә Давыт алтын алка бүләк итәчәк. Ә менә Фидаяга бер атна элек егерме тугыз яшь тулды — кем зурлады, кем затлы бүләк бирде? Иртән Искәндәров кулын кысты да, кичен Шәрифә бәлеш пешереп сыйлады! Кая инде Фидаяга мондый кадер, кайгырту, бу кадәр олылау һәм аның теләген үтәү өчен шулхәтле акча түгү!

Әллә соң ул Фидаяны кибеткә юри алып кердеме? Арабызга кысылып йөрмә, мин хатынымны яратам, дип кисәтү өченме?

Идарәгә Мирхуҗин үзе генә кереп чыкты. Фидая машинада утырып торды. Кузгалып киткәндә ул тәрәзә аша әчтә утырган Давытның баш артын шәйләде кебек: ул Фидаяны күз карашы белән генә булса да озатырга, аңа карап калырга да теләмәде!

Кармаш больницасында, чыннан да, эш кайный иде. Инженерлар түбәне ябып бетереп киләләр, ниндидер бер дәртле күтәренкелек белән кычкырып, көлеп-шаярып эшлиләр. Мирхуҗин белән Нурханова янына бригадирлары гына килеп, ашыгып сөйләшеп алды: измә өзлексез килеп торсын, арматура белән тәэмин ителсен, тегендә өзеклек булмасын, монысы кайгыртылсын... Мирхуҗин, гадәттәгечә көлеп, була, булдырабыз, дип җавап биреп торды. Әмма эшнең хәтта ул күз алдына китермәгәнчә тизлек белән баруы да Фидаяны куандырмады, аның күңелендәге бозны эретеп бетерә алмады.

Баш врач Газимовны күреп булмады. Казанга санавиация белән врач чакыртканнар, шуны каршыларга Суташка киткән икән.

Кайтырга кузгалыр алдыннан гына бер аңлашылмаучылык килеп чыкты. Алар белән бергә барырга дип, Гөлфия зур гына сумка тотып чыккан иде. Район больницасыннан, аптекадан нинәрдер алып кайтасы бар икән, эш вакытында барып җитсәм, аннан Билал белән бергә кайтырга мөмкин булыр, дип уйлаган. Ләкин инде машинага керәм дигәндә генә, рульдә Мирхуҗин утырганын күреп, кинәт туктап калды. Як-ягына, артына борылып карады, Фидаяның йөзенә текәлде, әллә Фидаяга гына шулай тоелдымы? Аннары сумкасын актара башлады.

— Бәй, хәзер генә бара алмыйм икән бит әле, — диде. — Карале, гел хәтеремнән чыккан, рецептларны яздырмаганмын! Ярар, мин сезгә җитешә алмам инде, башка берәр җай табылыр әле!

Һәм, хушлашып та тормыйча, борылып кире больницага кереп китте. Фидая машинадан төшмәкче иде, Мирхуҗин аны туктатты:

— Бала-чага түгел, үзе беләдер, — диде.

Канәгатьсез тавыш белән әйтте. Фидаяга ваклану килешмәгәнне сиздерде.

Тагын күңелгә бер кара ятты, тизрәк кайтып җитеп, бу машинадан котыласы килә иде.

Алар кояш баешына таба юл алдылар. Күк йөзен тагын болытлар каплый башлаган, кояш нурлары алар аркылы саркып, дөньяны сәер бер яктылык белән яктырткан иде. Һичектер көпә-көндез күз адаша, күңелгә сагыш иңә, басулар, юл, агачлыклар үзләренең табигый төсен генә түгел, рәвешен дә үзгәрткән кебек тоела иде.

Мирхуҗин да ялгышып китте бугай, туры кайтасы җирдән, бодай басуы аша салынган юлга борылды.

— Нигә, турыдан кайтмыйбызмыни? — дип сорады Фидая.

— Хәзер, хәзер... — диде Мирхуҗин, бик ашыккандай.

Алар Баллыболын басуындагы каенлык янына икенче яктан килеп чыктылар. Машинаның чирәм баскан юлдан агачлыкка таба борылганын күргәч, Фидая:

— Кая барабыз соң без? — дип сорады.

— Радиаторның суы бетте, су кирәк, — диде Мирхуҗин. Аның тавышы сәер иде, әмма Фидая моңа игътибар бирмәде. Гадәти хәл бит радиаторның суы бету. Әле ярый, чишмә юл өстендә.

Агачлык артында тыгыз чирәм үскән үр күкрәге күренде. Ул хәзер буш, ниндидер алсу яктылык белән яктыртылганга, сәер һәм серле тоела. Әйтерсең лә ул үзендә элекке елларны шаулашып бәйрәм иткән өлкәннәрнең һәм балаларның күзгә күренмәс шәүләләрен саклый; аннан да бигрәк, биегәеп, сагаеп, гаепләргә әзер булып, гүяки анда озын буйлы, туры сынлы, каты карашлы хатынның шәүләсе басып тора иде. Ул шәүләнең ике яңагы читендә кан тамчыларыдай кызыл кашлы алкалар чайкала иде кебек.

Фидая юлдашының машинадан чыкканын, каядыр китеп торганын искәрми дә калды, һәрхәлдә, аның Мирхуҗинда хәбәре юк, аңа карамый, аны уйламый иде. Ул каенлык арасында югалып торды бугай, озак тордымы анда, тиз килдеме, йөрәк сызлавы аша Фидая вакыт узганын сизмәде. Менә Мирхуҗин кинәт машина янында пәйда булды, арткы ишекне ачып, иелә төшеп, кулын сузды. Фидая аны, утыргыч артында аунап яткан төргәкләрнең берсен ала, ахрысы, дип, юл бирергә кырыйгарак шуышты. Шул минутта Тавис җәнлек тизлеге белән шуышып машина эченә керде. Фидая үзенең тимер капкынга эләккәндәй кысылганын тойды, иреннәренә Тависның каты, эссе иреннәре килеп капланды, авызын авырттырып, тешләрен кысты, сулышын буды. Ул нишләгәнен, нинди хәлгә юлыкканын аңлаганчы, утыргычка ауган, куллары артка каерылган, өстенә таш бастырылгандай итеп, кузгатып булмаслык гәүдә яткан иде инде. Фидая бар көченә тыпырчынып карады, әмма көтелмәгән бу хәлдән, бу көнне башыннан кичкән хәсрәтләрдән аның ихтыяр көче сынган идеме, ул каршы тора алмады. Кайсыдыр бер минутта хәтта башыннан: «Үтерсен, юк итсен, яшәмим бүтән!» — дип үз-үзенә үчле уй да чагылып китте һәм нәкъ менә шул аның хәлен алды да...

...Берничә минуттан, урынына тураеп утырып киемен рәтләгәндә, ул нәрсә булганын аңларлык хәлдә түгел иде әле. Ул кан аркылы саркыгандай кызгылт һәм шомлы яктылыкта үз төсләрен үзгәрткән каеннарга, күк йөзен тәмам каплап килгән болыт пәрдәсенә карады, яман төш күреп, кинәт уянгандай, зиһенен туплый алмады. Хәзер, менә хәзер, йокысыннан тәмам айнып җитәр дә, кара әле, минем котымны алган нәрсәләр саташу гына булган, дип, иркен сулыш алыр, җиңеләеп китәр сыман иде ул.

Ләкин янында Тавис утыра, менә ул әдәпсез рәвештә аңа каты терсәге белән төрткәләп, киемнәрен төзәтте, оятсыз хихылдап куйды — болар барысы да иң авыр, иң коточкыч саташулардан да ямьсез, котылгысыз һәм һушны алырлык аяныч иде.

Мирхуҗин, аның муенын каерып, башын утыргыч артына кысып,

тешләре белән иреннәрен изеп, сулышын буып торды, иреннәре авырту Фидаяны аңына китерде, ул тартылып, талпынып, ике кулы белән Тависны этеп җибәрде. Тавис бу юлы карышмады, он капчыгы кебек авыр гына читкә авышты, шаяртканын гафу иткәндәй, хихылдап куйды, аннары олы учы белән Фидаяның тезенә суккалады.

— Зарар юк,— диде.— Беренче тапкырында шулайрак килеп чыга инде ул. Иң матурлары алда булыр әле, менә күрерсең. Мин сине обижен итмәм!

Фидая аның кулын гына бәреп җибәрде. Мирхуҗин моны табигый чытлыклану дип кабул итте, рульгә күчеп утырды да педальгә басарга ашыкмыйча, бераз тынып торды.

— Хәзер берәр йөз грамм җибәрсәк тә әйбәт булыр иде,— диде.— Тамак бик кычыта. Нур өстенә нур гына булыр иде. Милициядән дә куркып тормас идек. Син ничеп уйлыйсың, ә? — Ул, башын чак кына бора төшеп, шул ук вакытта карашын алга текәгән килеш, җавап көтте. Фидая дәшмәгәч, көрсенеп:

— Әйе шул, икәү генә булганда, саграк йөрергә кирәк,— диде.— Праваларны биреп тормабыз, анысы, тик адәм баласының теленә йөгән кигезеп булмый, бер сөйләмәсә, бер ычкындыра. Салмыш хәлдә икебезне бергә күрсәләр, бөтен дөньяны сасытырлар, бәхетебезнең тамырына балта чабарлар! Башка чакта уйлабрак эшләрбез, җаен табарбыз!

Фидаяны гүяки әллә боздай салкын, әллә уттай эссе бер чоңгылга батырып алдылар да, ул аннан бөтенләй үзгәреп, икенче кеше булып чыкты, бөтен тәнен әллә кутыр басты, әллә сасы ләм катты һәм бу нәрсә, торган саен көчәя барып, аның йөрәгенә дә ябыша, аны кыса, сызлата иде кебек.

Сәер яктылык, ничек кинәт кабынган булса, шулай ук кинәт сүнеп китте, күз бәйләнә башлады, сыек болытлардан саркып вак яңгыр сибәләргә кереште. Әйтерсең лә күкләр елый иде...

Машина, алды белән күтәрелеп, үкереп асфальт юлга менде. Кайтыр юлга борылуга, Тавис фараларны яндырды, тизлекне бик нык арттырды. Шунда, Фидаяның буталган зиһенен яктыртып, бер уй килде: «Ашыга! Тизрәк миннән котыласы килә!»

— Тукта!

Мирхуҗин ишетмәде бугай, тамчылар белән чыланган алгы тәрәзә аша юлга текәлгән килеш, башын сузыбрак утыруында булды.

— Тукта, дим!

Бу юлы ул борылып карады:

— Нәрсә?

Аның тавышы канәгатьсез иде.

— Төшереп калдыр мине!

— Ерак бит әле, авыл очындарак төшәрсең.

Тавышы тыныч, ул берни аңламый: ул Фидаяны, кеше күзеннән качып, бу очрашулары фаш булмасын өчен төшеп калырга ниятли, дип уйлый һәм моны хуплый да иде! Ул Фидаяның бөтен тәненә эссе ләм уралганын, аның кибеп, тыгызланып, сулышны кыса барганын, бәгырьгә саркыганын тоймый да, белми дә иде.

— Тукта, дим, югыйсә, хәзер сикерәм!

Фидаяның ишекне ача башлаганын күреп, ул сагайды, тормозга басты, тәгәрмәчләр юеш асфальтта чинап, машина чак кына юл читенә авып китмәде.

«Волга» туктар-туктамас, Фидая сикереп чыкты да фаралары белән караңгылыкны кисеп килгән машина каршына ташланды. Чак тәгәрмәч астына эләкмәде, машина кинәт борылды, читтә торган «Волга»ны сыдырды дигәндә генә, могҗиза белән ничектер янышнан үтеп китә алды, тәгәрмәчләр ямьсез чинады, сүгенү тавышы ишетелде.

Бу — ике ягына кызыл тәреләр ясалган больница фургоны булып

чыкты. Ул бераз алгарак китеп туктады, аннан кемдер төшеп, Фидаяга таба йөгерә иде.

— Син нәрсә! Үләсең килдемени!

Ул арада «Волга» кузгалып киткән, аның артындагы кызыл утлар, яңгыр аша сибелеп, кичерәя барып җемелди иде. Фидая янында Билал басып тора иде.

— Фидая Госмановна! Ни булды сезгә? Нишләп йөрисез монда берүзегез?

Билал, гаҗәпсенеп, бер — Фидаяга, бер китеп барган машинага карады.

— Шунда! Шунда! — дип, кулын кире якка селтәде Фидая.

— Әйдәгез, утырыгыз!

Билал аны биленнән алмакчы иде, Фидая корт чаккандай читкә тайпылды, аның кулы җитмәслек итеп әйләнеп машина кузовының ачык ишегенә юнәлде. Аннан кемдер карап тора иде — бу ят ир кеше булып чыкты. Билал, машинага кереп, аның авырулар йөртү өчен җайланган эскәмиясенә утыргач, эчтәге өч кешенең Казаннан килгән врачлар икәнен, яңа больницаны җиһазлау турында киңәшләр бирергә килгәннәрен аңлатты, исем-фамилияләрен атады. Фидая да нидер әйтте, сүзләре урынлы да булгандыр, бәлки, ләкин бу сөйләшү шундук аның зиһененнән чыгып, җил-яңгырлы, караңгы далада калгандай юкка чыга торды.

Машина килеп туктауга, больницаның ишеге төбенә ак халатлы, ак башлыклы Гөлфия чыгып басты. Ишек өстендә янган лампа яктысында ул кырыс, горур һәм сүзен дә, фикерен дә үзгәртмәстәй каты күңелле булып күренде. Билал белән кунаклар ишектән кереп киткәндә ул читкә тайпылды. Фидаяның исә юлына аркылы төшәргә теләгәндәй, кире ныгып, тураеп, болдырның урта бер җиренә басты.

Шунда Фидая сулышны кыса торган сасы ләмнең бавырына барып ирешкәнен тойды, ул читкә, караңгыга, сүтелгән коймадан калган багана янына барды да тыела алмыйча коса башлады.

Ул башын күтәргәндә, Гөлфия әле һаман болдырда басып тора иде, аның йөзе тагын да кырысланган, хәтта ачулы кыяфәткә кергән, иреннәре кысылган иде. Фидая күрергә күнекмәгән, нинди дер ят Гөлфия иде бу, һәм аның ни уйлаганы аңлашыла да иде. Ул барысын да белә: моннан киткәч, Фидаяның кайда булганын, ни эшләгәнен дә, хәзер нәрсәдән күңеле болганганын да, барыннан да бигрәк, шушы бернич сәгать эчендә аның тәне генә түгел, җаны, намусы пычранганын да...

Фидая кесәсеннән кульяулык эзләде, тапмады, муенындагы капрон шарф белән иреннәрен, битен сөрткәләде, якынрак килеп, ләкин яктылыкка бик үк кермәскә тырышып, читтән генә:

— Мунча ягулымы сезнең? — дип сорады.

Гөлфиянең йөзе тагын да караңгыланды. Аның Фидаяны мунчага кертәсе килми, ләкин ул ялганлый да белми иде.

— Ягулы,— диде теләр-теләмәс кенә.

— Кереп, юынып чыгып булмас микән?— дип сорады Фидая. Тавышы ялынгандай да, гаепле дә чыкты.

— Белмим шул,— диде Гөлфия, артына карап алды, әйтерсең, ул Фидаяны мунчага кертмәс өчен берәр хәйлә, ышандырырлык чара эзли иде.

— Ничек булыр икән? — диде ул ачулы тавыш белән. Алай да, үзен тыярга тырышты.— Анда Шәмсеҗиһан апа янына керсәң генә инде. Ул юына иде.

Шәмсеҗиһан әле генә кергән, чишенеп тә өлгермәгән, башыннан шәлен салып, кофтадан килеш, сары нарат эскәмиядә утыра.

Фидаяны күрүгә, аның әле генә нинди дер зур фаҗига кичергәнен аңлап та алды. Аңа ничек авыр икәнлеген сизде, сәбәбен сорамады. Кеше явызлыгы аркасында юлыкканмы ул фаҗигагә, әллә үзенең хатасы

аркасындамы — Шәмсеҗиһан өчен анысы мөһим түгел иде — ул, фронтларны кичкән кеше буларак, дошман снаряды тигән сугышчыны да, ялгыш минага басып яраланганны да бер үк төрле дәваларга кирәк, дип саный иде. Үзе күп еллар тормышның иң кайнар нокталарыннан читләшеп яшәгән булуына карамастан, йөрәге яраланган кешеләрнең хәлен аңлый белә иде ул. Бу минутта ул Фидаядан күпкә көчлерәк, акыллырак, зирәгрәк күренде, эскәмиядә утырганга, аның гариплеге дә сизелми, ә йөзеннән, якты күзләреннән мәрхәмәт-шәфкать бөркелә. Фидая аның каршына барды да, тезләнеп, күкрәгенә маңгаен терәде.

Шәмсеҗиһанның куллары зур, көчле, беләкләре нык иде. Алар, Фидаяны дөньяның афәтләреннән саклагандай итеп, иңбашларыннан һәм аркасыннан урап алды:

— Нихәл итәсең, дөнья шундый, егылмый яшәтмиләр,— диде ул.— Егылгач торып китә алсаң, яши аласың әле. Аякларыңа ныгытып баса алсаң, бәхет килә әле...

Аннары, уйланып торды да, аркасыннан сыйпап:

— Бигрәк олы эшкә тотындың шул үзең дә,— диде.— Борынгылар әйткән бит: өйне өя-өя көеп беттем, дигән. Ә бу сиңа бер өй хәтле генәмени? Син генә күтәрерлекмени?!



34

Фидая үзен каһәрләнгән, ялгыз итеп тойганда һәм Шәмсеҗиһанның йомшак-көчле кочагында юаныч табарга тырышканда, аны уйлап үзәге өзелгән берәү турында бөтенләй оныткан иде.

Ул берәү — Мәгъсүмнең анасы Шәрифә иде.

Улының Фидая артыннан йөрүен Шәрифә башта ук ошатмады. Мәгъсүмнең ни сәбәптән велосипед белән кичнең кичендә Баллыбольшнга барганын белгәч, ул бу кызны Сугашка килгән чакта күреп калу җаен тапты, аның Баллыбольшннан алып килгән балалар белән сәхнәдән концерт куйганын карарга махсус барды. Җентекләп күзәтте һәм шомга төште: бу чибәр, чая, горур, үткен кыз кемгәдер баш бирә торганнардан түгел һәм аның улын санга сукмаячак, хәтта йорты, гаиләсе турында да артык кайгыртмаячак иде, аныңча. Мондый кызларны күп күрде инде Шәрифә үз гомерендә: алар бәйрәмнәрдә байрак күтәреп халык алдыннан барырга, җыелышларда трибуналардан сөйләргә, машиналарга утырып, тегендә-монда йөреп, халыкка акыл өйрәтергә яраталар. Иргә ярарга, өй карарга көчләре дә, теләкләре дә калмый. Хәер, алар ирләрен үзләреннән түбән куялар һәм аларның киемен юып, ашарга әзерләүне юкка вакыт сарыф итү дип саныйлар.

Юк, ошамады бу кыз Шәрифәгә. Сөйкемле, тыйнак, сабыр берәр кыз туры килсә ни әйтер идең бит... Алай да, бу чибәркәй аның тыйнак улына карамас, үзенә тиңнәрне табар, дип юанды ана.

Улы, бу тәкәбберне алып кайтып: «Әни, мин синең иң бәхетле улың!» — дигән көнне Шәрифә үзенең иң кайгылы көннәреннән берсе булыр, дип уйлаган иде.

Ул киленен күңеле белән кабул итә алмады, арада җылылык урнашмады. Ачуланышмыйлар, әйтешмиләр дә, шул ук вакытта ачылып сөйләшмиләр генә түгел, бергә аш-су әзерләргә туры килсә дә, бик авыр кичерәләр, шуңа күрә һәр икесе бер-берсеннән ерак булырга тырыша иде. Ире вафат булып, ике улының берсе бик еракларда, чит илләрдә йөргән Шәрифә, Мәгъсүм өйләнер дә, олыгайган көнендә алар белән яшәрмен, дип өметләнә иде. Ләкин бу килен каенана сөяген тотардай булып күренми, аның янәшәсендә Шәрифә үзен кечкенә, вак дип хис итә. бу хис аның йонын кабарта, киленнең һәр хәрәкәтен өнәмәскә котырта, һәр сүзенә каршы әйтергә телен кычыттырып тора иде.

Баштарак Мәгъсүм аларны ешрак очраштырырга тырышты: үзлә-

ре төп йортка киләләр йә карчыкны чакыралар иде. Ләкин бу очрашулар араларны тагын да ныграк бозганны күргәч, вакыт үзе бу икәүне дә бер киртәгә кертер әле, дип өметләнеп, кунак-кунак йөрешүгә артык кыстамады. «Үзләре әйбәт торгач, ярар инде»,— дип үзен юатырга тырыша иде Шәрифә, ләкин күңелендә сөйкемсез киленгә ачу кабара иде.

Мәгъсүмнең вафаты мөнәсәбәтләрнең астын-өскә әйләндерде дә ташлады. Уртак кайгы, әйтерсең, Шәрифәнең күзеннән кара пәрдәне алып ташлагандай итте һәм ул сөймәс килен урынында бөтенләй башка берәүне — өзелеп сөйгән ирен, баласының атасын югалткан, бу хәсрәтне күтәрә алмастай сыгылган хатынны күрде.

Иркәне Шәрифә электән дә ярата иде. Улын югалтканнан соң Шәрифә өчен тормышта бердәнбер якты нокта, таяныч, киләчәккә өмет, йөрәкнең ярасы һәм аның дәвасы булып шушы сабый калды. Фидая Суташка күчеп килгәч, Шәрифәнең куанычына чик-чама булмады. Алар чын мәгънәсендә аналы-кызлы булып якынаеп киттеләр, бергә чакларда Шәрифә аның тәкәбберлеген сизми, чибәрлегенә соклана иде. Әмма хатыннарның Фидая турында «чибәр шул ул», дигәнен ишеткәч, бәгыре сыкрана башлый иде. Әйе шул, чибәр, әйе, йөзе дә, күзләре дә ут янып тора, һәр адымында йөрәк кайнарлыгы сизелә. «Озак йөртмәсләр, алып китәр берәрсе»,— диләр хатыннар. Шәрифәнең йөрәгенә пычак белән сызып-сызып җибәргәндәй итәләр. Әйе шул, андыйларны ялгыз йөртәләрмени! Килерләр, алырлар. Ярый ла Суташның үзендә калдырсалар. Ә еракка алып китсәләр? Суташта калган сурәттә дә, Шәрифәне чит итә башласалар? Иркәне аның белән очраштырмасалар? Ирләрнең дә төрлесе була, кайчак кабердә яткан кешеләрдән дә көнләшәләр.

Шәрифә көрешкән саен килененең йөзеннән үзгәреш эзли, аның күзләре, йөрәге шулкадәр сизгерләнде ки, ул инде Фидая үзе дә аңлап өлгермәгән кичерешләрнең ялгалгысын күреп ала иде.

Йа алла, ул хәзер киленен үзе кулларына күтәреп йөрердәй була, аның аяк астында туфрак булырга риза, тик кияүгә чыгарга гына ашыкмасын, Иркәне Шәрифәдән аермасын иде!

Асылда, ул Фидаяга ялгызлык тели иде.

Фидаяның, больница төзим, дип җан атып йөрүе Шәрифәнең йөрәгенә сары май булып ятты: эшендә янсын-көйсен, тик ялгызлыгын уйларга вакыты гына калмасын. Килененең өйдә сирәк булуына да, соңарып кайтуына да эче пошмый Шәрифәнең, анысы, бер яктан уйлаганда, карчык өчен яхшырак та әле: ул Иркә белән бергә була. Килене кызын Шәрифә өенә илтергә бик үк яратмый, Шәрифәнең үзләренә килеп торуын хуплак күрә — монысы да карчыкның эчен пошырмый, бигрәк әйбәт, карчык анда чакта мир каршында Фидаяның намусы чиста.

Кыскасы, иң газиз кешеләрен югалтып, бер-берсен юатышып дигәндәй яши башлагач, сөймәс килен каенананың күңел түренә кереп урнашты. Хәзер инде аны башка берәүгә, ягъни икенче иргә бирү Шәрифә өчен җан газабы булачак иде. Кайбер ирләр хатын аеруны да алай авыр кичермәс!

Соңгы айда Фидаяда ниндидер үзгәреш сизеп, карчыкның эче бик тә поша башлады. Ниндидер аңлашылмас сизгерлек белән аяк астында җир убыласын сизеп алган киектәй тойды ул үзен. Беркөнне кечкә таба почтадан зур төргәк килгәч, Шәрифә аны әйләндерә-әйләндерә карады, адресын кат-кат укыды. Төргәк Казаннан иде. Шәрифә былтыр Казаннан рәссамнар килгәнен, Фидаяның алар белән бик мавыгып йөргәнен, арада бер куе сакаллысының күзләре елтыр икәнлеген исенә төшерде. Сакалы озын булса да, бит очлары бик шома, чәчләре кара иде ул адәмнең. Хәзер яшь-яшь егетләр дә сакал җибәрә, модасы шулай, диләр. Шәрифә, бик җентекләп, Казан адресының соңындагы сүзне-фамилияне укырга тырышып карады, ләкин анда кемнеңдер имзасы бик сырлап, хикмәтләп куелган, азагындагы койрыгы өскә таба каратып

бо̧жраланган, «а» гамы, «в» гамы тәмамланганын аерырлык түгел иде.

Шәрифә токмач басканда да, чәй кайнатканда да, Иркәне бакчадан иртәрәк алып кайтып, ашатып, көйләп йокларга яткырганда да һаман шул төргәк хакында уйлады. Кем җибәргән аны, ник җибәргән? Нигә өенә салган, эшенә түгел? Димәк, анда, эшендәге кешеләргә күрсәтәсе килми?

Фидая аны ничек кулына алыр, ничек карар? Йөзе ничек үзгәрер?

Бу юлы Шәрифә аны түземсезләнеп көтте. Ишектән атлап керүеннән үк күрде: нәрсәдер булган иде. Башыннан беретын салганнан соң шомарып, карасуланып калган чәчен күргәч, Шәрифә аптырап китте. Күз карашы да сүрелгән, йөзе сулган иде киленнең.

— Башыңны чылаткансың икән,— диде Шәрифә сак кына.

— Мунча кердем,— диде Фидая.

Нинди мунча? Кайда? Шәрифә белә: Фидая мунчаны кызы белән бергә керә. Әмма карчыкны иң нык борчыганы һаман әлеге төргәк иде, килене пинҗәген салуга, төргәкне китереп бирде. Фидая аңа күз генә салды да почмакка терәп куйды.

Шәрифәнең йөрәк өстеннән йөк төшкәндәй булды. Ул инде хәзер килененә җентеклебрәк карый алды. Әйе, зиһене чуалган, төсе качкан иде бүген киленнең. Елаган да шикелле, күзләре шешенеп чыккан, иреннәре бүрткән. Аш ашамады, чәй эчмәде.

— Рәхмәт, минем тамагым тук,— диде.

Гомер булмаганча, Шәрифә карчык каршында ук күлмәген салып ташлады. Шәрифә хатын-кыз сизгерлеге белән һәммәсен аңлады, күңелен ачы әрнү сызып үтте. «Яшь, чибәр шул, ирләр аңа балга сарылган чебен кебек сарыла. Кара төннәрдә кемнәр беләндер йөри... Үзен ничек саклап бетерсен!..»

Шәрифә, күз төпләренә килеп төелгән яшьне күрсәтмәс өчен, күлмәкне идәнгә ташлап, кухняга кереп китте. Ул төнлә бүре килгәнен сизгән алабай кебек улый-улый, чиный-чиный елап җибәрергә әзер иде. Әйтерсең лә авыл башында, куерып үсеп килгән яшь нарат астында яткан улының рәнҗүе аның буыннары аша йөрәгенә килеп тоташты. Нишләргә, ничек итеп аның исталегенг, аның намусын, аның кадерен сакларга?

Шәрифә кухняда утны сүндерде — аның бу кыяфәттә килененә күренәсе килми иде. Килененең ояты юк, ул әнә ничек, чәч төпләреннән алып үкчәләренә хәтле бөтен тәне, намусы пычранган хәлдә кайтып керде, ә менә Шәрифә аңа үзенең хәсрәттән көйгән күзләрен, йөзен күрсәтергә теләми.

Шулай күпмедер вакыт үтте, бүлмәдән шылт иткән тавыш та ишетелми иде. Шәрифәнең колаклары чыңлый башлады. Ул сак кына ишектән башын сузып карады: зал ягында да, Иркә бүлмәсендә дә ут юк, коридорда гына сары калпак астында лампочка яна.

Шәрифә, зал ишеге төбенә барып, сак кына дәште:

— Килен, син әллә ашамый-эчми яттың да инде?

— Яттым, әни, яттым.

Фидаяның тавышы бик әкрен генә булып икенче яктан, Иркә бүлмәсеннән ишетелде:

«Әни!»

Бу сүз карчыкның күңелен кинәт үзгәртте дә җибәрде. «Әни!» Кызыннан кадерле кешесе бит ул аның! Нинди хәсрәтләрдән яна икән аның йөрәге, ниләрдән кыйнала икән! Күренеп тора: тамчы да очыну, куаныч, морадына ирешкәннән канәгатьләнү юк бит аның кыяфәтендә, кыйналып ташланган, язгы ташу суларына төшеп өшәнгән маэмай рәвешендә бит ул!

Шәрифә ашыгып борылды, кулларын сузып, Фидаяны кочагына алырга теләгәндәй, күрше ишеккә барды, ләкин анда атылып керергә кыюлыгы җитмәде, ике ишек борысына тотынып:

— Син мондамыни, кызым? — дип сорады.
— Монда мин, әни, яттым инде.
Коридордан һәм тәрәзәдән тоныкк кына булып төшкән яктылыкта Шәрифә кулын Иркәнең юка, нәни гәүдәсенә салган ананы күреп алды. Әйе, ул баласын кочаклаган иде. Аның тәненнән җылы, көч алып, рухын дәваламакчы, аңа сыенып чистарынмакчы, күрәсең.
Шәрифә, ни әйтергә белми, ишек төбендә бераз басып торды да:
— Мин китим инде, кызым,— диде.— Ишекне бикләп кал.
— Шунда, залда гына йокла,— диде килене. Аның тавышында битарафлык сизеп, Шәрифә тетрәнеп куйды. Әгәр шунда, китмә, әни, кал инде, дип ачыграк итеп әйтсә, китмәс иде Шәрифә. Янәшә утырып, кочаклашып серләшергә, сөйләшергә кирәк булгандыр аларга!
Ләкин бу мөмкин түгел, язмыш аларның икесен ике якка этәрә иде.
— Кайтыйм әле, өй ялгыз бит анда,— диде Шәрифә.
Фидая Шәрифәне озатып кергәч җиңел сулап куйды, карчыкның текәлеп күзәтеп торуы аның болай да кыйналган җанын тагын да ныграк изә иде.
Әнисенең кузгалып, чыгып-кереп йөрүеннән Иркә уянды.
— Йокла, кызым, йокла. Иртәгә бакчага барасың бар.
— Әни, син кая бардың? Баллыболынгамы?
— Баллыболынга, кызым. Баллыболынга.
— Җыелышкамы?
— Әйе, кызым, җыелышка.
— Сәхнәдә утырдыңмы?
— Әйе, кызым, сәхнәдә.
— Сөйләдеңме?
— Сөйләдем, кызым.
— Матур итепме?
— Әйе, кызым, әйе.
Фидая күзләреннән аккан яшьләрен тыя алмый, тавышының калтыраганын сиздермәскә тырыша, учы белән баланың юка чәчле башын сыйпый да сыйпый иде.
«Тимәгез аңа! Тимәгез минем хисләремә!» — дигән сүзләр искә төшеп, бәгырьне телгәләде.
...Урамга чыккач, салкынча һава Шәрифәнең кызган маңгаен сыйпап, тынычландырып җибәргәндәй итте. Ул, асфальт юлга күтәрелеп, урам уртасыннан китте, клуб турыннан узды. Ике катлы бинаның тәрәзәләреннән якты бөркелә, музыка уйнаганы ишетелә, ишек төбендә егетләр кайнаша иде. Хәтта ресторанның да тәрәзәләре япякты, анда да ниндидер тырт-тырт иткән ят җыру уйнаталар, тәрәзәләрдә шәүләләр чагылып уза — бүген анда туй ясыйлар. Каршыга күзне чагылдырып машина килә иде. Шәрифә читкә тайпылды. Кыскасы, дөнья үз мәшәкатьләренә, гамьнәренә уралып яши иде.
«Нишләтәсең, тормыш үзенекен итә инде,— дип уйлады, башын иеп, аяк астына карап Шәрифә.— Утызга да җитмәгән, ирнең назын татыган, бала тапкан сау-сәламәт хатын бит ул. Янында кемнәр генә бөтерелми. Фәрештә дә түзә алмас! Бу сиңа сугыш вакыты түгел. Нихәл итәсең! Ире юк, ирекле кеше...— Шәрифә күзләрен сөртеп алды.— Итәген җыеп йөри алса ярый инде. Халык алдына йөзе кара булмаса, шуңа шөкерана итәрсең. Ояты Иркәгә төшәрлек булмасын, дип теләргә генә кала...»
Шулай уйлады Шәрифә һәм, килененең кыяфәтенә караганда, әлегә гашыйк булмаган, башы-күзе әйләнмәгән булса кирәк, дип юаныч тапты. Йөрсә йөрсен инде, әйдә, тик фаш булмасын да, ашыгып кияүгә чыгып кына куймасын. Шулай дип юанырга тырышты бичара Шәрифә.

Каләмгөлнең җеназасында да, аннан соң да Наилә Гыйззетдингә кат-кат әйтте:

— Олы мәет үзе артыннан бүтәннәрне тарта торган була, балаларыңны сакла, үзең дә саклан,— диде.— Син инде олы кыз, энеләреңне ач-ялангач йөртмә, йортны кара,— диде Заремага.

Кыз тузгыган бөдрәләре астыннан аңа зур, төпсез күзләре белән карады, әйткәнен аңламады, аңласа да, тыңларлык хәлдә түгел иде.

Наиләнең сүзләре Гыйззетдиннең дә зиһененә рәтләп барып җитмәде. Ул нишләргә, нәрсәгә барып тотынырга белмәде, тормыш җаен тапмады. Ярый әле, күрше хатыннары кереп өйне, мал-туарны карашалар иде.

Ләкин гомер буе күрше-күлән ярдәме белән генә көн итеп булмый. Хәсрәттән миңгерәгән Гыйззетдингә дә әнкәсез калган оядагы балаларны үз тирәсенә туплап яшәргә кирәк иде.

Бер төнне Зарема аны саташулы авыр йокысыннан уятты:

— Әти, дим... Әти, уян...

Урынына утырып, бераз һушына килгәч, Гыйззетдин ниндидер озын сызгыруга охшаган авазның сыкрану белән тәмамланганын ишетте, тончыгып һәм сулыгып, бала елап җибәрде.

Зарема диваннан Өлфәтне күтәреп алды:

— Ишетмисеңмени, буыла бит!

Баланың чырае җилсенеп чыккан, күзләре зур ачылган, сулыш алган саен тамагында ниндидер сыбызгы сызгыра, ләкин сыбызгы ярыгыннан узган һава гына җитми, малай, куркуданмы, авыртуданмы, еларга керешә, сулкылдау исә тамак сыбызгысын тагын да нечкәртә, ул буылып ютәлләргә керешә, әмма бу коры ютәлләү аның тамагын тазартмый иде.

Гыйззетдин үзе дә сулыш ала алмый башлады бугай. Келт итеп хәтергә Наиләнең: «Олы мәет үз артыннан... тарта...»— дигән сүзләре килде. Шушы сабыйны, Өлфәтне тарта микәнни? Мөмкин түгел, булмас!

Гыйззетдин сикереп торды, нишләгәнен белмичә, баланы Зарема кулыннан тартып алды, үзенә һава җитми башлады, ишекне ачып ташлады. Малайның йөзе күгәрә башлагандай тоелды.

— Мөниргә, Мөниргә!..

Гыйззетдин баланы күтәргән килеш урамга чыкты, бар көченә йөгереп китте. «Әз генә түз, сабыем, ничек кенә булса да чыда, хәзер, барып кына җитик, коткара ул сине, коткара, илтеп кенә җиткерим!»

Ул йодрыгы белән капканы төйде: «Мөнирә, ач, Мөнирә!» — дип кычкырды. Кеше ишетер, кемдер күрер, гаепләүче булыр, дигән уй аның башына да килмәде. Өйдә ут кабынды, тәрәзә пәрдәсен ачып... башта тышка Зиләйлә карады, йөзен кыйшайтты, ләкин Гыйззетдин аны да искәрерлек хәлдә түгел иде. «Ач! — диде ул.— Әниеңне чакыр, әниеңне!»

Ул арада кызының башы өстендә Мөнирәнең йөзе күренде, ул, кер, дигәнне белдереп, капкага таба ишарә ясады. Гыйззетдин тышкы ишеккә барып җиткәндә Мөнирә инде бусагада тора, ул ак халаттан, башына ак яулыгын бәйләп азаплана. Берни сорамады, алдан ашыгып атлап, өй ягына кереп китте, Гыйззетдингә исә: «Керә торыгыз!» — диде. «Нигә өенә кереп тора инде!» — дип үзәге өзелде Гыйззетдиннең, нигә баланы карамый! Ул медпунктның күңелне сагайта торган аклыкка уралган бүлмәсенә керде, нишләргә белми баласын кулында тирбәтте, малайның башы хәлсезләнеп артка каерыла башлаган иде инде. Ул арада Мөнирә килеп керде. Кулында сулы чынаяк иде, ул, пыяла шкафтан шешә алып, аңа берничә тамчы тамызды да,

баланың башын сак кына күтәреп, иреннәренә тигерде һәм нык тавыш белән: «Эч!» — диде. Бала керфекләрен күтәрде, иреннәрен чынаяк читенә тигерде, йотылып эчте.

— Утыр! — диде Мөнирә Гыйззетдингә, ак җәймә җәелгән тар ятакка күрсәтеп. Гыйззетдин буйсынды. Мөнирәнең болай катгый, тыныч сөйләшүе, ни булды, ник килдегез, нишләде, дип тә сорашып тормыйча эшкә керешүе аның йөрәгенә хәл кертеп җибәргәндәй итте, аннан да бигрәк, баланың сузып-сызгырып булса да көрсенгәндәй итеп сулыш алуы җанга җылы иңдерде.

Мөнирә тагын чыгып китте, әзрәк торып, ак эмаль чиләк алып керде, чиләктә яртылаш саргылт су, аннан пар күтәрелә һәм горчица исе аңкый иде.

— Аягын тык шуңа,— диде Мөнирә. Гыйззетдин баланың аркасын күкрәгенә терәп, нәни тәпиләрен суга чумдырды.

— Кайнар түгелме? — дип сорады Мөнирә. Бу юлы аның тавышы бик йомшак, ягымлы, хәтта нечкәреп киткән иде, ул балага дәшә иде.— Тәпиең пешмиме? Пешсә, әйт, әзрәк суыкны өстәрбез.

Ул, идәнгә чүгәләп, суга кулын тыкты, баланың аякларын тотты.

— Рәхәт бит, ә, рәхәт бит? Тәтиме?

Малайның йөзе алланып, тынычланып киткән, аның нәни йөрәге үлем куркынычыннан арына бара иде, ул тавышлы сулышы аша ак халатлы бу апага елмаеп куйды.

— Ие, тәтә,— диде карлыккан тавышы белән.

— Менә хәзер без сиңа кызыл оекбаш кигезәбез, яме? Шундый матурны, әйбәтне. Менә хәзер мин әзрәк кенә чәйнектән өстим дә, тагын да рәхәтрәк була...

Мөнирә шулай сөйләнеп, бөтерелеп йөрде, тагын чыгып чәчәкле ак эмаль чәйнек алып керде, аннары тагын чиләккә кулын тыгып, чәйнек борыныннан кайнар су агызды.

Баланың сулышы торган саен иркенәя барды. Дөрес, хырлау, сызгыру бетми, әмма инде буылганы сизелми, талчыккан башы Гыйззетдиннең беләгенә ята һәм аннан килгән җылы атаның бөтен гәүдәсенә ләззәт булып тарала иде. Бүгенге куркудан гына түгел, соңгы атнада килгән күтәреп булмастай хәсрәттән дә арына иде кебек аның талчыккан җаны. Ул аркасын стенага терәп күзләрен йомды: шушылай итеп, баласын тезләре арасына кыскан хәлдә, бернәрсәдән курыкмыйча, берниндн ваемсыз, мәңге утырса да риза булыр иде кебек тоелды.

Уколны да балага бик җиңел ясады Мөнирә — хәер, аның кул йомшаклыгы авылда дан бит инде. Күпме вакыт үткәндер, Гыйззетдин чамаламады. Мөнирә Өлфәтне аның тезләре арасыннан алды да, ятактагы ак мендәргә башын җайлап кына яткырды, өйдән әйләнеп кереп, өстенә ак тышлы юрган ябып куйды. Өлфәт тигез сулый башлаган, тынычланган, алланган яңакларына күләгә төшереп, керфекләре йомыла иде. Мөнирә аның битен сыйпады. Чиләкне читкәрәк этәрде, өстәлендә ниләрнедер җыештырды, аннары, Гыйззетдингә карамый гына:

— Үзеңнең дә төсең качкан, авырмыйсыңдыр бит? — дип куйды. Борылып янына килде дә, таләпчән хәрәкәт белән сул кулын ятактан күтәреп, бармак башлары белән беләзеген кысты — йөрәк тибешен үлчәргә. Әмма Гыйззетдин моны аңлап җиткермәде кебек, куллары белән аның беләгенә ябышты, яңагына кысты... Ул әле бала өчен коты очып куркуы турында сөйләмәгән иде бит, гомумән, Мөнирә аңардан хәтта: «Нишләде бу бала?» — дип тә сорамады, ә Гыйззетдиннең аңа сөйлисе, аңлатасы, эчен бушатасы килә иде. Ул Мөнирәнең крахмалланган, каты халат җиңенә битен ышкып, күзләрен йомып шуларны сөйләргә керешә бугай. Нинди сүзләр әйтте, күпме сөйләде — хәтерләмәде. Аннары тынып калды, Мөнирәнең сүзен йә булмаса бе-

рәр хәрәкәтен көтте, ә ул, кулын аның ихтыярына биреп, тынып калган иде. Гыйззетдин аның кайнар, йомшак бармакларын сыйпады.

— Ларингит анда,— дигән тавышы ишетелде Мөнирәнең.— Суык тигезгәнсең.

— Чирләгәне бер дә сизелми иде бит, йөткерми, төчкерми иде.

— Кинәт башлана шул ул.

— Җан бирә дип торам, котларым очты.

— Куркыныч шул,— диде Мөнирә, юатмады, киресенчә, пошынып әйтте.— Тамак эчтән шешә, сулыш юлы каплана.

— Әллә бөтенләй үк капланыр идеме?

— Алай да булуы ихтимал. Бер өч көннән үтә ул, гадәттә. Тик менә өч төн сакларга кирәк инде.

Гыйззетдиннең бөтен тәне куркудан тетрәнеп куйды: әгәр шунда уянып китмәсәләр, әгәр ул монда йөгереп килмәсә, әгәр Мөнирә өйдә булмаса!.. Аның берәр кая киткән булуы да ихтимал иде бит!

Гыйззетдин мең рәхмәтләр белән аның бармакларын уттай янган яңагына кысты. Бу кулларда күптән күңелгә кереп калган наз бар, аннан күптән таныш, шактый вакытлар онытылып торган, хәзер исә бик татлы, җанга ял һәм ышаныч биргән ис — дару исе килә иде.

— Нишләргә соң инде, нишләргә?— дип пышылдап сорады Гыйззетдин.

— Бер өч төн саклыйсың инде. Җылы сөт эчерергә, өйдә һаман җылы су тотарга...

Әмма алар бала турында гына түгел, алар зуррак, үз тормышлары өчен әһәмиятлерәк нәрсәләр хакында, өч төнне үткәрү турында гына түгел, ә бәлки озын гомерне кичү турында сөйләшәләр иде шикелле.

Мөнирәнең бармаклары Гыйззетдиннең учында хәрәкәткә килде, аның яңакларына сырылды, баш түбәсендә аның сулышы тоелды.

Нәкъ шул минутта шакылдап ишек ачылып китте. Бусагада, яктырып, мәһабәт бер кыяфәт белән, ак җәймәгә уралган Зиләйлә басып тора иде. Аның күзләреннән дәһшәт сибелә, бөтен кыяфәтеннән ачу ташый, муенына җыерылып уралган, очлары идәнгә бөгәрләнеп салынган ак җәймә кызның кыяфәтенә әкияти шом бирә иде.

Өчесе дә тынып калдылар. Гыйззетдин үзенең түгел, Мөнирәнең йөрәге тибә башлаганын ишетте — ул нәкъ колак турында дөпелди иде. Зиләйлә күз карашы белән аларны бер-берсеннән читләштерергә тели иде шикелле.

Менә ул җәймә астындагы кулларын ныграк күтәрде, шушы аклык эченә бөтенләйгә яшеренергә теләгәндәй, муенын җыерды, аннары кинәт кенә борылды да өйалдына чыкты, селтәнеп, бик каты шапылдатып ишекне япты. Күренеш шуның белән тәмамланырга тиеш иде, ләкин Зиләйлә уйлаганча килеп чыкмады, җәймәнең чите ишеккә кысылып калды. Ишекне янә ачарга һәм тагын да ныграк ачу белән ябарга туры килде, әмма, ике тапкыр кабатлагач, бу ишарә үзенең дәһшәтен киметтe, Гыйззетдингә дә, Мөнирәгә дә кызык булып китте. Бу — аларның икесен беррәттән гаепләү һәм ачулану иде, ачуланучысы исә икесенә дә бертигез газиз иде. Уртак хис тартылу көчен арттырды гына. Мөнирә ике куллап иренең башын күкрәгенә кысты.

— Яшьләр без дигәнчә уйламый шул,— диде.— Алар күп нәрсәне аңлап җиткерми әле.

Ул гүяки кызының дорфалыгы өчен Гыйззетдиннән гафу үтенә иде.

Шәрифәне шөбһәгә салган төргәк Рамиләдән иде. Больница стеналарына ясарга рәсем үрнәкләрен җибәргән, Фидаяның фикерен сораган: «Киләсе җәйгә кадәр башка яңа фикерләр дә килер әле, тагын бер елдан стеналарны торгызып бетерә алырсыз микән?» — дигән. Фидаяны сагынып искә алганын әйткән иде.

Тагын бер елдан? Ялгышасың, сеңелкәш, стеналар түбә астына керде, ишек-тәрәзәләрне куялар, идәннәрне җәяләр, штукатур эшләренә керешәләр озакламый. Синә тизрәк үзеңә монда килергә кирәк!

Нурханованың абруе районда үсә бара, сүзен дә хәзер эчке бер сагаю һәм хатын-кыз булганы өчен яшерен кимсетү белән түгел, ә ирләрчә җитди тыңлыйлар, ничек кенә булмасын, зур төзелеш аның дәрәҗәсен үстерде. Ләкин шул ук вакытта ул каядыр офык артында болытлар куерганын тойгандай була, аннан кинәт кара болыт өерелеп чыгар, давыл кубар һәм өермә аны күтәреп алып китәр иде шикелле. Ашыгырга, ашыгырга кирәк иде аңа.

Бу куркыныч, беренче чиратта, Мирхуҗиннан килә иде. Әйе, бүтәннәр Нурхановага ихтирам белән, зурлап караганда һәм һәр сүзен олылап кабул иткәндә, Мирхуҗин гына майлы күзләре белән астыртын мәгънә салып елмая, туры килгәндә, орынып китәргә чамалый, коридорда бер узганда беләгеннән шундый каты итеп чеметте, Фидая кычкырып җибәрүдән чак кына тыелып калды. Авыртудан да бигрәк гарьлеге ачы иде: бу рәвешле Мирхуҗин аңа үзенең тамгасын салды — башка ирләр белеп торсын, минеке, янәсе! Ул ике арада якынлык барын яшерергә уйламый да кебек, кеше алдында күз кысарга да күп сорамый, аңа нәрсә, районда бер чибәр һәм дәрәҗәле хатын белән чуалу ирлек абруен гына күтәрә, дип саный ич!

Никадәр генә кимсенсә дә, Фидая бу хәлдән котылу чарасын белми, чөнки ул теге көнне түбәнлеккә төште, анда, хыянәт дигән түбән мәйданда, гадел мөнәсәбәтләрнең булуы да мөмкин түгел иде. Әйе, ул көнне Мирхуҗин — хатынына, ә Фидая — намус сафлыгына хыянәт итте, ә хыянәтчеләр арасында бер-берсенә ихтирам да, кызгану да юк, һәркайсы фәкать үз рәхәтен генә уйлый, әгәр бу уйлары килешсә — алар бергә, әгәр дә берәрсе үзен рәнҗетелгән дип хис итсә — аңа беркемнән берни дә яклау да, аклау да юк. Башка рәвешле җәберләнгән кеше кемгәдер барып, зарланып күңелен бушата ала, хыянәтчеләр яклаудан мәхрүм. Пычрак итекләр таптасын аларның күңелен, рухын изсен — кылганнарының җәзасын алалар, шул кирәк!

Теге көннән соң Мирхуҗинны күргән саен Фидаяның күңеле болгана, хәле китә, күзгә-күз карап сөйләшү, аулакта күрешү турында сүз дә булуы мөмкин түгел иде. Мирхуҗин исә ул очрашуны эшнең башы гына дип исәпли, аныңча, хәзер инде Фидая бик тә күндәм булырга тиеш иде — яшь, сәламәт хатын бит ул, барыбер ирсез яши алмый, ә Мирхуҗиннан яхшысын каян таба, янәсе.

Ул иртәгесен иртән үк шылтырата башлады. Фидая телефон трубкасын ташлагач та исе китмәде, бүлмәсендә кеше бардыр, дип уйлады. Аныңча, хәзер инде кайда ничек очрашу җаен Фидая үзе табарга, ә Тавис аның янына кунак булып, иркәләнеп, көттеребрәк кенә барырга тиеш иде.

Ләкин ике-өч көн, атна үтте, Фидая очрашу ягын кайгырту гына түгел, телефоннан да сөйләшмәде, очраганда, керфекләрен аска төшереп, шома гына узып китә торган иде, төзелешне кайгыртуны да онытты хәтта!

Тора-торып бу нәрсә горур Мирхуҗинның мин-минлегенә тия башлады. Нәрсә ярамаган ул хатынга? Әллә ул Тависны ир буларак ошатмаганмы, башканы, яхшыракны эзлиме?

Мирхуҗин аны бик җентекләп күзәтә башлады һәм бу нәзберек апакайның кемгә күзе төшкәнен сизеп тә алды. Әллә каян килгән түгел, янәшә йөри икән бит! Бик тыйнак, тәртипле кебек, колга буе югарылыгыннан башкаларга керфекләрен кысып кына карап йөри, ә үзе, әнә ничек, начальнигына нәфесе кузгалган икән! Мирхуҗин моны бер киңәшмә вакытында, Фидаяның, Гаяровка карагач, кинәт кызарып-пешеп чыгуыннан һәм тегесенең дә йөзе үзгәреп, карашын читкә алуыннан аңлады.

Тәнәфес ясап, райбашкарма ишеге төбендә тәмәке тартып торганда, ул Гаяров янына барып басты. Гаяров үзе сирәк тарта, әмма бу юлы Мирхуҗин сузган затлы каптан сары саплы озын сигаретны суырып алды, бармаклары арасында шактый әвәләгәннән соң, авызына капты, башка вакытта йөзгә туры карап сөйләшә торган кеше, бу юлы урам аша үзенең «Газигы»на текәлеп карады, янында Мирхуҗин басып торганын онытып ук җибәргәндәй кыланды.

Тавис әйләнеп-тулганып тормады, үгезне мөгезеннән тотты:

— Әллә, мин әйтәм, без синең белән уртак малга тап булдык инде? — диде.

Гаяров, ниһаять, аңа борылып карады, гадәтенчә, күзләрен кыса төшеп, йөзенә текәлде. Аңламаган була, уйный бёлә үзе дә, дип уйлады Тавис. Көлемсерәп:

— Без бит ир кешеләр, кеше өлешенә керү килешми,— диде.

Давыт иреннәре белән сигаретны кысып куйды да:

— Кем өлешенә кергән әле мин? Чамалап сөйләшергә кирәк.— диде. Һәм Мирхуҗинны күрәсе килмәгәндәй, башын борып, югарыга, председательнең кабул итү бүлмәсенең ачык тәрәзәсенә карады, йөзе үзгәреп китте. Мирхуҗин да шунда күз салды — аннан Нурханова үрелеп, урамнан нәрсәдер карый иде — ә бәлки, машинасы шундамы, дип тикшерүе булгандыр, ирләрнең икәүләшеп башларын каерып үзенә текәлгәнен күргәч, ул тиз генә артка чигенде һәм күздән юк булды.

— Әнә, үзе дә сизә. Мин таптаган уҗымга кереп йөрмә инде син, малай,— диде Мирхуҗин. Давытның гаҗәпләнгәнен күреп, көлемсерәде: — Ышанмасаң, сул беләгенә кара,— диде.

Давыт сигаретын җиргә көч белән салды да, ялтыравык ботинкаларының үкчәсе белән боргалап изде һәм, Мирхуҗинга бер сүз әйтми, ишектән кереп китте.

## 37

Гыйззетдиннең кара төндә баласын күтәреп Мөнирә янына баруы, аннары Мөнирәнең Гыйззетдиннәргә килеп йөри башлавы турындагы хәбәр бөтен авылга бик тиз таралды, бу хакта хатыннар күп сөйләштеләр, барысы да диярлек хупладылар. Үз хатынына бармый, кемгә барсын тагын? Өч баланы ялгыз да үстермәс бит инде. Дөрес, Каләмгөлнең васыяте дә ничектер фаш булган, анысы да телдән телгә күчеп йөри иде, әмма моны күрәзәче хатынның чыннан да явыз булганлыгы, кабер якасына баскач та көндәшенә үчләнүе дип бәяләделәр. «Кеше күз яше төшми калмый ул, аңа да төште»,— диделәр.

Барысы да үз урынына кайта, гаделлек өскә чыга шикелле иде. Үлгән кеше турында начар сөйләргә ярамый, дигәнне истә тотып, Каләмгөлне сак кына искә алалар. Мөнирә өчен сөенәләр иде. Тик бер кешенең язмышы-кичерешләре ничектер искә алынмый — ул да булса Зиләйлә иде. Аның әтисен яратмаганы һәркемгә мәгълүм булса да, моны бер холыксызлык, әдәпсезлек, хәзерге заман яшьләренең олыларны санга сукмавының мисалы дип кабул итәләр: «Инде шул

Гыйззетдиннең дә кадерен белмәс икән! Аллы-гөлле киендереп, авылда беркемдә юкны алып биреп торды. Артык иркә дә үсте шул, аркасына атасының каешы тимәде».— диделәр.

Бу гаиләнең язмышы нинди дулкынга эләккәнен чамалаган Балкышның гына кыз өчен йөрәге сызлана иде.

Бер кичне, Нурханова өенә иртәрәк кайтып киткәч, ул Баллыболынга үзе генә барырга булды. Караңгы төшкән иде инде. Клуб янында туктап, караштырып чыкты: ишек төбендә егетләр җыелыша башлаган, тәмәке тарталар, үзара гәпләшәләр, елтыр күзләрен урамнан алмыйлар, нәрсәдер көтәләр кебек. Бу сагаюда, көлеп, шаулашып сөйләшүдә күңел тынгысызлыгы, нәрсәдәндер ризасызлык, каядыр сәбәпсезгә ашкыну һәм ниндидер ятимлек сизелә иде. Бу алгысауны, сусауны басар өчен, аларның күңелен шушы тын, серле җәйге кичтә зур авылның иркен урамына, агач ышыгына поскан тыкрыкларына, инешнең яшел ярлы чокырына һәм урам артындагы яшел болыннарына беркетер өчен, җиңел адымлы, көлгәндә тавышы дулкынланудан тирбәлгән кызлар кирәк, ә алар юк, алар каядыр еракта, утлары җемелдәгән, халык тулган шәһәр урамнарында йөриләр, анда исә аларның аяк тавышларын да, челтерәп узган көлү авазларын да болай көтеп, зарыгып каршы алучы юк.

Егетләрнең кайсылары Балкышның машинасына һәм үзенә сагаеп карадылар, алар арасында, әлбәттә инде, Зиләйләгә күз салып йөрүчеләр дә бар, һәм күңелнең иләс-миләс чагында, кул астына Балкыш кебек берәр килмешәк егет килеп кергәндә йодрыкларны эшкә җигәргә җай эзләп торулары да сизелә иде.

Балкыш: «Районнан клуб мөдиренә йомыш белән җибәрделәр».— диган булып, эчкә узды, анда, сәхнә артындагы бер бүлмәдә Зарема моңаеп утыра иде — Балкыш аңа сүз кушмады, ишеген ачып япты да чыгып китте.

Әлбәттә инде, Зиләйлә бу тирәдә артык буталмый, туры китерсәң, аның белән шул медпунктта гына очрашып була иде.

Балкыш машинасын арырак, авыл очынарак, юлдан читкә чыгарып куйды, үзе кире җәяү килде. Капкага якынлашкан иде, кинәт эчтән кычкырган тавыш ишетеп, туктап калды:

— Чыгып китсен хәзер үк! Эзе дә булмасын! Күземә күренмәсен!

Чарасызлыктан сулышына буылып кычкыручы бу кыз, шиксез, Зиләйлә иде. Балкыш ачык капкадан эчкә керде дә өйнең каршы ягына, ишек турына чыгарга яхшысынмыйча, туктап калды, чөнки тавыш нәкъ шул яктан яңгырый иде.

— Нишлисең син, кызым, нишләп болай холыксызланасың? — диде хатын-кыз тавышы, эчке дулкынлану белән, ләкин тыныч булырга тырышып.— Әтиең ич ул синең, үз әтиең!

— Миңа ата түгел ул! Заремага ата ул! Шуның белән яшәсен, бездә дәхеле булмасын!

Эчке яктан йөгереп килгәндәй авыр адымнар һәм кемнеңдер еш-еш сулаганы ишетелде. Балкыш стенага сеңәрдәй булып аркасы белән сыенды, аның яныннан яланбашлы ир кеше капкага таба узып китте — бу Гыйззетдин иде.

Ә эчтә Зиләйлә һаман кычкыра иде әле:

— Син үзең аны куып чыгарырга тиеш! Якын китермәскә тиеш! Ул безне ташлап китте! Ничә еллар буена хур итте! Шундый ата буламыни? Кая синең горурлыгың!

— Үз горурлыгымны үзем беләм мин,— диде хатын-кыз тавышы, ныгый төшеп, ачу белән хәтта.— Атаң белән анаң арасын тикшерергә башың яшь әле!

— Минемме башым яшь? Минемме? Алайса, ник мине катыштырдыгыз?

— Кем катыштыра сине? Тик кенә утыр! Синең башың житә торган эшмени?

— Сез теләсә ни кыланасыз, аерылышасыз, кушыласыз, ә кыены миңа төшсенме? «Кыйбатлы кыз» дип кемнән көләләр? Кемне мыскыл итәләр? Миннән оялмыйча, кем белән култыклашып йөрде ул!

— Телеңне тый, оятсыз!

— Минме оятсыз? Минме? Алайса, теләсә нишләгез! Үзегез яшәгез! Миннән башка!

Балкышның яныннан ук капкага таба Зиләйлә йөгереп узды, аның артыннан әнисе килә иде:

— Кызым, Зиләйлә, тукта, өйдәгене урамга чыгарып түкмиләр, килешми, ярамый!

Ләкин Зиләйлә, капкадан чыгып, авыл очына таба йөгергән иде инде — ачык капка турында аның ак күлмәге генә чагылып узды. Мөнирә исә, стенага сөялеп торган ят кешене күреп, сөрлеккәндәй туктап калды. Ләкин шундук үз-үзен кулга алды:

— Нишләп монда торасыз? — диде кырыс тавыш белән.— Нигә медпунктка кермисез?

— Мин хәзер,— диде Балкыш һәм Зиләйлә артыннан чыгып йөгерде.

Ул аны авыл башында, кайчандыр, кемнеңдер нигезе булган, хәзер инде куерып үскән алабута-кычыткан баскан төштә, агачлар арасында куып житте. Ул кызның күңеле тулгандыр, елый торгандыр, дип уйлаган иде, әмма якынрак килгәч, аның күзләре күмердәй елтыраганын күрде. Зиләйлә карт тупыл агачына аркасы белән сөялгән, кулларын артка куйган иде? Балкыш әкрен генә якын килгәндә кыймшанмады, бер сүз әйтмәде.

— Исәнме, Зиләйлә!

— Мин монда кеше күзеннән чүп алмыйм,— диде Зиләйлә коры гына.— Юньле кеше күз авыртуны сылтау итеп районнан монда килеп йөрми дә.

Ул ачуын Балкыштан алып бетерергә уйлый иде бугай.

— Ничава,— диде Балкыш.— Кирәк кешегә мин үзем дә ашыгыч ярдәм күрсәтә алам.

— Ярдәмгә мохтаҗ кеше монда түгел.

— Ә минемчә, нәкъ шушында,— диде Балкыш, аңа якынрак килеп.— Берәүнең йөрәгенә шырпы кергән, шуны аласы бар. Ашыгыч рәвештә.

Ул моны житди итеп, ләкин көлеп җибәрергә әзер тавыш белән әйтте. Зиләйлә шунда бер елмаеп куйса, ирексездән генә булса да көлемсерәсә, күңеле дә, теле дә йомшап китәчәк иде дә бит, әмма ул тагын да дорфарак кыланырга тырышты:

— Безнең йөрәкләргә шырпы кермәс, үзегезнекен саклагыз! — диде.

Балкыш сүзне үзгәртергә кирәк тапты, кулын аның баш очыннан сузып агач кәүсәсенә таянды да, кызга якын ук килеп:

— Син нәрсә, өйрәтелмәгән тай шикелле кешни-кешни чабасың? — дип сорады.— Берәүне бер якка тибеп очырдың, икенчене икенче якка, инде хәзер миңа тояк белән кизәнәсең!

Кыз аның кул астыннан чыкты, читләште, ләкин китеп бармады, сирень куагы астында, кара фонда ап-ак булып басып калды.

— Читтән карап сөйләү ансат ул,— диде.— Үз башыңа төшсә, син алай гына да булмас идең әле.

Балкыш әле генә Зиләйлә торгандай итеп, кулларын артка куеп, башын артка ташлады, тупылның кара-куе ябалдашына, ботакларның сирәгәйгән төшеннән күренгән йолдызларга карады.

— Синең урыныңда булсам, минем дә йөрәк әрнер иде, билгеле,— диде.

— Шул-шул менә, сөйләү рәхәт ул,— диде Зиләйлә, йомшап китеп һәм сулкылдап куйгандай итте.

— Шуңа күрә читтән караган кеше сүзен тыңларга кирәк,— диде Балкыш.

— Күп тыңлаган инде...

— Ни гаебе бар аларның? Әниең, әтиеңне хурлап, тиргәп куып чыгарсынмыни? Әтиең тагын килеп өченче хатынга өйләнсенмени?

Караңгыда кызның йөзе күренми, алай да соңгы сүзләрнең аңа китереп органдай тәэсир иткәнен тоеп алды Балкыш. Кызның борыны ныграк мышкылдый башлады:

— Менә үзеңне шулай итсәләр... Әллә кемгә ияреп чыгып китсәләр... тагын кире кайтсалар... Син үзең дә шундыйдыр әле! — Зиләйлә, куллары белән битен каплап, читкә борылды.

Балкыш, кузгалып, аның янына ук килде, ике иңеннән учлары белән сак кына тотып алды. Сабый баладан сораган кебек:

— Синең авылда бер генә ел укыйсың калды бит, әйеме?— диде. Зиләйлә кулларын битеннән алмыйча, «әйе» дигәнне аңлатып, иңбашларын гына тибрәтеп куйды.

— Аннары нишләмәкче буласың?

— Медучилищега,— диде кыз, сулкылдау аша.

— Аннары кайтасыңмы?

Зиләйлә башын чайкады.

— Нишләмәкче буласың?

— Мединститутка...

— Күрәсеңме, бер елдан чыгып китәсең, аннары кайтмыйсың. Ә әниең ялгыз кала. Ишеткән бар андый кызларны: аналарына кияүгә чыгарга рөхсәт бирмиләр, ә үзләре үсеп җитүгә ташлап китәләр.

Кызның сулкылдавы кимегән кебек булды, егетнең сүзенә колак сала башлады, ахры.

— Ә әниең — дөнья бәясе кеше,— диде Балкыш.— Тормышның терәге — шундыйлар.

— Горурлыгын югалтканнармы? — диде Зиләйлә янә кабынган ачу белән.

— Кеше хәленә керү, кызгану горурлыкны төшерәмени? — Балкыш кызны үзенә якынрак тартты.— Әгәр син әниең төсле булсаң, әгәр без дуслашсак, мин сиңа ышаныр идем... Хыянәт итәрсең дигән уй башыма да килмәс иде...

— Дуслашсак? — Зиләйлә аның кочагыннан шуып чыкты да шаркылдап көлә башлады.— Минем беләнме? Мин беләсеңме нинди булам? Фидая Госмановна кебек! Минем шоферым булачак! Машинам! Кабинетым! Олы дәрәҗәм! Синдәйләр минем авызыма карап торачаклар, беләсең килсә!.. Мәхәббәт!.. Гыйшык!.. Гашыйк булдым дип баш катырып, адәм хуры булып йөрергә юләрме әллә мин?.. Таптың кешесен!

Балкыш аның каршында әйтер сүз таба алмый аптырап басып калды.

## 38

Фазилә ире янына Баллыболынга күчеп килергә соңара язды бугай. Ул йортның өлгергәнен көтмәкче иде. Ләкин кыш үтте, яз җитте, төзелеш бик әкрен барды. Янган кешеләргә йортлар торгыздылар, больницага мунча салдылар, аннары язгы чәчү, чөгендер эшкәртү, печән әзерләү... Давыт хатынына түбән болындагы йортларны да күрсәтеп караган иде, ләкин ул ташландык корылмалар Фазиләгә ошамады. Ул, өйдәш торуның читенлеген аңласа да, Наиләдә фатир торырга риза булды. Карчыкның чәй янында: «Аерым-суырым яши-

ләр димени, хатын кеше ире янында булырга тиеш»,— кебек сөйләнеп утыруы да бик мәгънәле иде. Димәк, сузарга ярамый. Үзе монда килгәч, йорт торгызуны да ашыктырырлар... Шулай итеп Фазилә, яз башында улын алып, Наиләгә күчеп килде. Вакытсызрак та булды шикелле, нәкъ чөгендерне бүләләр генә иде. Фазилә, әле эшкә урнашып өлгермәгән булса да, хезмәткәрләр, бухгалтер, фельдшер, укытучылар белән берләттән, бер гектар чөгендер җире алып, эшкәртеп, иренең абруен да ныгытып өлгерде.

Наилә кинаяләгән куркынычның каян килгәнен дә чамалап алды ул. Куркыныч райбашкарма председателенең урынбасары Нурханова- вадан килә иде. Фазилә аны бер күрүдә яратмады: сары гына, юка гына, тавышы да нечкә генә, өрлектәй ирләрне нәрсәгә өйрәтсен дә ул, ничек сүзен тыңлатсын? Аннан да бигрәк, ни өчен куйганнар аны андый зур урынга? Ник кирәге булган?

Тикмәгә генә түгелдер, дип нәтиҗә ясады Фазилә, кемнедер карактандыр, кемгәдер ярагандыр, үзенең начальник булып карыйсы килгәндер. Нәфес торган саен арта, хәзер инде ирләрнең асылларына күзе төшә торгандыр...

Фазилә тикшереп-сорашып йөрмәде, иренең кесәләрен актармады, артыннан кача-поса барып, күзәтчелек итмәде, ул хәтта Нурхановага текәлеп туры карамады да. Гаиләсен кайгырткан хатынның бер генә коралы бар — күңеле сизгер булырга, башкаларның адымыннан, исәнләшүеннән, хәтта кайчакта исәнләшмәвеннән дә тиешле нәтиҗә чыгара белергә тиеш.

Фазилә чыгарган нәтиҗәләр җитди иде. Әлбәттә, Нурханованың Давытка күзе төшкән, дигән сүз халык теленә кермәгән, аларның даны чыкмаган әле. Әмма дан чыккач, соң була ул. Аннан да бигрәк, тегеләр бер-берсе белән аңлашып, очрашып йөри башласалар һәм бер-берсенә берегеп китсәләр, араларын ерагайту да бик кыен булачак!

Акыллы хатын мондый очракта аларның арасын алдан ук суытып кую чарасын күрә белергә тиеш. Чөгендер басуындагы чүп шикелле: никадәр иртәрәк утасаң, шулкадәр яхшырак. Авыз ачып, шикләнеп-икеләнеп йөрсәң, сарутның ныгып китүе мөмкин, аннары аны йолкып та ала алмыйсың, йолкыйм дисәң, ул чөгендерне актарып чыгара!

Беркемгә әйтмәде, теш арасыннан чыгармады, әмма бу хакта үзе бик ныклап уйлады Фазилә. Сиздерми генә Баллыболынның сатучысыннан, Наиләдән, идарәдәге хатыннардан белеште: Нурханова больница төзим дип җан атып йөри, төзелеш оешмаларына да, күрше колхоз җитәкчеләренә дә тынгы бирми икән. Бигрәк тә баш врачны гел шул эшкә җиккән, диләр! Газимов хасталарны да карый алмый, ди, һаман кирпеч тә такта артыннан чаба, төзүчеләр янында кайнаша икән.

Яңа больница турында халык күп сөйли иде. Давыт салдырган мунчаны да телгә алдылар, көннәрнең берендә Фазилә үзе анда барып кайтырга булды. Авылдан баручылар бар. Давыттан автобус сораганнар иде. Фазилә дә алар белән бергә утырып китте.

Башкалардан аермалы буларак, аның юлы уңды: Билал әлеге дә баягы шул Нурханова белән яңа бина тирәсендә әрле-бирле нәрсәдер сөйләшеп йөри, авыруларны яшь кенә врач терапевт кабул итә, хатын-кыз врачы исә әле һаман да юк икән, андыйлар Гөлфиягә зарларын сөйләп, аның белән киңәшәләр: авылда гына уколлар алып, дәваланып булмасмы, әллә инде районга барып, андагы врачларга күренергәме? Фазилә аңарчы Гөлфия белән таныш түгел иде, ләкин, кирәк булгач, җаен табасың...

Актан киенгән, сирәк сипкелләре түгәрәк йөзен бизәп торган бу хатын янына соңгы кеше булып керде ул, аның салкын карашына да

исе китмәде. Яшереп-нитеп тормады: күрүгә, үзенең кемлеген, чиренең, тән чиреннән бигрәк, йөрәк чире икәнлеген әйтте. Иренең председатель булганына әле бер ел да юк. Артта калган колхоз, усал халык. Менә аңа, Фазиләгә, көчеп килү белән, китмән тотып, чөгендер басуында сарут белән сугышырга туры килде. Анда бит сиңа хатын-кызның вакытсыз чагын-ниен дә, авырлымы-юкмы икәнлеген дә исәпләп тормыйлар, чөгендер вакытын гына саныйлар: бер атнадан бетерергә, унбиш көннән калдырмаска... Баллыбоһлынның бер хатыны, әнә, шул чөгендер аркасында үлеп тә киткән, ди бит. Председательнең үз эше чутсыз, җитмәсә, һаман шушы больница да больница, дип җанын кыйнап торалар. Моның кайчан бер чиге булыр микән? Нишләп соң аны күрше колхозның председателе кайгыртырга тиеш: төзелешнең үз кешеләре беткәнмени?

Гөлфия тәрәзәгә ян белән утырган, ишек төбендә туктап торган Билалга, Нурхановага һәм алар янындагы бер-ике ир-атка карап тора иде. Әнә алар, Билал белән Нурханова, рәхәтләнеп көлешәләр, теге ирләр тыенкы гына елмая. Гөлфиягә бу бик үк ошап җитми иде, күрәсең, аның түгәрәк мөлаем чырае тартышып куйгандай итте. Аны күзәтеп утырган Фазилә моны шундук тотып алды.

Минем ирем әле генә күтәрелә башлады, яшь кеше, аңа бөтен халык сынап карап тора,— диде ул.— Ә Нурханова — ялгыз хатын. Гөнаһы юктыр югын, тик эше бик җайсыз, һаман ир-ат арасында, һаман ир-ат арасында... Юлларда да бергә күп йөрергә туры килә. Андый чакта фәрештә дә ялгышып куяр. Авыл хатыннары арасында төрле сүз йөри. Башкалар белән дә, Билал белән дә икәүдән икәү күргәлиләр икән...

Гөлфия аңа карамады, әмма бит очлары алланып чыкты. Фазилә нәкъ ноктасына эләккәнен аңлады.

—Юк ла, анысы, гөнаһлары булыр, дип уйламыйм,— диде Гөлфия, ашыгып.— Билалга ябышмас анысы. Әле ничек сөйләшеп торалардыр! Бик үчле, ачулы булып калган иде ул безгә заманында.

Анысын да Фазилә белә иде инде. Наилә аңа барысын да — Фидаяның ире үлгәч, Билалны ничек каргаганын да, аннары Билал авыргач, аны ничек кайгыртканын да бик тәфсилләп сөйләгән иде.

— Шулайдыр,— диде ул, ризалашкандай итеп.— Йөрәк ярасы төзәлмидер аның да.— Аннары, бераз тынып торгандай итте дә:

— Йөрәккә яра ясаган кеше онытылмый да инде,— дип өстәде.— Андыйлар үзенчә якын була.

Шулай диде дә урыныннан торды.

— Алайса, хатыннар гел нахакка авыз чайкый торганнардыр инде,— дип куйды.— Кеше күз алдында бит, андыйлар турында сүз күп йөри. Әле мин әллә безнеке янына гына килеп йөри микән, дип борчыла идем. Монда да еш була икән. Эше шул булгач, нишләсен инде, мескен,— дип өстәде ул, җаны тынычлангандай.

Гөлфия аның белән шактый салкын саубуллашты. Алай да, аның йөзеннән, карашыннан каушап киткәне сизелеп тора иде. Фазилә ашыкмый да иде: ул җиргә орлыкны салды, ә теге — Нурханова дигәне үзе үк җирне йомшартып, сугарып торыр, мөгаен — монда килүен тагын да ешайтыр, чөнки төзелештә эш бик кызган икән, бу дәрәҗәгә җиткәч, начальство ут капкандай үзе чапалана һәм бүтәннәрне ашыктыра торган була. Билалның саулыгы һәм күңел тынычлыгы өчен борчылган Гөлфия моңа тыныч кына карый алмас.

Әйдә, бүртсен шик-көнләшү сарутының орлыгы, күзгә күренми генә тамырын туфракка беркетә башласын. Аннары Фазилә килеп, аны шыттыру чарасын күрер.

Ничек кенә булса да, Нурхановану ул үз кулы белән бәреп төшерергә тиеш түгел — моны башка берәүдән эшләтү җаен табарга кирәк иде.

Нурханова, чыннан да, Кармашта тагын да ешрак, көн саен диярлек була башлады. Ул анда һәр иртәне планерка үткәрә, кемнең нәрсә эшләгәнен үзе тикшерә, кемнең нәрсә эшләргә тиешлеген билгели. Мирхуҗин исә, көн дә бер сәбәп табып, планеркаларга бөтенләй йөрми башлады.

Фидая үзен кулга алган иде инде: ул үзен арада берни булмагандай тотарга тиеш. Бу, әлбәттә, җиңел бирелмәячәк иде, әмма Фидая һәрчак күңелендә үр башында күтәрелгән ак бинаны гына тотарга һәм Тавис белән сөйләшкәндә дә шуны гына уйларга мәҗбүр итәргә тырышты.

Ул Искәндәровның секретареннан Мирхуҗинны үз бүлмәсенә чакыртты. Тавис аның бусагасын атлап кергәч, йөзенә майлы елмаю чыгарып, ике кулын артист кебек алга сузып аңа таба атлады. Фидая, бөтен карашы, кыяфәте белән аңа бозлы су койгандай итте. Сузган кулларын күрмәмешкә салышты, каршындагы кәнәфигә рәсми хәрәкәт белән ишарә ясап:

— Рәхим итегез, утырыгыз!— диде.

Мирхуҗин моны ук көтмәгән, ул Фидаяны ирексездән каушап калыр, кызарынып чыгар, күз карашында гына булса да оялу яисә ике арада булган хәлләрдән соң калган якынлык чагылыр, дип уйлаган иде.

— Сез бригаданы төзелештән алгансыз,— диде Фидая, кулындагы зәңгәр ручкасын бөтергәләп.— Ни өчен миңа бу хакта әйтмәдегез?

Шундый итеп сорый, менә-менә шелтә биреп куяр диярсең! Шелтә! Кемгә диген! Теге чакта Тависның кайда да, үзенең кайда булганын бөтенләй онытты микәнни?!

— Ну инде, Фидая җаныкаем, барысын да әйтеп бетереп тә булмый,— диде Тавис кәнәфигә җәелебрәк утырып.— Безгә килгән-киткән бригадалар күп ул, кайсын-берсен син түгел, үзем дә белми калам.

Нурханованың яңаклары кысылды, ирен читләрендә чокырчыклар хасил булды, шул ук вакытта йөзендә усаллык чалымнары көчәйде, күзләре зур ачылып, Тависның маңгаен тишеп, миендәге уйлар агышын күргәндәй итеп карады.

— Сез монда циркта түгел, маймылланмагыз,— диде ул.— Больницада эш бер сәгатькә дә туктап торырга тиеш түгел, әгәр бер бригада аннан киткән икән, аның урынына шундук икенчесе килергә тиеш! Бу сезгә күптән әйтелгән! Әгәр бер-ике көнгә генә тоткарлык булса да, мин сезне райбашкармага куеп, бөтен катушкага чара күрүне тәэмин итәчәкмен.— Нурханова торып басты, башын арткарак ташлап:— Шул,— диде.— Хәзер үк кайтыгыз да чарасын күрегез, бүген үк, ишеттегезме, бүген төштән соң, ниләр эшләнгәнен миңа хәбәр итәрсез. Бетте. Мин сезне бүтән тоткарламыйм.

Мирхуҗинның күзләре шундый зур икәнен әйтсәләр, Фидая ышанмаган булыр иде. Ул урыныннан бик әкрен купты, әкрен турайды, ишеккә таба бик әкрен китте. Ишекне төртеп ача башлагач, тукталып калды, борылмады, башын ничектер астан, җилкә турыннан гына борып:

— Бу минутны искә төшерерсең әле син,— диде.— Исеңә төшербез!

Ул чыгып киткәч, Фидая кулындагы ручканы өстәлдәге кәгазьләргә атып бәрде, үзалдына көлеп, башын чайкап куйды: ахмак, тапты куркытыр кеше! Курка торган күлмәкләр тузып бара монда! Ләкин, әгәр дә ул ныклап торып аяк чала башласа, Фидая үзенең вәгъдәсен җиренә җиткереп үтәү өчен бөтен көчен, хатын-кыз кулыннан килә торган барча чараларны кулланачак иде — моны Мирхуҗин белеп торырга тиеш!

Әмма иртәгесен шул мәгълүм булды: Мирхуҗин төзелешкә бернинди бригада җибәрмәгән, чөнки ике хуҗалыкта ашыгыч рәвештә ындыр табакларын рәтләп бетерәсе бар — урып-җыю башланган борчакка керештеләр дә инде! Кыскасы, ул Искәндәров каршында акланып өлгерде.

Һичек кенә итәгеннән җыеп эшләсә дә, Мирхуҗинның да гаеп-кыегын табарга була иде. Нурханова, финанс бүлеге мөдирен чакырып, безгә жалулар керә, дип шуны белеште.

Бер-ике атна эчендә Фидая үзендә нык үзгәреш сизде. Ул үзенең хатын-кыз икәнлеген гүяки онытты, эш йөртә торган кешеләргә ир кеше итеп карау бетте — алар фәкать иптәшләр, хезмәттәшләр, уртак эш башкаручылар гына булып калды. Әйтерсең лә моңарчы Фидаяның кул-аякларына уралып, хәрәкәтен чикләп торган ефәкләр шуып төште, ул җиңел сулыш алды, тиз, иркен хәрәкәтләнә башлады, йөрәгенә гайрәт иңде. Хәзер инде аңа елмаеп карау урынсыз һәм мәгънәсез, кул сузу исә бөтенләй мөмкин түгел, ә менә кулына кыска саплы, кисеп кенә ала торган каеш камчы бик килешәчәк иде. Нинди ләззәт белән Мирхуҗинның, ә кайчакта хәтта Билалның сыртын каезлар иде ул!

Хәтта Искәндәров белән сөйләшкәндә дә Нурханованың тавышында тимер чыңнары ишетелә торган булып китте.

Искәндәров аңа, күзлеген маңгаена шудырып, гаҗәпләнеп карый, каты-каты әйтеп, бераз тыярга тырышып та куя, әмма Фидая үз сүзендә кала һәм хәтта аны да үз ягына аударырга чара таба иде.

Нурханова тагын да бер тапкыр чакыргач, Мирхуҗин шактый гайрәтләнеп кергән иде. Бу юлы Нурханова өстәле артыннан чыкты, аның каршына ук килеп басты һәм, үрелә төшеп, йөзенә терәлерлек итеп карап:

— Белеп тор,— диде.— Мин үземнекен итү өчен теләсә нәрсәгә барачакмын! Теләсә нәрсәгә!

— Нәрсә куркытасың син мине? Синнән дә куркып торырга мине кем дип белдең?— дип арткарак чигенде Мирхуҗин. Нурханованың күзендә инде боз гына түгел, уеп кына ала торган хәнҗәр үткенлеге һәм, чыннан да, бөтен нәрсәгә әзерлек күрде ул.— Минем куркыр нәрсәм юк! Синнән дә нык пычранган кеше түгел! Пычрансак, икебез бергә!

Монда астыртын мәгънә бар иде, әмма Нурханова керфеген дә какмады. Кире өстәл артына керде дә елмайгандай итте:

— Ә нигә безгә ачылышлы булырга, ә, Тавис?— диде.— Татулыкка ни җитә, шулай бит?

Аның бу елмаюы һәм татулык сүзе шундый килеп чыкты ки, Тависка иң каты тиргәү сүзләреннән ныграк тәэсир итте. Ул кабинеттан чыкканда этәчләнә иде әле: «Һе, кара син аны! Синнән куркып торган ди! Мин синең үзеңне көл итәм!» Ләкин күңел түрендә «сагай» дигән киңәш ята иде. Хатыннарның нишләсен һич белеп булмый, хәзергә аның белән йөзгә-йөз килеп бәрелешү егетлек тә булмас. Ходаем, шул хатын белән дошманлашып, җыелышларда куалашыргамы? Шуны дошман итәргәме? Чын ир кешегә хурлыгы ни тора? Тавис аяк астына төкереп куйды. Әйдә, хәзергә шулай булсын. Аныңча булып торсын. Ләкин килер бер вакыты, Тавис үчен алмый калмас. Шундый итеп алыр, үзләре генә белер, башкалар сизми дә калыр. Елата-елата, ауната-ауната алыр ул үчен. Ә хәзергә нәрсә аның белән вакланырга? Җибәрергә кирәк бригаданы, бугазы тыгылсын!

Нурханова, әйтерсең, бер тимер пружинага әйләнде — бу пружина күпләрне хәрәкәткә китерергә сәләтле иде. Күпләр хәрәкәткә килгәндә, сүзнең дә ишәюе ихтимал, әмма Нурханова үзе моның белән бөтенләй исәпләшми иде.

Искәндәров районда барган эшләр турында һәркөн иртән бирелә

торган сводкага больница төзелешен кертмәгән иде — Нурханова аны кертте: председатель өстәленә һәр иртәне аерым кәгазьгә, бинада күпме идән җәелгән, ничә тәрәзә, ничә ишек куелган, ничә квадрат метр стена штукатурланган, күпме электр чыбыгы сузылган — һәммәсе җентекләп язылган мәгълүмат биреп бара иде. Баштарак председатель, «кхм» дигән булып, аңа күз генә салып, читкә этәрә торган булса да, соңрак кызыксынуы арта барды — күңелне төшерә торган мәгълүматлар арасында бу саннар кәефне күтәреп җибәрә, алар белән хәтта республика җитәкчеләре каршында мактанып була иде.



Эшкә бирелеп кенә яшәү дөрес, күрәсең. Йөрәкне кан куа торган насос дип кенә уйларга, бөтен гайрәтне акылга бирергә.

Ә йөрәк исә моның белән килешергә теләми, сирәк кенә булса да, үзен шундый итеп сиздерә. Фидаяның башын кая куярга белмәгән чаклары була. Ялгыз калганда, кичләрен-төннәрен күңелгә бигрәк авыр уйлар килә.

Шундый сәгатьләрнең берсе аны юл уңаенда чишмә буена китерде.

Көн кичкә авышкан, җилле, каен башлары чайкала иде. Фидая Балкышка машинаны олы юлдан борырга кушты да, калкулыкның теге ягына чыккач, туктап, төште, таллыкка чишмә ягына юнәлде.

Анда барып җиткәндә генә, ниндидер ят аваз ишетеп, борылып карады: ауган каен кәүсәсендә Гыйззәтдин утыра иде, аягы турына гына газета җәелгән, анда ипи телемнәре, ит калҗалары ауный, уртада аракы шешәсе белән стакан тора. Фидая як-ягына каранды һәм каеннар арасында Гыйззәтдиннең «Нива»сын күреп алды: ул, мөгаен, басу ягыннан килеп туктаган иде.

Беренче карашка ук Гыйззәтдиннең кыяфәте сәер күренде. Аңа таба чирәмлектән атлаганда Фидая әле моннан ике көн генә элек Мөнирә белән сөйләшкәнен исенә төшерде.

— Беләгеннән башымны алмыйм,— дип эченнән балкып сөйләгән иде Мөнирә. Ул яшәреп, чибәрләнеп киткән төсле иде.— Мин шундый бәхетле, сөйләп бетерерлек түгел.

Аннары, бәхете өчен оялгандай:

— Минем гөнаһым юк бит,— дип, Фидаяның күзләренә, син нәрсә әйтерсең, дигәндәй карады.— Мин бүтән берәүнең үлемен гомердә дә теләмәдем. Ярымның урамнан үткәнен күреп кенә калсам да дөньям яктырып китә иде, нишлим?

Балалар турында да сөйләшеп алдылар. Зиләйлә укырга кергәнче күрше авылга, Мөнирәнең әнисе янына киткән икән, шунда торып тора.

— Зиләйлә акыллы кыз, тора торып аңлар, үз әтисе бит,— диде Фидая. Аны күбрәк Зареманың язмышы кызыксындыра иде: алар Зиләйлә белән икесе бер йортка сыя алмаячаклар, аннары Зарема бөтенләй чит кан бит инде... Ә бәлки, аны берәр интернатка урнаштыру ягын карарга кирәктер? Фидая моны кайгырта алыр иде. Әмма Мөнирә бу хакта ишетергә дә теләмәде:

— Аны Гыйззәтдин үз исеменә яздырган бит инде,— диде.— Үз кызы кебек, кая чыгарып җибәрсен.

Шулай итеп, алар зур мәшәкать куптармый, тыныч кына бергә оешып, яшәп баралар кебек иде.

Шуннан соң Гыйззәтдинне күргәне юк иде Фидаяның. Мөнирә бәхетле булгач, ул да кайгысыннан айныгандыр, дип уйлаган иде.

Ул Гыйззәтдин янына ук килеп басты, дәшмәде. Тегенең сүз башлавын көтте.

— Хуш киләсең, иптәш урынбасар,— диде Гыйззәтдин. Аның кара чәче буталган, кызыл күлмәк изүе ачык иде.

— Менә, кырыгын үткәрергә ниятләгән идем,— диде ул.— Югыйсә, искә-оска алган кеше юк аны, бер мин генә. Ә йоланы үтәргә

кирәк, ул кешедән киммени! Дәрт бар, дәрман юк, диләр, ялгыз булгач тамактан үтми икән! Бик вакытлы булды әле синең килеп чыгуың. Икәү искә алырбыз мәрхүмәне!

— Өеңдә үткәрсәң дә сүз булмас иде бит,— диде Фидая.— Каршы килерләр идеме әллә?

— Аныс, каршы килмәсләр иде, бәлки.— Гыйззетдин, утырган җиреннән бөгелеп, җайсыз итеп иелде, шешәдән тагын бер стаканга тутырып аракы салды.— Ләкин бит ул инде чын йөрәктән түгел. Минем белән ызгышмас өчен генә эшләнер иде. Ә мәрхүмә андый икейөзлеләнүне белми иде. Күңеле кушканча яшәде, сүзнең турысын сөйләде, теләгәнен эшләде, теләмәсә, аны берәү дә мәҗбүр итә алмады. Нигә мин аны үзе юкта теләмәгән кешесеннән искә алдырыйм, ә? Гадел буламы шул нәрсә, дөрес буламы?

Ул, стаканын күтәреп, сорау белән Фидаяның йөзенә текәлде. Фидая җавапсыз торды.

— Менә син аны ихтирам иткәнсеңдерме, белмим, аралашмадыгыз бит инде әллә ни, әгәр дә син чыннан да искә алырга телисең икән, әйтәсе килгән сүзеңне әйт тә, бер-ике йотып куй шушыны,— дип, Гыйззетдин аңа да стакан сузды. Фидая, аның күлмәк җиңеннән сузылып чыккан, таза, нык беләгенә карап, каушап калды. Каләмгөл янып торган ачык төсле күлмәкләр кигезергә ярата иде шул иренә. Аның ул күлмәкләре озакка чыдар әле, күңелендәге яра сызламый башлагач та, күлмәкләре хатыны истәлеген саклар, мөгаен. Әгәр аларның һәммәсен алыштырырга Мөнирәнең акылы җитмәсә...

— Сүз белән искә алырмын,— диде Фидая.— Ләкин мин эчмим бит.

— Ә син, гомер эчмәгән кеше, бер тапкыр эчеп куй! Аның истәлегенә. Ул моңа лаек — аның өчен гомер кылмаганны кылуга лаек ул. Андый кешенең мәңге туганы юк һәм моннан соң да тумаячак. Син менә районның бар халкын беләсең дияргә була: очратканың бармы шуңа тиңләшерлек берәрсен?

Гыйззетдин кулындагы стакан чайпалып, тамчылар чирәмгә сибелде.

Фидая башын иде:

— Әйе,— диде.— Андый юк шул бүтән.

Гыйззетдин аның сүзен күтәреп алды:

— Менә шул-шул,— диде.— Әле син шулай дисең, ә миңа ничек? Мин ничек яшәргә тиеш шушыннан соң, ә?

Ул, кулындагы стаканны күтәреп, эчеп куйды, йөзен җыерып, җиң очы белән иреннәрен сөртте, тагын бөгелеп, ит калҗасын алды. Ләкин ашамады, бер кулына стакан икенчесенә калҗа тоткан килеш, уйга калды, аннары, кулындагы әйберләрне газетага куйды да, башын тотып:

— Син каян беләсең ди аны!— дип куйды.— Ни беләсез соң сез барыгыз да, анда — житәкчелектә! Сезгә бездән ни кирәк? Кеше иртән эшкә барсын, эшләсен, эшләсен, күбрәк эшләсен, планын арттырып үтәсен... Аннары тыныч кына кайтып китсен дә, әзгә канәгать булып, ашап-эчеп ятсын. Артыгын сорамасын, сезне борчымасын. Менә шул кирәк сезгә. Ә нә, минем Мөнирә кебекләр кирәк...

Аның сүзне ачыктан-ачык Мөнирәгә күчерүе ярап куйды әле, Фидая да сүзгә кушыла алды. Юк, үзен дә, башка җитәкчеләрне дә яклап түгел, Гыйззетдинне Фидаядан да ныграк аңлаган кеше булмагандыр да, чөнки аның да башыннан үткән хәл бит бу. Әмма Фидая үзе хакында түгел, нәкъ менә Мөнирә турында сүз башлады. Аның булуы бер бәхет әле, диде. Менә балаларны аякка бастырасы бар, Гыйззетдиннең дә гомере алда бит әле. Яшәргә кирәк. Башны ташка орып булмый.

Башын иеп утырган Гыйззетдин ул сөйләгәннең кайсын ишетте,

кайсын юк бугай, һәрхәлдә, кыяфәте шундый иде.

— Сез аңлый торган түгел, бөтенләй башкача иде ул. Сезгә нәрсә, эш атлары кирәк. Ә ул — чабыш аты, алай гына да түгел, далаларны иңләп-буйлап, җилдән җитез чаба торган тай иде. Ул башкаларны да азга гына булса да, шундый итә ала иде. Йөгән юк, киртә юк. Кайчакта йөрәк күкрәк куышыннан сикереп чыгардай була, ә син чабасың, яшисең! Андый чакта янып үлсәң дә жәл түгел! Бер минутың бер гомергә торырлык...

Ул бераз тынып торды, тагын башын чайкап куйды.

— Ә Мөнирә нәрсә, ул сезнеңчә,— диде.— Аның яшәве шул эш аты кебек инде. Җылы абзар, су, солы. Барысы да тиешенчә, барысы да кагыйдә белән, ә уты юк, йөрәкне өтеп ала торган ялкыны юк, чын очынып яшәү юк! Их, урынбасар, яле, бер искә ал әле шуны!

Гыйззетдин, үрелеп, тагын стаканга аракы салды.

— Тукта,— диде Фидая, урыныннан торып.— Хәзер.

Үзе машинасы янына китте. Балкыш Гыйззетдинне агач арасыннан күрми, машина кырыена чыгып баскан да, бөтенләй читкә карап тора иде.

— Каенлыкның теге ягында бер «Нива» тора, шуның ачкычын ал әле,— диде Фидая.

Балкыш белән Фидаяның икәүләп килгәнен күргәч, Гыйззетдин урыныннан торып басты.

— Менә бит,— диде.— Минем белән бергә мәрхүмәне искә алырга теше күбәйде. Әйдә, әйдә, туган, кил әле, күтәрик әле бергәләп.

— Ул рульдә,— диде Фидая кырыс кына.— Аңа ярамый.

— Һаман «ярамый» да «ярамый» шул сезнең авызда. Кешегә кешечә яшәргә ярамый! Шулаймы! Алай булмаса, күтәрик әле менә бергә!

Фидая Балкыш машинасыннан бер стакан алып килгән иде, кизләүгә барып, су алып килде, килгәндә, сиздерми генә аягы белән тибеп, Гыйззетдиннең шешәсен аударды. Аңа бик җиткән, артып та киткәне күренеп тора иде.

— Нигә әле без Каләмгөлне исереп, адәм кыяфәтебезне югалтып искә алыйк?— диде.— Ул барда болай йөргәнең күренми иде ич.

Гыйззетдин, аның белән ризалашканын белдереп, башын селекте:

— Чабышларга эчеп бармыйлар,— диде.— Ул җыры-биюе белән исертә белә иде кирәк чакта. Хәзер ул юк. Йөрәк янганын басарга башка чара юк.

Фидая аны булдыра алганчы юатырга тырышты, балалары янына кайтырга үгетләде. Әмма исерү йөрәк януын гына арттыра һәм бу ут-сөрем аша Фидаяның үгетләре аңа барып та җитми иде шикелле.

— Минем тыным кысыла, беләсеңме!— дип сөйләнде ул һаман.— Менә шушыннан, күкрәк турыннан кысып, кыршау кигезеп куйдылар да сулыш алырга борын тишегенә ике салам гына тыгып калдырдылар! Беләсеңме, аңлыйсыңмы!

Ул өстән тагын ике төймәсен ычкындырып, күкрәген ачты. Кызыл күлмәге янында аның тәне пешкәндәй алсуланып күренә иде.

— Без синең машинаңның ачкычын алып китәбез,— диде Фидая.

— Ә ник аласың? Нәрсәгә ул сиңа?

— Сиңа хәзер рульгә утырырга ярамый. Өеңә җәяү генә кайтырсың. Ә машинаңны алып кайтып бирерләр. Без кеше җибәрербез.

«Әйдә, саф һавада утырса, чишмәдән су эчсә, бераз аңына килер әле»,— дип уйлады Фидая.

Алар Балкыш белән икесе борылып китеп баралар иде, инде каенлыктан чыкканнар, Гыйззетдин күздән югалган булырга тиеш иде. Шулчак арттан тавыш ишетелде:

— Әй, урынбасар! Урынбасар!

Борылып карасалар, Гыйззетдин каенлыкның бу ягына чыккан, кулына шешә тотып, болгап тора иде.

— Әй, урынбасар! Син дә шул абзарга япкан эш аты бит, әйеме! Дөрес бит! Шушындый көнне мәрхүмәне искә алып, аның хөрмәтенә минем белән берне тотарга да хакың юк, ә! Куркасың бит, ә? Куркып яшисең бит, дөрес бит!

Аның кулында тулы шешә иде.

— Запаслы кеше,— диде Балкыш, исе китмәгән кыяфәт белән.

Кайтканда, борчак урып яткан комбайн янында туктап тордылар. Әхсән дә, Гаяров та шунда, тузанга баткан комбайнчылар әле өскә менеп, әле машинаның эченә кереп нидер көйлиләр иде. Анда бераз сөйләшеп тордылар, сүз арасында каенлыкта Гыйззетдинне күргәннәрен әйттеләр.

— Уттай эш өсте дә дип тормый кеше,— диде, карашын читкә төбәп Давыт. Нурхнованың кулыннан машина ачкычын алып, пинҗәк кесәсенә салды да:

— Үзе килеп алыр әле, әллә кая китмәс,— диде.

Алар кайсы басуларны ура башлау, үлән чабуны дәвам итү, карчыкларны кычыткан себеркеләре бәйләргә үгетләү турында сөйләшеп алдылар. Янә машинага утырып, юлга чыккач, аларны зур тизлек белән зәңгәр «Нива» куып узып китте, артыннан, кызган һавага уралып:

— Әй, урынбаса-а-ар!— дигән сүз генә эленеп калды, бу — Гыйззетдин иде.

— Ничек кабызган ул машинасын?— дип сорады Фидая Балкыштан.

— Һи, аның ише тимер кортына чутмыни ул! Ярты сәгать азапланса, ул синең тырмаңны да үзйөрешле итә!

«Хәерлегә түгел! Хәерлегә түгел!» Фидаяның күңелен шом басты.

Бу шомлану һаман күңел түрендә торды, кичен эштән кайткач, тагын да көчәеп киткәндәй булды, һәм Фидая Баллыболынга шылтыратты. Болай гына, әллә алалар трубканы, әллә юк, дип кенә шылтыратам дигән иде үз-үзенә. Ләкин алдылар, Гаяров кабинетында булып чыкты. Фидая каушап китте хәтта һәм анда, телефон чыбыгының теге башында да дулкынлану сизелде кебек. Әйе, Гаяров бу юлы аның белән соңгы вакыттагыча кырыс сөйләшмәде. Гыйззетдиннең өенә кайтканын, капка төпләрендә машинасы торганын әйтте. Эчеп йөрүчеләргә без чараны каты күрәбез, диде, аны да тәртипкә чакырырга туры килер, дип тә өстәде. Фидая, дулкынланып, аңа каршы төште. Әйе, тәртипне сакларга кирәк, анысы турында сүз дә юк. Ләкин... кешеләр бит без. Фидая, ачылып китеп, Гыйззетдинне ничек озатканын, бүген Каләмгөлнең кырыгы икәнен әйтте. Ә бәлки, Каләмгөл истәлегенә матур итеп кичә үткәрергә, ул яраткан җырларны җырларга, аның биюләрен биергә кирәк булгандыр. Давыт Нурхнованың сүзен игътибар белән тыңлый, бүлми, ләкин сулышыннанмы, әллә бөтенләй дәшми тыңлавыннанмы, аның ризасызлыгы сизелә башлады. Кичәләр үткәрү вакыты түгел әле, дип җавап бирде ул, уттай эш өсте. Аның белән кем шөгыльләнсен? Күңелле кичәләр үткәрү өчен Каләмгөл үзе кирәк. Аннары, кырыгын үткәрү — гомумән, дини йола, андый сүзне район җитәкчеләре авызыннан ишетү — бөтенләй сәер.

Сүз шуның белән өзелде. Фидаяның йөрәк тибеше телефон аша тегендә ишетелә иде инде әллә? Аның тагынниләрдер әйтәсе килә, һич булмаса, менә шушы минутларны — ике араны тимерчыбык кына булса да тоташтырып торган минутларны озайтасы килә, шул ук вакытта ул, Давыт коры гына саубуллашыр да трубканы куяр, дип тә курка иде. «Дөнья фани, безнең дә гомер үтәр. Әйтәсе сүзләр

эйтелми калыр...» кебек уйлар күңелгә килә, ләкин тел очыннан төшми иде.

Давыт та көтә иде шикелле. Сүзсез тору уңайсыз була башлады. Шулай да Фидаяга трубкадан тынлыкны гына булса да тыңлап тору рәхәт иде. Давытка да рәхәт иде микән? Әллә ул Фидая житәкче булганга гына трубканы алдан куярга яхшысынмый идеме? Фидаяның соңгы вакытта нык калыпка кысылган хисләре ташып чыкты. Ул үзен кулга алырга ашыкты һәм калтыранган тавыш белән хушлашты.

Бу кичне ул үзен бик күптәннән булмаганча бәхетле тойды.

Ләкин күңеле сиземләү юкка булмаган. Наиләнең әйтүе дә хак икән...

Бер атнадан Гыйззетдин, исерек хәлендә машинада барганда, күпердән төшеп, һәлак булды... «Олы мәет үз артыннан тарта шул».— дип сөйләде Наилә. «Чын сихерче булган икән бу Каләмгөл,— диештеләр хатыннар.— Үлгәч тә тынгы бирмәде, Гыйззетдинне Мөнирә белән барыбер яшәтмәде. Үз дигәнен итте, үз янына тегे дөньяга тартып алды».

Аны күмеп, өчесен-җидесен үткәргәннән соң, Фидая медпунктка кереп, Мөнирә белән сөйләште. Мөнирәнең күзләре сүнгән иде, урамда машина тавышы ишетеп, сискәнеп китте, сүзен ярты юлда бүлеп, тынып калды, йөзе агарып чыкты. Тәрәзәдә шул ук челтәрләп чигелгән пәрдәләр, алар ап-ак, шоп-шома иделәр. Мөнирәнең куллары калтырый, кулындагы нәни шешәдә сыекчаның чайпалганы күренә иде.

Ак пәрдәләрне кайтарып урамга караганда, аннан Гыйззетдинне күреп-күзәтеп торганда нинди бәхетле иде ул!

Фидая аны юатырга тырышты, ләкин Мөнирә тыңламый, үз уйларына чумган иде. Күпмедер вакыттан соң, Фидая бөтенләй тынып калгач, ул аңа таман баскан елга төсле күзләре белән туры карады да:

— Нәрсә минем турыда сөйләргә,— диде.— Минем өчен бар да бетте инде. Берни дә булмаячак, берни дә!

Фидая яшәп бетерергә кирәклеге хакында, кызын кеше итү хакында сөйли башлады.

Мөнирә шкафларда нәрсәләрнедер урыннан урынга күчерә — тәртип урнаштыргандай итә, ләкин уйлары еракта икәнлеге күренеп тора иде.

— Балаларны аякка бастырырга кирәк. Анысы да булмаса, ничек яшәр идең?— диде. «Кызымны» димәде, «балаларны» диде. Кемнәрне? Бу бик аңлашылып җитми иде. Фидая тагын сак кына Зарема турында сүз башлады. Мөнирә аңа аңламаган кебек карады.

— Аны өйдән вакытсыз куып чыгарып булмый бит инде,— диде. Туганнары янында... Әтиләреннән ничек калган булсак, шулай яшәрбез,— дип өстәде. Ул моны — көндәшенең өч баласын карап үстерүне үзеннән-үзе аңлашыла торган табигый бурыч дип саный иде бугай.

— Алар да булмаса, ничек яшәргә кирәк?— диде, тагын башын күтәрми генә.— Алар йортта. Иртүк торып, кечкенәсен карап, киендереп, яслегә илтергә кирәк. Анысы бик чәрексез. Ларингит бик начар нәрсә бит, салкын тиде исә, тамагы гыжлый башлый. Төннәр буе янында утырырга кирәк. Кая аны детдомга бирәсең, ни җаның белән? Ә мин нишләрмен? Олырагы таза болай тазасын. Алай да бала бит әле. Быел укырга керәсе. Сакларга кирәк барыбер...

— Ә Зиләйлә?— дип сорады Фидая әкрен тавыш белән.

— Зиләйләгә дә пыр тузынып йөрер урын калмады инде,— моңысын ничектер катырак әйтте кебек. Күрсенде.— Хәзер шул бер эш инде безнең — оешкан ояны туздырмый гына гомер кичәргә...

Фидая аның ак халат астында иңебрәк калган иңнәренә, бу юлы

башлыгы астыннан бөселеп чыккан сары чәчләренә, иелгән йөзенә, очлаебрак киткән борынына карады. Дөнья бәясе кеше бит син, дияргә теләде. Дөнья нәкъ менә синең кебекләргә таянып бара да. Әгәр синдәйләр булмаса, синең йөрәгеңдәге кебек, бер кабынса мәңге сүнми торган һәм кешеләрнең яшәешен яктыртып, җылытып яна торган сөю хисе булмаса, нинди булыр иде бу тормыш һәм нинди булыр идек без?

Фидаяның аны кочып аласы, күккә күтәреп мактый торган сүзләр әйтәсе, бөселеп чыккан чәч толымнарын, назлап, башлыгы астына кертәсе килде. Ләкин ул дәшмәде, урыныннан кузгалмады, чөнки алай күпшы сүзләр сөйләсә һәм аны кочаклый башласа Мөниранә кыен хәлгә куясын, аның күңелен рәнҗетәсен аңлады. Өч ятимне үз канаты астына алу Мөнирә өчен табигый һәм ул моның өчен мактау да, рәхмәт тә көтми иде.

Юлда кайтканда, Фидая бу гаиләгә ничек ярдәм итеп буласын уйлады. Утын китерергә... Пенсияләрен тизрәк бирдерү чарасын күрергә. Мәктәп формалары алып бирергә...

Ләкин, ничек кенә ярдәм итсә дә, Фидая иң авыры Мөниранең үз җилкәсенә төшәчәген яхшы аңлый иде.

## 40

Киңәшмәдән соң берничә җитәкчене алып калдылар: болар урып-җыюны тәмамлап өлгермәгән хуҗалыклардан иде. Искәндәров каршында яткан кәгазьләргә текәлде дә:

— «Җиңүче»гә ярдәмгә ничә комбайн кирәк булыр икән?— дип, Хасият Ясәвиевка текәлде.

Хасият урыныннан торып басты, суга чумарга әзерләнгәндәй, тирән итеп сулыш алды һәм:

— Берәү дә кирәкми,— диде.

— Ничек алай?

— Мин уңышны әрәм-шәрәм итүгә юл куя алмыйм.

Искәндәров, ни рәвешле әрәм итү хакында сөйлисең, дип сорап тормады. Болай да аңлашыла иде: арпа бөтен көченә җитлегеп бетмәгән, ул әле туфрактан да, кояш нурларыннан да көч җыя, атна-ун көннән аның бөртекләре тәмам ныгыр, тыгызланыр, ул чакта уңыш та башкачарак булыр, һәр бөртек хуҗалыкның куәтен ныгытыр, җитәкченең абруен күтәрер...

Искәндәров артыгын бәхәсләшеп тормады, башкаларга күчте:

— Үзәк»кә биш комбайн: икесе «Спартак»тан, икене «Алга»дан, берне «Егерме бишенче партсъезд»дан...

Гаяров куен кесәсеннән блокнот тартып чыгарды да шытыр-шытыр яза башлады. Әмма Искәндәров аның Нурхановага таба карап алганын күреп калды. Керфек кенә сирпешеп алдылар, аңлаштылар.

Әлбәттә, арпаның тәмам җитлеккәнен көтеп, уңышны күбрәк алу Давыт өчен дә начар булмас иде. Ләкин Нурханова белән карашып алган арада ул үзенең чамасын да исәпләп өлгерде: алда бәрәңге, чөгендер аласы бар, кеше аз, эш күп, бөртекләрне алдан урыпжыеп кую хәерле булачак.

Давыт күрше колхозлардан килгән комбайннарны да, үзләренекен дә бөтен көченә эшләтергә тырышты. Нindидер бер ашкыну, үзенең гайрәтен, көчен күрсәтергә омтылу, дәрт белән алган иде аның күңелен. Шушы очыну аны, кичләрен бик соң ятса да, караңгыдан торгызып, басуларга алып китә, шушы дәрт ару-талуны сиздерми иде.

Егерме җиденче сентябрь көнне кич кояш баер алдыннан тезелеп килгән өч комбайн зур басуны урып бетерделәр. Тагын егерме генә гектарлык басу калган иде.

Жир башында Давыт янына җыелган комбайнчылар канәгать елмаялар, алар зур эшне башкарып чыкканнан соң була торган бер җиңеләю, рәхәт ару тоялар иде.

Давыт аларга берәм-берәм карап чыкты, баеп килгән кояш яктысында кызарынып күренгән, тузан баскан йөзләрдәге талчыгу галәмәтләрен күргәч, икеләнеп калды: ә бәлки, иртәнгә кадәр ял бирергәдер? Ул аларны, тын алырга ирек бирмичә диярлек, ничә көн эшләтте бит! Кайтып ашап-эчсеннәр, юынсыннар, йокласыннар рәхәтләнеп. Ә иртән...

Ләкин ул кояш баешын тоташ каплап алган, инде хәзер читчитләре аллана башлаган, тик уртасы гына каралып торган болытларга карады. Иртәгесе көнне белеп булмый...

— Рәхмәт сезгә,— диде Давыт.— Булдырдыгыз. Инде тагын бер тапкыр талпынып алыйк та...

Аның теге калган басуны да бүген үк урып бетерергә кирәклеге турында сүз башлавын ишеткәч, хәтта Родники комбайнчыларының да йөзләре каралып чыкты. Берсенең дә хәзер кире штурвалга менеп утырасы килми, тәннең аруы шул чиккә җиткән, кыймылдарлык та түгел кебек иде.

— Хәзер бераз ял итеп, әйбәтләп ашап алыйк, аннары, тәвәккәлләп, кузгалырбыз.

Давыт аларга ашарга китерткән иде инде. Зур термослардан аш бүләргә әзер торган кызларны күргәч, егетләр икеләнә калдылар.

Давыт алар янында бер табында утырды һәм бөтен ихтыяр көчен җыярга тырышты. Аңа бу кешеләрне күтәрергә, ничек кенә булмасын, эшләтергә кирәк булачак иде.

Ул беренче комбайнның алдыннан үзе барды.

Алар җир башыннан эшкә кузгалганчы, караңгы төште. Басуны әкияти бер күренешкә әйләндереп, сузылып, прожектор утлары ятты. Давыт алдан салмак адым белән башакларны ерып бара, итеге астында табаны белән җирнең йомшаклыгын, аның көчен һәм гайрәтен тоя иде. Бер кузгалып киткәч, гөрләп, алдан сузылган яктылык эзләре буйлап бара башлагач, комбайнчыларга да көч инде, аларны да бер ашкыну биләп алды.

Бу төн — Давытның гомергә хәтерендә калачак һәм ул аны бик еш сагынып искә алачак иде.

Ярты төннән соң алар бу басуны да урып бетерделәр. Һәм, гаҗәп хәл, кичтән председательгә җеннәре каршы торган, бик аздан гына аның сүзен аяк астына салып таптаудан тыелып калган, басу башында моторларны кабызганда эчтән кат-кат сүгенгән комбайнчылар да офыкның бер чите агарып килгән сәгатьтә, эштән кайтканда, күңелләрендә Давытка карата фәкать рәхмәт хисе генә тоялар иде.

Иртәнге якта болытлар куерды һәм башта әзләп кенә, аннары көчәеп яңгыр яварга кереште.

Нәрәт биргәннән соң, Давыт кайтып йоклады.

Кичкә таба исә тыела алмаячагын аңлады. Ул тиешен эшләгән, әйе, соңгы көннәрне бөтен ихтыярын туплап, үзен генә түгел, башка бик күпләрне мөмкин булмаслык дәрәҗәдә тоелган эшкә рухландыра алган иде. Ә менә хәзер коеп, җилләп яңгыр яуганда, ул үзенең ихтыяры сынганын аңлады.

Машина руленә үзе утырды да, район үзәгенә китеп барды. Давытның шушы минутта а н ы күрәсе килә, шул ук вакытта ул очрашудан курка да һәм юл буе, бәлки, ул бүлмәсендә булмас та, ә бәлки, ул бөтенләй Суташта түгелдер, дип уйлады. Чыннан да, нишләп утырсын соң ул кабинетында? Давытны көтепме? Ул, әлбәттә, Кармаштадыр, шунда булырга тиеш тә.

Нурханова, чыннан да, иртәнге якта Кармашта булды. Төзелештә эшне кызулаткан саен, күбрәк кеше тупланган саен ыгы-зыгы да,

житмәүчелек тә арта бара, тизлек тә, эшнең сыйфаты да Фидая күз алдына китергәннән бик ерак тора иде.

Әле ул гынамы, ул гынамы...

Нурханова килгәндә, баш врач иске инфекцион бинаның түбәсен сүттереп, шуны караштырып йөри иде. Хуҗалыкчан үзе, идән такталарына, борысларга карады да: «Боларын әйбәтләп алып, тезеп куегыз, агачы нык әле, берәр нәрсәгә ярар».— диде.

Ул иске агач-могачны кайгырта! Йөз илле еллык бина тирәсендә болганып йөри! Ә монда өр-яңа зур төзелешнең рәте юк! Соңгы төннәрне рәтләп йоклый да алмаганга, Фидаяның нервлары соң чиккә җитеп йончыган, ул инде эчтән калтырый башлаган иде.

Тыелырга тырышты Фидая, әмма ачуы, аның ихтыярына буйсынмыйча, күзләреннән, әкрен әйтелгән сүзләреннән ташып чыгып, Билалның да канын кыздыра башлады.

Билал аны сүзсез тыңлады. Аннары, теш арасыннан гына:

— Сез, Фидая Госмановна, үзегез генә бу эш өчен янып йөри, дип уйлыйсызмы әллә?— диде.— Сез минем кемлегемне онытТыгызмы әллә? Мин — врач, беләсегез килсә! Сез монда врачларның кадерен генә белмисез! Килгән кешеләр кача тора, врачы булсын, медсестрасы булсын! Ничә тапкыр әйттем мин сезгә, әллә нинди биналар корсагыз да, больница больница булмый ул, табиплары булмаса, дип! Сез, ичмасам, шуны кайгыртыр идегез! Ә сез үзегезнең кулыгыздан килмәгән эшкә — төзү эшенә тотынасыз, җитмәсә, мине дә шуңа мәҗбүр итәсез! Һәркем үз эшен яхшы эшләргә тиеш! Әллә бу бездән генә таләп ителәме? Әллә моны шул ук төзүчеләрдән таләп итеп булмыймы? Әллә сезнең Мирхуҗинга тешегез үтмиме?

Мирхуҗин фамилиясен телгә алуга, Фидаяның күз алларында утлы шарлар биеп үткәндәй булды. Аның бөтен җәбере, тапталган йөрәгенең ярсуы ташып чыкты, ул алга таба атлады да, кулын күтәреп, Билалның яңагына сугып җибәрде. Тагын! Тагын! Әгәр шунда кулында камчы булса, камчы булса...

Билал, учы белән яңагын тотты да, чиксез гаҗәпләнеп, таң калып, аның йөзенә текәлде.

Шул минутта арттан тавыш ишетелде:

— Бу ни бу? Билал! Билал! Нишләдең син? Ни булды?

Анда Гөлфия басып тора иде.

Фидая, кинәт борылды да, ашыгып машинасына утырды, Балкышка:

— Кайтабыз,— диде.— Тизрәк бул.

«Нишләдем мин? Нишләдем?..» Фидаяның гомерендә берәүгә дә сукканы юк, һәм ул киноларда хатын-кызның ирләр яңагына сукканын күрсә дә, мондый хәлне китаптан укыса да, җирәнү хисе генә кичерә иде. Кешегә ору-сугу, гомумән, вәхшилек; ә инде хатын-кызның ир-атка кул күтәрүе — анысы әшәкелекнең аргы ягына чыгу иде.

Ләкин нишләп соң әле ул Мирхуҗин турында шундый сүз әйтте? Белә микәнни? Барысын да белә микәнни?

Әгәр хәзер Тавис дигән адәм Фидаяның кул астына туры килсә... Хәер, ул үзенә суктырып тормаячак иде, билгеле.

Фидая, кабинетына кайтып керүгә, телефонга ябышты.

— Халтурага корылган бер генә эш тә кабул ителмәячәк,— диде ул.— Кара аны, телең белән яларлык итәрбез! Телең белән!

Мирхуҗин телефоннан аңа хихылдап җавап бирде:

— Кабул итәрсез, Фидая, хи-хи, Госмановна!.. Кабул итми кая барырсыз! Әле шулайрак эшләп очына чыксак, күтәреп йөрердәй булырсыз! Безнең шартларда ел эчендә шундый больница күтәреп куюны уен эш дип белдегезме әллә? Аны эшләгән кеше генә белә, күрсәтеп, өйрәтеп йөрүчеләр түгел!

Димәк, бөтен эшне Мирхуҗин башкарган, ә Фидая аяк арасында буталып кына йөргән! Фидая сүз таба алмый торды.

— Кара аны,— диде, тотлыгып, ни белән янарга белмичә.— бөтенесе өчен җавап бирергә кирәк булачак!

— Син! Син миңа яныйсыңмы? Синме?— Мирхуҗин тагын хихылдады.— Беләбез без синең нәрсәгә эчең пошканын! Беләбез! Шушылай чәпчеп йөрермен дә, халык теленә больница төзегән изге кеше булып керәп калырмын, дип өметләнәсеңдер. Ә бәлки, анда капка баганасына, бу бина Нурханова тырышлыгы белән төзелде, дигән сүзләр язган такта кагарлар, дип өметләнәсеңдер! Ялгышасың, Фидая Госмановна! Шартлаганчы тырышсаң да, рәтләп рәхмәт ишетмәячәксең! Заманы ул түгел! Маклашкасын бирерләр анысы. Тик без дә авыз ачып тормабыз! Бүлешергә туры килер маклашкаларны!

Давыт бүлмәгә сүзне бүлеп диярлек килеп керде. Аны күреп, Фидая трубканы куярга ашыкты.

Давыт ишек төбендә туктап калды. Алар икесе капма-каршы ике халәттә иделәр: Давыт — зур эшне тәгәлләгәннән соң булган рәхәт талчыгудан арынып җитмәгән, шул ук вакытта бу очрашудан бик дулкынланган хәлдә; Фидая исә, ярсуыннан арына алмыйча, бераз вакыт бер-берсенә карап тордылар. Шул вакытта аланлыкта очрашкандагы кебек үк, күз карашларында бөтен җаннары чагылган кебек булды, алар икесе дә бу очрашуны бик күптәннән көткәннәр, шул ук вакытта минуты килеп җиткәндә моңа әзер түгеллекләрен дә аңлыйлар иде.

Бүген кичергәннәрне сызып үткәндәй, Фидая күңелендә бер тавыш яңарды: «Менә ул килер... Каршыңа тезләнер... Синең һәр күзәнәгең аңа омтылыр, кулларың аңа сузылыр... Син уйлый алмас хәлгә килерсең, аңа орынуны гына да бәхетнең иң зурысы дип санарсың...»

Әгәр шунда арада өстәл булмаса, Фидая тыелып кала алмас иде! ул аңа омтылыр, гәүдәсе белән аңа сарылыр, башын аның күкрәгенә салыр иде. Гәүдәсе өстәл аша аңа таба тартылды, ләкин шундук тартыну, гаеп хисе Фидаяның сынын куырды. Ул — керләнгән, тапланган кеше, аның Давытка орынырга хакы юк, хокукы юк...

Ә Давыт моны уйламый, ул фәкать Фидаяны күргәнгә сөенә, аңа башка берни дә кирәкми.

Ул якын ук килмәде, Фидаяның нәрсәдәндер тартынганын тойды. Тәрәзә янына барып басты да, куллары белән тәрәзә төбенә таянып, кичә һәм бүген төнлә кичергәннәрен сөйләргә кереште. Комбайннарның ут белән төнне ярып барганын, үзенең алар алдыннан атлаганын, барысының да иртәнге якка ничек үзгәргәнен... Көлә-көлә, бәхетле бер кинәнү белән сөйләде ул боларны. Фидая аның сүзләрен аңлап та бетерми, ләкин тавышын, бәхетле көлүен ишетә, бөтен барлыгы белән сеңдерә, бу тавыш, бу көлү, аның тәненә саркып, җанына үтеп керә, җәрәхәтле күңелен дәвалый, бүген булган ямьсез чатаклыкларны юып ала, сафландыра иде. Күпме сөйләде ул, аннары тагын күпме вакыт дәшми торды,— белмәделәр. Тик бу вакытны сузасы, сузасы, сузасы гына килә иде.

Ниһаять, Давыт сәгатенә карап алды, Фидая айнып киткәндәй булды.

— Ә бүген мин монда түгел, фермада булырга тиеш идем,— диде Давыт.

Әйе шул, председатель үзе йөрмәсә, кем анда малларны тиешенчә кайгыртып бетерсен? Машиналарны җибәртергә, өстәп азык ташытырга... Ләкин Давыт үзен гаепле санамый, ул фәкать үзенең шушындый тилелегенә исе китеп, башын чайкап кына куйды, аның бу хәрәкәте шундый самими, шундый сөйкемле чыкты, Фидаяның күзләренә яшь килде.

...Иртәгесен сводкада Фидая беренче итеп «Үзәк»не күреп алды —

бер көн эчендә савым 400 килограммга кимегән иде. Бер очрашып сөйләшүнең бәясе...

Ул көзне яңгыр һич туктамый койды да койды. «Җиңүче» үзенең арпа кырларына комбайн кертә алмады, тәгәрмәчләр сазга бата иде. Бөтен авыл халкын җыеп, үгетләп, җыйганның ун процентын үзләренә вәгъдә итеп, эшкә кушарга туры килде. Ясәвиев үзе дә, парторг Фәләхова да, озын кунычлы итекләр киеп, алдан чалгы болган йөрделәр. «Мине тыңламады бит, картлач,— диде, бер күргәндә, Рәсимә Фидаяга.— Үз акылы белән йөрмәкче булды. Әгәр шунда Искәндәров комбайннарны бүлешкәндә мин булсам, шушы көнгә кала идекмени без! Әллә инде, аны төшереп, председатель булып кына менеп утырыйм микән?— дип көлде ул. Аннары башын чайкады: — Әй шулай да, үзең күләгәдә торып, дилбегәне нык тоту рәхәтрәк. Кодрәтеңне ныграк сизәсең. Син дә, алга чыгып, начальник булып хаталандың бугай, Фидая, әйе бит? «Ярый ла, ул дилбегәне кулыңда тота алсаң... Әгәр мин бу урындыкта утырмаган булсам, төзелеш дилбегәсен кем миңа тоттырыр иде соң?» — «Анысы шулай да бит, бигрәк игелексез эш инде! Менә мине хәзер председательнең май сарган җилкәсе аша күрмиләр дә, ә бит соңыннан, моны Рәсимә генә булдырды дип, авыл халкы искә алачак әле. Ышанам, шулай булачак, билләһи! Ә сиңа рәхмәт әйтерләр микән? Егене эшләп җиткермәгән дә монысын булдырмаган, диюче булыр, мөгаен, ә эшләгән кадәресенә рәхмәтне башкалар ишетер. Сиңа авырлыгы гына калыр, әзер тор!» — дип, шаркылдап көлде Рәсимә.

Ахмак, әллә инде ул да Фидаяны дан өчен тырыша дип белә! Ул да аңламый иде, ул да! Башкалардан нәрсә көтәсең?..

## 41

Рәсимәнең көлеп әйткән сүзе рас килде. Фидаяның башына тукмак килеп тә төште. Әлбәттә, Фидая офыкта болытлар куерган кебегрәк хәлне сизә, ниндидер күңелсезлекләр буласын да исәпкә ала, шуны уйлаганга, эшне дә ашыктыра иде, әмма алга килеп басканы бөтенләй көтелмәгәнчә һәм бик авыр тоелды.

Иртәнге якта Фидаяны Искәндәров чакырып алды. Керән итеп күрсендә, күзләрен күзлек астына яшергән хәлдә аска карап:

— Синең өстән жалу бар анда,— диде. Бераз тынып торганнан соң:— Бер генә түгел, икәү хәтта,— дип өстәде.

Ул тагын тынып калды, алдындагы газеталарны, сводкаларны тәртипкә салгандай кыланды. Фидаяның нидер сораганын көтте, әмма тегесе дәшмәде.

— Бер генә булса, ничек тә саклап калыр идек без сине,— диде Искәндәров.— Анысы финанс тәртипләрен бозуга бәйле, мин үз өстемә дә алган булыр идем. Барысын булмаса да, кайберләрен...

Фидая тагын дәшмәде. Җавап биргәндә, ул авырлыкны Искәндәровка салмас иде, билгеле. Нишләп алай итсен? Колхозлардан тиешсез акча түләткән документларга Нурханова кулы куелган лабаса, райбашкарма председателе белән киңәшеп тә торылмаган! Ләкин бу хакта сөйләшүнең мәгънәсе дә юк, чөнки жалуның икенчесе катырак, аяктан егарлык булырга тиеш. Һәм ул шулай булып чыкты да.

— Монда менә хатын-кыз мәсьәләсендә чатаклык килеп чыккан бит әле. Намусыңа кагылалар. Сиңа түзеп торырга кирәкмидер, акланыргадыр. Йөз аклыгың булырга тиеш.

Фидая көлеп җибәрде:

— Их, Җәгъфәр Латыйпович! Гайбәткә каршы көрәшеп буламыни? Аждаһаның җиде башын кисеп була, гайбәтнең башларын кисеп бетерү мөмкин түгел. Чөнки күпме тел булса, аның башы

шулхәтле, кискән саен үрчи генә бара. Хәтта судка биреп, мин гөнаһсыз, дип исбат итсәң дә, исемең мир телендә калачак, утсыз төтен булмый, диячәкләр, шулай бит?

Искәндәров аңа күтәрелеп карады:

— Ә нишләп син кем язганын сорамыйсың?

— Чамалыйм чөнки.

Искәндәров тагын башын иде.

— Алай да, минем башыма һич килмәс иде,— диде.— Билал белән син... Гаҗәп. Гөлфиясе дә тикшереп кенә торган, димәк.

— Билал белән Гөлфиянең монда ни катышы бар?— дип сорады Фидая.

Искәндәров тагын аңа гаҗәпләнеп карады.

— Кем язганын беләм, дисең бит. Гөлфия язган синең өстән. Бик каты итеп.

Гөлфия? Ә нигә? Мирхуҗинда ни катнашы бар аның?

— Миңа да бик гаҗәп тоелды инде бу,— диде Искәндәров, аның аптыраганын күреп.— Билал белән сезнең арагызда шундый хәл булыр дип минем башыма да килмәгән иде. Әгәр белгән булсам, без сине Кармашка йөртер идекмени? Төзелешне бүтән кешегә тапшырган булыр идек!

Искәндәров, үкенүен белдереп, йомры зур башын чайкап куйды.

— Сез бик дөрес эшләдегез,— диде шунда Фидая, телгә килеп.— Бик дөрес. Беләсезме, ни генә булса да, мин сезгә мәңге рәхмәт укып яшәячәкмен. Мәңге-мәңге!

— Ә миңа соң нәрсә өчен? Бәлки, безгә көрәшергә кирәктер?

— Миңа ышанганыгыз өчен. Миңа шундый эш тапшырганыгыз өчен. Ә хәзер шәүләләр белән көрәшүнең мәгънәсе юк. Төзелешне беркем дә туктата алмаячак, шулай бит?

— Юк инде,— диде, башын чайкап, Искәндәров.— Ул хәзер республика җитәкчеләренең теленә керде, быел төгәлләнәчәк төзелешләр исемлегендә йөри, беренче январьдан анда авырулар кереп ятачак.

Соңгысын ул горурланып әйтте.

— Менә бит. Рәхмәт сезгә.

Фидая, урыныннан торды да, аның янына ук барып, баш түбәсендә сирәгәйгән, йомшак чәченнән үпте.

— Ә мин китәм,— диде Фидая.— Хәзер гариза язып кертәм дә, бүтән сезгә күренеп тә йөрмәм.

— Кая китәсең?

— Хәзергә авылга, үземнең әти-әни янына, аннары күз күрер.

— Ронодан мәктәпкә направление бирикме?

— Бирегез. Бәлки, анда пионервожатый урыны буштыр әле?

Аерылышканда икесенә дә бик ямансу булып китте.

— Соңгы елларда сиңа бигрәк күп килде инде,— диде Искәндәров.— Бәлки, бөтен гомереңә тиешле кыены шушы елларда булгандыр. Ә бит син бәхетле булырга тиеш кеше. Синең чибәрлегең, акылың, уңганлыгың белән, синең сөйкемлелегең белән!

— Артыграк мактап җибәрә күрмәгез тагын, Җәгъфәр Латыйпович. Борынны артык чөяр бу, дип курыкмыйсызмы?

— Борыныңны күтәрергә ирек бирмәсләр, тиз сугарлар,— диде Искәндәров. Ишек төбенә килеп, Фидая белән хушлашканда, ул: — Синдәй кешеләр дөнья байлыгы бит, югыйсә,— диде.— Бик нишләптер урыныңда түгел кебек син. Әллә вакыты ул түгел, артык син бу дөньяда! Артык...

Кичкә таба Фидая ишегалдына — быел матур гына булып үсеп киткән карлыган куакларын, кураларны карап чыкты, бакчада җетеләп балкып утырган бәрхет гөлләрне сыйпады. Иркәнең:

— Әни, нигә чәчәкләрне өзәсең?— дигәне исенә төште.

— Озакламый кырау сугачак аларны, кызым,— ди Фидая.

Әйбер-караның иң кирәкләрен генә җыеп алды — калганын бер җитешкәч килеп алырга булыр.

Аннары, кичке уңайда Балкышны чакырып китерде дә, берничә төенне «Газик»ның артындагы аралыкка һәм утыргычларга салды. Иркәне кочаклап, алгы утыргычка утырды.

— Соңгы тапкыр илтеп куй әле мине,— диде.

Зират турыннан узганда, машинаны туктатты, капканы ачып, эчкә узды.

Зират өсте яшел чирәм, күзне әле сизмәгәндәй, җәй уртасындагы кебек күкрәп утыра, меңьяфракларның чәчкәләре кичке әңгер-меңгердә агарып тора. Фидая, ташлар куелган озынча калкулыклар һәм сирәк чардуганнар арасындагы бормалы сукмактан барып, зәңгәр чардуган янына килде, салкын тимергә кулы белән ябышты. Аның монда җәйдән бирле килгәне юк иде, ул арада чардуган уртасындагы яшь нарат нык кына күтәрелеп өлгергән, очындагы тармакта сыек яшел энәләре дәртле тырпаеп тора. Фидая, кулын сузып, аның салкын, тыгыз, чәнечкеле ботакларын сыйпады.

— Менә мин кайттым,— дип пышылдады.— Синең яныңа кайттым.

Ул сыгылып җиргә тезләнде, салкын, дымлы рәшәткәгә битен терәде. Нәрсәдер әйтергә, уй һәм хис җитмәслек караңгы, аңлашылмас мәңгелектәге изге, саф җанга бар кылганнарың, ирешкәннәрең һәм гөнаһларың турында сөйләп, ярлыкавын үтенер өчен моңлы җыр кебек сүзләр табарга кирәк иде...

## 42

Давыт, йокламаган да шикелле, кинәт күзен ачты. Гүяки аның кабыргасына кемдер сискәндереп төрткән иде. Шундук миен ярып бер уй узды: «Мин аны башка күрә алмаячакмын». Йокыдан айныгач, ул үзен тынычландырырга тырышты, әмма сагыш көчәя генә бара иде: «Без башка күрешмәячәкбез».

Гадәттәгедән иртә икән әле, биш тә тулмаган. Алдагы көн бик озын, күп эшләр майтарып булыр шикелле, алда торган мәшәкатьләрне колачлап бетермәгән, гадәттә, тыныч вакыт. Әмма Давытның җан тынычлыгы качкан иде инде.

Ул кабаланып торды, идарәгә гадәттәгедән иртәрәк килде, сабырсызланганга, аңа башкалар соңарган кебек тоелды. Нәрсәтне ашыгып бирде, аннары, бүлмәсендә ялгызы калгач, башын иеп, уйга калды һәм уйларының һаман бер тирәдә әйләнгәнен аңлады: Нурхановага барырга нинди сәбәп табарга?

Әлбәттә, сәбәпләр күп, ләкин нәкъ менә шушылай сабырсызланып эзли башласаң, аларның һәммәсе кинәт юкка чыккандай була. Ул, өенә кайтып, тамак ялгады — ни капканын сизмәде, аннары, тугызларга барып җитәргә дип чамалап, машинасына утырды да район үзәгенә китте.

Ул килгәндә, райбашкармада барлык ишекләр ачык, һәммәсе эшкә килгәннәр, тик Нурхpraнованың гына бүлмәсе бикле, ишегендә ачкыч бәйләме дә юк иде.

Кармашка юлны ничек үткәнен сизмәде, йөрәк ашкына, ярсый иде. Әгәр шунда бүлмәсендә Нурхановaның ялгызын очраткан булса, ул бу юлы тыела алмас, аны кочагына алыр, аның каршына тезләнер, кулларын үбеп, битенә маңгаен терәр иде.

Больницаның үр башындагы ак бинасы ерактан ук күренеп тора, күтәрелеп килгән көзге җылы кояшка каршы тәрәзәләре белән балкый. Ул берәүнең ак хыялы, матур омтылышлары булып күтәрелгән сыман.

Давыт акшарга буялган таш баскычтан менеп, авыр ишекне ачты. Эчтә буяу, агач исе катнашып, һәр яңа төзелештә була торган, тәмле-татлы ис аңкый, яңалык, иминлек һәм бөтенлек вәгъдә иткән халәт хөкем сөрә иде.

Шунда, ишекләрнең берсе ачылып, аннан ак халат кигән бер төркем ир-ат килеп чыкты, алар коридорның аргы башына таба юнәлделәр. Төркем алдында кысан халатыннан күкрәге-корсагы чыгып торган, яланбашлы Мирхуҗин бара иде. Ул Давытны әллә күрмәде, әллә юлдашлары белән мавыкканга, игътибар бирә алмады. Ул алдан нык-нык басып атлый, артыннан килгән кешеләр ишетсен өчен, кычкырып-кычкырып сөйли иде:

— Бу инде безнең район тарихында булмаган казаныш. Башка урыннарда да мондый зур төзелешне бер ел эчендә башкарып чыгарганнарын ишеткәнебез юк. Бөтен көчне салырга туры килде, бөтен резервларны эшкә җиктек. Республика җитәкчеләренә дә рәхмәт, алар да һаман ярдәмләшеп тордылар. Әлбәттә, вак-төяк кимчелекләр булыр, аның бит барысы да тиешенчә җиренә җиткереп башкара алмый. Йә осталыгы җитми, йә теләге булмый, йә юк-бар белән мавыгып, төп эшне онытып җибәрә. Без андыйларны төзәтергә тырыштык. Монда коллектив акыл бик зур роль уйнады.

Төркем артыннанрак Билал бара иде. Давыт аңа иярде, башын сузып, Мирхуҗинны тыңлады. Ә Нурханова кая соң? Ул моны Газимовтан сорарга кыенсынды.

— Кемнәр бу?— дип сорады.

— Казаннан килгән комиссия?— диде Билал, аяк очларына басып, пышылдап.— Жалу тикшерәләр.

— Нинди жалу?

— Нурханова өстеннән, финанс кагыйдәләрен боза, дип зур жалу язганнар.

— Ә үзе кая соң?— дип сораганын сизми дә калды Давыт.

— Кем?

— Нурханова.

Билал аңа гаҗәпләнеп карады:

— Нурханова юк бит инде.

— Ничек юк?

— Син белмисеңмени? Эшеннән китте бит ул. Суташтан ук киткән, диләр.

Давытның зиһене бу сүзләрне кабул иткәнче, төркем коридорның бер турында туктап калды. Анда акшарлы стенага бер картина сөяп куелган иде. Картинада — роза чәчәкләре бәйләме, кояш чыгышына караган тәрәзә төбенә куелган чәчәкләрнең бәбәкләре таң нуры көчәйгән саен ныграк ачыла, хуш исен көчлерәк сибә иде шикелле.

— Ә бу нәрсә?— диде ят ирләрнең берсе.

Мирхуҗин Давытка яны белән баскан иде, аның йөзендәге мыскыллы елмаю аермачык күренде.

— Менә шул инде, хатын-кыз шөгыле,— диде Мирхуҗин, мәсхәрә белән.— Без төзелеш белән шөгыльләнгәндә, ул менә шушыларны кайгыртты. Больницаны бизи, янәсе, авыруларны дәвалауга ярдәм итә. Картинкәләр белән. Хатын-кызны баш итсәң, шул көнгә калырыңны көт тә тор!

Давыт алга ыргылды — сөйләүченең авызын җимерергә, мәсхәрәле сүзләрне туктатырга! Ләкин нәрсәдер аның биленә уралды, атлаган аягын богаулады.

— Син нәрсә, ни булды?— дип, читкә сөйрәде аны Билал.— Сөйләсен, әйдә! Ә Фидая дан артыннан кумый иде бит. Син тирәягыңа гына кара: бина торамы — тора! Бөтен тирә-якка балкып тора. Аның өчен бүләкнең иң зурысы — менә шул. Намус каршында йөзе ак, димәк, кеше алдында да йөзе ак.

Ә төркем һаман әле рәсем каршында басып тора, ят ирләрнең берсе:

— Ну что же, хатын-кызга артык таләпчән килергә ярамый,— дип акыл өйрәтә иде.— Аның йомшак якларын кичерергә тиешбез. Ә бу картинага килгәндә, матурлык та кирәк бит кешеләргә!

Төркем коридор буйлап китте. Билал аңа иярде. Давыт чыгу ягына борылды.

Ишектән аның каршына ак берет кигән, муенына кызыл шарф ураган рәссам хатын килеп керде. Уң кулында зур гына сумка, сулында — култык астында — ак кәгазьгә төрелгән яссы әйбер — кысага куелган картина иде, ахрысы.

Исәнләштеләр. Давыт аңа өмет белән карады: бу хатын юкка гына килмәгәндер, Фидаяның чакыруы белән килгәндер, димәк, алар очрашырга тиеш!

Әмма рәссам хатын аңа моңлы, тирән күзләрен тутырып карады да:

— Нурханова киткән диләр, дөресме?— дип сорады.— Ә мин аңа сюрприз ясамакчы идем. Алдан әйтми генә килеп төшкән идем...

Шулай диде дә өметне өзде. Давытка бик күңелсез булып китте.

— Искиткеч,— диде Рамилә, як-ягына каранып.— Узган көзне монда нигез генә иде. Фидая Госмановна мине, монда кабинет, монда палата була, ди-ди, шушында йөртеп ардырып бетергән иде. Стеналарны рәсемнәр белән бизәргә үгетләде. Юк стеналарны. Ышанмаган идем. Ә хәзер һәммәсе ул дигәнчә булган...

Давыт аның култык астындагы төргәккә ымлады.

— Монда эләргә китердегезме?

— Юк. Фидая Госмановнага бүләккә алып килгән идем. Аның портретын ясадым. Хәтердән...

— Күрсәтегез әле!— дигәнен сизми дә калды Давыт.

Рамилә сумкасын идәнгә куеп, төргәкне чиште. Гади генә ак кысадан, Давытның күзләренә Фидая тутырып карады. Рәссам аны алтынсу нурлар эчендә тасвирлаган иде. Ул нурлар каяндыр аның баш очыннан төшеп, бөдрәләрен, зәңгәр күлмәк җиңеннән чыккан нечкә беләген, нәфис бармакларын яктырта, ә йөзенә күләгә төшкән. Моңлы, серле, уйчан йөздә, күзләрнең төбендә ниндидер шом, ялвару, ярдәм сорау ярылып ята.

Таныш караш бу. Фидаяның болай караганын Давыт үзе генә, фәкать ике генә тапкыр күрдем дип уйлаган иде. Наратлык буендагы чирәмдә һәм уракны тәгалләгәннән соң Фидаяның бүлмәсендә очрашкач... Ә менә Рамилә дә аны күреп алган икән...

— Күпме тора?— дип сорады Давыт карлыккан тавыш белән.

— Нәрсә?..— диде аптырап Рамилә.

— Портретны дим... сатыгыз миңа.

Рамилә иренен турсайтты.

— Сез нәрсә... Сату өчен түгел. Аның үзенә генә... Сез әллә бөтен нәрсә сатыла дип уйлыйсызмы?

Давыт аңына килеп гафу үтенде. Рамилә үпкә саклый белми икән, тиз кайтты.

— Ул булмагач, мин монда калмыйм инде,— диде.— Сез бу портретны аңа тапшыра алмассызмы икән?

Ул портретны кадерләп кире кәгазьгә ураганда, Фидаяны үзләренә кунакка чакырырга кайтканын әйтте.

— Беләсезме,— диде,— Фидая Госмановна минем язмышымда бик зур роль уйнады. Акылга утыртты ул мине. Без ирем белән аерылышкан идек инде. Монда килгәч, Фидая Госмановна белән озак-озак сөйләшкәч, мин үз тормышыма бөтенләй башкача карый башладым. Кешеләрнең дә, хисләрнең дә кадере артты минем өчен. Күрсәгез, әйтегез аңа: без ирем белән яңадан кавыштык, бергә яшибез.

Килсен, күреп китсен!

...Кармаштан кире Баллыболынга кайтканда Давыт, каенлык турына җиткәч, машинасын туктатты. Каеннар сары яфракларын җиргә түшәгәннәр, сирәк-мирәк кенә шәрә нечкә тармакларда сары, көрән яфраклар тирбәлә, алар ятим, кызганыч, ачы җилләр каршында чарасыз булып тоелалар. Давыт әчкәрәк, таллыктагы кизләү янына үтте. Анда, куе үлән-керфекләр арасында, рәшә сарган күккә төбәлгән яшьле күз кебек мөлдерәп ята иде ул. Давыт, кушучлап салкын су алды да, битен шуңа батырды. Әллә җирнең күз яше белән юынды ул, әллә үзенең күз яше белән йөрәген юды...

Озакламый кыш килер, җир туңар, бу кизләүне дә боз каплар. Алда бураннар, салкыннар, алда сагыш һәм өметсезлек көтә иде.

Аяк табаны аша ул җирнең суына барганын, анда тамырлар хәрәкәтенең тына барганын тоя иде кебек. Шул ук вакытта тәнгә әкренләп иңә барган бу суыклык күз яшьләрен дә киптерә бара иде. Әйе, алда салынкы болытлары, җил-давыллары, кар-бозлары белән кыш тора. Ләкин суынган җир инде үзенчә язга әзерләнә иде. Ул салкыннарның вакытлыча гына икәнен, алда тагын яз киләчәген, җир куенында тамырларның могҗизалы хәрәкәте башланачагын һәм гөлләрнең, өскә үрелеп, кояшка керфекләрен ачасын белә иде. Әйе, гөлләр чәчәк атар, тик бәбәгенә кояш нурын җыя торган алтынсу чәчәк Давыт өчен бүтән балкымас. Безнең өчен бер мәртәбә күкрәп чәчәк аткан гөлләр, бер коелгач, яңадан шытып чыкмыйлар...

Ләкин яшәргә кирәк иде. Кышны имин уздырырга, язны каршыларга кирәк иде. Давыт, чишмә янынннан кузгалып, каеннар арасыннан олы юлга таба атлады. Ни генә булмасын, язлар килер, ташулар агар, аның күңеленә шифа биреп, аяз күктән кояш нур сибәр. Чөнки ул белә хәзер: безнең баш очыннан бер агылып узган болытлар беркайчан да кире әйләнеп кайтмыйлар...

*1984—1987*

# ШИГЪРИЯТ

## Ренат Харис

### Көмеш нур

Идел өстенә көмеш нур
сузылган тулган айдан;
көмеш дулкыннар кузгатып,
җил чыкты әллә кайдан.
Көмеш нурларга дулкыннар
кагыла җайлап кына,
йөрәгем аша үтәли
узганын сайлап кына.
Күңелгә тулган көмеш чың
бер көчәя, бер тына...
Утырам Идел ярында
гомер агышын тыңлап...
Көмеш дулкыннар өстендә
нур йөзә эзсез генә...
Моңланып җырлап җибәрәм
тын гына, сүзсез генә...

Аңлыйм да кебек җырымны,
аңламыймын да кебек...
Идел суы — кара дулкын,
ә яры — көмеш күбек...

### Аңлап өлгермичә

Куера да Вакыт кеше була,
Яшәп китә фани дөньяда...
Һәм яшәүнең бөтен хасияте
йога, куна, сеңә аңа да.

Эшли, җырлый, сөя һәм сөелә,
гаҗәпләнә, елый, шатлана!
Әллә тормыш аны чыбыркылый,
әллә кеше аңа атланган?!

Кеше яши.
Аңа каргыш, рәхмәт,
аңа хурлау, мактау,
аңа — дан...
Ник туганын аңлап өлгермичә,
Вакыт була кеше яңадан...

---

Ренат ХАРИС *(1941) — шагыйрь, «Кайтаваз», «Ак сөлге», «Замана эзләре»h. б. татар, рус телләрендә дөнья күргән дистәдән артык китап авторы. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Теләсә генә ничек яшерсә дә,
һәрбер кеше мохтаҗ мактауга —
түмгәк зурлык горурлыгы аның
әверелә биек ак тауга...
Шуннан торып ул карашын ташлый
вак-төякләр тулы дөньяга.
Йодрык хәтле йөрәгендә шул чак
галәм зурлык кеше уяна.
Бәдәненә тула искиткеч көч,
ә аңына — даһи хыяллар,
һәрбер хыял балачактан килгән
гүзәл буяуларга буялган!
Шулар аша ул дөньяга бага:
— Җәннәт багы ич бу, ходаем!..
Җанда
күпме
җәннәт үтерделәр
хурлап-хурлап безне һәрдаим...

## Әгәр

һәр уемны әгәр
әйләндерсәм сүзгә,
һәр серемне әгәр
мин калдырсам эздә,
һәр ачудан әгәр
йодрык төенләсәм,
тузынып та әгәр
кабат өелмәсәм,
һәр үпкәне әгәр
куенда таш итсәм,
һәр нәфрәтне әгәр
күземнән ташытсам,
һәр үчемне әгәр
кабындырсам уттай,
һәр хурлауны әгәр
сүзсез генә йотсам,
һәр шакуга әгәр
йөрәгемне ачсам,
һәр мактауга әгәр
бөркет булып очсам,—
бәлки, яшәү җиңел
булыр иде миңа,
тик тирәмдә дуслар
калыр иде микән?..

## Әй Замана...

Олау әкәм-төкәм сыман,
җикеренсәк тә атка...
Көпчәк бетеп ыңгыраша,
ат та күбеккә баткан.
Олаучыны әй сүгәбез,
әрләшәбез үзара...
Ә арбабыз элеккечә —
әкәм-төкәм күк — бара.
Уйланабыз... Кинәшәбез —
нәрсәдән бу, нилектән?..
Олау шуышып шуыша
бозга тамган дегеттәй.
Ялтырады яп-якты уй,
башлар китте әйләнеп...
Дилбегәнең
уңын
сулга
алмаштырып бәйләдек!
Рәхәт булып китте безгә
(эш үзгәрә юктан да!)...
Ныклабрак бер карасак,
олавыбыз туктаган...

*

Хыялымда якты беткәч,
ябыштым да күз нурыма,
барып чыктым гаҗәп тауга...
Юк, тау килде хозурыма...
Мендем...
Якты...
Җирдә михнәт...
Ә күк — шәфкатьсез алдакчы —
бәхетне
тик вәгъдә итеп,
илаһи булып калмакчы.
Өстә ничек — аста шулай!..
Уй куера...
Кан да ката...
Ничек аңлыйм — килде тавыш:
үлем — дөрес, туу — хата...

*

Кичәге көнен алдылар
йөрәгеннән суырып...
Калды ул саңгырауланып,
калды ул сукыр булып...

Ишеткәнен аңлый алмый,
ул танымый күргәнен...
Юлын капшый да уйлана:
бу үргәме, гүргәме?

Шик-шөбһәсен әйтеп карый —
игътибар юк беркемнән...
Ә яшьләрнең керфегеннән
мыскыллы нур бөркелә.

Елый алмый карт коммунист
бик елыйсы килсә дә...
Йөрәк даруы эзли ул
гүр тирәнлек кесәдән.

Таба алмый... Кабалана...
Оныта шул, оныта!..
Валидол — киләсе көндәй
аңа шушы минутта...

## Тормыш-сыер

Без дигәнчә бармый тормыш-сыер:
алга кусаң — артка борыла...

Йөрәгемдә туган якты сүзләр
буялалар телдә корымга.
Нидер пыскый, пыскый җан түрендә...
Һәм башыма төтен тулганга,
гел елмайган йөзем бик еш чытык,
ә күземнән утлы яшь ага.
Өмет пыскый...
Башка бер утның да
мондый булмый төтен-сөреме...
Корымланган күзләремә минем
хәтта кояш якты күренми...

Без дигәнчә бармый тормыш-сыер...
Иртә язның якты кырына
куган саен,
печән исе сеңгән
тынчу абзарына борыла.

❁

«Замана җиле җанымда.
Күзләремдә куе томан.
Үзем сукыр юлчы сыман —
куркып атлыйм...
Туктыйм... Туңам...
Шәмәхә күк. Картайган Ай.
Йолдызлары күренми ник?
Бер тау каплый. Башы якты...
— Урап үтик...
— Туры меник...
Кайдан бу өн?
Кем киңәше?
Кайсы дөрес?
Кайсы ялган?..»

Бүген дә күпме Обломов
шулай уйга батып ята...

## Җил

Ул җил минем күкрәгемә
очып кереп җиткәнче
изге Ак бүре йөрәге
аша исеп үткән җил!

Ул җил күзем карасына
очып кереп җиткәнче
Идел акчарлагы күзе
аша исеп үткән җил!

Ул җил минем табаныма
очып кереп җиткәнче
дала айгыры тоягы
аша исеп үткән җил!

Ул җил минем кулларыма
очып кереп җиткәнче
Алып батырның беләге
аша исеп үткән җил!

Ул җил телемә-көемә
очып кереп җиткәнче
Орхон-Енисәй балбалы
аша исеп үткән җил!

Ул җил минем күңелемә
очып кереп җиткәнче
анам сөтенең хәтере
аша исеп үткән җил!

Ул җил нинди җил дисеңме?
Улым, якынгарак кил:
ул җил — минем аша үтеп,
сине татар иткән җил!

## Госман Садә

# Төнге кошлар

ТРИПТИХ

### I. «Өзек инде безнең ара...»

*1951 ел. 21 декабрь.*

Кич життеме, ауга чыга
Төнге кошлар — ябалаклар.
Ябалакмы җанны аңлар?
Кар өстендә — канлы таплар...

Төнге кошлар ишек кага...
Кобурадан төртә наган...
Өчәү алар...
Өчесе дә
Төндәй кара тужуркадан.

Өчесе дә кызыл күзле...
Аңкып тора сасы хәмер...
Алтын тешләр арасыннан
Шартлап чыкты кансыз әмер:

— Ике минут вакыт сезгә,
Киенегез, дошман мәлгунь!
...Бу әмердән дер калтырап,
Күзен ачты куркып Шәмгунь.

Кече яктан кача-посып
Түргә чыкты ялан тәпи.
«Нинди оят!
Нинди хурлык!
Димәк... дошман минем эти...»

...Өйдә әле көндез генә
Бәйрәм иде, ямьле иде...
Табындагы гөбәдия
Тел йотмалы тәмле иде...

Кош тоткандай, мәктәбеннән
Шәмгунь очып, балкып кайтты.
Тантаналы вәгъдә биреп,
Ал галстук тагып кайтты.

Көне диген — көне нинди —
Туган көне юлбашчының!
...Менә ничек килеп чыкты
Яман ягы бер яхшының.

...Тойды Шәмгунь: галстугын
Иртән тартып алачаклар.
Бу хурлыктан котылырга
Бер мөмкинлек, бер чара бар:

Кичекмәстән, соңламыйча
Ваз кичәргә нәселеңнән.
Тужуркалар ялгышмыйлар,
Алар монда белеп килгән.

— Улым минем! — Эти кеше
Дәвамчысын кочып үпте.
Уттан качкан бүре кебек
Шәмгунь һаман артка чикте.

Артка чигеп качмакчымы
Ул бүгенге язмышыннан?
Кара янып әйтте соңын,
Кырын карап каш астыннан:

— Бүтән миңа «улым» димә —
Синең белән өзек арам.
Мин дә сиңа «эти» димәм,
Кабереңә якын бармам!

...Ә этисе нәрсә дисен,
Күңеленнән улын аклый:
«Бу — бердәнбер дөрес адым,
Киләчәккә үзен саклый.»

...Эти кеше, улын уйлап,
Төн эченә кереп бара.
Арттан килә бер кайтаваз:
«Ө-зек
ин-де
без-нең
а-ра-а...»

Илле бернең салкын кышы...
Алда тагын күпме кышлар.
Караңгыга хуҗа булып
Оча бары төнге кошлар...

---

Госман САДӘ *(1949) — шагыйрь, «Мәхәббәт елы», «Җиләкле тәрәзәләр» һәм «Тайфун күзе» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## II. Иске елның соңгы киче

*1981 ел. 31 декабрь.*

Котыплардан җилләр исә
Төнге явыз кошлар сыман.
Күчә салкын, кайный-кайный,
Яңа елга — иске елдан.

Котыплардан җилләр исә,
Карамыйча бернигә дә.
Яңа ел ул килми калмый,
Керми калмый бер өйгә дә...

Шәмгунь күптән уйлап куйган
Кичен ничек эш йөртәсен:
Кочак җәеп каршы алыр
Чираттагы сөяркәсен.

Шәмдәлләргә шәмнәр тезеп,
Чыршысын да бизәп куйган.
Затлы коньяк, татлы шампан
Өстәленә кунаклаган.

Алар әле ачылмаган —
Йорт хуҗасы «әдәп» саклый...
Асыл кошы килде бугай —
Кемдер анда ишек шакый.

Бусагада — күрше кызы,
Очраштылар күзләр-күзгә.
— Эшегездән бүлдердемме?
Зинһар, гафу!..
Бу хат — сезгә.

Хатны алгач, эчтән генә
Кызны сүгеп калды Шәмгунь:
— Исәнлек тә бирә белми,
Тәрбиясез, иблис мәлгунь!

...Хатны ачып, күз төшергәч,
Тораташтай катып калды.
Бер күгәрде,
Бер агарды...
Кесәсенә хатны салды...

Тагын алды...
...Йорт хуҗасын
Өнсез иткән нинди хат ул?
Яңа елга каршы кичтә
Язган аны улы Наил.

Язган аны әрнеп-әрнеп,
Бәгырь-йөрәк канын савып.
Хатның һәрбер хәрефеннән
Ачы сагыш тора саркып:

— Саумы, эти!
Көтәм сине...
Нигә миннән
Син еракта?
Мин бәхеттән
Мәңге мәхрүм
Ятим йортта —
Интернатта.

Ашауны да
Начар димим,
Кайчагында
Артып кала.
Ләкин монда
Барчабыз да —
Артык кашык,
Артык бала.

Яшәсәк тә
Бер калада,
Нинди ерак
Безнең ара.
Йөрәгеңдә
Бармы җаның?
Җаның булса,
Уйлап кара:

Килер идең
Бер яныма,
«Улым» диеп
Кочар идең.
Сине күрү
Шатлыгыннан,
Канатланып
Очар идем...

Нигә, эти,
Күрешмибез?..
Нигә синнән
Күрмим кадер?
Гаҗизлектән,
Ятимлектән
Йөрәк әрни...
Сыза бәгырь...

Әнкәй булса,
Бер юатып
Сөяр иде
Иңнәремнән.
Әй син, язмыш!..
Үзе миңа
Гомер биргән —
Гүргә кергән.

Ваз кичкәнсең
Дәү этидән
Янаганда
Аңа үлем.
Тарих күптән
Исбатлады
Аның дошман
Түгеллеген...

...Хыянәтне
Беркайчан да,
Бер яклап та
Булмый аклап.
Юк, җыенмыйм
Үч алырга,
Сиңа нәфрәт,
Ачу саклап.

Барыбер дә
Минем янга
Килерсең, дип
Өмет итәм.
Тәрәзәдән
Күзем алмый
Мин, этием,
Сине көтәм!!!

...Корт чаккандай, бүртенүдән
Шәмгунь шабыр тиргә батты.
Кисәк-кисәк ертып, хатны
Дөрләп янган утка атты.

Өй эчендә бер мизгелдә
Балкып алды серле якты...
Кинәт сүнде...
Ул да булмый —
Кемдер тагын ишек какты...

...Түргә узды кара төннең
Чираттагы йолкыш кошы.
...Иске елдан — Яңа елга
Күпер суза котып кышы.

## III. Кышкы сукмак

*1988 ел. Декабрь.*

Уяныгыз, кыш кошлары —
Кызылтүшләр!
Кояш калка.
Агачларда көмеш нәкыш:
Җем-җем балкый энҗе-алка.

Күрәсезме, кызылтүшләр?
Сукмак буйлап икәү килә.
Алар миләш кәүсәсенә
Сезнең өчен җимлек элә.

Сыйланыгыз — сый җитәрлек!
Кошларга да кирәк бәйрәм.
Сыйлаучылар кем дисезме?
Берсе — Наил.
Берсе — Мәрьям.

Шул урында туктап торып,
Бер үткәнгә кайтыйк әле.
Балачакның хатирәсен
Бер яңартып алыйк әле.

...Кичкә каршы, кибеттәнме,
Мәрьям өйгә кайткан чакта
Өч исерек бәйләнделәр
Акча сорап аулак чатта...

Наил ничек күреп калган? —
Чабып килгән уңаена
Бер сәрхушне салып екты
Аулак чатның урамына.

Үзенә дә «өлеш» чыкты:
Син ятим дип тормадылар.
Батырганчы кара канга,
Тибә-тибә кыйнадылар.

...Тормыш сыный һәр адымда,
Кем дә шулай сынау уза.
Сынатмады Наил үзен! —
Мәрьям әнә кулын суза!

Дуслык килә шушы көннән —
Сукмак буйлап — бүгенгечә.
Агачларда көмеш бәсләр
Энҗеләрдәй җемелдәшә...

Күпләр узар җитәкләшеп
Алар тапкан чын юллардан...
Кыш кошлары —
Кызылтүшләр
Җылы җыя кушучлардан.

*1989. Малеевка.*

Газиз Үзиле

# ГЫЙФРИТ

РОМАН-ДИЛОГИЯНЕҢ ИКЕНЧЕ КИТАБЫ

Мөгзе бар куйның бары да кучкар түгел,
Очкан кошның барысы да шоңкар түгел.
Дастаннан

## Беренче башлам

### 1



мдык яңгыр ява, вак тамчылар ара-тирә ялтыравык кар тәңкәләренә әверелгәли. Ул тәңкәләр юл буендагы агачларның инде саргайган яфракларына төшеп-төшеп куналар, әмма аларның төсен агарта алмыйлар әле.

Сиксән бишенче елның көзе.

«Алырлармы-юкмы? Алырлармы-юкмы? Бу якларга кайтып дөрес эшләдемме?» — дигән борчулы уйлар Искәндәр Фидаяровның күңелен юл буе тырнап, борчып килә.

Иртәгә ахырзаман диярсең. Халык вокзалларга-юлларга сибелгән, кайсы шәһәрнең кайсы гына вокзалына барып кермә — халык, халык, халык... Бу юлы да автобус шыгрым тулы. Салонда бензин исе катыш җылы һава тирбәлә. Шуңа күрә утыргычларының аркасын артка җибәрә төшеп, ярым ятып баручыларның кәефе ярыйсы гына күренә, һәрхәлдә, тыштагы һава хәледәй эленке-салынкы түгел.

Әмма Фидаяров автобус эчендәге ыгы-зыгыга, ир-атлар сөйләгән мәзәкләргә тулысынча битараф. Аның күз алдыннан моңсуланып калган кырлар, юл читендәге шәрә агачлар, автобусның зур тәрәзәсендә төрлечә эзләр калдыра-калдыра түбән таба тәгәрәгән тамчылар — һәммәсе дә каядыр ашыккандай йөгерешеп кенә үтәләр. Дөрес, юлның ике ягындагы уҗым басулары күзгә шыксызлыкка ямь өстәпөстәп ала. Мондый чакларда Искәндәрнең дә йөзе ачылып киткәндәй була.

«Алырлармы-юкмы? Алырлармы?»

---

*Газиз ҮЗИЛЕ (Кашапов) (1942) — эдип. «Сәмум җиле», «Еллар тынып иде», «Тямышыңа ышан» һ. б. китапләр авторы. Чаллыда яши.*

*Әсәрнең журнал варианты.*

«Нишләп соң әле бу башкатыргыч уйлар юл ахырына якынлашкан саен күңелне ныграк били, котылгысыз итә, офыктагы болытлар кебек кабарына? Нишләп уйларның иге дә, чиге дә юктыр инде...

Әйе, Искәндәр соңгы биш-алты елда уйлар диңгезендә рәхәтләнеп, колач салып йөзде. Байкал-Амур магистрале узачак җирдән мәңгелек урманнарны кисеп юл ярган чакта ни генә уйламады да, нинди генә планнар кормады? Ул якларга бик күпләр төрле путевкалар, тантаналы озату-каршы алулар белән бардылар. Искәндәрне исә ишек-тәрәзәләренә тимер рәшәткәләр куелган вагонга утыртып, бикләп илттеләр. Дөрес анысы, Искәндәр үзенең шушы сәфәренә хәтле дә туган ягында яшәмәде. Ул вакыйгалар — инде тормышның «теге хәлгә» хәтле узган өлеше. Ә «теге хәл» Искәндәр тормышын, Европа белән Азияне аерып торган Урал тау тезмәләре кебек, икегә бүлеп тора. Турысын әйткәндә, ул тормыш хәзер инде Искәндәр Фидаяровныкы түгел дә кебек. Ул тормышта Искәндәр Фидаяров к е ш е иде, хәзер исә ул «б е т к ә н  к е ш е»гә әверелде.

«Беткән кеше»...

Тукта, ничек болай булып чыкты соң әле? Ничек итеп зур җитәкче Искәндәр Фидаяров шундый көнгә калды?

Бу сорауларга ашык-пошык түгел, озын-озак уйланганнан соң да төгәл җавап бирүе кыен, бик тә кыен иде. Моның өчен Искәндәрнең соңгы эш урынын, барлык хезмәт юлын, алай гына да түгел, балачагын, яшьлеген барлап чыгарга кирәктер. Бәлки, узганнарны кырмыска оясыдай кузгатмаскадыр? Байкал-Амур магистраленың кеше-кара күзеннән шактый ерак җирдә эшләгән иптәшләре арасыннан берәү аз битәрләмәде аны: «Ташла, бугор,* үз-үзеңне җәфалауны, ташла... Ташла да, безнең кебек итеп миннән киткәнче... дип эшлә, көн үтә, дип кенә яши башла.— диде ул ничәмә-ничә мәртәбә.— Син янасың, сине әнә шуның өчен, янып эшләгән өчен, күпне күргәнең өчен яндырганнар, валлаһи шулай... Син бит безнең кебек чи надан түгел, син бит кичен укып булса да институт бетергән кеше. Син бит үзең, начармы-яхшымы, түрә булгансың. Нуҗәли белмисең — алдан йөрүчеләргә, иртәме-соңмы, барыбер җәза бирелә. Гадирәк яшәргә кирәк. Төкер, Син, бугор, тормышны артык катлауландырасың. Өстәвенә тагын «намус, вөҗдан» дип үзеңне җәфалыйсың. Аңла син, юләр, хәзер андый нәрсәләр модадан чыкты, беләсең бит. Революцион күтәренкелек чоры узды. Әнә, еракларга китеп йөрисе юк, үз язмышыңнан гыйбрәт ал. Алар бит, кемнедер калкан итеп, үз тиреләрен һәм төшемле урыннарын саклап калучы кабахәтләр. Иң элек аларда булырга тиештер бит ул син әйткән «намус-вөҗдан» дигән нәрсә...»

Искәндәр исә, кызганычка каршы, бу сүзләрнең чынбарлыкка якынлыгын белә иде. Тик күңеленең ерак бер почмагында яшәгән, балачактан ук тормышка битараф була белмәү аны әлеге фикер белән килешмәскә өнди. Шуңа күрә теге бәндә: «Әй, аңа кеше сүзе кирәмени? Йөрсен әйдә әрвах кебек элтек-мелтәк килеп. Бөкрене инде аны кабер генә...» дип Фидаяровны тәрбияләүдән бөтенләйгә баз кичте.

«Ничек, ничек инде шулай булырга мөмкин? Мин бит гомер буе гаделлеккә ышандым. Битараф булмаска, баскычтан һаман, һаман өскә таба менәргә, кеше арасында кеше булырга, эшемне җиренә җиткереп эшләргә, бүтәннәрне дә шуңа күндерергә тырыштым. Чынлыкта... чынлыкта исә барысы да киресенчә була барды. Нигә? Кем гаепле моңа? Сәбәпләре нинди?»— Шулай фикер йөртте Искәндәр чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган котсыз җирдә уздырган

* Бугор — бригадир сүзен бозып әйтү (жаргон).

озын-озын төннәрдә.— Мин ни өчен атлаган саен каршылыкка, хаксызлыкка тап булдым? Ни өчен тормыш мин теләгәнчә югарыга таба гына үрләмәде? Ни өчен мин баскыч басмалары(нна)н мәтәлеп-мәтәлеп төштем? Ни өчен кеше кебек такыр сукмактан тыныч кына йөри белмәдем? Ни өчен мәгълүм кысаларга сыймадым? Дөреслек өчен көрәшәм, дип гел турысын ярып бардым, ә бит «туры барсаң, баш бәрелә» дип юкка гына әйтмәгәннәр. Ни өчен мин күз буяуларга, юкны бар итеп күрсәтүләргә түзмәдем? Атылып-бәрелеп чыктым да ярып-ярып салдым. Телемне тыя белмәдем? Миңа гына кирәк идеме соң ул? Тегеиптәш, бәлки, чынлап та хаклыдар үзенең шушы вак фәлсәфәсе белән?»

Искәндәр ничәнче тапкыр инде менә шулай итеп узган тормышын барлый иде. «Эх-ма,— дип уйлады ул тагын.— Авыл җирендә туып-үскән адәм баласына шәһәр кешесе булып китү җиңелдән түгел. Авылда гына каласы булган да бит... Нигәдер төзелеш тузаннары, аның мәһабәт күренешләре тартты. Газеталарда аларны кызыктырырлык итеп сурәтлиләр иде шул. Стройбатта сержант булып хезмәт иткәннән соң, иптәшләре белән Үзбәкстандагы яңа төзелешкә язылып китте. Аннары, андагы эшләр кими төшкәч, хатыны белән бергә Мангышлакка күчте һәм шунда зур идарә җитәкчесенә хәтле үсте. Моның юлны сайлавына баштарак үкенмәде үкенүен. Тик шулай да... соңрак үкенергә туры килде аңа. Көннәрдән бер көнне ул: «Син, Карамусаев — җәнҗалчы, син — ришвәтче, вөжданың югалткан хыянәтче. Төзелеш берләшмәсе башлыгы булу түгел, гомумән кешеләр арасында яшәргә дә лаек түгелсең. Синең урының йомшак кәнәфи түгел, җинаятьчеләр сәкесендә! — дип йөзенә бәреп әйтте. Менә шуның өчен утырган урыныннан һәм тормыштан читкә алып ташладылар Фидаяровны, гаеп өстенә гаеп уйлап чыгардылар. Ниһаять, үзен хөкем эскәмиясенә кертеп утырттылар... Искәндәр кешеләргә ышана иде. Аның шушы сыйфатыннан оста файдаландылар. Моны ул гаепләү актын укыганда гына аңлады. Әмма соң иде инде. Искәндәр хөкем вакытында, соңгы сүзендә дә бу гаепләүне кире кагарга тырышып карады, ләкин хөкемдарлар аны тыңларга теләмәделәр. Аларга Фидаяров дигән кешене акларга түгел, гаепләргә, тугры «үзләре өчен «Макар көтү көтмәгән җирләргә» җибәрергә кушылган иде.

Әмма Искәндәр дигән кешенең дә бәхете бары тик болытлар арасында яшәми икән ләбаса. Әйе. Искәндәрнең «күршесе утны-суны кичкән Чеке бабай очраткан саен: «Нихәл, Искәндәр Макидунски — дип юкка күрешмидер күрәсең. Аның йолдызы да көннәрнең берендә битарафлык караңгылыгын ярып,нахак ялалар ягылып ничарадан бичара Искәндәргә карады.

Яңарыш башланды. Сиксәнче бишнең апрель җиле исте.

Ислах һавасын сулау мөмкинлеге туды. Үзгәрешләр заманы килде.

Фидаяров «эше» Карамусаев кебек бәндәнең җинаятьләрен карауучыларның күзенә чалынды һәм хаклык Ерак Көнчыгыш якларына кадәр барып җитте...

Ниһаять, Искәндәр туып-үскән якларда башланган яңа төзелешкә, «азат ителде» дигән белешмәне кесәсенә салып кайтып бара. Булсын, әлегә шулай булсын... Аңа: «Син, Фидаяров, бер дә генә кайгырма, озакламый акланырсың».— дигән өмет күндерделәр. Бәлки, туган якларына кайтмаска. Карамусаев белән бәрелештә абынган җиренә барырга кирәк булгандыр. Бәлки анда аңа аягына ныклап басуы җиңелрәк булыр иде. Әмма Искәндәр элеккеге абруена таянып алга баруны хупламады. Билгеле, анда Фидаяровны яхшы беләләр, кайту белән берәр җаваплы эш бирерләр. «Карамусаевтан нахакка җәберләнгән кеше» диярләр иде. Юк инде. Фидаяров андыйлардан, үзенең үткәне-

нә салынып яшәүчеләрдән түгел. Ул яңадан, өр-яңа җирдәге төзелештә дә үзенә-үзе юл сала белер. Искәндәр моңа ышана. Башкалар әнә «йонлач кул»га таянып өскә үрмәләсен. Фидаяров бары тик үз көченә, сәләтенә, ихтыярына таянып менәчәк...

Кама буенда тагын бер зур төзелеш башланганны Искәндәр ишетеп, белеп йөрде. Бервакыт аның күңелендә дә: «Әллә кайтып китәргәме?» — дигән уй талпынып алды, әмма канатланып китә алмады.

Ерак җирләрдән кайтырга чыккач кына, тимер юл вокзалы да узырганда, аның күзләре үзәк газеталарның берсендә басылган хәбәргә төртелде. Анда КамАЗдан ерак түгел генә җирдә яңа АЭС төзи башлаулары турында язылган иде.

«Менә миңа урын,— дип уйлады Искәндәр.— Туган авылдан әллә ни ерак түгел. Бусы — бер. Өр-яңа төзелештә мине белүче, узгандагыларны күзгә төртеп әйтүче булмас. Бусы — ике. АЭС төзелешендә эшләп байтак кына тәҗрибә тупладым. Бусы — өч. Хәерле сәгатьтә булсын!» — дип, үзенә-үзе фатиха бирде.

Шулай да яңа төзелеш барган җиргә якынлашкан саен Искәндәрнең шөбһәләнүе көчәйде. Кесәсендәге белешмә, кукрәген чеметеп көйдереп алгандай, яткан урыныннан кузгалгалап куйды.

«Алырлармы-юкмы? Алырлармы?» — дигән уй Искәндәргә тын алырга ирек бирмичә, бимазалавын дәвам итте.

— Абзый, дим, абзый, син нәрсә, автобустан төшмәскә булдыңмы әллә? Килеп җитмәс борын кире таяргамы исәп? Көчәйткечтән яңгыраган бу тавыш Фидаяровны авыр уйларыннан арындырып җибәрде.— Җиттек килеп, абзый. Әллә инде кире уйладыңмы, җылырак җиргә шыларгамы исәп, дим?

Искәндәр автобус эчендә япа-ялгыз утыруын, юлчыларның инде бетон түшәлгән мәйданчыктан янәшәдә күренгән биек ак йортка таба атлауларын күреп алды. Ул ашыгып урыныннан торды, бөгелә төшебрәк утыргыч астыннан юл капчыгын алды да җиргә төште.

Тышта ымдык яңгыр ява, күк йөзен бетон плитәләрдәй авыр болытлар томалаган. Аяк астында, резин итек кунычын күмәрлек пычрак. Анда да, монда да актарып ташланган кантар-кантар җир өемнәре ята. Шофер егет юлчы агайның капчыгын җилкәсенә салган килеш туфлиләре белән пычрак ярып атлавын карап торгач, кинәт кулын селтәп: «Бетмәс монда җыен дивана»,— диде һәм урынына кереп утырды да кайту ягына таба борылды.

## 2

Фидаяров башын түбән иебрәк, калак сөякләрен беркадәр калкытыбрак, озын юлларда йөрергә өйрәнгән кешеләрчә, сирәк, сыгылмалы, әмма нык адымнар белән атлый иде. Ул очраган кешеләрдән сораша-сораша «Атомэнергострой» трестының өч катлы яңа бинасын эзләп тапты. Бина артындагы вагоннарның берсендә урнашкан кадрлар бүлегенә керде. Караса, бая автобуста үзе белән бергә килгән шаушулы, җор телле егетләр басып тора. Хәер, эшләрен бетерәләр иде бугай. Арадан берсе, Фидаяров янында утырып килгәне, гаҗәпләнеп:

— Син дә монда килдеңмени?— диде.— Нигә әйтмәдең аны, бергәләшеп йөгергән булыр идек монда таба. Югыйсә, күрәсең, бу архарларны, килделәр дә иң шәп урыннарны эләктереп тә өлгерделәр. Сиңа калмагандыр да инде,— дип, авызын колак артына кадәр ерып алды.

Фидаяров егетне баштанаяк карап-күзәтеп чыкты. Таза, нык гәүдәле бу егет төзүчеләр арасында күптән инде үз кеше булып өлгергән, үз урынын тапкан иде бугай.

— Кайгырма, дус кеше, өлешем кеше юлыннан йөрми. Миңа дигәне калгандыр әле.— диде Фидаяров капчыгын тегеләрнеке янына идәнгә ташлап.— Исемем — Искәндәр абый булыр, әйдә соң танышып куйыйк булмаса...

Фидаяров елмаеп кулын сузды. Һи хикмәттер, аның төзелешләрдә тупасланган ир-егетләр белән уртак тел таба торган сөйкемле сөяге бар иде. Бу юлы да шушы сыйфаты алга чыкты. Башта әлеге егет, аның артыннан бүтәннәр дә исемнәрен әйтә-әйтә күрешеп таныштылар. Ләкин Фидаяровның уйлары хәзерге хәлләрдән еракта иде, шуңа күрә аның хәтере бары тик егетнең каратут йөзен, кара кашларын һәм «Илдар Корбанов», дип әйтүен генә саклап калдырды.

Ул арада вагонның сулъяк очындагы ишек ачылды һәм аннан тулы гәүдәле бер хатын чыкты. Ул үзенең өстенлеген сиздереп, беркадәр кимсетүлерәк караш ташлап карап торды да:

— Йәгез, тагын нәрсә монда шаулашып торасыз? Эшегез бетте бит. Барыгыз, вагоннардагы койкаларыгызны алырга ашыгыгыз,— диде.— Иртәгә эшкә тотынырсыз. Бездә монда озын-озак «оформить итү» гадәте юк.

Коридорда тавыш тынып торган иде, ләкин «Иртәгә эшкә» дигән боеру ул тынлыкны яңадан бозды.

— О-го!— диде Фидаяровның кулын кысып торучы тәбәнәгрәк буйлы, сары мыеклы ир-егет.— Менә бу тизлек, менә бу миңа ошый...

— Ә сезнең, иптәш, ни йомыш, нәрсә кирәк?— диде хатын Фидаяровка.— Сез дә эшкә килдегезме?

Фидаяровның нигәдер тыны кысылып куйды, әмма ул тиз арада үзен кулга алды:

— Әйе... Эшкә килдем. Ләкин менә егетләр артыннан өлгереп булмады, алар белән бер автобуста ук килгән идек...

Көн саен төзелешкә килүче ничәмә ничә кеше белән сөйләшергә тиешле бу кырыс хатын үз эшен яхшы белә, күрәсең, Фидаяровка сөйләп бетерергә, шуның белән вакыт отарга ирек бирмәде, кыска гына итеп:

— Документларыгыз?— дип кулын сузды.

Фидаяровка, нишләмәк кирәк, кесәсенә тыгылырга, аннан әлеге «белешмә»не тартып чыгарырга туры килде.

— Документларыгызны?— диде хатын тагын бер кат.— Сез нәрсә миңа кәгазь кисәге сузасыз? Паспортыгызны, хезмәт кенәгәгезне бирегез?

Фидаяровның өстенә кайнар су сиптеләр диярсең, ул куырылып куйды. Соңгы дүрт ел эчендә кимсетелүләрнең төрлесен күргә дә карамастан, ул аларга күнегә алмаган иде. «Тегеннән кайткан кешенең мондыйрак хәлләрне дә үтәсе бар икән әле»,— дип уйлап алды. Билгеле, әгәр дә мәгәр кадрлар бүлеге бүлмәсенә кереп, икәүдән-икәү, күзгә-күз сөйләшсәләр, җайлырак әйткән булыр иде ул үз хәлләрен. Әмма монда башкачарак килеп чыкты.

— Паспортым да, хезмәт кенәгәм дә әлегә юк минем,— диде ул, ниһаять, йөзендә кайнарлык тоеп.— Менә шушы белешмәдә... Барысы да аңлашылыр.

Фидаяров күз кырыйлары белән генә ир-егетләр ягына карап алды. Тегеләр барысы да аның үзенә төбәлгәнен, сүзнең ни белән бетәсен көтеп торалар иде шикелле.

Кадрлар бүлеге хезмәткәре эшне аңлады.

— Кызганычка каршы, иптәш гражданин,— диде ул тавышын тагын да кырысландырып,— безнең төзелешкә заключениедән кайтучыларны алмаска дигән карар бар.— Һәм Фидаяров аны-моны әйткәләгәнче әлеге белешмәне кайтарып бирде.— Бу очракта мин сиңа, иптәш гражданин, ярдәм итә алмыйм. Безнең монда үзебездәге «яхшы»лар да бик җитәрлек.

Кадрлар бүлеге хезмәткәре шулай диде дә ишектән чыгып ук китте. Нишләмәк кирәк. зурның моржасы кыек булса да төтене туры йөри инде аның.— дип уйлап алды Искәндәр. Бу вакыйганың ирексез шаһитлары — егетләр дә Фидаяровка кушылып беравык тын тордылар һәм. ниһаять. аңнарына килеп. барысы берьюлы шаулашырга керештеләр:

— Менә сиңа мә!

— Тукта. ничек алай соң әле бу?

— Үзләре бөтен җиргә игълан язалар...

— Кайгырма. абзый. менә кадрлар бүлеге начальнигы керер. ул ир кешене аңлар...

— Аңлар. соң бит шушы хатын үзе инде.

— Начальникмы? Тапканнар икән...

Шулвакыт Фидаяровның каршысында ук торган сары мыеклы телгә килде:

— Кайгырма. агай! Тот та төзелеш начальнигының үзенә кер. Кем син? Төзүчеме дип әйтүем? Шулай булгач... Төзүче төзүчене аңлар. Менә Остап Безбожный әйтте диярсең. Егетләр.— диде ул янәшәсендәгеләргә борылып.— Илдар. әй. Илдар. дим. давай. бу агайны үзебезнең булачак бригадага алабыз. Әйтсен шулай дип начальникка..

Остап. иптәшенең ризалыгын да көтеп тормыйча. тагын сөйләп китте:

—Без. җыелышып үзебезгә бер мөстәкыйль бригада оештырырга килдек. Менә бу егет армиядә безнең сержант иде. хәзер бригадир булачак. Без КамАЗ төзелешенә дип килгән идек. Хәзер анда эшләр кимегән.. монда җибәрделәр.

Башкалар да Остапның сүзен җөпләделәр. «Әйе. шул. нигә әле сиңа начальникның үзенә үк кермәскә? Син бит малай-шалай түгел. кадрлар эшләргә тиешсең».— диештеләр.

Теге хатын дорфаланып чыгып киткән минуттан бирле Фидаяровның тамак төбендә утырган чуерташ бераз селкенеп куйды.

— Ну. ну. нәрсә телеңне йоттың. агай? Бик каты сукты сиңа. конешно. бу мадам сугуын. Тик син борыныңны салындырма әле. Әнә теге яктан әйлән дә кер баштыкның үзенә.

Шулай диде дә. Остап Безбожный үзенең сары мыегын сыпырып алды. Фидаяровның җиңеннән эләктереп ишеккә таба ишарәләде. Башкалар аны хупладылар.

— Дөрес. Остап. мыегыңны ныграк сыпыр. Ә син бер дә тартынма. агай. үзеңә җылы урын сорамыйсың лабаса. муеныңны камытка тыгарга омтыласың бит.— диештеләр.

Көч-куәтләре ташып торган бу егетләрне. бәхетләренә каршы. тормыш бабайның уникедән үргән чыбыркысы кыйнамаган. аркаларына сырлар салмаган иде әле.

Бу уй трест бинасының икенче катына менеп баручы Фидаяровны шатландырып җибәрде. Яшьләрнең үз язмышына битараф булмаулары күңелен күтәрде. аның үз-үзенә ышанычын арттырды.

Ә бит урамнарда магнитофон күтәреп. юньләп сөйләшерлек тә тавышы булмаган. әмма микрофонга йөзәр ялкыр рәттән бер үк сүз. бер үк җөмләне акыручы. бигрәк тә. аны тыңлаганда ни кылганын белмичә кыланучы яшьләргә карап. Искәндәр еш кына: «Кая баралар бу яшьләр. ник бу хәтле битараф соң алар? Нишләп аларга бер нәрсә дә кирәкми соң? Бары тик шул рок музыка һәм көтү-көтү җыелып сугышулар. талау-үтерүләр белән генә яшәп булмый лабаса». дип уйлый һәм шул сорауларына җавап таба алмыйча интегә иде. Баксаң. яшьләрнең дә төрлесе бар икән ич...

Нигә соң әле мин бу хәтле кара уйларга биреддем. Мин бит туган җиремә кайттым. Монда минем яңа юл башларга тиеш. Әгәр дә мә-

гәр гел яхшы булып торса, ялан-ялан бәйрәм итсәк, тормыш мәгънәсен каян белер идек тә, кешеләр турында ни уйлар идек? Йәле, Искәндәр, син бит кайчандыр кыю идең, каршылыклар алдында туктап калмый торган идең...

— Кем кирәк сезгә?— диде кабул итү бүлмәсенә кереп басуга каршысында пәйда булган джинсы чалбарлы, үтә җыйнак гәүдәле кыз. Шундук «Тәти кыз» дип исемләде аны Фидаяров. Ләкин авыз ачып сүз әйтергә өлгермәде, өстәлдәге ике те ефонның берсе зеңгелдәп тавыш бирде. Кыз тиен җитез тге белән борылды да «Управляющий» дип язылган ишеккә кереп югалды. Фидаяровның кыз артыннан күзәтеп барган күзләре дермантинлы ишеккә барып бәрелде. Япониядән кайтарылган бик сирәк очрый торган затлы материал иде ул. Биредә дә начар яшәмиләр бугай.

...Карамусаев белән чәкәләшкән Искәндәр Фидаяровның икенче каладагы яңа идарәгә күчеп эшли башлаган көннәре иде. Төзелеш мәйданыннан кайтып кергән сирәк бер сәгатьтә аңа Югарыдан шалтыраттылар.

«Фидаяровмы?— диде телефондагы тавыш.— Минем сезгә бер үтенечем бар иде... Рәхим итегез. Хәлдән килә торган эш булса... Сезнең дә хәлдән килмәсә, безнең кебек закон китаплары кимереп ятучыларга ни кала инде...— диде тавыш.— Әйтеп карагыз соң, бәлки, файдалы киңәштер? «Киңәш?» Әйе... Киңәшне аның хәзерге заманда теләсә кемгә өләшеп утырмыйлар, ипташ Фидаяров, сез минем белүемчә, мондый нәрсәләрне генә аңлый торган кеше.

Фидаяров аңлады: бу тавыш иясе бик күп нәрсәләрне белә һәм күп нәрсәләрне булдыра торганнардан иде.

Дәшмәде.

«Ярый соң алайса, иптәш Фидаяров,— диде теге,— турысын әйтәм мин сезгә. Чөнки безгә киләчәктә күп тапкырлар очрашырга туры киләчәк әле. Безгә японский дермантин кирәк иде. Минем ишетүемчә, сезнең оешмада андый нәрсәләр бар икән...

Фидаяров телефон трубкасын кулы белән каплады да селектор төймәсенә басты. ...эминатчыдан әлеге нәрсәнең булу-булмавын белеште. «Космос» ресторанын җиһазлаудан калган бер рулон бар иде,— диделәр.— Кирәк булса, Искәндәр Өмәтгәрәевич, оештырабыз аны...

Фидяров тагын аңлады: болар белән сөйләшеп эшләнгән эш иде бу.

Беравык уйлап торганнан соң Фидаяров телефонда көтеп торучыларга: «Барын бераз бар икән, әмма без андый кыйммәтле материалны читкә җибәрә алмыйбыз...— дип үтенүчене канәгатьләндерә алмавын белгертте.

Соңыннан аңа «эш» оештырып, тикшерү барган көннәрдә, аннары хөкем дәвамында япон дермантинының кыйммәтен аңа бер генә түгел, ике-өч мәртәбә исенә төшерделәр. Ләкин эш узган, тузасы кием тузган иде инде...

— Ә сезнең соң нинди үтенечегез бар иде?

Фидаяров шунда гына Тәти кызның бүлмәдән чыгып үз өстәле янына утырганын абайлады.

— Үтенеч? Ә нигә үтенеч булсын? Мин сезгә эшкә килдем, а кадрлар бүлегендә...

— Юрий Борисович андый мәсьәләләр белән шөгыльләнми, иптәш. Сез ялгыш кергәнсез, кадрлар бүлегенә барыгыз.

— Мин анда булдым инде... Юньләп сөйләшмиләр.

— Юрий Борисович Түбән мәйданда, монда юк ул хәзер. Кайчан буласы да билгесез.

Фидаяровның тамагына тагын баягы чүеләш килеп тыгылды. Аны шушы Тәти кыз бүлмәдән сөреп чыгарсынмы? Юк инде...

Фидаяров басып торган җиреннән кузгалды да әле генә Тәти кыз кереп чыкка ишеккә таба атлады. Бер, ике, өченче адымны атларга өлгермәде — секретарь кыз чәрелдәп килеп аның каршысына төште, күкрәгенә төртеп җибәрде.

— Нишлисең син, нахал?! Кая барасың, сарык? Хәзер үк милициягә озатам бит үзеңне!..

Мондый мәзәк һәм аяныч хәлдә калганы юк иде әле Фидаяровның. Ул ирексездән бая басып торган урынына чигенде. Ләкин инде Тәти кыз һөҗүмгә күчеп өлгергән иде.

— Чыгып кит, хәзер үк күземнән югал, нахал,— диде ул куна-ктасы кебек аз гына сырлы күкрәген киерергә тырышып.— Во-он!

Әгәр дә мәгәр Тәти кызның шушы «Во-он» дигәне йөзенә килеп бәрелмәсә, Фидаяров бүлмәдән чыгып киткән, бәлки әле төзелештән китеп тә барган булыр иде. Ләкин шушы сүз, бары тик урамда йөри торган көчекләргә генә кычкыра торган сүз, аны чынбарлыкка кайтарды һәм ул күзләрен нәфрәт томаны башлап анны сизмәстән алга таба атлады, әлеге кызны сыңар кулы белән зырылдатып юлыннан алды да ишекне ачты.

Шул ук мизгелдә:

— Нинди хулиганлык бу?— дигән тавыш ишетелде. Фидаяров ирексездән тетрәнеп (тавыш шундый-шундый таныш иде), артына борылып карады. Ләкин әле күз алдыннан баягы томан таралып бетмәгән, аннары тагын ике арада Тәти кызның курчак гәүдәсе дә тора иде. Бу юлы инде ул кулын күтәрергә өлгермәде, Тәти кыз аның карашыннан хәрәкәткә килде, бәләкәй учын Искәндәрнең яңагына чәпәде, шундук үкси башлап өстәле янына китте.

— Нинди башбаштаклык биредә?— дип кабатлады «Баш инженер» дигән язулы ишек бусагасында торган уртача буйлы, киң җилкәле, җилкәсенә турыдан-туры утыртып куелгандай зур башлы ир уртасы бер әү.

Тагын беркавым карашып торганнан соң, алар икесе берьюлы диярлек кычкырып җибәрделәр:

— Искәндәр!

— Сәйдәр, син?

Секретарь кыз, бу хәлдән авызын ачып, үксүен бөтенләй онытып катып калды.

3

— Нинди сәмум җиле ташлады соң сине монда, безнең якларга?— диде, ниһаять, күрешү кайнарлыгыннан бераз арына төшкәч, бүлмә хуҗасы.— Ничек безнең якларга килеп чыгасы иттең дим? Менә сиңа мә! Ничәмә-ничә еллар бит инде безнең күрешмәгәнгә! Җитмеш җиденче елны мәктәпне бетереп чыгуыбызның егерме еллыгын бик матур билгеләп үттек без. Син анда да күренмәдең. Күптән, би-ик күптән кайтканы юк аның, дип искә төшергәннәре генә хәтердә... Нигә соң әле без бу өстәл артына кереп утырдык? Менә бит ахмак... Әйдәле, әйдә, сабакташ, менә бу якка...

Бүлмә хуҗасы аркасын терәп утырган җиреннән торып, почмакка таба ике-өч адым атлады да себер карагачы белән зәвыклы эшләнгән стенадан сизелер-сизелмәс күренеп торган түгәрәк кызыл төймәгә басты. Ишек үзеннән-үзе ачылып китте һәм Сәйдәр Хәлилович Тынчурин — трест хәтле трестның баш инженеры, чәчләрен шома тараган зыялы кеше — ике кулын ике якка җәеп:

— Рәхим итеп керегез, Искәндәр әфәнде,— диде.

«Да-а-а, Аю Хәлил малае димәссең моны хәзер, — дип уйлап алды Искәндәр. — Дөнья нишләткән моны... Югыйсә, бер сала малае гына иде. Дөрес, хаклык өчен әйтергә кирәк, зирәк һәм хәйләгә маһир малай иде үзе. Бигрәк тә исәп-хисап, төгәл фәннәргә хирыс булып, математиканы су кебек эчә иде.

— Әйдә, әйдә, Искәндәр, кер әле, уз әле шушы бүлмәгә, рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк әле бер.— Сәйдәр Тынчурин кунакны алга уздырып җибәрде дә тиз генә борылып яңадан эш бүлмәсенә чыкты. Аның селекторга: «Динә, Динә дим, минем янга кеше кертмичә тор, мин. — Түбән Мәйданда», дигәне ишетелде. Аннары тагын: «Безгә чәй әзерләп чыксаң да ярар», — дип өстәде. Ләкин шунда ук селекторда нәрсәдер шытырдап алды һәм Тәти кыз тавышы: «Су юк бит», — диде.

Сәйдәр шундук Тәти кызга кырыс тавыш белән: «Тап!» — дип әйтте, тагын нидер өстәде, тик анысы Искәндәргә ишетелеп үк бетмәде, шулай да ул аның зәһәр ысылдавын, Тәти кызны ярты сүздә туктатуын чамалап өлгерде.

«Әһә-һә, Аю Хәлил малае Сәйдәр монда да сынатмый, балта сораганга көрәк бирә белә икән ләбаса».— дип уйлап алды Искәндәр. Ул арада Сәйдәр, әле генә берни дә сөйләшү булмаган сыман елмаеп, килеп тә керде. Килеп керде дә Искәндәргә күз ташлап алды: «Ишеткәнме-юкмы?». янәсе. Ләкин сабакташының йөзендә андый-мондый билгеләр күрмәгәч, бик тиз тынычланды, аңлатма биреп торуны кирәк тапмады.

— Йә, ни хәлләр соң, Искәндәр? Сөйләп җибәр әле иркенләп кенә.— диде бәләкәй өстәлнең икенче ягындагы креслога чума төшеп. Тик әңгәмәдәше сөйләгәнне көтеп тормыйча үзе башлап китте: — Менә, без шунда, шушы «тишек» җирне томалап яшибез инде. Мине беләсеңме. Чаллыярдан күчерделәр монда. Анда безнең эшләрне күргәнсең инде. Күрдеңме? Юкмыни? Ничек алай? Да-а-а! Сиңа, горурларның горуры Искәндәр Фидаяровка, андый җирләрне күрмәү бер генә дә гафу ителерлек түгел. Без анда нинди гигант корып куйдык! Күрсә-ә-әң, исләрең китәр. Кешенең акылына да, хыялына да сыймаслык Кол-лоос!— Сәйдәр пафослы сөйләвенә кул ишарәләре белән көч биреп тә бара иде. Соңгы сүзне әйткәндә кәнәфиеннән күтәрелә төште, уң кулының баш бармагын тырпайтып күрсәтте.— Ну малай, Искәндәр, анда күргәннәр безнең! Анда күргәннәр... Анда күргәннәр... Анда килгән министрлар дисеңме, ул министрларның председателе дисеңме, тагын чит илләрдән килгән меңләгән белгеч дисеңме? Во! Культураны без институтларда түгел, әнә шушы төзелештә, анда килгән иң-иң танылган язучылар, артистлар һәм тагын әллә кемнәрдән үзләштердек. КамАЗ һәм Чаллыяр төзелеше ул, Искәндәр малай, илдәге бер генә төзелешкә дә охшамаган. Магнитка диләр дә исләре китә. Ә нәрсә соң ул Магнитка? Ни техника сиңа, ни көч-куәт, ни колач киңлеге. Җыен кулак калдыгы, куылган элементлар оясы... Ә бездә? Юкка гына аны «Гасыр төзелеше» дип атамады бер француз язучысы. Кстати, менә ул язган китап, күргәнең юктыр әле. Монда без фәкыйрегез дә телгә алына.

Тәти кыз чәйнекне юри өстәлгә бәреп күчереп куйды, су тутырылган чәйнекнең шнурын розеткага тоташтырып чыгып китте. Чыгып киткәндә генә күзенең агы белән Сәйдәргә нәрсәдер ымлагандай булды.

Сәйдәр урыныннан торып басты, ул үзенең генә сөйләвен, кунакка авыз ачарга да ирек бирмәвен сизә иде бугай, шуңадыр:

— Соң, туктале, нишләп мин генә сөйлим соң, әйдәле, әйдәле, Искәндәр, син дә сөйләп җибәр... Тукта, мин чәйнекне карап килим әле,— диде һәм беравыктан Искәндәр янына таба атлый-атлый: — Ну эшләдек, эшләдек та соң инде! Ә монда-а-а? Монда андый колач киң-

легенең эзе дә юк. Быел менә дүртенче ел азапланалар. Җир кортлары сыман һаман шул җирдә казыналар. Дөрес, кое-что бар инде. Резерв җибәрү котельныен торгызабыз. Аннары тагын берничә ярдәмчел бина корылмаларын күтәрәбез. Реактор урынын казый башладык, язга, мөгаен, реактор куеласы корылмага бетон сала башларбыз. Әлегә коммуникацияләрне кору белән бимазаландык. Эш күп монда, эш монда башланмаган әле. Туктале соң, туктале. Искәндәр, кемдер миңа сине дә төзүче дигән иде бит. Чынмы соң бу? Әллә, минәйтәм, син дә?.. Булмас! Син анда, чит якларда, әйбәтләп урнашкансыңдыр инде. — Бу урында Сәйдәр яшьтәшенең өс-башына күз төшереп алды һәм гаҗәпләнүен яшермичә:

— Туктале, син соң, Искәндәр, ничек безгә, бу якларга килеп чыгасы иттең болай?..

Сәйдәр, өстәлендә затлы сигарет кабы ятуга да карамастан, эчке кесәсеннән портсигар чыгарып, сигаретны кабызды. Искәндәрнең борынына ниндидер ят, әмма таныш, ул йөргән якларда еш очраган ис килеп бәрелде.

Ниһаять, Искәндәргә сүз әйтергә чират җитте.

— Әйе, Сәйдәр, мин — төзүче. Шевченко каласындагы атом станциясен салышуга өлеш керттем. Мин, Сәйдәр, яшермим, бу якларга кайтып, нитеп... урнашып булмасмы дигән өметем бар.

— Шулаймы, бик шәп, бик шәп бу, Искәндәр, бик шәп! Бик дөрес уйлагансың. Ә бездә... мала-а-ай, эшләр! Югарыдагы үзгәрешләрдән соң... Без инде төзелешне ябарлар, безнең АЭСны төзүне туктатырлар дип тә уйлаган идек. Син бит андагы хәлләрдән хәбәрдарсыңдыр? Вот бит, малай, нинди бездельниклар, ә? Нәрсә белән шаяралар бит, ә? Шундый безответственностька юл куялар, понимаешь... Безгә министр килгән иде күптән түгел, ул, ма-а-а-лай, шундый нәрсәләр сөйләде безгә. Исләрең китә ишетсәң.

Тынчурин урыныннан сикереп торды, ашыгып барып чәйнек шнурын тартып алды һәм стенага кертеп үк ясалган бәләкәйрәк шкаф ишеген ачып чәй алды, тиз эри торган кофе алды һәм аны ике чынаякка салып бутады, аннары аларны Искәндәр алдына китереп куйды да кулларын угалап беравык көтеп торды.

— Йә, ничек, Искәндәр Өметгәрәевич, сиңа кайсысын салырга, «Золотое кольцо», өч йолдызлы әрмән коньягы бар? — диде яңадан баягы шкаф янына бара-бара. Ләкин тагын Фидаяровка сүз әйтергә ирек бирмәде, үрелә төшеп шкафтан ике кулына ике шешә алды, борылып өстәл янына килде дә кофе чынаягына коньяк өстәде, биек шешәне исә өстәлгә куйды.

— Дөрес, указ мондый нәрсәләрне тыя тыюын, ну бит инде сүз җилеме өчен генә берәрне салып җибәрсәк тә ярый торгандыр, ә? Син ничек карыйсың моңа? — дип яшьтәшенә ымлады.

Фидаяров — мәҗлесләрнең дә, мондый кабинет арты бүлмәләренең дә төрлесен күргән кеше, күрмәгән дип әйтеп булмый. Шулай да ул соңгы елдагы вакыйгалар, илдәге үзгәрешләрдән, бигрәк тә мәгълүм указдан соң мондый иркенлекләр беткәндер дип уйлый иде. Баксаң, монда әле элеккегедән ким кыланмыйлар икән. «Менә сиңа үзгәртеп кору, менә сиңа, яңарыш!..» — дип уйлады ул Тынчуринны күзәтә-күзәтә. Шулай да яшьтәшенә каршы төшәргә кыймады, кофе чынаягын кулына алды. Тынчурин рюмкага «Золотое кольцо»ны да салып куйды.

— Син үз кеше, шуңа күрә яшереп тормыйм, бераз гына монысын да җибәргәлим инде мин, ярасс,— диде ул елмаеп. Фидаяров күрде: бу юлы инде Тынчуринның күзләрендә баягы очрашудан туган шатлык чаткылары әллә нинди бер томанлы караш белән алмашынган иде.

— Ярый алайса,— диде Фидаяров чынаякны уң кулының ике

бармагында күтәреп тоткан килеш.— Очрашу хөрмәтенә булсын...

Искәндәр кофеның яртысын гына капты да чынаякны яңадан өстәлгә куйды. Тынчурин исә кофе артыннан алтын исемлесен дә эчеп җибәрде. Фидаяров монысын ук көтмәгән иде, әлбәттә.

— Туктале, яшьти, туктале... Мин сиңа тагын бер сюрприз ясыйм әле.— дия-дия Тынчурин урыныннан купты, чәйнек торган өстәлдәге телефон янына барып, аны берничә мәртәбә әйләндерде дә, беркавым көтеп алганнан соң трубкага: — Ашханәме? Директорыгызны? Нәрсә син анда, матурым, беренче көн эшлисеңме? Тынчурин бу. Әйе, әйе. Тынчурина апаңны чакыр әле.— диде. Искәндәргә борылып трубкага күрсәтте.— Исләрен китерәм әле мин аның, китерәм. Әй, синме бу? Менә нәрсә, карчык, син давай әле бүген, берәр сәгатьтән өйгә кайт әле. Нәрсәгәме? Бик кызыклы очрашу булачак бүген. Әйе. Кунак бар. Без аның белән берәр сәгатьтән кайтырбыз. Во, молодчага да инде үзең. Ү-ү-ү-бәм күзеңне.

Кызганыч, бик кызганыч, ләкин бу минутта Искәндәр яшьтәше Сәйдәрнең кем белән сөйләшүен башына да китермичә утыра иде. Аның башында хәзер: «Минем кайдан кайтуымны белгәч, нишләр бу Аю Хәлил малае?» — дигән бердәнбер уй иде. Әмма Сәйдәр андый сорауны бирүдән, бу якларга «төпләнергә» дип кайткан яшьтәшенең хәлен белешүдән ерак иде. Бу минутларда аның бар белгәне үзенең нинди олы дәрәҗәгә ирешүен, нинди кодрәтле кеше икәнлеген күрсәтү, турысын гына әйткәндә, ярыйсы гына тыйнак торган, киеме дә гап-гади булган, муенында галстугы да күренмәгән, куллары эштә ныгып каешланган Искәндәр Фидаяров алдында мактану, «Менә син яшь чакта горур идең, акыллы идең, мәктәптә дә сине төрлечә күтәрәләр иде, ә хәзер син кем дә мин кем?» дип шапырыну иде. Искәндәр, билгеле, моны баштагы минутларда ук сизде. Ләкин, нишләмәк кирәк, бер килеп кергәч, очрашкач та монда утырырга, Аю Хәлил малае Сәйдәрнең кыланмышларына түзәргә туры килә иде.

— Без дә гомерне бушка уздырмадык, яшьти, институтын да бетердек, минем математикага баш шәп эшләгәнне беләидең инде син, хезмәт баскычыннан да шактый гына күтәрелдек... Дөрес, мине әле мондый зур урынга беренче тапкыр куюлары. Мин Чаллыярда шактый гына Кама буе төзелеш берләшмәсе җитәкчесенең ярдәмчесе булып эшләдем. Аннары, все таки, СМУга урынбасар булып күчтем. Авыр булды, малай, төзелешкә күнегеп китүләре! Бер башлагач та китте аннары үзе. Менә хәзер трестның баш инженеры иттеләр. Зур эшләр башкарачакбыз монда. Бәлки әле Герое да бездән ерак йөрмәс аның. Ярар, ярар... Син соң, Искәндәр яшьти, кайларда йөрдең дә ничек үзебезнең якларга кайтасы иттең? Әллә, мин әйтәм, яндыңмы? Ха-ха-ха...

Фидаяровның иң авырткан җире иде бу. Ләкин ул хәзергә Тынчурин алдында бөтен тарихын да сөйләмәскә булды, бары тик кыска гына итеп әйтте:

— Өстенә бастың, Сәйдәр, яндым мин. Хәер, мин үземнең хаклыгыма бер генә мыскал да шикләнмим, шулай да яндырдылар мине. Турысын әйтим, минем трест управляющиена бәреп керүемнең сәбәбе дә шунда. Менә эшкә алмыйлар. Тәҗрибәм зур минем. Промышленность төзелешендә байтак эшләдем мин. АЭС төзелешен бик яхшы беләм дип әйттем. Мин хәзер, Сәйдәр, ерак җирләрдән кайтып киләм. Дүрт ел утырып кайтуым...

Сәйдәр тыңлады, берничә тапкыр бүлдерергә омтылып караса да, Искәндәрнең ышанычлы, нык тавыш белән, бүлдерергә урын калдырмыйча ихтыяри сөйләве аны, зур җитәкчеләр каршында буйсынырга өйрәнгән кешене, туктатып килде. Ниһаять, Фидаяров үзе үк туктап: «Йә, моңа ни әйтәсең инде хәзер».— дигәндәй, яшьтәшенә карады.

Бүлмәдә тынлык урнашты.

Чирек гасыр буена бер-берсен күрмәгән-белмәгән ике авылдаш, яшьтәш һәм классташ, хәзер икесе дә ир уртасына җиткән ике кеше бер-берсенә карашып утырдылар...

Әйтеләсе сүз әйтелгәнгә күрә, Искәндәр үзен иркенрәк хис итә башлады, өстеннән ничәмә-ничә потлы зур капчыкны шуытып төшергәндәй булды. Әле генә сандугачның үзе булып сайраган Сәйдәрнең генә сөмсере коелып торды. Моны күргәч, Искәндәр үкенеп куйды: «Бәлки, әйтергә кирәк булмагандыр? Без бит аның белән беркайчан да дус булмадык. Өстәвенә, мөнәсәбәтләрне дә җайлый алмадык. Дөрес, каршылык тышка бәреп чыга алмады. Шулай... китәргә кирәк моннан. Яңа гына игелекнең үзе булырга тырышып утырган Тынчурин әнә бит ничек кара коелып төште... Чыгыйм булмаса».

Искәндәр урыныннан торды: нияте — саубуллашып чыгып китү иде. Ул өстәл яныннан ике адым ишеккә таба атлады, ләкин аны әллә нинди бер көч туктатты. «Тукта, түз, Искәндәр, әле бит ул сиңа бер сүз дә әйтмәде. Түз. Кая барасың? Бу синең туган-үскән ягыңдагы төзелеш. Син шушы җирдә эшләргә, тормышыңның өзелгән юлын шуннан ялгап китәргә дип кайттың бит»,— дигәндәй булды.

Тынлык хөкем сөргән шушы ике-өч минут эчендә Сәйдәр дә үз-үзен кулга алган, аңарда тагын «яхшы булу» теләге уянган иде бугай. Ни әйтсәң дә аның каршында түбәнчелек күрсәтеп, аның хәлиткеч сүз әйтүен көтеп торалар. Һәм ул аны әйтергә тиеш иде.

— Тукта, Искәндәр, тукта, утыр яңадан урыныңа,— диде, ниһаять, Сәйдәр.— Көтмәгәндә генә шундый хәбәр ишетү, үзең беләсең, теләсә кемне дә аптырашта калдырыр иде. Туктале, туктале... Ничек алай булып чыкты соң дисәм? Сөйләмәссең инде, хәзер аның вакыты да юк бит әле.

Ул сүзен тәгәлләр-тәгәлләмәс борын идән уртасында басып торган Искәндәрне әйләнеп узды да кабинетына чыга башлады. Фидаяров аның таза һәм нык гәүдәсен, бераз гына базыгая башлавына карамастан, төзлегенә карап озатып калды. Әмма бу гәүдәдә ниндидер, бары тик тәҗрибәле күзләр генә күрә торган, картаюга таба илтә башлаган билгеләр бар иде кебек.

...Сәйдәр эш өстәле янына килеп утыргач та сөйләшә белә икән. Аның тавышы бөтенләй үзгәрде, икенчегә әверелде, хәзер инде ул тавышта һич каршы төшәргә урын калдырмый торган, шул ук вакытта сизелерлек масаю, башкаларга кимсетеп дәшә торган билгеләр — корыч чыңы керту бар иде. Аның кул астында эшләүчеләр моны яхшы беләләр, күрәсең, чөнки кадрлар бүлегендәге баягы хатын аңа телефоннан нәрсәдер әйтә башларга өлгермәде, Тынчурин аны бүлдерде.

— Әйткәнне үтәгез,— диде ул.— Калганы өчен мин җаваплы. Искәндәр Фидаяровны хәзер үк эшкә алыгыз. Кем итепме? — Сәйдәр кулы белән телефон трубкасын каплады һәм шулай ук арттагы бүлмәдән бирегә чыгып баскан яшьтәшенә карап: — Кем итеп алсыннар соң сине, Искәндәр? — дип сорады.— Белемең югары диден бит әле. Ә, әйе, шулай шул. Әйдә, ярар, башың кирә торсын,— диде дә, Искәндәрнең үзе белән килешеп тә тормастан, кадрлар бүлегендәге хатынга: — Бригадир итеп алыгыз. Нәрсә? Мин ике сөйләргә яратмыйм, иптәш Камышева. Һәм үз сүзләрем өчен үзем җавап бирергә яратам. Беләсез? Белсәгез шул: Фидаяровны... Документлары юк? Ничек юк? Паспорты юк? Хезмәт кенәгәсе? Яңаны языгыз. Паспортны ул эшкә урнашып яшәр урын тапмыйча ничек алсын ди? Алыр. Калганын тутырыгыз. Элеккеге урынына запрос ясагыз. Анысы сезнең эштер бит... Во-во! Димәк, Искәндәр Өметгәраевич Фидаяровны эшкә бригадир итеп аласыз һәм иртәгәдән аңа бригада туплыйсыз. Ниндиме? Комплекслы бригада. Ул безнең өчен хәзинә. Ул, иптәш Камыше-

ва, атом станциясе төзелешендә эшләгән кеше.

Сәйдәр трубканы куйды да Искәндәргә таба борылып: «Менә бит, тиз генә аңлатып буламыни аларга?» — дигән сыман кулларын җәеп күрсәтте, маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен сөртеп алды.

— Киттек әйдә, икәү керәбез.— диде.— Югыйсә тагын берәр нәрсә уйлап табарлар. Бюрократлар...

Алар икәүләшеп кабинеттан чыктылар. Сәти кыз иреннәре әле дә булса турсаеп тора иде. Ул Искәндәрне күргәч үк арты белән борылып басты һәм, Тынчуринның да аның белән чыгып китүенә гаҗәпләнеп, ни кылырга белмичә, озын тырнагын каезларга кереште.

## 4

Көз дисәң көз инде: бер карасаң — ал да гөл, икенче карасаң — егыл да үл, дигәндәй, үзгәрә дә куя һава. Хәер, көзнең дә соңгы көннәре бара. Озакламый үзенең ачы бураннары, чатнама суыклары белән кыш җитәр... Искәндәр баягынак автобустан төшеп, чокыр-чакыр аша былчырак ерып, «Атомэнергострой» тресты бинасын эзләп килгәндә көн ачылыбрак киткән кебек иде. Автобуста килгәндә çирәкмирәк кар бөртекләре күренгәләгәндәй генә иткән иде, аннары ул ымдык яңгыр булып дәвам итте. Хәзер исә инде кар ягы көчәя төшкән. Җил дә сиртмә шикелле тыгызланган. Баягы авыр болытлар исә тагын да куера төшкән. Хәзер алар теткәләнеп беткән иске юрган кисәкләренә охшаш. Әнә шушы теткәләнгән кисәкләрдән туктаусыз су катыш кар ява. Кешеләргә әнә тегендәге икешәр катлы, җыйнак һәм пөхтә тулай торакларга, шәһәр буласы урынның хәзерге актарылып ташланган җиренә, теге якта инде күтәрелеп-күтәрелеп килгән бишәр, тугызар катлы йортларга, трест бинасы янына сыенышып, билгеле бер тәртиптә урнашкан вагоннарга да ява. Гомумән, көзге көннәр, әнә шушы явымнары белән күңелгә сагышлы моңсулык өсти, шуңадырмы, ерак-еракларга күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга олагасыны китерә иде.

Бүгенге көн Искәндәр өчен аерата авыр булды. Башта көн яктысын һәм тирә-якны күрмичә диярлек автобуста килде. Аннары үзенең ярты гомере үткән төзелеш ыгы-зыгысы да күңеленә шатлык түгел, ниндидер югалту сагышын өстәде. Алда — билгесезлек. Кисәккисәк булып актарылган болытлар кебек үк караңгы билгесезлек иде. Ул сагышны авылдашы, яшьтәше һәм сабакташы Сәйдәр белән очрашу да баса алмады. Киресенчә, бу очрашу Искәндәр күңелендә шатлык уятмады гына түгел, тамак төбендәге үкенеч төерен арттырды гына. Ул Сәйдәрнең кем икәнлеген яхшы белә иде, хәзергесен әлегә төшенеп өлгермәде. Эшкә урнашырга булышуына, билгеле ки, рәхмәт. Тик барыбер бу очрашу аның күңелендә авыр тәэсир калдырды. Ник дисәң, Сәйдәр Тынчурин кайсыдыр сыйфаты белән Искәндәргә үзе каршы чыккан икейөзлеләрнең дәвамы сыман тоелды. Ярый ла, беренче карашка гына шулай булса. Ярый ла Тынчурин теге Карамусаевларның мондагы дәвамы булып чыкмаса...

Гаҗәп, бик гаҗәп, дип уйланды Искәндәр, әллә чынлап та инде соңгы еллардагы очышы һәм ул биеклектә кала алмыйча мәтәлеп төшүе, үзе күренмәгән, ләкин барлык нәрсәне дә астыртын юллар белән хәл итеп утыручыларга каршы көрәштә авызы-борыны кан ителеп җиңелүе аның омтылышларына, тормыштагы максатына хилафлык кылдырмаса да, һәркайда хакимлек иткән барыберлек бактерияләрен йоктырдымы? Нык ихтыярлы Фидаяровны яшәү принципларыннан, димәк, максатыннан чигенергә, алай гына да түгел, алардан баш тартырга ук мәҗбүр иттеләрме? Әллә соң ул хәзер үзендәге

ышанычны гына түгел, кешеләргә булган ышанычын да югалттымы? Нигә?

Соңгы вакыйгалар, бигрәк тә Апрель җиле алып килгән сафлык Искәндәргә көч өстәп, аны яңадан тормыш дулкыннары арасына көрәшкә, хыялындагы эшләргә ашкындырмасмыни? Әнә бит нихәтле үзгәреш! Бәлки, алар бары тик газеталарда гынадыр? Ә бәлки алар матбугат әһелләре уйлап чыгарган ялтыравык нәрсәләрдер? Бәлки шушы саф җилне пычратырга, аңа каршы көрәшүчеләр, көч өстәүчеләр дә бардыр? Хәер, ничек инде булмасын ди? Әнә бит, Искәндәр газетадан укыды: Карамусаев һәм аның кебек тагын берничә бәдбәхетне бәреп төшереп кенә калдырмыйча, аларны кулга алдылар һәм җинаять эше ачтылар. Әнә бит шушы Карамусаев эшләрен тикшергән вакытта кемнәрдер Фидаяровның «эше»нә дә юлыкканнар. Югыйсә аның тагын ике елга якын тайга урманнарындагы канечкеч черкиләрне туендырасы бар иде бит әле. Хаклык җиле аны ерак җирдән эзләп табып иреккә чыгарды түгелме соң? Алай гынамы, аңа үзе эшләгән якларга кайтырга, андагы яңа җитәкчеләргә күренергә куштылар.

Фидаяров алай итмәде. Ул инде нахак эшнең кара пәрдәсе ябылган, шуның аркасында кара көннәр кичергән якларга беркайчан да кайтмаячак. Билгеле, анда яңадан күтәрелүе, сәләтенә тәңгәл эшләрне башлавы җиңелрәк булыр иде. Турысын әйткәндә, анда аны, бәлки, Карамусаевтан җәберләү кичергән кеше буларак игътибар үзәгенә куярлар иде.

Хәер... Инде Фидаяров та күп нәрсәне башкача күрә, бөтенләй икенче төрле аңлый. Киресенчә, шушы пычраклыкларны кабул итмәгәнгә, аның кабахәт кочагына ташланмаганга күрә тәгәрәде түгелме соң Фидаяров күпме көч түгеп менгән тау башыннан? Шул эшнәлек ялчылары аны «беткән кеше»гә чыгардылар түгелме соң?

Кайдан һәм кайчан башланды соң әле аның аларга каршы атлаган адымнары?

Бу сорауга җавапны Искәндәр бетмәс-төкәнмәс дәвергә сузылган дүрт ел дәвамында эзләп-эзләп тә таба алмады...

...Хәер хәлләрнең барысы да моннан җиде ел элек башланды. Ләкин ул чагында әле үз дигәнендә тора белүче, хаклыкка ышанган Искәндәр нибары өч елдан үзенең тәвәккәл башы җинаятьчеләр карьясына тәгәрәр дип уйлап та карамаган иде.

Көннәрнең берендә, көтмәгәндә-уйламаганда, Фидаяровның укытучы-завуч булып эшләп йөргән хатыны Нәркизәне өлкә шәһәренә конференциягә чакырдылар. Аның нишләптер ул конференциягә барасы килмәде. «Минем бит эшем муеннан, мәктәпне уку елына әзерләп бетерәсе бар. Директорга ничә ел буена көтеп йөргән путевкасын бирделәр. Трускавецка китте»,— дип бетеренде ул. Күндерделәр. Кем, ничек моңа ирешкәндер — Искәндәр белмичә калды. Иртәгә конференция дигән көнне өйгә гадәттәгедән иртәрәк кайтты, җыештырырга. Искәндәрнең һәм кызлары Нәзирәнең кирләрен уып үтүкләргә, анары тәмле итеп камыр ашлары пешерергә дә өлгерде Нәркизә.

Табын янына өчәүләшеп утырдылар. Чөкердәшеп, һәркайсы үз кайгысы-мәшәкатен генә сөйләп түгел, башкаларныкын да уртаклашу җаен тапты. Искәндәрнең квартал планы яна иде. Хатын-кызларга бу хәл әллә ни тәэсир итмәсә дә: «Кайгырма, әти, син аны барыбер үтисең инде. Хәзергәчә сынатмадың бит әле, инде дә сынатмассың»,— дип тынычландырдылар. Аннары Нәзирәнең «кайгысын» кайгыртырга керештеләр. Эш шунда ки, кызлары быел сигезенче классака керәчәк. Ул үзе күптән инде: «Мин, әти-әни, унынчы класска хәтле мәктәптә укып йөрмәм инде, тотармын да техникумга тапшырырмын»,— дип сөйләнә иде. Баштарак аның бу ниятен балалык мавыгуына санадылар, юньләп игътибар бирмәделәр. Чөнки Искән-

дәр белән Нәркизә икесе дә (дөрес, Искәндәр кичке бүлекне тәмамлады) югары белемле кешеләр, бердәнбер кызларының да шундый белем алуын телиләр иде. Бигрәк тә әнисе шулай ди иде. Искәндәр бу юлы кызы ягындарак булды. «Әгәр дә мәгәр чынлап сөйләсәң, кызым, барырсың-керерсең техникумга. Техникумда да бик әйбәт белем алырга була»,— диде. Нәркизә шунда ук каршы төште: «Кит аннан, башта ми булмаса, ике аякка көч килә ул, балага нинди акыл биреп утырасың, булмаганны»,— дип өтәләнеп алды. Ләкин ул вакытта ата белән ананың: «Кайда соң ул техникум, нинди һөнәр иясе булырга телисең?» — дигән сорау бирергә башларына да, телләренә дә килмәде.

Ниһаять, икенче көнне иртүк Искәндәр хатыны Нәркизәне үзенең җитез «Жигули»енә утыртып махсус автобус янына илтеп куйды.

Әй, Искәндәр, белгән булсаң иде син шушы минутларда хатыныңны нинди юлга озатып куйганыңны! Белгән булсаң, аны автобуска үзең илтеп утырту түгел, конференция дигәннәренә бөтенләй якын җибәрмәгән булыр идең. Мең дә бер сәбәп тапкан булыр идең, әмма аны өлкә шәһәренә җибәрмәс идең. Кызганычка каршы, адәм балаларына күрәчәген күрә белү сәләте бирелмәгән. Искәндәр дә шул адәми затларның берсе буларак, ул көнне башына һичбер төрле шик-шөбһә китермәде. Баштанаяк үз мәшәкатьләренә күмелде.

Нәркизәне икенче көнне кичкырын кара «Волга»га утыртып кайтарып куйдылар. Юк, өй турына түгел, әгәр дә мәгәр өй турына кадәр кайтарган булсалар, Искәндәр аны күрмәгән-белмәгән, соңыннан озын теллеләр җиткерсәләр дә, ышанмаган булыр иде. Ә болай... Ә болай ул Нәркизәнең машинадан төшкәнен, аннары аны озатучы кешенең аны үз тәненә кысып битеннән үпкәнен үз күзләре белән күреп калды. Гөнаһ шомлыгына каршы, Искәндәр эштән кайткач та, Нәркизәнең юклыгын белеп, сөттер-катыктыр алырга дип якындагы кибеткә китте. Ләкин ул азык-төлек артыннан бик сирәк, әллә нигә бер генә бара иде, шуңа күрә сөт һәм катыкның иртәнге якта ук сатып бетергәннәрен белмәде. Алар йөри торган кибеттә сөт тә, катык та булмагач, үзе җитәкләгән идарә янындагы кафеда андый нәрсәләрне күргәләвен искә төшереп, ул шунда таба атлады. Илле-алтмыш адым үткәч тә ул «морс» тутырылган мичкәгә юлыкты. Балачагыннан ук шушы «морс» дигән кызыл суны үлепләр ярата иде, чөнки сабан туена, район үзәгендәгесенә баргач та ул булыр-булмас көмеш һәм бакыр акчаларын шушы «морс»ка гына тота иде. Әмма беркайчан да морс эчеп туйганы булмады аның. Бу якларда исә ул эчемлекне чат саен сатып торалар. Хәзер дә Искәндәр шушы татлы суны авыз итмичә узып китә алмады, чиратка басты. Һәм, ике-өч минут басып тордымы-юкмы, үзеннән унбиш-егерме адым чамасы үтеп туктаган кара «Волга»ны күрде. Кем белсен, язмыш дигән нәрсәнең нииндидер чакыруы булган, күрәсең: нәкъ менә Нәркизә машинадан төшкән мизгелдә Искәндәрнең күз карашы шушы якка юнәлде. Башта күзләре кара «Волга»га игътибарын җәлеп итмичә, йөгереп кенә узды, әмма теләсә генә кайда, теләсә күпме кеше арасыннан аерылып торган таныш һәм якын хәрәкәтне чамалап, таш диварга терәлгәндәй туктап калды. «Нәркизә?! — диде ми җисемендәге бер җепселдән ашыгып килеп җиткән сорау.— Нинме соң бу?»

Әйе, Искәндәр күрде, үз күзләре белән күреп ышанды: машинадан төшүче асыл зат хатыны Нәркизә иде. Әмма барыбер ул әле Нәркизәнең машинага утырып кайтуына яман мәгънә салмас иде. Икенче бер мизгелдә Нәркизә артыннан чыккан ярыйсы гына тулы гәүдәле, шомырт кара чәчле кеше, аны тәненә кысып кочты һәм бит алмасыннан үбеп алды. Шундук Искәндәр ул кешене таныды — берләшмә җитәкчесе Карамусаев иде ул.

Искәндәр кибеткә чыгуын, аннары кафега таба баруын, хәтта су чиратында торуын тәмам онытты. Озак кына урамда йөрде һәм туктаусыз диярлек бер үк сүзләрне кабатлады: «Сабыр бул, Искәндәр, сабыр бул, тынычлан. Бәлки нинди дә булса очраклы хәл генәдер? Үзеңнең хатыныңа тап ташларга, бигрәк тә бу хәлне күрүеңне аңа әйтергә, аны да, үзеңне дә кимсетергә ашыкма, яме»,— диде ул. Һәм күңеленә шул сүзләрнең мәгънәсен сеңдерүгә иреште, өйгә үзүзен берни булмагандай гадәти тотарга күндереп кайтып керде. Дөрес, Нәркизә (хатын-кыз зирәклегенә нинди генә бәя бирсәң дә, ул бәя тулы булмаячак иде) аның үз табагында түгеллеген бер карауда ук чамалап алды. Хәер, игътибар биребрәк караганда, Искәндәрнең һәрвакыт сәламәт йөзенә иңгән акбүз төсен күрмичә калу мөмкин дә булмагандыр. Шулай да Искәндәрнең ихтыяры, аның сабырлык белән эш итәргә күнектерелгән акылы бирешергә теләмәде. Үзе корган гаилә бурасын бер селтәнүдә сүтеп-туздырып ташларга ашыкмады ул. Нәркизәнең ара-тирә: «Ни булды сиңа, Искәндәр, нигә төсең качкан?» — дип соравына каршы бары тик: «Арыдым мин бүген, Нәркизә»,— дип җавап бирергә ашыкты. «Ә син, син соң нинди тәэсирләр алып кайттың конференциядән?» — дип сорады. Юк, ул Нәркизә нәрсә әйтер, баягы хәлне, үзенең ниндидер «Волга» белән кайтуын, кемнеңдер үзен озата килүен әйтерме дип уйламаган да кебек иде. Ләкин, күңел дигән нәрсә үзеннән-үзе шушы сорауларга юлыгып, үзенең ерак төпкеленнән тиешле җавапларны тартып чыгарырга уйлаган, күрәсең... Нәркизә — бүтән вакытларда өлкә конференциясе, үз шәһәрендәгесен әйтеп тә торасы юк инде, мәктәптәге хәлләрне Искәндәр кайтып керү белән бәйнә-бәйнә сөйләргә күнеккән Нәркизә — бу юлы иренең соравына җавап бирү урынына, дәшми-нитми генә, ишетмәгәнгә салышып, арты белән борылып басты һәм «Әй»,— дип кул селтәү белән канәгатьләнде, кухня ягына ашыкты.

Искәндәр белер-белмәс килеш тавыш чыгармаска булды: «Әгәр дә мәгәр шундый хәл бар икән, бәлки, Нәркизә үзе дә әйтер, әйтмичә булмас,— дип тынычландырырга тырышты Искәндәр үзен.— Без бит ул кадәр сөеп-сөешеп, мәхәббәт романнары кичерешеп өйләнешмәдек. Дөрес, моңа карап без бер-беребезне хөрмәтләмичә яшәмәдек. Әмма ләкин хәзергәчә, өйләнешеп яши башлаганнан соң унбиш ел гомер үткәчтен дә, безнең арада чын мәхәббәт яралып китә алмады. Без берничә мәртәбә турыдан-туры сөйләштек: әгәр инде беребезнең яшисе килми икән, рәхим итсен, тартып-сузып тормыйча турысын әйтсен, хыянәткә юл куймасын, дип сүз куештык».

Аннары... аннары инде Фидаяровка ябырылган мәшәкатьләр, аның җилкәләренә салынган җаваплылык андый шикле-шөбһәле уйларга урын, хатыны артыннан күзәтеп йөрергә вакыт дигән нәрсәләрне калдырмады. Тагын бер айдан, «бу капчыкны күтәрергә синең көчең җитәрме?» дип сорап та тормыйча, аны зур бер трестка тиң төзелеш идарәсенең башлыгы итеп куйдылар.

Кызганыч, ләкин бу көннәрдә һәм аннан соң да ике ел буена Искәндәр Фидаяров үз язмышына нинди кодрәт иясенең канатлары кагылып киткәнлеген белмичә йөрде.

Шулвакыт, пошындыргыч уйларны бүлдереп, каяндыр өстән: «Әйдәле, кер әле монда, Искәндәр,— дигән тавыш ишетелде. Фидаяров ирексездән борылып өскә карады. Анда, икенче катның ачык тәрәзәсеннән, Хәйдәр карап тора иде.— Кер, әйдә, алыштыр аягыңдагы туфлиләрне. Безнең урамнарда әлегә андый җыйнак нәрсәләр белән йөрерлек түгел. Бездә иң ходовой аяк киеме гап-гади резин итек булыр...»

Искәндәрнең күңеле әллә нишләп китте: аның турында кемдер кайгырта иде. Ул борылды да трест бинасының ишеген ачып керә-

керешкә: «Ә мин яшьтәшем һәм сабакташымның һәр хәрәкәтеннән гаеп табарга тырышам. Әгәр дә ул кайчандыр, яшьлек елларында миңа караганда бәхетлерәк булган, тормышта миңа караганда азрак кыйналган һәмирешәсе үрләренә тизрәк һәм җиңелрәк ирешә барган икән, аны мин дә бер төрле гөнаһларда гаепләү дөрес була алмый. Искәндәр мәрмәр плитәләр салынган баскычтан икенче катка ашыкты.

Сәйдәр аны кабул итү бүлмәсендәге шкафтан резин итекләр алаала каршылады.

— Менә, Искәндәр Гәрәевич... киеп җибәр,— диде ул резин итекләрне ике кулына тоткан килеш сузып.

— Рәхмәт, рәхмәт, Сәйдәр... Болай ук борчылмаска идең...

Күңеле йомшарудан булса кирәк, Искәндәрнең тамак төбенә ачы таш сыман төер килеп тыгылды.

5

Фирәзә иртәдән бирле үзенә урын табалмыйча, җанын кая куярга белмичә йөрде. Моның сәбәбен ул таң алдыннан гына тузга язмаган төш күреп уянуыннан һәм аннан соң инде кабат йоклый алмавыннан күрде. Керә бит кешенең башына шундый кеше ышанмаслык ямьсез төшләр... Фирәзә, үзе дә рәтләп төшенеп бетмәгән әллә нинди бәхәскә кереп, ире Сәйчуриннан аерылырга йөри, имеш. Аларның өйләрендә хәзергедән бик күп, бик күп мәртәбә күбрәк кыйммәтле әйбер тулы, имеш, алтын-көмеш дисеңме, асылташ һәм бәллүр дисеңме — һәммәсе дә чутсыз, имеш. Аның өстәвенә бәйләм-бәйләм, нәкъ банктагы шикелле төгәл санап куелган акча өемнәре дисеңме, арада ире чит илгә баргач яшереп алып кайткан, зәңгәрсу яшькелт төстәге доллар кәгазьләре дә бар, кыскасы, җанын ни тели — шул тулып ята, имеш. Фирәзәнең дә, Сәйдәрнең дә шушы нәрсәләргә нәфесләре төшкән һәм алар бу байлыкны берсеннән-берсе яшереп йөриләр, имеш. Бүлмәдән бүлмәгә. Берсе яшерә, икенчесе кереп таба, икенчесе яшерә, тагын беренчесе ул урыннан алып, бүтән төшкә куя, имеш. Шуңа карамастан, ул нәрсәләр бер генә дә кимеми, өй тулы, шкафлар тулы, стенка һәм өстәл өсләре тулы, имеш. Күпмедер вакыт шулай азаплангач, бичарадан ничара булып беткәч тә Фирәзә ни күзләре белән күрсен, иге-чиге күренмәгән чиратның очына барып чыкты һәм хатын-кызлар ягының койрыгына ук басты, имеш. Бу никах теркәүчеләр чираты икән. Ләкин анда торучылар үзләренең өлешен — кем белән никахлашасыларын — белмиләр, имеш. Янәмәсе, басып торасың-торасың да, чиратның никах теркәүче сәркәтипләр өстәле янына җиткәч кенә ир-егетләр сафында туры килгән кеше белән язылышасың. Ир-атлар да, хатын-кызлар да шуңа риза-бәхил, имеш... Ярый, торалар болар, торалар... Бер кереп баскач, ул чираттан чыгу, кире чигенү һич мөмкин түгел, имеш. Ярый, торалар болар, торалар, тик Фирәзә инде бу хәлгә риза-бәхил түгел, имеш. Ләкин ничек чыгып котылырга икәнлеген һич кенә белми һәм уйлап табалмый. Берзаман үзеннән алдагыларның аяк астына төбәгән күзләрен күтәреп читкәрәк караса, ни күрсен, аңа таба бер кеше йөгерә, имеш. Кулларын болгый-болгый, әллә нинди аңлашылмас телдә әллә нинди сүзләр кычкыра-кычкыра бире таба чаба. Үзе чаба, ләкин бер генә дә якынаймый, имеш. Шулай булса да Фирәзә ул кешене таный, тик исенә генә төшерә алмый. Чөнки алар инде моннан мең ел элек очрашканнар да шул гомер эчендә бүтән бер тапкыр да күрешмәгәннәр, имеш. Тукта, бу соң минем күңел хисләремне бирмәгән, әллә нинди аяусыз, бары тик уңҗиде яшьлек кызларга гына хас аяусызлык белән мәхәббәтен кире кагып килгән кешем түгелме?

Ис-кән... дәәәр түгелме соң бу? Каян килеп чыккан ул? Моннан мең ел элек үк, Фирәзәнең үткиде яшьлек чагында ук, галәм чиксезлегендә ыгы-зыгы килгән янар ташлар арасына кереп югалган иде түгелме соң? Шулай иде бит... Карале, дип уйлый Фирәзә, галәмнән җиргә төшеп булмый дип әйтәләр, бер генә дә дөрес түгел икән ләбаса... Менә бит ул, менә бит Искәндәр төшкән. Исән-сау килеш Фирәзәгә таба йөгерә, аңа ниндидер сүзләр әйтә-әйтә йөгерә. Мөгаен, ул безнең моннан мең ел элек яшәгән телебездә, ул вакыттагы сүзләр белән сөйләшә торгандыр. Аңа соң галәм барыберлегендә мең елны үткәрүе ни торган? Аның өчен нибары бер мизгел генә инде ул. Шуңа да күрә һаман да унсигез яшендәге кебек матур, һаман да шундый житез. Әле дә Фирәзәгә, бары тик Фирәзәгә таба гына омтыла ул... Юк инде, мең ел буена яшәп тә үзенең көчен югалтмаган мәхәббәтне Фирәзәнең кире кагасы юк хәзер. Ул аны бүген, менә хәзер үк кабул итәргә тиеш. Фирәзә аның белән, Искәндәр белән, менә шушы чират агымы житүгә никахлашырга тиеш. Ләкин аны ничек барып тотарга соң? Андый көчне кайдан алырга? «Йә, илаһи күк йөзе! — дип кулларын өскә таба суза Фирәзә,— йәгез, галәм чиксезлегенә нур бөркеп торучы сансыз йолдызлар! Алыгыз мине бу төштән суырып, алыгыз, зинһааар, а-а-а-лы-гы-ыз!!!»

Һәм ул бу мәңгелек чираттан, аның тарту көченнән тарихта беренче кеше булып ычкына...

Ычкына да үзенә каршы йөгергән Искәндәргә таба оча башлый, имеш. Иксез-чиксез даладагы түмгәкләргә, меңәр еллык кылган башларына тибеп-тибеп ала да өскә күтәрелә һәм Искәндәренә таба якыная, имеш. Ниһаять, алар кул сузымы арага килеп житәләр. Фирәзә дә, Искәндәр дә бер-берсенең кулыннан тотарга, күрешергә, аннары инде беркайчан да шушы кулларны аермыйча Җир шары буйлап мәңгелек сәяхәткә, илләр һәм диңгезләр гизәргә хөкемләнәләр, имеш...

Әйе, бу урынлы-урынсыз, вакытлы-вакытсыз һәм теләсә генә нинди шашкын хыял да барып житмәслек, таң алдыннан кергән тузга язмас татлы төш көннең көн буена кәефне бозу гына түгел, әледән-әле искә төшеп, яңарып, һаман да күңелне кытыклап торды. Фирәзә берничә тапкыр үз-үзенә: «Ташлале, юк белән булышырга вакытыңны кая куярга белмисеңме, әллә инде эшең беткәнме соң синең», дип тыелырга, ул төшне бүтән исенә дә кертеп чыгармаска тырышып карады... Инде бер уянганнан соң Фирәзә йоклый алмады. Йоклавын йокламады, әмма ләкин бу төш аның күңелен шулкадәр кузгатып җибәрде ки, ул инде янындагы иренең вакыт-вакыт гырылдап алуын да, йокы аралаш ара-тирә әле бер, әле икенче кулын сузып аны кочаклавын да сизмәде. Аннары гына, Сәйдәрнең кулы тик тормыйча йомры-йомры, ташып тулган, ләкин бер генә тапкыр да бала авыз итеп карамаган күкрәкләрен учлап-учлап тота башлагач кына Фирәзә үзен-үзе белештермичә, шул ук вакытта сак булырга, ирен уятмаска тырышып аяк очына таба шуды, аннары юрган астыннан төшеп халатын киде дә йокы бүлмәсеннән чыгып ук китте. Өстәлдәге бәллүр савыттан җимеш суы салып бер генә капты да шуның белән сусавын бастыргандай итте. Аннары үзе дә ни өчен икәнен аңламыйча урта бүлмәгә керде. Монда Фирәзә белән Сәйдәрнең эш бүлмәсе иде. Сәйдәр үзенең эше белән шунда утыра, ул булмаган чагында Фирәзә дә үзенең отчетларын шунда кереп караштыра. Бу бүлмәнең өч диварына да китап киштәләре куелган, идәннән түшәмгә чаклы — китап та китап... Фирәзәнең бар рәхәте әнә шушы китапларда иде. Монда килгәнче, Чаллыярда чагында шуларда иде. Бирегә килгәч тә аңа ашханәне житәкләргә куштылар, Фирәзә карышмады. Дөрес, Сәйдәр аңа каршы төшеп карады: «Анда ниең калган, бу бит сиңа

әллә кайчангы шәһәрдәге кафе-фәлән генә түгел, монда эш-че-ләр ашханәсе. Яңа ярала торган шәһәрдә... Анда тәртип беркайчан да булмаячак. Анда бары килмешәкләр генә тулып ятачак»,— дип үртәшергә дә азапланды. Ләкин Фирәзә аның авызын тиз томалады. «Әгәр дә мәгәр, Чынчурин, мине өеңдә генә биклəп яткырасың килә икән, әйдә урынга... тырышып кара, бәлки, мине өйдә бәйләп тотардай сабый кисәге әвәли алырбыз»,— дип ычкындырды. Ярыйсы гына тупас чыкты чыгуын, әмма бу темада аларның сөйләшәсе сүзләре күптән инде сөйләшенгән, ачыкланасы нәрсәләр ачыкланган, тикшерәләсе тикшерелгән иде...

Гомеренең буеннан буена Сәйдәр иң изге бер нәрсә — ата булу бәхетеннән мәхрүм ителгән иде. Моңа ул бик озак еллар ышанырга теләмәде, бөтен гөнаһны Фирәзәгә сылтарга тырышты, бер мәлне хәтта: «Син, мөгаен, кыз чагыңда ук... кешегә сиздермичә генә авырыңны төшерткәнсең»,— дип тә ычкындырды... Ычкындырды. Шул ук мизгелдә Фирәзәнең ирләрнекеннән бер генә дә ким булмаган кулы аның яңак төбенә кунаклады! Сәйдәрнең күзләреннән, тубал хәтле үк булмаса да, җаен туры китереп «махсус» кибеттән алып кайткан папахасы хәтле чаткы өере чәчрәп чыкты шикелле. Шуннан соң Фирәзә беренче тапкыр аерылышу турында сүз кузгатты. «Китәм булгач, китәм»,— дип этәчләнде. Ләкин Чынчурин белә иде: Фирәзәнең Казанда тулай торактан башка китәр урыны юк... Хәер, Фирәзәнең чаялыгы һәм усаллыгы җитәрлек, аңа гына карап тормас, тулай торагына да киткән булыр иде. Бик Сәйдәр моны бик тиз аңлап өлгерде, иптәшләре арасында да, кеше арасында да чибәрлеге һәм булганлыгы белән танылган, тормышны дөбердәтеп алып бара, теләсә нәрсәне таба торган хатыннан коры каласы килмәде. Бер көн ярым турсаеп йөрде дә алдагы кичләрнең берсендә Фирәзә бүлмәсенә кереп аның алдына тезләнде...

«Яшь идем шул, яшь идем, шушы кеше сөймәс нәмәрсәнең мәкерләрен ачып сала алмаганмын, нәрсәгәдер ышанып яшәгәнмен,— дип битәрләп алды хәзер Фирәзә.— Әгәр дә шушы вакытта, беренче тапкыр аның нәфрәтеннән нишләргә белмичә өстемә пычрак сүзләр ташлаган чагында ук чыгып киткән булсам?.. Киткән булсаммы? Хәзер менә дуадак каз шикелле кеше балаларына, бала имезүче аналарга, урамда ирләре белән парлашып-парлашып бала арбасы тартып йөрүчеләргә кырын-кырын карап, тешләремне кысып, күз яшьләремне тыеп яшәмәс идем. Әйе, ул вакытта ышандым мин Чынчуринның төче теленә. Ул мине шулай ышандырып килде. Ул бит шушы төче теллелеге белән мине теге чакларда ук, мәктәптә укыганда ук артымнан бар дөньясын онытып йөрүе, ни әйтсәм шуны үтәргә әзер торуы белән җаным яраткан Искәндәрдән биздерү җаен тапты... тапты...»

Фирәзә, әллә нинди бер көчкә буйсынып, тагын баягы төшен исенә төшерде. Юк, исенә төшерде дип әйтү дөрес булмас, чөнки ул төш онытылмый гына түгел, ничектер башыннан алып ахырынача тәртип белән түгел, башы да, уртасы һәм ахыры да — һәммә мизгеле берьюлы истә тора. Җигә соң шулай булды әле бу? Җигә соң бүген генә Искәндәр аның төшенә килеп керде әле?

Искәндәр...

Ә бит Фирәзә аңа карата бер генә дә битараф түгел иде, түгел иде. Алай гынамы соң, ул аны ярата иде. Берәүгә дә әйтмичә, сиздермичә ярата... Һәм атлаган саен аның җанына тия, чая кызларга хас усаллык белән җаен табып кимсетә, аңардан көлә иде.

Беренче тапкыр ул аңа кызлар күзе белән сигезенче класста укыганда карады бугай. Ә ничек, ничек булды соң әле ул?..

Әйе, ул көнне Фирәзәләр классын Пар каен басуына колхоз бәрәңгесен алырга җибәрделәр. Ул вакытта әле басуларга машина бе-

ләң төялеп йөрмиләр иде, шуңа күрә бу юлы да укучылар тиз генә өйләренә таралып, эш киемнәре дигәннәрен киенеп килделәр дә мәктәп ишегалдындагы чирәмлеккә тупландылар, әмма басу ягына таба кузгалырга ашыкмадылар, чөнки кемнәрдер килеп үк җитмәгән иде. Билгеле инде, мондый чакта унбиш-уналты яшьлек яшүсмерләр һәм кыз-кыркын тик кенә басып торалмый. Аларга уен-көлке кирәк. Бу юлы да шулай булды, тиз генә түгәрәк ясап алдылар да гармун урынына такмак-җыр көйләп биешергә, әйлән-бәйлән уйнарга керештеләр. Шулвакыт Фирәзәнең күзе кызлар-егетләр кулга-кул тотынышып хасил иткән түгәрәк уртасында калган Искәндәргә төште.

Һәй, бу дөньяның хәлләрен кем белсен дә, кем аңлатып бирсен соң? Фирәзәнең карашы түгәрәк уртасында басып торган чабаталы Искәндәргә төште. Бәлки, чабата дисәң... Хәер, сугыштан соң тын алып, иркенрәк сулый гына башлаган илленче елларда да әле бу игелекле юкә чабатасы хәзерге кебек искитәрлек нәрсә түгел иде. Ул елларда да әле мәктәпкә, клубка, кунакка барудан башка эшләргә — юлга, урманга, колхозның бүтән эшләренә, малай-шалайларга хәтле шушы чабата дигән нәрсәне кия торган иде. Халык элек-электән әлеге аяк киеменә бераз гына көлемсерәп караган, әмма шушы нәмәстәкәй ничәмә-ничә буынга игелекле хезмәт иткән, яланаяк йөртмәгән. Шуңа күрә дә ул аны үзенең җырларына керткән, мактап та, бераз гына юмор салып көлебрәк тә җырлаган. «Чабата җанга ята»,— дип тә җибәргән... Ә ул көнне, мәктәп ишегалдындагы чирәмдә уен башлап җибәргән яшь-кыркын арасында түгәрәк уртасына чыгып баскан Искәндәрнең аягында, гөнаһ шомлыгына каршы, шушы сап-сары юкә чабаталар иде. Күрәсең, Искәндәрнең хәлләре бик үк шәптән булмагандыр... Хәер, каян булсын соң, ул бит әтисез-әнисез үсә, үзенең әбисендә тәрбияләнә иде... Бу хәлне түгәрәк хасил итүчеләр арасындагы Фирәзә дә белми түгел, белә иде. Әмма ни булгандыр, нинди корт чаккандыр, ул һич тә көтмәгәндә-уйламаганда үзенең теленә килгән җырны көйләп җибәрде:

> Алтылымы чабатаң,
> Җиделеме чабатаң?
> Кай җирендә мәхәббәтең,
> Ник бу кадәр яратам?..

Нигә, нигә җырлады соң Фирәзә ул җырны чабаталы Искәндәр уртага чыккач кына?

Ничек булды соң әле бу? Әйе, Фирәзә җырын җырлап бетерербетермәс борын Искәндәр уртадан, куллар боҗрасын ярып тышка атылды. Уйнаучылар монысын да әле аның әллә нигә юрамадылар. Ә юрыйсылары булган икән. Искәндәрнең үз араларында бердәнбер чабаталы икәнлеген күрәселәре булган икән... Юрамадылар, күрмәделәр...Яшьлек бит ул катгый була. Искәндәр түгәрәк уртасыннан чыкты да мәктәпкә, үзләренең классына кереп китте, ике минут та үтмәгәндер, аннан да атылып чыкты һәм урамга таба йөгерде.

Әй, Фирәзә, Фирәзә, белсәң иде, күрсәң иде син ул чагында малайлыктан чыгып бетмәгән, егетлеккә кереп җитмәгән, ләкин инде үзен егет итеп сизә башлаган бу ир-ат затының күзләрен, ул күзләрдәге мөлдерәмә тулы күз яшьләрен. Ләкин син күрмәдең, күрергә теләмәдең, хәтта уйлап та карамадың. Иптәш кызларың сиңа шунда ук: «Бар, йөгер артыннан, Фирәзә, берәр тилелек эшләп ташламасын. Юри генә җырладым, сиңа атап түгел бит, җырның ертыгы юк лабаса диген, телемә генә килде диген»,— дип үгетләп карадылар. Ләкин кая ул? Фирәзә барамы соң, йөгерәме соң ул егетләр артыннан! Бер адым да атламады. Нибары мәктәп ишегалдын яңгыратып көлде генә...

Ә барасы булган, булган икән.

Искәндәр шул китүдән күренмәде. Икенче көнне дә, өченче көнне дә күзгә-башка чалынмады ул. Вакыты шундый иде аның, укырга теләмәгәннәрне урта мәктәп бетер дип кодалап йөрмиләр иде ул чакта. Әмма инде бер кереп укый башлаганнарны тиз генә ычкындырмыйлар да иде. Искәндәр бер атнадан артыграк мәктәпкә килмәгәч, класс җитәкчеләре Салия апа көннәрдән бер көнне дәрестән соң барысына да калырга кушты. Калдылар.

— Укучылар,— диде Салия апалары үзенең йомшак, ягымлы һәм ышандыргыч тавышы белән: — Укучылар, минем белүемчә, сез үз иптәшегезнең ярлылыгыннан көлгәнсез. Бу ярый торган эш түгел. Чөнки сезнең үзегезнең дә әлегә мактанырдай киемегез юк. Ил өстеннән шундый дәһшәтле сугыш узды. Меңнәрчә шәһәр һәм авыллар яндырылды, туздырылды. Хәзер бөтен байлык шушыларны, аларга өстәп завод-фабрикаларны яңартып төзү эшенә тотыла. Шулай булгач, сез дөрес эшләмәгәнсез. Дөрес эшләмәгән кеше үзенең гаебен танырга, гафу үтенергә тиеш. Бу элек-электән шулай. Димәк, сез Искәндәр янына барырга, аның рәнҗүен басарга һәм аны мәктәпкә алып килергә тиеш буласыз. Менә сезгә төргәк. Шуны Искәндәргә алып барырсыз. Ул төргәктә — мәктәп күрсәткән ярдәм — бер пар ботинка.

Шулай диде дә Салия апалары класстан чыгып китте. Ә класс, парталар тутырылган бүлмә әче тынып калды. Колаклар чыңлагандай булды. Хәтта мич астындагы бер чикерткә «чик-чирик» дип тә куйды. Гаҗәп, ләкин үзе күзгә дә күренмичә яшәгән шушы бөҗәкнең чиркылдавы бүлмәдәге киеренкелекне йомшартып җибәрде. Барысы да моңардан ниндидер кызык табып елмаешып куйдылар. Барысы да бу елмаюларыннан уңайсызланып, күз чите белән бер-берсенә карашып алдылар һәм барысы да берьюлы сөйли башладылар.

— Кигә без барабыз? Әнә... Фирәзә барсын. Ул бит җырга оста,— дип куйды мич артына ук кертеп куелган партадан Сәйдәр.— Барсын, барсын да ярлы дустыннан гафу үтенсен... Ха-ха-ха...— Һәм сабакташлары көтмәгәнчә өстәп куйды: — Кара син аны, хәерчене, үзенә күрә түгел тагы...

Сәйдәрнең беренче сүзләрен ишеткәч тә Фирәзә урыныннан сикереп үк торды. «Кигә мин генә барыйм, барыгыз да миңа кушылып җырлалыгыз ич»,— димәкче иде ул. Ләкин Сәйдәрнең каһкаһәле көлүен, шуның артыннан ук әйтелгән мыскыллавын ишеткәч, әлегә хәтле теленә килмәгән сүзләрне кычкырды.

— Хәерче? Ә син кем? Аның әтисе сугышта ятып калган, ә синеке — Аю, синеке сугышка бармыйч, кайдадыр качып, чиргә сабышып яткан...— диде ул нәфрәтеннән нишләргә белмичә. Парта араларыннан йөгереп алга чыкты, укытучы өстәлендәге төргәкне кулына алды һәм үз тынына үзе буыла-буыла урамга чыгып чапты...

— Нәрсә инде, таң әтәче шикелле, хыялыйланып торасың? — диде йокысыннан уянып почмак ягына чыккан Сәйдәр Фирәзәне сискәндереп.— Әйдәле, керәбез, бер сүз әйтәм...

Үзен баш инженер итеп куйганнан бирле Сәйдәр еш кына авызыннан чыккан сүзләрнең телгенен ычкындырып җибәрә иде. Хәзер дә ул, «Ат булып кешнәр, елан булып тешләр» дигәндәй, астыртын шуышып килгән елан шикелле чагарга җыена бугай, дип уйлап алды Фирәзә һәм үзенең бу уеннан аптырабрак та китте. Чөнки әле моңарчы үз ире турында болай ук нәфрәтләнеп уйлаганы юк иде. Димәк, арада инде бер генә уртак нәрсә дә калмаган, димәк, аларны уртак урын-җирдән башка бер генә нәрсә дә бәйләми. Күңелләрне бер-берсенә тоташтырып торган җепселләр өзелеп-сүтелеп беткән... Хәер, ул җепселләрнең ышанычлы бәйләнгәне бар идеме соң?

— Әйдәле, кереп бераз ятып торыйк,— диде Сәйдәр аның җилкәсе аша күкрәгенә үрелеп. Фирәзә иренең йонлач кулын, кап-кара төк-

ләрен күрде. Йонлач куллар халат төймәләрен ычкындырып җилкәдән шуып төштеләр дә, шәрә күкрәкләргә кагылдылар. Фирәзә ирексездән чирканып куйды.

— Юк инде, синең белән ятып торыйктан ни файда?— диде Фирәзә Сәйдәрнең авырткан җиренә суктырып.

Сәйдәр, аның бу сүзләрен ишетүгә, корт чаккандай кулларын тартып алды. Аннары хатынының ике җилкәсеннән тоткан хәлдә зырылдатып үзенә таба әйләндерде.

Фирәзә күрде: аның күзләрендә коточкыч нәфрәт, йөзендә теләсә генә нинди җинаятькә дә әзерлек барлыгын күрде.

Шуңа карамастан, Фирәзә калтырап төшмәде. Чөнки ул Сәйдәрнең андый нәрсәләргә, кул күтәреп сугуга, яки тагын да хәтәррәк нәрсәләр кылырга кыюлыгы җитмәсен белә иде. Аның үз урыны, карьерасы никадәр кадерле икәнен яхшы белә иде.

Фирәзә ачынып, аның явызлык тулы күзләренә карады:

— Йә, сук, сук инде, ичмасам бер... Ирдер бит син... Син бит... син бит...

Ул тел очында торган сүзләрен әйтеп бетерә алмады, сулкылдавыннан тынына буылып урындыкка шуып төште. Ләкин анда да утырып кала алмады, идәнгә егылды. Озын кара-көрән чәчләре иңнәре аша йөзен каплап, куерак йомырылары өстенә сибелеп төштеләр...

## 6

Искәндәр резин итекләрне кыяр-кыймас кына алды. Сәйдәргә бу ошады, ул шундук: «Менә бит ул дөнья ничек үзгәрә. Теге елларны, студент чакларда син — Искәндәр Фидаяров — бигрәк тә горур идең, син Фирәзәнең сөйгәне идең. Ул башта сине артыграк күрде. Шуңамы артык горур идең син. Ә менә хәзер мин нинди зур төзелеш трестының баш инженеры... Ә син өтермәдән кайтып килүче, булган тормышын да югалткан, беткән кеше. Менә хәзер минем яныма эшкә урнаштыруны сорап кердең. Гади эшче итеп. Мин сиңа игелек күрсәттем. Бригадир итеп урнаштырырмын анысы. Инженер булсаң соң? Син бит ул инженерлыгыңны өтермәгә илтеп калдыргансың... Элекке урыныңнан характеристика, гомумән, мөмкин булган нәрсәләрне тиз генә соратып алырга һәм килгәч тә үз кулыма төшерергә кирәк булыр. Динәгә дә әйтеп куярга кирәк». Ул әнә шулай уйлый-уйлый көлемсерәбрәк басып тора бирде.

Ул арада Фидаяров үзенең гап-гади туфлиләрен салды һәм кая куярга белмичә кулларына тоткан килеш як-ягына каранды, аннары Сәйдәргә таба борылды. Сәйдәр аның ни сорарга теләгәнен аңлап ишек катындагы стенканың аскы бер өлешен ачты.

— Куй шунда, беркая да китмәс. Әйе, синең кабул итү бүлмәсендә капчыгың да бар бит әле.— Ул Искәндәрнең оекчан килеш шунда таба омтылыш ясавын күргәч: — Әйдә, әйдә, ки бу вездеходларны, үзем алып керермен,— дип кабул итү бүлмәсенә чыкты.

Динә әлегәчә авызын турсайтыбрак өстәле янында утыра иде. Сәйдәр аның янына ук килеп аркасына терәлеп басты.

— Угрюмов кайтмадымы?

— Белмим...

— Йә инде, йә инде, Динә, шаулама, яме. Бу бәндә минем сабакташ һәм... Аның әле синең белән миңа яхшылыгы тиюе ихтимал.

— Тия ди, тимичә... Тия башлады инде... Хәзер мин кич буена гумран шикелле япа-ялгызым утырырга тиешме?

— Иртәгә, иртәгә, Динә, без бүгенге сен дә кайтарырбыз, ярыймы?— Һәм ул Динәнең җилкәсе аша үрелеп башын артка таба як кырын, бит алмасыннан үбеп алды.— Гуд бай, Динәкәй...

Тынчурин бүлмәсенең ишеге ачыла башлады. Сәйдәр бүрсык житезлеге белән тәрәзә янына атлап өлгерде.

— Булды бу, Сәйдәр Хәлилович, шәп булды. Моның белән сезнең Көмеш Алан урамнарыннан да йөреп булыр болай булгач,— диде Искәндәр.

— Сезнең түгел, иптәш Фидаяров, сезнең түгел. Безнең Көмеш Алан... Ялгышмасам, син инде, Искәндәр Гәрәевич, гаризаңны бирдең, эшкә урнаштың һәм бүгенге көннән син шушы трестның тулы хокуклы бер әгъзасы. Таныш булыгыз, иптәш Динә Фәритовна, бу ир-егет мин фәкыйрегезнең сабакташы — Искәндәр Фидаяров. Безнең төзелештә дан казаначак бригаданың яңа житәкчесе.

Динә тәрәзә янында басып торган килеш керфеген дә какмыйча:

— Без таныштык инде, карап икән...— диде.

— Ярый, алайса, Динә Фәритовна, без киттек... Юрий Борисович сораса, мин өйдә булырмын.

Трестның баш инженеры буларак, Сәйдәр Тынчурин үзен иң кунагын биредәге төзелеш белән таныштыра башлауны кирәк тапты. Аннары яңа салынып ята торган шәһәрнең әзер йортларына барып житкәнче кимендә ярты сәгать узачак иде.

— Менә болары безнең, Искәндәр Гәрәевич. Пионер базасы корылмалары инде... Турысын әйткәндә, биредәге төзелеш менә шушы урынга бер төркем кеше килеп, аннары карда чистартып, берәнче казыкны кагудан башланып китте. Мин үзем беренче казыкны каккан идем.— Монысын Сәйдәр Тынчурин артык тырыбрак җибәрде, чөнки ул соңгы өч ел дәвамында да монда килүчеләр арасында юк иде әле. Чаллыярда бер үк берләшмәдә эшләгән кеше буларак, ул мондагы хәлләрне ишеткәләп йөрде, билгеле, әмма биредәге төзелешкә килергә туры килмәде аңа. Үзәкләргә үтәрлек салкын көн, февральнең беренче көне иде.

— Зур төзелешләр шулайрак башлана инде,— диде Искәндәр дә аның сүзен хуплап.— Безнең яклардагы КамАЗ төзелешләре турында күп укырга, ишетергә туры килде.

— Уку һәм ишетү бер хәл, Искәндәр Гәрәевич, ә менә үзең шул эшләрдә катнашу... БАМны белмим аныысы, алдашыр хәлем юк, әмма безнең КамАЗ гөрләде, шаулады, дөньяны дер селкетеп алды. Кемнәр генә килмәде дә, кемнәр генә булмады анда!..

Беравык сөйләшмичә бардылар. Искәндәр тирә-якны жентекләп күзәтте. Хәзер алар авыл буенча урыннан баралар. Тегендәрәк әлегәчә ишелмәгән йортлар да моңаешып тора, элеккеге бакча урыннары сизелә, чөнки өеп-өеп куелган җир чүмәләләреннән җимеш агачларының ботаклары һәм кәүсәләре сузылышып ята лар.

— Безнең трест, нигездә, Искәндәр Гәрәевич, АЭСның үзен төзү белән шөгыльләнә. Ул моннан, әнә теге якка таба,— Сәйдәр артка таба борылып кулын сузып күрсәтте,— тагын уникe чакрым чамасы баргач... Анда да безнең эшләр колач жәйгән. Быелга инде йөз миллион чамасы капитал салыначак. Эш житәрлек.

— Син, Сәйдәр Хәлилович, миңа бригадир итәм, дидең. Ә бригадасын каян алырбыз соң? Кешеләр, дим, килерләрме? Эшчеләрме, әллә авыл җирләреннән җыелаларммы?

— Төрлесе бар. Безгә хатлар көн саен өем-өем килә. Әлегә торак житешми... Нибары уникe йорт өлгерттек дүрт ел эчендә... Без түгел, ул эшләр белән йортлар төзү идарәсе шөгыльләнә. Сиңа инде кешеләрне үзеңә тупларга туры килер. Хәзергә монтажчы-ябыштыручылар һәм башкалары дигәндәй...

— Менә бүген минем белән шәп егетләр килде, әгәр дә аларны миңа бирсәгез...

— Ярый соң, иртәгә Мария Степановнага әйтеп чыгармын.

— Сәйдәр, анысын билгеле, син хәл итәрсең, шигем юк. Инде болайга киткәч, мине АЭС төзелешенә аласы булгач, тагын бер-ике соравым бар иде.

Тынчурин сабакташына: «Йәле, әйтеп карале, ни кыр(ы)сың икән?» — дигәндәй күз төшереп алды.

— Рәхим ит, Искәндәр Гәрәевич, берне түгел, икене-унны сора, — дип, киң күңеллелек күрсәтте.

— Мин, Сәйдәр, әйткәнемчә, атом станцияләре кору проблемаларыннан хәбәрдар кеше... Һәрхәлдә, дүрт ел элек хәбәрдар идем. Мондагы АЭС шул вакытларда уйланылган. Беренче казык кагу вакытын үзең әйттең, мин шунның нәтиҗә ясыйм һәм шуңа сорамакчы булам. Мондагы — Искәндәр һич кенә дә «без»нең сүзен куллан(мыйча) ал(д)ый иде әле. — АЭСта, Сәйдәр, минем кебек кешегә әйтергә ярасадыр, әйт әле: нинди реактор куелачак?

Тынчуринның турысын әйтергә кирәк, АЭС төзүче трестның баш инженеры булса да, мондый ук нечкәлекләрне белеп бетерми иде әле. Шулай да, эшләү дәверендә беркадәр шөгыльләнергә ала(р) гынамы, шушы мәсьәләләргә күмелер(г)ә туры килде аңа.

— Кайсысы да барыбер түгелмени? — диде ул. — Галәмгә очкан безнең заманда АЭС реакторлары күптән сыналып, эшкә җигелгән нәрсәләр бит инде...

Искәндәр аны бүлдерде:

— Юк, Сәйдәр, барыбер түгел. Чөнки без синең белән менә шушы җирнең балалары. Үзең беләсең, безнең авыл моннан ерак түгел... Менә мин монда килгәндә карап килдем. Чаллы һәм андагы КамАЗ үзе генә дә ни тора. Анда күпме кеше яши?

— Ярты миллион чамасы булыр, — диде Сәйдәр, сабакташының ни әйтәсен көтеп. — Шул чама бугай...

— Менә... Аның янына Түбән Кам(а) химия гигантын куш. Шәһәрен куш. Теге якта Алабуга — анда да трактор гиганты кора башлыйбыз, дип шау-гөр килә(ләр). Чистайга һәм Зәйгә дә ерак түгел. Димәк, АЭС реакторларының нинди булуы барыбер түгел. Ул иң ышанычлысы булырга тиеш. Гомумән, миңа калса, бу АЭС урынын бик ашыгып сайлаганнар. Халыкның тыгызлыгын, Чулман, Иделнең мөһимлеген, ГЭС сусаклагычының аскы агымында булуын исәпкә алмаганнар.

Сәйдәр башта ел(ма)ебрак тыңлаган иде, әмма Искәндәрнең ышанычлы, мәсьәләне белеп сөйләве, аның фикерләренең хаклыгын күңеленнән кай төше беләндер сизү аның күз ката башлады. Ләкин ул инде күңелендәге андый гына кузгалышларны басып торырга өйрәнгән тәҗрибәле җитәкче, шуңа күрә Искәндәрне бүлдермәде. Бары тик:

— Йәле, йә, кызык кына фикерләр әйтәсең син, Искәндәр, — дию белән канәгатьләнде. Искәндәр дәвам итте:

— Болары инде аның икенче мәсьәлә. Ләкин бу хакта да озаклап(?) ламый халык уйлый башлар... Күрәсең бит, экология хәлләре ничек кузгала. Әнә, төньяк елгаларын борып көньякка җибәрергә маташучы кайнар башлар(ы)га салкын су сиптеләр, суытып куйдылар... Син, Сәйдәр, нинди реактор буласын әйтмәдең әле? Гафу ит, мин бик еракка сикердем бугай...

— Әйе, — диде Сәйдәр, — синең соңгы вакытта эштән китеп торуың, төрле уйларга чумып яшәвең күренеп тора. Бунтарьлана башлагансың, дип әйтимме. Хәер... Син мәктәптә чакта ук шулай башк(ал)арның исе китмичә, гадәтигә саналган нәрсәләреннән әллә нинди гаепләр таба торган идең. Шул гадәтең калган. Син кузгаткан мәсьәләләр инде алар, Искәндәр сабакташ, безнең генә баш җитә торган нәрсәләр түгел. Мәскәүдәгеләр уйлаганнардыр, төрле ягын караганнардыр төзергә керешкәнче. Безнең бурыч кушканны эшләү-

дән гыйбарәт. Син, килеп җитмәс борын, мондагы хәлләрне аңларга тиеш буласың. Ләкин бу реакторларны тәнкыйтьләргә ашыкма. Югыйсә...

Сәйдәр, шушы төштә югыйсә нәрсә буласын әйтеп бетермичә, тын алырга тукталды.

Искәндәр шулай ук туктап калды: аның инде мондый «югыйсә»-ләргә иштеткәне бар иде...

— Ә инде реактор мәсьәләсенә килгәндә,— дип дәвам итте Тынчурин,— бик кирәкле мәгълүмат дип санасаң — әйтәм: бирелә РБМК дигән реактор куелачак. Адәм балалары теленә әйләндерсәк, ягъни реактор большой мощности канального типа дип аңларга кирәк була ак. Йә, күңелең булдымы?

Сәйдәр сабакташына борылып карады һәм исе китте: Искәндәрнең иреннәре ялт-йолт уйный, күзләрендә ачулы чаткылар чагылып-чагылып ала иде.

— Ни булды сиңа, Искәндәр,— диде Сәйдәр атлап барган җиреннән туктый төшеп.— Нигә болай кабарындың?

Әмма Искәндәр дәшмәде. Ул инде мондагы АЭСның нинди булачагын күз алдына китергән иде. Чөнки ул эшләгән җирдә бу хакта бәхәс күп булды. Аннан тыш Искәндәр илдәге шушы реакторлар куелган станцияләрдә әледән-әле вак-төяк күңелсез хәлләр булгалап торуын ишетеп хәбәрдар, аларның кайчан да булса олы һәлакәткә китерәчәген белә иде. Ләкин Искәндәр үзенең әле мондагы төзелешкә башы белән кереп баш... кеше да. койрыгы кермәгәнлеген искә төшерде. Ул тагын: «Бетте, мин моннан беркая да китмәячәкмен. Үз куллар... белән сала башласам да, АЭСка куела... ак реакторны алмаштыру өчен көрәш башлаячакмын...— дигән фикергә килде. «Ярый, әлегә дәшмә, Искәндәр,— диде ул үз-үзенә тешләрен кысып, йодрыкларын йомарлап.— Син монда кирәк булгансың. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Югыйсә бөтен эшне бозасың, эшкә керә алынмыйча ук китеп баруың ихтимал. Тынчурин күрә торып... үзенә дошман арттырмас лабаса...

— Юк ла, искитәрлек нәрсә түгел.— диде Искәндәр.— Макар бабай бозау кумаган җирдәге тәэсирләрдән тиз генә арынып бетеп булмый. Шуның галәмәтләредер...

Алар авылның дөресрәге соңгы көннәрен кичереп ятучы авылның элеккеге төп урамыннан, хәзер бары тик тимер-бетон плитәләр белән ныгытылган, төзүчеләр бераз көлебрәк «проспект» дип атаган урамы буйлап аска, Кама ягына таба төшеп баралар иде.

— Бу авылның киләчәге юк инде, беткән авыл иде инде ул...

Сәйдәр шулай дип сүз башламакчы булган иде, ләкин соңгы ярты сәгать эчендә икенче тапкыр «беткән» сүзен алып әйтүеннән булса кирәк, тукталып калды, тагын Искәндәргә таба карады.

— Син соң, Искәндәр, нинди гөнаһларың өчен Макар бабай бозау кумаган җирләргә барып чыктың? Ни өчен утырттылар?— дип сорап куйды.

Искәндәр моңа үпкәләмәде, чөнки бу сорау табигый иде. Бер караганда эшкә алу рәсмиләштерелгәнгә кадәр үк сорасалар да үпкәли алмыйсың...

— Нәкъ өстенә бастың: у-тырт-ты-лар... Булды инде, Сәйдәр, булды хәлләр...— дип сузды Искәндәр.

Тагын беравык дәшмичә-сөйләшмичә атладылар. Каршыга бер төркем төзүчеләр килә иде. Тынчурин белән исәнләшеп уздылар. Арадан берсе, итегенең озын-озын балтырлары кайтарып куелганы, узып киткәч тә: «Сәйдәр Халилович, мөмкин булса, туктагыз әле бер генә минутка...» — диде.

Искәндәр акрын гына алга атлавын дәвам итте, Сәйдәр исә туктап калды.

«Һәр төзелешнең үз төсе, үзенә генә хас үзенчәлекләре була инде,— дип уйлады Фидаяров.— әле кайчан гына без, әнә теге шау-

шулы егетләр төркеме кебек, армия хезмәтен тутырып кайткан солдатлар, яңа салына башлаган Нәвои шәһәрен төзешергә барып төштек. Кая инде безгә ул чагында мондагыдай бөтен уңайлыклары булган тулай торак-вагоннар?.. Безне палаткаларга урнаштырдылар. Җылысын җылы иде инде, хәтта артыгы белән җылы, әмма ул якларның көзге яңгырларын, ачы җилләрен, шул җил-яңгырларның салкынлыгын анда булган-яшәгән кеше белә, гене белә. Шулай да Искәндәрләрнең бирешер чаклары түгел иде. Аларга ничәмә-ничә кеше берьюлы сыярлык, үзе бер казарма хәтле зур чатырда яшәве дә бик рәхәт иде.

Шушы төзелешкә килеп, солдат хезмәтеннән соң, аңа хәтле ике елга якын студент булып, кефир белән ипигә дә туя алмыйча яшәгән егетләрнең эшен эшләп, уч тутырып акча алуы, ул акчаны кая куярга белмичә ... теләсәләр шунда тотуы, билгеле, күңелен ярыйсы гына кытыклап тора иде.

**Шундый көннәрнең берсендә Искәндәр дигән егет Нәркизәне очратты. Дөресрәге, Нәркизә Искәндәрне очратты. Кыскасы, көннәрнең берендә Искәндәр исемле татар егете белән үзбәк белән татар каны кушылган Нәркизәнең тормыштагы сукмаклары кисеште.**

Ул болай булды: Искәндәр бригадасына ярдәмче эшләргә Самарканд университетыннан килгән студент кызларны бирделәр. Арадан берсе — Нәркизә исемлесе — кызларның өлкәне булып чыкты. Алар килгәндә Искәндәр измә-бетон узелына киткән иде, шуңа күрә кызлар вагон алдында эшсез утырганнар-утырганнар да, дәррәү кузгалып, «начальство»ны эзләргә керешкәннәр. Һәм, кирәк бит шундый чагында, төзелеш парткомы секретареның үзенә очраганнар. «Шулай, шулай, безгә, студентларга эш бирүче юк»,— дип әләкләп тә өлгергәннәр. Теге, билгеле инде: «Нинди бригадага җибәрделәр соң сезне?» — дигән. «Кем белсен аны,— дигәннәр кызлар.— без аны күрмәдек әле. Ә-ә-нә тегендә аның бригадасының вагоны, ә-ә-нә тегендә»,— дип, үзләре белән төзелеш парткомы секретарен ияртеп тә килгәннәр. Алар килеп җиткәндә Искәндәр дә кайтып, КрАЗ үзбушаткычыннан сикереп төште. Партком секретаре болай ук каты бәйләнмәде бәйләнүен, әмма ләкин ярыйсы гына нык итеп әйтте: «Бу кызларга эш җитәрлек булсын штубы, куллары тик тормасын, әмма да ләкин аларның башыннан бер бөртек чәчләре генә югалса да... карагыз аны... миңа җавап бирерсез»,— дип китеп барды.

Нишләмәк кирәк, эшнең кызуы — хәзер генә алып кайткан измәне төзелеп яткан биш катлы йортның түбәсенә ташудан гыйбарәт иде. Кичә кичкырын гына, үч иткәндәй, кранның кай төшедер ватылган, әлегә хәтле аны төзәтергә килмәгәннәр, җитмәсә. Искәндәр беравык башын кашып торды да, кинәт шатланып:

— Әйдәгез соң, кызлар-йолдызлар, мин сезгә эшнең иң шәбен бирәм,— дип, аларны яңа гына бушатылган измә-бетон янына алып килде.— Күрәсезме, әнә тегендә носилкалар, менә монда кирәк дигән нәрсәләр, күрсәтегез үзегезнең уңганлыкны! Ташыгыз шушы измәне ә-нә-нә шушы баскычтан түбәгә.

Кызлар артык ялындырып тормыйча эшкә дә тотындылар. Искәндәр үзенең меңдә бер мәшәкате белән китеп барды. Ул китеп барды баруын, әмма кызларның берсе, Нәркизә дигәне, аңардан үзенең елтыр күзләрен алмады...

Ул көнне кызларга анда-монда карап торырга туры килмәде. Искәндәр бер ачылган капкадан бер-бер артлы алты машина алып чыкты. Измәне дә кызлар гына ташымадылар, бригада егетләре дә булышты. Әмма баштагы ике машинаны бушатуга, аны түбәгә күтәргән арада кызларның «чәч бөртеге коелуын коелмаса» да, уч төпләренә сусыл куыклар кабарып-кабарып чыкты һәм алар инде озакламый носилканы да, көрәкне дә тота алмаслык хәлгә килделәр.

Кыскасы, икенче көнне ул кызкайларның ник берсе күренсен, эшкә бөт нләй үк чыкмаганнар. Шулай итеп, ике көн үтте дә китте. Бригадир егеткә кызларны эзләп тулай торакка барудан бүтән чара калмады.

Бө ен җилләргә дә ачык дала уртасына салына торг н шәһәрнең теләсә кайсы ягыннан килеп керергә һәм теләгән йортны әлл ни бимазаланмыйча гына табарг була иде ул чагында. Искәндәр дә кызлар туктаган йортны озын-озак эзләп йөрмичә генә барып тапты. Башта ишек төбендәге үзбәк апа кертмичә торган иде дә, анн ры яртылаш үзбәкчә, яртылаш татарча сөйләшкәч-гәпләшкәч: «Ярый алайса, бар инде, озак торма гына!» — дип кисәтә-кисәтә үзе үк кайсы бүлмәгә керергә икәнлеген әйтеп җибәрде.

Барып ишекне шакыды Искәндәр. Кызлар ишеген. Армиягә киткәнче, Казанда институтта укыгандагы хәлләрдән соң, ул инде беркайчан да тулай торакка кермәскә, алай гына да түгел, кызлар тирәсендә йөрмәскә ант ук бирмәсә дә, шул тирәдәрәк фикерли иде.

«Рәхим итегез — хош килибсингез...» — диде ишек артындагы тавыш. Искәндәр таныды: Нәркизә тавышы иде б... Таныды һәм үзе үк гаҗәпләнеп куйды: «Ничек инде бер ише удән үк мин ул тавышны от ып калганмын?»

Искәндәр иш кне ачып, бүлмәгә атлады.

Йә хода!!! Ишектән кергән Искәндәр идәнгә басар-басмас борын ук артка таба тартылды, ләкин б рыбер бусага аша атлаган беренче адымын ясамыйч калырга көче җитмәде аның. Шундук кире тартылды, күзләрен чатырдатып йомды Искәндәр. Ләкин... ләкин соң иде инде, чөнки эшләнәсе эш эшләнгән: күзгә күренергә ти шле табигать җимеше — татар белән үзбәк каны кушылып яралга... гүзәл гөлнең сурәте егетнең күз алмаларына сеңеп өлгергән, хәтердә бер күз сирпеп алудан оза... елларга җитәрл к нурлы сурәт ясалган иде.

Искәндәр артка чигенде, ләкин әллә нинди бер илаһи көч к зләрен кабат ачарга мәҗбүр итте һәм ул инде бая пәйда булган сурәтнең, ир-егетләр күңеленә киерелеп суга орган нәрс ләрнең чәчәкле халат астында югалуларын күр е. «Бәлки, мин тиленең күзләрен енә күренгәндер...» — дигән уй бе әң Искәндәр баскан урынында ту -гап калды.

— Мөмкинме?— диде ул ир неннән нинди авазлар чыкканын үзе дә сизмәгән-тоймага... килеш.— Дөрес кердемме?

— Вай, Искәндәр ак , сезме соң бу?— диде Нәркизә берни булмаган, әле генә үзенең сихерләгеч кыяфәтен Искәндәргә күрсәтмәгән, аның күзләренең явын алмаган кеше кебек.— Рәхим ит, Искәндәр ака...

Керсә дә керде, утырса да утырды Искәндәр күрсәтелгән урындыкка.

— Нигә эшкә чыкмыйсыз, студент туташ?— дигән булды ул тәрбияле булырга тырышудан битәр аптырагакнан.— Мин шуны белергә килдем.

— Майле, Искәндәр ака, майле... Күк чәй эчәсезме, Һиндстаннан ка гканынмы?

Искәндәр моньсына ни җавап бирергә дә белм де. Ул үзенең эш киемнәреннән иде, эштә ныгыган, эссеdә каралган кулларын кая куярга белмичә әле тезләренә сузды, әле кесәләренә яшерергә чамалап карады, ләкин алай да, болай да килешмәс сыман тоелды, шуңа күрә отыры каушап.

— Кайсы да ярый... Хәер, чәй эчәргә вакытым юк шул. Егет әр көтә. Озакламый планеркага барасы бар.— диде.

Әмма, Нәркизә туташ, Искәндәрдән өч-дүрт яшькә яшьрәк булса да, мо дый эшләодә тәҗрибәле кыз иде инде. «Ярый алайса, күк

чәй генә эчертермен.— дип, Искәндәрнең алдыннан ук узып китте. Ул узганда хасил булган сизелер-сизелмәс җил Искәндәр моңарчы бер тапкыр да тоймаган-татымаган, ләкин күңелгә ятышлы хуш ис бөркеп алды. Бу бәлки шулай тоелган гынадыр, бәлки шушы кыз сурәтенә кергән мәхәббәт фәрештәсенең канатлары җилпеп алуы булгандыр — анысы инде Искәндәр яшендәге буйдак егетләргә беркайчан да белергә язмаган. Ни булса да булгандыр. «Китәсем, планеркага барасым бар».— дип үзенә чигенү әзерләп куйган Искәндәр ун минуттан да, унбиштән дә, ярты сәгатьтән дә чыгып китә алмады...

Әй, бу уйларны, әй бу уйларны!.. Кешене кайларга, кайсы гына якларга алып бармыйлар да, үткән гомернең кайсы гына вакытларына илтеп ташламыйлар. Шушы уй дигән нәрсәгә бирелеп азмы кеше үзенең һәлакәтенә юлыга, урам уртасыннан ажгырып килгән машина астына керә... Керә яза... Бу юлы каршыга үкереп килгән КамАЗ үзбушаткычы, йөрешен кинәт салмагайтып, биш-алты адым кала туктады. Искәндәр Фидаяров аның томанда яктыртучы ялтырап торган пыяла күзенә килеп төртелгәч кенә күзләрен ачты. «Ни булды тагын?» дигәндәй күтәрелеп карады. Шофер егет түзмәде, урынында утырган килеш уң кулының бармагын чигәсенә якынайтып уйнатып-уйнатып алды. Янәсе: «Син нәрсә, агай, яшәүдән туйдыңмы, әллә акыл дигән нәрсәңә зыян-зарар килдеме?» — дию иде аның.

Искәндәр артка чигенде һәм юлга салынган плитәдән читкә, пычрак эченә төшеп басты. Ул арада арттарак сөйләшеп калган Сәйдәр дә килеп җитте. Ул килә-килешкә үк шоферга:

— Син нәрсә, каршыңа кеше килгәнне күрмисеңме, күзең чыкмагандыр ич?— дип шелтәләп кычкыра иде. Тик кабинасында утырган егет, двигатель тавышы аша аның бу сүзләрен ишетмәде, ләкин шулай да мәгънәсен чамалады бугай, ишеген ачты да кабинасыннан яртылаш чыгып:

— Соң, Сәйдәр Хәлилович, үзе бит котырынган үгез кебек килә минем өскә...— дип кычкырды.

— Ярый, ярый, юлыңда бул... Бирермен мин сиңа котырган үгезеңне... Үзең дә шул үгездән ким түгел син.

Шофер егет, баш инженерның бу сүзләреннән кәефе килеп, ихахайлап көлеп җибәрде дә машинасын салмак кына урыныннан кузгатып китте.

7

— Менә бу йортта, Көмеш Аланда салынган берничә торак йортта яшибез инде без.— диде Сәйдәр бер катлы иске бинаны узып бераз атлагач та.— Син ни, Искәндәр Гәрәевич, анда кергәч...— Ул башын өскә табарак селкеп күрсәтте.— Бик үк гаҗәпләнеп калма. Берсы — бер, икенчесе — без ирлә белән бераз әйткәләшеп алган идек... Син инде андый-мондый төрткәләшү булса, ни... гаҗәпләнмәссең...

Искәндәр яшьтәшенең мондый игелек күрсәтеп, чәй эчәргә дә чакыруыннан канәгать һәм баштарак аның хакында килделе-киттелерәк уйлавына бераз үкенә дә иде инде. Бу юлы:

— Юкны сөйләмә, Сәйдәр...— диде ул.— Син әллә беренче көн дөньяга чыккан кешеме? Бер дә борчылма... Әй бәлки, бәлки, миңа кермәскәдер? Шулай торакка китәргәдер?— дип туктап калды Искәндәр тышкы ишектән кермичә.

— Юк инде, ничек ишек төбеннән борылып китәргә була?— Сәйдәрнең тавышы ук үзгәргәндәй тоелды, аңарда ниндидер бер эч-

керсезлек сизелгәндәй булды. Искәндәр, бәхетенә каршы, яшьтәшенең шулай оста үзгәрүчәнлеген белми һәм Сәйдәр башындагы мәкерне акылына да китерми. Хәер, хәзер, тагын бер минуттан, Сәйдәр индә ачкычын чыгарып ача башлаган ишек артында үзен нинди очрашу көткәнлеген уйлап та карамый иде ул.

«Баш инженерның кабинет ишеген тышлаган әйбәт дерматинның икенче очы мондагы ишектә икән».— дип уйлап алды Искәндәр.

— Әйдә, рәхим итеп кер,— диде Сәйдәр һәм, тәрбиялелек күрсәтеп, кунакны алдан уздырды.

Искәндәр, аны-моны искәрмәгән Искәндәр, киләчәк тормышында нинди үзгәрешләр, кыенлыклар, авыр кичерешләр һәм бернинди үлчәүгә салып та булмаслык шатлык, аның белән бергә үзе бик күптәннән көтеп-көтеп тә өметен өзә башлаган шәхси бәхет китерәчәк очрашуга таба атлады, бусага аша керде.

Алар кергәнне чамалап булса кирәк, савыт-саба шылтырап куйды, аннары кухня ягыннан хатын-кыз атлавы ишетелде һәм коридор белән бүлмә арасындагы тонык пыялалы ишек ачылып китте. Искәндәр, әле яңа гына бусагадан атлап кергән Искәндәр, күзләрен тутырып ишеккә карады. Карады һәм ихтыярсыздан артка таба чигенергә кереште, ләкин чигенүе бер адымга да тулмады, үз артыннан ук кергән Сәйдәрнең нык, таза гәүдәсенә төртелеп калды. Шул мизгелдә Искәндәрнең баш миен ярып, чигә турыннан томан ты бер чың үтеп киткәндәй булды. Әйтерсең, аның башына авыр чукмар белән тондырдылар, әйтерсең, кемдер йөрәгендәге яшерен тамырларының берсен мандолина кылын тарткан шикелле тартып торды да ычкындырып җибәрде! Искәндәрнең иреннәре ирексез кыймылдады. Ике ирен арасыннан чыккан авазларның нәрсә аңлатканын ул үзе дә төшенмәде. Ә ул иреннәр арасыннан инде ничәмәничә еллар буена бары тик хыялда гына килеп, йөрәген сискәндереп киткәләгән исем иде:

— Фирәзә...

Өстенә затлы халат кигән хатынның күзләрендә гүя печән кибәне астыннан агылып чыккан үр куяны сикергәндәй булды. Гаҗәпләнү катыш үкенү, канәгатьләндерелмәгән хисләр, моңарчы нибары бер тапкыр татып караган сихерләгеч мизгелләре — һәммәсе берьюлы чагылды. Гомер буена көтеп-көтеп тә очраша алмаганга рәнҗү һәм тагын әллә ниләр ялтырап-ялтырап күренде бу күзләрдә. «Без әле яшәргә, без әле бер-беребезгә яшәү дәрте бирергә тиешбез»,— дигәндәй мөлдерәшеп торган иреннәре ихтыярсыздан:

— Ис-с-кән-дә-ә-әр...— дигән өзек-өзек авазларны сибеп төшерделәр.

Сәйдәр акылга сай кеше түгел, ул үзенең ни өчен шушы Фирәзәгә генә гашыйк булуы, теләсә генә нинди бәягә аны үзенеке итәргә тырышуы һәм шушы киребеткәннең тәнен үзенеке итеп тә күңелен күндерә алмавының сәбәбе турында уйламады түгел, башы авырткәнчы, чигәләрендә чәчләре агара башлаганчы уйланды. Алай гынамы, бу омтылыш күп еллар буена мин-минлегенә сугып килгәнлектә... отыры тискәре үҗәтлек белән яшәде, көтте... Фирәзәнең күңеле кайчан да булса йомшарыр, ул да тере кеше бит, аның да иртәме-соңмы ярату дигән нәрсәнең тәмен татыйсы килер, дигән өмет белән көтте... Ниһаять, аңлады: буш өметләр белән яшәү иде бу. Үз сүзен итте, итүен. Фирәзә белән бергә яшәде, әмма калганына ирешә алмады. Аныcына Аю Хәлил малае Сәйдәрнең көче дә, сәләте дә, мәкерлеге дә җитә алырлык түгел иде.

«Стоп,— диде Сәйдәр Тынчуринның аңында мәкерле планнар корып ята торган бер җепсел.— торып тор!..» Ул Искәндәр Фидаировны очратканнан соң да үзе кичерә башлаган халәтне аңлагандай булды. Баядан бирле нинидер мөһим бер уйның җеп очын тота алмыйча

азапланган иде. Менә хәзер ишектән кереп баскан Искәндәрнең һәм аның каршындагы Фирәзәнең бер-берсенә чекерәешеп карап торуларыннан тәннәре чымырдый башлады... Искәндәр Фидаяров гомере буена Сәйдәр Тынчуринның юлына, тормышына аркылы төшеп килде, аның бугазында чуерташ булып утырды, аның мин-минлегенә сугып килде.

Фирәзә гомер буена Искәндәрне яратты.— моны Сәйдәр күптән белә, бу аның өчен сер түгел иде. Хәзер очрашкач та алар бер-берсенә битараф яши алмаслар... Алмаслар... Шуны белергә, шуны кешеләр алдында аклану өчен оста файдаланырга үзен ничәмә-ничә еллар бәйләп торган зынҗырлардан шулай иппле генә итеп арынырга тиеш ул. Сәйдәр үзенекен итмәде түгел, итте, бик итте. Фирәзәнең күкрәкләрен буйсындырды. Әмма у р т а к җан булмаган икән. Күрәсең, Сәйдәр дөньяга килгәнче үк инде кемдер аның бәхетен күпсенгән, кемдер шуның чарасын күреп куйган.

Сәйдәргә эссе булып китте. Ул күн плащ-пальтосының сәдәфләрен ычкындырды, аннары галстугын бушата төште. Шулай да аңарда үзсүзлелек җитәрлек иде әле, бирешергә теләмичә баягы рухта уйлавын дәвам итте...

## Икенче башлам

### 1

Йокы килми иде.— Бер уянгач та йоклап буламы соң инде ул! Искәндәр, ниһаять, бөтән йоклый алмасына ышангач, урыныннан торды. Ул аяк астындагы палас кисәгенә басарга тырышып, бераз капшанып торды, тапмагач, яланаяк килеш идәнгә төшеп басты. Идән ярыйсы гына салкын иде. Ләкин Искәндәр җылы якларда яшәгәндәге кебек җылы сөяк түгел иде инде, аңа БАМ ягындагы тайга урманында моның ише генә салкыннарны байтак кичерергә туры килде.

Искәндәр бүлмәдәше Илдар Корбановның урынына җәелеп, аякларын як-якка ташлап, каһарманнарча йоклавына карап алды, урындыктан алып трикосын киде, кедаларын эзләп тапты һәм караватына утырып шнурларын бәйли башлады.

Бәхете ерак йөрми икән, бригадасына тупланган егетләрдән уңды Фидаяров. Әбит... теге көнне иртә белән кадрлар бүлеге янында Мария Степановна чыгып: «Сезгә, егетләр, бригадир сайларга кирәк инде, үзегез беләсез. Без сезгә бер иптәшне, элек зур төзелешләрдә эшләгән кешене тәкъдим итәбез»,— дигәч тә тегеләр гу килеп алдылар. Искәндәр башта аларның ни әйтергә теләүләрен тиз генә төшенеп тә бетмәде, чөнки тегеләрнең аерым-ачык сүз әйтергә вакытлары юк иде. Шулай да бер-ике минуттан аларның ни теләүләре аңлашылды. Арадан берсе — сары мыеклы, тәбәнәк буйлы украин егете — турыдан ярып салды: «Безнең үз бригадирыбыз бар, безгә бөтәне кирәкми,— диде ул, тирәсендәгеләрнең хуплаулы «әйе»сеннән кыюлана төшеп.— Әнә безнең армиядәге отделение командирыбызны бригадир итегез». Мария Степановна мондый эшләрдә ярыйсы гына тәҗрибәле икән: тегеләрнең шаулашып беткәннәрен көтеп торды да: «Туктагыз әле, егетләр, сез бит белмисез, бәлки ул кеше дә сезгә ошап куяр. Аның бит төзелешне белүе дә кирәк. Аннары кичә сез аның өчен менә шушы бүлмәдә таш дивардай тордыгыз, оныттыгызмы әллә?» — диде. Кичә автобуста бергә килгән, бергә-бергә эшкә урнашырга торган егетләр Искәндәргә таба карадылар.

Кешенең үзе алдында ук «кирәкми безгә» диюләреннән бераз уңайсызландылар булса кирәк. Шулвакыт каратут йөзле, озын, таза һәм көрәш батырыдай нык гәүдәле егет алгарак чыкты. Аның нидер әйтергә теләвен күрүгә — армия гадәте! — егетләр тынып калдылар. Ә Илдар дигәннәре, бер атна элек кенә отделение командиры булуыннан файдаланып: «Туктагыз әле, игътибарлырак булыйк без, егетләр, мондый тәкъдимгә. Миңа калса, мондый зур төзелештә эшләргә безнең тәҗрибәбез дә, белемебез дә җитеп бетми. Бу агай, мөгаен, чын төзүчедер, шулайрак тоям. Әйдәгез, тыңлыйк без олы кешенең сүзен. Сайлыйк бу абыйны бригадир итеп... Ә инде ошап бетмәсә, үзебез үк алмаштырып сайларга мөмкин ич», — диде.

Ул көннән соң ай ярым вакыт узды инде. Хәзер егетләр резервтагы җибәрү котельныен коруда беренче чыныгу узалар. Хәер, аларга үзләренә генә озын-озак эшләргә туры да килмәде, атна-ун көн эчендә җиде кешелек бригада җитмеш кешегә җитте. Төзелешкә кеше туплауның кызган чагы булгангамы? әллә, чынлап та, төзелешнең баш инженеры Тынчуринның кулы уйнадымы — ничек кенә булса да булгандыр, әмма бригадага кеше бик тиз тупланды.

Искәндәр шушы уйлар белән тулай торак ишегеннән чыкты.

Тышта гаҗәп бер үзгәреш: бөтен җир өсте күзләрне чагылдырырлык аклыкка күмелгән, тупыл мамыгы сибелгән сыман иләп кар ява иде. Һава шундый саф һәм ул үзенең чималы салкынлыгы белән тәнне рәхәтләндереп тора, тын юллары аша үпкәләргә уза һәм ир уртасы кешенең канын тукландырып, аңа яңа дәрт, яшәү дәрте өсти иде.

«Ә бит тормыш шундый матур, сокландырырлык үзе, — дип уйлады Искәндәр. — Бары тик аның тәмен белеп, матурлыгын күрергә, аңа соклана белергә генә кирәк. Тормыш ул гел кара көннәр, яңгырлы, бозлы явымнардан гына тормый, анарда шатлыклы, менә бүгенгедәй аклыкка төренгән көннәр дә җитәрлек».

Искәндәр болдыр баскычларыннан төште дә җиргә йомшак мамык юрган булып яткан кар өстенә беренче эзләр сала-сала тар сукмакка чыкты. Аннары бераздан киң юлга төшеп, АЭС төзелә торган якка таба йөгереп китте. Ләкин монда инде ул беренче түгел, монда инде беренче эзләрне машиналар салып узган иде. Әмма барыбер алар әле кар астындагы бетон юлны ачарга өлгермәгәннәр.

Иртәнге салкынча һаваны сулый-сулый яңа яуган кар өстеннән йөгерүе рәхәт иде. Искәндәр үзенә кирәкле темпны тотты да шуны сакларга тырышып йөгерә башлады.

«Ә Фирәзә, Фирәзә бу минутларда нишли икән? Йоклыймы, әллә уяу микән?» — дип сорады ул эч китмәгәндә үзеннән-үзе. — Нишли икән?..

Теге көнне очрашканнан соң да ай ярым вакыт үтте. Шуннан бирле Искәндәр аны бер генә мәртәбә, анда да кеше арасыннан гына күреп алды.

Ну бу Сәйдәрне, Аю Сәйдәрен! Теге көнне Искәндәрне малайшалай хәленә төшереп, тәки алып керде бит.

Искәндәр әлегәчә сөйкемлелеген югалтмаган Фирәзәнең йөзенә бүтән күтәрелеп карамады, күзгә-күз очрашудан курыкты. Аның зифа буен, бөтен кыяфәтен күрүдән курыкты. Әгәр дә мәгәр аның йөзендә тормышыннан канәгатьлелек, баш инженер хатыны булуыннан, өй эче тулы зиннәттән масаеп яшәү билгеләре, өстенлек белән каравын күрсә, нишләр иде соң Искәндәр? Юк, ул анда кәефе килүдән тәмам ярсыган, шуңа күрә бертуктамый сөйләп торган Тынчуринның өендә утырып кала алмаган булыр иде.

...Теге чакта Фирәзә кулына төргәк тотып килеп кергәндә, Искәндәр идәнгә чүгәләгән килеш идән юа иде. Ишек ачылган тавышка артына борылып карады һәм нинди хәлдә чүгәләгән булса, шул

килеш калды. Кулындагы мунчаласын ташларга да, урыныннан торырга-тормаска да белмичә аптырады.

— Исәнмесез.— диде Фирәзә кинәт тавышын югалтып.— Керергә ярыйдыр бит?

...уйдан соң дөмбергәрәк килеп чыкты чыгуын. Фирәзә кереп баскан иде, артыннан ишекне дә ябып ук куйган иде инде.

— Ис...сәнме?...— диде Искәндәр, көтелмәгән бу кунакны шундый кыяфәттә каршы алуыннан уңайсызланып.

— Мин ни... Искәндәр... синең яныңа килгән идем. Мине ...әлия апа җибәрде. Менә шушы төргәкне бирергә кушты.— диде Фирәзә тавышының кай яклардандыр әйләнеп кайта башлавын сизеп.

Искәндәр урыныннан торды. Аның чалбар балаклары тезләреннән югары сызганып куелган, күлмәк изүләре ачык иде. Мунчаланы ташларга онытып, Фирәзәгә таба бер-ике адым атлады. Бары тик шунда гына кулындагы мунчаласын күреп алды. Бит алмалары гына түгел, колак очларына кадәр кызарынды, мөлдерәп пешкән помидор төсенә керде һәм әлеге каһәр суккан мунчаланы, артына борылып, чиләк янына томырды.

— ...әр...сә ул? Кемгә?

Искәндәрнең тавышында таныш түгел калтырау барлыкка килде.

— Кемгә булсын, сиңа-а-а.— дип суздЫ Фирәзә.

Искәндәр төргәкне алды, акрын гына сүтә башлады, сүткән саен әле куерып өлгермәгән кашлары җыерыла барды, төсе-төсмере коела төште. Шулай да төргәкне сүтеп бетерде.

Аның күз алдында өр-яңа ботинкалар пәйда булды. Фирәзә күрде, аермачык күрде: Искәндәрнең күзләрендә шатлыклы очкыннар кабынып, әлеге ботинкалар өстенә, аны китерүче рәхмәтле бәндәгә сирпелделәр. Ләкин бу шулхәтле тиз арада булды ки, Фирәзә әлеге очкыннардан сукыраймас өчен күзләрен йомгандай итте.

Икенче мизгелдә әлеге ботинкаларны, яулык өстендә торган килеш киредән Фирәзәгә таба сузды. Бу шулхәтле тиз арада булды ки, Фирәзә нәрсә эшләгәнен үзе дә сизмичә ике кулын алга таба куйды һәм пар ботинка аның куллары өстенә менеп тә кундылар.

— Миңа хәзер кирәкми.— диде Искәндәр сулы чиләге янына бара-бара.— Үзеңә булсын... ...агын уртәшеп җырлар идең бугай...

Фирәзә ни эшләргә, ни әйтергә белмичә тора иде. Ләкин аңарда бер генә кагыйдәгә дә буйсынмый торган хатын-кыз холкы, шушы зат логикасы иде. Ул логика исә үзенең логикасызлыгыннан гыйбарәт.

— Менә юләр... менә бит син шыр тиле, Искәндәр.— диде өй эчен яңгыратып көлә-көлә.— ...и-ле-е-е...

Фирәзә аягын да салып тормыйча Искәндәр янына ук килде, төпсез диңгез сыман үзенә тартып торган күзләрен тутырып Искәндәргә карады.

— Ал, Искәндәр,— диде.

Юк инде, бу юлы Фирәзәнең сүзләрендә ялыну да, ишек төбенә кереп баскач үзен белән торган аптырау да, «җибәрделәр» дигәндәге битарафлык та юк иде. Бу юлы Фирәзәнең тавышында ярсу йөрәкле ирләрне дә карусыз буйсындыра торган мәхәббәтле хатын-кыз затының күкрәк тирәнлегеннән чыккан әмерле тавышы иде.

Һәм... Искәндәр Фирәзәнең шушы әмерле дә, серле дә, тылсымлы да тавышына буйсынды, ике кулын сузып, әлеге төргәкне яңадан алды.

— Киеп кара, таманмы?

...агын буйсынды Искәндәр, үзе басып торган идәннең әле юарга өлгермәгән төшенә утырды да берәзрак калтыранган куллары белән ботинканың берсен үрелеп алды, яланаяк икәнлегенә игътибар да

итмичә киеп куйды. Фирәзә аңа икенчесен сузды. Искәндәр икенчесен дә киеп җибәрде. Ул арада аның алдына килеп чүгәләгән Фирәзә, йомры кулларын сузып, ботинканың таманмы-түгелме икәнлеген карагандай итте һәм... тигезләгән саклап кала алмыйча, Искәндәрнең күкрәгенә ауды.

Фирәзә килеп кергәннән бирле ике-өч тетрәнү кичергән Искәндәрне бу юлы инде бөтенләй таныш булмаган тойгылар биләде. Моңарчы үзенең хатын-кыз затыннан әнә шундый кичерешләр-тетрәнүләр тоярга сәләтле булуы турында уйлап та караганы юк иде. Аның, хәтта ана назларын да тоймаган бу үсмернең, Фирәзәдән бөркелгән җылыны, шушы җылының күңел кылларын тетрәндереп алуын, беренче мәхәббәтнең рәхәтлек биреп һәм авырттырып йөрәгенә кадалуын тәүге тоюы иде бу.

...иләр генә күрмәде, ишетмәде һәм кичермәде Искәндәр Фирәзәнең әнә шундый тискәрелеге-якынлыгы аркасында!

Бер мәлне, тугызынчы классны башлаганнар гына иде әле, мәктәптән ерак түгел Болын урамында янгын купты. Укучылар да, укытучылар да аны мәктәп өстенә төтен ябырылгач кына күрделәр. Математика укытучысы: «...уктагыз әле, директордан рөхсәт сорап керим»,— дип тыймакчы иде дә, кая ул,— үсмерләр көзге көннең ачык тәрәзәләреннән, кызлар исә чыр-чу килеп укытучы үзе үк ачып куйган ишектән чыгып йөгерделәр.

Искәндәрләр янгын чыккан йортка барып җиткәндә анда авыл халкы байтак кына җыелган һәм, тезелешеп басып, инештән чиләк-чиләк су бирүне җайга салганнар иде инде. Ул арада янгын сүндерүчеләр дә килеп җитте. Ләкин су сиптергеч насоска җайланган моторлары һич кенә дә кабынырга теләмәде.

Шулвакыт капка төбендәге бала-чага арасыннан:

— Фәргать... Фәргать өйдә калды,— дигән ачы тавыш яңгырады.

Бернилә ир-ат, алар белән бергә Искәндәр һәм аның берничә иптәше шундук капка төбеннән өй ягына ыргылдылар.

Өйнең тәрәзәләрен, ишекләрен, түбәсен ялкын телләре чорнап-чорнап алган һәм инде берәүне дә якын җибәрергә теләми иде.

— Фәргать балакаем өйдә калды!— дигән ачынышлы тавыш якында ук ишетелде.

...абан туйларында көрәшеп дан алган, кыюлыгы белән авылдашлары арасында куш йөрәкле дигән исем йөрткән Бәхтияр болдырга таба атлый башлаган иде, ләкин аның өстенә каяндыр килеп чыккан хатыны сарылды:

— Кер-мәәә, кермә, Бәхтияр!..— диде хатын бала анасыннан да ачырак кычкырып.— Кермә... Алты балаң белән нишләрмен?..

Бәхтияр селтәнеп карады, ләкин аның селтәнүе ул кадәр үк гайрәтле түгел иде инде.

Кайсыдыр берәү:

— Кермә, кермә, Бәхтияр, балаларыңны ятим итмә,— дип өстәп куәт биргәч, ул борылып ук чыкты. Бәхтиярны тыйган тавыш янә.

— Менә, ыржык кебек яшьләр бар... Кирәгез, егетләр,— диде һәм ...әйдәр каршысына килеп басты.— Йәле. Аю токымы, күрсәт әле үзеңнең нәселеңә хас өлгерлекне.

...әйдәр мондый борылышны һич көтмәгән иде, ул теге апай сүзен бетергәнче үк ак кәгазь сыман агарынып калды, телен йотты.

Шулвакыт үсмерләр каршысына Фирәзә килеп чыкты:

— Йә?!— диде ул иреннәре аша сыгып Искәндәргә.— Йә, Искәндәр?!

Болай да ой эченә ташланырга соңгы тәвәккәллеген туплап торган Искәндәргә шушы таләпчән тавыш соңгы этәргеч, канат булды.

Ул хатыннар янына атылып барып бер чиләк суны өстенә койды, башына иске бишмәт каплады һәм тирән итеп сулыш алгач, ишеккә ташланды, күз ачып йомган арада юк та булды.

Янгынга җыелган халык, андагы ыгы-зыгы, бер-берсенә бирелгән боерык-киңәшләр берьюлы тынды, ишегалды өстендәге тынчу һавада бары тик:

— А-аһ!— дигән кыска, ләкин фаҗигале аваз бөркелде.

Соңыннан сөйләде Фирәзә, соңыннан барлык кызлар алдында ничәмә-ничә тапкыр горурланып сөйләде:

— Мин... мин Искәндәр башына су коеп, эчкә атлаган мизгелдә тын алган идем,— диде ул.— Искәндәр Фәргатьне кочаклап су сибүчеләр янына чыгып егылганчы тынсыз тордым, кызлар...

Искәндәрне ут эченә кертеп җибәрде җибәрүен Фирәзә, әмма үзе аның белән кергәндәгедән аз пешмәде. Аның йөрәге тынсыз торудан чак кына туктамады... Ярый әле, бәхетенә һәм бәхетсезлегенә каршы, җыелган халык тәрәзәдән эчкә туктаусыз су аткарып тора иде...

## 2

Кичә кичкырын ирен Мәскәүгә озатып калган Фирәзә, киң һәм йомшак урынына сыймыйча, бәргәләнә-бәргәләнә елый иде. Башында буталган үкенечле уйлар үзәкләрен өзеп-өзеп ала, бәргәләнергә, әллә кайчаннан бирле чыкмаган күз яшьләрен киселгән каен төбеннән бәреп чыккан сут шикелле мөлдерәп коелырга мәҗбүр итә иде. Нигә, нигә соң мин шундый бәхетсез? Нигә соң мин үзем яраткан, җанымны гына түгел, тәнемне дә башлап тапшырган кешене рәнҗеттем дә, аңа чыгудан баш тарттым? Нигә соң бу язмыш нибары бер сыңар бала да бирмәде? Нигә соң мин инде онытып бетердем, гомеремне шулай җәза-җәфа эчендә уздырырмын дип ышанып беткән көннәрдә генә Искәндәрне яңадан күрдем? Ул соң, ул соң ничек кыюлыгы җитеп безнең өйгә килеп керде икән? Хәер, Сәйдәрнең хатыны мин икәнлекне белмәгәндер ул, мөгаен. Чөнки көннәрнең берендә җир читенә китте дә олакты, кайтмады, хәбәр бирмәде. Аның әнә шундый үҗәтлегенә үч итеп чыкты бит Фирәзә Сәйдәр Җынчуринга.

...Урта мәктәпне тәмамлап чыккан көннәр Фирәзәнең хәтерендә өлгергәнлек аттестаты алу белән генә түгел, тагын татлылыгы, кабатланмаслыгы һәм ачылыгы белән гомер буе җәфаланырлык вакыйгасы белән дә истә калды. Аттестат алганның иртәсендә Фирәзә белән Искәндәр мәктәпкә кереп тиешле белешмә юнәтteләр дә паспорт кайгыртып райүзәккә киттеләр. Искәндәр инде ул вакытта бераз тернәкләнгән, җәйге көннәрдә йөрергә дип үзенең күзләре шикелле зәңгәрсу төстәге велосипед алган иде. Авылны аерым-аерым чыктылар. Бикчабар елгасы башында очрашырга сөйләшкәннәр иде.

Һәрвакыттагыча, Фирәзә соңга калыбрак килде. Искәндәр аны күпереп үскән яшел чирәм өстенә чалкан ятып көтә иде.

— Искәндәр,— диде Фирәзә йомшак кына итеп.— Искәндәр, ни карыйсың ул кадәр?

Искәндәр яткан җиреннән сикереп торып утырды.

— Фирәзә... Килдеңме, Фирәзә?— Ул утырган җиреннән куллары алга сузды, Фирәзәне үзенең кочагына чакырды. Фирәзә Искәндәр кочагының җылылыгын, көчле кулларының җилкәләрен авырттыра төшеп кысачагын алдан ук тоеп тирән сулыш алды һәм икә арада калган дүрт-биш адымны атлап үтте.

Әйе, ул вакытта кочаклашу, үбешү алар өчен сер түгел, тылсым-

лы сихерләнүләрне татыган-кичергәннәр иде инде. Алар шушы тылсым һәм сихер аша мәхәббәт кыясының мавыктыргыч көченә, чагыштыргысыз биеклегенә торган саен якынлаша баралар иде.

Кем белгән, кем белгән бит аны. Искәндәр белән Фирәзәнең шушы биеклеккә нәкъ менә шул көнне менеп җитәселәрен?

Районда эшләре уңды аларның, документларыгызны ике көннән килеп алырсыз, диделәр.

Дөрес, алар әле тиз генә кайтып китмәделәр, район үзәгендәге кибетләргә кереп йөрделәр, ашханәсенә кереп гуляш ашадылар, «морс» эчеп чыктылар. «Дөньяда ике генә нәрсәне — сине һәм менә шушы кызыл суны яратам мин»,— диде Искәндәр болай да исәрләнгән Фирәзәнең йөрәген әллә нишләтеп...

Аннары кайтырга чыктылар.

Аннары район үзәге белән ике арадагы калын карурманга җиттеләр...

Аннары Чәчәкле аланында учлап-учлап җир җиләге, каен җиләге ашадылар.

Аннары агач яфракларын, җиләк сабакларын иркәләп-иркәләп искән җылы һәм йомшак җил аларны әллә нишләтте.

Аннары алар җиләк сабакларына күмелделәр. Дөньяданиләр барын, үзләрен нинди бормалы-бормалы сукмаклар көткәнлеген исләренә дә кертеп карамыйча Яшьлек түземсезләнеп көткән Рәхәт диңгезенә сикерешеп төштеләр. Колачларын җәеп шуның дулкыннары өстендә тирбәлергә керештеләр...

Аннары алар бер-берсенә күз сирпеп карарга да кыймыйча озак яттылар.

— Фирәзә, кадерлем,— диде Искәндәр һәм тынып калды.

— Нәрсә, Искәндәр җаным?

Искәндәр тагын тирән итеп сулыш туплады.

— Без... безгә кайтыйк инде хәзер... Без бит бер-беребездән башка яши алмыйбыз.

Фирәзә дәшмәде.

Фирәзә бик озак, ялыктыргыч озак дәшмәде.

Искәндәр, Фирәзәнең сулкылдап елый башлавын сизеп, урыныннан күтәрелде.

Алар торып утырдылар. Хәер, Искәндәр торып утырды. Фирәзә исә шундук яңадан җиләк сабаклары өстенә авып төште. Тик бу юлы инде ул аларга җилкәсен түгел, үзенең кайнарланган битләрен, кабарынган иреннәрен куеп ятты. Ятты һәм сукылдавын дәвам итте.

Искәндәр бу хәлдән бөтенләй аптырап калды.

— Ни булды, нигә син болай итәсең? Нигә син, Фирәзә, безнең иң бәхетле көнебезне күз яшьләре белән чылатасың?— диде Искәндәр ике кулы белән Фирәзәне күтәреп алырга, янәшәсенә утыртырга тырыша-тырыша.

Фирәзә дәшми генә сулкылдавында булды. Хәзер инде аның сулкылдавы-үксүләре көчәйгәннән-көчәя барып, әллә нинди шомлы елауга әверелде.

— Туктыйсыңмы син, юкмы?— диде, ниһаять, аптыраудан ни кылырга белмәгән Искәндәр тавышының кинәт үзгәреп, көчәеп һәм басынкыланып, утырып җиткән ирләр тавышына әверелүенә гаҗәпләнеп.— Тукта дим... — Ул Фирәзәне күкрәгенә кысып торды, аннары үзеннән кул сузымына ераклаштырып җиргә бастырды, битләренә каплаган кулларын каерып алды.

— Юләрләнмә, Фирәзә... Тукта дим...

Фирәзәнең баш миендә яшерен бер кыл зыңгылдап куйды һәм ул, теле нәрсә сөйләгәнне белмичә, сулкылдый-сулкылдый:

— Юләр... Юләр шул мин, юләр... Юләр булмасам... Нишләттең син мине, нишләттең, Искәндәр? Нигә мине бу урманга алып кил-

дең? Нигә мине шул хәлгә җиткердең? Нигә? Нигә? Нигә?— һәм ул үзен-үзе белештермичә beләкләрен аптыраулы Искәндәр кулларыннан тартып алды да аның әле генә татыган мәхәббәт рәхәтеннән, наздан арынып бетмәгән битләренә уңлы-сулы сугарга, сугарга, сугарга кереште.— Нишләттең, нишләттең???

Искәндәр карышмады, йөзен яшермәде. Фирәзәнең шашып-шашынган кулларын тотмады, ничек басып торган булса, шул хәлдә калды, торагаш булып катты.

Ниһаять, Фирәзәнең куллары хәлсезләнеп асылынып төште. Иреннәре сүз әйтәлмәс хәлгә җитте һәм ул, күз аллары томаланып, Искәндәрнең күкрәгенә капланды.

Күпме вакыт шулай басып торганнардыр. Фирәзә соңыннан да чамалый алмады, әмма беравыктан Искәндәрнең куллары үзенең чәчләреннән сыйпап иркәләгәнен тойды һәм ул инде үзен шундыйшундый бәхетле итеп сизде. «Менә хәзер без Искәндәрләргә кайтырбыз... Рәхәтләнеп яши башларбыз. Безнең балабыз булыр. Без аны назлап кына үстерербез».— дип уйлап алды баштарак. Ләкин тагын берничә мизгелдән, икенче бер уй аның колагына пышылдап кына: «Һәм шулай бала-чагага күмелеп авылда яшәп калырсыңмы?»— дип әйтте. Бу аңа кыюлык бирде, ул Искәндәрдән күпты һәм аңа карамаска тырышып:

— Юк, Искәндәр, без Казанга... укырга китәрбез...— диде. — Без бит анда да бергә-бергә булырбыз, әйеме?..

Казан каласы аларны үзенең таш диварлары-йортлары, шаушулы урамнары, кеше тулы парклары белән каршы алды. Баштагы көннәрдә аларга тулай торакта урын табылмады. Дөрес, Фирәзә бу хәлгә артык кайгырып та тормады, чөнки аның әллә ни ерак булмаган туганнары табылды. Ә менә Искәндәр беренче атнаны тимер юл вокзалы белән елга порты эскәмиясендә уздырды. Көннәре бик үк мәшәкатьле сыман тоелмады аңа, чөнки көннәрен ул үзенең төзүче инженерлар институтына барып консультацияләр алырга, аннары Болак буена килеп Фирәзәне күрергә, аның белән Кремль эчендәге биналарны, Ленин укыган университетны карарга, паркка барып йөрергә дә иренмәде. Шулай булса да биш-алты төннән аның түзәрлеге, вокзалларда утырган килеш йокларлыгы калмады. Өстәвенә, соңгы төнне — күрәсең, бу егет инде күзгә чалынып өлгергәндер — ике милиционер килеп, аның документларын сорадылар. Искәндәр өр-яңа паспортын алып күрсәткәч тә алар: «Сез нишләп монда, нишләп тулай торакта түгел?»— диделәр, үзләренең бүлмәсенә алып кереп, тегесен-монысын язып алдылар.

Шуңадырмы, иртәгесен Искәндәр институтка бармыйча, Фирәзә янына китте. Аның кыяфәте әллә ни мактанырлык түгел, ярыйсы гына таушалган, кәефе дә шуның шикелле генә иде.

— Булмас, ахрысы, Фирәзә, миңа кайтып китәргә туры килмәгәе,— дип сүз башлаган иде... Фирәзә аны «эттән алып эткә салды», егетнең мин-минлегенә ярыйсы гына сукты. «Син нәрсә,— диде ул, Казанда бары тик Искәндәр Фидаяров кайчан килер дип көтеп торганнар, дип уйлыйсыңмы әллә? Нигә син институтның комсомол комитетына кермәдең? Нигә, мин фронтовик баласы, яу кырында һәлак булган сугышчы улы димәдең? Әнә... Сәйдәр Тынчурин да синең институтка керә. Ул урын тапкан, аның бер үзенә бер бүлмә... Бар, бар да кер аның янына, ул бит авылдашың, сабакташың, яшьтәшең синең... Куып чыгармас, юлын да күрсәтер...»

Искәндәрнең Фирәзәгә ышанычы, аңа тугрылыгы шул хәтле көчле иде ки, Сәйдәрнең һәркөнне Фирәзә янына килеп-китеп, аны паркка, киноларга чакыруын башына китереп тә карамады.

Дөрес, Фирәзә: «Син, Сәйдәр, вакытыңны әрәм итмә, имтихан-

нарың турында кайгырт».— диде. Тегесе аңа карап кычкырып көлде генә: «Син үзеңне бел. Минем өчен кайгырма...— Һәм, кызулык беләнме, әллә бераз гына Фирәзә алдында мактанасы килепме, ычкындырды:— Минем керү хәл ителгән, әтинең бик шәп танышы шушы институтта укыта».— диде. Фирәзә шунда гына Казанга килгән чакларын исенә төшерде. Зәйдәрнең әтисе белән килүен һәм Чистайда пароходта ике тапән алып килүен шәйләп калган иде ләбаса. Әле Искәндәргә дә: «Карале, карале, Искәндәр».— дип күрсәтә башлаган иде дә, ниндидер шау-шу аларны бүлдерде.

Шулай итеп, Искәндәр белән Зәйдәр бер бүлмәдә яши башладылар.

Ә аннары, аннары Фирәзә күзгә-башка күренмәс булды.

Бер барды, ике барды, өч барды Искәндәр, ләкин Фирәзәне очрата алмады. Фирәзә чыкмады һәм, мөгаен, чыга да алмас иде. Чөнки ул бу көннәрдә җиңгәсе белән генә серләшеп, ул алып килгән врач ярдәмендә карурман аланында кичергән мәхәббәтенә хыянәт итә, шушы мәхәббәтнең җимешеннән арына иде... Фирәзә авыр газапланулар кичерде, аның йөрәге куркудан тавык йөрәге кебек кечерәеп-кечерәеп калган вакытлар да булды, әмма тәҗрибәле врач һәм андый эшләрдә тагын да тәҗрибәлерәк җиңгәсе үз эшләрен эшләделәр. Фирәзә, авырту һәм куркуларын санамаганда, хәвеф-хәтәрсез генә котылды бу йөктән...

Шулай да ул карынында җан иясе ярала башлаганны тоеп-сизеп йөргән затка әверелгән иде инде. Үзенең хатын-кызларга хас, берниндиаңлатуларга буйсынмый һәм бер генә төрле кануннарга да карамый торган фикерләве белән аклану җаен тапты. «Әгәр дә мәгәр институтка керә алсам,— дип үзенә-үзе сүз бирде ул,— авырлы икәнлегемне Искәндәргә белгертмим һәм, берәр төрле җаен табып, арынам... Яшьлегемне харап итәр хәлем юк, яңадан шушы авылга кайтып сыер саварга, дуңгыз карарга керә алмыйм... Тагын булыр әле... Әнә бит әнисе: «Орлыгы Бохарада түгел аның, акча түләп әллә кайларга барып йөрисе юк».— дип ычкындырды күрше хатыннарына... Ә менә хәзер Фирәзә «андый нәрсәнең» орлыгын Бохарага гынамы, әллә кайларга хәтле барып эзләп карады, әмма тапмады. Хәтта Карловы Варыдагы атаклы профессор да аңа ярдәм итә алмады. Дөрес, ул Фирәзәнең үзен генә чакыртып: «Эшнең сәбәбе сездә түгел, сез ахыр чиге, бик нык яраткан, үзегезне тетрәндергән мәхәббәтне очратсагыз, ана булу шатлыгын кичерерсез, әмма ирегез...»— диде. Борынычландырды, имеш... Шул көнне үк Зәйдәрне гаҗәпләндереп: «Әйдә, Бынчурин, кайтып китик илгә».— дип кыстый башлады. Аннары, нибары биш көн калды бит, түзик инде дип ялынгач кына, калырга булды.

Тегe чакларда Искәндәр белән бер ай чамасы очрашмады ул. Әллә нинди бер шаукым ерагайтты да ерагайтты Фирәзәне Искәндәреннән. Җәйге каникуллар җиткәч, Искәндәр иптәшләре белән чирәм җирләргә төзү отрядына язылып китәргә җыенды. Фирәзә моны хыянәткә санады. «Йә минем янда каласың, йә шул далаларга китәсең».— дип катгый таләп куйды Искәндәргә. Мондый газаплanулардан Искәндәрнең түземлеге сына башлаган чак булды, күрәсең. Тагын да бер көнне Фирәзә шушы таләбен кабатлаганнан соң: «Син, Фирәзә, беләсең бит, миңа Бынчуринга килгән кебек килеп тормый. Минем дә бит кеше арасына чыгардай берәр костюм алып киясем килә».— дип каршы төште.

Шушы сүзләр генә җитмәгән дә, шушы тамчылар гына касәне чайпалдырмый торган икән. Фирәзәнең барлык кирелек-тискәрелекләре бер-ике секунд эчендә өермәгә, аннары инде көчле туфанга әверелде. Ул үз-үзен белештермичә Искәндәрнең йөзенә нәфрәтле, бозлы, һәрберсе чеметеп кенә калмыйча, йөрәгенә үк үтеп төшәрдәй

сүзләрен сибәргә керештe: «Син, син соң Ис...кәндәр... Ма...ке...донский... үзеңнең кем икәнлегеңне белми идеңмени соң? Нигә дип син алай булгач институтка килеп кердең? Ни дип син минем башымны әйләндердең? Ни дип? Мине... ел буена бер тапкыр үз акчаңа киногa да алып бара алмагач...»

Тагын нинди генә сүзләр әйткән булыр иде Фирәзә кызулык өянәгенә бирелеп, анысын хәзер дә чамалап карый алмады. Ләкин... ул Искәндәрнең ничек итеп йөзеннән кан качуын, аның һәрвакыт тулы, үзенә тартып «мине үп, мине үп», дип чакырып торган иреннәренең кара көеп чыгуын, ә күзләреннән нәфрәтле чаткылар чәчелүен күреп, телен тешләде. Ләкин... соң, соң иде инде. Әйтеләсе сүзләр әйтелгән, очасы сүзләр читлектән чыккан каракош балалары кебек күкләр киңлегенә чыгып очкан иде шул инде.

Икенче мизгелдә Фирәзәнең яңагында әллә нинди бер нәрсә шартлап ярылгандай булды, аның күзләреннән тубал хәтле чаткы очып чыкты һәм кыз аркасы белән якындагы агачка килеп бәрелде... Шушы агач аны егылудан саклап калды, ләкин тормыш һәлакәтеннән саклап кала алмады. Ул күзләрен ачып, теле белән ни әйткәннәрне чамалый алырлык хәлгә килгәндә, Искәндәр аның янында юк иде инде...

Шул китүеннән соң егерме елдан артыграк вакыт узгач, ниһаять, ул үз аяклары белән, аны-моны әйтмичә-кисәтмичә, кыш уртасында яуган ләйсән шикелле, Фирәзәнең өенә килеп керде.

Менә бер айдан артыграк инде Фирәзә шушы Ләйсәннең җылысын тоеп, бер үк вакытта җаны өзгәләнеп яши. Аның бөтен сүзләрне-күзләрне калдырасы да, кайчандыр үзенең мәхәббәтен, җанын һәм тәнен тапшырган Искәндәр янына атылып барасы килә. Ул очрашуның кайда, нинди урында булуына карамастан, берәүдән дә курыкмыйча, барысына да ишеттереп:

— Искәндәр! Мин сине хаксызга рәнҗеттем... Сине үземнән-үзем кудым, бәгыремнән өзеп әллә кайларга, әллә кемнәр янына китәргә мәҗбүр иттем. Мин сине генә түгел, үземне дә гомерлек кайгыга салганмын икән... Кичер! Кичер син мине, Искәндәр, булдыра алсаң?— дип аның күкрәгенә капланасы килә...

Ләкин ничек соң аның каршысына барырга да, ничек башларга андый сүзләрне?

3

Кичкә таба күк йөзе болытлардан арынды, атнадан артык искән көчле җил дә тынып калды. Инде җир өстенә калын булып кар яткач, һава агымы тыгызланды, хәтта күкрәк тутырып сулаган чагында аның авырлыгы тоелган кебек була башлады.

Көмеш Аланнан әллә ни ерак түгел бер җирдә, Борынгы елганың күз күреме җитмәслек әйләнеч ясап, кош-кортка җиләк-җимешкә бай бер тугай хасил иткән урынындагы төзелеш мәйданы өстендә утлар кабынды. Алар әлегә күк йөзенә сибелеп-сибелеп куелган Җидегән йолдыз һәм аның тирәсенә тупланган тоныграк җисемнәрне хәтерләтә. Җидегән йолдызның чүмечен хасил иткән йолдызлар сыман утырачак атом реакторларын урнаштырыр өчен коточкыч зур һәм тирән нигез чокыры казыла. Фидаяров килгән көннәрдә дә биредә әле җир йөзеннән югалырга, туачак Гыйфрит йотарга тиешле авылның берничә йорты тора иде. Хәзер аларның барысы да диярлек күченде инде, нибары бер карт агай гына үз нигезен ташлап китәргә теләмәде. Аны тегеләй дә, болай да үгетләп карадылар — күнмәде. Көмеш Аланда яңа гына төзелеп беткән йортның өч бүлмәле квар-

тирына ордер китерделәр — әйләнеп тә карамады: «Син Совет власте яклымы соң, әллә аның дошманымы?» — дип куркытырга тырыштылар — керфеге дә селкенмәде. «Алайса, ялынмыйбыз, җәһәннәмгә ишелеп төшкәнче утыр шушы чалшаеп калган өеңнең эчендә, без котлован казырга керешәбез»,— диделәр — барыбер курыкмады. Агайның яхшылык белән үгетләделәр: «Соң бит, агай, син аңларга тиеш сең — минә синең йортың торган урында атом реакторының йөрәге тибәчәк. Шулай туры килгән, язмышның шундыйдыр инде».— дип карадылар — «Кешене нигезеннән яздыручы Гыйфрит ялчылары сез»,— дип кулын изәде. Нәһаять, картның тискәрелегенә игътибар итмичә, әллә бар ул әллә юк, капкасы белән өй стеналарына нибары ике-өч адым чамасы ара калдырып, казырга керештеләр. Куәтле бульдозерлар, әллә нинди, филсыман скреперлар чын-чын Гыйфрит явы гөрелдәде, көнләп түгел, сәгатьләп җирне казып, эчкәре таба тирәнәйделәр. Агайның йорты-җире, диңгез уртасындагы уч төбе хәтле утрауда үскән сыңар пальма агачы шикелле, биектә торып калды — агай күнмәде, нигезен ташлап китмәде. Бер көн җитте ки, агайга кибеткә чыгар өчен вертолет кирәк була башлады — барыбер күнмәде. Нәһаять, танылган төзүче Наур үзенең егетләренә агай йорты тирәсеннән бүтән казымаска боерды, чөнки агайның йорты утырып калган җир баганасы сизелер-сизелмәс кенә янтая башлаган кебек иде. Агын вәкилләр килде, аларны агай янына меңгерү өчен унлап ир-егет алмаш-тилмәш сәгатьләр буена баскыч казыды. Ләкин комиссия әгъзалары ул баскычтан «пальма башындагы оя»га, үзсүзле «Робинзон» янына менүдән баш тарттылар. Утрау башына менеп кунаклаган егетләр агай өенә кереп чыгарга ниятләделәр.

Алар килеп кергәндә ата-бабасының нигезеннән китәргә теләмәгән бу агай, ярый әле ялгызы гына яши иде, түрдәге сәкесенә урынын җәйгән дә «Бу дөнья белән алыш-бирешем бетте, шушы нигезебезне атом Гыйфрите җәһәннәмгә әверелдергәнче чыксын җаным»,— дип сузылып яткан иде. Бары тик шунда гына инде атнаун көн пальма башындагы «оя»сыннан чыкмавын, күзгә-башка күренмәвен искә төшерделәр. Агайның тешләрен каерып ачып, авызына су салдылар, беравык маташканнан соң ул күзләрен ачып җибәрде. «Йә инде, агай, бимазалама үзеңне, яңа дөнья һөҗүменә каршы төшеп маташма, син аны барыбер туктата алмыйсың. Тегермәче зур аның, алга таба туктаусыз тәгәри дә тәгәри, астында каласың бит болай булса»,— диделәр. Үзсүзле агай хәлсез күз кабакларын ачарга тырыша-тырыша: «Юк, күчмим, чыкмыйм»ны аңлатып, башын янякка селкетеп куйды, шундук күзләрен чатырдатып йомды да сузылып яткан килеш әҗәлен көтәргә кереште.

Егетләр аска төшеп хәлне аңлаттылар.

Төзелешнең баш инженеры Тынчурин шул тирәдә икән, аны чакырдылар. Ул инде вакыйгадан хәбәрдар булып чыкты. Килеп җитүгә:

— Дөмекмәгәнме?— дип, кистереп сорады. Төзүчеләр дәшмәде. Алар инде Тынчуринның кем икәнлеген, кискен урыннарда сүз сайлап азапланмавын беләләр иде.

— Каяле, үзем менеп соңгы тапкыр сөйләшеп төшим әле,— диде ул һәм егетләр ясаган баскычтан җиңел адымнар белән менеп тә китте. Бераз менгәч артына борылып карады, артыннан менеп килүче Өмет Наур белән тагын бер егеткә нәрсәдер әйтмәкче булган иде — әйтмәде, өскә таба күтәрелүен белде.

Нәһаять, ул капка төбендәге, күп булса ике-өч адымлык мәйданга менеп җитте, астагыларга карап алды. Андагы филсыман скреперлар, куәтле үзбушаткычлар ярыйсы гына кечерәеп калганнар, ул утырып килгән «Волга» исә бөтенләй уенчык сыманрак күренә иде.

Ул арада аның артыннан атлаган Өмет Наур белән механизатор

егет тә менеп җиттеләр. Алар белән бергә беркавым тын алгач, Тынчурин:

— Сез, егетләр, торып торыгыз шунда, мин үзем генә кереп сөйләшәм, кирәгегез чыкса, чакырырмын,— диде дә ныклы карарга килгән һәм ни кыласын төгәл белгән кеше кебек, капкадан кереп китте.

Ишегалдында биш-алты тавыгын ияртkән әтәч җим эзләп йөри иде. Алар шөгыльләреннән туктап, тагын кем комачаулый, дигәндәй башларын күтәреп, муеннарын тырпайтып елт-елт карагандай иттеләр. Җил-җил атлап килгән Тынчурин йорт эченә кереп югалды.

— Әй, иптәшләр,— диде ул капкадан чыга-чыгышка кычкырып.— Картыбыз соңгы минутларын кичерә бугай. Әйдәгез тизрәк скорый чакыртыйк. Югыйсә картның тыны-тавышы юк. Нибары бер тапкыр сыңар күзен ачып карады.

Баярак менгәч тә, картны күреп төшкән егет:

— Алай ук түгел иде бит әле...— димәкче иде дә, Тынчуринның нәфрәтле карашына төртелеп, әйтергә җыенган сүзләрен бугазында ук буып калдырырга мәҗбүр булды.

«Инде нишләргә, бу агайны нишләтергә?» — дигән сорауны хәл итәр өчен трест, Көмеш Алан, Түбәньяр районы җитәкчесе, хәтта төзелешкә килгән берләшмә башлыгы — Бабакай үзе дә килде. Агайны оясыннан алып төшү үзе бер проблемага әверелде. Шулай да җаен таптылар: булачак реактор чокыры янына тезелгән «Волга»-ларның берсенә утырдылар да, тиз генә Ширәмәткә барып, янгын сүндерүчеләрнең кызыл машинасын алып килделәр. Анда эшләүче егетләргә ни тора ул: кызыл машинадан алагаем баскычны суздылар-суздылар да, реактор чокыры кырыендагы җимерелгән зират, анда күренеп торган кеше сөякләре өстеннән узып, баскыч очын агай өенең ачылмалы тәрәзәсе төбенә терәделәр. Һәм шушы баскычтан... (хөрмәтле һөнәр ияләре, зинһар гафу итсеннәр, башка чагыштыру таба алмадым) пальма башындагы «оя»га җитез маймыллар сыман үрмәләшеп менеп тә киттеләр. Аннары алар хәлсез-хәрәкәтсез агайны әле генә үзләре менгән баскыч өстенә юрганы-ние белән җайлап-беркетеп тә куйдылар. Баскыч үзеннән-үзе тагын кызыл машина эченә кереп югала башлады. Шулай итеп, агай «сират күперен» кичте. Аста ашыгыч ярдәм машинасы күптән көтеп тора иде инде. Ак халатлы фәрештәләр чыгып, агай янына ашыктылар. Аларның өлкәне баскычта яткан килеш үк агайның беләгеннән тотып карады. Беравык шулай матавыклангач, ачуыннан булса кирәк, уң кулын күтәреп кылыч белән чапкан хәрәкәт ясады һәм кызыл хачлы машинасы янына чигенде.

Бу хәлне күзәтеп торган төзүчеләр, алар арасында Фидаяров егетләре дә бар иде, шаулашып куйдылар. Кемнеңдер: «Бөркет үз оясында үлә»,— дигәне ишетелеп китте.

Ул арада ашыгыч ярдәм машинасы, «утрау» тирәсеннән әлмәк ясап борылды да, җир өстенә алып менә торган юлдан үрмәләде.

— Менә сиңа мә!— диде Остап Безбожный үзенең сары мыекларын селкетеп.— Бөтенләй үк үлгәнме соң әллә ул агай?

Арадан берсе көлеп:

— Юк, нишләп бөтенләй булсын, яртылаш кына үлгән,— диде.

Шундук аңа каршы төштеләр:

— Алай димә, бу агай бөтен уңайлыклары булган фатирга кызыгып, нигезен авылдашлары кебек җиңел генә ташлап китсә, аңа мондый ук тантаналы үлем килер идеме? Әнә кара, ничәмә-ничә «Волга» гына басып тора...

Агайның тискәрелеге аркасында реактор чокыры уртасында хасил булган «утрау» тирәсенә филсыман скреперлар тезелеп баскан. Алар артына, үткер теш-пычакларына таянып, бульдозерлар тезел-

гән. Чокыр тирәнлегеннән ясалган әйләнмәле юлда казылган җирне чыгаручы «МАЗ»лар, «Беларусь»лар, «КрАЗ»лар, алар янында җыйнак, житез, көяз «КамАЗ»лар белән «Татр»лар туктаган иде.

Агайны алып китүче ашыгыч ярдәм машинасы «утрау» тирәли әйләнеп узган чакта әлеге машиналарның барысы берьюлы клаксоннарына бастылар. Төрле көрлектәге тавышлар бергә кушылудан тулы бер оркестр авазлары хасил булды.

Бу күренешне язып та, сөйләп тә бирерлек түгел: аны бары тик шушында торып күрергә, ничәмә-ничә төрле тавыш хасил иткән оркестрның үзәк өзгеч бердәм авазын үз колакларың белән ишетергә кирәк иде. Бары тик шул чагында гына әлеге күренешнең көчен, дөньяның фанилыгын, тормышның төрлелеген, фаҗига-шатлыкларын аек акыл белән чамалап була, әмма ләкин кешеләрнең үз куллары белән җир өстенә үлем чыганагы коруларын, кыяматкә тик һәлакәт әзерләүләрен әлегә берәү дә әйтеп бирә алмый иде.

Фидаяров та бу күренештән тетрәнеп куйды, аның күңелен БАМ якларында яшәгәндә һәм хөкем эскәмиясенә басар алдыннан кичергән көннәрендәге сыман авыр уйлар биләп алды.

«Әйе, Җирдәге халыкларның алга таба хәрәкәтен берәү дә туктатып тора алмый,— дип уйлады ул котельный төзелә торган мәйданга таба атлый-атлый.— Җирдәге байлык-чыганаклар да чиксез түгел. Аларны һәрвакыт тулыландырырга, ниндидер чыганакларны эзләп табарга туры килә. Бигрәк тә энергетика чыганакларын. Ләкин тарих, чал тарих ата-бабаларыбыз нигезен туздырган, бәлки, киләчәк буыннарга һәлакәт әзерләп калдыруыбыз өчен безне акларммы? Реакторның нигез чокыры казый торган җирдә катлам-катлам булып тарих ята. Әнә кызыл, саргылт комлы, төсле-төсле булып берсе өстенә берсе яткан катламнарда тарих үзе язып калдырган «язмаларны» укырга мөмкин. Тел аңлый белгән кешегә, мөгаен, әллә нинди серләр сөйлидер алар. Әмма әлегә безне, ерактагы заман серләрен аңлый белмәгән кешеләрне, шушы катламнар уйландырмый. Алга таба барганда һәрвакыт аяусыз булырга, тарих чытырманлыгын ерып барырга туры килә. Без ул каршылыкларны лаеклы төстә уза алабызмы соң? Без, кешеләр, ялгышмыйбызмы? Максатка ирешүдә без Җир шары дигән изге анабызга хилафлык кылмыйбызмы? Максатка ирешүдә без бик күп алымнарны беләбез. Алар күбесе, кызганычка каршы, кеше затының җирдә исән-имин яшәвенә комачаулый. Хәер, ул зат бит үзе үк аны вата-җимерә, сулар һавасын, эчәр суын бетерә. Ләкин Җир ананың көче, чыганаклары чиксез түгел. Алар, иртәме-соңмы, бетәчәк... Тарих һәм Җир. Яшәештәге бурычны аңлау һәм шуңа тугрылык кына Адәм балаларын киләчәккә таба алып барачак...»

* * *

...Хәтерендә: ял көне иде. Хатыны Нәркизә: «Зөлфияләргә барып көн уздырып кайтам әле»,— дип кунакка җыена башлады. Искәндәр аңа: «Әле теге атнада гына булдың бит, бергә-бергә ял итик бүген. Мондый мәшәкатьсез көннәрем сирәк ләбаса»,— дип караса да, Нәркизә җыенуын белде. «Әллә соң машина чакырыймммы, тизрәк йөрер идең?»— дип кайгыртты Искәндәр. Ләкин Нәркизә аның бу сүзләреннән сискәнебрәк: «Юк, юк, Искәндәр, кирәкми миңа машина. Нигә эш машинасын тоткарларга?»— дип кире какты. Искәндәр шушы җаваптан соң сагаебрак калды: теге кара «Волга» исенә төште...

Нәркизә чыгып киткәч, Искәндәр кызы Нәзирәнең (ул инде техникумның беренче курсын тәмамлап килә иде) магнитофонын жи-

бәреп, җыр-музыка тыңларга тырышып карады, ләкин андагы чит ил музыкасы аның күңел кылларын тибрәтә алмады. Әлеге шомлы фикер аңа тынычланырга ирек бирмичә, чүпрә салган камыр шикелле күперүен белә иде.

Ниһаять, Искәндәр хатыны Нәркизәнең кая китүен тикшереп карарга кирәк дигән фикергә килде. Ул моны ничек эшләргә икәнлеген белми иде. Кешегә әйтсәң, идарәдә андый эшнең осталары юк түгелдер. Ләкин мондый йомышны кешегә тапшырып булмый. Бу калада иң зур оешма — төзелеш идарәсе җитәкчесе артык күренекле урын тота. Аның һәр сүзен тулы бер җөмлә, ә җөмләсен мавыктыргыч повесть итеп кабул итүләре бик ихтимал.

Шушы уйлар белән Искәндәр «Жигули»ен гараждан чыгарды. Үзен йөртүче шофер машинаны карап, кирәк чагында юлга чыгып китәрдәй итеп тота иде. Рәхмәт аңа. «Жигули»ның тигез генә гүләп эшли башлавы Искәндәрнең күңелен күтәреп җибәрде.

Озак та үтми, Искәндәр Зөлфияләргә (Нәркизәнең университетта бергә укыган дусты) барып та җитте. Аны-моны уйлап тормыйча кыңгырау төймәсенә басты. Эчке яктан аяк тавышы ишетелде һәм ишек ачылып та китте. Зөлфиянең ире — инженер-физик, кулына ниндидер журнал тоткан килеш, күзлеген сала-сала ишек төбендәге Искәндәргә күтәрелеп карады. Аларның сирәк булса да күрешкәннәре бар иде. Таныды.

— Рәхим итегез, Искәндәр Гәрәевич, керегез.

Искәндәр, тамак төбендәге төернең кинәт югалуын тоеп, тагын да күтәренкерәк кәеф белән эчкә атлады. Ул шушы бүлмәдә үзен борчыган, җанына шом салган нәрсәдән арынырмын, Нәркизәне күрермен дә: «Өйдә генә утыра алмадым, гафу ит, синең янга килдем мәнә»,— дип әйтергә уйлаган иде.

Зал бүлмәсенә үттеләр. Хәл-әхвәл сораштылар. Ләкин кухня ягыннан да, теге яктагы бүлмәдән дә тавыш-тын ишетелмәде. Хатыннар үзләре дә күренмәде.

Шулай да Искәндәр килеп керүгә: «Хатының кайда?» — дип сорарга кыймады. Хәер, озакламый Зөлфиянең ире:

— Нәрсә соң, әллә хатыннар үз мәҗлесләрен оештырып, сезне дә куып чыгардылармы, Искәндәр Гәрәевич?— диде өстәлдәге икенче күзлеккә үрелеп.— Зөлфия сезгә китте бит...

Бая югалган төер яңадан Искәндәрнең бугазына кайтып утырды, авырттыра ук башлады. Ул:

— Әә-әй-йе шу-ул,— диде, бераз тотлыгыбрак. — Бер җир селкетеп утырышып алыйк әле, дип җыела калдылар. «Ничек, ничек котылырга бу хәлдән?» Шулвакыт аның күзләре телефонга төште.

— Рөхсәтме? Идарәгә шалтыратасы бар иде?

— Рәхим итегез, Искәндәр Гәрәевич,— диде Зөлфиянең ире.— Мин хәзер, кофе әзерлим...

Искәндәр телефонга үрелде. Үзенең эш телефонын җыя башлады. Әлбәттә, берәү дә җавап бирмәде. Әмма Искәндәрнең уенда гөнаһсыз хәйлә әзер иде инде.

Шәһәр үзәгеннән чыгып, тигез асфальт юлдан биш-алты километр үтүгә Искәндәрнең куллары, аяклары һәм бөтен гәүдәсе машина гүләвенә, аның хәрәкәтләренә кушылды. Ул башта җитмеш, аннары туксан һәм йөз километр тизлек белән җилдерергә кереште.

Алда, Ташлы елгасының борылып-борылып аккан бер төшендә гүзәл оазис, ә ул оазис эчендә Карамусаев агайның дачасы иде. Ни хикмәт, моңарчы Искәндәр Фидаяров бу якка таба борылып караганы, күз төшереп алганы да юк иде. Дөрес, сөйләгәннәрен, Карамусаев агай дачасының ниндилеген, аны кемнәр төзегәнне, аңа күпме затлы материаллар киткәнен ишеткәне бар иде төзүче Фидаяровның, бар иде...

Яшеллеккә житеп бераз баргач та Фидаяров, баярак кына булган алдашудан күңеле җилкенүне бераз басу нияте белән, юлдан читкәрәк төште һәм үзенә ошаган урынны табып, машинасын туктатты да ял итеп алырга булды. Әгәр дә ул үз юлыннан икенче тапкыр читкә борылмаган булса икән!.. Искәндәр шушы оазисны күрмәгән һәм бераз алгарак баргач «кирпеч» билгесен күреп, аннары тагын милиция постына юлыккан булыр иде. Ә болай ул аны күрмәде, юлыкмады, узып узды.

Аһ! Очраклылык, очраклылык бу! Тормышта мондый тоташтан килгән очраклылык хәлләре булмый, ялганлама, чынбарлыкка хилафлык кылма, Автор, диярсең бәлки син, хөрмәтле укучым... Кызганычка каршы, тормышның тоташ очраклылыктан гыйбарәт булган өлеше дә чынбарлык икән. Шулай икән. Әгәр дә мәгәр мин ул Чынбарлыкка хилафлык кылырга уйласам, Искәндәр Фидаяров дигән бу кешене яңа сынауларга ташлар, һәм, иң мөһиме, шушы оазиста очрашудан соң, белә торып, мин аның тормышын, тормыштагы юлын, ниһаять, аның язмышын пыран-заран китерер идемме дә, бары тик үзенең сәләте, максатка омтылучанлыгы һәм тырышлыгы белән ирешкән биеклегеннән тормышның төбенә төшереп җибәрер һәм аны «беткән кеше»гә әверелдерер идеммени?!.

Кинәт тирә-юньне яңгыратып көлү тавышы ишетелде. Агачлар арасыннан яңгырап торган көлү тавышы тынарга өлгермәде, әлеге тавышның хуҗасы да килеп чыкты. Искәндәр сәер бер сизгерлек белән чинар агачына сыенып өлгерде. Югыйсә, табигатьнең гүзәллегеннән атылып чыккан... шәрә Нәркизәнең үзенә бәрелүеннән котыла алмаган булыр иде. Әйе, Нәркизә, шундый таныш һәм шундый якын Нәркизә нибары ике-өч адым читтәнрәк узып китте. Искән җил кебек узды да китте. Кая инде ул үзенең зур корсагын көчкә күтәргән Карамусаев агайга аның артыннан куып җитү? Кая инде ул аңа өлгерлек? Ул алга таба йөгерә алмыйча, еш-еш сулаган хәлдә Искәндәр яшеренеп торган агач янына килеп басты һәм үзенең кысык күзләрен аңа төбәде:

— Кем бу? Әһә, синме?.. Синә монда ни кирәк? Син монда ничек кердең?— диде, Искәндәрдән ким аптырамаган Карамусаев...— Син, кабахәт җан, минем артымнан күзәтеп йөрисеңме әле? Син... Син... шакал баласы... Мин... мин бит сине шушы фәрештә баласына ия булуың өчен урыннан урынга күтәрдем. Башта участок начальнигы, аннары баш инженер... Инде үзеңә дә шундый мөмкинлекләр тудырдым... Рәхәтен күрә белмисең икән... үзеңә үпкәлә... Шакал...— диде.

Искәндәр агачка сыенган җиреннән чыгып баскан иде инде. Ул, ике араны атлап узды да, Карамусаевның тагын нидер әйтергә теләп ачыла башлаган ияк астына ярыйсы ук саллы йодрыгын сылады. Бу хәрәкәттән Карамусаевның тешләре шыгыр-шыгыр итеп алды һәм гәүдәсе артка таба авышырга кереште. Искәндәр тагын бер адым атлады һәм бу юлы инде сул ботинкасын «шакал» сүзе белән авыз чайкап торучы шакалның, кешегә күрсәтергә ярамый торган йомшак җиренә юнәлтте... Карамусаев күкрәгенә озын пычак кадалган чучка сыман чинап-акырып җибәрде, җирдә яткан килеш «каравыл» кычкырырга кереште.

Аның ачы тавышын ишетеп, агачлар арасыннан яшь бия шикелле уйнаклап Нәркизә килеп чыкты...

Искәндәр аны да, үзе янына ук килеп туктаган Зөлфияне һәм аның «кадерлесен» дә күрмәде. Күзләре күрерлек хәлдә түгел иде аның. Ул тизрәк машинасына таба атлады...

— Искәндәр абый, Искәндәр абый!— дип кычкырды вагон болдырына чыгып баскан Илдар Корбанов.— Бүген безгә измә бирә-

чәкләр. Төнге сменага калырга кушалар. Нәрсә дип әйтим?

Искәндәр Фидаяров як-ягына каранды һәм үзенең егетләр арасында,— туң җир кантарларына абына-абына реактор булачак нигез чокыры ягыннан кайтучылар арасында икәнлеген күрде. Йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгар хәлгә җиткән, үзе исә кимендә берничә чакрым йөгереп үткән кеше кебек еш-еш сулый иде ул.

— Хәзер! Хәзер барып җитәм. Килә!— диген...

4

Фирәзә инде эштән кайтып, тегесен-монысын карап, күптән түгел генә кулына төшкән «Мастер и Маргарита»ны укырга керешкән иде. Йомшак кына зеңгелдәп телефон шалтырады.

— Әйе, әйе,— диде Фирәзә,— Тынчурина тыңлый.

— Гафу ит, Фирәзә, борчырга туры килде. Шәрифуллин бу.

Фирәзә таныган иде инде трест башлыгының көнкүреш һәм кадрлар буенча урынбасарын, чөнки ул гына аңа шулай үз итеп эндәшә.

— Әйе, мин тыңлыйм, Шәфигулла абый.

— Эш чыгып тора бит әле, Фирәзә сеңелем,— диде Шәрифуллин. Фирәзә аның тыйнак елмаюын күз алдына китерде. Ул Шәрифуллинның йомшак җәеп катыга утырта торган гадәтен бик яхшы белә иде.

— Безгә аның чыгып тормаган чагы бармы соң?— диде Фирәзә шаярып, сүзенең ике төрлерәк мәгънәдә булуын төшенеп, үзе дә елмаеп алды.— Тагын нишләргә, иртәгә иртүк ярминкәгә китәргәме?

— Юк лааа,— дип сузды Шәрифуллин: — юк лааа, монда гына... Түбән мәйданда бер бригада кала. Аларга төне буе измә киләчәк икән. Шуларны ашатырга куштылар...— Фирәзәнең дәшмичә торуын киреләнүе дип уйлады булса кирәк.— Йә, нишлибез инде, Фирәзә сеңел?

— Кирәк булгач, барырбыз инде, тик хәзер кызлар кухняны җыештырып бетергәннәрдер инде, бер-ике сәгатьтән ярыймы соң?

— Ярый, ярый, анысына гына түзәр төзүчеләр.— Шәрифуллинның шатлыгы эченә сыймый иде. Чөнки ул әле биш-алты ай элек кенә колхоз председателе булган һәм анда төрле эшләргә, бигрәк тә сыер савуга кеше эзләп, аларның карышуына шулхәтле күнегеп беткән ки, бирегә, трест управляющие урынбасары булгач та шундагычарак эшләвен дәвам итә иде.— Машина ашханә алдына килеп баскан булыр, Фирәзә сеңелем...

Фирәзә трубканы куйды, шундук яңадан күтәрде һәм ашханәгә шалтыратырга кереште. Трубканы озак кына алмыйча тордылар, бераздан гына таныш тавыш ишетелде:

— Әйе, ашханә тыңлый.

— Наденька, китмәдегезме әле? Китмәгез, җаным, хәзер үк унсигез кешегә второй әзерләргә керешегез, салат ясагыз. Мин озакламый барып җитәрмен, яме?— диде.

Наденька, һәрвакыттагыча, канәгать түгел иде. Ул трубканы куймас борын ук: «Мин дежурда чакта шулай инде, көн юк, төн юк»,— дип мытырдый башлады. Ләкин Фирәзә игътибар биреп тормады, чөнки ул Надежда Фролованың туктаусыз шулай мытырдап йөрүен, үзе исә бөтен эшне башкалардан күп мәртәбә җиренә җиткеребрәк башкаруын белә иде.

Фирәзә халатын салып өс-башын алыштырды, җылы свитер киде дә: «Гадәттә, мондый очракта теләсә нинди машина җибәрә торган иде Шәрифуллин, бүген дә ачык машина булмагае»,— дип уйлады.

Декабрь үзенекен итә, тышта чатнама суык. Яңа салынган йортлар арасындагы сукмаклар сузылып-каралып яталар. Мондагылар көләп: «Көмеш Алан дигән булачак кала урамнарына да Кыш бабай асфальт түшәде. Хәзер әнә теләсә кайдан йөрергә мөмкин»,— дип куаналар. Чөнки яз, яңгырлы җәй һәм көзге пычракларда резин итекләр белән йөри-йөри арыган аякларга туң җирдән баруы бик рәхәт иде.

Фирәзә биредәге башлангыч чор хәлләрен күрмәде. Ул килгәндә инде берничә вагонны бергә кушып-кушып ясалган ашханә төннәрнең берендә янып киткән һәм аның урынына, бөтен эшне ташлап, хәзерге ашханәне өлгертеп куйганнар иде.

Наденьканың мытырдавы, чынлап та, гел бушка булган, чөнки ул Фирәзә апасы әйткән минуттан ук эшкә керешкән һәм плитәсен кабызып, кастрюльләрен куеп җибәргән, хәзер исә аның ак беләкләре ялт-йолт итеп кенә йөри, бармаклары арасыннан туралган кызыл чөгендер кисәкләре очып-очып чыга иде.

— Әзерләвен әзерлим, Фирәзә апа,— дип каршы алды ул мөдирне,— ну Түбән мәйданга ни за что бармыйм, яме, Фирәзә апа... Әнә Гөлниса барсын, яме. Минем әле... күрешергә барасым бар. Бу кухняда ятып кияүгә чыкмыйча калыр хәлем юк.

Наденька күзләрен йомрыландырып, авызын җыя алмыйча елмаеп Фирәзәгә карады. Аның карашы шул хәтле мөлаем, шул хәтле үтенүчән иде ки, Фирәзә ирексездән:

— Ярый, ярый, алай бик күрешәсең килгәч, үзем барырмын инде алайса,— дип вәгъдә итте.

Шуны гына көткән хәйләкәр Наденька бер кулына бала башы хәтле кызыл чөгендер, икенчесенә пычак тоткан килеш Фирәзә янына атылып килде дә: «Рәхмәт, Фирәзә апа»,— дип аның бит алмасыннан «чуп» иттереп үбеп алды. Фирәзә аңа:

— Ярый, ярый, эшеңне бел, влюбленная,— диде шелтәләбрәк. Тик аның тавышында ул шелтәнең әсәре дә юк иде. Ул шушы кызыйның бәхетенә, әле Фирәзә башында йөргән уйларның эзе дә юклыгына көнләшеп куйды. — Ярый, ярый, куштанланма...

Шул ук мизгелдә Фирәзәнең йөрәге кысылып куйды: ул үзенең өзгәләнүләрен исенә төшерде. «Элек, Искәндәрне күргәнгә хәтле дә шулай өзгәләнгән вакытларым була иде,— дип уйлап алды ул.— Ләкин болай озак һәм тетрәндергеч хәлгә төшкәнем юк иде әле. Аның безнең булачак шәһәребезгә килеп чыгуы... бер генә дә яхшыга түгел инде. Дөрес, минем Тынчурингә карашым-мөнәсәбәтемне ул килеп кенә үзгәртмәде, без элек тә шулай этле-мәчеле идек. Әмма хәзер мин үземнең т е г е вакытта нинди хыянәт кылуымны аңлыйм, вәгъдәләшкән, «әйдә, Фирәзә» дип миннән башка яшәүне күз алдына да китермәгән кешегә хыянәт кылуымны, баласын... карынында килеш үтергәнемне аңлыйм... Хәзер ул эшне бары тик шундый сүз белән генә аңлатып була. Үземне ана булу бәхетеннән мәхрүм итү генә җитмәгән, Искәндәрнең тормышын да боздым. Ул бит мин китергән кайгыларны, минем кылануларымны күтәрә алмыйча институттан чыгып, армиягә китеп барды. Мин инде аны онытканмын, болай гына, яшьлегемнең беренче мәхәббәте булганы өчен генә искә төшергәлим, дип уйлап йөргән идем. Юк, һич кенә дә алай булмаган икән шул...»

Озакламый кухня ишеге төбенә машина килеп туктады.

Термосларны машинага төяп, шофер янына менеп утыргач та Фирәзә каушавын, эченә салкын йөгерә башлавын тойды. Бик сирәк була торган хәл иде бу. Бары тик бер тапкыр, теге вакытта райүзәктән кайтканда җиләкле аланында туктагач кына... булган иде Фирәзә белән мондый хәл.

— Туктале, тукта, энекәш,— диде ул шоферга.— Булмый болай, мин үзебезнең савыт-сабалар янына күчеп утырыйм әле. Анда синең түзәрлектер бит...

Шофер машинасын яманлабрак телгә алгангамы:

— Нишләп, Фирәзә апа, минем машинаның вахта йөртер өчен махсус кузовлы икәнлеген белмисеңмени? Аның менә диган миче дә бар әле хәтта,— диде үпкәләбрәк.

— Бигрәкләр дә шәп. Күчим әле шунда.

Ул үзенең бөтен тәне белән калтырана башлавын күрсәтмәскә тырыша иде. «Нәрсәгә булыр соң бу, нигә болай дулкынланам соң әле мин?— Шушы уй яктырып узар-узмас, Фирәзә җавабын да эзләп таба язды.— Кем бригадасы икәнлеген сорарга башым җитмәде бит, әй! Кемнеке икән?»

Төзелеш мәйданында эшнең кызган чагы иде. Бер атна буе күренмәгән измәне бер төн эчендә китерергә исәплиләр бугай. Егетләр баштагы машинаны бушатып, кирәк измәне тиешле җиргә күчереп салдылар гына, икенчесе, аның артыннан ук өченчесе һәм дүртенчесе килде. Шулай итеп, төзүчеләр декабрь салкынының барлыгын онытып, бушлатларын салып ташларга мәҗбүр булдылар. Ә машиналарның туктыйсы күренми, киресенчә, берсе килеп бүксәсенә тутырган измәне бушатырга өлгерми, икенчесе күренә. Арадан кемнеңдер:

— Безне болай бимазаламасалар ярамыймы соң, бригадир? Нигә эшне һаман да шулай бабайларча башкарырга? Нигә бернинди механизация юк соң бездә? Моны үзебез күтәрмәсәк, берәү дә китереп бирмәс... Монда ярый ла түзәрбез... Ә реактор оясына бетон сала башлагач нишләрбез?— дип сукранганы ишетелде.

— Ну акыллы да баш соң инде син,— дип җавап бирде аңа Илдар Корбанов,— ну акыллы да баш... Неужели атом реакторы булачак ояга измә-бетонны шулай кул белән салдырырлар? Сиңа бераз гына башыңны уйлатып карарга да ярыйдыр бит, Револь?

— Уйларсың монда! Бригадирыгыз ни дә, үзегезне әйтер идем... Тегендә ташланасыз, монда килеп тотынасыз. Юк бер төштә генә утыру. Начальство белер иде әле, кирәк булса күчерер иде.

— Ярый, ярый, без сине чакырып китермәдек, үзең килдең...

Бу күптән түгел генә бригадага килеп кушылган Револь Вәлиевнең авырткан җире иде.

— Син, Илдар, билдән түбәнрәк сукма яме!

— Үзең бит...

Искәндәр егетләрнең эш арасында шулай әйткәләшүләрен тыңлый-тыңлый көрәген измәгә батыра, сабыннан тотып селкетеп тирәнгәрәк кертә һәм күнегелгән хәрәкәт белән күтәреп ала да, бераз гына арткарак селтәнеп, носилка-савытка томыра. Баштагы мәлне егетләр аңа карап соклана һәм: «Кайчан гына өйрәндең соң син моңа, Искәндәр абый?»— дип сорыйлар иде. Аннары, аның элек төзүче бригадир булып эшләвен белгәч, сорашудан туктадылар.

Револь Вәлиевнең кадрлар бүлегеннән эшкә алуны үтенеп килгән көнен Искәндәр яхшы хәтерли. Унбиш-егерме көн элек булды бу. Ноябрь ахырлары иде, инде ярыйсы гына салкынайтуга карамастан, төзелеш мәйданы янындагы вагон алдына җиңел кроссовка, джинсы чалбар һәм малайлар өстеннән алып кигәндәй кечкенә, биленә дә төшеп җитмәс кыска куртка кигән егет килеп туктады. Мондый очракта төзүче егетләрнең язылмаган бер кагыйдәсе бар: килгән кешене күрмәмешкә салышалар, әмма аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торалар. Бу юлы да шулай булды. Заманча киенгән әлеге егет кемгә барып сүз кушарга белмичә «биеп» тора башлады. Салкын диган нәрсә бит ул сиңа яраткан апаң түгел, бер керә башласа, тун-

лы-бушлатлының да әллә кай җирләренә керер юл таба.

Ниһаять, Искәндәр эшен куеп, аның янына атлады.

— Кем кирәк сиңа, егет?— диде.

— Фидаяров кирәк, бригадир кирәк иде,— диде ул.

— Мин булам, ни йомыш?

Төти егет кечкенә курткасының кай төшеннәндер алып, кәгазь кисәге сузды. Камышева җибәргән иде аны.

— Ярый, көтеп тор бераз. Төшкә туктаган арада егетләр белән сөйләшеп карарбыз. Алырлармы-юкмы?

— Ничек? Сез бригадир түгелмени?

— Бездә бригадир түгел, бригада хәл итә мондый мәсьәләне.

— А-а-а...

Аннары, бригада төшкә туктагач, аңа: «Нинди эштә эшләдең соң?»— дип сорау бирделәр. Егетнең авыр эштә эшләмәгәнлеге киеменнән, үз-үзен тотышыннан гына түгел, кызларныкыдай җыйнак кулыннан ук күренеп тора иде.

— Ресторанда... официант булып...— диде ул.

Аның бу җавабыннан егетләр беравык телсез калып тордылар һәм барысы берьюлы көлеп җибәрделәр.

— Во-о, дает! Ә нишләп, нишләп соң әле син андый җылы урынны ташларга булдың?

Егет дәшмәде.

— Әйтергә теләмисең икән, ирекләгә — ирек... Кайтасың да китәсең. Бездә андый серләрне яшерү тыела...

— А-а-алимә-э-энт...— дип сузды яңа килүче.

Инде бригада төзүчеләре аның хәлен аңлап:

— А-а-а...— диделәр.

Шулай да Искәндәр абыйларына кырын-кырын карап куйдылар, «шул чебешне алабызмы?» янәсе...

Бригадир исә егетне күзәтеп торган җиреннән:

— Бездә бит, туганым, күрәсең нинди эш. Бери больше — кидай дальше... Аннары эш тә тәлинкә-поднос күтәреп йөрү ише түгел...

— Бел-ә-әм,— диде егет.— Тик минем төзелештә чыныгасым килә. Миңа бер кеше шулай киңәш итте. Төзелеш кенә сине кеше ясар диде.

Төзүчеләр тагын көлеп җибәрделәр, ләкин бу юлы инде аларның көлүендә үз итү бар иде.

Эшли башлавын башлады Револь дигән сәер исемле егет, ләкин аңа тиз генә «кеше» булулары кыен, бик кыен иде. Чөнки аның авыр эшкә, кыенлыкка күнекмәгән тәне бик сыек, шуңа күрә иптәше бер алганны аңа өч тапкырдан каерырга туры килә... Әнә хәзер дә аның түземлеге, тәнендәге көче чамалы гына калды бугай, ул инде туктарга, ял итеп алырга җай эзли.

«Ничего,— дип уйлап алды Искәндәр,— теге кеше сиңа бик дөрес әйткән: түземлегең җитсә, бу төзелеш сине чынлап та кеше итәчәк».

Тик ул уй-фикерен очлап бетерә алмады, Револь кычкырып җибәрде, күрәсең, юкка гына ресторанда эшләмәгәндер:

— Искәндәр абы, Искәндәр абы... Ашарга китерделәр...

Искәндәр, вагон ягына борылып карауга, сискәнеп китте. Чөнки термослар бушатып торучы шофер янындагы хатын-кызның хәрәкәтләре, гәүдәсенең тотышы һәм тагын нияндидер сизелер-сизелмәс чалымнары аңа таныш, бик тә таныш иде...

*Ахыры киләсе санда*

# ШИГЪРИЯТ

## Клара Булатова

### Күктүбә дәфтәреннән яңа шигырьләр

❀

Бер каләмем гел буш килгән,
Бер каләмем җете кара.
Тәмле шигырь яза торган
Яшел карам бетеп бара.

Ая, Диңгез! Гомер бакый
Эзләнүле төсең табыйм,
Каурыйларым сиңа маныйм,
Чын төсләрне синнән алыйм.

Әмма, һәйһат! Синдә дә төс
Бер агара, бер кызара.
...Тәмле шигырь тудырасы
Яшел төсләр бетеп бара...

❀

*Үземә*

Кайчак сине өздерепләр сүгеп ташлыйм,
Аты-юлы белән тетеп, тиргәп атам.
Кайвакытта кызганудан елый башлыйм,
Кайчагында гаҗәпләнеп шаклар катам.

Кайбер чакта сокланудан өнсез булам:
Күпме эшләр килә синең кулларыңнан!
Өлгерәсең ничек диеп башлар ватам.

Кешеләрчә җәлләп ярдәм итәр булам,
Кайчак көләм, кайчак кайнар яшьләр түгәм
Шигырьләрең, җырларыңны укып синең...

И, шагыйрә! Әгәр дә син — мин булмасаң,
Сиңа атап мәдхияләр язар идем.

---

Клара БУЛАТОВА — *шагыйрә, «Язлар алда», «Гел кояшка карап», «Марс китабы» һ. б. шигырь китаплары авторы. Әлмәттә яши.*

❁

Диңгез гөжли бүген көне буе,
Бүген монда габрияклар[1] туе,
Сикерешә алар, биешә.
Дулкын буйлап җәяү йөгерешә,
Чыйкылдаша, ауный, тибешә —
Шайтаннарга шулай килешә.

Кайвакытта акыл, олпатлыкны
Алып атып ярсу суларга,
(Җенләнергә шагыйрьләр дә хаклы!)
Иярәсе килә шуларга.
...Бүген монда габрияклар туе.

❁

Туфан да татар иде шул,
Татарча тыйнак иде.
Кирәктә җиңен сызганып
Яклаудан ерак иде.

Әйдәде — кулын бирмәде,
Тартмады, этәрмәде,
Еракта тотып сокланды,
Янына күтәрмәде.

Ул бары хаерхак җанлы
Чиста, пакь күңел иде.

Редактор түгел иде ул,
Директор түгел иде.

Булышса әгәр, үзенә
Яман ат алыр иде...
Туфан да татар иде шул,
Бик тыйнак, сабыр иде.

Яшьлектә талант-сәләтем
Шауламый калды шуңар.
Габриак булыр идем мин!
...Табылса Волошиннар[2].

❁

Яңа яңгыр юган якты йөзле
Диңгез ята балкып, елмаеп.
Шул диңгездә рәхәтләнеп йөзде
Минем улым, гүя бер балык.

И табигать! Адәм баласына
Биргәнсең лә көчне, сәләтне:
Суда йөзә, күктә оча белә,
Төзи ала җирдә җәннәтне.

Тик кызганыч, шушы сәләтле зат
Яманлыклар кыла кайчакта.

Кан коюга жирдә, жан кыюга
Хак-табигать үзе шаккаты.

Яр буенда улым яшьтәшләре
Сугыштылар кичә җыйналып.
Ни бүләләр алар? Нәрсә җитми?
Ник кыйбласыз, динсез бу халык?

Әйтерсең лә шушы вәхшилеккә
Гаҗәпләнеп калды диңгез дә:
Күләгәләр ятты әле генә
Яңгыр юган якты йөзенә.

❁

Кем юрый сине юылмас
Кара, тын сагышына,—
Мин тыңлим сине үземнең
Бу чуар язмышыма:

Күкләргә күпме урләп тә
Җирдән күчмәгән кыя,
Кире кагылган алиһә,
Көнгә ашмаган хыял.

---

[1] Диңгез шайтаннары.
[2] М. Волошин ярдәме белән шигъриятькә килгән, Ч. Габриак имзасы белән танылган рус шагыйрәсе күздә тотыла. Ред.

*Айвазовскийга*

Зәмзәм суы бөркеп торган, диләр,
Феодосиядә фонтаның.
Ә мин бүген авыз итәр өчен
Тамчы су да анда тапмадым.

Безнең буын, и беркатлы буын,
Алга китеш диеп алданган,
Кая илдә затлы фонтан төзү —
Булганын да саклый алмаган.

«Гөл бакчасы булды Илебез!» дип,
Тудырганда кызыл җырларны,
Харап булган йөзем бакчалары,
Коргаксыган Кырым кырлары.

...Кичәгеңне сүккән бүгенгеләр
Үзләре дә күп сүзле генә...
Хак-табигать, белмим, күпме түзәр
Бу тормышның юньсезлегенә?..

Күк күкрәсен, бәрсен, дөбердәсен —
Саңгыраулар ишетә белми аны.
Яшен яшьнәп, сузсын ут көлтәсен —
Сукыр күзләр барыбер күрми аны.

Алар шулай гомер буйларына
Күрми-белми яши бирәләр.
Безнең дә бит шулай көн күргә
Күнеккәннәр иде түрәләр.

*Аз гына Абдулла Шердан*

Йолдызлар бит күктә, күмәкләшеп,
Төркем-төркем яшәп киләләр.
Ә сүнгәндә менә ялгыз гына,
Берәм-берәм генә сүнәләр...

Сыңар бер йолдызның күпме якты
Биргәнлеге Йолдыз иленә,

Ни өчендер, янган чакта түгел,
Үзе сүнгәч кенә беленә.

...Шигърият тә нәкъ йолдызлык кебек:
Хак-бәяне шагыйрь халкына
Күп вакытта куя башлый халык...
Соңгы тапкыр атылгач кына.

Диңгез бер дулап ала да
Тагын тыелып тора.
Кара-Тау, кашын җыерып,
Кара коелып тора.

Ул шулай ачуланамы
Артык сабырлыгына?
Аптырый, хәйран каламы
Дөньяның барлыгына?

Үзгәреш, дибез... Ә монда
Төзәлү әле ерак.
Шәп түгел иде, ә хәзер
Начардан начаррак.

Арыклар сусыз, аларны
Бака ефәге сарган...
Кайчандыр гөлстан булган
Үзәннәр корып калган...

Сокланып түгел, кызганып
Күзәтеп йөрим сине,
Исемен-атын югалта
Язган Күктүбә иле.

...Диңгез бер дулап ала да
Тагын тыелып тора.
Кара-Тау, кашын җыерып,
Кара коелып тора.

*Әлвидаг*

Улым йөзеп уйнаган,
Чумып-чөмереп туймаган
Тирән диңгез, исән бул!
Күпме шагыйрь җырлаган,
Җырларына сыймаган
Зәңгәр диңгез, исән бул!

Күктәбәләр ярына
Килербезме тагын да? —
Белмәс диңгез, исән бул!

Көн айкалган чагында,
Ил чайкалган чагында,
Түзмәс диңгез, исән бул!

Насыйп булса, улларның
Үткәргәчтен туйларын,
Без килербез, исән бул!
Улым йөзгән дулкында,
Онытмыйны шушында
Йөздерермен, исән бул!
Исән бул!

Актарылып, кайнап озатасың,
Халәтеңне аңлыйм мин бүген.
Синең кебек әй айкалган чагы,
Әй чайкалган чагы илемнең.

Кузгатырга кирәк иде микән
Тарих төпкә салган ташларны?
Бөтенесе дәррәү кубып өскә,
Афәт булып кайный башлады.

Синең якта Абхаз, Грузиннар,
Ерактарак Төрек, Үзбәкләр
Суешалар — ничә дистә еллар
Дус яшәгән тату милләтләр.

Син булдыклы, син үзеңә хуҗа,
Үз ярыңны үзең юасың.
Упкыннарың, чоңгылларың шунда,
Дулыйсың да тагын тынасың.

Илнең-көннең төптән актарылган
Давыллары теткән ярларны.
Яраларны кемнәр юар икән,
Кем төзәтер икән аларны?

Гел хатадан торган тарих белән
Ничек яшәр икән бу илем?
...Айкалган ла, чайкалган ла чагың,—
Безнең кебек чагың, диңгезем.

# Нәҗип Мадьяров

## Дулкын таулары эчендә

Чулманда давыл котыра,
Ыргый дулкын таулары.
Шом тарата — әллә суның,
Әллә җилнең шаулавы.

Тирбәлә җилкәнле каек
Шул зилзилә эчендә,
Тетрәнә җан — аңардагы
Сәер бәндә өчен дә.

Каегы аның дәрьяда
Гүя йомычка гына.
Кешесе шуңа ябышкан
Нәни кырмыска гына.

Нигә кергән елгага ул?
Ни калган аңа анда?
Ни эзли икән чайкалып
Дулкын араларында?

Кем ул? Белмим. Җил-давылда
Бер дә юкка йөзмидер:
Мәхшәр кочагыннан, бәлки,
Үлемсезлек эзлидер?!

## Туган җирләремә көз килгәндер

Төньяк җиле иңләп су буйларын,
Җәй үтте дип, хәбәр биргәндер.
Түр болыны, төсен җуеп тагын,
Өр-яңадан көзгә кергәндер.

Саргаюын яшел киңлекләрнең
Җаным-тәнем белән тоямын.
Яр читендә үскән зирекләрнең
Күрәм кебек яфрак койганын.

Басуында кунып киткәләрдер
Һаман да шул моңлы торналар.
Киткән чакта азан әйтәләрдер,
Тыныч булсын диеп дөньялар.

Инештә дә тирәнәйгән булыр
Көзге моңнар, көзге сагышлар.
Анда җилләр әфсен укыйлардыр,
Саргайсыннар өчен камышлар.

И, туган җир!
Син бит якты дөньям!
Яшәсәм дә чит-ят җирләрдә,
Синең белән мин җәйләргә чыгам,
Синең белән керәм көзләргә.

## Мәгънәсезләр

Эшлисең, эшләгән эшең
Күренгәч күзләренә,
Күрә алмауны аңлаткан
Төс чыга йөзләренә.

Эшлисең, эшләгән эшең
Күп булу да ярамый.
Алар аңа — эче пошмый,
Күпсенмичә карамый.

Эшлисең, кулыңнан килгәч,
Ару-талуны белми.
Эшләтмәс иделәр алар,
Тик кулларыннан килми.

Җир ничек күтәреп тора,
Белмим, ул бәндәләрне?
Хәер, игътибар итмидер —
Булмагач мәгънәләре.

---

Нәжип МАДЬЯРОВ *(1928) — шагыйрь, унбиш китап авторы. Проза әсәрләре дә яза. Чаллыда яши.*

## Юлларым язга илтә

Ак минем барыр юлларым
Кыш буйлап язга кадәр.
Кичәрмен җилен-буранын,
Башым сау булса әгәр.

Үтәрмен көртләрне ярып,
Максатым юлдаш булыр.
Тукталмам, бетсәм дә арып,
Җыр дәрман биреп торыр.

Зыкысыннан да курыкмам,
Алса да битем ялап.
Сүрелмәс җаным суыктан,
Барганда язга карап.

Аяк басмаган җәйләрем,
Күзләрем көтә мине.
Ак юллар, бөркеп ямьнәрен,
Шуларга илтә мине.

Һәм шул уйлардан алып көч,
Дөрли пакь мәрхәмәтем.
Эрер кыш, әмма ана һич
Эремәс мәхәббәтем.

## Гаяз Исхакыйга

Сабый чагыңнан җилкенеп
Мәгърифәт үзәненә,
Язучы булып килдең син
Тормышның үзәгенә.

Яздың, язганнарың синең
Кемнәрнедер сагайтты.
Кемнәрнеңдер күңелендә
Сүнгән утны яңартты.

Ил-җирең туфрагын ташлап,
Аяныч уйлар уйлап,
Нигә соң киттең син бездән,
Моң-сагышыңны җыйнап?

Торгынлык елларын, бәлки,
Алдан сизенгәнсеңдер.
Репрессиядән калдым, дип,
Читтә сөенгәнсеңдер.

Йөз бора һаман илебез
Яктылыкларга таба,
Юнәлешне нык алды ул
Яхшылыкларга таба.

Шуңа без иркле хәзер,
Тиеш түгел куркырга;
Синең әсәрләреңне дә
Хокук алдык укырга.

Бу хәлләрне һәм исмеңнең
Алынуын кадергә
Ишетерсең күк тоела —
Ятсаң да чит кабердә.

ПУБЛИЦИСТИКА

**Айдар Хәлим**

# ИЛЕ БАРНЫҢ ТЕЛЕ БАР

1

Җитмешенче еллар башында булды бу хәл. Беренче шигырьләр китабым чыгуга, кош булып туган ягыма, дәресрәге, Башкортстанның Оренбург тарафындагы Кыргыз-Миякә авылы мәктәбенә очып кайттым. Күрегез әле: сез тәрбияләгән балакай шагыйрьгә әйләнеп бара бугай, дип башта укытучыларымны сөендерәсем килә иде. Ләкин мәктәбемне... таба алмадым. Язларын шау чәчәккә күмелә торган, бөтен районга даны таралган бердәнбер алмагач бакчасы, мелиораторлар актарып ташлагандай, зир-зәбәр китерелгән иде. Мәктәпнең әле искереп бетмәгән бинасы кабер караңгысы бөркелгән сукыр тәрәзәләре белән җанны өшетте. Гомеремдә хәсрәтле-сагышлы минутларны аз кичермәдем түгел, әмма бусы хәтеремә мәңгегә уелып калды. Сөекле мәктәбем!.. Без, аңа килеп сыеныр өчен, ничә мең чакрымны җәяү уза идек бит. Авылларыбыз райүзәктән еракта, аркада — биштәр, аякта — чабата. Бөтен районга үрнәк мәктәпкә укырга йөрибез. Утызынча елларда ук Ленин ордены белән бүләкләнгән күренекле педагог Хәсән абый Солтанов җитәкчелегендә бәйрәм саен спектакльләр, концертлар куябыз. Озын тәнәфесләрдә, бигрәк тә язларын, алмагачлар төбендә бию-ләр, уеннар оештырабыз. Гармун сыздырабыз. Һәрберебез уйный белә. Шатлыгыбыз оясы булган мәктәбебездә беренчедән унынчыга кадәр татар һәм рус класслары икешәрдән иде. Үзара нинди тату яши идек без! Рус теле һәм әдәбияты тансык дәресебез була торган иде, чөнки үз телебездә төп нәрсәләрне танып-белеп бетергәннән соң, серле атомны таркатырга омтылган кебек, калган белгесез дөньяны рус теле ярдәмендә ачарга ашкынабыз. Халыкара бердәмлек хисе белән сугарылган гражданлык тойгыбыз җитлегүенә рус теле дә өлеш кертте.

Армиядә — солдат, калмык далаларында — нефть эзләүче, Түбән Кама химия комбинаты төзелешендә — балта остасы, Казан университетында — студент. Кыргыз-Миякә мәктәбенә әйләнеп кайтканчы әнә шулай йөреп, унбиш ел узган иде. Тик мин туган мәктәбемне бу юлы икегә бүленгән хәлдә күрдем: райүзәктә яшәүче «элита», ягъни, туган телгә мохтаҗлыгы юк балалар өчен иң күркәм җирдә, өч катлы яңа бинада русча гына укыта торган мәктәп ачканнар. Ә авыллардан килүче «абориген-нар» — кара сөякләргә, бер абзый әйтмешли, «райпромкомбинат чүплеге артындагы ике катлы барак»ны биргәннәр. «Милли мәктәп» дип атасалар да, аерма бер-ике сәгать туган тел укытуда гына булганлыктан, анысын да асылда рус мәктәбе санарга мөмкин иде. Әмма, бер үк программа белән укытуга карамастан, бу ике мәктәпнең укучылары да, укытучылары да бер-берсеннән нык аерыла, имеш: беренчесендә һәммәсе ал да гөл, икенчесендә — боеклык, моңсулык. Рус мәктәбендә — «сайланма» халык, «милли»дә — калдык-постык, кайсы ягы беләндер «элита» арасына керә алмаган бичаралар! Элекке укыту бүлеге мөдире, безгә туган телебез, әдәбиятыбызның бай хәзинәләрен ачып, фикер, хис матурлыгына мәхәббәт уяткан, Башкортстанның атказанган укытучысы Г. Гыйниятуллина, менә шушы хурлыклы бүленешне кабул итә алмыйча, инфаркт белән шифаханәгә кереп яткан икән.

Район мәгариф бүлегенә киттем. Анда мине фән-техника революциясе заманында туган тел кирәкмәвенә иман китергән мөдир каршы алды һәм, иң зур, иң зирәк акыл иясе шикелле, телләр кушылып бетүнең сәгате генә түгел, минуты да җиткәнлеген аңлата башлады.

— Мәктәпне нинди нигездә болай гаделсез бүлдегез? — дип сорадым.— Нигә барлык фәннәрне дә русча укыта башладыгыз?

— Ата-аналар теләге буенча.

— Аларның хатларын күрсәтегез әле? Җыелыш беркетмәләрен...

— Ә сез кем буласыз?

Билгеле инде, аның белән тарткалашу мәгънәсез иде.

Сүтелеп бетмәгән иске мәктәбебезгә таба атладым. Беренче тапкыр күңелемдә әдәбиятка мәхәббәт уяткан, шигырь юллары тудырган классыбызга килеп кердем. Әйтерсең лә шушында укыган йөзләгән укучыларның илчесе идем мин. Башкорт әдәбияты классигы Гариф Гомәр, Советлар Союзы Геройлары Мансур Абдуллин, Миңлегали Гобәйдуллин һәм башкалар, миңа төбәлгәннәр дә, мондагылар гамәле өчен җавап таләп итәләр иде сыман. Ә мин нишләргә дә белми аптырап калдым. Лозунг язылган фанер кисәге әле һаман эленеп тора. Күзләремне иденнән алмастан, җанны сызлатыр дәрәҗәдә таныш сүзләрне пышылдадым: «Кешелек дөньясы тудырган барлык белем хәзинәсе белән зиһенеңне баетканда гына коммунист булырга мөмкин».

«Төн вә көндез сине онытмаучылар исеменнән туган мәктәбемә автордан»,— дип язу яздым да бүләккә алып кайткан китабымны бакчада очраклы рәвештә исән калган алмагач төбенә күмеп куйдым.

Без менә шулай туган мәктәбебездән мәхрүм калдык. Мең ел гомер кичергән әлифбабыздан аерылдык. Туган авазлар моңыннан, тел бизәкләреннән башка рухи бөтенлекне саклау нинди авыр буласын мин шунда бик ачык төшендем. Алтмышынчы еллар башыннан алып «рус телен өйрәнүне яхшырту» сылтавы белән һәм, әлбәттә, «ата-аналар теләген искә алып», йөзләгән милли мәктәпләр рус телендә укытуга күчерелде. Нәтиҗәдә, Урал буе шәһәрләрендә һәм авылларда чын мәгънәсендә милли дип әйтерлек бер генә мәктәп тә, балалар бакчасы да калмады.

Шушы эшләр матур сүзләр сөйләнеп, совет власте исеменнән тормышка ашырылды. Ә совет власте хезмәт ияләренә кайчан начарлык эшләде соң? Беркайчан да! Кемнәр һәм кайчан рус теленә каршы иде соң? Берәү дә, беркайчан да! Ләкин пролетар интернационализмның асыл мәнфәгатьләренә каршы килеп сөйләнгән матур сүзләр совет властеның чын йөзен каплый башлады. Совет власте белән ачыктан-ачык һәм намуслы рәвештә, чал чәчле анаң белән сөйләшкәндәй сөйләшәсе килде, ләкин тавышыбыз ишетелмәде. Ата-аналарның сәяси беркатлылыгын намуссыз файдалану, аларның ышанычы белән сату-алу итү Башкортстан халык мәгарифенә тиңсез зур рухи югалтулар китерде: республика халкының төп өлеше (алтмыш процентка якыны) — башкортлар, татарлар, марилар, чувашлар, украиннар һәм башка милләтләр үз мәктәбеннән мәхрүм калды. Революциянең иң бөек казанышларының берсе — туган телдә белем алу хокукы бюрократик төзәтмәләр, өстәмәләр кертү аркасында хур ителде, кайчандыр зур мәхәббәт белән «халыкныкы» дип аталган нәрсә торгынлык елларында,— бер дә күпертмичә әйтәм,— «халыкка каршы мәгариф»кә әйләнде. Башкорт яки бүтән теләсә кайсы милләт мәктәбендә туган тел укытылмый икән, аны совет мәктәбе санарга мөмкинме? Минемчә, юк. Чөнки Советлар Союзы — кардәш халыклар берлеге ул. Димәк, мәктәпләрдә барлык халыкларга хас сыйфатларны, шул исәптән, аларның телләрен дә эченә алырга тиеш.

Милли мәктәп, туган тел Башкортстаннан читтә дә юкка чыга барды. Чөнки аларны якларга мөмкин түгел, шунда ук «милләтче» тамгасы тагалар. Матбугатта туган халкыңны телгә алу, районда ана теле укытучыларының семинарын үткәрү, радио-телевидение аша туган тел матурлыгы хакында сөйләү дә хупланмый башлады. Без шулай милләтләрне чәчәк аттыра алдыкмы соң? Юк. Тормышыбызда җыр кимеде. Матур халык йолалары юкка чыкты. Кешеләр арасында табигый аралашу яме бозылды. Изге саналган нәрсәләргә битарафлык тамыр җәйде. Хезмәт дәрте сүрелде. Бу елларда сәнгатькә күренекле шәхесләр килү дә тукталды диярлек. Чөнки аларны туган тел сулышын буып әзерләү мөмкин түгел иде.

Без шулай халыкларны якынайттыкмы соң? Юк. Бары ераклаштырдык кына. Үзара ышанычны какшаттык. Башкаларга өстән карау, аларны санга сукмау рәнҗү хисләрен генә тернәкләндерде. Чынлыкта без дуслыкны суыту өчен диверсия генә ясадык. Аның зыянын әле ничәмә буын күрәчәк һәм халык «ата-аналар теләге белән» меңнәрне, миллионнарны туган телсез калдырган җитәкчеләрне каргаячак.

Чөнки тел культурасы ул — кешенең гомум культурасы нигезе. Тел ул — фәлсәфә һәм әхлак, йолалар һәм гореф-гадәт, рухи хәзинәләр, матурлык тойгысы һәм мәңге саф, мәңге тере шигърият чыганагы, кеше хәтеренең йолдызы, дигән сүз. Тел ул — мәхәббәт чишмәсе. Әгәр атом реакторы яки нефть скважинасы сафтан чыгу, шахталар ишелү яки поездлар, теплоходлар бәрелешү, самолетлар егылып төшү ешая икән, бу мөгаен, совет кешесенә беренче нәүбәттә йогынты ясый торган вөҗданлылык, җаваплылык хисе, рухи ныклык һәм фикер йөртү ачыклыгы кебек кыйммәтләрнең үз вазифасын үти алмавыдыр.

«Милли гаделсезлек пролетариатның сыйнфый теләктәшлеген үстерүгә һәм ныгытуга барыннан да күбрәк тоткарлык ясый, һәм җәберләнгән милләт кешеләре

тигезлек хисенә һәм бу тигезлекнең саксызлык аркасында гына булса да, шаярту төсендә генә булса да бозылуына, бу тигезлекнең пролетариат иптәшләре тарафыннан бозылуына барыннан да сизгеррәк карыйлар. Менә шуңа күрә бу хәлдә азчылык милләтләргә карата юл куючанлык һәм йомшаклык күрсәтүнең җитәрлек булмавына карaганда, арттырыбрак җибәрелүе яхшырак. Менә шуңа күрә бу хәлдә пролетар тәләктәшлекнең һәм, димәк, пролетариат сыйнфый көрәшнең дә төп мәнфәгате безнең милли мәсьәләгә беркайчан да феодаль карамавыбызны, бәлки изелгән (яки кечкенә) милләт пролетариеның изүче (яки зур) милләткә карашындагы мәҗбүри аерманы һәрвакыт исәпкә алуыбызны таләп итә»,— ди В. И. Ленин.

Хәзер бездә, билгеле, классик мәгънәдә изелүче һәм изүче милләтләр юк. Кеше саны күп яки аз булган милләтләр генә бар. Аларның үзара чын тигезлегенә ирешергә әле ерак. Минемчә, союздаш, автономияле республикалар, милли өлкәләр һәм округлар арасында җитештерү һәм куллану, социаль үсеш, культура һәм халык мәгарифе тармакларында тигезсезлек торгынлык елларында аеруча артты. Бу нәрсә милли мөнәсәбәтләрдә дә чагылмый калмады. Политик җитлегү, гражданлык җаваплылыгы күпләрдә аксады. Культура һәм мәгариф мәсьәләләрендә пролет-культча кыланулар, тулы бер буын язмышын чыгырыннан чыгарган шәхес культы бәлаләре җәмгыятебез үсешен шактый гариплəндерде. Яңа дөнья, яңа җәмгыять корырга омтылганда ватаныбыз һәм башка илләр педагогикасы бай тәҗрибәсен дә искә алмадык, хәтта аны белмәмешкә салыштык. Кешенең беренче ихтыяҗын канәгатьләндерергә хаҗәт макарон, ярма, май җитмәгән шартларда, вульгар социология каһарманнары тел өлкәсендә халыкны көне белән «коммунизм»га китереп җиткерде. Интернациональлекне чамадан тыш актив яклаучы мондый каһарманнар әле кайчан гына изелгән халык сафыннан шытып чыкты, тиешле әзерлеге булмаган хәлдә җаваплы урынга утырды һәм, авантюристлар коралына әйләнеп, үзе менеп атланган ботакка балта чаба башлады. Ярык мулла дин боза, ярым галим ил боза, дигәндәй, менә шундый кол рухлы, югарыдагыларга ярарга атлыгучы түрәләр милли телләрне иясеннән аерып, колониаль товарга әйләндерде: «Туган тел интернациональ байлык түгел, димәк, перспективасыз, кирәксез; рус теле — интернациональ, димәк...»

2

Дистәләгән авылларны йөреп чыгып, йөзләгән ата-ана белән сөйләштем. Шәһәрләрдәге гаиләләргә дә кагылгаладым. Мәсьәләне аңлауда шәһәр белән авыл арасында сизелерлек аерма бар. Әмма мине шаккатырган нәрсә  аларның һәммәсенә хас төп сыйфат булды: компьютерлар гасырында яшәүче малкуар ата-аналарның күпчелеге педагогиканың элементар нигезләрен аслан белми икән.

Авыл халкына килсәк, туган тел язмышына мөнәсәбәт төрлечә: балалары сөйләм телен белгән ата-аналар шуңа бик канәгать. Алар өчен бернинди хәвеф-хәтәр юк шикелле. Уллары-кызлары туган телдә инде авыр аралаша, катнаш телдә яки русча гына җавап бирә башлаган авылларда исә ата-аналар эшнең ал да гөл түгел икәнлеген чамалый, баласын кисәтә, орыша.

Рус телендә укытырга күчүне яклаган ата-аналар, чыннан да, мин көткәннән күбрәк булып чыкты. Дәлилләре бер: туган тел белән кая барып була соң? Мин аларга бүген файдалы сыман күренгән нәрсәнең иртәгә һәлакәт китерәчәген әйтәм, алар миңа һавадагы торнадан кулдагы үрдәкнең кыйммәтрәк икәнен исбатлый. Әмма һәлакәтнең ничек бик тиз үз башларына килеп төшәчәген тәфсилләп аңлатырга керешкәч, алар килешә һәм гаҗәпләнә: «Дөрес! Мәсьәләнең бу ягын без бөтенләй уйламадык ич. Бу хакта безне бераү дә кисәтмәде...»

Шәһәрдә инде кемнәрдер балаларының туган телне онытуына кул селтәгән, моңа күнеккән. Икенчеләр бу хәлне фаҗига итеп саный, эчтән сызлана. Егерменче-утызынчы елларда әти-әниләребез төтен бөрки башлаган һәр биек морҗаны һәм русча өйрәнгән егет-кызны күргән саен шатланган. Чөнки алар бу яңалыкта илнең промышленносте ныгуын, укымышлы белгечләре артуын күргән. Хәзер инде алар һәр ялтырагaн нәрсәнең алтын түгеллеген аңлый. Чөнки бөркеп утырган морҗа һаваны агулый, русча өйрәнү исә туган телне инкарь итү бәрабәренә алып барылган. Шуңа күрә шәһәр кешесе хәзер: «Их, балам туган телен дә белсә икән!» — дип уфтана. Баласының русча укып та әллә ни алга китмәвен күргән авыл агае исә: «Нинди мәктәп бу, улыбыз ни русча, ни татарча юньләп белми»,— дип сукрана һәм ул хаклы.

Ата-ана үз баласының укымышлы, эшкә яраклы кеше булып үсүен тели һәм бу өметен русча белүгә китереп бәйли. Бу бер дә гаҗәп түгел. Ләкин онытмыйк: ул бит моны туган телен гамәлдән чыгару хисабына эшләргә кирәк дип санамый. Менә шушындый очракта инде мәгариф министрлыгы «каһарманнары» егетлек күрсәтә башлый. Ата-аналарга:

— Сез балагызның русча яхшы белүен телисезме? — дигән сорау бирә. Уңай җавап алгач, үзенчә зирәк һәм бердәнбер нәтиҗә чыгара: — Димәк, сез аны русча укыту яклы!

Һәм әлеге туп-туры ят телдә укытуны җайлап җибәрә. Туган тел ясләдән үк кысрыклап чыгарыла, ата-аналарга өйдә дә ят телдә генә сөйләшергә киңәш бирелә, еш кына катгый таләп ителә.

Ә хакыйкать бер генә: бала ана телендә ишеткәнне генә йөрәге һәм акылы белән хәтеренә нык сеңдерә, ул туган телендә генә ансат һәм тиз фикер йөртергә өйрәнә, дөньяны камил танып-белә ала. Ана телен яхшы белгән бала гына башка телне җиңел, тиз өйрәнә, төрле фәннәрне тирән үзләштерә. Ләкин безнең мәгариф «каһарманнары «ата-ана теләге»нә аркаланып, рус телендә укытуга күчерүне үзенең ике йөз процент интернационалист икәнлеген исбатлар өчен файдаланучы кайбер карьеристларга күндәм буйсынып милли политика әхлак кануннары тупас бозылуга күз йомды, яшь буынны ялгыш юлдан алып китүгә мөмкинлек бирде.

В. И. Ленин исә СССР төзелгән көннәрдә халыкны: «Безнең Союз эчендәге башка милли республикаларда милли телне куллану турында каты кагыйдәләр кертергә һәм бу кагыйдәләрне аеруча җентекләп тикшерергә кирәк. Шик юк ки, тимер юл хезмәтенең берлеге, дәүләт хәзинәсе эшләренең берлеге һәм башка шундый сылтаулар белән бездә, хәзерге аппаратыбыз яшәгәндә, чын-чыннан руска хас башбаштаклыклар бик күп булыр»,— дип кисәткән иде.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, безнең «хәзерге аппаратыбыз» чынлап та йокымсырап ятмады, дәүләт хәзинәсе эшләре бердәмлеге урынына тагын да гөнаһсызрак, «демократиграк» сылтау — «ата-аналар теләге» дигән нәрсә уйлап тапты. Тик бюрократларның ул сылтавы Ленинның: «Чын коммунистик тәгълиматны һәр халык теленә тәрҗемә итәргә... кирәк»,— дигән күрсәтмәсенә, гармоник үскән шәхес тәрбияләү турындагы СССР законына туры киләме соң?

Моннан тыш, безгә хәзерге ата-аналарның күпчелеге баласын ашатучы, киендерүче һәм югары уку йортларына әзерүче генә булуын, ләкин һич тә педагог дәрәҗәсенә үсеп җитмәвен, кешедәге милли һәм интернациональ башлангычларны, теге яки бу телдә укытуның өстенлекләрен һәм кимчелекләрен ачык күзалламавын, бу хакта үзенә хисап бирә алмавын һич тә онытырга ярамый. Хәзерге ата-аналарга иң әүвәл дәрәҗә, ягъни баласын югары уку йортына кертү кирәк. Анда исә имтиханнарны русча гына тапшыралар. Бичара ата-ана нишләсен мондый шартларда? «Теләк белдерде» алар! Шуның нәтиҗәсендә, мәктәпләребез балаларга тулы белем, әхлакый тәрбия бирә торган нигездән бөтенләй ят, сыналмаган юлга кучте — саф татар һәм башкорт авылларында да уку-укыту беренче класстан ук русча алып барыла башлады. Табигый ки, үзләре аңламаган телдә балалар фикер йөртә алмый. Ят тел белән кинәт очрашу, шул телдә белем үзләштерү мәҗбурияте әзерлексез укучылар миенә икеләтә йөк булып төште. Нәтиҗәсе — стресс, фикер йөртү сәләтенең зәгыйфьләнүе. Русча белү дәрәҗәсе, күтәреләсе урында, түбәнәя бару гына. Милли мәктәп русча укытуга күчкәннән соң, ни гаҗәп, югары уку йортына керүче милли яшьләр саны үсмәде, кимеде генә. Авыл балалары һөнәр училищеларына килеп тулды. Әлбәттә, улыңның яки кызыңның һөнәр алуы начар түгел, ләкин ата-ана өмете башкачарак иде ләбаса...

Туган тел адәм баласы өчен беренче роль дә уйнамыймыни соң?! Аны бишектән үк теләсә кайсы телдә тәрбияләү барыберме?! Һәр очракта да бик шәп кеше булып җитешүе ихтималмы?!

Мәшһүр чех педагогы Ян Коменский (1592—1670) «Мәңгелек дидактика» дигән хезмәтендә туган тел таралышы максатын һәм чикләрен түбәндәгечә билгели: «Телләр, белем, укымышлылыкның бер өлеше буларак түгел, гыйлем алу һәм аларны башкаларга тапшыру кораллы рәвешендә өйрәнелә. Шуңа күрә бөтен телләрне өйрәнү кирәкми... Ихтыяҗы чыкканнарны гына өйрәнү дә җитә... Шәхси тормышта — туган тел, күрше халыклар белән аралашуда исә шуларның телләре кирәк була. Туган тел мәктәбенең максаты һәм вазифасы — алтыдан унике (яки унөч) яшькә кадәрге балаларга гомер иткәндә кирәк булачак түбәндәге нәрсәләрне өйрәнү: 1. Туган телдә басылганны һәм язылганны җиңел укырга. 2. Әүвәл матур, аннары тиз һәм, ниһаять, дөрес язарга. 3. Чутта дөрес исәпләргә. 4. Барын да дөрес үлчәргә. 5. Киң таралган җырларны җырлый белергә. 6. Әхлак кагыйдәләрен күңелдә беркетергә. 7. Көн саен өендә һәм шәһәрдә күз алдында аккан тормышны аңлар өчен җитәрлек күләмдә политик һәм экономик хәлләрне белергә. 8. Тарих, дөнья яратылышы, бозылуы, вәсвәсәләре хакында төшенчә булдырырга. 9. Космография нигезләрен, диңгезләр, океаннарны, Европа илләрен белергә. 10. Барлык һөнәр алымнары белән таныштырга...»

Ян Коменскийны бөтен дөнья педагогия фәненә нигез салучылардан Иоганн Песталоцци (1746—1827) да куәтли.

Бөек рус педагогы К. Ушинский да ят телләрне кече яшьтән өйрәтүгә катгый төстә каршы килә. Аның «кешелекле белем бирү» системасы нигезен туган тел һәм әдәбият тәшкил итә. «Туган телен ансат һәм көч түкми үзләштергәндә һәр яңа буын шул ук вакыт үзенә кадәр яшәгән, инде күптән җирдә череп беткән меңнәрчә буыннарның фикер һәм хис җимешләрен дә күңеленә сала. Ата-бабаларның исәпсез-хисапсыз күп буыннары күргән, кичергән, татыган, уйлаган барлык нәрсә дөньяга әле яңа гына килгән балага җиңел генә тапшырыла. Туган телен откан бала гомер юлына кирәкле көчләрне туплап аяк баса, ул туган телен өйрәнгәндә шартлы авазларны гына аңына сеңдерми, туган җиренең рухи тормышын һәм куәтен дә эчә...»

Бала тәрбияләү, аңа белем бирүнең иң нәтиҗәле юлларын эзләгән акыл ияләре, дөнья педагогия гыйлеме классикларының фикере әнә шундый. Бу фикерләрнең совет галимнәре тарафыннан кире кагылганы юк. Әмма без хөрмәтле галимнәрнең исемен телдән төшермәсәк тә, аның гыйльми-педагогик мирасын иң ерак шүрлекләргә яшереп куйдык, үткән буыннар тәҗрибәсенә нык таянып әйткән бик урынлы киңәшләрен укыту программасында файдаланмаска тырыштык.

Укыту телен дөрес сайламау, тормышыбызның башка тискәре вакыйгалары белән бер җепкә тезелеп, милли мәктәбебез эшчәнлеген каршылыклы, ялгыш юлга кертте, фән нигезләрен тиешенчә үзләштермәгән, рухи фәкыйрь, әхлагы түбән балаларга «өлгергәнлек» таныклыгы тоттырып, мөстәкыйль тормыш юлына чыгара башлады.

Туган телдә укыту, туган тел һәм әдәбиятны өйрәнү принциплары коммунистлар партиясенең күренекле эшлеклеләре В. Ленин, Н. Крупская, А. Луначарский, А. Макаренколар тарафыннан һәрвакыт совет мәктәбенең нигезенә салына килде. Күренекле педагоглар Л. Щерба, В. Аврорин, В. Сухомлинский, Ф. Филиннәр марксистик-ленинчыл нигездә ике теллелек принцибының туган телгә таянырга, шуннан үсеп чыгарга тиешлеген исбатларга тырыштылар. Әмма җавапсыз мәгариф «каһарманнары» өчен форма төрлелеге, күплеге башка сыймый торган нәрсә иде. Бер тел, бер әдәбият, бер дәреслек — нинди уңайлы бит ул «бер» дигәнең! Киметергә, бергә калдырырга, шушы юнәлештә йөз, йөз илле процент күрсәткечкә ирешеп, рәхмәт ишетергә, мактаулы исем, бүләкләр казанырга!! Бу аларның иң татлы хыяллары иде.

Менә балалар беренче яки әзерлек классына килә. Укытучы керә дә:

— Садитесь, дети! — ди.

Балалар төшенми, һаман басып тора. Ләкин укытучының бу сүзләр мәгънәсен туган телдә аңлатып торырга вакыты юк. Аның «югарыда» расланган программаны үтәсе бар, ул программада исә туган тел кебек «вак-төяк» искә алынмаган. Димәк, балаларга бик күп таныш түгел нәрсәләрне таныш түгел телдә аңлатырга кирәк. Ничек? Укучыга бердәнбер юл кала: зиһененә барып җитмәгән нәрсәләрне ятлау! Бала гаҗизлектән тинтери. Аңы үсми, томалана гына. Ачышлары белән аңа шатлык китерергә, җанына оҗмах булырга тиешле мәктәп бик тиз арада җәһәннәмгә әйләнә. Сабыйның генетик код аша килгән сәләте яралгы хәлендә катып кала. Бу инде аның рухи халәтенә дә китереп суга — балада җитлекмәгәнлек тойгысы барлыкка килә. Ят тел, карачкы рәвешендә, бер үк вакыт туган теленә ямьсез күләгәсен дә төшерә. Русча акцентсыз сөйләшергә көчәнеп, сабый туган телен кулланмаска тырыша. Менә шулай нәни кешенең әхлакый, акыл һәм хис дөньясы табигый тотрыклылыгын җуя. Ихласлыкны — икейөзлелек, хакыйкатьне — принципсызлык, гаделлекне — гаделсезлек алыштыра. Әчке каршылык мәктәп бусагасын атлап чыккач та бетми, хәзер инде ул мөстәкыйль тормыш юлында бер төрле сөйли, икенче төрле эшли башлый.

Сабыйның фикер йөртү агышын шушылай сүлпәнләндерә ала торган бүтән тормоз уйлап табарга мөмкин микән?! Тискәре көчләр туган телгә каршы бүтән агу таба алмаганда, һәр заманда телләр дуслыгын какшатырга тырышкан. В. И. Ленин шундыйлар хакында совет дәверендә: «Бездә, мәсәлән, мәгариф комиссариатында яки аның тирәсендә: бердәм мәктәп, шуңа күрә рус теленнән башка телдә укытасы булмагыз! — дип әйтүче коммунистлар да бар. Минемчә, андый коммунист — великорус шовинисты. Ул безнең күбебездә бар һәм аңа каршы көрәшергә кирәк»,— дип язган.

### 3

Урал буенда авыл «милли» мәктәпләре әнә шулай мөшкел булгач, шәһәр һәм поселокларда яхшыга өметләнү бөтенләй мөмкин түгел. Чөнки шәһәр җирендә халыкның күпчелеге — руслар. Билгеле, татар, башкорт, чуваш, марилар да аз түгел, әмма, авыллардан җыйналган ятимнәр укый торган интернатларны гына искә алмасак, шәһәр җирендә тулаем милли мәктәпләр юк. Дөрес, Казанда ике «татар», Уфада бердәнбер «башкорт» мәктәбе эшли. Ләкин әлеге интернатларның һәм «милли» мәктәпләрнең миллилеге — аларда туган тел һәм әдәбият фәне укытылуда гына. Ул дүртенче-

сигезенче классларда атнасына берничә дәрес, тугызынчы, учынчыларда — берәр сәгать. Калган фәннәр һәммәсе русча өйрәнелә. Башка азчылык милләтләре исә бу «казаныштан» да мәхрүм.

Уфадагы бер мәктәпкә укучылар белән очрашуга баруым әле дә хәтеремдә. Интернациональ дуслык клубы активистлары чакырды мине. Әйтүләренә караганда, бөтен шәһәргә үрнәк мәктәпкә бардым.

Мин класска килеп керүгә, инде мондый эшкә остарган укучылар шаулатып кул чаба башлады. Бу кадәр хөрмәт күрсәтүгә лаекмы соң мин, дип кыенсынып та куйдым. Аннары, тукта, беләләрме соң монда мине укучылар, дип уйлап алдым да үземне Башкортстанның халык шагыйре Рәшит Нигъмәти дип таныттым. Утыз ел элек вафат булган кешенең исемен ишетүгә, тәрәзәләрне чыңлатып, стеналарга эленгән портретларны тетрәтеп, тагын кул чаба башладылар. Кая инде ул без «фәкыйрьләрне» белү! Аларга кем килсә дә барыбер икән ләбаса. Иң мөһиме — активлык күрсәтү.

Яшь интернационалистларга иң гади сораулар бирә башладым: Салават Юлаев кем? Кайда туган, нинди батырлык күрсәткән, кайчан һәлак булган? Габдулла Тукай, Мәҗит Гафурилар кем? Ишеткәннәре бар икән үзе, әмма өзеп әйтергә кыймадылар. Араларыннан берәү дә, хәтта рус малайлары да Пушкинның һич югы бер шигырен сөйләп бирә алмады — кая инде ул Тукайга сан! Залда утырган егерме өч татар һәм башкорт баласының берсе дә туган телен белми икән. Байтак сорауларымны: «Нигә кирәк инде бу?» — дип көлеп каршы алдылар. Чыннан да, нигә? Туган телнең нигә кирәк икәнлеген аңлатыр хәлгә калгач, эшне төзәтеп буламыни? Бу бит — аларның ни өчен кеше булып туганлыкларын аңлату белән бер.

Бу мәктәп укучылары чит илләрдәге яшьтәшләре белән хат алыша. Ул хатларның кайсыларын мин дә караштырдым. Кызыклы. Безнең ил халкына хөрмәт күрсәтеп, русча язганнар. Ә безнең интернационалистлар, ул илнең телен дәрестә өйрәнсәләр дә, җавапны русча гына сырлый. Күп кабатлаудан шомарып, «уңып» беткән җөмләләр. Җавап язганда берсе дә ерактагы дусларга шулай ук кешеләрчә итагатьлелек, хөрмәт күрсәтергә тиешлекне башларына да китермәгән...

Туган телемдә шигырь укырга керештем. Ялгышуымны шунда ук аңладым. Балалар пыш-пыш килә, авыз ера, этешә-төртешә башлады. Әле бая гына мине алкышлаган формаль интернационализм кая китте соң? Нигә минем йөрәк авазым аларга барып җитми? Без аларны шулай тәрбияләгән ләбаса — милли әдәбият аларга кирәкми...

Кайдадыр «өләшенгән» интернационализмның кадере зурмы? Интернационализммы соң ул? Башка халыкларга туган җирнең нинди нурын, нинди рухи байлыгын илтер икән? Бу балалар кеше әйтеп торганны теркәгән хатларында чит ил гражданнарына ни өчен мәхәббәтләрен тонналап бүләк итә (бу яхшы, билгеле!), үзенекеләргә мыскылын да кызгана соң? Туган халкың мәхәббәтеңә мохтаҗ түгелмени? Чит илләр, ят халыклар белән кызыксынуың яхшы яхшысын. Ә үз халкыңны беләсеңме соң? Кардәш чуваш, мордва яки украиннарны беләсеңме? Аларның гаҗәп матур җырларын? Дөрес, аларда җырдан башка хәзинәләр дә җитәрлек. Шулар арасында яшисең ләбаса син!

Соңыннан бер таныш укытучым әлеге «активистлар»ның кайберсе хакында әхлакый мәгълүматлар китерде. Икесе милициядә исәптә тора икән. Берсе үз әнисенә кул күтәргән. Икенчесе — өй баскан. Араларында бер отличник та юк. Укуда аксый, җәмәгать эшләреннән кача, укытучыларны тыңламый торган балалар. Безнең халыкка хас күркәм сыйфатлары кайда соң боларның? Бу укучыларның интернационалист аталырга хакы бармы?

Туган җирендә яшәүче, ата-бабасы учагы янына кеше кыяфәтенә кереп якынлашучы, ата-анасы тапкан ризыкны ашап үсүче кыз белән егет боларның һәммәсен оныта, эреләнә икән — үткәненә һәм бүгенгесенә хыянәт итә. Дөрес, моңа без үзебез үк шартлар тудырабыз. Аның тәкәбберлеге яследә үк тамыр җибәрә башлый. Тәрбияче яс-
ледә һәм бакчада туган телдә сөйләшүне тыйгач, саф күңелле сабый ана теленә
үзе кебекләр арасында хөрмәт юклыгын күрә дә, аның кирәклегенә шикләнә, күңелен-
дә гомер буена җитәрлек икеләнү һәм... масаю комплексы оялый. Ул, янәсе, өйдәгеләр
кебек түгел, артта калган бабалары теленнән башка да яши ала! Шулай итеп, бу адәм
баласы көтелмәгән рәвештә «үз халкыннан өстен» булып чыга! Шуннан соңгы үсеше
аны инде төрле чирләр чыганагы булган милли нигилизмга, үз халкын инкарь
итүгә генә алып килә. Шәһәр кызы яки егетенең милли нигилизмы иң агрессив, иң
азгын, иң ямьсез төс ала — бу сыйфаты аны икмәк исе килгән кара туфрактан, сөт исе
аңкыган җылы яңгырлардан һәм, аеруча үкенечлесе,— күңелне сафландыра торган
физик хезмәттән аера. Миллилек белән интернациональлек нисбәте бозылу кешене рухи
гарипләндерә. Ана теленнән — хис теленнән коры калган, дөньяны тойгы аша танып-
белүе зәгыйфьләнгән саен, шәхеснең салкын акыл, исәп-хисап белән эш итүе көчәя.
Матурлык, әхлакый гүзәллекне адәм баласына хис теле генә тирән сеңдерүен истә

тотсак, ана теленнән мәхрүм калу шәхестә каты күңеллелек, тәкәбберлек, көнчелек һәм башка тискәре сыйфатларның куәтләнүенә китерә. Үзенең ялгыш тәрбияләнүен аңлаган очракта, мондый шәхесләр үпкә, ачу хисләре кичереп, төзәлмәс милләтчегә дә әйләнергә мөмкин.

Күпмилләтле совет педагогия фәне милли психологияне бик нык искә алырга тиеш. Академик Д. Лихачев, күренекле совет шагыйрьләре М. Луконин, К. Симоновлар торгынлык заманында ук бердәнбер телне генә күтәрүгә каршы чыктылар.

Чыннан да, ничек инде ул «гүзәл киләчәк хакына» мин гел эшләргә дә эшләргә генә тиеш, ә минем тирем һәм каным белән барлыкка китерелгән иң гүзәл җәмгыятьтә кемдер бердәнбер буларак яшәргә, рәхәт күрергә мандат алачак? Бары аның теле генә чәчәк атачак? Һәр халык үзенең үлемсезлегенә ышанырга тиеш, югыйсә ул бүген үк яшәү дәртен югалтачак.

4

Җитмешенче еллар башында мәктәпләребезгә ябырылган, бер афәт хакында язуы миңа гадәттән тыш кыен. Юк, мәсьәлә аның четерекле, баш җитмәс дәрәҗәдә катлаулы, сәяси яктан нигезсез, ялгыш, укучыларны шаккатырыр дәрәҗәдә сәер булганы өчен генә түгел. Киресенчә, без, шушы җир вәкилләре, бик нечкә аңлыйбыз: мәсьәлә монда махсус рәвештә катлауландырылган, чын сәясәттән сәясәт белән уйнашчылык итүгә әйләндерелгән. Кем әйтмешли, тарыдан дарыга дүндерелгән. Әйе, мәсьәлә ике игезәк халыкның — башкортның һәм татарның вөҗданына, намусына, дәрәҗәсенә кагылганга күрә, ифрат дәрәҗәдә читен. Искәрмәстән Дәрдмәнд хәтергә төшә:

*Бертуганың чит тибәдер,*
*Дәүләт тигез булмаса;*
*Ана сөтен айры имә,*
*Бала игез булмаса...*

Әллә без буртуган түгелбезме соң? Әллә без алданганбыз? Бу куркыныч сораудан күңел иңри, тын кысыла. Юк, дисең син үз-үзеңә, без — бертуган, без игезләр, бу бәла-казаларда гади башкорт халкының, татар халкының бер генә дә гаебе юк! Иншалла, шулай! Без, типтәрләр, үзебезне татар итеп тоя, яши, башкорт итеп исәпли торган сәер бер милләт вәкилләре идек. Үземә килгәндә, мин татар белән башкорт арасында, татар исәбенә, яңа бер ясалма «типтәр милләте»н барлыкка китерү серләренең төбендә әүвәлдә патша хөкүмәте, соңыннан Сталин бөек державачылыгы ятуын соңлап, бик тә соңлап аңладым. Әле без сабый чакларда авылы-нәселе белән башкорт язылган һәм шуңа бер очракта үзен-үзе инандырган, күп очракларда дәүләт тарафыннан инандырылырга тырышылган авыл картлары еш кына кабатлый иде: «Син — үзең өчен татар, дәүләт өчен — башкорт». Мин гаепләргә ашыкмыйм. Киресенчә, керәшенләнүдән качып, «башкортка әйләнгән» һәм иманын-динен саклап калган бабаларыма мең рәхмәтләр укыйм. Әйе, бернинди өстенлеккә, матди тәэмин ителеш, өстәмә табышка исәп тотмыйча, безнең төбәк халкына хас булган әчкерсезлек һәм беркатлылык белән мин үземне гомер буе ике халыкның улы итеп исәпләдем. Яшь Башкортстан хөкүмәтенең әле 1923 елда ук татар халык шагыйре Мәҗит Гафурины декрет нигезендә башкорт халык шагыйренә әйләндерүендә нинди «тирән мәгънәләр» һәм перспектива ятканлыгына да мин әле генә төшендем шикелле. Ничек кенә булмасын, нәкъ менә шушы ике тугандаш башкорт һәм татар халкы мине — икесенең уртак улын — ашаттылар, эчерттеләр, киендерделәр, кеше итеп тәрбияләделәр, аннары бары хакыйкатьне, бары дөреслекне генә язарга кушып, кулыма каләм тоттырдылар. Минем ни гаебем бар? Әллә мин дә ялганлыйммы? Аерым көчләр тырышлыгы нәтиҗәсендә, шушы ике халык арасында барлыкка китерелгән күңелсез хәлләр нә аларның үткән тарихларында, нә Ватаныбызның башка халыклары тарихында тулаем очрамаганлыктан, ул хакта язу янә дә авырлаша. Ләкин язмыйча ярамый. Мондый хәлләр беркайчан да кабатланмасын өчен кирәк ул.

Сүз таң калдыргыч, әхлаксыз тәҗрибәләр тезмәсе турында барачак.

Җитмешенче елларда Башкортстандагы татар мәктәпләре, нигездә, рус телендә укытуга күчерелгәч, бер дә көтмәгәндә, уйламаганда, ата-аналар, укучылар һәм җәмәгатьчелек белән киңәшеп тә тормыйча, программада фән буларак кына калган татар теле һәм әдәбиятын башкорт теле һәм әдәбиятына алыштырдылар. Кемгә хаҗәт иде соң бу? Әгәр бу өянәкнең башлап йөрүче юлбашчысы тар максатларга, турысын әйткәндә, милләтчелек, урындагы шовинизм даирәләренә хезмәт итә башласа, Ленин телгә алган «хәзерге аппаратыбыз» теләсә нәрсәгә, хәтта аңлатуы кыен, акылга сыймый торган кырын эшләргә дә сәләтле икән, дигән хакыйкать ачыла. Әйе, бер караганда КПСС Үзәк Комитеты, Башкортстан Өлкә Комитеты үзебез үстергән зур

җитәкченең икътисади, сәяси өлкәләрдә җитәкчелек итү алымнарын хөкем итте. Нәтиҗәдә, Шакиров һәм аның яраннары зур гөнаһлары өчен эшеннән алынды. Әмма, әйтергә кирәк, милли мөнәсәбәтләрдә, мәдәният-мәгърифәт нисбәтләрендә халыкларга каршы алар эшләгән искиткеч зур җинаятьләр «Софронов эше» артына күмелеп калдырылды. «Шакировчылык» күренешен әле ахыргача ачасы, фаш итәсе, төрле гаделсезлекләрне, башбаштаклыкларны тулаем бетерәсе бар.

Бер төркем кешенең нәфесе барлыкка китергән, җирле милләтчелекнең бугазына таш булып торган татар мәктәпләре мәсьәләсе элекке җитәкчелекнең иң зур гаепләреннән берсе булып тора. Рәсми органнарның карарына нигезләнмичә, яшерен, телефон аша күрсәтмә биреп, шыпырт кына эшләнгәнлектән, республика җәмәгатьчелеге укыту телен алыштыруны шактый соңга калып белде. Матбугатта ачыктан-ачык язылмагач, хәбәрдар булмаган кешеләр аңа бөтенләй ышанмыйлар иде. Бу хәрәкәткә карата үзенең аз гына булса да кире мөнәсәбәтен белдергән затлар рәхимсез рәвештә эзәрлекләнде. Соңыннан, «ата-аналар теләге» буенча (!), «Башкортстанның көнбатыш районнары мәктәпләрен туган телдә укытуга күчерү» дип аталган бу тәҗрибә баштан ук драматик төс алды. Күрәсездер, монда да «ата-аналар теләгенә» таянылган. Аһ, шул «теләк» булмаса! Хәзер инде ун еллык тәҗрибәне йомгаклап, шуны әйтергә була: бу дәвердә шулкадәр ата-ана, укучы һәм укытучыларның күз яше түгелде, шулкадәр йөрәк бозылды, шулкадәр күп язмышлар тапталды, теге дөньяга китеп барды, төрле оешмаларга һәм редакцияләргә шулкадәр күп шикаять, зар язылды ки (алдан ук тыелу аркасында ул хатларның берсе дә матбугатта басылмады), әгәр аларның барысын җыеп өйсәң һәм ут төртсәң, аның кайнарлыгы Төньяк боз океанының теләсә нинди почмагын эретергә җитәр иде кебек. Әмма «партиянең тугры җитәкчесе» Шакировның бәгыре боз тауларыннан катырак булып чыкты...

Һәрбер иҗтимагый күренешнең, философия фәне өйрәткәнчә, объектив һәм субъектив сәбәпләре була. Башкортстан җирлегенә күчергәндә, бу сәбәпләрнең нигезендә, кыска гөнә итеп әйткәндә, әхлаксызлык һәм мәдәниятсезлек белән коралланган тупас көч ята. Шулай да уйланып карыйк әле: бер халыкның телен тугандаш икенче халык теленә күчерү өчен тарихи яктан акланган мохтаҗлык бар идеме? Шушы адым нәтиҗәсендә әлеге халыклар, аларга җитәкчелек иткән Үзәк ни отты? Әллә соң бер бишектә кан-кардәш булып үскән ике төп милләтне маңгайга-маңгай чәкештергән Беренче секретарь шушы гамәленнән шәхсән файда күрдеме?

Гомумән, татар халкына каршы бу эш ничек әзерләнде?

Моны ачыклау өчен безгә бераз гына булса да артка чигенергә, тарихка күз салырга кирәктер.

Билгеле булуынча, «Идел-Урал штаты», «Татар-башкорт республикасы» проектларын тормышка ашыру ике халык өчен дә заманында иң кулай юл итеп фараз кылына иде. Аларның берсе гамәлгә ашкан хәлдә дә, тугандаш татар һәм башкорт халыкларының мәдәни-сәяси үсеше тоткарланмаячак, бүгенге хәлгә төшмәячәк иде. Әмма башланып киткән гражданнар сугышы, Казанның — чехлар, Уфа губернасының Колчак тарафыннан басылып алынуы, мөстәкыйль дәүләт төзергә омтылган башкорт милли хәрәкәтенең үзен татар-башкорт җөмһүриятенә каршы куеп, аклар ягына чыгуы, соңгы чиктә Милләтләр эшләре буенча Халык Комиссары Сталинның халыкларны, бигрәк тә төрки халыкларны, бүлгәләп хакимлек итү юлына басуы үз нәтиҗәләрен бирми калмады.— 1919 елда «Кече Башкортстан» дип аталган республика һәм 1920 елда аерым Татарстан республикасы төзелде. Миллион ярым чамасы татар, ярты миллионлап рус һәм башка халыклар яшәгән Уфа губернасы ике арада «хуҗасыз» торып калды. Алга киткән авыл хуҗалыгы, тимер юлы, телефон-телеграф челтәре, промышленность һәм җитештерү чыганаклары, шәһәрләре, аннан да әһәмиятлесе — чамасыз «милли рухлы «Кече Башкортстан» җәмәгатьчелеген нейтральләштерергә» тиешле күп санлы ят этносы белән губерна 1922 елда башкорт дәүләтчелегенә кушылды. Бу кушу икътисадый-социаль үсеше ягыннан артта калган, ни шәһәрләре, хәбәрләшү чаралары булмаган Кече Башкортстанны куәтләндерү итеп танытылса да, чынлыкта, бер яктан, әле һаман «бәйсезлек» хакында хыялланган башкорт җитәкчеләрен «авызлыклар» өчен, икенче яктан исә, татарларны әнә шулай таркатып, бүлгәләп, аның милли дәүләтчелеген зәгыйфьләндерер өчен дә эшләнде. Шулай итеп, милли сәясәтне үзенчә тормышка ашырган Сталин, Ленин түшәктә ятудан, М. Х. Солтангалиев тарафдарлары тиешенчә оешырга өлгермәүдән файдаланып, ике игез халык арасына мина куйды. Аның проекты буенча, икенче бер республикага үз ихтыярыннан тыш куып кертелгән миллион ярым татар азчылык тәшкил иткән башкортлар янында хокукый яктан гарантияләнмәде — аның исеме җөмһүрият атында чагылдырылмады, милли ихтыяҗларын канәгатьләндерү юридик яктан беркетеп куелмады, теләсә нинди җәбер-кысымнарга дучар ителәчәк килмешәк хәленә төшерелде.

Нәтиҗәләр озак көттерми. Шул ук елда Уфада исеме бөтен илгә билгеле «Нур»

татар театр группасы таратыла. Беренче башкорт дәүләт театры өчен актерлар әзерләгән тугандаш татар труппасын Уфа сыйдыра алмый башлый. Милләте белән татар, үз гомерендә бер генә шигырен дә башкорт телендә язмаган, бер генә китабын да башкорт телендә чыгармаган Мәҗит Гафури (1880—1934), әйткәнемчә, бу вакыйгалардан соң бер ел да үтеп өлгермәстән, Башкортстанның халык шагыйре итеп игълан ителә, тора-бара бу исемнең «Башкортстан» мәгънәсе «башкорт» даирәсенә күчерелеп, этник бизәккә дә әйләндерелә. Уфада яшәп иҗат иткән күренекле татар шагыйрьләре һәм язучылары Афзал Таһиров, Сәйфи Кудаш, Шәехзадә Бабич, Гариф Гомәр, Хәсән Мохтар һәм башкалар башкорт язучылары дип атала башлый. Кырыгынчы еллар башында Уфада татарча китаплар чыгару тыела. Булган газета-журналлар ябыла, йә башкорт теленә күчерелә. Язучыларыбызның яңа буыны Мәлих Харис, Наҗар Нәҗми, Тимер Арыслан, Иосыф Гәрәй, Гали Ибраһимов, Мостай Кәрим, Ибраһим Абдуллин һәм башкалар иҗатларын туган телдән башкорт теленә күчерергә мәҗбүр булалар.

1926 елда үткәрелгән Бөтен Россия халык санын исәпкә алу чорында Башкорт АССРында йөз меңнәрчә татар башкорт итеп яздырыла. Сугыштан соңгы елларда бу афәт тагын да көчәйде һәм кешелексез формалар алды. Аны 1959 елда халык санын алган чакта КПССның Башкортстан өлкә комитеты беренче секретаре булып эшләгән З. Н. Нуриев яңа көч һәм дәрт белән дөрләтеп җибәрде. Әмма ул чакта «көнбатыш башкортлар» төшенчәсе дә, ходайга шөкер, мәктәпләребезне башкорт теленә көчләп күчерүдә юк иде әле. Әмма Нуриев кулыннан башкортлаштыру дилбегәсен алган М. З. Шакиров һәм аның яраннары бу эшне ничектер «фәлсәфи» нигезләү, «конституциягә туры китерү» кирәклеген чамалаган. Моны инде күктән өмет итү дә кирәкми, республика законнары үз кулларында, аның яңа редакциясен кабул итү көннәре дә якынлашкан чак. Шуңа күрә Шакиров һәм аның әшнәләре Башкорт АССР Төп Законына, үз биләмәсенә кергәндәй, үз догалыклары белән бәреп керәләр. Нәтиҗәдә, Башкорт АССРның 1978 елда кабул ителгән Төп законында республикабызда яшәүче халыкларның демократик хокуклары чикләнгән булып чыкты. Башкорт АССРның 1937 елгы Конституциясенең 24 статьясында «Башкорт АССР Югары Советы кабул иткән законнар башкорт, рус һәм татар телләрендә басып чыгарыла» диелгән. Яңа редакциядә исә «һәм татар» дигән тәгъбир рәхимсез рәвештә сызып ташлана: шулай итеп, миллионнан артык кешенең — халыкның киләчәк язмышы бер селтәнү белән балта астына куела. Шулай итеп, Башкорт АССРның 1978 елгы Конституциясендә бары тик башкорт һәм рус телләре генә гамәлдә калдырыла.

1937 ел Конституциясенең 78 статьясында: «Башкорт АССРның башкорт, рус, татар, мари яки чуваш халкы күпчелек тәшкил иткән районнарында, шәһәр районнарында һәм поселокларда хөкем эшләре шул нисбәттә башкорт, рус, татар, мари һәм чуваш телләрендә, ә үзәк хөкем учреждениеләрендә — башкорт, рус һәм татар телләрендә алып барыла»,— диелә. 1978 елгы Төп законда инде: «Хөкем эшләре... башкорт һәм рус телләрендә яки шул урында күпчелек тәшкил иткән халык телендә алып барыла»,— дип кенә белдерелә. «Күпчелек халык» ниндирәк халык икән ул? Аның исеме юк микәнни? Тиргә төшеп эшләгәндә, республика казнасын баетканда исеме булган халыкның үз рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә дигәндә нишләп исемен дә телгә алырга тартыналар? 1978 елгы Конституциянең милли мәсьәләләрне «уңай хәл итүдә» 1937 елгы Сталин бабай Конституциясеннән ни дәрәҗәдә «демократиграк» икәнен укучылар үзләре дә абайлагандыр, дип уйлыйм.

Мәктәпләребезгә тоташ һөҗүм нинди фәлсәфә нигезендә башланды соң? Аның халыкка әле дә булса тәкъдим ителмәгән платформасы нидән гыйбарәт иде? Бу «документ» беркайда да басылып чыкмаган һәм тикшерелмәгәнлектән, аны бары тик фараз итәргә генә кала. Бу җәһәттән Башкортстан тел, әдәбият һәм тарих институтының Башкортстан мәгариф министрлыгына һәм КПССның Башкортстан өлкә комитетына әзерләгән тәкъдимнәре билгеле. Имештер ки, Көнбатыш Башкортстан районнарындагы халык — ул һич кенә дә татар түгел, ә кайчандыр татарлаштырылган башкортлар, алар укытуны үз телләренә кайтаруны сорый, шуңа күрә бу эш — безнең изге бурыч. Кыска гына итеп әйткәндә, бу тәкъдимнәрне шулайрак итеп гомумиләштереп булыр иде. Мондый зур мәсьәләләрне трибуна артыннан, йә булмаса телефон аша хәл итү урынына халыкның үзеннән аның нинди милләт вәкиле итеп тоюын референдум тәртибендә сорашу, халык теләген исәпкә алып эшләү иң мәгъкуль нәрсә дә бит, тик нишләтәсең, ул чакта узурпаторлар уйлаган ниятнең барып чыкмаячагы көн кебек ачык.

Бу каршылыкны яхшы аңлаган аппарат районнарда, халыктан яшереп, «фәнни-практик» конференцияләр үткәрә. Шундый иң зур корылтайларның берсе 1979 елның җәендә Илеш районында җыела. КПССның район комитеты беренче секретаре Тәлгать Рахманов, үзе җитәкчелек иткән районда башкорт телендә сөйләшкән бер генә авыл да булмауга карамастан, район мәктәпләрен бер ел эчендә башкорт теленә күчереп

бетерергә социалистик йөкләмә алып, Шакировтан Социалистик Хезмәт Героеның икенче йолдызын дәгъвалый. Әйе, эшләр майлаган кебек бара. Син бел дә мин бел! «Көнбатыш районнарны туган телдә укытуга күчерү»гә багышланган «фәнни-практик конференция»гә Башкортстанның көнчыгыш төбәкләреннән «тәҗрибә уртаклашу» өчен дистәләрчә башкорт теле һәм әдәбияты укытучылары җыела. Илеш районының кичә генә татар телен укытып, иртәгә инде, вата-җимерә булса да, башкорт телен укытырга тиешле укытучылары, көнбатыш районнарның халык мәгарифе бүлеге мөдирләре, шулай ук тел-әдәбият белгечләре чакырыла. Башкортстан татарларына карата яманлык кылуда зур өлеш керткән филология фәннәре кандидаты, ошбу конференциянең теоретигы, илһамчысы булган шагыйрь Рәшит Шәкүров бу уңайдан матбугатта ялкынлы мәкалә белән чыгыш ясый. («Совет Башкортстаны», 20.12.79. «Белем аскысы — тәрбиә коралы»). Исеменнән күренүенчә, аннан да бигрәк, «Илештә мәсьәләнең бу нечкәлеген бик яхшы төшенеп» эш итүче Рахманов кебекләрне чамасыз мактавыннан чыгып караганда, бер нәрсә яхшы аңлашыла: татар халкына «белем ачкычы һәм тәрбия коралы» булып һич кенә дә туган татар теле түгел, ә бары тик башкорт теле генә хезмәт итә ала һәм итәргә тиеш.

Без бүген бу сүз берләшүнең эзен тарихка сеңдереп калдыруы өчен Р. Шәкүровка мең рәхмәт әйтәбез. Чөнки конференция хакында башка газеталар — ләм-мим. Р. Шәкүров иптәш тасвирлавынча, анда катнашкан кешеләр исемлеге дә шактый саллы. Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим, язучы һәм әдәбиятчы Кирәй Мәргән, шагыйрьләр Абдулхак Игебаев, Равил Нигъмәтуллин, БАССР Мәгариф министры С. Җиһаншин... Башкорт тел гыйлеменең барлык диярлек приват-доцентлары, шагыйрьләр белән ярыша-ярыша, икенче телдә укытуга күчәргә тиешле укытучыларга үгет-нәсихәт бирәләр. Бу сәхифәләрнең төп илһамчыларыннан булган КПССның Башкортстан өлкә комитеты секретаре Т. Ахунҗанов һәм — мәктәпләр бүлеге мөдире Ә. Азнабаев, ни сәбәпледер, конференциядә катнаша алмыйлар. Аларның вазифасын бүлек мөдире урынбасары Г. Иргалин башкара.

Кичен Яркәй мәдәният сараенда Илеш халкы белән әдәби очрашу үткәрелә. Кунаклар туган тел хакында матур итеп сөйли, әмма илешлеләр аның кем «туган тел»е булачагы турында уйлап та бирми, алар бу сүзләрнең мәгънәсен еллар үткәч кенә аңлаячак. Башкортстанның егермедән артык районындагы татар мәктәпләре чын-чынлап кан-яшькә батырылачак, татар китаплары һәм дәреслекләре җыелып алына, яндырылачак, укытучылар куылачак, кайсылары йөрәген тотып егылачак. Ата-анага — бала, балага ата-ана ят кешегә әйләнәчәк. Мәктәпләргә татар газета-журналлары алдыру тыелачак. Башкортстан радиосы фондындагы татар җырлары язылган меңнәрчә метр тасма юкка чыгарылачак. Татарча өндәмәләр элү, спектакльләр кую, конкурсларда татарча шигырь сөйләү, җыр җырлау гамәлгә яраксыз дип игълан ителәчәк. Башкортстан радиосы һәм телевидениесе татар телендә концертларны туктатачак. Кешене яңа вазифага тәгаенләгәндә Шакировның иң әүвәл келәмгә бастырылган шәхестән милләте татар булганы өчен көлүе, аннан үз кулы белән аның паспортындагы милли билгесен татардан башкортка әйләндерүе гадәткә керәчәк...

Бу хакта бихисап сөйләп булыр иде. Әмма кирәге юктыр, болай да аңлашыладыр. Ул елларда Башкортстанга кайтып киткән татар кешесенең никадәр рәнҗегәнлеген күз алдына китерү һич кенә дә авыр түгел.

Газета язуынча, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим, Илеш конференциясендә чыгыш ясап, үзенең сүзләрен менә ничек тәмамлый: «Без бүген инсафлы, иманлы халыкның җирендә, Илеш туфрагында, телебезнең, культурабызның киләчәге турында хәстәрлибез... Бу сокландыргыч мәҗлес — тарихи мәҗлес. Мин шушы мәҗлестә катнашуым белән бәхетлемен». («Совет Башкортстаны», 20.12.79.)

Зыя Камали, Сәйфи Кудаш, Фәридә Кудашеваларны дөнья мәдәниятенә бүләк иткән Келәш авылында туып үскән халык шагыйре М. Кәрим, күрәсең, бу мәҗлеснең ни кадәр «тарихи» булачагын алдан сизенгәндер. Тагын да Дәрдемәнд хәтергә килә:

*Ни газизрәк — бу ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!*
*Ул мөкатдәс кан белән ул*
*Изге сөткә ни җитәр!...*
*Сөт калыр, ватан китәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!*

Ана сөте белән сеңгән туган телдән сабыйларны аеру... Җир йөзендә моннан да яманрак нәрсә бар?

«Гафури районының Ялгыз Каен мәктәбендә туган тел дәресе урынына көтмәгәндә генә башкорт телен керттеләр, — дип яза Р. Уразаев. — Бөтен халык аптырашта калды. Бу яңалык кертелгәндә бөтен кеше көзге кыр эшендә иде. Авылыбызда бер

генә дә башкорт юк. Мондый күрсәтмәләрне кем бирде икән? Иле барның теле бар, диләр. Без хәзер нәрсә, ватансыз да калдыкмыни инде?»

«Башта мин бу яңалыкка җитди игътибар бирмәгән идем,— дип яза «Кызыл Таң» газетасы редакциясенә Бүздәк районы Картамык авылыннан Ф. Ихсанова.— Оныгым укырга кергәч кенә, башкорт теленең балаларыбыз өчен никадәр авыр икәнлеген төшендем. Чөнки алар, ата-бабаларыбыз шикелле, татарча гына сөйләшә. Кайда соң ул гаделлек?»

«Ата-аналарының һичбер ризалыгын алмыйча, ана теле урынына башкорт теле укытуны кертүгә каршы протест белдерәбез. Туган тел чолганышында яшәсәләр дә, аңа өйрәнмәү мәктәптә исә берьюлы өч яңа тел — башкортча, русча, немецча укый башлау балаларыбызны чыгырыннан да чыгара, надан да калдыра. Башкорт телен өйрәнү аларның тел культурасын, дөрес укый-яза белүен нык аксатты. Алар хәзер дөрес иттереп сөйләшә дә, фикер йөртә дә алмыйлар. Бу алардагы зиһен үсешен нык тоткарлый. Халык мәгарифендә гасырлар буе формалашкан нигезне — балаларны туган телдә укытуны җимерү кемгә кирәк? Ашыгыч чаралар күрүегезне үтенәбез! Дүртөйле районы Иске Яндыз мәктәбе ата-аналары»...

Республика мәгариф министрлыгына, редакцияләргә менә шундый күпләгән хатлар җибәргән җәмәгатьчелек чара күрелүен көтеп көтек булды. Берсен берсе алыштырган министрлар С. Җиһаншин һәм С. Сөләйманова кул куйган җавапларның һәммәсе: «Барып тикшерү нәтиҗәсендә, сезнең мәктәптә балаларның укый-яза белүе әйбәт булуы ачыкланды. Туган башкорт телен өйрәнү ата-аналар теләге буенча тормышка ашырыла»,— дип белдерә иде.

«Гаиләләребездә балалар һәм ата-аналар төрле телдә сөйли хәзер,— дип яза Бакалы районыннан пенсионер Т. Топоркова.— Бу аларның әхлагы аерымлануга, бер үк гаиләдә яшь буынның өлкән буынга каршы куелуына китерә... Үз ана теленнең кадерен җую, дәрәҗәсен төшерү халыклар дуслыгын кайчан булса да ныгытканы бармыни? Яшьләр татарча белмәгәнгә күрә, бәйрәмнәрдә спектакльләр куя алмыйбыз. Шушы да культура алга китүме инде? Нишләп бу хәл җитәкчеләребезне борчымый?»

Топоркова ханымның халыклар дуслыгын телгә алуы бик табигый: ул бу идеянең тонықланмавын, болгандырылмавын тели. Сүзнең эштән аерылмавын, һәр фикернең алтын нигезгә таянуын куәтли. Әлекке җитәкчеләребезгә нәкъ менә шушы нәрсә җитешмәде дә инде. Сүз белән эш еш кына капма-каршы куелдылар. Нәкъ менә татар мәдәнияте, мәгарифенә каршы яшерен һөҗүмен башлар алдыннан, М. Шакиров КПСС-ның XXV съезды трибунасыннан торып: «Халыклар дуслыгы — могҗизалар тудырырга сәләтле казанышыбыз. Республикабыз хезмәт ияләре барлык казанышлары, бәхетле, шатлыклы тормышы ленинчыл милли политика нәтиҗәсендә барлыкка килүен яхшы аңлый... Республикабызның коммунистлары һәм бөтен хезмәт ияләре ихтыярын һәм көчен түрендәге уйларын чагылдырып, без шушы биек мөнбәрдән халыкларның изге дуслыгын киләчәктә дә күз карасы кебек саклаячагыбызны белдерәбез» — дип чыгыш ясады.

Үз мәктәбемә кире әйләнеп кайтып, мин шуны гына әйтәм: юк, Шакиров халыкларның изге дуслыгын күз карасыдай саклый алмады. Дөресрәге, теләмәде. Тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, ул туган халкының күз карасына чәчәк авыруыннан кала торган ак булып төште. Әле җитмешенче еллар уртасында икегә аерылып, «икенче сортлы» булып булса да, татар теле һәм әдәбиятын укып азапланган мәктәбемдә сиксәненче еллар башында аңа алмашка башкорт теле һәм әдәбияты килеп урынлашты. Сиксән процент татар тәшкил иткән төбәктә бу шаккаткыч хәл иде. Операция белән Миякә район комитеты секретарьлары Ш. Гайсин һәм Г. Мөлекова җитәкчелек иттеләр. Гәүһәр Мөлекова белән без кайчандыр — әле иске мәктәптә — бергә укыган, комсомол комитетында бергә эшләгән һәм халкыбызга тугры хезмәт итәргә дип бергә ант иткән идек. Милли үзаңы бар кеше иде ул. Татар кызы иде. «Интернационализмштерү»нең башта рус вариантына, аннан башкорт вариантына хезмәт иткән вазифалы кеше ничек кенәләр үзгәрми икән ләбаса! Күп тә үтми, балалар һәм ата-аналар көчләп тагылган телдән баш тарттылар. Әмма читтән китертелгән директор һәм аның хатыны эшсез калмадылар. Исем өчен генә булса да биш-алты бала өчен башкорт классы тотылды, татар теленнән мәхрүм балалар ул сәгатьләрдә урамда трай типте. Хәзер дә туган мәктәбемдә элеккечә үк шыксыз хәл: мәктәпне кире татар мәктәбенә әйләндерерләр иде — «ата-ана теләми», имеш; җитәкче акыл белән рухланып, бәлки, ачып та җибәргән булырлар иде — өстән күрсәтмә юк, үзләре тотынырга куркалар. Менә әхлаксызлык нинди түбәнлеккә төшерә. Минем классташым Гәүһәр Мөлековага килгәндә, аны райкомнан әйбәт кенә итеп кудылар, әмма ул югалмады — беренче рус мәктәбенә килеп, башлангыч классларга бүлегенә мөдирә булып урнашты. Күптән түгел генә күрешеп тә алдык: тормышыннан бик тә канәгать, үзенең тирән рухлы интернационалист, минем исә түбән рухлы милләтче икәнлегемне кистереп әйтә...

Партиянең Февраль (1988 ел) Пленумыннан соң алган сабаклар нәтиҗәseme бу? Кайчандыр бер философ, тарих ул тарихтан сабак алмау өчен кирәк, дигән иде. Нәкъ шулай килеп чыга түгелме? Хәтеребез йомшарган булса, әйдәгез, искә төшереп үтик. «Туган телне, аның үсешен һәм рус теле белән үзара бәйләнешен кайгырту табигый күренеш. Һәр тел — безнең уртак байлыгыбызның аерылгысыз өлеше,— диелгән иде Февраль Пленумында сөйләнелгән төп докладта.— Тел мәсьәләсендә бернинди өстенлекләргә яки чикләүләргә, бигрәк тә, мәҗбүр итүләргә юл куярга ярамый.

Кызганыч ки, кайбер төбәкләрнең партия һәм совет органнарына бу мәсьәләләрдә әек акыл, сыгылмалылык, кайвакытта исә мәсьәләне сәяси яктан аңлау җитешми. Аерым алганда, Башкортстанда нормаль булмаган хәл туды — монда башта татар телендә укыта торган мәктәпләр ябылды, аннары бүтән җирле телләрдәге мәктәпләр дә юкка чыкты. Хәзер бу эшне төзәтергә туры килә».

Якындагы үткәннәр искә төшсә, йөрәк өшеп куя. Ул көннәргә кире кайтып, «Правда» газетасы болай дип тә язган иде: «Ике республика арасындагы рәсми дәрәҗәдәге мөнәсәбәтләрдә, йомшак кына итеп әйткәндә, егерме елга якын салкынлык хөкем сөрде. Башкортстанның элекке җитәкчелеге киңәйтелгән якынаюга бармады, әмма әчтә зыянлы «башкортлаштыру», ягъни көчләр милләтне алыштыру. КПСС Үзәк Комитетының Февраль (1988 ел) Пленумында дөрес билгеләнүенчә, татар мәктәпләрендә туган тел урынына башкорт телен кертү политикасын тормышка ашырды. Мондый тайпылышлар милләтара багланышларга билгеле дәрәҗәдә зыян китерә иде...»

Нәфрәт уята торган шушы әхлаксыз эшләрне планлаштыруда һәм турыдан-туры гамәлгә ашыруда катнашкан югары вазифалы җитәкчеләрнең исемнәрен атарга да вакыт җитте хәзер. Алар — Республика Югары Советы рәисе Ф. Солтанов, партия өлкә комитетының идеология буенча секретаре Т. Ахунҗанов, өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире Ә. Азнабаев, мәгариф министрлары С. Җиһаншин һәм С. Сөләйманова, БАССР Министрлар Советы рәисе урынбасарлары Г. Сабитов, В. Байтурина Башкортстан тел, әдәбият һәм тарих институты директоры З. Ураксин, БАССР Югары Советының мәгариф буенча комиссия рәисе Р. Кузеев һәм башкалар.

Ничек кенә булмасын, югары әхлактан читтә калган Шакиров, юмарт хәерләр өләшеп, туган халкы исәбенә арттырган «башкортларның рухи атасына» әверелә алмады, башкорт сәнгате һәм мәдәниятында яңа Ренессанска да нигез сала алмады. Ул ике халыкны берьюлы бөлдерде һәм бүгенге көндә политик шәүләгә әйләнде.

Бүгенге аппарат һәм аның вәкаләтле вәкилләре исә вакыйгалардан соң киләчәккә сабак алдылармы? Кешелек тарихы һәм цивилизациясе күзлегеннән чыгып карап, алар тупас көчнең бер вакытта да ирекле рухны җиңә алмаганлыгына иман китерделәрме? Кызганыч ки, эш башында торган, йә булмаса шушы эшкә фәлсәфи юнәлеш биргән даирәләрдә уңай үзгәрешләр күзгә ташланмас дәрәҗәдә аз әле. Соңгы вакытта бу «теоретиклар» Башкортстанда татар халкының этник берәмлек буларак барлыгын (!) ачыктан-ачык инкяр итә башладылар. Дөнья филологиясендә, мәсәлән, ике тел арасында яткан диалекталь телләр билгеле түгел иде әле. Әйтик, рус һәм украин телләре «арасында» нинди шивә булуы мөмкин? Аның бары тик йә рус теле шивәсе, йә украин теле шивәсе генә була. Теләсә нинди телнең үз сөйләмнәре йолдызлыгы бар, ә менә ике тел арасындагы сөйләмнәр... Юк, юк! Республикабызның Мәгариф министры булып эшләгән С. Сөләйманова ханым, филология фәннәре кандитаты булуына карамастан, бу гади хакыйкатьтән читләшергә тырышып, фәндә яңа материклар «ачарга» омтыла: «Бу авылларда (көнбатыш районнарның татар авылларында — А. Х.) халык чиста татар телендә сөйләшми. Аларның теле — башкорт һәм татар телләре арасындагы (?!) диалект».

Башкортстан тел, әдәбият һәм тарих институты директоры профессор З. Ураксин да, милләтара багланышлардагы императив юнәлешләрне билгеләп, сүзен кыска тота: «Халыкның сөйләм теле (көнбатыш районнар халкы була инде — А. Х.) катнаш. Ул башкорт һәм татар телләре арасында аралаш сөйләш».

Мондый «фәнни» концепцияләрнең халыклар дуслыгы, чын бердәмлек белән тәңгәл килүе мөмкинме? Коткыдан башка, тагын нәрсә дип атарга мөмкин бу «тырышлыкларны?» Иң кызганычы шулдыр ки, бу нигезсез, бер сүз белән әйткәндә, икенче бер тугандаш халыкны йоту рухы белән сугарылган уйдырмалар эфирдан агыла, экраннарда чагыла, халыкларның саф зиһенен куралмаучылык төтене белән ыслый. Без милләтара багланышларны гармоник тәртипкә китерү турында сөйлибез. Һәм шул ук вакытта халыкка каршы законнар кабул итәбез, күрсәтмәләр төшерәбез. Бер ике генә мисал. БАССР Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясе, мәсәлән, 1988 елның 28 декабрендә, «Башкортстанның көнбатыш районнарындагы татарлар теле башкорт теленең диалекты ул» дигән уйдырманы раслап, махсус документ кабул итте һәм аны, үз татарыбыз — министр Р. Гарданов имзасы белән ныгытып, көнбатыш районнар халык мәгарифе бүлекләренә мәктәпләрне башкорт теленә укытуга күчерү

буенча рәсми күрсәтмә итеп төшерде. Татар җәмәгатьчелеге халыклар арасына кара мәче җибәрүче бу документны киң җәмәгатьчелеккә фаш итте һәм ул шуннан соң гына гамәлдән чыгарып ташланды. Җәмәгатьчелек менә ничә ел инде татар теленең рәсми хокукын БАССР Конституциясендә аякка бастыру өчен көрәшә. Башкортстан өлкә Комитетының татар халкына, аның мәдәниятына, мәктәбенә карата үткәргән кысымы үзәк органнар тарафыннан күп тапкырлар тәнкыйть ителде, гаделсезлекләрне төзәтергә кушылды. Бер караганда, урындагы түрәләр, халык алдындагы гаепләрен тоеп, һәр нәрсәгә игътибарлы булырга, үзгәртеп кору шикелле җаваплы заманда яхшы, хезмәтчел кәеф өчен барысын да эшләргә тиешләр иде кебек. Яхшы кәеф — ул яхшы хезмәт, дигән сүз. Әмма, юк. БАССР Югары Советының 1989 елның 2 ноябрендә үткән сессиясе дүрт миллион күз алдында миллион ярымга якын татар халкының телен сайлау турындагы законнан төшереп калдырды. Һаман да шул: башкорт теле, рус теле — гамәлдә, ә татар теле гамәлдә түгел. Бу сәясәттәге балачагалык күренеше түгелмени? Әле күптән түгел генә БАССР Халык мәгарифе министрлыгы, Башкортстан тел, әдәбият һәм тарих институты, Башкортстан укытучылар белемен күтәрү институты һәм «Урал» башкорт мәдәният үзәге республиканың көнбатыш районнарындагы татар мәктәпләрен яңадан башкортча укытуга күчерү буенча Борай районында тагын да бер «фәнни-практик» конференция үткәрергә омтылыш ясап карады. Әмма барып чыкмады.

Кем мәнфәгатьләренә хезмәт итә бу тырышлыклар? Башкорт мәнфәгатьләренәме? Юк, түгел. Башкорт халкы исеменнән чыгыш ясаган бер төркем милли алып-сатарлар ике бертуган халыкны бер-берсенә каршы куеп, нинди җиңүләргә ирешерләр икән? Татар халкына нәфрәт тәрбияләү өчен нинди нигез бар? Ул бит башкорт мәдәнияты, мәктәбе мәнфәгатьләренә зыян китерми. Киресенчә, иң якын, тугандаш халык буларак, аларның сагында тора һәм бер үк вакытта җимерелеп, таркалып барган үз мәдәнияты белән дә кызыксына. Башкорт зыялыларының аны аякка бастырудагы ярдәме өчен татар халкына, аның укымышлыларына булган рәхмәте шушымы?

Дөнья тарихында халыкларның үзара үрелеп үсүе, хезмәттәшлек итүе — табигый күренеш. Татар халкы гасырлар тирәнлегендә теге яки бу халыкка күрсәткән рухи ярдәме өчен бер нинди дә хак сорамый бит. Үз гомерендә шундый ук ярдәмне ул башка халыклардан, мәсәлән, гарәпләр һәм фарсылар, төрек һәм һинд халыкларыннан алган. Ләкин моңа карап кына кимсенергә яки кимсетелергә ярыймы? Халык язмышы табигый үсеш бәҗралары аша үтә. Аларны беркем дә сикереп уза һәм чикли алмый.

Татарлар егерменче йөзгә иҗтимагый сыйфатлары, институтлары җитәрлек дәрәҗәдә үскән буржуаз милләт хәлендә аяк басты. Иван Грозный басып алганнан соң рухи үсеше бик нык тоткарланса да, 1905 ел инкыйлабыннан соң канатларын киң җәеп җибәрде һәм бу канат башка төрки халыкларга да җылыны мул төшерде. Моны бер генә халык та инкар итми. Бик нык баеп китеп, үз үткәнеңне, сиңа кул биреп, үргә тартып менгезгән изге затларны оныту — дан эш түгел. Нишләмәк кирәк, үз милләтенең рухи ихтыяҗлары белән янәсы урында, кайбер көчләр аның бәхетен икенче милләт исәбенә тәэмин итәргә чамалый, тарихны боза... Өмет юк түгел, үтәр, бу бәла дә үтәр, хаклык өскә чыгар, иншалла!

Герценның үткен сүзләре белән әйтсәк, «Европа идеяләренең Азиягә үтеп керүе юлында төп кәрвансарай бурычын үтәгән Казан «гасырлар буе типографияләре, галимнәре, китаплары белән без башкортларга мәгърифәт нуры китерде. Рәхмәт аңа! Татар зыялылары мәктәпләр ачарга, мәдрәсә, мулла-мөдәррисләр, хәлфәләр тотарга, балаларны укырга-язырга өйрәтергә булышты, халык зиһенен мәҗүси караңгыдан йолып алырга тырышып, китаплар белән тәэмин итте,— шуның өчен патша яраннары тарафыннан эзәрлекләнде һәм җәберләнде. Боларның һәммәсе дә тарихтан яхшы мәгълүм. Рус, гарәп һәм шәрык мәдәниятларының алдынгы идеяләре белән сугарылган татар зыялылары башкорт милләтенә ярдәм итте, кулына каләм белән әлифба тоттырды. Бу ике халыкның дуслыгы, тарихи яшәеш дәвамында берсенең икенчесенә эчкерсез ярдәм итүе чын-чын интернациональлекнең асыл үрнәге булып тора. Нигә моны онытырга яисә тарихтан сызып ташларга?

Тагын шунысы да игътибарга лаек: Идел-Кама буйларында үз чикләренә аерым башкорт кабиләләре дә кергән Бөек Болгар, Казан ханлыклары яшәгән заманнарда да бу ике халыкның нә авыз иҗаты, нә борынгы язма әдәбияты, нә тарихы соңыннан Казан татарлары дип атала башлаган болгар кавеменең башкортларга каршы сугышуын, аларны талавын, рәхимсез рәвештә кырып, бастыру күренешләрен хәтерләми. Хәзерге көндә безнең кайбер галимнәребез шундый «сугыш-талашлар» барлыгын раслаган кобаерлар эзли эзләвен, әмма таба гына алмый.

Икмәк һәм җыр, шатлык һәм хәсрәт бергә уртаклашылды. Киленнәр бергә төшерелде, кияүләр бергә каршыланды. Чын интернационализм менә шушы иде.

Бүгенге башкорт сәнгатен һәм Башкортстан экономикасын татар этносыннан башка күз алдына китереп карагыз. Бу бит ниндидер халыкны кимсетүдән, йә булмаса аны кысудан әителми. Бу бит тарих, күз алдындагы чынбарлык. Татар халкы тугандаш башкорт халкын, үзе шундый искиткеч авыр шартларда торып калуына карамастан, бүген дә ярдәменнән ташламыи, ихтирам итә, чөнки ул аларны талаштырырга теләгән көчләренең нисбәтен һәм кайда ятканлыгын яхшы аңлый! Бер кардәш халыкның интеллигенциясе тарихи борылышларда аны кабул иткән икенче бер халыкка — яктыга омтылган башкортларга туры мәгънәсендә беренче хезмәт каһарманнарын, беренче шагыйрьләрен, беренче артистларын, беренче композиторларын бүләк итте. Кем әйтмешли, һич тә үзеннән артканга түгел. Үз милли сәнгатеңне күтәрүдә хәлиткеч роль уйнаган икенче бер милләт вәкилен, дистә еллар үткәч, ниндидер «татар экспедициясе»ндә гаепләү тарихи чынбарлыкка туры киләме? Тар бер даирәнең бу карашы — бик тиз сүтелә торган уйдырма, ясалма фикерләү сөреше.

Егерменче еллар уртасында беренче башкорт әлифбасы барлыкка китерелеп, утызынчы еллар урталарында башкорт телендә китап басу җайга салына башлады. Аңарчы башкорт хезмәт иярәрендә китап теле булып хезмәт иткән татар телен һәм халкын нинди гөнаһлар өчен гаепләргә мөмкин? Әлифба төзү комиссиясе эшендә, татарлардан тыш, башкорт зыялылары да катнашты. Атаклы татар шагыйре Сәгыйть Рәмиев комиссиянең җаваплы сәркәтибе иде. Башкорт әлифбасының аталарыннан берсе булган әдип Уфа җирендә вафат булды. Без бүген шәһәрнең Октябрь революциясе урамында урнашкан ике катлы йортка киләбез. Анда башкорт телендә исталекле таштакта: «Бу йортта 1920 — 26 елларда күренекле шагыйрь Сәгыйть Рәмиев яшәде».— ди. Бик хуш. Әмма сорау туа: Тукай йолдызлыгының иң якты шәхесе булган татар шагыйренең исталеген татарча язып мәңгеләштерү ярамас идеме? Тыелган мәллә татар теле Уфада? Аннан, «күренекле шагыйрь»нең милләте кем? Нигә әле без аны белмәскә тиеш? Егерменче еллар уртасында беренче башкорт әлифбасы барлыкка китерелеп, ул әлифбаны тудырган татар мәгърифәтчеләре, язучылары һәм галимнәре үзләре үк башкорт кантоннарына барып, укытуны башкортчага җайга сала башлады. Шушы әчкерсез ярдәме өчен, кардәш татар халкы башкортларның ихлас ихтирамын казанды — бу тарих битләрендә һәм документлар җыентыкларында мәңгегә теркәлеп калган.

Республикалар арасында мәдәни кыйммәтләр — китаплар һәм вакытлы матбугат алмашу ирекле барды. Башкортстанда телләр тормышында сәламәт рух өстенлек итү һәр милләтнең рухи үсеше өчен тигез мөмкинлекләр ачты: әйтик, республикабызда туып-үскән татар егете яки кызы, туган телендә белем алып, туган җиренә төпләнсә, татар культурасына да, башкорт культурасына да хезмәт итә ала, соңгы очракта бу башкорт сәнгатен алга җибәрүгә яңа мөмкинлекләр өсти иде. Мондый хәл бер кемне дә таң калдырмый иде. Әмма шушы рәвештәге ирекле үсеш суслолварның идеологик аппаратына тынгы бирмәде, көн килде дә бу үсеш аның ярдәмендә өзелүгә дучар ителде... Татар мәктәпләрен бетерү республика җәмәгатьчелегенә нәрсә бирде соң? Күз яше һәм нәфрәт.

Бүген исә татар телендә сөйләшкән миллион ярым диярлек халык балаларының нибары ун проценты гына үз телен-әдәбиятын өйрәнә. Бу — нибары егерме мең укучы дигән сүз. Йөз илле мең мәктәп яшендәге баладан — егерме мең... Коточкыч хәл бит бу. Эшләр шушы дәрәҗәгә җиткәч, Башкортстан мәктәпләре яңа Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Нәҗар Нәҗми, Фатыйх Кәрим һәм Константин Ивановларны бирә алырмы икән? Һич тә хәлләреннән килмәс. Аннан, аклану һәм үз-үзебезне яклау өчен тапкан сылтавыбыз да гаҗәеп «демократик» бит: имеш, туган телендә укытырга «ата-ана үзе теләми». Ә менә, нишләптер, башка телдә укытырга ул «атлыгып тора». Кайсы цивилизациядә, кайсы илдә ата-ананың үз теләге белән үз теленнән ваз кичкәнен күргәнегез бар? Бу кадәр «үсешкә» тик безнең җәмгыять, бары тик безнең ата-ана гына барып җитте. Кайчан коткарырбыз әле без аны бу кадәр алданудан һәм караңгылыктан?

5

Без озак еллар буе шәхестәге табигый интернациональ сыйфатларны алардагы милли сыйфатлардан аерып, хәтта бер-берсенә каршы куеп килдек. Югыйсә, милли сыйфатлар — ул бит шәхеснең яшәү үзенчәлеге. Милли сыйфатлардан мәхрүм кеше, гомумән, булмый, әгәр була икән, ул инде — һичшиксез, космополит, үз халкына хас йолалардан, гореф-гадәтләрдән, телдән, мәдәнияттән һәм милли әдәптән йөз чөерүче, ягъни гармоник тәрбия алмаган бәндә. Ләкин шуңа да карамастан, без андыйларны «интернациональ рухлы» булганы өчен, милли тамырларыннан аерылмаган кешеләрдән өстен санап, үрнәк итеп мактап, җитәкчеләрнең идеаль тибы итеп үстерә

килдек. Нигезендә халыкларны тизрәк кушу, ассимиляцияләштерү яткан бу теориянең нәтиҗәсе озак көттермәде. Республикабыз җитәкчеләре белән килеп чыккан күңелсез күренешләр нәкъ менә шуның трагик җимешләре иде. Башкортстан шартларында мондый «кысыр» интернационализм, башка тискәре нәрсәләр һәм безнең җирлегебезгә хас тискәре идеяләр белән тыгыз бәйләнеп, социаль һәм милли мөнәсәбәтләрне агулаган кичәге «вәлидовчылык»ның эзлекле дәвамы — «шакировчылык»ның чәчәк атуына булышты. Ләкин «шакировчылык» күренеше үз идеясе белән «вәлидовчылык»тан күпкә әхлаксызрак, идеясезрәк булып чыкты. Ул диалектик үсеш боҗрасының тупас кабатланышы, чөнки аның идеясе мәдәни төшенчәләрдән читтә торып, тар даирә, мафия мәнфәгатьләренә генә барып тоташа. Менә ни өчен Башкортстанда күпчелек халыкларның туган телләре, милли мәктәпләре генә түгел, культуралары да әзәрлекләнүгә дучар ителде.

Нәрсә, башкорт халкының тормышында барсы да ал да гөлме? Аның хәле шулай ук башка халыкларныкы кебек авыр түгелмени? Аның үзенә генә хас күңел таләпләре, тетрәнүләре юкмы? Бар. Башкорт халкы юридик яктан яклауга мохтаҗ. Аны аңлый идеме Шакиров? Аңлый иде. Эшли ала идеме башкорт халкы өчен изгелекләр? Эшли ала иде. Нигә эшләмәде? Милләтчелектә гаепләрләр, дип курыкты. Ә нигә ул чакта аны татар белән чәкәләштереп, үзе дә сизмәстән милләтче исеме алды? Чөнки ул кайберәүләргә республиканың «төп» халкын татар халкы исәбенә үстереп ярарга тырышты. Бу аңа өстән, югарыдан аңлатуларынча, интернационализм балкышы булып күренде. Башкорт һәм татар халыкларының мондый хәлдә калуы бер дә очраклы хәл түгел иде. Иманым камил: Башкортстан татарларына карата үткәрелгән рухи геноцид төрки-татар халкына карата бөтен җир шары, барлык илебез, регионыбыз, төбәгебез буйлап үткәрелгән кысымның бер өлеше генә иде. Менә шул кысымны үткәрергә мәҗбүр булган «интернационалист» Шакиров, югары партия-совет иерархиясе тарафыннан үзенең нинди көлке хәлгә куелганлыгын аңлау хәлатенә җитмәгән зат, бу сәясәтнең үзе теләп эшкә җигелгән ирекле һәм корбаны булды.

Башкортстан. Аның башкаласы Уфа. Үзендә генә дә дүрт йөз меңләп татар яши. Тирә-ягында тагын да — бер миллионлап татар. Янәшәдә генә Татарстан. Казан. Әмма Казан радиосы тавышы ишетелми. Уфаның үзендә бер генә татар балалар бакчасы, бер генә татар мәктәбе дә юк. Аларны ябуы җиңел булса да, ачуы бик җиңелдән түгел икән. Татар мәдәният учакларын ачтырмау өчен монда биек гөмбәзле департаментлар эшли. Дөрес акыл белән уйланганда, ат кебек тырыш халкыбыз яхшы ял итеп, тагын да тырышыбрак эшләсен өчен, бу департаментлар, әлбәттә, мәдәният учакларын ачарга тиешләр. Алар исә хәзергә бар тырышлыкларын нәкъ менә «һич кенә дә ачмас өчен»гә багышлый. Нишлисең, могҗизалар илендә яшибез...

Дөрес, Башкортстанның сәламәт көчләре ике кардәш халык — татарлар һәм башкортлар арасында татулыкны саклау, дуслыкны үстерү өчен кулыннан килгәнне эшләргә тырыша. 1988-1989 елларда әдәбият-сәнгать атналыкларын алмашу, милли театрларыбызның алмаш гастрольләрен уздыру, азмы-күпме китаплар тәрҗемә итешеп бастыру шуңа мисал булып тора. Саф күңелле, татар белән башкорт кардәшлегенә күләгә төшүгә ихлас борчыла торган кешеләр дә аз түгел.

Шул ук вакытта тантаналы дуслык бәйрәмнәре шау-шуы астында астыртын гына «башкортлаштыру» эшен дәвам итәргә маташучылар да җитәрлек. Менә шуңа күрә туган төбәгемдә әле дә мине бары тик борчу, бары тик җәрәхәт көтә. Әмма берни эшләп булмый — туган җир ул туган җир инде. Бары шушында гына катлаулы мәсьәләләрне уртага салып, түгәрәк өстәл артында тугандаш халыкларның бәхетле килячәге хакына, һәммәсен гадел хәл кылырга мөмкин.

Республикабызда татар телендә сөйләшүчеләр, әйткәнемчә, миллион ярым тәшкил итсә дә, соңгы утыз ел эчендә халыкның профессиональ әдәбияты да, сәнгате дә үстерелмәде. Татарстандагы татар халкы КамАЗлар төзеп, республикага читтән ярты миллион кеше китертеп, этник сыекланугa дучар ителсә, Башкортстандагы татар халкы үз интеллигенциясе үстерелмәү юлы белән рухи таркатылды. Уртак фаҗига түгелмени бу? Башкортстан язучылар союзында татар секциясен, филармониядә татар бригадаларын булдыру, китап нәшриятыбызда татар телендә китаплар чыгару ни өчен һаман юлга салынмый? Халкыбыз өчен, илебездәге яңа законнарга нигезләнеп, берничә татар профессиональ театры ачып җибәрергә мөмкинлегебез һәм хакыбыз бар. Без исә булганнарын ябып бетердек. Башкортстан халкының өчтән берен тәшкил иткән, милли табышның өчтән берен җитештергән массаның иң гадәти, бик тыйнак ихтыяҗларын канәгатьләндерүне кем кайгыртырга тиеш соң? Аның хезмәт җимешләрен файдаланудан бер дә тартынмыйбыз лабаса! Оят бит, оят: республиканың сәяси нигезен өч зур халыкның дуслыгы тәшкил итә, ә көндәлектә менә ничек килеп чыга: биш башкорт дәүләт театры, биш рус дәүләт театры эшләп килә, әмма беренче татар театрын оештыруга каршылык күрсәтү үзләрен бик нык интернационалист сана-

ган рус һәм башкорт интеллигенциясе вәкилләрен һич кенә дә борчымый. Шушымы тугандаш халыклар теләктәшлеге?! Күптән түгел Уфада Яшь тамашачылар театры ачылды. Һаман да шул ук әкәмәт: башкорт труппасы бар, рус труппасы бар, ә менә татар труппасы юк, аны ачу өчен «акча кирәк» икән. Уфада Яшь тамашачылар театры ачу шен татар милли хәрәк те кузгатып җибәргән иде бит, барлык газеталарда аның мөрәҗәгате дә басылып чыкты.

Күп тә үтмәс, Башкортстанда дәүләт телләре статусы кабул ителер. Республикабызның үзенчәлеге, аның өч төп һәм зур халык федерациясе икәнлеге исәпкә алыныр дип ышанабыз. Әгәр исәпкә алынмаса, тагын да демагогия һәм күз буяулар артына яшеренеп, барлык халыкларга бары тик бер тел генә көчләп тагылса, бу хәл өстәмә киеренкелек тудырачак һәм республикада иҗтимагый-сәяси тормыш шартлары тагын да катлауланачак. Безнең карашка, бу җәһәттән бер генә дөрес юл бар. Ул — Башкортстанның көньяк-көнчыгыш районнарында дәүләт теле итеп башкорт телен, төньяк-көнбатыш районнарында дәүләт теле итеп татар телен, ә барлык республикада милләтара аралашу теле итеп рус телен игълан итү. Бүтәнчә альтернатива күренми. Һәр халыкның үз телен өйрәнүе хәлиткеч шарт булып торырга, башка халык вәкилләре урындагы дәүләт телләрен тәшкил иткән башкорт һәм татар телләрен мәктәптә һәм югары уку йортларында өйрәнергә тиеш. Закон бу хакта сүз сөйләүгә генә кайтып калмас, дип өмет итик.

Тел өлкәсендә бернинди өстенлекләргә, чикләүләргә дә юл куярга ярамый. Әгәр бу принциплар бозыла икән, йөрәгендә ватандарлык, халыкара туганлык, дуслык хисләре булган һәр адәм баласы гаделлек өчен көрәшкә күтәреләчәк. Барлык көчен, барлык акылын һәм белемен туплап! Чөнки туган җирне ярату — ул әллә нигә бер тапкыр үз туган телендә «кәнсирт» карау-тыңлау гына түгел. Ул бөтен җирне ярату, туган халкыңны сөю — җирдәге барлык халыкларны да хөрмәтли белү, туган телеңне кадерләү — җирдәге бөтен телләрне кадерләү ул. Табигатьнең бөтенлеге, кешенең матурлыгы, камиллеге шулардан башка мөмкин түгел. Бүгенге көн бездән гадел һәм акыллы адымнар көтә...

*Уфа. 1990.*

## *Котлыйбыз*

# Энгель Нигъмәтуллинга 60 яшь

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Энгель Галимҗан улы Нигъмәтуллин 1930 елның 6 ноябрендә Казан шәһәрендә күренекле тәнкыйтьче Галимҗан Нигъмәти гаиләсендә туган. 1948 елда урта мәктәпне тәмамлагач, ул Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый. Аннары Алтай крае, Новосибирск һәм Казан мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1972 елдан филология фәннәре кандидаты. 1977 елда университетның рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасында доцент итеп раслана.

Энгель Нигъмәтуллин, нигездә, Октябрьгә кадәрле һәм Октябрьдан соңгы татар әдәбиятында милли һәм интернациональ бәйләнешларны өйрәнә. Көнбатыш әдәбияты даһиларыннан Руссо, Гете, Шекспир кебек әдипләр иҗатындагы әдәби-эстетик карашларның татар язучыларына тәэсирен тикшереп, ул рус телендә «Раздвигая века и границы» дигән монография бастырды.

1968 елда читтән торып Мәскәү чит телләр институтын да тәмамлый. Әдәбият галиме булу өстенә, Э. Нигъмәтуллин бүгенге әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә актив эшләп килә.

*Татарстан Язучылар союзы һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлый, аңа ныклы сәламәтлек һәм иҗат уңышлары тели.*

## Җәмит Рәхимов

# АКЛАНМАГАН ӨМЕТ

Бу хәлләргә инде ярты гасыр вакыт үтеп китте. Сугыш башланыр алдыннан гына Шөгергә әллә нинди ят кешеләр килеп төшкән иде. Аларның машиналары, тау-тау тимер-томырлары безнеңише малай-шалайларны гына түгел, олыларны да шаккатырды. Утын ягып эшли торган тракторлары, иләмсез зур һәм юлда гел ватылып, туктап ята торган автомашиналары, аларыннан да искитмәлесе — тимерне эретеп ябыштыра һәм без — «тишек борыннарны» сукырайта торган җайланмалары һәм тагы әллә ниткән әкәмәтләре бар иде аларның. «Нефтеразведчиклар» дигән бу кешеләргә өлкәннәрнең дә исе китүен әйт әле син! Аларның күбесе бит инде автомобиль генә түгел, чын паровоз күргән, кайберәүләре исә «кәҗә тракторы»нда, хәтта НАТИда, «Коммунар» комбайннарында эшләп тә караган. Алай да хәйран калды бит авыл халкы. Кич җитеп, ир-ат халкы берәрсенең капка төбендәге бүрәнәләр өстенә җыелдымы — телләрендә бер генә сүз: «Нефть чыкса-а!»,— дип, авыз суларын корыталар.

Нефть эзләүчеләрнең килүенә ай да үтмәде, Яңа Шөгер артындагы ямь-яшел чирәмлек тапталып-изелеп бетте. МТС тавындагы хәтфәдәй матур урынны вәйран иттеләр. Авылны һәрьяклап чолгап алган чишмәләрнең берәрсе янына суга дип килсәләр, артларыннан бөтен тирә-юньгә керосин исе, мазут тәме сеңеп кала. Төтенгә уралып йөри торган тракторлары исә авылның бөтен урамнарын изеп ташлады. Өлкәннәр исә һаман шуларны сөйләпме сөйлиләр. Тапканнар кызыгып нәрсә!

Юк, бернигә дә кызыкмаганнар икән агайлар, алар бары өметләнгәннәр. Тын бер татар авылына куәтле промышленность предприятиесе килеп урнашу безнең гел берөрле дәвам итеп яткан ярлы тормышны үзгәртеп җибәрер, моңа кадәр колакка чалынып-чалынып киткән электр, газ, пар, тигез юллар авылга да килеп җитәр, нефтьчеләр көнебезне яктыртыр, дип өметләнгәннәр икән алар.

Һәм, әйтергә кирәк, бу өмет бер дә нигезсез булмаган. Шөгер авылы тарихы өчен мондый хәлләр яңалык түгел һәм аларның элеккеләре халык өчен файдасыз калмаган. Әйтик, әле 1870 елда ук монда Америка промышленнигы Шандор килеп чыккан. Бу якларда гомер бакый саркып яткан дегет базлары исен иснәнеп, ул нефть коелары тишәргә һәм ансат кына баерга ниятләгән. Нинди дә булса производство ачып җибәрү өчен, беренче чиратта, әлбәттә, җир кирәк. Авыл крестьяннары җәмгыяте белән ул азгын кәҗәләр йөрүдән башкага ярамаган текә тау битләре хакында сүз алып барган һәм аны 20 елга арендалауга ирешкән. Ләкин бушка түгел, шушы ташландык җир өчен дә ул авыл халкының имана ясагын түләп торган.

Моннан 120 ел элек, Шөгергә килеп кагылган промышленность шаукымы, ул җәелеп киткән тәкъдирдә, халыкка тагын ниләр биргән булыр иде икән — әйтүе кыен. Шандор нефть эзләүдә уңышсызлыкка очрый һәм бөлә. Әмма борынгы дегет базлары булган шөгерлеләр әлеге Шандордан соң «Жандур тавы» дип аталып калган тауның игелеген тагы бер тапкыр күрә язып калалар әле. 1913 елда бирегә «Казан ОЙЛ филде лимитед» («Казан нефть кыры») акционерлар компаниясе вәкилләре килеп чыга һәм авыл крестьяннары белән әлеге дә баягы «Жандур тавын» арендага алу хакында сүз кузгала. Акционерлар килешүгә ирешә алганнармы-юкмы, ул хәтлесен белмим, кулымда бернинди документ та юк. Мәгәр әле 70 елларда Галәлетдин бабай Насретдинов: «Тау өчен англичаннар йөз ел дәвамында безнең крестьяннар җәмгыятенең салымын түләп торырга булдылар»,— дип сөйли торган иде. Әгәр дә 1914 елгы Бөтендөнья сугышы башланып китмәсә, сүз дә юк, шөгерлеләр «Жандур тавы»ның игелеген гасыр буе күрәселәр икән.

Шөгергә нефтьче-разведчиклар килеп төшкәннән бирле, авылда: «Шандор», «Англичаннар»,— дигән сүзләрнең бик еш кабатлануы да өметнең яңаруын аңлаткан икән. Дөрес, болары Шандор яисә англичаннар кебек киңәшеп, җирне сорап тормадылар торуын, килеп төштеләр дә дөбер-шатыр вата-җимерә башладылар. Әмма җир бит инде ул авыл халкыныкы: алганнар икән, ни белән булса да бәхилләтәчәкләр, димәк.

Тора-бара әлеге өмет дигән нәрсә картлардан-яшьләргә, бала-чагаларга да күчте, авыл халкы бер ышаныч белән яши башлады. Хәер, болай гына дип әйтү һич дөрес булмас; әлеге өмет шаукымы акрынлап бөтен районга, аннан инде бөтен Бөгелмә төбәгенә, хәтта бөтен Татарстанга таралды һәм без барыбыз да озак еллар буе әнә шул чыкмаган кояшка кызынып яшәдек.

Нефтьчеләрнең «күк капусы» ачылачагын ач-ялангач балалардан да ныграк өметләнеп көтүчеләр булмагандыр. Өметсез — шайтан, дигәннәре хак икән. Ниһаять, ул көн килде һәм без аларның игелеген күрә башладык. Минем шәхсән үзем өчен ул игелек әвәл «күктән төште». Нефтеразведка конторасы янында уйнап йөргәндә, нигез буеннан кызыл сызыклар белән бүлгәләнгән һәм һәр шакмакка айның көннәре сугылган кәгазь кисәге табып алдым. Баксаң, нефтьчеләр ашханәсенә кереп ашау хокукы

бирә торган карточка икән. Тик әле анысы белән дә бушка бирмиләр, акча кирәк. Анысы ничек җайлангандыр — хәтерләмим, әмма беренче тапкыр ашханә дигән кысырык өйгә кереп казанның кәбестә шулпасын чөмерүем гомергә истә калган.

Янә дә килеп авылдан алты чакрымдагы Зеленая Роща дигән «социалистик шәһәрчек»тә (ул — Шөгердән дә кайтышрак бер поселок) азык-төлек кибете ачылды. 1947 елда, карточка системасы бетерелгәч, бөтен тирә-як авылларының малайлары һәркөн таң кан торып, нефтьчеләр поселогына ипигә йөгерәбез. Әниләр акча юнәтә алсалар, калганы инде безгә чүп тә түгел. Алты чакрымны тәпиләп барасың да, көн буе чиратта торасың. Нефтьчеләрдән арткан тәкъдирдә, безгә дә ипи эләккәли. Кайчак хәтта шикәр, макарон ише ризыклар да кулга төшә. Көнозын чиратта торып, буш кайткан чаклар да була. Алай да, акмаса да, тама. Кыскасы, рәхәтләнде авыл халкы нефтьчеләрнең бу игелегенә!

Мәгәр монысы баласы гына булган икән. 1943 елның җәендә безнең Шөгердә, Татарстанда беренче, промышленность нефте табылды. Мин ул көнне яхшы хәтерлим. Нефтьчеләр зурлап бәйрәм ясадылар. Алар иртәдән, машиналарга төялеп, Каравыл тавындагы урманга киттеләр. Анда ниләр булгандыр. Әмма кичен авыл тарихында беренче тапкыр, урамнарда исерек хатын-кызлар күренде. Ул чакта бу хәл авыл өчен бер табышмак-кәмит булса, еллар үткән саен, төбәктә исерек хатын-кызларның (ирләрне әйтәсе дә юк) күбәюе халкыбызның фаҗигасына әверелде. Инде сүз әхлак турында бара икән, тагы бер нәрсәне әйтеп узмый булмый. Нефтьчеләр килгәнче, безнең авыл халкы йозак дигән нәрсәне белми иде. Берәү кая да булса китә икән, ишеген таяк белән терәтеп куя да — вәссәлам. Беренче йозак безгә шул нефтьчеләр белән бергә килде бугай.

Хәер, ул чакта боларны кем уйлаган?! Авыл кешеләренең башында бүтән уй иде: үзебездә нефть чыккан икән, димәк, ул җирле халыкка да файда китерергә тиеш. Һәм, күп тә үтмәде, җир маеның игелеген күрә башлады тирә-як кешеләре. Әй рәхәтләндек соң «уф алла» арбаларының күчәрләрен майлап!

Алай да, нәфсе дигәнең хәтәр нәрсә бит ул — аз-маз тамдымы — аңа тагы да күбрәк кирәк. Авыл халкы да нефтьтән һәм нефтьчеләрдән күбрәген өмет итте: вакытлыча булса да, трактор бирмәсләрме, яңа алачыкны салырга булышмасларммы?! Клуб та ишелергә тора, район культура йорты да дуңгыз фермасы кебек, райондагы бердәнбер татар урта мәктәбе дә иске-москыдан корашрылган. Сугыш туктауга, бөтен районның дүрт-биш ел буе укый алмый яткан бала-чагасы Шөгерне басып алды. Нефтьчеләрнең үзләренең бала-чагалары бар — аларга да укырга кирәк. Укулар көндезләрен генә түгел, төннәрен дә бара. Электры булса, бер хәл иде...

Һай, саный китсәң, халыкның өмет иткәне күп инде ул: район китапханәсенә бина юк, китаплар битум заводының бәләкәй генә бер бинасына тутырылган; больница исә — әле утызынчы елларда ук шомартылмаган ташлардан салынган гараж сыман йортта. Дәүләт банкы һәм почта да шул ук хәлдә. Барыннан битәр, район үзәгендә эчәргә су юк... Халык көтте. Авылда нефть хәтле нефть табылгач, шул иске-москы биналар урынына яңалары салыныр дип өметләнде. Әмма барысы да искечә кала бирде.

Чү, тагы бер өмет чаткысы ялтырап алды — 1950 елда район үзәгенә эшчеләр поселогы статусы бирелде. Хәзер ул нефтьчеләр поселогы. Димәк!.. Аһ, өметләр яңа акланмады. Яңа сайланган поселок Советы җитәкчеләре җил-яңгырдан ышыкланырлык бер агач бина укмаштырып керделәр дә, шуның белән эш тәмамланды.

Инде авыл халкы гына түгел, район башлыклары да нефтьчеләргә өметләнүнең һавадагы торна икәненә инандылар. Район культура-көнкүреш биналарын үз көче белән әмәлли башлады. Башта әйбәт итеп агачтан буратып дәүләт банкы (анда нефтьчеләрнең миллионнары ачыла) һәм китапханә бинасы салынды. Башкалар белән рәткә Шөгер нефтьчеләре дә җылы, якты бүлмәләрдә китап уку бәхетенә ирештеләр. Сүз уңаенда шунысын да әйтик поселоктагы китапханә әле бүген дә шул агач бинада халыкка җай гына хезмәт итә.

Беренчеләре артыннан поселокта яңа биналарның башкалары күтәрелде. Район пайчылары, тиенләп җыйган акчаларына, тау ташыннан (ярый әле, бу якларда анысы бар!) ашханә салырга тотындылар. Аның каравы, район халкы гына түгел, нефтьчеләр дә рәхәтләнделәр соң кайнар аш ашап! Аннан колхозчылар, күмәкләшеп, ермагын кулдан казып, поселокка чишмә суы китерделәр. Анысы нефть объектларына, шул исәптән Шөгер нефть-битум заводы поселогына да бирелде. Һәм әлеге чишмә, нефтьчеләр аны харап иткәнче, поселок халкына бик яхшы хезмәт итте.

Тора-бара Шөгердә яңа мәктәпләр дә, больница да салынды. Болары, нефть чыга башлаганга, утыз биш-кырык ел үткәч пәйда булды. Һәм алар колхозларның, җирле Советларның барлы юклы акчаларына төзелде. Больница исә әле өченче ел гына сафка басты.

Болары, күрдегез, нефтьчеләр ярдәменнән башка эшләнде. Район кешеләренең, шулай ук бөтен төбәк халкының иң зур өмете — юллар һәм газ иде. Беренче чиратта юллар кирәк. Юл бит ул — кешеләрне олы дөнья белән бәйләүче иң кирәкле чара. Шөгер — иң якын тимер юл станциясе булган Бөгелмәдән алтмыш чакрым ераклыкта. Ә юл дигәнең юк. Дөрес, Шөгер халкы үзе әле утызынчы елларда ук, көрәкләр һәм кул арбасы белән, элеккеге Яңа Писмән районы чигенә кадәр шоссе юлы салган иде. Ә менә күршеләр — Яңа Писмәнлеләр кыймылдамадылар. Менә шуңа да төбәк халкының бөтен өмете — моннан утыз чакрымдагы Келәүле станциясендә. Шунысы алама, ул тарафка юл дигәнең бөтенләй юк. Колхозчылар шул ук дәртле утызынчы елларда

Келәүлегә дә юл сузып маташтылар. Тик монысы да ахырына җитмәде. Хикмәт шунда ки, юлның нибары алты-җиде чакрымы гына безнең районга туры килә, калганы Куйбышев өлкәсенә карый. Анда яшәүчеләргә исә юл кирәкми, бездә йомышлары юк диярлек, станция — үзләрендә.

Әй, җәфаланды, әй җыкланды халык шул юлсызлыктан. Бит районга кайтасы товарлар башлап шул Келәүле станциясенә килеп төшә, дәүләткә тапшырыласы ашлык та шул ук станциягә ташыла. Бу каһәрле арада күпме камыт баулары өзелгәндер дә, күпме тәгәрмәчләр изелгәндер?! Юлда үлеп калган атлар, адашкан, өшеп үлгән кешеләр...

Кыскасы, халыкның бөтен өмете нефтьчеләрдә иде. Салсалар, алар салачаклар юлны. Үзләренә кирәкле тимер-томырны, азык-төлекне һәм башка нәрсәләрне дә шул станциядән ташыйлар лабаса! Хак, алар атлар белән чиләнми, вагына-тәягенә трактор куа. Күр дә тор, машиналар белән ташуга күчәрләр. Аның өчен исә юл кирәк.

Шулай дип фараз кылды, шулай дип өметләнде халык. Нефтьчеләр исә төчкермәделәр дә, ичмасам, колхозчылар көрәк-тачка белән салган юлларны да изеп-сытып бетерделәр дә, арырак, нефть күленең тирәнрәк җиренә күченделәр. Дөрес, Шөгердә нефть чыгару беркайчан да туктамады, тик шунысы гыйбрәтле: бу якларда калганнар хакында еллар буе уйлап караучы да булмады.

Ярый, калганы инде калган, алар авыллардагы юлсызлыкка, хәерчелеккә күнегеп беткән. Нефть шаукымы белән Лениногорск, Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә якларына чыгып киткәннәр дә күп бит. Берзаман шулар туган-үскән нигезләренә кайтып йөри башладылар. 1959 елда, уйламаганда-нитмәгәндә, район үзәген Лениногорскига күчереп куйдылар — Казаннан килеп-китеп йөрүче түрәләргә ара якына төште. Тик күп кенә авыллар район үзәгеннән 100—120 чакрымда калды. Монысына кемнең исе киткән?! Килмәсләр, йөрмәсләр, юк йомышны бар итеп. Әмма нефтьтә һәм район учреждениеләрендә эшләүчеләрнең күбесенең гаиләсе, ата-анасы авылларда торып калды — кайтмый чараң юк. Юл гына начар — «вездеход»лар да көч-хәл белән уза моннан. Халык исә йөри: йөк машинасына утырып та, үзбушаткычларга төяләп тә, трактор арба-чаналарына асылынып та. Әлеге каһәрле юлда батып ятуларның, туңу-күшегүләрнең, эт булып машина этүләрнең бәласен үзе газапланганнар гына белә.

Дөнья алга барган саен, юлларда автобуслар артты. Әмма юл булмау сәбәпле, Шөгер якларына йөрмәделәр алар. Халык бик нык йөдәткәч, маршрутларга йөк таксилары чыкты. Шул ук йөк машинасы инде ул, тик өсте генә беркәүле дә, әрҗәсенең ике ягына ике эскәмия беркетелгән. Үзе тәбәнәк, үзе караңгы. Урын ун-унбиш кешегә генә тия, калганнар, бөкрәйгән хәлдә, басып кайта. Утыз-кырык чакрым җирне шул рәвешле үткәннән соң, кешеләрнең күбесе тәмам хәлсезләнә, аларны машинадан күтәреп төшерәләр иде.

Шөгер юлларындагы бу газап чирек гасыр чамасы дәвам итте. Сиксәненче еллар башы иде бугай. Тирә-юньгә элекке Шөгер районы колхозларындагы культуралы көтүлекләр буенча Бөтенсоюз семинары булачак икән дигән хәбәр таралды. Семинарга ай-ай ярым вакыт калды дигәндә, әллә каян гына акча да, юл төзүчеләр дә табылды — Шөгергә кадәр асфальт юл салып куйдылар. «Нефтьчеләр тотынса, булдыра инде алар»,— дияр кайберәүләр. Юк шул, әлеге юл колхозчыларның муеннары бурычка батып юнәткән акчалары исәбенә салынды. Хәзер аны карап-төзәтеп торучылар да шул ук колхозлар һәм район оешмалары. Нефтьчеләр исә бинниһая зур машиналары белән аны изеп-таптап, авыз ерып йөри бирә.

Инде сүз бу хакта бара икән, тагы бер нәрсәне әйтми калдыру гөнаһ булыр. Шөгердән алты чакрым ераклыкта гына атаклы Бәкер курорты бар. Бу шифаханәгә култык таяклары белән килгән авырулар таякларын ташлап, савыгып кайтып китәләр. Курортның алтмыш елга якын эшләү дәверендә кемнәр генә дәваланмаган монда! Шул исәптән нефтьчеләр дә. Илленче-алтмышынчы елларда чабатадан кар сулары ерып скважиналар бораулаган, җир мае чыгарып йөргән кешеләр ревматизмлы аякларын, радикулитлы билләрен нәкъ менә шушы курортта дәвалыйлар. Нефтьчеләрдән ел саен йөзләрчә кеше сихәтләнә монда. Шунысы аяныч, соңгы елларга хәтле әлеге данлыклы шифаханәгә юл булмады. Дәваланырга дип ерак-ераклардан килүчеләр юлларда батып ятты, тездән саз ерып машиналар этте, туңып-күшегеп интекте. Алар арасында «Татнефть» берләшмәсен, СССР нефть чыгару министрлыгын эттән алып эткә салучы нефтьчеләр бик күп иде. Әмма аларның ачулы авазлары «Татнефть» берләшмәсенең түбәсе болытларга тигән бинасына барып җитмәде, Мәскәүдә исә бу хакта уйлап караучы да булмады. Аптырагач, халык депутатларының Лениногорск район Советы, барлы-юклы бюджетыннан акча тотып, Бәкергә хәтле асфальт юл салдырды.

Шулай да әйтергә кирәк: нефтьчеләр Әлмәт, Азнакай, Лениногорск якларында яхшы юллар булдырды. Хәтта тәүлегенә нибары бер кеше эшкә килеп-китә торган су кудыру станцияләренә кадәр дә юл суздылар. Хәзер исә бу станцияләрнең барысы да диярлек автоматлар ярдәмендә эшли, аларга атналар буе килүче-китүче юк. Мәгәр юлларын карап-көйләп кенә торалар. Әйе, производство өчен кирәк булганда акчаны кызганмый «Татнефть» идарәсе. Ә менә турыдан-туры үзенә хаҗәте булмаганда...

Нефть мәйданнарының нәкъ уртасында Зәй-Каратай дигән зур авыл бар. Андагы халыкның 70-75 процент чамасы нефть объектларында эшли. Менә шул авыл кырыеннан әле 1953 елда ук Лениногорскидан Әлмәткә уза торган олы юл салынган иде. Авыл үзе әлеге юлдан, кырый йортларыннан исәпләгәндә, бер чакрымда, үзәгеннән алганда, ике чакрымлап читтә калды. Шул ике чакрымлы арага асфальт «җитмәде». Нефтьчеләр

еллар буе олы юлга кадәр җәяү тәпиләделәр. Ниһаять, сиксәненче елларда мондагы «Уңыш» колхозы, муеннан бурычка батып, авылга кадәр һәм берничә урамга асфальт түшәтте. Шуннан соң гына нефтьчеләрнең вахта автобуслары авыл үзәгенә кадәр йөри башлады.

Бу һич кенә дә очраклы мисал түгел. Калаларга, нефть промыселларына бара торган олы юллар буендагы Яңа Чыршылы, Алешкино, Иске Писмән, Юлтимер, Александровка, Восход, Керкәле Тукмагы (Лениногорский районы), Суркино, Тайсуган, Югары Мактама, Мәмәт, Чупай (Әлмәт районы) һәм башка дистәләрчә авыллар да нәкъ шундый хәл кичерде, бик күбесе исә бүген дә юлсызлыктан интегә. Кыскасы, югарыда телгә алынган районнарда салынган меңнәрчә чакрым юллар һич кенә дә халык мәнфәгатен күздә тотып түгел, бәлки тәбәктәге хәзинәне күпләп һәм тизрәк сыгып алу өчен салынды. Авылларның иң зур күпчелеге исә әле һаман да юлсызлыктан изалана.

Халыкның икенче иң зур өмете — газ, дигән идек. Әлеге кыйммәтле чимал ун еллар буе бер файдасызга бәсу түрләрендә, бакча башларында гөрләп янып утырды һәм, әйтергә кирәк, хәзер дә яна. Миңлебай газ эшкәртү заводында тәүлекләр буена һавага сөрем һәм корым атып утыручы факел гына да тулы бер районны утын ягудан коткарырга җитәр иде. Кама аръягы халкының тулы бер буыны исә, әнә шул исрафка сыкрый-сыкрый, инде дөньядан кичеп бара, авылларда әле һаман да газ юк. Ул йөзләрчә авылларның бакча башларына салынган торбалар буенча әллә кайларга китә, Татарстан газына Европа илләре рәхәтләнә, үзебезнең халыкка — юк.

Дөрес, сөйли-зарлана торгач кайбер авылларга бәхетке ирешә. Ләкин ифрат кирәкле бу эш бик озакка сузылды. Лениногорскига терәлеп торган Тимәш авылын гына алыйк. Монда беренче тапкыр девон нефте бәреп чыкты, башка бер яңа исем (Ромашкино) белән ул республикадагы уникаль нефть чыганагы дип аталды. Шунысы да бар, «Татнефть» берләшмәсендә күп еллар буе генераль директор булып торган Ә. К. Мөхәммәтҗанов шушы авылда туып үсте. Авылдашлары аны күп еллар буе төрле Советларга депутат итеп сайладылар, шуңа да авыл халкы Тимәшкә газ кертү мәсьәләсендә, башлап, аңа мөрәҗәгать итте. Әмма шулай башланган эш тә дистәләрчә елларга сузылды, кайбер йортларга әле бүген дә газ кертелмәгән.

Лениногорск районында газдан «авыз итүчеләрнең» икенчесе — Зәй-Каратай. Монда бу эш Тимәштәгедән дә озакка сузылды. Монысы аңлашыла да, чөнки биредә колхоз бер үзе чиләнә.

Былтырлы-быелллы дигәндәй, райондагы Иске Шөгер һәм Керкәле авыллары да газга тиенә язды. Бу хакта мактанып язылган рапортлар газеталарда, авылның ун-унбиш йорты газ алуга ук, басылып чыкты. Әмма эшнең әле дә тәмамланганы юк.

Ярый, алары инде менә бүген, менә иртәгә дигән өметтә яши. Нефть районнарында газның ни икәнен дә белмәгән авыллар йөзләрчә. Бу уңайдан узган кыш РСФСР Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән иптәшләрнең Лениногорск районы сайлаучылары белән очрашулары искә төште. Кандидатлар арасында байтагы нефтьче түрәләр иде. Җыелыштa Бәкердән алып Германиягә кадәр җиңүле сугыш юлы узган, хөрмәтле хезмәт һәм партия ветераны Якуп ага Нигъмәтуллин җан ачысы белән чыгыш ясады:

— Инде кырык ел авылларыбыз астыннан бихисап нефть һәм газ суыртыла,— диде ул, ачынып,— ә без әле һаман утын ягабыз, юлсызлыктан интегәбез. Нефтьчеләргә кыен вакытта без аларга атлар белән ярдәм иттек, сафларына иң яхшы егетләребезне һәм кызларыбызны бирдек. Рәхмәт урынына исә чишмәләребез корыды, тозланды, басуларыбыз пычранып эштән чыкты, урман-әрәмәләр вәйран булды, елгаларыбызда балык түгел, бака да калмады, суларга һава юк. Җитте, аларны сайламыйбыз!..

Районның бөтен авылларыннан җыелган вәкилләр аның сүзен күтәреп алдылар. Бу инде кырык еллык өмет өзелгән дигән сүз иде.

Хәер, өметнең акрынлап кисела баруы электән дә сизелгәләде. Чөнки нефтьчеләр авыл халкының өметен акламадылар гына түгел, үз мәшәкатьләренең байтак өлешен дә җирле кешеләр җилкәсенә аудара тордылар. Әйтик, авылда яшәүче нефтьчеләр өчен өйләр салынмады. Алар йорт-җирне үзләре җитештерүгәләр. Нефть предприятиеләре аларны төзү материаллары белән киңәндерделәр, дип тә әйтеп булмый. Кайсы ялынып-ялварып, кайсы сорамыйча гына электереп, шифер, такта ише нәрсәләр юллаучылар булды булуын. Әмма бу гадәти күренеш түгел иде. Нефтьче йортлары, нигездә, колхозчыларга дигән бүрәнәдән буралды, аларга тиешле материаллардан җиткерелде. Әмма тормыш бер өй белән генә бармый бит әле. Ягулыгы, печәне-саламы һәм башкалары кирәк. Чәй кайнату өчен кайтарыла торган газ баллоннарын гына алыйк. Аларны авыл өчен, нигездә, колхозлар үз машиналарында ташыйлар. Үзләре алып кайткач, әлбәттә инде, башлап колхоз кешеләре тәэмин ителә. Авылда яшәүче нефтьчеләргә тисә, тия, артмаса — бигайбә. Авылда яшәгән кешенең бәрәңге бакчасы бар да бар. Шәһәрләрдә яшәүчеләрнең кымәк участокларын сөрүне профсоюз оешмалары кайгыртып йөри, ә менә авылдагы нефтьче бакча сөрүчене кесәсенә ярты тыгып эзләргә мәҗбүр. Авыл кешесенә мал-туар асрамыйча да ярамый. Мондагы кибетләрдә сөт-катык, каймак, май һәм башка ризыклар юк. Сыерың бар икән — аңа азык кирәк. Анысы исә колхозчыларның үзләренә дә җитешми. Нефтьче терлек азыгын ничек булдыра ала, шулай таба. Кайберсе урманчыга ялына, күпләр ял сәгатьләрендә колхозда эшләргә мәҗбүр. Колхоз эшенә катнашсаң, салам сатып алырга, аз-маз печәнен электергәләп кайтырга мөмкин.

Бер сүз белән әйткәндә, нефть предприятиеләре авылларда яшәүче күпсанлы

эшчеләрнең мәшәкатен колхозлар җилкәсенә салганлыгы гадәти күренешкә әйләнде. Азык-төлек ягы гына түгел, тормышның башка кирәк-ярагы да күп бит әле. Әйтик, клублар, мәктәпләр, медпунктлар, балалар бакчалары. Миллиардлар белән эш йөртүче нефть берләшмәбез авылларда культура-көнкүреш объектларын күпме салды икән?

Әгәр дә бу сорау нефтьче-җитәкчеләргә бирелсә, җавап, әлбәттә, бер: «Ник булмасын?!» — диярләр. Һәм, билгеле, беренче чиратта, Тимәш, Түбән Мактама һәм тагы берничә авылны санап китәчәкләр. Дөрес, кайбер авылларда (эшче поселогына әверелә башлаганнарында) нефтьчеләр салган культура-көнкүреш объектлары бар-барын. Ләкин алар, кагыйдә буларак, нефтьчеләр оешып яши торган төбәктә генә. Шул ук Тимәшне, яисә Түбән Мактаманы алыйк. Мондагы һәйбәт мәктәпкә барып җитү өчен укучылар кимендә өч-дүрт чакрым юл үтәргә тиеш. Фактта бу — күрше авыл мәктәбе. Шуннан инде сорау туа: әлеге авыл өчен файдамы бу, әллә зыянмы?

Фикерем ачыкланып җитсен өчен, тагы бер мисал китерәм. Узган кыш без Карабашка әдәби очрашуга бардык. Сүз татарча барганлыктан, кичәне оештыручылар, очрашу өчен, авыл клубын сайлаганнар. Хан заманыннан калган иске мәчет бинасы, елан кышлагыннан да салкынрак, өскә тун кигән килеш тә калтырата. Билгеле инде, мондый клубка нибары биш-ун кеше килгән иде. Карабаш авылында яшәүчеләр исә тулысы белән диярлек нефтьчеләр. Поселокның «яңа» өлешендә, ватык-җимерек булса да, Культура сарае бар. Әмма буранлы көннәрдә биш-алты чакрымга кем йөрсен?! Төбәктәге Тимәш, Түбән Мактама, Яңа Писмән кебек авылларда да шул ук хәл. Әлеге Карабаш поселогындагы совхозга карый торган Иркен авылында да нефтьчеләр бик күп. Мондагы борынгы клуб исә менә-менә ишелергә тора. Әмма бу хакта «Лениногорскнефть» идарәсендә дә, «Иркеннефть» идарәсендә дә уйлап караганнары юк. Бүтән бик күп авылларда исә нефтьчеләр колхозлар көче белән салынган мәктәп-клублардан файдалана.

Миңа күптән түгел нефтьчеләрнең Куакбаш авылын буеннан-буена җәяү узарга туры килде. Авыл аша асфальт юл салынса да, яңгыр артыннан булганга, урам пычрак. Җитмәсә, бер өзлексез машиналар йөреп тора. Тротуар юк. Өч чакрым ара үткәнче, манма тиргә баттым, әллә ничә тапкыр машина бәреп китә язды. Бу хәл — безнең яклар өчен гадәти күренеш. Әнә шундый шартларда балалар ике-өч чакрым җир үтеп мәктәпкә барырга тиеш. Куакбаш нефть афәтеннән иң нык интеккән авыл. Аның шаулап бәреп торган бихисап чишмәләре хәзер шыр тоз, һавасы күкерт газы белән агуланган. Бу яклардагы Сугышлы, Керкәле, Шөгер, Түбән Чыршылы, Тихоновка кебек дистәләрчә авыллар тротуарлар юклыгыннан иза чигә. Кыскасы, бу якларны аркылыга-буйга йөреп, мин барысы өч авылда гына тротуар сыман нәрсәләр күрдем: Тимәштә, Габдрахманда һәм Түбән Мактамада. Алар да — ташка үлчим.

Тротуарсыз юллар авылларны һәм поселокларны урап үтәргә тиеш иде. Моның чыгымы зуррак. Шул ук исеме теллләрдән төшмәгән Тимәшне алыйк. Бу — республикада башлап асфальтка тиенгән авыл. Аның аша олы юл үтә: төнен дә һәр ике якка машиналар кәрваны агыла. Мондагы тавышка, һавадагы сөремгә халык ничек чыдыйдыр?! 25-30 ел буена әлеге авыл урамында ел саен биш-ун кеше машиналарга таптапып һәлак була. Хәтта кешеләрне үзләре яши торган ишек алларына барып кереп таптату очраклары да бар. Урау юл салырга уйлаучы гына күренми, халык исә әле һаман дәшми.

Республикабызда нефтьнең пионеры булган шул ук Шөгергә кайтыйк әле. Биредә автобус көткән арада ук күкертле газ исеннән баш әйләнә, күңел болгана башлый. Авыл уртасындагы битум заводы зәңгәрләнеп торган газ эченнән томандагы кебек кенә күренә. Өстәвенә авылда һәм поселокта мазут белән эшли торган унлап мич ягыла. Шуларга авыл аша бер генә минутка да тукталмыйча узып торучы машиналар «көч өсти». Урау итү өчен юлны ике чакрымга озайта төшү кирәк, әмма нефтьче агайлар халык иминлеге турында баш ватуны кирәксенми шул. Республиканың бөтен почмакларыннан битумга килүче меңнәрчә машиналарны поселокка һәм авылга кертмичә, Балпы Үлән тавы ягындагы юлдан, ягъни торак йортлардан читтән җибәрергә тулы мөмкинлек бар. Шуннан промыселга бара торган асфальт юл үтә. Ләкин моның өчен бераз арага таш түшәргә кирәк. Миллионнар сугучы завод шуны да эшләргә теләми. Без шушы хакта поселок Советы депутатларына да, халык депутатларының район Советы җитәкчеләренә дә әйтеп карадык — кул гына селтиләр. Халык әлегә дәшми. Сәламәтлек өчен бик зарарлы предприятие буларак, битум заводын авылдан куу мәсьәләсен әллә кайчан куясы бар югыйсә.

Кама аръягындагы бик күп авыллар әнә шундый хәлдә. Лениногорскиның үзендә каланы урап уза торган юл салу хакында утыз ел сөйлибез. Әле аның да төзелеп җитә алганы юк.

Бу җәһәттән шунысы да гыйбрәтле: промыселларда эшләргә тиешле меңнәрчә дизель машиналары, ни сәбәптәндер, калаларда өелеп яталар. Лениногорск, Әлмәт, Бөгелмә кебек шәһәрләрнең зур мәйданын гаражлар биләп тора. Ул агрегатларны промыселлар янына туплау, шәһәрләрдән читкә чыгару кирәк. Санитария-эпидемия станцияләре дә, табигатьне саклау җәмгыятьләре дә бу мәсьәлә хакында бер сүз дә әйтми.

Кыскасы, авыл нефть чыганагына ни кадәр якын булса, алардан зыянны да шул кадәр күрә. Шул ук Карабаш, Шөгер, Тимәш, Габдрахман, Сөләй, Зәй-Каратай һәм башка авыллар сусыз, һавасыз калды, басулары эштән чыкты, урамнары тәмам вәйран ителде. Шулар ук — милли мәдәниятсез, телсез калучы төбәкләр.

Бу хәлләрне халык элегрәк тә күрде, билгеле. Ләкин: «Тукта, файдалары тимәс-

ме!» дигән өмет — барын гафу иттерә килде. Бигрәк тә колхоз, авыл җитәкчеләре ике-өч капчык цемент, яисә иске торбага, предприятие биргәләп-алган бульдозерга алданып, нефтьчеләр китергән коточкыч бәлаләрне күрмәмешкә салынды. Хәзер исә дәшми торудан узды — экологик катастрофа алдына килеп басты. Лениногорск районында гына да дистәләгән авыллар чишмәсез калды. Шөгер, Чүте, Куакбаш кебек йөзләрчә авылларның кырлары-урманнары тапталды, изелде, пычранды, вәйран ителде. Бу яклардагы бихисап тауларның түбәсенә менеп, кайсы гына якка карасаң да, басукырлар, үзән-болыннар тулы тимер-бетон хәрабәләр күренә. Җирне алардан арындырмау — җинаять ләбаса!

Лениногорск районының Керкәле авылы янында Сары Тау бар. Ул, шәһәрләр һәм поселоклар салганда, күпме таш бирде! Таш чыгару әле дә дәвам итә. Бичара тауның тирә-ягында, күз күреме җирдә коточкыч чокырлар, ташландык карьерлар калып бара. Әйтерсең, монда дистәләрчә атом бомбасы берьюлы төшкән дә, тауның күкрәген умырып-умырып ыргыткан. Бу күренеш, инде 1952 елдан бирле, монда яшәүчеләрнең бәгырьләрен сызлата. Ләкин мәсхәрә ителгән җирләрне рәтләү турында уйлаган кеше дә юк. Әлмәт каласы булып күчкән Чупай тавы, меңнәрчә чакрым юллар булып яткан күп кенә башка таш-тауларның хәле дә шул чама. Төбәктә вәхшиләрчә вәйран ителгән табигать турында зур-зур томнар язсаң да, барын әйтеп бетерү мөмкин түгел.

Автор кара күзлек киеп алган да, бер дә уңга-сулга карамый. Без бит менә дигән кала-поселоклар салдык, әллә ниләр майтардык, ул шәһәрләрдә кешеләр рәхәтләнеп яши, диючеләр, әлбәттә, булыр. Аларын инкяр итмим. Бу якларда күп кенә шәһәрләр, эшчеләр поселоклары үсеп чыгуы дөрес. Нефтьне сыгып алырга эшче көч кирәк булгач, аңа торак төземи, кая барасың?! Биш бәясенә төшереп булса да, Яңа Чаллыны да салдык ич. Тик аларда халык ничек яши соң?

Азнакайга кайсы яклап кына килсәң дә үрдән төшәсең. Сәфәрегез җилсез көнне булса, калага кергәнче, туктап, аның өстенә карагыз. Шәһәр урнашкан үзән өсте зәпзәңгәр булыр. Бу — томан түгел, газ. Шуны сулап «рәхәтләнә» инде мондагы халык. Бер Азнакай гынамы?! Әлмәт, Бөгелмә, Ланиногорск кебек башка калаларда да шул ук хәл. Әлмәткә килгәнегез булса, мондагы суның сырага охшаганлыгын искәрми калмагансыздыр. Кырыкмаса кырык төрле агулы матдәләрдән торган Кама суы бу.

Инде мәктәпләргә игътибар итик. Санитария кагыйдәләре буенча һәр ана дуңгызга 4,5 квадрат метр мәйдан тиешле дип ишеткәнем бар. Безнең төбәктәге кала мәктәпләрендә исә бер балага бер квадрат метр гына мәйдан тия икән. Класс саен 40-45 бала. Мондый шартларда төпле белем, ныклы физик һәм эстетик тәрбия алу хакында сөйләүнең һичнинди мәгънәсе дә юк.

Лениногорскида үзәктән шактый читтә, һәркайсында ике-өч мең чамасы шәхси йорт булган Геофизиклар һәм тимер юл станциясе поселоклары бар. Алар, үзләре барлыкка килгәннән бирле клуб, мәктәп дигән нәрсәләрне белмиләр. Балалар, 4-5 чакрым ара үтеп, үзәктәге мәктәпләргә йөрергә мәҗбүр. Геофизиклар поселогындагы кайбер йортлар үзәктәге мәктәпләрдән 6-7 чакрым чамасында. Юллар начар. Балалар мәктәпләргә тездән саз ерып йөриләр.

Әнә шундый шартларда яшәсә дә, һәркемнең өе булса, бер хәл иде. Алары да җитешми бит әле аның. Бәләкәй генә Лениногорск шәһәрендә квартирага чират торучыларның исемлеген карыйсың да (алар, гадәттә, коридорларга элenә), баш чайкап куясың. Бу исемлекләр гүя кимүгә түгел, артуга таба бара. Илгә миллиардлаган байлык биргән нефть төбәгендәге мондый күренеш тәмам аптырашта калдыра. Кыскасы, нефтьчеләр әле үзләренә иң кирәкле нәрсәләр белән дә тәэмин ителмәгәннәр. Халыкның аларга булган өмете — суга таяну белән бер.

Өметләр акланмауда гаепләләрне мин, шартлы рәвештә, «нефтьчеләр» дип атадым. Чынында, беренче чиратта, әлбәттә, министрлык һәм төрле ведомстволарны күздә тотарга кирәк. Көне-төне мазутка батып, җан аямый эшләп йөргән бораулаучы һәм нефть чыгаручы кешеләрдән ни өмет итәсең?! Алар кулыннан килә торганы — шул, ат кебек эшләү бит инде. Урыннардагы катлы-катлы буйсынуга мәҗбүр ителгән вактөяк предприятиеләрне гаепләүдә дә мәгънә юк. Ул бичаралар, миллиардлаган тонна нефть чыгарсалар да, бакыр тиен санап яшиләр. Бар байлыкны, валютаны үзәк сыпырып бара. Татарстан нефте исәбенә алынган өч йөз миллиардка якын валютаның республикага тиене дә калмавы хакында инде күп язылды. Союздаш республикалар табышының 40-70 процентын үзләрендә калдырса, бездә автономияле республикада, бу сан юк дәрәҗәсендә. Безнең нефть предприятиеләре шундый хәлгә куелганнар ки, кайберләре күп еллар буе үзләренә контора гына да сала алмады. Булган кадәресен дә төрле алдашу юллары белән төзеделәр. Мәсьәлән, Лениногорскидагы иң бай предприятиедән саналган «Лениногорскнефть» идарәсе, бу — фәлән-фәлән цех, дип, алдашып салынган бинада утыра. Нефть калаларында булганнар игътибар иткәннәрдер, алардагы бөтен культура чаралары Техника йортында үткәрелә. Бу атаманың хикмәте бар икән: «Культура йорты» дисәң, аларны үзәк финансламый.

Кыскасы, итекченең итеге юк. һәм әлеге шартларда, ягъни автономияле республикалар кысасында яшәгәндә, әлеге «итек»нең булуын көтәргә дә ярамый. Бөтен ышаныч — Татарстанга союздаш республика статусы алуда. Бу мәсьәлә күтәрелгәч, халкыбызда янә өр-яңа өмет уянды. Союздаш республика хокукына ирешеп, үзебезнең нефтькә һәм башка байлыкларга үзебез хуҗа булу өмете. Беренче өметләр акланмады, монысы ничек булыр? Хәер, авыз ачып көтеп кенә утырсак, бу соңгы өметнең дә һавадагы торна булып калуы ихтимал. Үз хокукларыбызны даулап алыр чак.

# КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

## Сүрәтү Йасин

### سُورَةُ يسٓ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

يسٓ ﴿١﴾ وَٱلْقُرْءَانِ ٱلْحَكِيمِ ﴿٢﴾ إِنَّكَ لَمِنَ ٱلْمُرْسَلِينَ ﴿٣﴾ عَلَىٰ
صِرَٰطٍ مُّسْتَقِيمٍ ﴿٤﴾ تَنزِيلَ ٱلْعَزِيزِ ٱلرَّحِيمِ ﴿٥﴾ لِتُنذِرَ قَوْمًا مَّآ
أُنذِرَ ءَابَآؤُهُمْ فَهُمْ غَٰفِلُونَ ﴿٦﴾ لَقَدْ حَقَّ ٱلْقَوْلُ عَلَىٰٓ أَكْثَرِهِمْ
فَهُمْ لَا يُؤْمِنُونَ ﴿٧﴾ إِنَّا جَعَلْنَا فِىٓ أَعْنَٰقِهِمْ أَغْلَٰلًا فَهِىَ إِلَى
ٱلْأَذْقَانِ فَهُم مُّقْمَحُونَ ﴿٨﴾ وَجَعَلْنَا مِنۢ بَيْنِ أَيْدِيهِمْ سَدًّا
وَمِنْ خَلْفِهِمْ سَدًّا فَأَغْشَيْنَٰهُمْ فَهُمْ لَا يُبْصِرُونَ ﴿٩﴾ وَسَوَآءٌ
عَلَيْهِمْ ءَأَنذَرْتَهُمْ أَمْ لَمْ تُنذِرْهُمْ لَا يُؤْمِنُونَ ﴿١٠﴾ إِنَّمَا تُنذِرُ
مَنِ ٱتَّبَعَ ٱلذِّكْرَ وَخَشِىَ ٱلرَّحْمَٰنَ بِٱلْغَيْبِ ۖ فَبَشِّرْهُ بِمَغْفِرَةٍ
وَأَجْرٍ كَرِيمٍ ﴿١١﴾ إِنَّا نَحْنُ نُحْىِ ٱلْمَوْتَىٰ وَنَكْتُبُ مَا قَدَّمُوا۟
وَءَاثَٰرَهُمْ ۚ وَكُلَّ شَىْءٍ أَحْصَيْنَٰهُ فِىٓ إِمَامٍ مُّبِينٍ ﴿١٢﴾ وَٱضْرِبْ

لَهُم مَّثَلًا أَصْحَـٰبَ ٱلْقَرْيَةِ إِذْ جَآءَهَا ٱلْمُرْسَلُونَ ﴿١٣﴾ إِذْ
أَرْسَلْنَآ إِلَيْهِمُ ٱثْنَيْنِ فَكَذَّبُوهُمَا فَعَزَّزْنَا بِثَالِثٍ فَقَالُوٓا۟ إِنَّآ
إِلَيْكُم مُّرْسَلُونَ ﴿١٤﴾ قَالُوا۟ مَآ أَنتُمْ إِلَّا بَشَرٌ مِّثْلُنَا وَمَآ أَنزَلَ
ٱلرَّحْمَـٰنُ مِن شَىْءٍ إِنْ أَنتُمْ إِلَّا تَكْذِبُونَ ﴿١٥﴾ قَالُوا۟ رَبُّنَا يَعْلَمُ إِنَّآ
إِلَيْكُمْ لَمُرْسَلُونَ ﴿١٦﴾ وَمَا عَلَيْنَآ إِلَّا ٱلْبَلَـٰغُ ٱلْمُبِينُ ﴿١٧﴾ قَالُوٓا۟ إِنَّا
تَطَيَّرْنَا بِكُمْ ۖ لَئِن لَّمْ تَنتَهُوا۟ لَنَرْجُمَنَّكُمْ وَلَيَمَسَّنَّكُم مِّنَّا
عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿١٨﴾ قَالُوا۟ طَـٰٓئِرُكُم مَّعَكُمْ ۚ أَئِن ذُكِّرْتُم ۚ بَلْ أَنتُمْ
قَوْمٌ مُّسْرِفُونَ ﴿١٩﴾ وَجَآءَ مِنْ أَقْصَا ٱلْمَدِينَةِ رَجُلٌ يَسْعَىٰ
قَالَ يَـٰقَوْمِ ٱتَّبِعُوا۟ ٱلْمُرْسَلِينَ ﴿٢٠﴾ ٱتَّبِعُوا۟ مَن لَّا يَسْـَٔلُكُمْ
أَجْرًا وَهُم مُّهْتَدُونَ ﴿٢١﴾ وَمَا لِىَ لَآ أَعْبُدُ ٱلَّذِى فَطَرَنِى
وَإِلَيْهِ تُرْجَعُونَ ﴿٢٢﴾ ءَأَتَّخِذُ مِن دُونِهِۦٓ ءَالِهَةً إِن يُرِدْنِ
ٱلرَّحْمَـٰنُ بِضُرٍّ لَّا تُغْنِ عَنِّى شَفَـٰعَتُهُمْ شَيْـًٔا وَلَا يُنقِذُونِ ﴿٢٣﴾
إِنِّىٓ إِذًا لَّفِى ضَلَـٰلٍ مُّبِينٍ ﴿٢٤﴾ إِنِّىٓ ءَامَنتُ بِرَبِّكُمْ فَٱسْمَعُونِ ﴿٢٥﴾
قِيلَ ٱدْخُلِ ٱلْجَنَّةَ ۖ قَالَ يَـٰلَيْتَ قَوْمِى يَعْلَمُونَ ﴿٢٦﴾ بِمَا
غَفَرَ لِى رَبِّى وَجَعَلَنِى مِنَ ٱلْمُكْرَمِينَ ﴿٢٧﴾ ۞ وَمَآ أَنزَلْنَا عَلَىٰ

قَوْمِهِۦ مِنۢ بَعْدِهِۦ مِن جُندٍ مِّنَ ٱلسَّمَآءِ وَمَا كُنَّا مُنزِلِينَ ﴿٢٨﴾
إِن كَانَتْ إِلَّا صَيْحَةً وَٰحِدَةً فَإِذَا هُمْ خَٰمِدُونَ ﴿٢٩﴾ يَٰحَسْرَةً
عَلَى ٱلْعِبَادِ مَا يَأْتِيهِم مِّن رَّسُولٍ إِلَّا كَانُوا۟ بِهِۦ يَسْتَهْزِءُونَ ﴿٣٠﴾
أَلَمْ يَرَوْا۟ كَمْ أَهْلَكْنَا قَبْلَهُم مِّنَ ٱلْقُرُونِ أَنَّهُمْ إِلَيْهِمْ لَا
يَرْجِعُونَ ﴿٣١﴾ وَإِن كُلٌّ لَّمَّا جَمِيعٌ لَّدَيْنَا مُحْضَرُونَ ﴿٣٢﴾ وَءَايَةٌ
لَّهُمُ ٱلْأَرْضُ ٱلْمَيْتَةُ أَحْيَيْنَٰهَا وَأَخْرَجْنَا مِنْهَا حَبًّا فَمِنْهُ
يَأْكُلُونَ ﴿٣٣﴾ وَجَعَلْنَا فِيهَا جَنَّٰتٍ مِّن نَّخِيلٍ وَأَعْنَٰبٍ
وَفَجَّرْنَا فِيهَا مِنَ ٱلْعُيُونِ ﴿٣٤﴾ لِيَأْكُلُوا۟ مِن ثَمَرِهِۦ وَمَا
عَمِلَتْهُ أَيْدِيهِمْ أَفَلَا يَشْكُرُونَ ﴿٣٥﴾ سُبْحَٰنَ ٱلَّذِى خَلَقَ
ٱلْأَزْوَٰجَ كُلَّهَا مِمَّا تُنۢبِتُ ٱلْأَرْضُ وَمِنْ أَنفُسِهِمْ وَمِمَّا
لَا يَعْلَمُونَ ﴿٣٦﴾ وَءَايَةٌ لَّهُمُ ٱلَّيْلُ نَسْلَخُ مِنْهُ ٱلنَّهَارَ فَإِذَا هُم
مُّظْلِمُونَ ﴿٣٧﴾ وَٱلشَّمْسُ تَجْرِى لِمُسْتَقَرٍّ لَّهَا ذَٰلِكَ
تَقْدِيرُ ٱلْعَزِيزِ ٱلْعَلِيمِ ﴿٣٨﴾ وَٱلْقَمَرَ قَدَّرْنَٰهُ مَنَازِلَ حَتَّىٰ
عَادَ كَٱلْعُرْجُونِ ٱلْقَدِيمِ ﴿٣٩﴾ لَا ٱلشَّمْسُ يَنۢبَغِى لَهَآ أَن تُدْرِكَ
ٱلْقَمَرَ وَلَا ٱلَّيْلُ سَابِقُ ٱلنَّهَارِ وَكُلٌّ فِى فَلَكٍ يَسْبَحُونَ ﴿٤٠﴾

وَءَايَةٌ لَّهُمْ أَنَّا حَمَلْنَا ذُرِّيَّتَهُمْ فِي ٱلْفُلْكِ ٱلْمَشْحُونِ ﴿٤١﴾ وَ
خَلَقْنَا لَهُم مِّن مِّثْلِهِۦ مَا يَرْكَبُونَ ﴿٤٢﴾ وَإِن نَّشَأْ نُغْرِقْهُمْ
فَلَا صَرِيخَ لَهُمْ وَلَا هُمْ يُنقَذُونَ ﴿٤٣﴾ إِلَّا رَحْمَةً مِّنَّا وَمَتَٰعًا
إِلَىٰ حِينٍ ﴿٤٤﴾ وَإِذَا قِيلَ لَهُمُ ٱتَّقُوا۟ مَا بَيْنَ أَيْدِيكُمْ وَمَا
خَلْفَكُمْ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿٤٥﴾ وَمَا تَأْتِيهِم مِّنْ ءَايَةٍ مِّنْ ءَايَٰتِ
رَبِّهِمْ إِلَّا كَانُوا۟ عَنْهَا مُعْرِضِينَ ﴿٤٦﴾ وَإِذَا قِيلَ لَهُمْ أَنفِقُوا۟
مِمَّا رَزَقَكُمُ ٱللَّهُ قَالَ ٱلَّذِينَ كَفَرُوا۟ لِلَّذِينَ ءَامَنُوٓا۟ أَنُطْعِمُ
مَن لَّوْ يَشَآءُ ٱللَّهُ أَطْعَمَهُۥٓ إِنْ أَنتُمْ إِلَّا فِي ضَلَٰلٍ مُّبِينٍ ﴿٤٧﴾
وَيَقُولُونَ مَتَىٰ هَٰذَا ٱلْوَعْدُ إِن كُنتُمْ صَٰدِقِينَ ﴿٤٨﴾ مَا يَنظُرُونَ
إِلَّا صَيْحَةً وَٰحِدَةً تَأْخُذُهُمْ وَهُمْ يَخِصِّمُونَ ﴿٤٩﴾ فَلَا
يَسْتَطِيعُونَ تَوْصِيَةً وَلَآ إِلَىٰٓ أَهْلِهِمْ يَرْجِعُونَ ﴿٥٠﴾ وَنُفِخَ
فِي ٱلصُّورِ فَإِذَا هُم مِّنَ ٱلْأَجْدَاثِ إِلَىٰ رَبِّهِمْ يَنسِلُونَ ﴿٥١﴾
قَالُوا۟ يَٰوَيْلَنَا مَنۢ بَعَثَنَا مِن مَّرْقَدِنَا ۜ هَٰذَا مَا وَعَدَ ٱلرَّحْمَٰنُ وَ
صَدَقَ ٱلْمُرْسَلُونَ ﴿٥٢﴾ إِن كَانَتْ إِلَّا صَيْحَةً وَٰحِدَةً فَإِذَا هُمْ
جَمِيعٌ لَّدَيْنَا مُحْضَرُونَ ﴿٥٣﴾ فَٱلْيَوْمَ لَا تُظْلَمُ نَفْسٌ شَيْـًٔا

وَلَا تُجْزَوْنَ إِلَّا مَا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ﴿٥٤﴾ إِنَّ أَصْحَٰبَ ٱلْجَنَّةِ
ٱلْيَوْمَ فِى شُغُلٍ فَٰكِهُونَ ﴿٥٥﴾ هُمْ وَأَزْوَٰجُهُمْ فِى ظِلَٰلٍ عَلَى
ٱلْأَرَآئِكِ مُتَّكِـُٔونَ ﴿٥٦﴾ لَهُمْ فِيهَا فَٰكِهَةٌ وَلَهُم مَّا يَدَّعُونَ ﴿٥٧﴾
سَلَٰمٌ قَوْلًا مِّن رَّبٍّ رَّحِيمٍ ﴿٥٨﴾ وَٱمْتَٰزُوا۟ ٱلْيَوْمَ أَيُّهَا
ٱلْمُجْرِمُونَ ﴿٥٩﴾ ۞ أَلَمْ أَعْهَدْ إِلَيْكُمْ يَٰبَنِىٓ ءَادَمَ أَن لَّا تَعْبُدُوا۟
ٱلشَّيْطَٰنَ ۖ إِنَّهُۥ لَكُمْ عَدُوٌّ مُّبِينٌ ﴿٦٠﴾ وَأَنِ ٱعْبُدُونِى ۚ هَٰذَا
صِرَٰطٌ مُّسْتَقِيمٌ ﴿٦١﴾ وَلَقَدْ أَضَلَّ مِنكُمْ جِبِلًّا كَثِيرًا ۖ
أَفَلَمْ تَكُونُوا۟ تَعْقِلُونَ ﴿٦٢﴾ هَٰذِهِۦ جَهَنَّمُ ٱلَّتِى كُنتُمْ تُوعَدُونَ ﴿٦٣﴾
ٱصْلَوْهَا ٱلْيَوْمَ بِمَا كُنتُمْ تَكْفُرُونَ ﴿٦٤﴾ ٱلْيَوْمَ نَخْتِمُ عَلَىٰٓ
أَفْوَٰهِهِمْ وَتُكَلِّمُنَآ أَيْدِيهِمْ وَتَشْهَدُ أَرْجُلُهُم بِمَا كَانُوا۟
يَكْسِبُونَ ﴿٦٥﴾ وَلَوْ نَشَآءُ لَطَمَسْنَا عَلَىٰٓ أَعْيُنِهِمْ فَٱسْتَبَقُوا۟
ٱلصِّرَٰطَ فَأَنَّىٰ يُبْصِرُونَ ﴿٦٦﴾ وَلَوْ نَشَآءُ لَمَسَخْنَٰهُمْ عَلَىٰ
مَكَانَتِهِمْ فَمَا ٱسْتَطَٰعُوا۟ مُضِيًّا وَلَا يَرْجِعُونَ ﴿٦٧﴾ وَمَن
نُّعَمِّرْهُ نُنَكِّسْهُ فِى ٱلْخَلْقِ ۖ أَفَلَا يَعْقِلُونَ ﴿٦٨﴾ وَمَا
عَلَّمْنَٰهُ ٱلشِّعْرَ وَمَا يَنۢبَغِى لَهُۥٓ ۚ إِنْ هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ وَ

قُرْءَانٌ مُّبِينٌ ﴿٦٩﴾ لِّيُنذِرَ مَن كَانَ حَيًّا وَيَحِقَّ ٱلْقَوْلُ عَلَى
ٱلْكَٰفِرِينَ ﴿٧٠﴾ أَوَلَمْ يَرَوْا۟ أَنَّا خَلَقْنَا لَهُم مِّمَّا عَمِلَتْ أَيْدِينَآ
أَنْعَٰمًا فَهُمْ لَهَا مَٰلِكُونَ ﴿٧١﴾ وَذَلَّلْنَٰهَا لَهُمْ فَمِنْهَا رَكُوبُهُمْ وَ
مِنْهَا يَأْكُلُونَ ﴿٧٢﴾ وَلَهُمْ فِيهَا مَنَٰفِعُ وَمَشَارِبُ أَفَلَا
يَشْكُرُونَ ﴿٧٣﴾ وَٱتَّخَذُوا۟ مِن دُونِ ٱللَّهِ ءَالِهَةً لَّعَلَّهُمْ
يُنصَرُونَ ﴿٧٤﴾ لَا يَسْتَطِيعُونَ نَصْرَهُمْ وَهُمْ لَهُمْ جُندٌ
مُّحْضَرُونَ ﴿٧٥﴾ فَلَا يَحْزُنكَ قَوْلُهُمْ إِنَّا نَعْلَمُ مَا يُسِرُّونَ
وَمَا يُعْلِنُونَ ﴿٧٦﴾ أَوَلَمْ يَرَ ٱلْإِنسَٰنُ أَنَّا خَلَقْنَٰهُ مِن نُّطْفَةٍ
فَإِذَا هُوَ خَصِيمٌ مُّبِينٌ ﴿٧٧﴾ وَضَرَبَ لَنَا مَثَلًا وَنَسِىَ
خَلْقَهُۥ قَالَ مَن يُحْىِ ٱلْعِظَٰمَ وَهِىَ رَمِيمٌ ﴿٧٨﴾ قُلْ يُحْيِيهَا
ٱلَّذِىٓ أَنشَأَهَآ أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ ﴿٧٩﴾ ٱلَّذِى
جَعَلَ لَكُم مِّنَ ٱلشَّجَرِ ٱلْأَخْضَرِ نَارًا فَإِذَآ أَنتُم مِّنْهُ
تُوقِدُونَ ﴿٨٠﴾ أَوَلَيْسَ ٱلَّذِى خَلَقَ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلْأَرْضَ
بِقَٰدِرٍ عَلَىٰٓ أَن يَخْلُقَ مِثْلَهُم بَلَىٰ وَهُوَ ٱلْخَلَّٰقُ ٱلْعَلِيمُ ﴿٨١﴾
إِنَّمَآ أَمْرُهُۥٓ إِذَآ أَرَادَ شَيْـًٔا أَن يَقُولَ لَهُۥ كُن فَيَكُونُ ﴿٨٢﴾

فَسُبْحَٰنَ ٱلَّذِى بِيَدِهِۦ مَلَكُوتُ كُلِّ شَىْءٍ وَإِلَيْهِ تُرْجَعُونَ ﴿٨٣﴾

صَدَقَ ٱللَّهُ ٱلْعَلِيُّ ٱلْعَظِيمُ

سُبْحَٰنَ رَبِّكَ رَبِّ ٱلْعِزَّةِ عَمَّا يَصِفُونَ وَسَلَٰمٌ عَلَى

ٱلْمُرْسَلِينَ وَٱلْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ ٱلْعَٰلَمِينَ ٱلْفَاتِحَةُ

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмиллаhир-рахманир-рахим.*

*Йасин (1) вәл-Коръәнил-хәким. (2) Иннәкә ләминәл-мөрсәлин. (3) Галә сыйрātим мөстәкыйм. (4) Тәнзйләл-газизир-рәхими. (5) Литүнзирә кāумәм мā үнзирә āбāәүhүм фәhүм гāфилүн. (6) Ләкад хаккаль-каулү галә әксәриhим фәhүм лә йүәминүн. (7) Иннā җәгальнā фй әгънāкыйhим әглāлән фәhийә иләл-әзкани фәhүм мукъмәхүн. (8) Вә җәгальнā мим бәйни әйдйhим сәддән вә мин хәлфиhим сәддән фәәагъшәйнāhүм фәhүм лә йубсыйрүн. (9) Вә сәвāәүн галәйhим ә әнзәртәhүм әм ләм түнзирhүм лә йүәминүн. (10) Иннәмā түнзирү мәнит-тәбәгаззикрә вә хашийәр-рахмәнә бил-гайби фәбәшширhү бимәгъфирәтин вә әҗрин кәрим. (11) Иннā нәхнү нухъйил-мәутā вә нәктүбү мā каддәмү вә асāрәhүм, вә көллә шәйәин ахъсайнāhү фи имамим мөбин. (12) Вадриб ләhүм мәсәлән асхāбәл-карьйәти из җāәәhәл-мөрсәлүн. (13) Из әрсәлнā иләйhимус-нәйни фәкәззәбү hүмā фәгаззәзнā бисāлисин фәкāлү иннā иләйкүм мөрсәлүн. (14) Кāлү мā әнтүм иллә бәшәрун мислүнā вә мā әнзәләр-рахмәну мин шәйәин ин әнтүм иллә тәкзибүн. (15) Кāлү раббунā йәгъләмү иннā иләйкүм ләмөрсәлүн. (16) Вә мā галәйнā илләл-бәлāгуль-мөбин. (17) Кāлү иннā тәтайййарнā бикүм ләәил ләм тәнтәhу ләнәрҗүмән-нәкүм вә ләйәмәссәннәкүм миннā газāбун әлим. (18) Кāлү тāәйрүкүм мәгакүм, әәин зүккиртүм, бәл әнтүм каумүм мөсрифүн. (19) Вә җāәә мин акъсал-мәдйрәҗүлүн йәсгā кāлә йәкаумит-тәбигуль-мөрсәлин. (20) Иттәбигу мәл лә йәсәәлукүм әҗрāн вә hүм муhтәдун. (21) Вә мā лийәлā әгъбүдүл-ләзи фәтарәни вә иләйhи түрҗәгүн. (22) Ә әттәхизү мин дуниhи āлиhәтән ин йүриднир-рахмәнү бидуррил лә түгни ганни шәфāгатүhүм шәйәән вә лә йүнкыйзүн. (23) Иннй изән лә фи далāлим мөбин. (24) Инни әмәнтү бираббикүм фәсмәгүн. (25) Кыйләдхүлил-җәннәh, кāлә йәләйтә каумй йәгъләмүн. (26) Бимā гафәрәли рабби вә җәгаләни минәл-мөкрәмин. (27) Вә мā әнзәлнā галә каумиhи мин бәгъдиhи мин җүндин минәс-сәмāәи вә мā кунна мүнзилин. (28) Ин кәнәт иллә сайхәтән вāхидәтән фәәизā hүм хāмидүн. (29) Йахәсрәтән галәл-гыйбāди мā йәәтиhим мир рәсүлин иллә кәнү биhи йәстәhзиәүн. (30) Ә ләм йәрәү кәм әhләкнā каблəhүм минәл-курүни әннәhүм иләйhим лә йәрҗигүн. (31) Вә ин күллүл-ләммā җәмигуль-ләдәйна мухдарун. (32). Вә āйәтул-ләhүмул-āрдул-мәйтәтү әхъйәйнāhа вә әхрәҗна минhа хәббан фәминhү йәәку-*

лу́н. (33) Вә җәгальна́ фиһа́ җәннәтин мин нәхи́лин вә әгънабин вә
фәҗҗәрна́ фиһа́ минәл-гуйу́н. (34) Лийәәкүлү мин сәмәриһи вә ма́
гамиләтһү әйди́һим ә фәлә́ йәшкүру́н. (35) Сөбха́нәл-ләзи халәкаль-
әзва́җә күлләһа́ мимма түмбитүл-арду вә мин әнфүсиһим вә мим-
ма́ лә́ йәгъләму́н. (36) Вә а́йәтүл-ләһүмүл-ләйлү нәсләхү минһүн-
нәһа́рә фәәиза́ һүм музлиму́н. (37) Вәш-шәмсү тәҗри лимөстәкаррил
ләһа за́ликә тәкъди́рүл-гази́зил-гали́м. (38) Вәл-камәрә каддәрна́һү
мәна́зилә хәтта́ га́дә кәл-гурҗу́нил-кади́м. (39) Лә́ш-шәмсү йәмбәгый
ләһа́ эн түдрикәл-камәрә вә лә́л-ләйлү сабикун-нәһар, вә көллүн фи
фәләкин йәсбәху́н. (40) Вә а́йәтүл-ләһүм әнна́ хәмәлна́ зүррийәтәһүм
фил-филкил-мәшху́н. (41) Вә халакъна́ ләһүм мим мислиһи ма́ йәр-
кәбу́н. (42) Вә ин-нәшаә нугрикуһум фәлә́ сариха ләһүм вә лә́ һүм
йунказу́нә. (43) Иллә́ рәхмәтәм-минна́ вә мәта́ган илә́ хи́йн. (44) Вә
иза́ кыйлә ләһүмут-тәку ма́ бәйнә әйди́күм вә ма́ хәлфәкүм ләгал-
ләкүм түрхаму́н. (45) Вә ма́ тәәтиһим мин а́йәтин мин а́йәти, раб-
биһим иллә́ кә́ну ганьһа́ мугъриди́йн. (46) Вә иза́ кыйлә ләһүм эн-
фику мимма́ рәзакакүмүл-лаһу ка́ләл-ләзи́нә кәфәрү лилләзи́нә
а́мәнү әнутгыймү мәл-ләү йәша́әүлла́һү атгамәһ, ин әнтүм иллә
фи дала́лим мөби́н. (47) Вә йәкулүнә мәта́ һа́зәл-вәгъдү ин күнтүм
садыйкыйн.(48) Ма́ йанзуру́н иллә́ сайхатән вахидәтән тәәхузүһүм
вә һүм йәхиссыйму́н. (49). Фәлә́ йәстәтыйгу́нә тәусыйәтән вә лә́
илә́ әһлиһим йәрҗигу́н. (50) Вә нүфиха фис-сури фәәиза́ һүм минәл-
әҗдаси илә́ рәббиһим йәнсилу́н. (51) Ка́лү йа́уәйләна́ мәм бәгасәна
мим мәркадина́, һа́зә ма́ вәгадәр-рахмәнү вә садакаль-мөрсәлу́н.
(52) Ин кә́нәт иллә сайхатән ва́хидәтән фәәиза́ һүм җәми́гуль-лә-
дәйна мухдару́н. (53) Фәлйәүмә лә тузламү нәфсүн шәйәән вә лә́
түҗзәүнә иллә́ ма́ күнтүм тәгъмәлу́н. (54) Иннә әсха́бәл-җәннәтил-
йәүмә фи шугулин фа́киһу́н. (55) Һүм вә әзва́җүһүм фи зыйлалин
галәл-әра́ики мүттәкиәу́н (56) Ләһүм фиһа́ фа́киһәтүм вә ләһүм-ма́
йәддәгу́н. (57) Сәла́мүн каулән мир-раббир-рәхи́м. (58) Вәмта́зүл-
йәүмә әййүһаль-мәҗриму́н. (59) Ә ләм әгъһәд иләйкүм йа́ бәни́
Адәмә әл лә́ тәгъбүдүш-шәйтанә иннәһу ләкүм гадүүм-мөби́нун. (60)
Вә әнигъ-бүдүни, һа́зә сыйра́түм мөстәкыйм. (61) Вә ләкад адал-
лә минкүм җибилләән кәси́ра, ә фәләм тәкүнү тәгъкыйлу́н. (62) Һа́-
зиһи җәһәннәмүл-ләти күнтүм тү́гаду́н. (63) ислауһа́ль-йәүмә бима́
күнтүм тәкфүрун. (64) Әл-йәүмә нәхтимү галә́ әфва́һиһим вә түкәл-
лиму́на әйди́һим вә тәшһәдү әрҗүлүһүм бима́ кә́нү йәксибу́н. (65)
Вә ләү нәша́әү ләтамәсна́ галә́ әгъйуниһим фәстәбәкус-сыйра́та
фәәәнна́ йүбсыйру́н. (66) Вә ләү нәша́әү ләмә-сәхна́һүм галә мәкә-
нәтиһим фәма́с-тәта́гу мудийан вә лә йәрҗигу́н. (67) Вә мән-нугам-
мирһү нүнәккисһү фил-хальқъ, ә фәлә́ йәгъкыйлун. (68) Вә ма
галләмнаһүш-шигърә вә ма́ йәмбәгый ләһ, ин һүвә иллә́ зикрүн вә
Корънүм-мөби́нүн. (69) Лийүнзирә мән кә́нә хәййән вә йәхиккаль-
каулү галәл-кәфири́н. (70) Ә вә ләм йәрәү әнна́ халакъна́ ләһүм
мимма́ гамиләт әйди́на́ әнга́мән фәһүм ләһа ма́лику́н. (71) Вә зәл-
ләлна́һа́ ләһүм фәминһа рәку́бүһүм вә минһа йәәкүлу́н. (72). Вә лә-
һүм фиһа мәна́фигу вә мәша́риб, ә фәлә́ йәшкүру́н. (73) Вәт-тәхазү
мин ду́нил-ла́һи а́лиһәтәл-ләгалләһүм йунсару́н. (74) Лә́ йәстәтыйгу́нә
насраһүм вә һүм ләһүм җүндүм мухдару́н. (75) Фәлә́ йәхзүнкә кау-
лүһүм инна́ нәгъләмү ма́ йүсирру́нә вә ма́ йугълиму́н. (76) Ә вә ләм
йәрәл-инса́нү әнна́ халакъна́һү мин нутфәтин фәәиза́ һүвә хасыймүм
мөби́н. (77) Вә дарабә ләна́ мәсәлән вә нәсийә халькаһ, калә мән
йухъйил-гыйза́мә вә һийә рәми́м. (78) Куль йухъйиһәл-ләзи әншаә-
әһа́ әүвәлә мәррәһ, вә һүвә бикөлли халькыйн гали́м. (97) Әлләзи
җәгалә ләкүм минәш-шәҗәрил-ахдари на́рән фәәиза́ әнтүм-минһү ту-
кыйду́н. (80) Ә вә ләйсәл-ләзи халакас-сәма́ва́ти вәл-арда бика́дирин
галә́ эн йәхлука мислүһүм, бәла́ вә һүвәл-халлакуль-гали́м. (81) Ин-
нәма́ әмруһу иза́ әра́дә шәйә́ән эн йәку́лә ләһү күн фәйәку́н. (82) Фә-

*сөбхәнәл-ләзи бийәдиhи мәләкутү көлли шәйәин вә иләйhи түрҗәгүн.*

*Садакал-лаhуль-галиййүл-газыйм*

*Сөбхәнә раббикә раббил-гыйззәти гаммә*

*йасыйфүн вә сәләмүн галәл мөрсәлин вәл хәмдү лил-ләhи раббил-галәминәл-фатихату.*

ТӘФСИР

## «Йасин» сүрәсе.
## Мәккәдә иңгән утыз алтынчы сүрә,
## сиксән өч аять

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаhы хакына

Йасин — сүрә исеме, яки Аллаhы белән илчесе — Мөхәммәд пәйгамбәр арасында бер серле, ягъни тай телендәгечә «Әй, адәм!» дип әйтү мәгънәсендә. Моннан Мөхәммәд галәйhис-сәламгә эндәшеп: «Йа, сәййидел-бәшәр!» — («Әй, кешеләрнең хуҗасы!») дип әйтү аңлашыла. Икенче төрле мәгънәсе — сүрә башлануны белдерә hәм «бу сүрә башланды» дип әйтү аңлашыла. (1) Хикмәт иясе булган Коръән белән ант итеп әйтәмен ки: (2) чыннан да, син, әй, Мөхәммәд, дин өйрәтер өчен җибәрелгән илчеләрдәнсең, (3) тугры hәм хак юлдасың. (4) Һәр эштә өстен булган, мәрхәмәт иясе булган Аллаhының ул — хикмәт иясе булган Коръәнне иңдерүе хакында, уйлыймын. (5) Ул Коръәнне аталары куркытылмаган hәм шулай итеп иманны да белмәүче кауемне куркытыр өчен иңдерде. (6) «Һичшиксез, җәhәннәмне адәмнәр hәм җеннәр белән тутырырбыз»,— дигән сүзебез ул кауемнең күбрәгенә туры килде, димәк, ул кауемнең күбрәге иман китермәсләр. (7) Дөреслектә, Без, куркыту файда бирмәгән кауемнең муеннарына богаулар салдык. Шулай итеп, ул богаулар ияклэренә кадәр тиеп торыр. Димәк, ул кауем — башларын күтәреп, күзләрен йомып торучылар. (8) Дәхи, Без ул кауемне алларыннан пәрдә кылдык hәм артларыннан пәрдә кылдык. Шулай итеп, ул кауемнең күзләрен томаладык, димәк алар күрмәсләр [1]. (9) Дәхи, алар Мәккә кяфирләренә, ягъни мәҗүсиләргә бәрабәр, кирәк куркыт син аларны, яки куркытма син аларны, алар иман китермәсләр. (10). Чыннан да, Син Коръәнгә уйлавы hәм гамәл кылуы белән иярган адәмне hәм кыямәт көнендә мәрхәмәт кылучы Аллаhыдан (газабыннан) куркучы адәмне куркытырсың. Шулай итеп, андый күркәм сыйфатлы адәмгә ярлыкау hәм олуг әҗер (җәннәт) берлән сөенеч бир! (11) Дөрестән дә, Без чынлап үлгән адәмнәрне каберләреннән кубару белән, яки наданлык сәбәпле хөкем карары белән үлгән адәмнәрне туры юлга күндереп hәм гыйлем белән тергезербез hәм үзләренең элек кылган изге гамәлләрен hәм явыз гамәлләрен, шулай ук үзләреннән соң калган изге истәлекләрен (өйрәтеп калдырган гыйлем hәм тәрбияле бала, вакыф калдырылган мәктәп hәм мәдрәсә, мәсҗедләр hәм маллар кебек) hәм явыз истәлекләрен (бозык эшне дөньяга чыгарып калдыру hәм тәрбиясез балалар калдыру кебек) — hәммәсен язарбыз. Һәм Без hәрбер нәрсәне язмыш тактасында сакладык. (12) Әй, Мөхәммәд! Мәккә кяфирләренә кария, ягъни авыл (Антакия авылы) кешеләрен мисал итеп куй. Шул вакытта Ул Антакия авылы кешеләренә Гайса пәйгамбәрнең Яхъя hәм Юныс исемле илчеләре килде (13). Шул вакытта Без Антакия кешеләренә илче — Яхъя hәм Юнысны җибәрдек. Нәтиҗәдә Антакия кешеләре бу ике илчене ялганга санадылар. Шулай итеп, Без бу ике илчене өченчесе — Шәмгун белән куәтләдек. Бу өч илче әйттеләр: «Без сезгә (Антакия халкына) дан өйрәтү өчен җибәрелгән илчеләрбез»,— дип. (14) Бу илчеләргә Антакия кешеләре әйттеләр: «Сез түгелсез, сез безнең кебек адәмсез hәм мәрхәмәт итүче Аллаhы сезгә илче булу өчен берни дә иңдермәде, сез илчеләр түгелсез, ә илче дәгъвасын кылучы ялганчыларсыз»,—диделәр. (15) Хәзрәти

[1] «Гүя ки Мәккә кяфирләре — тәрәзәсез, җир астында булган төрмәгә ябылган, алдын hәм артын күрми торган адәмнәр кебек» аятьләрдә hәм дәлилләрдә фикер кылудан тыелалар. Ш. Хәмиди искәрмәсе.

Гайсаның илчеләре әйттеләр: Раббебез белә, чыннан да, без сезгә дин өйрәтер өчен җибәрелгән илчеләрбез. (16) Безнең илчелегебезне ачык итеп ирештерү — үзебезгә тиеш түгел. (17) Антакия кешеләре әйттеләр: «Без сездән шомланабыз. Әгәр сез бу дингә өндәүдән тыелмасагыз, әлбәттә, без сезгә таш белән атарбыз. Дәхи, безнең тарафтан сез каты газабка дучар ителерсез»,— диделәр. (18) Хәзрәти Гайсаның илчеләре әйттеләр: «Шомлануыгызның сәбәбе (бозык иманнарыгыз һәм явыз гамәлләрегез) үзегез белән бергә. Әгәр безнең сүзебез белән вәгазьләнсәгез иде, шомланыр идегезме... Әйе, сез исраф кылучы (гөнаһта чиктән үтүче) кауемсез!» — диделәр. (19) Дәхи, Антакия шәһәренең ерак җиреннән ашыгып бер ир килде, ягъни Хәбибен-Нәҗҗар. Бу ир әйтте: «Әй кауемем, дин өйрәтер өчен килгән илчеләргә иярегез! — диде. (20) — Дин өйрәтү бәрабәренә әҗер сорамый торган һәм хак юлга күчкән адәмнәргә иярегез!» — диде. (21) Дәхи, Хәбибен-Нәҗҗар әйтте: «Үземне яраткан һәм Аның каршысына сез дә кайтачак Аллаһыга гыйбадәт кылмаска — миңа ни булды? (22) Әллә мин Аллаһыдан башка бүтән аллалар тотармынмы? Әлбәттә, тотмыйм. Әгәр Аллаһы миңа зарар китерергә теләсә, ул аллаларның яклаулары һич нәрсәгә файда бирмәс. Дәхи, ул аллалар ярдәм бирү белән мине Аллаһының теләгән зарарыннан коткармаслар да. (23) Чыннан да, мин бу вакытта, ягъни Аллаһыдан башка алла тоткан вакытта, әлбәттә, ап-ачык азгынлыкта булам. (24) Чыннан да, мин сезне яраткан раббегезгә иман китердем, шулай булгач, минем иманымны ишетегез». (25) Хәбибен-Нәҗҗарны кауеме үтергәннән соң, Хәбибен-Нәҗҗарга сөенеч биреп: «Син оҗмахка кер!» — дип әйтелде. Хәбибен-Нәҗҗар әйтте: «Эх, әгәр дә минем кауемем белсә иде, (26) Раббемнең ни сәбәпле мине ярлыкавын, дәхи, ни сәбәпле мине хөрмәтле адәмнәрдән кылуын!» — диде. (Егерме икенче парәнең, ягъни кисәкнең тәрҗемәсе тәмам булды).

(27) Хәбибен-Нәҗҗарны һәлак кылганнарыннан соң аның кауеме өстенә Без гаскәр иңдермәдек, дәхи, Без иңдерүче дә булмадык. (28) Хәбибен-Нәҗҗар кауеменең газабы булмады, мәгәр бер кычкыру булды. Шулай итеп, хәзрәти Җәбраилнең кычкыруын вакытында ук Хәбибен-Нәҗҗар кауеме — сүнгән ут кебек үлүчеләр булдылар. (29) Әй, колларга хәсрәт! Колларга дин өйрәтүче илче (пәйгамбәр) килмәс. Әгәр килсә, ул илчене (пәйгамбәрне) хурлый торган булдылар [1]. (30) Без алардан элек булган кешеләрнең күпмесен һәлак иткәнне әллә Мәккә кяфирләре белмәделәрме? Чыннан да, һәлак булучылар үзләрен һәлак итүчеләргә кайтмауларын белмәделәрме? (31) Дөреслектә, халыкларның һәрберсе җыелырлар һәм безнең хозурыбызда җәза өчен кыямәт көнендә җыелырлар. (32) Дәхи, әдәмнәр өчен каберләрдән кубарылуның барлыгына — үлгән җир дәлил. Без үлгән җирне тергездек һәм үлгән җирдән орлыклар чыгардык һәм ул орлыкларны ашыйлар. (33) Дәхи, Без җирдә хөрмә агачларыннан һәм дә йөзем агачларыннан бакчалар яраттык һәм Без җирдә чишмәләр ярып чыгардык. (34) Бу — телгә алынган агачларның җимешен ашасыннар өчен һәм куллары ясаган нәрсәләрдән ашасыннар өчен, әллә бу нигъмәтләргә шөкер кылмас释лармы? (35) Төрле сыйныфларның барчасын яраткан Аллаһы кимчелекле сыйфатлардан ерак булды. Җир үстергән нәрсәләрдән, ягъни үсүенә җир сәбәп булган нәрсәләрдән, дәхи бәндәләрнең үзләреннән төрле сыйныфлар (ирләр һәм хатыннар) яратты. Дәхи, бәндәләрнең белми торган нәрсәләреннән төрле сыйныфлар яратты. (36) Дәхи, бәндәләр өчен Безнең олуг кодрәтебезгә — төн билге булып тора. Ул төннән көнне суырып алабыз. Шулай итеп, шул вакытта идәмнәр караңгылыкка керәләр. (37) Дәхи, Кояш — күкнең уртасында гомеренең торган урынына ирешкәнгә кадәр, эшеннән бушанган адәм — эшеннән бушанганнан соң урнашкан кебек. Кояш та хәрәкәт гомере тәмамланганнан соң урнаша. Бу Кояшның йөрүе — һәрнәрсәне белүче һәм һәр эштә өстен булган Аллаһы тәгаләнең тәкъдире. (38) Дәхи, Ай. Аның йөрешен егерме сигез урында чикләдек. Иске хөрмә сабагы, яки йөзем сабагының кәкре ботагы кебек булганга кадәр. (39) Шулай итеп, Кояшка Айны куып тотып Айга тыгызлык бирүе — дөрес булмас. Дәхи, төннең көннән алдан булуы — дөрес булмас, бәлки төн — көннең урынына

[1] Әлбәттә, дөнья вә ахирәтнең сәгадәтләренә — бәхетләренә ирешүгә сәбәп булган нәсыйхәтләр белән нәсыйхәт кылучы пәйгамбәрләрне хурлаучылар — һичшиксез, хәсрәтле булырга лаеклар. Ш. Хәмиди искәрмәсе.

килә. Боларның бөтенесе күктә көчеп йөриләр [1]. (40) Дәхи, адәмнәр өчен безнең кодрәтебезгә билге — чыннан да, Без адәмнәр сәүдә кылырга җибәргән балаларын эче тулы булган көймәгә тутырдык. (41 Дәхи адәмнәр өчен көймәнең охшашыннан атлана торган нәрсәләрен (дөяне) яраттык чөнки дөя — коры җирнең көймәсе кебек (яки пароходларга һәм башка машиналарга ишарәт булыр). (42) Әгәр теләсәк, Без адәмнәрне диңгезгә батырырбыз. Суга батканнан соң адәмнәр өчен батудан коткара торган ярдәмче булмас һәм суга батып үлүдән котыла алмаслар, (43) ә бары тик Безнең рәхмәтебез һәм бер вакытка кадәр дөнья тереклеге белән файдаландыруыбыз аркасында котылырлар. (44) һәм һәркайчан кяфирләргә: «Алдыгызда булган нәрсәдән (ахирәт газабыннан), дәхи артыгызда булган нәрсәдән (үткән вакыйгалардан), мәрхәмәт ителүегезне (кичерелүегезне) өмет итүегез өчен куркыгыз»,— дип, ягъни шул рәвештә әйтелсә — йөз дүндерерләр. (45) Кяфирләргә раббеләренең аятьләреннән бер аять тә килмәс, әгәр килсә — ул аятьтән йөз дүндерерләр. (46) Һәм кайчан Мәккә кяфирләренә мөселманнар тарафыннан: «Аллаһы үзегезне ризыкландырган нәрсәдән өлеш чыгарыгыз!» — дип әйтелсә, кяфир булган адәмнәр — иман китергән адәмнәргә: «Әллә без шул адәмне туендырырбызмы? Әгәр Аллаһы теләсә — ул адәмне туендырыр иде. Сез мөселманнар түгелсез, ә ап-ачык азгынлыктасыз,ягъни безгә Аллаһының теләвенә каршы булган эш белән боерасыз»,— дип әйттеләр. (47) Дәхи, кяфирләр мөселманнарга әйтәләр: «Әгәр сез дөрес сүзлеләрдән булсагыз, бу — каберләрдән кубарылу вәгъдәсе кайчан?» (48) Кяфирләр бер тавыштан башка бүтән тавышны (Исрафил фәрештәнең әүвәлге быргы (сур) тавышы) ишетмиләр. Ул бер тавыш кяфирләрне тотар, хәлбуки, ул кяфирләр кычкырыша торган булырлар, ягъни сату-алуларында һәм башка мөгамәләләрендә кычкырыша торган булырлар, кыямәт булуы күңелләренә килмәгән дә булыр. (49) Шулай итеп, эшләреннән бер эшкә кушарга да көчләре җитмәс, дәхи, өй җәмәгатьләре янына да кайта алмаслар, бәлки шул урында үләрләр. (50) Дәхи, икенче мәртәбә быргыга (сурга) өрелер. Быргыга (сурга) өрү — җаннарны хәшер, ягъни бер җиргә туплау өчен чакырудан киная була. Шулай итеп, шул вакытта ук кабердәге адәмнәр каберләреннән раббеләренә ашыгырлар. (51) Адәмнәрдән кяфир булганнары әйтерләр: «Ни хәсрәт безгә, безне йоклаган урыннарыбыздан (каберләребездән) кем кубарды?» — дип. Фәрештәләр һәм мөселманнар кяфирләргә җавап биреп әйтерләр яки кяфирләр икърар итеп әйтерләр: «Бу — кабердән кубарылу, Аллаһының вәгъдә кылган нәрсәсе, дәхи, пәйгамбәрләрнең дөрес сөйләгән нәрсәсе!» — дип. (52) Бу — икенче быргы (сур) тавышы булмады, мәгәр бер тавыш булды. Шулай итеп, һәр кайчан, икенче быргы (сур) тавышы булса — бөтен адәмнәр җыелалар һәм безнең хозурыбызга килеп баскан көндә һичбер җанга һичнинди җәбер-золым кылынмас. Дәхи, һичбер җанга җәза бирелмәс, мәгәр эшләгән эшенең җәзасы бирелер, ягъни изге эш эшләгән булса — изге җәза, явыз гамәл кылган булса — явыз җәза бирелер. (54) Дөреслектә, бу көндә оҗмах ияләре мәшәкатьсез эшләрдә һәм нигъмәтләр белән ләззәтләнерләр. (55) Оҗмах ияләре һәм хатыннары — күләгәләрдә, зиннәтле сәкеләрдә таянып торырлар. (56) Оҗмах ияләре өчен оҗмахта тәмле җимешләр бар, дәхи, алар өчен сораган һәм теләгән нәрсәләре бар. (57) Мәрхәмәтле Раббеләреннән аларга сәлам бар, ягъни Аллаһы тәгалә оҗмах ияләренә фәрештәләр аркылы үзенең сәламен әйтә. (58) Әй, кяфирләр, бу көндә (кыямәт көнендә) мөэмин-мөселманнардан аерылыгыз! (59) Әй, Адәм балалары! Сезгә йөкләмәдемме, ягъни сезгә Аллаһыдан башкага гыйбадәт кылмау өчен, шайтанга гыйбадәт кылмаслык (шайтан сүзе буенча йөрмәслек) итеп дәлилләр билгеләмәдемме? Әлбәттә, билгеләдем! Дөреслектә ул шайтан — сезнең өчен дошманлыгы ап-ачык булган дошман! (60) «Миңа гыйбадәт кылу — тугры һәм хак юл. (61) Һәм, чыннан да, шайтан сездән күп халыкны аздырды. Иясез гакылыгызны ертып карап, шайтанның дошманлыгын белмәдегезме? (62) Бу — күзегезгә күренгән нәрсә — сезгә вәгъдә кылынган җәһәннәм. (63) Бу көндә дөньяда Аллаһыны танымаганыгыз, аны инкяр итүегез сәбәпле җәһәннәмгә керегез һәм эсселекне татыгыз! (64) Бу кыямәт көнендә адәмнәрнең авызларын мөһерләрбез, ягъни авызларын сөйләшүдән тыябыз һәм Безгә адәмнәрнең куллары сөйләр. Дәхи,

[1] Ягъни кояшлар һәм айлар, яки Кояш белән Айны телгә алу — йолдызларны белдергәнлеге өчен, йолдызлар — күчереп йөрүче мәгънәсендә булыр. Бу урында шуннан артык сөйләргә куәттән килмәде. Тәфсирчеләр, ягъни аңлатып бирүчеләр бәянынча, төрле сүзләр бар. Теләгән адәм мөрәҗәгать итәр. Ш. Хәмиди искәрмәсе.

аяклары гуаһлык (шаһитлык) бирер, ягъни кулларында һәм аякларында гөнаһ эзләре күренеп торыр, яки куллары һәм аяклары кылган гөнаһларын кәсеп кылган нәрсәләре белән дәлилләп бирер. (65) Һәм әгәр теләсәң — Без күзләрен сыйпап йомдырабыз, ягъни күзләрен бөтенләй бетереп сукыр кылырбыз. Шулай итеп, гадәтләнгән юлларына ашыгырлар, ә соң күзсез юлны ничек күрерләр. (66) Һәм әгәр теләсәң — баскан урыннарында сурәтләрен алмаштырбыз. Шулай итеп, барырга да, дәхи, кайтырга да көчләре җитмәс. (67) һәм кемдер ул кешегә озын гомер бирсәң, ул кешене яратылуда эшен әйләндерербез, ягъни ул кешегә куәт урынына зәгыйфьлек, яшьлек урынына картлык килер һәм дә зәгыйфьлеге артыр вә куәте кими барыр. Шулай итеп, кяфирләр белмәсләрме, ягъни бу эшләргә кодрәте җиткән Аллаһы — ничек каберләрдән кубаруга кодрәте җитмәсен? Кяфирләр Мөхәммәд пәйгамбәрне җырчы диделәр. Аллаһы тәгалә шуны кире кагып, телгә алыначак аятьне иңдерде. (68) Һәм Без Мөхәммәд пәйгамбәргә Коръән өйрәтүебез белән шигырь өйрәтмәдек, чөнки Коръән белән шигырьнең сүзләре дә, мәгънәләре дә башка. Дәхи, Мөхәммәд пәйгамбәргә шигырь яраклы да булмады. Безнең Мөхәммәд пәйгамбәргә өйрәткән нәрсәбез түгелдер. Ә өйрәткән нәрсәбез — вәгазь, дәхи, ап-ачык Коръән — гыйбадәтханәләрдә укыла торган, күктән иңгән бер китап. (69) Терек (гакыллы) булган адәмне куркытсын өчен Ул Коръәнне иңдерде. Белмәүче, аңсыз адәм — мәет хөкемендә булганга күрә Аллаһы тәгалә терек адәмне сайлады. Дәхи, кяфирлекләрендә ягъни динсезлекләрендә дәвам иткән адәмнәргә газап сүзе тиеш булсын өчен. (70) Әллә кяфирләр дөреслектә Без алар өчен Үзебезнең кодрәт кулларыбыз барлыкка китергән нәрсәләрдән дүрт аяклы хайваннар яратканыбызны белмәделәрме? Шулай итеп, ул кяфирләр ул дүрт аяклы хайваннарга хуҗа булып торалар. (71) Дәхи, Без ул дүрт аяклы хайваннарны ул кяфирләргә буйсынучы итеп кылдык. Шулай итеп, ул дүрт аяклы хайваннарга атланып йөриләр һәм ул хайваннарның итләрен ашыйлар. (72) Ул кяфирләр өчен ул дүрт аяклы хайваннарның йоннары һәм тиреләре кебек файдалары бар. Дәхи сөтләре һәм катыклары кебек эчемлекләре бар. Әллә бу кадәр нигъмәтләргә шөкер кылмаслармы? (73) Кяфирләр Аллаһының шулкадәр камил кодрәтен һәм ап-ачык нигъмәтләрен күрә торып та бер Аллаһыдан башка аллалар тоттылар. Аллалары тарафыннан ярдәм бирүләрен өмет иткәннәре хәлдә. (74) Аллалары кяфирләргә ярдәм бирүгә кодрәтле булмаслар. Хәлбуки, ул кяфирләр аллаларының ярдәме өчен хәзерләнгән гаскәрләр, ягъни «аллаларыбыз саклар һәм ярдәм итәр» дип хәзерләнеп торалар. (75) Шулай итеп, әй, Мөхәммәд пәйгамбәр, кяфирләрнең «Аллаһының тиңдәше бар» дигән сүзләре сине кайгыртмасын. Дөреслектә без кяфирләрнең яшерен эшләгән эшләрен дә һәм дә яшермичә эшләгән эшләрен дә беләбез. Һәркайсы кебек тиешле җәза бирербез. Хәшернең, ягъни үлекләрне терелтеп бер җиргә туплау көненең хаклыгын исбатлауда Аллаһы тәгалә телгә алыначак аятьне иңдерде һәм ул аятьнең иңүенә сәбәп шул: Хәләф углы Өбәй бер вакытта кулына корган сөяк тотып рәсүлуллага килде һәм ул сөякне кулы белән таратып күрсәтте һәм әйтте: «Әй, Мөхәммәд! Аллаһы бу корып һәм таралып беткән сөякне дә тергезә, дип ышанасыңмы?» — диде. Рәсүлулла әйтте: «Әйе, шулай дип ышанам, Аллаһы бу сөякне дә тергезер һәм сине дә җәһәннәмгә кертер»,— диде. (76) Әллә адәм (Хәләф углы Өбәй) белмәдеме: дөреслектә без адәмне мәни суыннан яраттык. Шулай итеп, шул вакытта адәм Безгә ачык һәм каты итеп дәгъва кыла. Үзен мәни суыннан яраткан Аллаһының кайтадан яратуын инкяр итә. (77) Корган сөяк белән безгә мисал итеп аңлатып бирде. Дәхи, үзенең нәҗес мәни суыннан яратылуын онытты. Ул адәм әйтте: «Бу сөякне кем тергезер? Хәлбуки, бу сөяк чергән һәм таралган»,— дип, ягъни бу сөякне череп һәм таралып беткәннең соңында әүвәлге халәтенә кем кайтарыр?» — диде. (78) Әй, Мөхәммәд! бу кешегә әйт син, бу сөякне әүвәл мәртәбә дә юктан бар кылган Аллаһы тергезер һәм Ул — Аллаһы бөтен халыкны аерып-аерып белүче һәм ничек яратачагын да белер. (79) Ул — шундый Аллаһыдыр. Ул — Аллаһы сезнең өчен яшел сулы агачтан ут чыгарыр. Шулай итеп, шул вакытта сез ул яшел агачтан сугып ут чыгарырсыз ягъни бу агачтан чыккан нәрсәнең ут булуында шикләнмисез, шулай булгач, яшел агачтан ут чыгарырга кодрәте җиткән Аллаһы — ничек итеп үлекләрне тергезергә кодрәте җитмәсен! Хәлбуки, яшел агачта утның капма-каршысы булган су да бар. (80) Әллә олуг булган күкләрне, дәхи җирләрне яраткан Аллаһының көче җитмәсме? Адәмнәрнең затта, сыйфатта охшашлыгы булган адәмнәрне яратуга яки күкләргә һәм

җирләргә карата кечкенәлектә һәм мескенлектә адәмнәрнең охшашлыгы булган адәмнәрне яратуга кодрәте җитмиме? мәгънәсендә. Әйе. Аллаһының кодрәте җитә һәм Ул — Аллаһы күп мәхлукълар, ягъни җан ияләре яратучы һәм күп белүче, ягъни Аллаһының мәхлукы һәм мәгълүматы күп. (81) Әгәр Аллаһы үзенең әмере белән берәр нәрсәнең барлыкка килүен теләсә, ул нәрсәгә «бар бул, син! дип әйтә һәм шулай итеп ул нәрсә барлыкка килә. (82) Шулай итеп кодрәтендә һәр нәрсәнең хуҗасы булган Аллаһы белән мәҗүсиләрнең сыйфатлаган нәрсәләре арасында ераклык бар. Дәхи Ул — Аллаһыга һәммәгез кире әйләнеп кайтырсыз. (83)

Иасин сүрәсенең тәрҗемәсе тәмам булды.

* * *

Бөек Аллаһы үзенең әҗер-савапларын насыйп итсен![1]

Әй, Мөхәммәд! Бөтен халыкның саф күңеленнән чыккан иң изге мөнәсәбәтләргә лаек булган кадерле Раббегә — синең Раббеңә мактау, дан булсын! Ике дөньяның да хуҗасы булган Аллаһыга гына мактау, дан булсын!

Дога бирү.

---

[1]Бу соңгы юллар Коръәннең аерым сүрәләрен тәмамлагач укыла.

## *Безнең календарь*

# Эдуард Касыймовның тууына 60 ел

Эдуард Салихҗан улы Касыймов 1930 елның 9 ноябрендә Киров өлкәсенең Слободский районы, Нократ авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. 1948—53 елларда Казан дәүләт университетында укыган. Шул елларда көндәлек матбугатта аның беренче иҗат тәҗрибәләре — очерк һәм хикәяләре күренә башлый. 1953 елда университетны тәмамлагач, Э. Касыймов башта Азнакайда, аннары Киров өлкәсенең Түбән Шөн урта мәктәбендә тарих укыта. 1957 елда ул Казанга килеп Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасына керә. Фән эшчесе буларак, фольклор белән ныклап шөгыльләнә.

1959 елда аның беренче китабы — «Кызыл маяклар», ә 1962 елда «Совет әдәбияты» журналында «Кояш көн дә чыга» исемле повесте басыла. Тагын ике елдан әдипнең «Гомер ике килми» исемле романы да дөнья күрә.

1965—67 елларда ул Алабуга дәүләт педагогия институтында укыта. 1966 елда филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Алабугада яшәгән чорда әдип «Томан аша», «Бир кулыңны, дустым», «Көмеш язулы кылыч», «Сорбонна профессоры һәм без» повестьларын иҗат итә. 1971 елда ул «Һаваларда тургай» романын тәмамлый. Бу роман русчага да тәрҗемә ителә һәм, Бөтенсоюз конкурсында катнашып, профсоюзлар белән СССР Язучылар берлегенең кызыксындыру бүләгенә лаек була.

1972 елдан әдип Чаллыга күчә. Биредә ул күп еллар буе «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә җитәкчелек итә, 1980 елда Чаллы язучылар бүлеге ачылгач, аның җитәкчесе була.

Эдуард Касыймов 1986 елда кинәт вафат булды.

## Рафаэль Мостафин

# ТЕЛЕБЕЗ ЯРЛЫ ТҮГЕЛ!

### Күршемнең кәефе нигә кырылды?

Минем күршем — «рәхмәт» белән «исәнмесез»дән тыш бер авыз сүз татарча белми торган кала татары — сүзлек сатып алган. Шатлыгы эченә сыймый:

— Бер сәгать чамасы чират торып алдым. Сугышып-тартышып, дигәндәй. Күптән шундыйны эзли идем...

Әлбәттә, ул русча сөйләшә. Әлегрәк туган теле турында уйлап та карамый иде. Соңгы елларда исә, гомуми шаукымга ияреп булса кирәк, милли хисләре кузгалды. Татар халкының тарихы, мәдәнияты, әдәбияты белән кызыксынып, «картаймыш көнемдә булса да» диеп, тел үзләштерергә ниятләнеп йөрде. Шактый абруйлы, югары белемле белгеч булса да, үзен бу яктан хаклы рәвештә надан кеше итеп хис итә башлады.

Сүзлек дигәне «Тематический русско-татарской словарь» булып чыкты. Төзүчеләре — Ф. Сафиуллина һәм Р. Галиуллин. Татарстан китап нәшрияты 1989 елда 14.700 данә белән бастырып чыгарган. Татарстан мәгариф министрлыгы сүзлекне кулланма-әсбап рәвешендә тәкъдим иткән. Эчтәлектә сүз төркемнәренең кайсы биттә урнашуы да күрсәтелгән. Куллану өчен бик уңайлы сүзлек, нәкъ күршем сыман тел өйрәнергә теләүчеләрне истә тотып эшләнгән. Телчеләребез дә кул кушырып утырмый, заманадан калышмаска тырыша, дип, эчемнән шатланып алдым.

Ләкин бер-ике көн үтмәде, күршем шактый күңелсез-ризасыз кыяфәт белән янадан килеп керде. Сүзлекне ачу белән өстәлгә бәрде дә:

— Сүзлек мондый булырга тиешменни? — дип, миннән сорау ала башлады.— Әллә мин бернәрсә дә аңламыйм, әллә телебез шундый хәлгә калганмы? Бу бит русчадан татарчага түгел, русчадан русчага тәрҗемә!

Һәм сүзлекне очраган бер җиреннән ачып, укып та күрсәтте:

— Физкультура — физкультура, спорт — спорт, стадион — стадион, ринг — ринг, корт — корт, трамплин — трамплин, тир — тир, бассейн — бассейн, каток — каток, зарядка — зарядка, гимнастика — гимнастика, тренировка — тренировка, клуб — клуб, команда — команда, капитан — капитан, секция — секция, тренер — тренер, разряд — разряд...

«Йә, кайсысы монда русча, кайсысы татарча?» Үзем дә аптырап калдым. Сүзлекне алып, үз күзем белән укып карадым. Барысы да дөрес. 135 нче бит, «Физкультура һәм спорт» бүлеге. Бер биттә 31 сүз китерелгән булса, 25 е һичниндиң үзгәрешсез «татарча»га әйләнгән дә куйган!

Башка бүлекләрне карыйм. Анда да шундый ук хәл. Мәсәлән, янәшә биттә генә урнашкан «Сәяхәт» бүлеге: поход–поход, туризм — туризм, турист — турист, экспедиция — экспедиция, экскурсия — экскурсия, экскурсовод — экскурсовод, гид — гид, багаж — багаж, чемодан — чемодан, сумка — сумка, рюкзак — рюкзак, гостиница — гостиница, номер — номер... Бу бүлектәге сүзләрнең дә яртысы (33 тән 15 е) шул көе калган. Туклану, йорт-җир, өс киеме, аяк киеме бүлекләрен ачып карадым — шул ук чама.

Тукта, мин әйтәм, нишләп «гостиница» булсын, «кунакханә» инч!. «Номер»ны да бездә «бүлмә» дип кенә йөртәләр. «Рюкзак»ны — «биштәр», «сумка»ны — «букча», «багаж»ны — «йөк», «ринг»ны — мәйданчык (бокс мәйданчыгы, көрәш мәйданчыгы), «тренировка»ны — «күнегү» («тренироваться» — сүзлектә күрсәтелгәнчә «тренировка ясарга» түгел, «күнегү үткәрергә»), «тренер»ны — «остаз», «капитан»ны — «башлык», «секция»не — «бүлекчә», «разряд»ны — «дәрәҗә» дип була... Һич югы янәшә, мәгънәдәш сүз итеп күрсәтелсен иде... Бу әле уйламый-нитми әйтелгән, башка беренче килгән сүзләр генә... Әзли төшсәң, тагы да табылыр иде.

Күршем мыскыллы итеп карап алды.

— Син шулай дип әйтәсең дә бит... Сиңа ышаныйммы, министрлык хәтле җаваплы оешма тарафыннан тикшерелеп расланган белешмәгәме?

Бераз җитдиләнеп, моңсу гына дәвам итте:

— Әйе, татар телендә рус сүзләренең күп булуын мин чама белән белә идем. Ләкин бу хәтле дип һич башыма да китермәдем... Дөресен әйткәндә, мондый телне өйрәнәсе дә килми. Шулай да татарның рус сүзләренә тәңгәл булырлык бер дә үз сүзләре юк мени?

Кием-салым бүлеген ачты да, китте тезеп, китте тезеп: джинсы — джинсы, шорты — шорты, сарафан — сарафан, блузка — блузка, жакет — жакет, юбка — юбка, свитер — свитер, джемпер — джемпер, пуловер — пуловер, кофта — кофта, купальник — купальник, плавки — плавки, майка — майка, трусы — трусы, комбинация — комбинация, пижама — пижама, халат — халат, бюстгальтер — бюстгальтер, лифчик — лифчик, пояс — пояс, шарф — шарф, кашне — кашне, зонтик — зонтик... Җитteme? Бу бары бер биттә, 40 нчы биттә китерелгән «татар» сүзләре генә!

Дөрес, арада бераз «татарлаштырып» бирелгән сүзләр дә бар иде: панталоны — панталон, перчатки — перчатка (хәтта «пирчәткә» дә түгел!) Ә инде арага ялгыш килеп кысылган «эшләпә» бөтенләй үз, чын татар сүзе булып яңгырады.

Көлкеме? Тик минем нишләптер елыйсым килде. Бигрәк тә фәкыйрь хәлгә калганбыз ич! Гасырлар буе яшәп килгән «билбау» «пояс»ка әверелгән (мисалы да китерелгән: широкий пояс — киң пояс», имеш), башкасын әйткән дә юк. Югыйсә, «бюстгалтер» һәм «лифчик»ны «күкрәкчә, «косынка»ны — кыек яулык», «босоножка»ны — «ачык туфли» яки, русчадан үрнәк алып «ялан тәпи», «гольфы»ны «озын оекбаш» дип булмый идемени?

Мин инде «җилән», «казаки» ише борынгы сүзләрне искә дә алмыйм. Сүзлектә аларның эзе дә юк.

Һич тә үземне тел белгече, тел остасы дип санамыйм. Авылда үскән бик күп каләмдәш дусларымнан аермалы буларак, мин шәһәрдә, рус балалары белән аралашып үстем. Русча укыдым, яздым, хәтта фикер йөрттем. Ана телемне дә ана сөте белән түгел, шуның ише сүзлекләрдән, әдәбият, тормыш аша үзләштердем. Шулай да сүзлектә китерелгән бик күп сүзләрнең колакка ят булуын ачык сизәм. Әйтик, «пассажир»ны — «юлаучы», «ванна бүлмәсен» — «юыну бүлмәсе», «шампунь»не — сыек сабын», «губка»ны — «диңгез мунчаласы», «парик»ны — «ясалма чәч», «завивка»ны — «бөдрәләндерү», «помазок»ны — «кырыну пумаласы», «пумалачык», «полка»ны — «киштә», «лезвие»не — «пычак йөзлеге», «бритва»ны — «пәке»,— дип әйтеп булмый идемени? Мондый мисалларны дистәләп, йөзләп китерергә була.

Күптән гамәлгә кергән, язма һәм сөйләм телебездә киң кулланган сүзләр дә нишләптер русчадан алынган сүзләр белән алмаштырылган. Мәсәлән, «бәдрәф» — «туалет»ка, «суүткәргәч» — «водопровод»ка, гап-гади «бөке» — «пробка»га, «чәнечке» — «вилка»га алмаштырылган. Дөрес, соңгы ике очракта сүз электр бөкесе һәм штепсель чәнечкесе турында бара. Вашта колакка ятрак булып тоелса да, үз сүзләрең булуы отышлырак, минемчә. Руста да мондый төшенчәләр беренче вакытларда сәеррәк булып яңгырагандыр. Һәрхәлдә, кеше кесәсенә кергәнче, үз букчаңнан эзләү хәерлерәк!

Менә ни өчен күршемнең кәефе кырылган! Менә ни өчен ул сүзлекне ташлап, кул селтәп чыгып китте...

## Кем гаепле?

Шулай да мин бөтен гаепне сүзлекне төзүчеләргә генә аударып калдырмас идем. Аларның сүзлеге озын чылбырның бер буыны, күптәннән килә торган сәясәтнең бер чагылышы гына. 1955 елдан башлап берничә томда яки шактый саллы бер томда чыккан русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләрне актарып карадым. Анда да хәл нәкъ шундый ук! Кайсысында азрак, кайсысында күбрәк, ләкин һәрберсендә дә кырык-илле (кайбер хәрефләр буенча — алтмыш-җитмеш) процент чамасы — рус сүзләре. Дөресрәге, рус теле аша кергән сүзләр, чөнки аларның күпчелеге — саф рус сүзләре дә түгел, башка телләрдән күчеп кергән төшенчәләр.

Без мондый күренешкә шулкадәр күнеккәнбез ки, хәтта «Советская Татария» газетасы битләрендә татар теленең факультатив дәресләрен алып барган чакта да (җитәкчеләре Казан педагогия институты галимнәре К. Бадыйков һәм З. Сәетов) 25-30 сүздән торган нәни генә сүзлек бирелсә, шуларның 20-25е рус сүзе була. Әйтик, газетаның 1989 ел, 15 ноябрь санындагы (нәкъ күршем белән сөйләшеп утырган көнне) дәрестә татар сүзләрен үзләштерергә теләүчеләргә шундый «саф татар» сүзләре тәкъдим ителә: археолог — археолог, балерина — балерина, бухгалтер — бух-

галтер, механизатор — механизатор, секретарь — секретарь, хирург — хирург һ. б. «Татарча»га әйләнгәннәре болай яңгырый: докладчик — докладчы, колхозник — колхозчы, нефтяник — нефтьче, тракторист — тракторчы...

Руслар кәлә: бер «чы» кушымчасы кушылган өчен генә тел өйрәнеп йөрүнең мәгънәсе юк, имеш. Күптән гамәлгә кергән, һич югы янәшә торырлык, синоним буларак кулланырлык — казынулар алып баручы тарихчы, биюче, хисапчы, сәркәтип, табип, нотык тотучы һ. б. шуның иже башка сүзләрнең булуын әйтеп карыйсың — ышанмыйлар. Акка кара белән баскач, ничек ышансыннар...

Бу күренешнең тамыры шактый тирәнгә китә. Милли тел белән астыртын көрәш 20-30 елларда ук башланды. Иң элек татар теленнән болгар чорыннан башлап мең ел дәвер эчендә әкренләп керә барган гарәп-фарсы сүзләре сөрелде. Аларның гомуми саны ун меңгә җитә. Күз алдыгызга китереп карагыз: әгәр, мәсәлән, рус теленнән латин яки төрки тамырлардан ясалган сүзләр сөрелсә, ни калыр иде? Телнең тамыры чабылып, ул корый, үлемгә йөз тота башлар иде. Күк йөзе өчен һәр йолдыз кадерле булган сыман, тел өчен дә һәрбер сүз кадерле ич!

Ләкин һөҗүм моның белән генә чикләнмәде. Төрки тамырлардан ясалган саф татар сүзләре булган очракта да алар урынына көчләп-көчләп рус сүзләре тутырылды. Мәсәлән, «батыр», «каһарман» ише сүзләребез була торып, «Советлар Союзы герое», — дип язабыз. Яки «һөнәр» («промысел») сүзе була торып, «һөнәрчелек» димибез, телне вата-җимереп булса да «промышленность» дип язабыз.

Һәр тел үз законнарына буйсынып үсә. Яңа төшенчә кергән чакта да тел иң элек үз мөмкинлекләреннән файдалана. «Холодильник», «пылесос», «лифт», «мороженое», «дезодорант» ише сүзләрне чын мәгънәсендә үзләштергән чакта, алар табигый рәвештә «суыткыч», «тузан суырткыч», «күтәргеч», «туңдырма», «һава сафландыргыч» кебек үз сүзләргә әверелә. Әгәр дә бу закон бозыла икән, әгәр телнең үзенчәлеге, аның табигате белән исәпләшмичә чит ят сүзләр «дыңгычлап» тутырыла икән, тел яшәү халәтен югалта, төп вазыйфаларын үти алмый.

Болар барысы да аңлы рәвештә, Сталинның «телләрне берләштерү» теориясенә таянып эшләнде. Чынында исә бу «теория» башка, бигрәк тә төрки телләрне бетерүгә, һич югы — хәлсезләндерүгә юнәлтелгән иде. Сталин үлгәч тә бу «теория» үлмәде, аның шаукымы торгынлык елларында да дәвам итте, тел байлыгыбызга бик күп зыян салды. Мәсәлән, 50 нче еллар ахырында бер төркем галимнәр «Волга» урынына «Идел» сүзен куллануы өчен Гомәр ага Бәшировка ябырылдылар. Югыйсә, гарәп-фарсы да, «дини» яки «феодаль-буржуаз» сүз дә түгел. 37 нче елларда исә бер сүз өчен башың Себер китә иде кайчак...

Тегe яки бу сүзләр яшәүенең төп билгеләмәсе итеп сүзнең тарихы да, язма әдәбиятта кулланууы да түгел, ниндидер мифик «гади кеше»нең аңлавы яки аңламавы алынды. Әйтик, район газетыннын тыш бернәрсә укымаган, «ярты»дан тыш бернәрсә белән кызыксынмаган Гайни ага аңласа — сүз яши. Аңламаса — чит сүз, «феодаль» яки «буржуаз» сүз дип сызып ташлана иде. Сызылган сүз урынына исә, үзеннән үзе аңлашыла, рус сүзе куып кертелә...

Шулай итеп, телнең таралу мәйданы тараю белән беррәттән, аның куллану сыйфаты да елдан-ел түбәнәя барды. Тел исә барысына да түзде-фәкыйрьләнде, бозылды, чүпләнде һәм, ниһаять соңгы чиккә килеп терәлде.

Шундый бер мәзәк бар. Имештер, ферма мөдире колхоз рәисенә әйтә икән: «Мин, алай бик кирәк булса, сөт савымын иртәгә үк илле процентка арттыра алам». Тегесе: «Ә йөз процентка арттыра алмыйсыңмы?» — дип сорагач, «Юк,— дигән,— алай иткәндә тоташ су гына була ул»,— дигән.

Шуның шикелле, тел дә чит сүзләрне күпмедер дәрәҗәдә күтәрә ала. Ләкин ниндидер чикне узгач (фән телендә ул «хәлиткеч нокта» дип атала), тел үзенең мөстәкыйльлеген тәмам җуя. Дөя аркасын сындырган соңгы салам бөртекләре сыман, чит сүзләр, артыкка китү белән, телнең умыртка сөяген сындыралар.

Трамвайда яки автобуста баручы кайбер милләттәшләребезнең «татарча» сөйләшүләрен тыңлап карагыз:

— Син миңа мозгиларны пудрить итмә, яме! Как хатын ул бер ни дә не представляет, ләкин аның душасы замечательный.

Шул булдымы инде «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле»?

Бер Казанда гына телче галимнәрнең саны ике йөзгә якынлаша, диләр. Ел саен татар теленең «үсеше» турында докторлык һәм кандидатлык диссертацияләр яклана. Фән үсә, яңадан-яңа уңышларга ирешә. Ә тел, мескен, әкренләп бетүгә таба бара...

Моңа кем гаепле? Сталин теориясеме, әллә аны тормышка ашыручы, шул теориягә нигезләнеп югары дәрәҗәгә, симез калҗага омтылучы тәлинкә тотучыларммы?

# Үзебездән тора

Үткән — беткән. Хәзер инде, үзгәртеп коруның алтынчы елында, бу турыда сөйләп тә тормас идек, әгәр дә... Әгәр дә иске гадәтләр, элекке карашлар бүген дә яшәүләрен дәвам итмәсә... Сүз уңаенда шуны да әйтеп китим: иң күп таралган, иң еш кулланыла торган сигез мең сүз арасында (сүзлек төзүчеләрнең әйтүенчә, аларны электрон-хисаплау машинасы белән сайлап алганнар) бүген бөтен дөньяга таныш булган «перестройка», «гласность» ише сүзләр юк. Машина гаепләме? Минемчә, бәла тирәндәрәк: әлеге сүзлектә үзгәртеп коруның, хәбардарлык чорының рухы сизелми, демократияләштерүнең яңа мөмкинлекләреннән файдаланырга теләк тә күренми.

Сүзлек кемгә дип чыгарылган? Кереш сүздә, рус телен өйрәнергә теләүче татарлар һәм татар телен үзләштерергә ниятләгән башка милләт кешеләре өчен, диелгән. Ләкин ике көймәнең койрыгын берьюлы тотып булмый бит! Андый киң максат куелгач, сүзлек бер вазыйфаны да рәтләп үти алмый.

Әйтик, русча өйрәнергә теләүче укучы бала сүзлектән өй җиһазларының русча исемнәрен белергә теләде, ди. Ачып карый: кран — кран, раковина — раковина, душ — душ, балкон — балкон, лоджия — лоджия, веранда — веранда, форточка — форточка, лампа — лампа, торшер — торшер, люстра — люстра... Телчеләр мондый парлы сүзләрне кертүне «уртак лексика» дип аклыйлар. Ләкин укучы балага моңардан ни файда? Әгәр ул бу сүзләрнең мәгънәсен элек тә белсә — бер хәл. Әгәр инде белмәсә, әйтик, авылда яшәсә, шулай белмәгән хәлдә калачак та, чөнки мондый «пар»ларның информацион кыйммәте — нульгә тиң. Әгәр без, чыннан да, рус теленә өйрәтергә теләсәк, бөтенләй башка төр сүзлекләр кирәк: аңлатмалы, рәсемле, җанлы сөйләмнән мисаллары булганы...

Сүзлекнең кереш сүзе һәм аңлатмалары русча язылгач, ахырдагы алфавит теркәгечтә дә рус сүзләре китерелгәч, аның төп адресаты — татарча өйрәнергә теләүчеләр булса кирәк. Ләкин аларга да мондый кабатлаулар берни дә бирми, чөнки алар бу сүзләрне болай да беләләр ич! Сүзлек төзүчеләр нинди генә дәлилләр китермәсен, мин бер үк сүзләрнең кабатланып килүенә катгый рәвештә каршымын. Чөнки сүзлек үзенең төп вазыйфасын — тәрҗемә итү, аңлату максатын югалта, аның информацион кыйммәте юкка чыга.

«Әгәр дә теге яки бу рус сүзе татар теленә кергән булса? Әгәр аның урынына башка татар сүзе булмаса, нишләргә?» — дип сораулары мөмкин. Әлбәттә, мин бу өлкәдә белгеч түгел. Шулай да «кара акыл» белән кайбер юнәлешләрне күрсәтәсем килә.

Төп юнәлеш, минемчә, бер: татар халкының тарихына, мәдәниятына, мең еллык әдәби казанышларына, тел байлыгына ныграк таянырга кирәк. Гаделсез сөрелгән, урынсыз «репрессияләнгән», нигезсез онытылган сүзләрне кайтарырга, торгызырга, аларга яңа рух өрергә вакыт. Артык гомумиме? Ярый, төгәлрәк сөйләшик. Сүзлек буенча барам. «Парикмахерская — парикмахерская». Әллә бездә беркайчан да чәч алмаганнар, төзәтмәгәннәр, тарамаганнармы? Бик матур, саф татар сүзе дә бар — «Чәчтараш». Ул нишләп онытылды соң? «Мебель — мебель». Мисалы да китерелә: «Мебельный магазин — мебель кибете». Ә нишләп «җиһаз» «өй җиһазлары» түгел? «Политика — политика», «культура — культура». Әйтерсең бездә беркайчан да сәясәт тә, мәдәният тә, мәдәни агымнар да булмаган һәм бу турыда XX нче йөз башы вакытлы матбугаты кызу-кызу бәхәсләр дә алып бармаган. «Сезон — сезон (Ел фасыллары турында), «Антракт — антракт» (Шул ук тәнәфес ич!), «Пауза — пауза». Минем, мәсәлән, мондый сүзнең русча әйтелешен гади сөйләмдә дә, язма әдәбиятта да очратканым юк. Кирәк булса, бер ара тынлык яки ял итеп алу,— дибез.

Сүзлек авторлары иң гади, халыкта киң таралган сүзләрне дә «күрмәмешкә» салышалар. «Виноград — виноград». Моңача халкыбыз «йөзем җимеше»н, «йөзем куагы»н, «йөзем җиләге»н белмәгән, бу төшенчәләрне кулланмаганмени? «Компот — компот». Әллә ата-бабаларыбыз җиләк-җимештән ясалган ширбәт эчмәгәннәрме? Бу сүз хәтта рус теленә дә кергән. «Микстура — микстура». Нигездә, бу шул ук дару ич! «Одеколон», «духи», «холл», «коридор», «кухня» кебек сүзләр белән янәшә, үзебезнең гасырлар буе яшәп килгән «ислемай», «хушбуй», «кунак бүлмәсе» яки «алгы бүлмә», «аралык», «аш-су хәзерләү бүлмәсе» кебек сүзләр дә куллана ала. Әлбәттә, бу аерым мисаллар гына. Һәркем яңадан-яңаларын китерә алыр иде.

Икенче юл: яңа төшенчәне телнең үз мөмкинлегенә, үз милкенә таянып тудыру. Югарыда бу турыда әйтелгән иде инде. Берничә мисал белән генә чикләнәм. «Грелка»-ны — «җылыткыч», «соус»ны — «аш тәмләткече», «столетникны» — «йөзъяшәр», «сквозняк»ны — «ашаҗил» дип була. Кайбер шундый юл белән барлыкка килгән сүзләр телебезгә бик табигый рәвештә кереп тә бара шикелле.

Дөрес аңларлар, дип уйлыйм: мин искиткеч бай, бөек, сыгылмалы рус телен

чын күңелдән ихтирам итәм, аны үземнең икенче туган телем дип исәплим. Ләкин «җен башка, пәри башка» дигәндәй, һәр телнең үз язмышы, үз юлы, үз байлыгы бар. Телләрне «кушып» та, «берләштереп» тә булмый. Сүз вә лөгать белән алмашкан тәкъдирдә дә, тел чит сүзне үз законнарына буйсындыра, фонетик вә грамматик яктан үзләштерә. Шул юл белән бездә «арыш», «өстәл», «бүрәнә», «марҗа» һәм шуның ише бик күп сүзләр барлыкка килде. Ләкин соңгы вакытта рус сүзен керткәндә аны ничек тә үзгәртмәскә, «имгәтмәскә», шул көе сакларга тырышалар. Башкача булса, укучыларыбыз рус сүзен үзләштерә алмаслар, аны язганда хата җибәрерләр, дип уйлыйлар, күрәсең. Әйтик, әлеге сүзлектә дә күптәннән кергән, үз ителгән «әфлисун» түгел — «апельсин», «гыйнвар» түгел — «январь», «фатир» түгел — «квартира», «плитва» түгел, «бритва» дип бирелгән. Мондый «чәйнәлмичә» йотылган сүзләрнең исәбе-хисабы юк.

Сүзлек төзү — иҗади эш. Ул туктаусыз эзләнү, казыну, яңача юллар табуны таләп итә. «Бу сүз бездә юк»,— дип, икенче телдән күчереп кенә утырмаска, кирәк икән, кыю рәвештә телнең үз җегәренә таянып, яңа сүзләр дә кертергә кирәк. Әлбәттә, сүзне халык үзе сайлый,— аны беркем дә көчләп тага алмый. Шулай булгач, сүзлек төзүче берничә вариант, тәңгәл килерлек синоним сүзләр китерергә тиештер.

Бу алым әлеге сүзлектә сирәк булса да кулланыла. Әйтик, «ничья» — «отышсыз уен», «легенда» — «риваять», «художник» — «рәссам», «ландыш» — «энҗе чәчәге», «космос» — «галәм киңлеге», «дрессировщик» — «хайваннар өйрәтүче» дип тә бирелгән. Бу алымны киңрәк кулланып, аны башка бик күп сүзләргә карата да кулланып булыр иде. Әйтик, «скульптор» дип кенә бирелгән. Ә бит соңгы елларда телебезгә бик матур «сынчы» сүзе кереп бара. «Класс — класс» («сыйныф кайда төшеп калды икән?), «колхоз — колхоз» («күмәк хуҗалык» сүзе дә күптән гамәлгә кергән бит!). Минемчә, әлеге юл белән сүзлеккә кергән рус сүзләренең барысына да булмаса да, күпчелегенә мәгънәдәш татар сүзләре табып булыр иде.

Сүзлекне төзүчеләр икенчерәк чиккә ташланып, саф татар сүзләре булганда да янәшәдә рус сүзе кертәләр. Әйтик, «букет — букет, чәчәк бәйләме», «атака — атака, һөҗүм». Минемчә, бу урыннарда рус сүзләре бөтенләй кирәкми, чөнки татар сүзе мәгънәне тулысынча ача. Җитмәсә, мисал рәвешендә «атаковать» сүзе «атакаларга» дип тәрҗемә ителә. Әйтеп кенә карагыз: «атакаларга» — нинди ямьсез, аңлаешсыз яңгырый! Үзебезнең күптән кергән, сыналган «һөҗүм итәргә» дигән сүз тезмәсе булганда бу бигрәк тә шулай... «Производство — производство, җитештерү». Мисалга «производственный план» тезмәсе китерелгән, әмма «җитештерү планы» дип түгел, «производство планы» дип тәрҗемә ителгән. «Справка — справка, белешмә». Монда да конкрет мисалга җиткәч, «медицинская справка» — «медицина справкасы» дип тәрҗемә ителә. «Ухаживать — илтифат күрсәтергә, ухаживать итәргә». Болай да шәһәр халкы телендә «печатать итәргә», «влюбляться итәргә», «разговаривать итәргә» дип сөйләшәләр. Әдәби тел өчен бу — һич килешмәслек хәл. Төзүчеләр — телче галимнәр — мондый вульгар сөйләмгә юл куймаска тиеш иделәр.

Татар фигыле — искиткеч бай, аның мөмкинлекләре таң калдыргыч. Шуңа күрә дә бездәге фигыль ассимиляциягә әлегә бирешми (моны әлеге сүзлектән дә күреп була — фигыльләрнең күпчелеге саф татарча калган). Ләкин бу юл белән рус тамырыннан «татар фигыльләре» төзи башласак — эшләр харап!

Сүзлек татар телен шактый фәкыйрь итеп, аның лексикасын бик нык тарайтып күрсәтә. Әйтик, русның «учитель, преподаватель, педагог» сүзләре барысы да бер сүз — «укытучы» дип кенә бирелә. Ә бит бездә борын-борыннан килгән «мөдәррис», «хәлфә», «мөгаллим» сүзләре бар... «Учащийся», «ученик», «школьник» — «укучы» дип кенә бирелә. Җанлы сөйләмдә исә, әлегәчә «шәкерт» сүзе дә яши. Горурланып, авыз тутырып: «Ул минем шәкертем»,— дип әйтәбез. «Общество — җәмгыять». Ләкин, кайбер очракларда бу мәгънәдә «ширкәт» сүзе дә кулланыла. Мәсәлән, «сәүдә ширкәте». «Мораль — мораль». «Әхлак» сүзенең ни гаебе бар, нишләп ул сүзлектән төшеп калган?

Мондый мисалларның иге-чиге юк. Шуның белән чикләнеп, тагы бер генә юнәлеш күрсәтеп китәсем килә. Әгәр инде һичничек тәңгәл сүз табылмый икән, урауракюл сайлап, мәгънәне аңлатмалы рәвештә биреп була ич. Бу юл да сүзлек төзүчеләргә күптән таныш. Әйтик, 1971 елда чыккан бер томлык «Русча-татарча сүзлек»тә шактый катлаулы терминнар һәм телебездә булмаган рус сүзләре шулай бирелгән. «Абсорбция — йоту, суыру, сеңдерү. Абсорбция газов — газларны йоту». «Абсцесс — абсцесс, эренле шеш». «Авангард — авангард», алдынгы отряд». «Абажур — абажур, лампа калфагы» һ. б.

Тематик сүзлектә исә бу алым бөтенләй диярлек кулланылмый. Гәрчә, бу очракта ул аеруча кирәк, аеруча урынлы булыр иде. Мәсәлән, «пароним — пароним». Әйт ул аеруча кирәк, аеруча урынлы булыр иде. Мәсәлән, «пароним — пароним». Әйт ул аеруча кирәк, аеруча урынлы булыр иде.

сүзлекләрдән карарга мәҗбүрмен. Кыскасы, әйтергә теләгәнем шул: хәзер инде беркем дә чит сүзләрне көчләп такмый. Барысы да үзебездән тора. Дөресрәге, конкрет эшне башкаручылардан.

## Кулланма була аламы?

Соңгы берничә ел эчендә Казанда һәм татарлар яши торган башка бик күп шәһәрләрдә татар телен өйрәтү буенча дистәләгән факультатив курслар, түгәрәкләр ачылды, түләүле һәм түләүсез дәресләр алып барыла. Мәктәпләрдә, вузларда, техникумнарда һәм башка уку йортларында да татар теленә өйрәнүгә игътибар нык артты. Бөз, ниһаять, кузгалды дип әйтергә була. Барысы өчен дә кулланма-әсбап кирәк. Шуңа да «Тематик сүзлек» чыгу белән таралып, сатылып бетте. Ләкин ул көтелгән бурычны тулысынча үти алыр микән?

Моңарчы мин сүзлекнең бер ягына — рус сүзләренең чамадан тыш күп булуына тукталган идем. Ләкин сүзлекнең башка җитди кимчелекләре дә җитәрлек. Ярлыландырылган, тарайтылган лексика нигезендә татарча матур җөмлә төзеп була микән? Менә сүзлектәге бүлек исемнәре: «Җан иясе буларак кеше» (Русчасы: «Человек, как живое существо»). Яки: «Ихтыяр актының мотивы» (Русчасы — «Мотив волевого акта»). Сәер яңгырый, шулай бит? Сүзләре татарча да кебек, җөмләсе русчадан күчереп алынган сыман тәэсир итә. Кыскасы, «чыктым аркылы күпер» килеп чыккан!

Кайвакыт сүзлектәге татар сүзләре дөрес бирелгән, әмма шуларны расларга тиешле мисаллар шик уята. Мәсәлән, «пудра» — «пудра» дип тә, «кершән» дип тә бирелгән (югыйсә, соңгысы да бик җиткән иде!) Ә мисал өчен китерелгән «компактная пудра» «компактлы пудра» дип тәрҗемә ителә. «Каты кершән» дип әйтергә дә була иде ич! «Сок яблочный — алма согы». Ни өчен «алма суы» түгел? «Женский характер — хатын-кызлар холкы» турында бара булса кирәк...

Сүзлектә җитди төгәлсезлекләр, мәгънә хаталары да күп. Әйтик, «Бодрый старик» — «таза карт»,— дип тәрҗемә ителә. Ләкин «таза» — «крепкий» дигән сүз. Монда исә «күтәренке күңелле» «җитез карт» турында сүз бара. «Флюс — чуан». Юк, «чуан» «фурункул» мәгънәсен бирә, ә «флюс» — «яңак шеше». «Пухлые щеки — тулы яңак». «Тулы» — «полные». Монда исә «кабарынкы яңак». «Кривые зубы — тигезсез тешләр». Юк «тигезсез — неровные». Бу очракта исә — кәкре тешләр».

Кайбер күрсәтелгән төгәлсезлекләр вак нәрсә кебек тоелырга мөмкин. Ләкин бу бит киң катлам укучыларга кулланма, өйрәнү, татар телен тирәнрәк аңлап, шул телдә уңышлырак эш итү өчен чыгарылган белешмә. Аның һәр сүзе, һәр мисалы эталон, кагыйдә булып кабул ителәчәк.

Минем мондый катгый фикерләрем белән килешмәүчеләр дә табылыр. Табылыр гына түгел, алар — бар. Мәсәлән, КДУ доценты, филология фәннәре кандидаты М. Хәйруллин үзенең әлеге сүзлеккә язылган рецензиясендә («Социалистик Татарстан» газетасы, 1989 елның 17 декабрь саны) тематик сүзлекне күккә күтәреп мактый, аның бер генә кимчелеген дә күрми. Аныңча, әлеге сүзлек «укучылар, студентлар, укытучыларның, һәр ике телне өйрәтүчеләрнең практик яктан сөйләм телен үстерүгә аеруча зур өлеш кертәчәк». Автор сүзлекне «кирәкле, заман таләбенә җавап бирерлек» кулланма-әсбап дип атый, аның тел үзләштерүче киң укучылар катламының ярткан китабына әверелүенә ышана.

Чыннан да, бәлки мин, тәнкыйть белән мавыгып китеп, сүзлекнең бер уңай ягын да күрмәгәнмендер? Әлбәттә, сигез мең баш сүз арасында уңышлы тәрҗемә ителгәннәре дә бар. Әйе, кайвакыт төзүчеләр, сүзгә-сүз, «калька» рәвешендә тәрҗемә итүдән котылып, максатка иҗади рәвештә якын килгәннәр, уңышлы мисаллар биргәннәр: «мотор действует безотказно — мотор төгәл эшли», «часы стоят — сәгать йөрми» һ. б. Ләкин аерым уңышлы мисаллар гына сүзлекне коткара алыр микән?

Соңгы сүзне киң укучылар массасы, халык үзе әйтергә тиеш. Сүз бит, ахыр чиктә, бер конкрет кулланма турында гына бармый. Сүз безнең газиз телебез, аның бүгенге хәле һәм киләчәге турында бара.

**Энҗе Сәгыйдова,**
*педагогия фәннәре кандидаты*

# ГАЛИМ, ПЕДАГОГ, ЖУРНАЛИСТ...

Меңтугыз йөз бишенче-алтынчы елларда татар вакытлы матбугатын оештыруда, татар журналистикасына нигез салуда зур хезмәт куйган кешеләрнең исемнәрен барлаганда, һичшиксез, Габделкәрим Мөхәммәтша улы Сәгыйдовны да хөрмәт белән искә алу — изге бурычыбыз. Чөнки аның үткен каләме белән бер татар халкының гына түгел, ә башка төрки кардәшләребезнең дә тарихына, мәгърифәтчелек хәрәкәтенә, мәдәнияте һәм әдәбиятына, шулай ук милли нәшрият мәсьәләләренә багышланган бихисап мәкаләләр язылды. Татар газета һәм журналларында ул һәрвакыт «Кәрим Сәгыйд», «К. Сәгыйд», «К. С.», «К.», «Сәгыйдов», «Мин», «Петербург хәбәрчесе» дигән имзалар белән чыгып килде.

К. Сәгыйдов тиз аралашучан, бик кызыксынучан, киң эрудицияле кеше булу ягыннан да яхшы мәгълүм. Аның әдәби һәм журналистика эшчәнлеге татар интеллигенциясенең танылган вәкилләре белән турыдан-туры бәйле иде. Күп еллар дәвамында ул Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, Ф. Кәрими, Г. Камал, Гыйльметдин һәм Галимҗан Шәрәфләр, Җ. Вәлиди, Г. Исхакый кебек күренекле әдипләр, мәдәният әһелләре, галимнәр белән дустанә һәм эшлекле элемтәдә булды.

Кәрим Сәгыйдов 1888 елның 5 сентябрендә (яңа стиль буенча) Казан губернасы Тәтеш өязе Кыр-Тәүгилдесе авылында хәлле гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килгән. Әтисе Мөхәммәтша абзый, үз заманында Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре мәдрәсәсендә укыган кеше буларак, балаларын да тиешле дәрәҗәдә гыйлемле итәргә тырышкан.

Аннан соң Буа мәдрәсәсендә белем алган вакытында Кәрим яхшы итеп гарәп каллиграфиясен үзләштерә, Коръәнне мәкам белән җиңел итеп укырга өйрәнә, гарәп, фарсы, төрки телләр нигезләре серләренә тирәнтен төшенә, Шәрык әсәрләре белән ныклап таныша. Алга таба да һәрчак белемен күтәрү өстендә эшли, экстерн юлы белән Алабуга укытучылар институтын тәмамлый. Шулай ук үзлегеннән чит телләрне өйрәнүне дә кирәкле бер шөгыль итеп саный. Тәрҗемә эше дә аның өчен ят түгел иде. Ул күренекле библиограф һәм язучы Н. А. Рубакинның «Китаплар арасында» кебек хезмәтләрен җитди игътибар белән тәфсилле өйрәнде, аның «Вакыт караңгылыгыннан якты киләчәккә» исемле китабын татар телендә бастырып чыгарды.

Тынгысыз эзләнүләр, чит телдә язылган әсәрләрне нөсхәдә уку Кәрим Сәгыйдовка тел белемендә генә түгел, палеография фәне өлкәсендә дә шактый тирәнтен тәҗрибә тупларга ярдәм итте һәм аны археограф, кульязмалар буенча төпле белгеч буларак та танытты.

1905 елгы революция шартларында Россиядә эшчеләр хәрәкәте үсешен, илдәге хәл-вакыйгаларга объектив бәя биреп, урыннардагы төрле милләт гавәмнәренә дөрес итеп аңлату таләп ителә иде. Нәкъ шушы вакытларда яшь Кәрим бөрадәран Кәримовларның Оренбургтагы типографиясенә хәреф җыючы һәм корректор булып эшкә керә. Биредә эшләү дәверендә ул үзенең беренче мәкаләләрен «Фикер» газетасында һәм «Әл-гасрел-җәдит» журналында бастыра. Аның бу мәкаләләре Г. Тукайны да кызыксындыра. Тиздән алар хат алыша башлыйлар, нәтиҗәдә, ике арада дустанә мөнәсәбәт урнаша.

1907 елда Оренбургта К. Сәгыйдовның үз тәрҗемәи хәленә нигезләнеп язылган «Әдрәс бишмәт» исемле повесте китап булып чыга. Ләкин Сәгыйдовка биредә озак

эшләргә һәм яшәргә насыйп булмый. Типография эшчеләренең баш күтәрү хәрәкәтендә катнашканы өчен полиция эзәрлекләвеннән яшеренеп, тиздән Петро-Александровский (хәзерге Каракалпак АССРындагы Дүрткүл) шәһәренә китәргә мәҗбүр була. Анда барып, мөгаллимлек итә башлап бер ел да тулмастан, урындагы полициянең «ышанычсыз» кеше дигән күрсәтмәсе нигезендә бу эштән дә читләштерелә. Шуннан соң ул бер кибеткә приказчик булып урнаша. Бер үк вакытта әдәбият һәм журналистика өлкәсендә эшчәнлек алып бара. Нәтиҗәдә, «Бохарага сәяхәт» (Казан, 1909) исемле әсәре дөнья күрә. Шул ук елда Хива ханлыгында яшәүче халыкларның тарихи-этнографик яктан бәян ителгән тормыш-көнкүреше, мәдәнияты, әхлакый холкы турындагы мәкаләләре «Шура» журналында бер-бер артлы басыла.

Кәрим Сәгыйдовның «Авыл баласы» дигән икенче китабы 1910 елда Казанда «Милләт» матбугасында нәшер ителә. Аның өчен куанычлы булган бу вакыйга Г. Тукай белән очрашып, алга таба әдәби эшчәнлектәге уй-фикерләр белән уртаклашып-сөйләшеп йөргән көннәрнең берсендә була. Кәрим шагыйрь дустына тиздән Петербургка барачагын әйтә һәм аннан татар газета-журналлары өчен хәбәрләр җибәреп торырга ниятен белдерә.

Башкалага килгәч, К. Сәгыйдов яшәү өчен акча юнәтү максатыннан Г. З. Понизовскийның мануфактура келәтендә эшли башлый, шул ук вакытта мәкаләләр язу белән дә мәшгуль була. Мәгълүм булганча, 1912 елда Г. Тукай Петербургка килә. Ике дусның бирелдәге очрашулары соңгысы була.

Бу вакытларда Кәрим Сәгыйдов «Кояш» газетасының Петербургтагы рәсми хәбәрчесе булып исәпләнә. Аның тарафыннан төрле темаларны яктырткан саллы мәкаләләр шулай ук «Вакыт», «Әл-Ислах», «Сүз» газеталарында, «Шура», «Ак юл», «Мәктәп» һ. б. журналларда һәрвакыт үз укучыларын табып тора. Аның иҗади журналистика эшчәнлеге туган халкына кайнар мәхәббәт хисләре белән сугарылган иде. Күп кенә басмаларында ул татар әдәбиятын пропагандалады, татар вакытлы матбугаты («Шура», «Мәгълүмат») турындагы библиографик белешмәләр язды. Журналлар өчен язылган мәкаләләренең күбесе сәнгать, тел белеме, икътисади мәсьәләләргә багышлана. Мәсәлән, «Азәрбайҗандагы татар театр сәнгате тарихыннан очерклар» (Татар театрының 25 еллык юбилее уңае белән чыгарылган җыентык. Казан, 1926), «Татар телендәге терминологияләргә гыйльми анализ» («Мәгариф», 1928, 1—3 саннар), «Тюрколог В. В. Радлов һәм аның үткәне» («Аң», 1917, 23 сан), «Татар республикасындагы сәүдә һәм промышленность конторалары» («Безнең юл», 1923—24, 5, 10—11 саннар) моның ачык дәлилләре.

Кәрим Сәгыйдов илнең иҗтимагый тормышыннан бер вакытта да читтә булмады. Педагогика, мәгариф мәсьәләләре белән дә үтә кызыксынучан кеше буларак, Петербургта 1913 елның 23 декабреннән 1914 елның 1 гыйнварына кадәр үткәрелгән халык мәгарифе Беренче Бөтенроссия съездында катнашты. Бу турыдагы тәфсилле хәбәрләрне ул «Мәктәп» (1913, 14 сан; 1914, 1 сан) журналында язып чыкты. Соңга таба, кайбер фәннәр буенча татар телендә уку әсбаплары җитешмәү ихтыяҗларын истә тотып, җитди рәвештә китаплар төзергә алына. Нәтиҗәдә, урта мәктәп һәм техникумнар өчен татар телендә «Табигать белеме» (Казан, 1920), «Зоология» (Казан, 1924), «Энергия» (Казан, 1932) һ. б. әсбаплар укучыларга барып ирешә.

К. Сәгыйдов үз вакытындагы башка билгеле хәл-вакыйгаларның да уртасында булды. 1917 елның 1—11 май көннәрендә Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнары съезды үткәрелә. Ул Бөтенроссия мөселман Башкарма комитетының әгъзасы һәм техник сәркатибе була һәм бик җентекләп съездның беркетмәсен язып бара, аны соңыннан татар телендә бастырып та чыгара. Съезд барган көннәрдә аның тарафыннан һәр киңәшмә турындагы хәбәрләр урыс телендә чыга торган «Утро России» газетасы битләрендә яктыртылып бара.

Мәгълүм булганча, Октябрь социалистик революциясеннән соң бер айдан артык вакыт үтү белән яшь Совет хөкүмәте В. И. Ленин кул куйган «Россия һәм Шәрык мөселман хезмәт ияләренә» дигән мөрәҗәгать белән чыкты. Анда закон каршында барлык дин тотучылар да бертигез булуы һәм хөкүмәтнең аларга ихтирамлы мөнәсәбәттә булачагы әйтелгән иде. Шуннан соң Россиядә яшәүче мөселманнар изге «Госман Корьән»ен үзләренә кире кайтарып бирүләрен сорап Совет хөкүмәтенә мөрәҗәгать иттеләр. Халык Комиссарларының милләтләр эше буенча бүлегенә бу хәбәр килеп керү белән, В. И. Ленин 1917 елның 6 декабрендә «һич кичекмәстән бирергә!» дигән күрсәтмә юллый. Ә инде 9 декабрьдә А. В. Луначарскийга үзәк китапханә фондларында 1869 елдан бирле саклана торган «Госман Корьәне»н съезд вәкилләре У. Токумбетов һәм К. Сәгыйдовларга тапшырырга кушыла. Шулай итеп, Кәрим Сәгыйдов, милли парламент әгъзасы буларак, Совет хөкүмәте тарафыннан эшләнгән тарихи актта турыдан-туры катнаша.

1917 елның август аенда К. Сәгыйдов татар теле укытучысы Хәлисә Шәрәфкә

өйләнә һәм алар 1918 елның март аенда Казанга күчеп киләләр. Биредә ул башта укытучылык эше белән шөгыльләнә, шул ук вакытта Татарстан җир эшләре буенча Халык Комиссариаты тарафыннан чыгарыла торган «Игенче» журналы һәм «Авыл хуҗалыгы бите» исемле газетаның рәсми хәбәрчесе дә булып санала. 1923-24 елларда Татарстан Мәгариф Комиссариатының «Безнең юл» дигән гыйльми-сәяси һәм иҗтимагый-әдәби журналына да хезмәттәшлек итә.

1934 елда К. Сәгыйдов СССР Фәннәр академиясенең Тарих-археография институты чакыруы буенча гаиләсе белән Ленинградка күчә һәм бу институтка беренче разрядлы фәнни хезмәткәр итеп кабул ителә. Биредә ул үткән гасырларда язылган кулъязмаларны өйрәнә, аларны урыс теленә тәрҗемә итә. Бу эшне бик яратып һәм вакытын кызганмыйча башкара. Ел ярым эшләү вакытында ул 500 том күләмендәге кулъязмаларны өйрәнә. Әйтергә кирәк, алар арасында 1755 елгы халык кузгалышы җитәкчесе каһарман Батырша Алиев хатлары да бар. Профессор Н. К. Дмитриев Кәрим Сәгыйдов эшчәнлегенә болай дип бәяләмә бирде: «Сәгыйдов башкарган эш нык канәгатьләнү хисе тудыра. Татар, чыгтай, гарәп телләреннән камил хәбәрдар булуы сизелеп тора, Шәрык кулъязмаларын, иске документларны, аларның телен өйрәнүгә бик һәвәсле. Янә аның урыс телен дә яхшы белүен исәпкә алсак, кыю әйтергә мөмкин, К. Сәгыйдов институт тарафыннан җәлеп ителгән тәрҗемәчеләр арасында иң остасы булып санала. Бу эшне (әлегә кадәр лингвистик һәм палеографик яктан тикшерелмәгән беренчел чыганакларны өйрәнү) К. Сәгыйдов уңышлы башкара».

1935 елның сентябрь аенда К. Сәгыйдов иран сәнгате һәм археологиясе буенча Ленинградта үткәрелгән Халыкара конгресста катнаша, анда чыгыш ясый. Аны башка гыйльми җыелышларда, конференцияләрдә дә бик еш күрергә була иде ул вакытларда.

Шулай барлык белемен, тәҗрибәсен кулланып, нәтиҗәле генә эшләп йөргәндә, Кәрим Сәгыйдов 1936 елда нахакка гаепләнеп, кулга алына. Бу вакытта аңа әле 48 яшь кенә була. Ә инде 1939 елда ул мәңгелеккә юк ителә. Бары тик 1957 елда гына безгә аны аклый торган «... җинаять эшләре булмау сәбәпле...» дигән белешмә бирелде.

# ГАФУР КОЛӘХМӘТЕВНЫҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН ХАТЫ

*Гафур Коләхмәтев Пенза губернасыннан 1918 елны Милли мәҗлескә вәкил булып сайлана. Шул уңай белән ул Уфага барырга тиеш була һәм якын танышлары Гариф Сәйфетдинев белән Нургали Әминевкә берничә хат яза.*

*Гариф Сәйфетдинев — телче галим Фатих Сәйфи-Уфалының бертуган абыйсы, «Галия» мәдрәсәсенең хуҗалык эшен башкара. Атаклы биюче Нургали Әминев — «Нур» труппасының актив һәвәскәре, С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның биюдә пардашы. Нургали Әминевнең апасы Фәсахәт ханым — Уфа татар хатын-кызлар җәмгыятенә ярдәм иткән кеше, Уфаның зур меценаты Садрый Нәзиревнең хатыны. Садрый Нәзирев «Галия» һәм «Госмания» мәдрәсәләренә күп акча сарыф иткән шәхес. Ул 1925 елда Казанда вафат була.*

*Г. Коләхмәтевның яңа табылган хатын матбугатка тәкъдим итәм. Кызганычка каршы, Коләхмәтевның башка хатлары сакланмаган. Фото һәм хат матбугатта беренче тапкыр басыла.*

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН,**
**сәнгать фәннәре кандидаты.**

Гариф җаным!

Мин кичә Казаннан мәктүп алдым. Алар миңа язалар, син минем адресымны сорап язгансың, дип. Бу минем өчен бик гаҗәп бер нәрсә. Чөнки үктәбер аенда мин Уфага Нургали әфәнде исеменә мәктүп яздым. Ул мәктүптә Нургали әфәндегә вә сиңа да бер йомышымны яздым. Күрәсең, ул мәктүпне сез алмагансыз. Минем йомышым шул иде. Мин

Пенза губернасыннан Милли мәҗлескә вәкил булып сайланган бер адәм. Бу сәбәптән мин Уфага барып торырга тиеш булган идем. Менә Нургали дә вә син дә бөтен Уфага таныш булганга, сез миңа бер яхшы гына бүлмә яки бөтен пансионы берлә бер урын табып бирерсез дип ышанып мәктүп язган идем. Һәм ике адресымны язып күрсәткән идем. Ярый, булган эш булган. Мәҗлес ачылды инде. Әмма мин Уфага һаман бара алмыйм. Чөнки миңа бик каты салкын тиеп, бик каты авырдым. Хәзердә дә авырыйм әле һәм шул сәбәптән мәҗлескә дә бара алмыйм. Сәламәтлегем яхшыргач та барачакмын һәм сезнең берлә күрешәчәкмен вә бик шат булачакмын!

Мин хәзер, Гариф җаным, авыру килеш кардәшем Суфиядә ятам. Адрес менә шул:

Базарная Дубровка, Пензенской губ., имение Л. Д. Бакулина, с. Агеевой.

Һәм миңа әгәр буңа каршы бер мәктүп язып йибәрсәң, бик шат булырмын. Суфия берлә Ислам бик яхшы торалар. Суфия үз эшендә. Ислам волость рәисе булып бик деловой сыман булып йори. Алар бик күп әйтеп сәламләр укыйлар.

Тагын ни языйм, җаным? Бунда, авылда, хәбәрләр юк. Хәбәрләр сездә күп булырга кирәк. Чөнки сездә Милли мәҗлес бар, аның вәкилләре бар. Күбесе яңа адәмнәр, интересный адәмнәр булырга кирәк. Чөнки вәкил бит алар.

Хәзергә сәламәт бул.

Нургалигә вә барчасына күп-күп сәлам.

Дустың Гафур Коләхмәдев.



**Рәсемдә**: *калфактан һәм сул якта утырганы — Фәсәхәт ханым, аның янында басып торганы — сеңлесе Кәримә, уртада Г. Коләхмәтев утыра, аның янында басып торалар Нургали белән Гариф Сәйфетдинев, уң якта Гарифның хатыны Мәймәнә ханым. Фотога 1916 елда Ялтада төшкәннәр.*

## ТАТАРСТАН — АКШ

Татарстан республикасының сәяси мөстәкыйльлек алуы аңа экономикасын үстерү, чит илләр белән турыдан-туры бәйләнешләр булдыру мөмкинлеге ачты.

12—20 октябрьдә Татарстан ССР Министрлар Советы Рәисе М. Г. Сабиров җитәкчелегендәге республика делегациясе Америка Кушма Штатларында булып кайтты. Делегация Нью-Йорк, Оклохома, Хьюстон һ. б. шәһәрләрдә булды, алардагы фирма җитәкчеләре, сәяси эшлеклеләр белән очрашты.

Сөйләшүләр нәтиҗәсендә Американың аерым фирмалары белән эшлекле хезмәттәшлеккә нигез салынды.

## ФӘН ҺӘМ ВУЗЛАР ТУРЫНДА

Базар экономикасы һәм республиканың суверенитетлыгын ныгыту шартларында фәнне үстерү, югары уку йортларының эшчәнлеге мәсьәләләре 25 сентябрь көнне ТССР Министрлар Советы Президиумы утырышында каралды. Анда күп кенә вузларның һәм СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәге җитәкчеләре катнашты.

Вузларның мөстәкыйльлеген күтәрү, аларның материаль базасын ныгыту, өстенлекле фәнни юнәлешләрне үстерү, белгечләр әзерләүнең һәм фәнни тикшеренүләрнең сыйфатын күтәрү, вузларның хокукый яклангалылыгын тәэмин итү, Татарстан Фәннәр академиясен булдыру — республикада югары уку йортларын һәм вузларда фәнне үстерүнең төп юнәлешләре итеп билгеләнде.

Киңәшмәне ТССР Министрлар Советы Рәисе М. Г. Сабиров алып барды һәм чыгыш ясады.

## ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ КОРЫЛТАЕ

12—15 октябрьдә Казанның Актерлар йортында татар яшьләренең беренче корылтае булып узды. СССРның төрле төбәкләреннән (Сарытау, Самара, Мәскәү, Кырым, Новосибирск, Төмән, Башкортстан...) һәм республикабыздан җыелган делегатлар, кунаклар саны 200ләп иде.

Анда яңа төзеләчәк Татар Яшьләре Оешмасының уставы һәм эш программалары каралды. Чыгыш ясаучылардан Ирек Гарипов, Фәрит Бәшири (Казан), Дамир Сираҗетдинов (Мәскәү), Үлвия Аблаева (Кырым) һәм башкаларның фикере уртак иде: Татар Яшьләре Оешмасы төзелү зарур һәм ул милләт алдында торган мөһим проблемаларны хәл итүгә җитди өлеш кертергә тиеш.

Корылтай белем һәм мәдәният, бүгенге сәяси хәл, хәрби хезмәт турында резолюцияләрне тикшерде.

«Азатлык» дип аталган татар яшьләре берлегенең оештыру корылтае оешма эшчәнлеген тәэмин итү өчен Үзәк шура һәм аның рәисе итеп Татар иҗтимагый үзәгенең актив эшлеклесе, Казан ветеринария институты студенты Ирек Гариповны сайлады.

## ХӘТЕР КӨНЕ

14 октябрьдә Татар иҗтимагый үзәге, «Иттифак» милли бәйсезлек партиясе Иван Грозный Казанны алганда һәлак булучылар истәлегенә Хәтер көне үткәрде. Ирек мәйданыннан Сөембикә манарасы янына кадәр сузылган халык ташкыны, тәкбир әйтеп баручы дин әһелләре, милли байраклар астында бердәм сафта атлаучы татарлар, әзербайҗаннар, нугайлар, үзбәкләр, литвалылар — барчасы да халкыбызның ачы язмышын, кайгылы тарихын күңелләренә салганнар иде. Сөембикә манарасы янында, әби-бабаларыбызның изге рухына багышлап, ясин чыгу булды. Тарихчылар исә бабаларыбызның көрәше турында яңа мәгълүматларга бай булган чыгышлар ясадылар.

## КИТАПХАНӘГӘ 125 ЕЛ

Татарстан ССРның В. И. Ленин исемендәге Үзәк фәнни китапханәсенә 125 ел тулу уңае белән 16 октябрьдә китапханәнең уку залында республикабыз районнарыннан һәм илебезнең төрле төбәкләреннән килгән мәдәният хезмәткәрләре, китапханәчеләр катнашында «Милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм китапханә» дигән фәнни-практик конференция булды. 17 октябрьдә К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында Китап бәйрәме һәм юбилей тантанасы үткәрелде.

## ТАТАРСТАН — ТӨРКИЯ

Татарстан Республиканың чит илләр белән элемтәсе көннән-көн ныгый бара: уртак предприятиеләр оеша, сәүдә мөнәсәбәтләре юлга салына, дуслык җәмгыятьләре төзелә. Сентябрь аенда Казанда «СССР — Төркия» дуслык җәмгыятенең Татарстан бүлеге оешты. СССР Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең физика-техника институты директоры, Ленин премиясе лауреаты профес-

сор К. Салихов житәкчелегендә җәмгыятьнең идарәсе сайланды. Аңа мәдәният хезмәткәрләре, дин әһелләре, хөкүмәтебез вәкилләре, фән эшлеклеләре, предприятие житәкчеләре һ. б. керделәр. Җәмгыять Төркия дәүләте белән икономик, мәдәни, фәнни элемтәләрне юлга салу юнәлешендә эш башлады.

## ТАТАР ГАЛИМЕ ТӨРКИЯДӘ

5—10 сентябрьдә Төркиянең башкаласы Әнкарада Төрек тарих корымы (җәмгыяте) тарафыннан оештырылган XI халыкара Тарих конгрессы булды. Дистәләгән иллэрдән килгән берничә йөз галим катнашкан бу конгресста Казан дәүләт университеты проректоры профессор Миркасыйм Госманов «XV—XVIII йөзләрдә Рус дәүләтенең көнчыгыш илләре белән дипломатик бәйләнешләрендә татар теленең урыны» дигән темага төрек телендә доклад ясады. М. Госманов Әнкарада булган вакытта Төркиядә яшәүче якташларыбыз профессор, доктор Әхмәт Тимер, Мәрмәрә университеты доценты, доктор Надир Дәүләт, инженер һәм җәмәгать эшлеклесе Мәхмүт Таһир, Фазыл Агиш һәм башкалар белән очрашты. Күренекле татар җәмәгать эшлеклесе Садри Максудиның кызы, Төркиянең Италиядәге элеккеге илчесе Адилә ханым Айда әтисенә Гаяз Исхакый тарафыннан язылган хатларның күчермәләрен М. Госманов аша Казанга юллады. Мәхмүт Таһир Казан университеты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә Төркиядә 11 ел дәвамында чыгып килгән «Казан» журналының тулы төпләмәләрен, егерменче елларда Харбинда татар телендә чыккан «Ерак Шәрык» журналының дистәләгән нөсхәләрен һәм күренекле татар галиме, язучы Риза Фәхретдиневнең 20-30 елларда Финляндия татарларына язган биш хатының төп нөсхәләрен бүләк итте. М. Госманов бу сәфәр вакытында Казан университеты белән Истанбул, Мәрмәрә, Әнкара университетлары арасында хезмәттәшлек урнаштыру турында сөйләшүләр алып барды.

## ШАТЛЫКЛЫ ВАКЫЙГАГА БАГЫШЛАП

21 октябрьдә Казан консерваториясенең зур концерт залында кичә булды. Сөембикә манарасына ай куюга багышланган әлеге тамашада органчы Рубин Абдуллин, композитор Мәсхүдә Шәмсетдинова, җырчылар Зилә Сөнгатуллина, Вафирә Гыйззәтуллина, язучылар Батулла һәм Әхмәт Рәшиди, нәфис сүз остасы Илдус Сафин һәм башкалар чыгыш ясады.

## ӨЧЕНЧЕ АНСАМБЛЬ

Мәскәүдә «Хыял» ансамбле эшли башлавын барлык татарлар шатланып каршы алган иде. Ансамбль биш ел эчендә илле шәһәрдә концертлар куйды. Озак та үтмәде, яшь композитор Рифгать Сәйфетдинов «Бәйрәм» ансамблен оештырды.

Әле яңа гына, зәңгәр экраннарда яңа артистлар җыелып, тагын бер татар ансамбле — «Алтын Ай»ны ачу турында сөйләделәр. Ансамбльнең житәкчесе — Равил Кузнецов. Равил болай ди: «Минем ансамблем чын мәгънәсендә халыкка хезмәт итәчәк. Концерт залларында халкыбызның моңнары белән хозурлансалар, җыелган акчаны үземнең туган ягымда — Түбән Новгород өлкәсендә төзеләчәк мәчет файдасына бирәчәкбез».

## ВӘГЪДӘ ИТӘЛӘР

Сентябрь ахырында КПССның Мәскәү шәһәр комитеты иҗтимагый-сәяси үзәгендә шәһәрдәге милли-мәдәни җәмгыятьләр вәкилләре Мәскәү Советының милли эшләр буенча комиссиясе әгъзалары белән очрашты. Ул бик кискен төстә барды. Эш шунда: милли ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә шәһәр житәкчеләре әлегә тиешле игътибар бирмиләр. Мәскәү Советындагы депутатлар арасында 90 проценты — урыс милләтеннән. Мәскәү телевидениесеннән чыгышларны буры урыс телендә генә ясап була.

«Туган тел» татар мәдәни җәмгыяте әгъзаларыннан Әгъдәс Борһанов, Урал Шәрипов, Нур Гарипов иптәшләр чыгыш ясап, җәмгыять алдында торган кыенлыкларга тукталдылар. «Туган тел» кебек милли җәмгыятьләр биналар өчен аренда хакы түләргә мәҗбүр, ә урыс оешмалары нишләптер аннан азат ителгән. Шәмси Әсәдуллаев йортын «Туган тел» җәмгыятенә бирү эше дә һаман сузыла. Эчке эшләр министрлыгының биредә урнашкан типографиясенә һәм курсларына башка урын табу турында кайгыртучы юк. Мәчеттә исә «Русские узоры» остаханәсе эшләп килә.

Депутатлар бу мәсьәләләрне хәл итәргә ышандырдылар.

## АЛДЫРСАГЫЗ — ОТАРСЫЗ

110100, г. Москва, ул. Космонавта Волкова, 19. Магазин «Книга-почтой». Әлеге адрес белән «Татарско-русский учебный словарь» дигән китапка заказлар килә башлады. Ул 1991 елда Мәскәүдәге «Рус теле» нәшриятында басылачак. Китап татар телен өйрәнүче руларга да, туган теленең нечкәлекләрен аңларга тырышучы татарларга да файдалы ярдәмлек булыр.

## ТАГЫН БЕР МӘЧЕТ

Татарстан Министрлар Советы Казанның Печән базары мәчетен (Киров һәм Париж Коммунасы урамнары чатында) дин тотучыларга кире кайтарып бирү турында карар кабул итте.

Мәчет мөтәвәллияте инде беренче утырышын үткәрде. Мөтәвәллият рәисе

итеп Мәрҗани мәчетенең имам-хатибы Габдулла әфәнде Галиуллин сайланды. Аның урынбасарлары — Госман Миннебаев һәм ТССРның халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова. Мөтәвәллият әлеге мәчетне яшьләр карамагына тапшырырга булды. Биредә киләчәктә татар яшьләре өчен мәдрәсә ачылачак, милли видеосалоннар һәм спорт төрләре буенча түгәрәкләр эшләячәк. Шулай ук типография оештыру да күздә тотыла.

## БӨТЕНРОССИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

26-28 сентябрьдә Казанда республикалар, өлкәләр һәм округлар архитектурасының милли үзенчәлекләре проблемаларына багышланган Бөтенроссия конференциясе булды. Анда Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Зиннур Мансуров чыгыш ясады.

## ШӘҺРИ БОЛГАРГА СӘЯХӘТ

11 августта Ульяновскидагы «Туган тел» җәмгыяте шәһри Болгарга сәяхәт оештырды. Барлыгы 84 кеше чал тарихыбыз төбәгендә булып, андагы истәлекһәйкәлләр белән таныштылар, изге чишмәләр суын татып карадылар, мәшһүр Рабига күлен күреп хозурландылар.

## ЯРДӘМ КИРӘК

Балтыйк буе республикаларында соңгы ике елда татар халкының милли хәрәкәте киң җәелде.

Латвиядә оешкан «Идел» татар җәмгыятенә төрле төбәкләрдән өч йөзгә якын милләттәшләребез берләшкән, ләкин әле бу республикада яшәүче биш мең татар халкының биш процентын гына тәшкил итә. Җәмгыятьнең максаты — Татарстаннан читтә яшәүче халкыбызны милли рухтан мәхрүм итмәү. Моның өчен җәмгыять тарафыннан шактый эшләр эшләнеп килә.

Ригада дингезчелек музеенда «Идел» дигән татар почмагы ачылды һәм Я. Райнис исемендәге 2 нче шәһәр китапханәсенең бер бүлмәсе татар халкына бирелде. Монда Гөлйөзем Сабитова хезмәт күрсәтә, ләкин аларга татар китаплары җитми.

Әгәр дә милләттәшләребез «Идел»гә ярдәм итәргә теләләр икән, алар түбәндәге адрес буенча яза алалар: 226017, Рига шәһәре, Лиелирбес урамы, 6 йорт, Я. Райнис исемендәге 2 нче шәһәр китапханәсе (татар секторы). Г. Сабитовага, тел. 27-03-42.

## КАЗАННЫ ЕРАКТА ТЫҢЛЫЙЛАР

Бер көнне Татарстан радиосына Вильнюс шәһәреннән: «Сезнең көндезге тапшыруыгызны Мәскәү аша тыңлыйбыз, әйбәт ишетелә»,— дип шалтыраттылар. Республикадан еракта яшәүче милләттәшләребезнең шулай Казанны тыңлый алуы — шатлыклы күренеш. Менә икенче ел инде Казан тапшырулары тулысынча шәһәр телефон каналы аша Мәскәүгә бирелә, анда көндез — 25, ә кич 17 метрлы кыска дулкында трансляцияләнә.

Хәзер Казанны Пермь шәһәре дә кабул итә һәм тапшыруларны 41 метрлы кыска дулкында эфирга тарата. Быел Куйбышев өлкәсе элемтәчеләре дә Татарстан радиосы программасын трансляцияли башладылар.

## ЯҢА ОРКЕСТР ОЕШТЫРЫЛА

Татарстан ССР Телевидение һәм радиотапшырулар комитеты каршында музыка кораллары оркестры оештырыла. Оркестрның дирижерына конкурс игълан ителгән иде. Конкурста алты белгеч катнашты. Комиссия өстенлекне Казан музыка училищесында укытучы булып эшләүче, белгече буенча дирижер Рөстәм Үтәйгә бирде. Ул җитәкләгән музыкаль коллектив чыгышлары тамашачыларга һәм радиотыңлаучыларга яхшы таныш.

Хәзер яңа оркестр музыкантларына конкурс игълан ителде.

Оркестр оештыруга кирәкле средствоны СССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитеты бирде.

## ҮЗЕ ҮЛГӘННӘН СОҢ

Күренекле татар язучысы Нәби Дәүли, Бөек Ватан сугышы елларында фашист тоткынлыгына эләгеп, концлагерьларда газап чигә. Әмма ул анда да гитлерчыларга каршы көрәшен дәвам итә.

Сугыштан соң совет рәсми органнары язучыга кырын карыйлар, аңа сатлык сугышчы дигән мәсхәрәле исем тагарга маташалар, китапларын чыгаруда аяк чалалар, хәтта берникадәр вакыт аны «Бөек Ватан сугышында катнашучы» дигән исемнән мәхрүм итеп, закон тарафыннан сугыш ветераннарына тиеш өстенлекләрдән файдаланырга ирек бирмиләр.

Нәби Дәүли 1989 елда вафат булды.

Күптән түгел язучының гаиләсенә Мәскәүдән бер хат килеп төште. Аны Сугыш ветераннары Совет комитеты (СКВВ) каршындагы халыкара комиссиядән язганнар. Анда, Нәбиулла Хәсәнович Дәүләтшинның (Нәби Дәүли), үлгәннән соң, Бухенвальд үлем лагерендагы яшерен антифашистик оешма эшендә катнашуы, кораллы восстание ясау өчен (соңыннан восстание лагерьны коткара) сугыш кораллары җыюда зур көч куюы өчен СКВВның «Антифашистик азатлык көрәшендә катнашучыга» медале белән бүләкләнүе турында хәбәр ителә.

## Кәрван-сарай

Халкыбызның милли архитектура үрнәкләре Казан яисә Татарстан белән генә чикләнми. Татар халкы кайда гына яшәмәсен рухи һәм матди мәдәниятның тонықланмас һәйкәлләрен иҗат иткән. Вакыт һөҗүме, 20—30 нчы еллар вәхшияте, соңгы дәвер башбаштаклыгы, җавапсызлык, ваемсызлык аларның инде шактыен харап иткән. Шулай да, бәхетебезгә, афәт шаукымы гаҗәеп корылмаларның һәммәсенә дә бер дәрәҗә шәфкатьсез кагылмаган. Фаҗига беркадәр аяган шундый милли архитектура һәйкәлләренең берсе итеп, шөбһәсез, Оренбург шәһәрендәге Кәрван-сарайны күрсәтергә мөмкин.

Беренче нәүбәттә Оренбургның элек-электән зур сәүдә юлына урнашуын искәртик. Шуңа күрә бирегә сәүдә эшләре вә башка мөһим йомыш белән килгән кешеләргә тукталу һәм ял итү өчен уңайлык тудыру бер зарурияткә әйләнгән. Шулай итеп, 1838 елда шәһәрдә зур Кәрван-сарай салына башлый һәм 1844 елда тәмам була. Ш. Мәрҗани үзенең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар...» китабында исә сарайның 1843 елда төзелә башлап, 1845 елда ачылуы турында яза. Корылма татар-мишәр һәм башкорт халкы хәрәҗәте һәм көче белән салынып, нигездә шул милләт вәкилләренә хезмәт итәргә тиеш була. Ул атлы юлаучылар кереп куна торган йорт хисапланып, мәчет, зур бакча, күп санлы ярдәмче каралты-бүлмәләрдән гыйбарәт бинаны тәшкил итә. Кәрван-сарай тугандаш милләт вәкилләренең икътисади һәм мәдәни мәнфәгатьләренә егерме еллар чамасы уңышлы хезмәт итеп килә. Әмма тиздән корылма аянычлы язмышка дучар була. 1865 елда җирле түрәләр бәрәкәтле традицияне бозып, Кәрван-сарайны хөкүмәт администрациясе карамагындагы рәсми учреждениегә әйләндерәләр.

Мөселманнар дистәләгән еллар буенча Кәрван-сарайны яңадан үзләренә кайтаруны таләп итәләр, икътисади һәм дини хакларын даулыйлар. Фәкать нәтиҗәсе булмый. Патша хөкүмәте дә, Вакытлы хөкүмәт тә халык гозеренә колак салмый.

Табигый ки, Октябрь революциясеннән соң бу мәсьәлә яңадан көн тәртибенә куела. Милләтләр халык комиссариаты (Наркомнац) коллегиясе әгъзасы Шәриф Манатов истәлекләренә караганда, алар Мулланур Вахитов белән берлектә Сөембикә манарасы һәм Кәрван-сарай мәсьәләсе буенча Ленин янына керәләр һәм бу эшкә аның фатихасын алалар. Совет хөкүмәте 1918 елның 27 гыйнварында Сөембикә манарасын һәм Кәрван-сарайны мөселманнарга кайтарып бирү турында карар кабул итә.

Әйткәнебезчә, Кәрван-сарай мәчет, ярдәмче бүлмә-хөҗрәләр, төрбәне хәтерләткән купшы бина һәм башка компонентлардан гыйбарәт тулы бер комплексны тәшкил итә. Мәчет турында сүз алып барып, Ш. Мәрҗани болай дип яза: «Бинасы гүзәл, төгәл. Янында Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләре үрнәгендә ике катлы бүлмәләрдән торган «Кәрван-сарай» исемле бер бинасы бар. Мәчет эченең әйләнәсендә алтын белән җомга сүрәсе язылган». Зәвык белән эшләнгән һәм истирахәт идеясенә буйсындырылган пулатларга XIX йөзнең беренче яртысындагы архитектура чалымнары хас. Мәчет манарасының мәһабәтлеге хәйран калырлык.

Кызганыч, бүген корылманың хәле аяныч. Мөселманнар аңа хуҗа булу гына түгел, әлеге тарихи һәм архитектура һәйкәленең эченә дә үтеп керә алмыйлар. Кәрван-сарайны «Оренбург-геология» берләшмәсе басып алган һәм әлегәчә биләп тора. Бабаларыбызның истирахәт хөҗрәләрендә лабораторияләр урнашкан, аларда төрле тозлар, минераль ашламалар, химикатлар, селте-серкәләр тулып ята. Бер өлеше планетарий вазифасын үти. Аяныч, Ленин күрсәтмәсе нигезендә 1918 елда кайтарылганнан соңында дин тотучы кан-кардәшләребездән янә тартып алынган мәһабәт бина әлегәчә үзенең чын ияләренә кабат кайтарып бирелгәне юк.

Равил ӘМИРХАН,
тарих фәннәре кандидаты

Рөстәм МӨХӘММӘТҖАН фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле әдип, Татарстан ССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ибраһим Салахов.

Рәмил ГАЛИ фотосы.

## Таныш булыгыз: «Татарстан» журналы

**«Мин кем?»** Бөек татар революционеры Мирсәет Солтангалиевның 1923 елда кулга алынгач Сталинга язылган публицистик хаты әнә шулай аталган. Ул яңа чыгачак «Татарстан» журналының январь санынннан дөнья күрә башлый. Журналда Солтангалиевның ВКП(б) Үзәк Контроль Комиссиясенә биргән җаваплары да басыла. Бу язмада Солтангалиевның Туран республикасы төзү турында фикерләре беренче тапкыр тулы ачыклана.

Журнал битләрендә сәяси-публицистик әсәрләргә зур урын биреләчәк. Җ. Вәлидинең «Идел буе татарларының белем дәрәҗәсе һәм мәдәнияты буенча очерк», В. Ирвингның «Мөхәммәт пәйгамбәрнең тормышы», Л. Гумилев, А. Куркчиның монголлар явына яңача карашлы «Кара риваять», Г. Мансуровның «Татар коткычылары», М. Татюнинның «Кызыл туган» (генсекка каршы заговор турында сәяси роман) дигән китаплардан кайбер өзекләр бастыру күздә тотыла. А. Литвинның «Кызыл мулла Ваисов ничек һәлак булган?», Ш. Рәкыйповның «Шәкүр карак», Б. Солтанбековның «Николай Ежов: сәяси биографиянең башы» документаль очерклары, Б. Урманченең «Соловкида татарлар» дигән истәлекләре дә кызыксыну уятыр.

Шулай ук республикадагы иҗтимагый-сәяси, милли хәрәкәтнең үсеше, Татарстан суверенитетын гамәлгә ашыру, базар экономикасына, Советларның тулы властьлыгына күчү темалары, сатира-юмор, файдалы киңәшләр дә журнал битләрендә киң урын алачак.

**Журналга язылу бәясе бер елга —6 сум, ярты елга —3 сум, өч айга — 1 сум 50 тиен. Журналның индексы: татар телендә — 73377, рус телендә — 73947.**

*Исегезгә төшерәбез: «Казан утлары»на һәм башка газета-журналларга ел дәвамында язылырга мөмкин.*

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА